
ISSN 0206-41



# Казан утлары

7.1989





**ТАТАРСТАН АССР**
**ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ**
**УКАЗЫ**

**Ә. Н. Еникеевка «Татарстан АССРның халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында**

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникеевка «Татарстан АССРның халык язучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

Татарстан АССР
Верховный Советы Президиумы
Председателе
Ш. МОСТАЕВ

Татарстан АССР
Верховный Советы Президиумы
Секретаре
Д. ДӘҮЛӘТШИНА

Казан, Кремль. 1989 ел, 24 март.

*(Ә. Еникинең «Халык язучысы» дигән исем алгандагы чыгышы журналның 184 битендә.)*



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1989

7

(801)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда:*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

М. ХӘБИБУЛЛИН. Илчегә үлем юк. *Роман* 3

Ш. МАННАПОВ. Үкенмәслек булсын. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . 113
К. СИБГАТУЛЛИН. Ашкын ат. *Шигырьләр* 116
Г. МОРАТОВ. Атом-кирмән. *Фрагментлар* 119
Ә. МӘХМҮДОВ. Мәхәббәт. *Шигырьләр* . . . 123

ПУБЛИЦИСТИКА

Г. ПАУШКИН. Идел бит ул, Идел бит ул! . . 125
Ф. ЛАТЫЙПОВ. «Якты юл»ның йөзе якты . . 128

БОРЫНГЫ БОЛГАРДА ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ 1100 ЕЛ

Җан тынычлыгы — ышануда *(Мөфти Тәлгат Таҗетдин белән язучы Салих Маннапов әңгәмәсе)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 137

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

А. СӘГАДИЕВ. Мәрҗани һәм гарәп фәлсәфәсе . . . . . . . . . . . . . . . 152
М. ӘХМӘТҖАНОВ, Н. ИЛЬЯСОВА. Шиһабетдин Мәрҗани шәҗәрәсе . . . . . . . . . 155
Р. ҮТӘБАЕВ. Габделгалләм Фәезхан угылы турында . . . . . . . . . . . . . 158
Ф. ИБРАҺИМОВА. Могтәбәр шәхес . . . . 162

С. АЛИШЕВ, М. МӨЛЕКОВ. Вәисевчеләр тарихыннан. . . . . . . . . . . . . . . 164

КИТАП КҮЗӘТҮ

Г. ЗӘЙНАШЕВА. Гөлләр елы . . . . . . . 170
Р. ШӘРИПОВ. Юлдагы табышлар. . . . . 172

СӘНГАТЬ

Г. СӨЛӘЙМАНОВА-ВӘЛИЕВА. Татар ювелир сәнгате: үткәне һәм бүгенгесе . . . . . . 174

Р. ИСХАКОВА-ВАМБА. **Сәйдәшев ничек язган?** . . . . . . . . . . . . . . . . 177

ТАТАР ХАЛЫК МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Р. ГЫЙЛӘҖЕВ. **Курай** . . . . . . . . . . 181

Ә. ЕНИКИ. **Тәвәккәллек телим** . . . . . . . 184

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

М. ГАЛИЕВ. **Ие шул...** *Хикәя* . . . . . . . 185

**Мәдәният тормышы көндәлеге** . . . . . . . 187

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . 190

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС
*Редколлегия*
ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: продолжение романа М. ХАБИБУЛЛИНА «После нет смерти». Стихи Ш. МАННАПОВА, К. СИБГАТУЛЛИНА, Г. МУРАТОВА, А. МАХМУДОВА.
«Публицистика»: очерки Г. ПАУШКИНА «Волга-матушка» и Ф. ЛАТЫПОВА «Якты юл» — значит, светлый путь».
К 1100-летию принятия ислама в Древнем Булгаре: беседа писателя С. МАННАПОВА с главой управления мусульман Европейской части СССР и Сибири муфтием ТАЛГАТОМ ТАЗЕТДИНОМ.
«К истории культуры»: статья А. САГАДИЕВА «Марджани и арабская философия»; генеалогическое дерево — родословная Ш. Марджани; статьи Р. УТЯБАЕВА и Ф. ИБРАГИМОВОЙ о татарских просветителях Г. Фаезханове и Х. Максуди.
С. АЛИШЕВ, М. МУЛЮКОВ. Из истории ваисовского движения.
«Библиография»: рецензируется книга поэтессы Э. Шарифуллиной.
«Искусство»: статьи Г. СУЛЕЙМАНОВОЙ-ВАЛИЕВОЙ «Татарское ювелирное искусство» и Р. ИСХАКОВОЙ-ВАМБА о творческих особенностях С. Сайдашева.
«Татарские народные музыкальные инструменты»: Р. ГИЛЯЗОВ. Курай.
«Желаю дерзания» — выступление народного писателя ТАССР А. ЕНИКИ.
«Юмор и сатира»: рассказ М. ГАЛИЕВА.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: вход в Казанский Кремль. XIX век. Репродукция с литографии английского художника Э. ТУРНЕРЕЛЛИ. Кожаная мозаика.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Р. Сөләйманова.

Производствога бирелде 04.05.1989 ел. Басарга кул куелды 28.06.1989 ел. ПФ 05232. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 78149. Заказ Б-219. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1989 ел.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Мөсәгыйть Хәбибуллин

# ИЛЧЕГӘ ҮЛЕМ ЮК

РОМАН

9



Ике бәхеткә бер афәт килер, ди. Сарайны тәмамлап җиткәндә оста Алпар кисәктән авырып китте, урынга калды. Сарай бизәү эшләрен төгәлләүне Сәлим хан Дәуранга йөкләде. Бер тапкыр хан кызы Назлыгөл бизәүчеләр янына килгәч, Дәуран юри чүкеч белән бармагына сукты. Кыз моны күрде дә «аһ!» итте, әтисенә нидер әйтергә ымсынды һәм, үз-үзен тыя алудан гаҗиз калып, оста егетнең бармагын кулъяулыгы белән кысып тотты. Кайнар кан чигүле ап-ак кулъяулыкны кызылга буяды.

— Авыртамы?

— Авыртмый, без күнеккән инде аңа,— диде егет һәм кызның күзләренә карады. Назлыгөлнең гүзәллеген ни белән дә чагыштырырга белмәде оста. Озын муен, ай сыман йөз, шомырт кара күзләр, күзләрендә энҗедәй нурлар биешә.

— Бәйлә инде, бәйлә!— диде Сәлим хан көлемсерәп. Көлемсерәве янә шуннан иде: кызында да, егеттә дә мәхәббәт ялкыны кабынып китүен күрде ул. Иллә моңа бер дә таң калмады. Ханбикә Зөбәрҗәт кебек, кызы Назлыгөлне оста егет яныннан алып китәргә дә ашыкмады. Чөнки ул белә иде: бу хәл озакка бармас, тиздән Назлыгөлне йә бирәр хан гаиләсенә, йә кенәз угланнарына соратырлар һәм Сәлим хан рәхәтләнеп кызын шуларның берсенә биреп җибәрер. Чит илгә кыз бирү кияү булдыру гына түгел, үзенә күрә сәясәт тә. Оста егеткәме моны аңларга?! Шул вакытта Сәлим хан бу егетнең Туйбикәдән тууын да исендә тота иде. Җан тартмаса, кан тартыр, диләр, хак әйткәннәр икән шул. Сәлим хан бер сүз белән: «Дәуран кызыма гашыйк»,— дигән фикергә килде.

Назлыгөл Дәуранның бармагын бәйләгәндә яралының күзләренә карап алды. Сабыр гына елмая иде егет. Тик бу елмаюда шундаен гаярьлек, тәкәбберлек, горурлык, бирелгәнлек күрде ки хан кызы, икенче мәлдә аучы каршына килеп чыккан җәйран кебек сискәнеп китте. Әмма бу сискәнү шундук узды, егетнең зәңгәр күзләрендә: «Мин сине яратам, мин сиңа, хан кызы, гашыйк»,— дигән сүзләр укыгандай итте, ул гы-

---

Дәвамы. Башы 6 санда.

намы, иреннәре дә: «Мин сине яратам, хан кызы, яратам, яратам!» — дип кабатлыйлар кебек тоелды. Хан кызы керфекләрен каккалап алды, аның нидер әйтәсе килде, мәгәр артында атасы басып тора иде.

— Йә, кузгалыйк, Назлыгөл,— диде Сәлим хан.

* * *

Шул көнне Туйбикә улының бәхет өләшкән җирдә булгандай елмая-көлә кайтып керүен күреп: «Аллага шөкер, кам юраган дөрес чыга, балам хан кызын күргән, бәлкем әле яратам дип тә әйткәндер»,— дип уйлады.

— Аны күрдеңме, балакай, бик шатсың?

— Кемне «аны», инәй?

— Хан кызы Назлыгөлне?

— Назлыгөлне!?— дип анасының күрәзәлегенә шаккатты Дәүран.— Әй, атасы белән килеп киткәннәр иде шул.

— Карале, эшең уңдымы, балакай? Атаң көнозын сине көтте, хәле авыр аның, юкка борчыма. Аның сиңа бер үтенече бар, сабыр гына тыңла, ышандыр. Өметләнеп торсын, өметле көн күрер, өметсез гүр керер, диләр.

«Килер бер көн,— дип уйлады Туйбикә.— Алпар да сәламәтләнер, хан кызы да сиңа ябышып чыгар. Чыкмый нишләсен, язмыштан узмыш юктыр. Кем белә, бәлкем әле Туйбикә Зөбәрҗәт кодачасы белән бер табында утырыр. Утырыр, утырмый кая барсын!»

* * *

Иллә барысы да Туйбикә уйлаганча булмады, хан сараен төзеп бетергән елны осталарның остасы Алпар урыныннан кузгала алмас булды.

Дәүран сарайга юнәлде. Ике көн көтте ул Сәлим ханның кабул итүен. Ахыр өченче көн дигәндә оста Дәүран хан тәхете каршына кыяркыймас кына килеп басты, тезләнеп баш иде.

— Әүвәл йомышың әйт,— диде Сәлим хан.

— Ханиям, атам каты авырып китте. Аның бер үтенече бар сезгә: ирек алып үләсе килә. Бирегез, ханиям, атама ирек!

— Китап, колларның урыннары җәннәттә булыр, диган. Нигә ул үлеп яткан адәмгә ирек?

— Ханиям, борын заманда берәүдән: «Бу дөньяда иң татлы нәрсә ни була?»— дип сораганнар. Ул: «Ирек!» дигән. Атамның ирекле булып үләсе килә, ханиям. Ул сезгә гомере буе тугрылыклы булган...

— Әүвәл терелсен,— диде Сәлим хан.— Үзе килер каршыма. Атаң ирек алса да, син минем колымдыр.

— Мин колыгыз, ханиям. Тик атама гына ирек бирегез.

— Түшәктә яткан кешегә мин ирек бирә алмыйм.

— Ирек бирегез атама, ханиям. Алдыгызга тезләнеп үтенәм. Гомерем буена тугрылыклы хезмәт итәрмен.

Оста Дәүран янә хан алдына тезләнде, башын түбән иде.

— Ярый, уйлап карармын,— диде хан, йомшара төшеп.

Дәүран ашыга-ашыга өйгә кайтты, атасына сөенче әйтәсе иткән иде, әмма ул минутларда осталарның остасы, Бөек Калада күп биналар күтәргән, ханга яңа сарай салган Алпар вафат иде инде. Атасының баш очында шәех Игәнәйнең мөриде ясин чыгып утыра, анасы ир-канаты күкрәгенә капланган да үксеп елый. Үлеп яткан атасын, үксеп елаган анасын күреп Дәүран баскан җирендә катты да калды. Ирек ала алмый үлеп китте атасы. Ул алай итмәс, коллыктан котылу җаен табар, атасы кебек, богауларын кочаклап үлмәс. Бу яшь колның атасы каршында биргән анты, әрнүле ярсуы иде.

* * *

Шуңа күрә, Шайтан каласын күтәрергә әмер алгач, атасын җирләгәннән соң җитдиләнеп киткән оста Дәүран Сәлим ханга бер шарт куйды:

— Ирек бирсәгез генә кирмәнкаланы салырга керешермен, ханиям,— диде.

Сәлим хан кулын аның иңенә салды да:

— Әүвәл эшең күрсәт, оста, хан вәгъдәсендә торыр,— диде.

Дәүран Шайтан кирмәнкаланы күтәргән ташчыларга да алдан ук әйтеп куйды: «Кирмәнне салгач, хан һәммәбезгә дә ирек ышандырды»,— диде.

Менә ни өчен меңгә якын ташчы, кирмән салынып беткәч, зар-интизар булып Сәлим ханны көтә башлады. Ниһаять, хан килде. Иң әүвәл ул кирмәннең тышкы диварларын карап чыкты, ташчылар эшеннән канәгать калып, асма күпер аша кирмән эченә узды, туктап, тимер белән ныгытылган капкаларга игътибар итте. Илла төп манарага кермәгән иде әле, әйтер сүзен әйтми торды.

Моңа кадәр дә ташчылар ирек дәгъвалап йөргән иде, Сәлим хан һәрчак кичектерә, юмалый килде. Ирек сорап-сорап та ала алмагач, ташчыларның күбесе чиргә китә — мәгәр анда да бал белән майда гына яшәми иде кеше. Яу чабулар була, яулар килә — күбесе орыш кырында ятып кала иде. Әмма шуңа да карамастан, ташчыларның беришесе хан гаскәренә языла иде.

Дәүран да Сәлим ханнан ирек сорады, әмма хан якын да килмәде. Мәгәр өметсез шайтан, диләр бит. Дәүран һәрчак ирек турында хыялланып яшәде. Һәм менә, ниһаять, бүген ул ирекне алыр, алмаган очракта— барысы да ташчылар белән сөйләшеп куелган иде.

Сәлим хан башта кечкенә манараларны карап чыкты, аннары борынгы бабайлардан калган, диварлары киңәйтелеп күтәртелгән күзәтү манарасына юнәлде. Дәүран аңа иярде. Керер алдыннан Сәлим хан югарыга карап алды — мәһабәт, дәһшәтле иде манара. Аның менәсе, эчен күрәсе, түбәсенә җитеп, тирә-юньгә күз саласы килә иде.

Төп манарага керер алдыннан оста Дәүран Сәлим ханны ишек төбендә туктатты.

— Ханиям, мин анда яшерен ишекләр куйдым, аулак бүлмәләр уйдым. Берәү белгәнне икенче белсә, өченчегә җитәр, анысы илгә таратыр, ди. Манарага үзегез генә керсәгез иде, ханиям.

Сәлим хан яшь остага сирпелеп алды һәм артыннан бер тотам калмый йөргән җансакчыларына: «Калыгыз!» дип кул селтәде.

Оста һәм аңа ияргән Сәлим хан манараның беренче катына керделәр. Дәүран кулына кисәү агачы алды, ут салды һәм ханга бирде. Хан бер сүз әйтмәде, өске катка менеп китте, әмма җаен тапмыйча, кире әйләнеп төште, шулай ук ашыга-кабалана ул түбәнгә юнәлде, бу юлы да кергән ишек янына килеп чыкты. Хан ачулы да, бераз гаҗәпләнгән дә кебек иде.

— Үзең күрсәт юлны!— диде хан.

— Әүвәл ирек вәгъдә ит, ханиям.

Сәлим хан Дәүранга бер сүз әйтмәде, ишекне ачып ике җансакчысын чакырып алды, тегеләр йөгереп килеп кергәч, ул останың йөзен яктыртырга кушты. Тәкәббер, горур рәвештә басып тора иде оста. Элек ул колларның йөзләрен дә бер-берсеннән рәтләп аермый иде, илла Дәүран башка иде, оста Алпар углы, Туйбикәсенең баласы. Хан шул берничә мизгел эчендә егет йөзендә Туйбикәсенең тәкәбберлеген, горурлыгын, атасы оста Алпарның кыюлыгын, тәвәккәллеген күрде. Алар ханнан тетрәп торалар, аның ихтыярына буйсыналар, дип уйлый иде, ә монда бөтенләй башка йөз — таләп итүче, шарт куючы. «Яшь, кыю, дорфа, ханның кодрәтен белми, камчысын, сөрсу-дымсу зинданын татыганы юк»,— дип уйлады Сәлим хан һәм җансакчыларына боерды:

— Каерып бәйләгез кулларын!

— Кагылмагыз миңа! Мин ирек дәгъва итәм сездән, хан! — диде Дәүран ханны янә гаҗәпкә калдырып.

— Тотып бәйләгез, тик үлтермәгез, оста миңа исән кирәк!

— Ашыкмагыз, ханиям. Җансакчыларыгыз монда кылыч белән керде, кылычтан китәрләр дә. Боермый торыгыз аларга!

— Син кем ул хәтле хан кадәр ханны өйрәтергә, эт ялаган нәмәстә! Колчуар!

— Мин — оста, ханиям. Алпар углы Дәүран булам. Җансакчыларыгызны миңа өстерганче белеп калсагыз иде. Күрәзә миңа: «Хан үлеме — синең үлемең, синең үлемең — хан үлеме», диде. Шуның өчен мин сездән андый боерыкны бирмәскә үтенер идем.

— Күрәзә?! — Сәлим хан каһкаһәләп көлде. — Мин сине үзең салган манараның очына астырачакмын. Күрәзә юрады, имеш... Нәрсә карап каттыгыз, бәйләгез кулларын каерып!

— Ханым, белеп калыгыз, мин — сезнең үлемегез. Мин сезне соңгы тапкыр кисәтәм. Ышанмасагыз ишекне ачтырып карагыз, кирмән эче тулы коралланган ташчылар. Сезнең йөз азатыгыз... Ирек вәгъдә итегез, ханиям, ирек! Бер миңа гына түгел, барыбызга да!

— Тотыгыз, бәйләгез, башкисәрне! — дип тамагы ертылырдай итеп кычкырды Сәлим хан.

Оста Дәүран азатларның берсенә, итек кунычыннан алып, хәнҗәр ыргытты. Дошманы йөзтүбән каплангач, аның кылычын кулга төшереп, икенче азатка селтәнде. Азат шәп орыша иде, Дәүран акрын гына артка чикте һәм, кисәк борылды да, каршы якка күчте, азат аның артыннан ташланды һәм бушлыкка туры килде, күрәсең, яман итеп кычкырып җибәрде дә юкка чыкты. Сәлим ханның тез буыннары бушап китте, ул ишеккә таба дивар буйлап шуыша башлады. Әмма оста Дәүран ишек янында иде инде, ул этеп җибәрүгә хан башы белән диварга килеп бәрелде һәм, ыңгырашып, артына утырды. Оста Дәүран ишекне тибеп ачты һәм ярсулы тавыш белән:

— Туганнар, коралга! — дип кычкырды.

Шуннан соң ишегалдында мәхшәр башланды. Кирмән эче умарта күче кебек гөжли, җан ачуы белән кычкырган тавышлар манарага кадәр ишетелә иде.

— Ханиям, — диде оста Дәүран. — Әле соң түгел. Ирек, ирек бирегез!

Сәлим хан торып басмакчы итте, әмма яңадан утырды. Оста Дәүран янә ишекне ачты, хан янына килде.

— Ирек, ирек ышандырыгыз, ханиям!

— Әйт әле, оста, төшемдәме, өнемдәме бу хәл?.. Мин кая...

Сәлим хан күтәрелеп түшәмгә карады, ишектән төшкән яктылык урталай ярып салган имән бүрәнәләргә төшкән, ишегалдында яман тавышлар яңгырый. Манара эчендә мәчеләр чинашкан, бүреләр улаган, козгыннар каркылдаган шау-шу тулгана. Әллә соң чынлап та Шайтан үзе торамы монда?.. Нигә килде ул бирегә?

— Ханиям, ирек вәгъдә итегез, ирек?!

Шул чак ишектә кораллы азатлар күренде, алар артыннан кулына кылыч тоткан әмир Хаҗи килеп керде, ул үзенә таба ыргылган оста Дәүранның кылычын бер селтәнүдә бәреп төшерде. Һәм азатларына:

— Бәйләгез кулларын! — дип боерды. Шуннан соң әмир Хаҗи дивар буенда утыручы атасы янына килде, күтәреп торгызды, күзләренә карады.

— Калдыр мине, углан, калдыр...— Шунда хан кисәк исенә килгәндәй булды: — Оста Дәүранны тотып бәйләгез. Үлтермәгез! Ул миңа исән хәлдә кирәк, исән. Ташчылар баш күтәрде. Барысын да елгага, елгага! Котыртучы оста Алпар углы Дәүранны сак астында Бөек Калага озаттыр!

Хан шулай диде дә ишеккә юнәлде. Шайтан каласындагы суеш-кырылышны Болгар халкының күбесе белми дә калыр, әмма бирегә булган хәлне Сәлим хан гомере буе онытмас, онытырлык итмәделәр аңа ташчылар бу хәлне.

Сәлим хан акрын гына ишегалдына чыкты һәм кадалып, суелып яткан мәетләр өстеннән, итеген канга буйый-буйый, абына-сөртенә, елга ягындагы капкага таба китте. Берәү дә аны тотмады, берәү дә ярдәм итәргә кыймады. Асылма күпергә житкәч, ханга атын китерделәр, жансакчысы атланырга ярдәм итте. Сәлим хан берәүгә дә күтәрелеп карамады, күпердән чыгуга, атын Бөек Кала тарафына борды. Аңа суеш-кырыштан исән калган ике жансакчысы иярде.

Әмир Хажи баш күтәргән ташчыларга жәзаны үзе бирде. Ул башта аларны бер бауга тезеп бәйләтте, аннары әсир ителгән ташчыларны текә яр буена илттерде. Шуннан беренче әсирнең башын кистереп, яр астына атырга боерды. Башы киселгән мәетләр, бер-берсен тарта-тарта, аска тәгәрәделәр, боларның барысын да кыю остага күрсәтеп торды әмир Хажи. Дәүран кычкырмады, йөрәгенә кан сауган хәлдә бары тик иреннәрен чәйнәде.

Аннары әмир Хажи йөзбаш азатына куллары артка каерып бәйләнгән Дәүранны атка атландырырга һәм Бөек Калага озатырга боерды.

Шайтан кирмәнен торгызырга киткән меңнән артык ташчыдан Бөек Калага бары тик бер Дәүранны алып кайттылар. Ир-канатларын каршы алырга чыккан хатын-кызга Сәлим хан:

— Ирләрегезне баш күтәрергә котыртучы оста Дәүран исән. Ә менә ирләрегез кайтмас, аларны котыртучы останы мин зинданда черетәчәкмен. Йөз азатым Шайтан каласында ятып калды. Котыртучыга каһәр!..— диде.

Хан азатлары оста Дәүранны ярсынган хатын-кызлардан көч-хәл белән аралап, зинданга илтеп яптылар. Сабый чактан ук төрле йолаларга, сихерче хикмәтләренә ихластан ышанган Сәлим хан, оста Дәүран гомере чынлап та үзенең гомере дип уйлап, аны күз карасы кебек сакларга кушты.

Гәрчә угланы мең азаты белән килеп, ханны үлем тырнагыннан алып калган булса да, ата кеше әмир Хажига Шайтан каласында булган хәл өчен ризасызлык белдерде.

Моннан соң шактый гомер узса да, Сәлим хан Дәүранны зинданнан чыгармады. Яңа кала салу мәсьәләсе кузгалгач, ул сарайга угланын, әмир Хажины чакыртты.

Ага Базарда күренгән һәр кам үзен нигәдер Болгар ата дип атый икән. Угланы килеп керүгә һәм хәл-әхвәлләр сорашуга, Сәлим хан аңа шул сорауны бирде.

— Белмим, атам,— диде әмир Хажи.— Күргәнем булмады. Бу хакта белсә, зинданында утыручы оста Дәүран беләдер.

— Миңа житкерделәр, углан, Шайтан каласы нигезенә Болгар ата үз-үзен корбан иткән, имеш. Хакмы шул, күргәнме берәрсе? Күрсә, исбатлый аламы?

— Кирмәнгә нигез казытучы оста Дәүран булды, атам.

— Борынгы бабаларыбыз яңа салынасы кала нигезенә хан нәселеннән углан корбан итә торган булганнар. Шунсыз кала дошман кулына күчә, имеш.

— Гафил булган бабаларыбыз, атам. Бу хакта шәех Игәнәй ишетсә килештермәс. Болгар камының үз теләге белән кирмән нигезенә кереп ятуына ышанмыйм, атам.

— Шәех Игәнәйдә минем эшем юк. Иллә бабаларыбызның яңа кала нигезенә угланнарын корбан итүләре булган хәлдер. Ә син мине шәех белән куркытасың,— дип канәгатьсезлек белдерде Сәлим хан.— Ярый, анысын куеп торыйк. Илче Садакны үлтерүчене тапмадыгыз, хәерле булсын. Ни син, ни вәзир ул хакта бер кәлимә сүз әйткәнегез юктыр. Хуш. Минем бүген менә нәрсәне беләсем килә, углан. Нигә манарага кергән бер кешене елгадан үле көе табып алалар? Кем эше бу? Кирмән синеке, углан. Ул серне үзең ачарга да тиеш. Нинди серле урын ул?.. Киңәшем шул булыр сиңа, углан: кайт та бер азатыңны Шайтан манарасына кертеп жибәр. Исән-имин әйләнеп чыкса, миңа китер, инде ул-бу була кала икән — кадерләп күмдер. Шуннан соң миңа килерсең.

— Барысын да сез дигәнчә итәрмен, атам.

— Кисәтәм, углан, бу хакта берәү дә белмәсен, бер җан иясе дә...

Сарайдан чыгуга, әмир Хаҗи Шайтан каласына чапты. Анда кунды да, көн тууга, әле яңарак кына кирмән сакларга килгән азатны үз янына чакыртып алды.

— Егетем, бүген кичен кояш баегач, Шайтан манарасына менәрсең. Бар нәрсәне дә карап, күреп чык. Әүвәл өскә күтәрел, Чулманнан түбән һәм югары якка хәрәкәт иткән корабларны күзәт. Санын яз. Ничә кораб түбән төшә, ничәсе югары күтәрелә.

Кичен әмир аны үзе Шайтан манарасына кертеп җибәрде. Янында басып торган юлдашына:

— Менә нәрсә, каравылбаш, азатның анда кереп китүе хакында син дә мин генә беләбез. Телең тешлә, озын тел белән бергә баш дигән нәрсәнең дә өзелеп очуы бар.

Каравылбаш барысын да аңлады, әмиргә сорау бирмәде.

Икенче көнне кояш чыгуга, яшь азатның үле гәүдәсен елга буеннан табып алып кайттылар. Суга батып үлүчеләр булгалап тора иде, шунлыктан бу хәлгә бик үк игътибар итмәде кирмән халкы.

Икенче көнне әмир Хаҗи Сарайга чапты һәм атасы Сәлим хан каршына килеп басуга:

— Атам, азатның гәүдәсен иртәнге якта елгадан табып алдылар,— диде.

Сәлим хан тәхетеннән торды, ишекле-түрле йөренергә кереште. Ул әлегә кадәр оста Дәүран белән ни кылырга белми иде, хәзер аны угланга бирергә дигән карарга килде. Кертеп җибәрсен Шайтан манарасына. Исән-имин чыга икән, димәк, манарада бернинди Шайтан юк. Инде аны да үлтерәләр икән... Йә хода, әйткән сүзе хак булып, оста гомере — минем гомер булса?..

— Син аны миңа бир, атам,— диде әмир Хаҗи, атасының кем турында уйлавын белгән сыман.

Сәлим хан гаҗәпләнгәндәй итте, әмма сер бирмәде.

— Халык ни әйтер?..

— Мин аңардан яңа кала салдырам, тиңе булмаган кала.

— Идел буенамы?

— Әйе.

— Әүвәл вәзир Исхак кайтсын, мин аны яңа калага урын сайларга җибәргән идем,— диде хан.

— Кайтсын,— диде әмир Хаҗи.— Ә останы алып китә торыйм. Сызымнарны эшли торыр.

— Алып китәрсең,— диде Сәлим хан.— Тик исеңдә тотсаң иде: кайда гына яшәмәсен, ниләр генә кылмасын, оста исән булырга тиеш...

— Башыннан бер чәче дә төшмәс, атам...

## 10

Бер атнадан соң хан зинданында ятучы оста Дәүранны ун азат белән Кашанга алып киттеләр. Сак астында алып кайтса да, әмир Хаҗи останы зинданга япмады, иртәгә үк яңа калага сызымнар сыза башлыйсың, дип, кайчандыр кәтиб Хафиз яшәгән бүлмәдән урын бирде.

— Әүвәл миңа яңа кала салынасы нигезне күрсәтегез, әмир,—диде оста Дәүран.

Әмир Хаҗи йөзбаш Бачманны чакыртып алды һәм останы аның белән яңа кала салынасы төбәккә җибәрде. Киткәндә әйтте:

— Оста сызымнарны Казан кирмәнендә эшләр, баһадир. Үзенә аерым өй бир, күзәт, тәрбияле тот, күз-колак бул.

— Баш өсте, әмир, миннән качмас, миннән качкан кеше тумаган әле,— диде мактана төшеп Бачман баһадир.

— Белеп торсаң иде, баһадир, оста Дәүран качкын түгел. Ул беркая да качмас, мин аңа ирек бирергә булдым,— диде әмир.

— Ә-ә,— дигән булды баһадир Бачман һәм юлга җыена башлады.

* * *

Бер айдан Казан кирмәненә килгән әмир Хаҗи, останың сызымнар сызып ятуын күрде дә, ышбу сәер кешедән канәгать калып, аны ни белән булса да куандырырга теләде.

— Яңа кала Бөек Каладан да мәһабәтрәк булса, икенче көнне үк ирек алырсың, оста.

— Атаң миңа ул иректе бирде инде, әмир. Рәхмәт аңа.

— Вәгъдәне синең акылына җиңеләя башлаган атам түгел, әмир Хаҗи бирә!

— Кем ул әмир Хаҗи? Сәлим хан угланымы?! Ул меңләгән ташчымны елгага башларын чабып ташлатты. Шул кеше ирек вәгъдә итәме миңа?!

— Дуамалга — йөгән, усалга битлек кигезерләр, ди, оста. Ирекне мин сиңа хәзер үк бирә алам.

— Әмир, мин коры сүзгә ышанмый башладым. Миңа ирек бирүең хакында мөһерең сугып, язу язып бир. Мин хан вә әмирләргә ышанмый башладым. Ирек бирсәгез, тирә-якта тиңе булмаган кала салынган булыр, әмир.

— Башта эшең күрсәт, оста, эшең. Шул булыр сиңа әмир Хаҗи сүзе!

Оста Дәүран аягүрә басты, әмиргә түбәнчелек белән баш иде. Хаҗи егеткә күзен текәп. «Үҗәт, кыю, тәвәккәл, матур кеше. Анам, Назлыгөл ышбу остага гашыйк, дип сөйләгән иде, булуы да бар»,— дигән нәтиҗәгә килде.

Дөнья гизгән бер дәрвиш Хаҗига хикмәтле бер сүз әйткән иде. «Һөнәр иясе буларак һәр оста — үз-үзенә хан, акыл иясе буларак без үз-үзебезгә хан». Дәшмә остага. Кешене изге юлга салу аны юлдан яздыруга караганда мең тапкыр кыенрактыр. Кем әйтмешли, шәүләне турайту өчен, иң әүвәл шәүлә ясаучыны турайтырга кирәк.

Ике көннән әмир Хаҗи оста Дәүранга ирек бирде. Мөһер әмирнеке иде. Оста Дәүран язуны кулына алды да бик озак битенә каплап торды, аннары дүрткә бөкләп түшенә — йөрәк янына тыкты, шуннан соң гына әмиргә баш иде.

— Оста, син — бүгеннән иректә кеше!

Тагын өч көннән яңа каланы салырга Бөек Каладан меңләгән ташчы килде. Аларны күргәч, оста Дәүранның йөрәге кысылып куйды. Берьюлы аларга да ирек сораган булса? Бирер идеме икән әмир ирекне? Сорар ул аны, тик бүген түгел. Башта эш күрсәтергә, ташчыларның мәхәббәтен яуларга кирәк...

## 11

Көтмәгәндә килеп кергән Бачман баһадирга әмир Хаҗи хәтта күтәрелеп тә карамады. Әмирнең тез өстендә кече углан утыра һәм углан атасына иҗекләп китап укый иде. Бала тотлыгып калганда ата кеше сукранып ала.

— Гали абыең синең кебек чакта шартлатып укый иде инде, син әле һаман әлпине таяк дип белмисең,— диде әмир Хаҗи һәм ишек төбендә басып торучы баһадирга күтәрелеп карады: — Йә, нинди йомыш китерде баһадирны?

Бачман баһадир авызын да ачарга өлгерми калды, углан кычкырып:

— Тимер тапкан тилмермәс, бала баккан көн күрмәс,—дип әйтеп салды.

— Хак әйткәннәр бабайлар,— диде әмир.— Бала баккан көн күрмәс. Әй, кем бар анда, алыгыз угланны! — Йә, нинди йомыш төште, баһадир, әмиреңә?

Бачман баһадир асраунын угланны алып чыгып киткәнен көтеп тор-

ды. Әмир Хажи аякларына кеш тиресеннән тегелгән юрганны япты.

— Әллә нигә тезләр өши, кыш көне ауда салкын тидердем, ахры. Чәчкә Ананы чакыртасы иде дә, һаман җае чыкмый тора. Кала ничек анда, баһадир, күтәреләме?

— Кала ай үсәсен көн үсә, әмир.

— Йә, йомышың әйт инде?

— Әмир, чынмыдыр, ялганмыдыр, сеңлем Зәйтүнә Шайтан каласына йөри икән дигән хәбәр җиткерделәр.

— Шуннан ни? Йөри бирсен...

— Әмир, кыз бала ул. Шайтан кирмәнендәге халыкны беләм мин.

Әмир Хажи көмеш кыңгыравын зеңләтте.

— Ни булды, әмирем? — дип Акбикә килеп керде. Шулай диде дә, ишек төбендә басып торучы баһадирны күреп, авызын яулык очы белән каплады.

— Зәйтүнә кая югала көнаралаш, бикә?

— Урманга җиләккә йөри ул, әмирем. Тубал-тубал җиләк җыеп алып кайта.

— Үзе генә чыгамы, сак беләнме?

— Әмирем, урманыңны Йомагыл тарханың саклый түгелме соң?

— Таптың урман саклый торган кеше, бикә. Кул астында алты-җиде азаты бар. Кая гына өлгерсен ул? Бикә, Зәйтүнәгә әйт, моннан соң ялгызы гына урманга йөрмәсен. Әнә, абыйсы борчылып килгән. Мин беләм, Зәйтүнә бернәрсәдән дә курыкмый, укны мәргәннәрдәй ата, кылыч белән дә ару селтәнә. Килешми кыз кешегә берүзенә урманга йөрү.

— Мин алай дип әйтмәс идем, әмирем, хатын-кыз гомер-гомергә урманга җиләккә йөргән.

— Җиләккә йөрсен, бер сүзем дә юктыр. Шайтан каласына нигә бара, менә шуны бел син, бикә. Кая соң әле үзе Зәйтүнә?

— Җиләккә дип чыгып киткән иде.

— Тагын җиләккә! Әйттем бит инде, килешми аңа япа-ялгызы җиләккә йөрү...

— Син алай ук кырт кистереп куйма әле, әмирем, ярамый дип. Беләсең килсә, борын заманда туран хатын-кызлары ирләр белән бер сафта орышканнар.

— Сеңлемне ук атарга, атта йөрергә үзем өйрәттем, әмир.

— Мин, әмирем, Зәйтүнәгә көнләшеп карыйм. Тели — урманга җиләккә бара, тели — Шайтан каласының могҗизаларын күреп кайта. Ул кирмәнгә менеп елгага бер баксаң — дөнья читләрен күргәндәй буласың, ди. Барасым килә шунда бер.

— Бик барасың килсә, бар, күр, кара. Әнә баһадир озата барыр, — диде әмир Хажи.

Акбикә баһадир ягына сирпелеп алды, тегенең ризалыгы йөзенә үк чыгуын күреп:

— Рәхмәт, әмирем, игелегеңне онытмам, — диде.

— Тик бүген түгел, бикә. Бүген анда мин үзем барып кайтам. Тимерче Әхмәт ямьсезләнә башлады. Алачыгына Яким сәүдәгәрнең энесе Апанайны алган, угланы Бәкерне урыс кызына өйләндермәкче, ди. Зинданга ябам мин аны бу эшләре расланса, ике дә уйламый ябам.

— Анасы синең эшең, әмирем, — диде бикә һәм баһадирга таба борылып: — Барыр көнемдә үзем хәбәр итәрмен, баһадир, — дип, чыгып китте.

— Әмир, саксыз юлга чыкмагыз, урманда ишләре белән Җик Мәргән йөри икән дигән сүз йөри.

— Булмас, ышанасым килми. Тубыкбай баһадир энесе Җик Мәргән — качкын? Бер күренмәсә, бер күренер иде, юк сүздер.

— Мин дә ышанып җитмим җитүен, әмир. Алай да саксыз юлга чыкмасагыз иде.

— Абыйсына муен бирмәгән Җик Мәргәнгә ни кирәк булды икән

безнең урманнарда? Мин кайчак шиккә калам, баһадир, кызларны да шулар урламый микән? Урлыйлар да Олуг Мөхәммәткә саталардыр. Атам, Олуг Мөхәммәт миннән үч ала башлады, дип бара. Булмас диясем килми, булуы да ихтимал. Тик кем хәбәр итеп торды микән аңа? Атам хәтта сәүдәгәрләрне дә читләтеп уздырды лабаса.

— Кызлар урлап сатарга Җик Мәргәннең башына тай типмәгән. Нигә аңа агасы белән булган бәхәсне безнең урманга китерергә? Иртәме, соңмы, без аны барыбер табарбыз. Җик Мәргәннең безнең урманнарда йөрүен Сәлим хан да беләдер ич? Миңа калса, Җик Мәргән моңа бармас, әмирем.

— Ярый, мин Шайтан каласына киттем, үзем белән тимерче Әхмәтне дә алырга исәп. Угылы ни кырып ята икән анда. Бусагабаш, атым иярлә — Җирән кашканы! Көнен әйләнергә исәбем.

* * *

Әмир Хажи Бачман баһадирның киңәшен тотмады, сакны гадәттәгечә алды — ун азат. Башта ул Әхмәт алачыгына юнәлде, тимерче Әхмәт Кашанда зур алачык тота һәм Бәкер ясаган чуенны тимер итеп, тирә-юньгә сатып ята иде. Шунысы да хак, аның янында һәрчак әмир кешеләре булыр, тимер сатудан җыелган акчаның күп өлеше әмир казнасына керер, иллә тимерче дә кул кушырып ятмый иде, күрәсең, баеган саен байый бара, хәзер әнә үзенә азатлар да тота башлаган, диделәр. Елдан-ел тимерче Әхмәтне күзәтү авырая, ул күрәләтә мөстәкыйльлеккә омтыла иде.

Тимерче алачыгына әмир Хажи ун азатын ияртеп килеп керде. Алачык капкасын әмиргә киереп торып ачтылар. Биредә меңнән артык тимерче эшли, арада бер генә кол да юк. Әхмәт һәммәсе белән дә уртак тел таба белә, барысына да, башкарган эшенә карап, хезмәт хакы түли икән. Әмир Хажи Әхмәт эшенә кысыласы килмәсә дә, кул астындагы кешенең узына башлавын, үзбаш хакимлек итүен ошатып җитмәде, тик аның тимерче белән бәхәскә керәсе килми иде, шул ук вакытта үзенең кем икәнен сиздерәсе дә килә иде.

Ишегалдына килеп керүгә, әмир туп-туры бер читтәрәк торучы тимерче останың өенә таба китте. Өй янына җитүгә, сикереп атыннан төште, болдырда басып торучы тимерчене күрмичә (дөресрәге — күрмәмешкә сабышып), өйгә узды.

— Көтмәгәндә-уйламаганда, әмирем! — диде аның артыннан ук ияреп кергән тимерче Әхмәт.

— Хәлләр иминме, оста?

— Аллага шөкер кылып яшим, әмирем. Сукранасым килми, сукранып та караган чакларым булды, сукыр бер тиен дә бирүче булмады.

— Чуен күп кайтамы алачыкка?

— Җитә болай. Рәхмәт углыма, тырыша.

— Ульдәмир кенәзенә ничә олау тимер озаттың инде?

— Тарханың язып бара, әмир. Беркөннәрне Яким сәүдәгәр килгән иде, үзендә шундый алачык салмакчы икән. Ярдәм итәрбез, дидем, безнең әмир киң күңелле кеше, булышыр, дидем. Сөенде. Акчаны мулдан түләде.

— Аннары синдә энесе Апанайны калдырып китте. Шулаймы?..

— Әйбәт кеше, барысы белән дә кызыксына. Тимерче булмакчы.

— Тагын нинди бүләкләр бирде Яким сәүдәгәр?

— Углыма каравыш кыз китергән, күрде дә гашыйк булды егетем. Өйләнәм дип җанга тия. Менә шуңа синнән фатиха алырым дигән идем әле, әмирем.

— Ходадан курыкмыйсыңмы соң? Шәех Игәнәй ни әйтер?

— Игәнәй — Бөек Калада, без — монда. Монда, әмирем, шәех тә сез, хан да. Ышанмасагыз, корьән тотып ант итәм, барысы да шулай, ди

Кайчан әмиребез акылы җиңеләя башлаган Сәлим ханга баш июдән туктар икән, диләр.

— Атасына хыянәт иткән бала игелек күрмәс, ди шәех Игәнәй. Оста, ни сөйләгәненне беләсеңме? Бу сүзләр атама җитсә?

— Кичер, әмирем, мин кеше әйткәнне генә әйттем, кеше сүзе кеше үтерер, диләр, хак икән.

— Ярый, күп тор ул хакта. Яким сәүдәгәр Шайтан каласына бармакчы иткән икән, тархан җибәрмәгән, хакмы шул?

— Сорады, иллә бер дә алай барам дип бәргәләнмәде, әмирем, языклы буласым килми.

— Каравыш кызны Шайтан каласына үзең илттеңме, углың кайтып алдымы?

— Үзем илттем, әмирем. Сылу кыз. Мәгәр, әмирем, минем малай да төшеп калганнардан түгел: кыз, углымны күрде дә, комачтай кызарды. Көтмәгән икән шушындый сөлек кебек булыр дип углымны. Ә ул үзе бер кашык белән кабып йотарлык. Кавыштылар, каршы килмәдем. Яким сәүдәгәр дә канәгать китте. Кимсетәсем килмәде, сер булса да әйтим инде, ул кыз аның асраудан туган үз кызы икән, әмирем. Менә шундый хәлләр безнең бүгенгә көндә. Әнә шулай Яким бай сәүдәгәр белән кардәшләшеп киттек әле. Никахны укытыр, саф мәхәббәткә никах ни ул, аңа үлем дә куркыныч түгел. Кирәк булса, чиркәвенә дә барырлар, саф мәхәббәт өчен бер чиркәүгә кереп чыгу ни ул — күңел ачу гына. Кызның да күңеле була, егетнең дә.

Ул арада озын өстәлгә ике савыт әче бал китереп куйдылар. Әмир Хаҗи эчеп куйды да мыекларын сыпырып:

— Һә, һә, балыңны кем ясый, бигрәк усал, бигрәк татлы? — дип сорады.

— Чирмеш карчыгы. Алтын куллы карчык, белмәгәне юк.

— Оста, бик күп яңалыклар сөйләдең, рәхмәт сиңа. Иллә гөнаһы булса булыр, бүген сине мин зинданга ябам.

— Йә раббым, әмирем. Сезнең алда гына түгел, аллаһы тәгалә алдында да гөнаһым юктыр. Һич югы, сәбәбен әйтер идегез?...

— Мин моны чуен кою сере Яким сәүдәгәр кулына күчмәсен дип эшлим, оста. Ишетсеннәр, шаукымы Ульдәмиргә кадәр җитсен... Ә хәзер, — диде әмир Хаҗи һәм алдындагы бал савытын этеп җибәрде. — Җыен, Шайтан каласына барып кайтабыз.

— Баш өсте, әмирем.

Әмир Хаҗи ишеккә таба китте, оста янына ярдәмчесе килде, сак кына иңенә кагылды.

— Йөзбаш керсен, тиз йөр! — диде оста Әхмәт җитди төстә.

— Мин монда, иям! — дип килеп керде йөзбаш.

— Әмир мине Шайтан каласына алып китә. Азатларың ал да, бераз кала төшеп, артыбыздан бар!

Аннары Әхмәт өс киемнәрен алыштырды, болдыр янына китергән атка атланды да, чаптырып, капка төбендә торган әмир Хаҗига таба китте. Аты тоягыннан чәчрәгән балчыкларга караганда, оста гаять тә ачулы, гасабилана, иллә бер дә куркып юлга чыкмый кебек иде.

* * *

Әхмәт әмир Хаҗины каланы чыкканда гына куып җитте.

— Һәй, әмир, янәшәңнән урын бир! — дип кычкырды ул килеп җитәр-җитмәс. Әмир янәшәсендәге ике азат читкә каерылдылар, оста Әхмәт атын тыя төште, янәшә атлатып китте.

Әмир Хаҗи, остаңың бу кыланышына гаҗәпләнүен сиздереп, артына әйләнеп карады. Оста артыннан бераз кала төшеп, йөз азат килә иде.

— Кемнәр болар, чирүеңме, оста?

— Юк, сезнекеләр, әмирем. Ләкин алар бүген мине сакларга булды.

Кем ул азат? Кем күбрәк түли, шуны саклаучыдыр, әмирем. Тимерчеләре өчен борчылуларыдыр, әмир аны зинданга ябам дип янаганны ишеткәннәрдер, мөгаен.

— Аңламадың булып чыга, оста. Минем синең хакта кайгыртуым иде.

— Оста Дәүранны да, үзе турында кайгыртып, хан зинданыннан коткардыгызмы, әмир?

— Оста Дәүран ирекне алтын бәһасенә сатып алды дияргә була, — диде Хажи, атын куалый төшеп.

— Ирекне сатып алмыйлар, ирекне яулыйлар, әмирем.

— Ирекне әле ничек кенә сатып алалар, оста. Ибраһим хан Бөек Каланы саклап калу хакына Ульдәмир кенәзе Юрий Долгорукка өч мең алтын һәм кенәзнең угланына сеңлесен биреп котыла.

— Үткән эшкә салават, әмирем. Мине бүгенгесе борчый. Шайтан каласына нигә барасыз, әмирем?

Әмир Хажи җавап бирмәде, атына камчы белән сукты, туры айгыр куш аяклап алга ыргылды, әлә оста Әхмәт әмирнең атын бик тиз куып җитте һәм йөгәненә ябышты.

— Тпру-у, ашыкма, әмирем. Вәгъдәгезне бирегез, тимәссезме углыма?

— Мин углыңны яман эштән коткарырга дип барам, оста.

— Шайтан манарасына ябыпмы, әмирем? Аннан берәүнең дә исән чыкканы булмады әле. Яшь азатны да кертеп җибәрдегез. Аңа яшисе дә яшисе иде әле, әмирем.

Хажиның ачуы килә башлады, ул янә арттан бастырып килгән оста азатларына карап алды.

Алда Шайтан каласы күренде. Атларын куалый торгач, килеп тә җиттеләр.

— Әй, кем бар анда! Асма күперне төшерегез, капкаларны ачыгыз! — дип кычкырды әмир Хажи.

Аны таныдылар, асма күпер шагырдап төште, капкаларны ачып җибәрделәр. Әмир, атын куалый төшеп, алдан кузгалды, каравыл башына житкәч, ул:

— Минем азатларым кергәч тә капкаларны яп! — дип боерды.

Кирмәндәгеләр шулай иттеләр дә. Әмир һәм оста, янә ун азат үткәч, капкаларны яптылар, асма күперне күтәрделәр. Әмир Хажи атыннан төште, каравылбашка тезгенен ташлап, түр өйгә таба китте.

— Йөзбаш, Бәкер оланны өйгә дәш!

Оста Әхмәт өйгә керергә иткән иде, аның юлына кирмән азаты аркылы төште. Оста аны селтәп җибәрде, ике сикерүдә болдырга менде, анда басып торган сакчыны төртеп төшерде дә өйгә кереп китте. Ишекне каерып ачты, гаҗәп ки, әмир Хажи аның өйгә килеп керүенә бер дә аптырамады, каршындагы түмәрдән урын күрсәтте. Ул арада тимерче егет килеп керде, әмиргә сәлам юллады.

— Утыр, каршыма, Бәкер, — диде әмир Хажи тыныч кына.

— Саумы, атам, исән-сау килеп җиттеңме! — диде чуен коючы яшь оста.

— Атаң исән-сау, мәнә хәлең белергә килде. Ичмасам, сыйлар идең, авызым кипте, — диде Әхмәт, әмиргә карамый гына көлемсерәп. — Иябез әмирнең сине күрәсе килде, углым. Ни кырып ята анда чуен коючы егет, ди.

— Чуен коючы егеткә сорауларны үзем бирермен, ата кеше.

— Шулай итәрсез, әмирем. Мәгәр онытмасагыз иде, чуенны үзбаш коя башласа да, тимерчелеккә аны үзем өйрәттем.

— Углың өчен син генә түгел, оста, мин дә горурланам. Рәхмәт аңа, чуенны әйбәт коя. Әйт әле, егет, чуен кою ысулын тагын берәр кеше беләме, әллә булмаса бер син генә сәләтлеме ул эшкә?

— Чуенны коючылар булыр, әмирем. Тик эш бер коярга өйрәнүдә

генә түгел, мич сала белүдә, эремә таш сайлый белүдә, күмер сайлауда, ниһаять, күзәтеп эретүдә. Чуен кою ипи пешерү белән бердер, әчеп китсә дә начар, төче булса да әйбәт түгел.

— Хәбәрең өчен рәхмәт, егет. Инде әйт, өйләндеңме әле?

— Өйләнергә йөрим, әмирем. Яраткан кызым бар.

— Яким сәүдәгәр кызымы?

— Әйе, әмирем. Мин аны ятатам, ул — мине.

— Аты ничек инде ул гүзәл кызның?

— Аты Дүнә, әмирем. Дөньяда бик күп кадерле вә бәһале әйберләр була, тик минем өчен Дүнәдән дә кадерле бернәрсә дә юктыр. Аның өчен мин утка да, суга да керергә әзермен.

— Белеп торсаң иде, егет. Ышбу якты дөньяда иң-иң кадерле вә бәһале нәрсә ирек вә туган илдер.

Әмир Хажи күтәрелде дә чыгып китте. Оста Әхмәт әмир артыннан ташланды. Ата кеше углы Бәкерне тәгаен танымады. Әмир кадәр әмир белән ни тамаша сөйләшә бит. Һәй, бу яшьләрне! Тик кенә утырырга бит! Әллә соң мәхәббәт сукырайтты, чукраклаттымы кешене? Ичмасам, атасына күз ташласын иде. Йә ходa, бу ни инде тагын?! Ахырзаман, ахырзаман киләдер, бер дә бүтән түгел, шул юлга чыккандыр.

Оста Әхмәт әмирне болдырдан төшкәч куып житте.

— Әмирем, кичерә күр углымны. Үе яманлыкта түгел, күңеле ашкынулыдыр. Чуен кою серен ул берәүгә дә әйтмәде, берәү дә белми ул серне...

Оста Әхмәт әмир каршына чыкты, алдына тезләнде.

— Тор, оста! — диде әмир Хажи. — Углың бик әйбәт сөйләште. Бераз уйлап кара әле, оста. Яким сәүдәгәр ул гүзәл кызны нигә дип Бәкергә бирде дип беләсең? Дәшмисең! Углың кирәк аңа, әнә шул Шайтан каласында чуен коеп ятучы углың. Гашыйк кеше — диванага хас кеше диләр. Кирмәнне минем азатларым саклый, углыңны үзең сакла, оста. Углың Бәкер Күчтем сәүдәгәр кызына ияреп китә кала икән, нәсел-нәсәбеңне корытырмын, алачыгыңны жир белән тигезләтермен.

— Әмирем, мин бары тик кылыч-корал ясаучы, әмма сакчы түгел, кая ул углымны, алачыгымны да караштырып бетерә алмыйм.

— Болгардан Ульдәмиргә ары китеп Наугурыдка сузылган сәүдә юлларын кем саклый, оста?.. Углың Ульдәмиргә китә кала икән, икенче көнне үк башы сөңге очында булыр. Мин сине кисәттем, оста, калганын үзең кара. Ә хәзер минем белән Кашанга кайтырсың.

— Кайтырмын,кайтырмын, әмирем.

Әмиргә атын китерделәр, ул атына жилле генә сикереп атланды да ачык капкага юнәлде. Оста Әхмәт йөгереп аты янына килде, болдырга чыккан углына кул гына селтәде дә әмир артыннан куалап алып китте. Әмирне ул кирмәнне чыгып, берара юл үткәч кенә куып житте.

— Синдә бүген йөз азат, — диде әмир аңа. — Син мине үтерә аласың, оста. Мәгәр мин сиңа андый ахмаклык эшләмәскә киңәш бирер идем. Вакытлы көчең белән ирәймә.

Кашан каласының басу капкасын узганда оста Әхмәт әмир Хажи атыннан жир буе ара артта калган иде инде. Калага керәрәк, әмир Хажи аны көтеп алды.

— Әмирем, туры зинданыгызга барыйммы, өйгә кайтып хатынымны күреп килимме? — диде оста Әхмәт һәм, атыннан төшеп, чатан-потан атлап китте.

— Туры зинданга баруың әйбәтрәк булыр, оста. Инде әйт, Яким Күчтем сәүдәгәр энесе сиңа ник килде дип беләсең?

— Һөнәр алырга дип беләм, әмир.

— Һөнәрне бүтән жирдә дә алыр иде ул, оста. Яким сәүдәгәр энесе Апанайга чуен кою сере кирәк. Шул нәрсә ачыклану белән сине зинданнан чыгарырмын, оста.

Ул арада останы азатлары куып житте.

— Тукталмагыз, алачыкка кайтыгыз. Мин әмирем янында калып торам. Иншалла, ике-өч көннән әйләнеп тә кайтырмын. Атымны да алып китегез, — диде оста.

Оста Әхмәт азатларына тегеләр күздән югалганчы карап торды. Аннары акрын гына әмир Хаҗи йортына таба кузгалды. Йортка кергәч, әмир кул чапты, шундук ике азат пәйда булды.

— Останы зинданга ябыгыз!

— Әмирем, мин сездән моны көтмәгән идем, — диде Әхмәт артына каерылып.

— Көтәргә иден, көтәргә иден. Җик Мәргән кай тарафта качкынлык кыла? Илче Садакны үлтерүче кем? Шайтан манарасындагы яшерен юлларны аңа кем күрсәтте? Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә кем янына йөри? Белмисеңме, оста?... Белмисең. Бәлкем зинданда исеңә төшәр.

— Ялган, әмирем, бинахакка рәнҗетәсез мине, бинахакка.

— Алып китегез! — дип боерды әмир азатларына.

## 12

Оста Әхмәт Кашан каласында хөрмәткә ия кешеләрнең берсе иде. Соңгы елларда ул Владимир сәүдәгәре Кучтем белән тыгыз элемтәгә керде. Остага Кучтем сәүдәгәрнең киң күңеллелеге ошады, эчкерсезлеге, акчаны мулдан түләве. Әйе, алтын кулга кергәндә тимер кызгана буламы, корал-кылычны күп озатты шул. Яхшы кешегә мал кызгана буламы оста Әхмәт. Башына бер тапкыр да, ичмасам, Кучтем сәүдәгәр аңардан чуен кою серен белергә тели, дигән уй килмәде. Илче Садакны кем үтерүен дә белми, аннары кызларны кем урлавын да белми иде. Ә менә әмир Хаҗи аңардан шикләнә. Дәүләт серен сатар дип курка. Курка гынамы, әллә хыянәткә аның да катнашы бар дип уйлавымы? Румнар рум уты серен сигез йөз ел буена саклый, табгачлар кәгазь ясау серен биш йөз елга якын сер итеп тота. Болгар чуен кою серен ничә ел саклый алыр?

Оста Әхмәт зинданның сәке сәндерәсенә менеп ятты. Әйе, ул нәрсәнедер уйлап житкермәде, күрәсең. Ә бит барысы да көйле бара кебек иде. Уйланырлык иде Кашан остасы Әхмәткә. Әмир Хаҗи, илче Садак Бәкер артыннан килгән, дип расларга маташа. Хуш, шулай да булсын, ди. Алып та китсеннәр ди егетне. Шуннан ни?.. Оста аларга чуен кою серен ачармы? Ачмас, Әхмәт үз углын белә, муенына бау ташласалар да, ачмас... Әйе, бау ташласалар да. Ә менә Яким сәүдәгәр кызы кочагына керсә? Йә хода, шулай булып куюы да бар икән бит! Углы кызны ярата, ярата гына аз, ул аның өчен...

Оста Әхмәт бик озак вак имәннәрдән тезеп ябылган түшәмгә карап ятты. Бүрәнә араларына үрмәкүч тозак корган, ә үзе бер читкәрәк поскан да корбанын көтеп тора. Пәрәвезен зур итеп, божралап үргән үрмәкүч... Әллә соң Сәлим хан куштымы угланы әмир Хаҗига аны зинданга ябарга? Моңа кадәр әмир Хаҗи оста Әхмәткә үзенә ышанган кебек ышана иде ләбаса!

Әхмәт оста чапанын салды, баш очына кыстырды. Кичә аңа Яким Кучтем сәүдәгәр энесе Апанай хикмәтле бер сүз әйтте. Имеш, ханнар белән кенәзләргә беркайчан да ышанма. Аның үзен кенәз Китан әзәрлекли башлаган, шуннан бирегә качып китәргә мәҗбүр булган, имеш. Апанайга ышансаң, ул кенәзгә: «Безгә Болгар белән орышырга түгел, сәүдә итәргә кирәк», — дип әйтеп әйткән, имеш. Барысы да хак булса, хикмәтле сүз әйткән Апанай кенәз Китанга. Менә замана, Болгардан Владимиргә осталар күчә, Владимирдән сәүдәгәрләр Болгарга кача.

Оста Әхмәтнең уйланып ята-ята тәмам башы катты, иллә үзалдына куйган сорауларга җавап таба алмады.

Ул гаепле түгел. Әмир Хаҗи каршында аның берниндә дә гаебе юктыр. Ачсыннар ишекне, чыгарсыннар аны биредән. Аның әмир белән

аңлашасы килә. Нинди хата кылды ул? Кемне рәнжетте, кемгә хыянәт итте? Кемгә кул салды, кемне ханга каршы котыртты!?

Оста Әхмәт сикереп сәндерәдән төште, ике куллап ишекне дөңгечләргә кереште.

— Кем бар анда, сакчы, ач дим, ач! Юкса, ишегеңне ватам!

Берәү дә аны ишетмәде, берәү дә килмәде, берәү дә ишек төюенә колак салмады. Оста Әхмәт тәмам хәлдән тайды, ахырда җир идәнгә утырды. Аның янына шундук озын, шома койрыклы, борыны очлаеп килгән, күрер күзгә шыксыз, җирәнгеч күсе йөгереп килде. Оста Әхмәт, коты алынып, сикереп торды һәм җан көче белән күсегә тибеп җибәрде. Күсе таш диварга очып барып бәрелде, кан чәчрәде, ул да түгел, почмактагы тишекләрдән, берсе артыннан берсе йөгерешеп, күселәр чыкты; алар, чинаша-чинаша, кан эчендә яткан ишләрен өзгәләргә тотындылар һәм күз ачып йомганчы юк та иттеләр. Моны күреп, оста Әхмәтнең коты катты, аркасы чымыр-чымыр килде, бөтен тәне калтырана башлады. Ул ике сикерүдә сәндерәдәге чапанын эләктереп алды да, иң өскә менеп ятты. Мәгәр тынычлану килмәде, киресенчә, теше-тешкә тими шыкылдарга тотынды. Кинәт ул сәндерәдән сикереп төште, йөрәк өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде һәм, тамагы чатнап киткәндәй, тынып калды. Ахырда җан ачуы белән янә ишекне төя башлады.

Ишекне ачканда оста Әхмәт хәлсезләнеп җирдә ята, канаган куллары янында күселәр кайнаша иде. Аңын җуяр дәрәҗәгә җиткән оста һаман бер сүзне кабатлый иде:

— Ачыгыз, ачыгыз, ачыгыз...

## 13

Әмир Хаҗи һәрчак үзен атасы Сәлим ханнан да, энесе Илһамнан да өстен күреп яшәде. Башта ул Болгар тәхетенә утыру турында хыялланды, атасы ике туган арасындагы бәхәсне икесен ике калага әмир итеп хәл иткәч, үз кул астындагы калаларны ныгытырга кереште. Шулай Шайтан кала барлыкка килде, шулай ук яңа Казан кирмәнен салып яталар. Аңарда иң яхшы урманнар, иң уңдырышлы басулар, су юллары, моның өстенә Төн илләренә үткән һәр сәүдәгәр аның казнасына җыем калдыра иде. Бермәлне әмир Хаҗи Болгарның башкаласын Кашанга күчерергә маташып йөргән иде, барып чыкмады, хәзер бөтен өметен яңа калага юнәлтте. Каланың исеме Казан булыр, кирмәне күчкәч, исеме дә күчәр. Моңа берәү дә каршы килмәс. Хәер, яңа каланы халык күптән Казан дип йөри инде. Кала чынлап та мәһабәт булыр. Моның өчен ул оста Дәүранның кулын чиште — теләсә нишләсен, ирек аңа, мәгәр кала бер дә Бөек Каладан ким булмасын.

Ә инде оста Әхмәт мәсьәләсенә килгәндә, ул аны болай гына, бераз куркытыр өчен генә зинданга япты. Һәм хак булып чыкты. Оста аның тирәсендә тәгәрәп йөри, углын каравыллый. Оста Әхмәт аңа кирәк иде, ул аны беркайчан да күздән яздырмады. Кем Болгарның коралын камилләштерә? Оста Әхмәт. Кем әмир казнасына иң күп җыемны кертә? Оста Әхмәт. Әмир Хаҗи үзе дә аңа бик күп изгелек кылды. Җир бирде, йорт салдырды, алачык ачтырды. Хәтта колларын тамакка эшләтүдән түләүле хезмәткә күчергәндә дә дәшмәде. Оста Әхмәт тимерчеләрен коллыктан азат итеп, аларга акча түли башлап, бермә-бер отты, дисәң, бер дә ялган булмастыр. Әмир Хаҗиның баеп китүе дә шуннан башланды. Оста Әхмәтнең чуен коя башлавын да шуннан күрде әмир Хаҗи. Мәгәр артык мөстәкыйльлеккә омтылуы, җитмәсә, үзенә азатлар тотуы, аның янына Яким Күчтем сәүдәгәр угланнары белән элемтәгә керүе әмиргә ошап җитмәде. Шуңа бераз куркытып алуы иде. Хак анысы, Кашанга Бөек Кала һөнәрчеләре күчеп килә башлагач, атасы Сәлим хан да аны кисәткәндәй иткән иде. Имеш, нигә качкан колларны үзенә җыеп,

аларга ирек бирәсең? Һәм бу хакта олуг хан бөтен мәҗлес алдында кисәтте аны. Яшерми әмир Хаҗи, Бөек Каладагы тимерчеләрне, тире иләүчеләрне, чүлмәкчеләрне Кашанга күчәргә котыртып йөрде, әмма берәүсенең дә кулыннан тотып алып китмәде. Үзләре килделәр, үзләре Бөек Кала иярләреннән качтылар. Әмир Хаҗи аларны үз каласына урнаштырды. Җитмәсә, Бөек Кала кәрвансараена тиңнәрлек кәрвансарай салдырды, әүвәл башта җыемны бермә-бер ким алды, шуның белән күп кенә сәүдәгәрләрне үз каласына тартты. Кашанга кәрвансарай салынганнан соң күп кенә сәүдәгәрләр Бөек Калада туктамас булдылар, туры Кашанга юнәлделәр. Әмир Хаҗи Табгач тарафыннан килгән сәүдәгәрләр өчен аерым кәрвансарай салдырды, сәүдәгәрләрне Кашанга җибәрсен өчен, Ефәк юлын саклаучы баһадир Тубыкбайга өстәмә хак ышандырды. Тубыкбай белән тату яшәү тимерче Әхмәт өчен дә файдалы иде. Бәкер шул тарафлардан эремә таш алып кайта, ә ул җирләр Тубыкбай баһадир кул астында. Уралып-ишелеп торган тауларда эремә ташның исәбе-хисабы юк икән. Тубыкбайга ни, ул эремә ташның кадерен беләме, аңа аяк астындагы таш та таш, эремә таш та таш. Оста Әхмәт углы Бәкер эремә таштан чуен коярга өйрәнде. Бу хакта берәү дә белми иде, хәзер әнә барысының да күзе кыза башлаган ул чуенга. Чуен. Ни ул? Үзе тимер дә түгел, шул ук вакытта сызгыра торган туплар, чукмарбашлар да коеп була. Моның өчен Бәкерне күз карасы кебек сакларга кирәк. Чуен ул Болгарның куәте, байлыгы, тынычлыгы, ниһаять, кулында кылычы булган кешегә хәнҗәр тотып бармыйлар.

Бик күп уйлана торгач, әмир Хаҗи янә бер тапкыр Шайтан каласына барып кайтырга булды. Бу юлы ул үзе белән бер азатын да алмады. Кирмәнгә ялгызы гына барып кайтасы килә иде әмирнең.

Кашаннан чыгуга, әмир Хаҗи атын, җилне куып җитәргә теләгәндәй, куалап алып китте. Саф һава, тыгыз җил аның кәефен күтәрә төште. Кайчан шулай җан-фәрман атын чаптырып Кашаннан чыгып киткән иде әле ул? Әйе, Гали угланның Яңа кала нигезенә корбан ителүе турында ишеткәч. Әй чабып та караган иде, әйтерсең, угланы җанын алган газраилне куып бара иде. Ул көнне яңа кала нигезенә эңгер иңгәч кенә килеп җитте. Һәм Чияле тау түбәсендә чынлап та угланның каберен күреп, кабергә капланып йөрәк каны белән елаган иде. Шунда ул ант эчте. Гали углан истәлегенә булачак каланы тиңе булмаган итеп салдырырга. Аның угланы кала нигезенә корбан ителгән икән, каласы да аныкы булыр — әмир Хаҗиныкы. Углан хакында онытырга теләп йөрде, иллә шул якларга барып чыктымы, янә йөрәгенә кан сауды. Шуның өчен әмир Хаҗи анда бик сирәк барды, килсә дә озак тормады, тизрәк китү җаен карады. Гаебем юк дип барса да, әмир Хаҗи бу хәл өчен атасын кичермәде, атасын яклаучы Камайны күралмас хәлгә җитте.

Әмир Хаҗи Чулман елгасы ярына килеп туктагач кына тезгенен бушатты, атыннан төште, җәяүләп яр буйлап китте. Алда — Шайтан кирмәне, кирмәнгә ашыкмады әмир. Шулай уйларга рәхәт иде. Ат үрелепүрелеп кенә үлән каба, башын селкеп, йөгән тимерләрен зеңләтә, пошкырып ала. Кояш авышка таба тәгәри, көн аяз, бераз җиләс, зәңгәр күккә карап ял итеп ятасы иде дә бит, кичкә Кашанга кайтып җитәсе бар — иртәгә Бөек Калага китәсе. Атасы дәшкән.

Киң иде дөнья биредән караганда. Бабалары җир-суларны сайлый белгән, рәхмәт аларга. Уңга баксаң — Чулман елгасы, сулга баксаң — урман-кырлар. Елга ярының иң биек җирендә Шайтан каласы — кирмән. Шайтан манарасы исә барысыннан да өскә калкып тора. Ташчылар баш күтәргәннән соң, манарага берәүнең дә кереп караганы булмады, кергәннәрен елга буеннан табып алалар... Кем бар анда? Әллә чынлап та Шайтан үземе? Башкалар өчен генә түгел, хәтта иясе әмир Хаҗи өчен дә серле манара иде ул. Илче Садак шунда кереп китә, кире әйләнеп чыкмый, әмир үзе яшь азатны үлемгә кертеп җибәрде — үле гәүдәсен елга буеннан табып алдылар. Әллә соң бирегә кала салдырып, кирмән торгызып

ялгыштымы әмир Хажи? Ялгышмады кебек. Бәкер оста монда чуен коя.

Әмир Хажи күп еллар элек булган бер хәлне исенә төшерде. Көнел көгендә һәрчак сакланып килгән хәлне ул берәүгә дә сөйләмәгән иде, хәтта искә төшергән чакларда да тизрәк башка нәрсә хакында уйларга тырыша иде.

Ул вакытта яшь иде әле әмир Хажи. Кашанга әмир булып яңа килгән еллары иде. Җирләре, биләмәләрен үз күзе белән күрергә теләп, менә бүгенге кебек, бер ялгызы каладан чыгып китте. Һәм, йөри торгач, менә шул төбәккә килеп чыкты. Ярның иң биек җирендә утырган хәрабә манараны күреп, таң калып карап торган иде. Шул чак, җир астыннан калыккан сыман, аның алдында кам пәйда булды. Әле булса хәтерендә, аның кулында таяк иде, кисәк ул таягын җиргә кадады һәм күз ачып йомганчы таяк ботаклар чыгарды, яфрак ярды. Нинди хикмәткә ия таяк булды икән? Кам таякны янә җирдән суырып алды һәм таяк янә шәп-шәрә калды. Әмир Хажиның ишеткәләгәне бар иде, имеш, сергә ия таякны камнар буыннан-буынга биреп киләләр, таяк чынлап та сихри көчкә ия икән. Шәех Игнәй ничәмә-ничә камның әнә шул сихри көчкә ия таякларын утка ташлаганы бар. Ә камнар һаман шул таякларына таянып йөри бирә, гәрчә үзләренә ышанучылар елдан-ел азая барса да. Болгарда камнарның беткәннәре юк иде. Янә бер нәрсә хәтерендә ачык калган әмир Хажиның, камны күрүгә, аты өркеп, пошкырынырга тотынган иде. Шунда кам атка мөрәҗәгать итеп нидер әйтте һәм, гаҗәп, ат берни булмаган кебек утлый башлаган иде. Ниһаять, кам аңа дәште:

— Атың беркая да китмәс, миңа ияр, әмир,— диде, шулай диде дә, артына да әйләнеп карамыйча, Шайтан манарасына таба кузгалды. Янә гаҗәбе шул булды: әмир Хажи аңа карусыз буйсынды, аңа иярде. Манара хәрабәгә әверелгән, кызганыч бер хәлдә иде, мәгәр якынайган саен манара әмир күз алдында үзгәрә барган кебек булды. Аның зур-зур ташлардан өйгән диварлары, ярымтүгәрәк ишеге күңелне үзенә җәлеп итә, кайчандыр монда яшәгән, дөнья көткән кешеләрне күз алдына китерә иде. Кам манара янына житте дә таягы белән дивар кырына төртте, шундук җирдән чишмә тибеп чыкты һәм, күз алдында юл ярып, чылтырап агып тора башлады.

— Эч чишмә суын! — диде кам. Әмир карусыз тезләнде, кушучына көмеш кебек чиста, боз кебек салкын су алды, иреннәренә якын китерде. Су аңа татлы да, бераз тозлырак та сыман тоелды.

Әмир Хажи әкрен генә күтәрелде, зәңгәр күккә карады, биектә-биектә тилгән тибрәлә иде. Юк, төшендә түгел бу хәл, өнендә. Кам да чын. Тик атын гына әйтмәде. Алай дисәң, чишмә кайдан? Чынлап та, сихри көчкә ияме бу кам, әллә күз буамы?

— Әмир Хажи, Болгар камның гомере күп калмады, хәрабә булса да керик манара эченә. Сиңа күрсәтер төньюлларым, әйтер сүзләрем бар.— Әмир Хажи карусыз аңа иярде.— Борын-борын заманда, ышбу якларда ни төрки, ни чирмеш яшәмәгән чакта, бирегә үзенең алыплары белән Кубрат хан килеп чыга. Ышбу төбәккә баса да тирә-юньгә карап тора. Чулман елгасының иң биек ярына кунарга була. Иртән торып кояш чыгышка бакса — иге-чиге булмаган җир-сулар, урман-тайгалар күрә. Кубрат хан алыпларына үзе басып торган төбәккә манара торгызырга куша. Манараны торгызалар. Ханның манараны ни өчен салуы билгеле — биредән ярты илне күзәтеп була. Манарада Кубрат ханның тамгасы бар. Кубрат хан киткән — тамгасы калган. Ә инде угланы Кодрак бу төбәкләргә күчеп килгәч, манара янына кәрвансарай салдырган, үткән-сүткән сәүдәгәрләрдән җыем ала башлаган. Борынгы бабаларыбыз кәрвансарайны Төн иле капкасы дип атаганнар. Вакыт үтү белән бу төбәкләрдә юлбасарлар күренә башлый, талау-рәнҗетүгә түзмичә, сәүдәгәрләр кәрвансарайны уратып үтәргә мәҗбүр булалар. Бирегә туктаган сәүдәгәрләрне йә үтерәннәр, йә елгага ташлаганнар. Шуннан соң халык кәрвансарайны Шайтан каласы, күзәтү манарасын Шайтан манарасы дип атый. Тора-бара кәрвансарай җимерелгән, Кубрат хан алыплары салган күзәтү манарасы

хәрабәгә әверелгән. Хәзер монда бер сәүдәгәр дә туктамый, кеше аяк басмагач, чишмә дә җир астына кереп кача. Мин сиңа Кубрат хан битен юган шифалы сулы чишмә чыгарып бирдем, әмир. Сакла син аны, олуг хан Кубрат бабабыз исәтәлеге итеп сакла. Манарага менсәң — Кашаның күренер, аяз көндә Бөек Кала төсмерләнер.

— Атың Болгар диден, кам. Нигә мин сине белмим?

— Камның аты буламы, әмир? Мин тәңремезнең җирдәге вәкиледер. Сиңа тап булуымның сәбәбе шулдыр: сине Чәчкә Ана дәвалады, ә ул... Әүвәл манарага мен дә тирә-юньгә бак, әмир...

Әмир Хаҗи тар баскычлардан манарага менде һәм, тирә-юньгә күз ташлавы булды, гүя күккә ашты — очып китәр сыман иде. Еракта-еракта зәңгәр офык читендә Кашан каласы төсмерләнә, иллә күпме генә күрергә тырышмасын, әмир Бөек Каланы күрә алмады. Ә Чулман елгасы офык читенә зәңгәр җеп булып кереп югала. Елга өстендә ике-өч сәүдә корабы күренә. Әмирнең башына тиле бер уй килә: кәрвансарайны торгызырга, манараны әйләндереп, кирмән итәргә!

Әмир Хаҗи ашыга-ашыга түбән төште, аскы якта аны кам көтеп тора иде, әмир төшеп җитүгә, ул аңа кул изәде, үзенә иярергә кушты.

Түргәрәк үтүгә, кам сихерле таягы белән диварга кагылды, шундук кеше сыярлык кына ярык барлыкка килде, ул шунда керде, үрелеп кенә кисәү агачы алды, чакматашы белән ут салды һәм, әйдә минем арттан, дип, әмиргә кул изәде.

— Ышбу тоньюлы урман яклап, упкын тарлавыкка барып чыгар, искәреп кал,— диде кам һәм бик тиз алга таба китте. Әмир Хаҗи аңа чакчак кына иярә алды. Кисәк аңа нәрсәдер килеп бәрелде.

— Кам!

— Ярканат ул, ярканат,— диде кам, ерагая барып. Әмир аны көчкә куып җитте.

— Кем салган бу тоньюлын?..

— Юлбасарлар. Алар монда яшәгән, көн күргән, кыш чыккан.

Чынлап та, тагын бертын баруга, көн яктысы күренде һәм алар тарлавыкка килеп чыкты. Аннары килгән юлдан кире әйләнеп кайттылар. Тоньюлдан чыккач, кам таягы белән диварга төртте, дивар элекке хәленә кайтты. Кам манараның көнчыгыш тарафына күчте, шулай ук диварга таягы белән кагылды, янә могҗиза күрде әмир, янә дивар кеше сыярлык кына ачылды һәм кам, әмир Хаҗины ияртеп, түбән таба төшә башлады. Караңгы, кисәү агачы сүнәр-сүнмәс леперди, кам үрелеп кенә икенче кисәү агачы алды, аңа ут салды, кызурак атлап китте. Аяк астында су чыпылдый, түбәдән тамчылар тама, таш баскычлар тайгак, менә-менә таеп китәрсең кебек.

— Җитәбезме инде, кам?

Теге дәшмәде, һаман төшә бирде.

Әмир Хаҗиның зиһене сафланып киткәндәй итте. Бу камны күргәне бар лабаса. Еш кына Кашан базарына килер, сүзсез генә халык арасында йөрер, артыннан бала-чага ияргән булыр, кам аларга бөтенләй игътибар итмәс, ил-доньядан ваз кичкән бераүдәй, кемнедер эзләр, иллә берәү янына да туктамас, сүз катмас. Нигә ул үзен Болгар кам дип атады? Аты чынлап та Болгармы?.. Аты чынлап та Болгар булса, бу кеше кайчандыр Чәчкә Ананың ире булган булырга тиеш, ире булмаганда якын кешесе.. Алай булгач, нигә икесе илнең ике тарафында яшиләр? Чәчкә Ана Ык елгасы буйларында, монысы Чулман буенда, ата-бабалардан калган манара хәрабәсендә? Болгарга ислам һәм христиан дине таралгач, барча халык мәчет-чиркәүләргә йөри башлагач, бил каешына төрле шалтыравык савыт-саба, башына бүре башы сөяге, түшенә кыңгыраулар таккан камга кәмит итеп кенә карыйлар, ул халыкны бөтенләй кызыксындырмый, кайчандыр бабалары инанган тәңре бары тик телдә генә калган. Тәңре динен әле булса халык күңеленә салырга өмет итеп, атын Болгар дип йөргән камга хәтта сәдака бирүчеләр дә юктыр. Хәер, ул үзе дә берәүдән дә

сәдака алмый, һәрнәрсәгә игътибар итми, ул ыгы-зыгы килгән халык арасында сабыр-тын гына йөри дә йөри. Кайчак ул кисәктән бер ярлы янына туктый, ярлының башында чалмасы, өстендә җиләне юк, киндер күлмәгенең җиң очлары теткәләнгән, әмма ул мөселман — ул үзен, ярлы булса да, камнан өстен күрә, аңа югарыдан торып, мескен итеп карый, гәрчә алдына мескен бүреген куеп, хәер сорашып утырса да. Кам исә аны кызгана, керләнеп беткән мескен бүрегенә бер көмеш акча ташлый. Үзен камнан өстен санаган мөселман аңа баш ия-ия рәхмәт укый, биргән хәеренә дога кыла.

— Синең рәхмәтеңнән өй салып булса икән ул,— ди аңа кам.— Ач кешегә ипи бирсә икән аллаң,— ди һәм, ярлы мөселманның мескен бүрегенә зур бер телем ипи салып, китеп бара. Ярлы мөселман аңа, иреннәрен кыймылдата-кыймылдата, белгән догасын укый.

Әле булса сөйли базар картлары, имеш, борын-борын заманда, болгар халкы Таман ярымутравында дөнья көткәндә, элек төп-тәңре исемен йөрткән камнар халыкның иң яраткан кешеләре булган, халык аларны хөрмәт иткән, өй ишекләре аларга һәрчак ачык булган. Хәзер әнә камнарга ышанучылар бөтенләй калмады диярлек, булганнары да кеше күзенә күренергә курка, чөнки шәех Игәнәй мөридләре, епископ Габбас дьяклары камнарны эзәрлеклиләр, кеше-кара күрмәгәндә, иблисләр дип, агачка асып куялар. Хәтта шул кадәрегә барып җиттеләр ки, илгә корылык, үләт, яман яу килсә дә, камнарны гаепли, аларны аса, сөңгегә алалар. Ә хан боларның берсен дә күрми, һәрхәлдә, күрмәмешкә салыша. Шуңа күрә камнарның күбесе урманнарда, тау куышларында шәех Игәнәй мөридләренең куллары җитмәгән җирләрдә яши, соңгы көннәрен кичерә.

Ары таба баскычлар бетте, кам туктады, куе яфраклар каплаган кеше сыярлык кына тишекне ачты. Аста су шаулый иде.

Кам сүзсез генә кире борылды. Манарага килеп чыккач, ул әфсен укып диварга кагылды, дивар янә үз хәленә кайтты.

Әмир Хаҗи ашыга төшебрәк манарадан чыкты һәм, янында камны күрмәгәч, чак кына кычкырып җибәрмәде.

Әгәр дә мәгәр бу мәлдә әмир Хаҗига кояш тотылачак, дөнья бетәчәк, ахырзаман килде, дисәләр, бу кадәр гаҗәпләнмәгән булыр иде. Ул йөгереп манара эченә керде, кам кагылган диварга этеп, төртеп карады, мәгәр һичнинди ишек тә, эз дә күрмәде. Әмир Хаҗиның мизгел эчендә башыннан әллә ниткән уйлар килде. Ул монда кәрвансарай сала. Шайтан манарасын күзәткеч итә ала ич. Чулман елгасыннан түбән төшкән һәм югары менгән сәүдәгәрләр аның уч төбендә кебек булыр, сәүдәгәрләрнең корабларын йөзәр чакрымнан күрер... Яу килгән дошман хакында әйтеп тә торасы юк...

Шушы хәлдән соң әмир Хаҗи Болгар камны күрмәде. Кемдер аңа әйтте: имеш, Шайтан каласына нигез салырга килгәч, җир астыннан диярлек кам килеп чыга һәм кала нигезенә үзен тереләй күмәргә куша. Ташчылар аннан көләләр, ә инде кам үзе нигез казылган чокырга төшеп яткач, ни кылырга белми аптырап калалар. Шунда ташчылар янына кала салырга фатиха бирергә килгән шәех Игәнәй килеп чыга һәм, иблисне күмгән кешенең урыны оҗмахта булыр дип, камны күмәргә куша. Мөселманнар арасында оҗмахка керергә теләүчеләр бик тиз табыла. Шулай итеп, Болгар кам Шайтан каласы нигезенә күмелә.

Шул хәлдән соң икенче көнне үк әмир Хаҗи, кала салырга рөхсәт сорап, атасы Сәлим хан янына китте. Атасы аны теләмичә генә кабул итте. Атасының Владимир кенәзе Андрей Боголюб белән мөкшы җирсулары өчен бәхәскә кергән чагы, кәефе юк, угланының теләген тыңлартыңламас: «Сала бир», — генә диган иде.

...Әмир Хаҗи Шайтан каласына кермәде. Ат тезгененнән тотып, яр буйлап йөри-уйлана торгач, кайтып китәргә булды. Нигәдер Шайтан каласына аягы тартмады.

14

Көн үткән саен, кәтиб Хафиз өчен дөнья тарая барды. Казан кирмәненнән кайтканнан соң, атна гомер үтеп тә китте. Ә Сәлим хан аны чакыртмады. Иллә бу хәл озакка бармас, тиздән ул Сәлим хан алдына басар. Аның тарафыннан булмаса да, явызлык кылынды: вәзир Исхак хан оныгы Галине яңа кала нигезенә корбан итте. Күп тә үтмәс, ул төбәккә меңләгән ташчыларны куып китерерләр һәм Гали күмелгән Чияле тауга сарай торгыза башларлар. Каланы оста Алпар углы Дәүран сызымнарына карап салачаклар икән, кәтиб Хафизга бу хакта бусагабаш Камай әйтте. Әйе, кала күтәрелер, тиздән ул төбәккә төрле илләрдән сәүдәгәрләр агыла башлар, базар урамнары умарта күчедәй гөжләп торыр, ләкин берәү дә биредә булган фаҗига хакында белмәс. Белгәннәре дә дәшмәс, чөнки ханның нәфрәтеннән куркыр. Хәер, Сәлим хан анда булганнарның берсен дә калдырмас, шаһитларның барысыннан да арыныр, хәтта кәтибе Хафиздан да, чөнки ул да анда булган хәлләргә шаһит.

Алай да кәтиб Хафиз тыныч иде. Гали оланның исән-имин булуы хакында бары тик ике кеше генә белә: ул да, сәүдәгәр Биккол. Кәтиб Хафиз, утлы табага бастырсалар да, бу турыда беркемгә әйтмәс. Биккол янә дәшмәс. Башкалар күрмәде, кам барысын да җиренә житкереп эшләде. Кайтырга чыккач та, юлда чакта да, Бөек Калага житәрәк тә һәммәсе дә Гали оланның яңа кала нигезенә корбан ителүе турында сөйләделәр. Хәтта бу хәлнең алай түгел икәненә инанган кәтиб Хафиз да курка калган иде. Гали оланны кам коткарып кала алмаган булса? Биккол аны Өргәнечкә алып китмәгән булса? Йә хода, йә хода, әллә нинди уйлар килә башка. Кәтиб Хафиз чынлап та курка калган иде, бу куркуы соңрак та китмәде, чөнки аны Сәлим хан дәшмәде, гүя кәтибе юк та иде. Шуннан шиккә калган иде кәтиб Хафиз. Уйлана торгач, үзен янә тынычландырырга кереште. Әйе, ул аны күрмәде, ләкин ул исәндер, аны сәүдәгәр Биккол Өргәнечкә алып киткәндер, хәзер инде алар Саксин каласын узып баралардыр. Әлбәттә, Гали олан һични аңламый калгандыр, соңрак Биккол белән юлга төшкәч, тегесе барысын да аңлаткандыр. Барысын да уен итеп кенә кабул иткән олан үртәлеп елап алгандыр, аннары тынычлангандыр, чөнки ул чынлап та яңа кала нигезенә корбан ителергә тиеш иде һәм моны эшләргә кем дә булса түгел, бабасы Сәлим хан үзе боерган икәнен аңлагандыр.

Кәтиб Хафиз Гали оланга иртәгә буласы хәл хакында аңлатырга теләгән иде, хан оныгы аңа ышанмады, ул барысын да уен итеп кенә кабул итте. Кәтиб Хафиз аңа бу турыда янадан сүз кузгатмады һәм олан үзе дә сорамады. Әле булса күз алдында, кәтиб Хафиз угланны кочагына алды, юаткандай итте. Ә бит ул аның белән саубуллашты... Әйе, кәтиб Хафиз тантана итәргә тиеш иде, хаклык жиңде, тик әллә нигә күңеле тыныч түгел, гасабилана, хафалана. Бу серне кемнең дә булса ачуы бар иде. Кем? Биккол? Ул аңа ышана, аннары ул инде ерак. Вәзир Исхак? Аның үз хәле хәлдер. Шымчы азатлар? Аларны икенче көнне үк Җаек буена озаткан Сәлим хан. Кала бер кеше — казый Саксин? Менә кемнең серне белү ихтималы бар иде, гәрчә кам бар нәрсәне бик оста башкарган булса да, нәкъ менә шул кешедән курка иде кәтиб Хафиз. Әйе, Сәлим хан чынын белсә, ни инсафлы кәтибе Хафизны да җәллад балтасы астына куярга оялмас. Гаделлек, хакыйкать турысында көн-төн сөйләсә дә, Сәлим хан иң якын кешеләрен җәллад балтасы астына сала һәм мыскал да вөждан газабы кичерми иде. Кем-кем, кәтибе Хафиз бу хакта бик яхшы белә.

Хаклык.

Ни ул? Нигә хаклыкны яклаган кешеләрне һәрчак әзәрлеклиләр дә алардан тизрәк котылу җаен карыйлар?

Янә бер хәл кәтиб Хафизның күз алдында тора. Кайтыр якта Ибраһим каласына килеп кергәч, кала бие Ягкуб капкасыннан яшь бер кыз чәчрәп чыкты. Хан азатларын күрде дә, канатланып киткәндәй, очына-очына аларга каршы йөгерде. Әмма азатларга җитәрәк шып туктап калды. Хан вәкилләре арасында Гали углан юк иде. Кыз Исхакка таба ымсынып куйды, ә ул аның ягына күз дә салмый үтеп киткәч, Булат оланга дәшмәк итте, әмма Булат та кызны күрмәмешкә салышып үтеп китте. Бу хәлне күреп, йөрәге юл өстенә өзелеп төшәр дәрәҗәгә җиткән Хафиз да кызга күтәрелеп карарга базмады. Барыбер юата алмас иде, аннары ул үзен, нәкъ менә үзен, ышбу кыз бала алдында гаепле итеп тойды. Берара киткәч, Хафиз артына әйләнеп карады. Аның каерылып каравына юл читендә басып калган кыз янә бер талпынып алгандай итте, тик янә туктальш калды һәм бөтенләй өметен өзеп булса кирәк, ике кулы белән йөзен каплады да сыгылып төште. Капкадан кызның ата-анасы чыкты, сулкылдаудан иңнәре калтыранган кызны җитәкләп, юата-юата, ишегалдына таба алып киттеләр...

Икенче атнада гына кәтиб Хафиз янына бусагабаш Камайның ярдәмчесе килде. Ул кыяр-кыймас кына кәтиб Хафизны хан сараена дәште. Кәтиб Хафиз кара савытын билбавына элгән күн капчыкка салды, очлап куйган каләмнәрен түшенә тыкты. Сарайга килеп кергәч, Хафиз ханга баш иде, сәлам юллады, әмма күтәрелеп карарга базмады, үз урынына үтеп утырды, кара савытын өстәлгә куйды, бөкесен ачты, каләмнәрен өстәлгә тезеп салды. Шуннан соң гына хан ягына сирпелеп алды. Ханның чапаны астыннан кызыл итеге күренә. Чапан яңа көмеш һәм алтын җепләр катыштырып тукылгангамы, җем-җем итә. Ханның башында кеш тиресе белән каелган бүрек, бүрекнең өске ягы затлы асыл ташлар белән бизәлгән, кулында кам таягы. Кәтиб Хафиз белә, бу таяк бик күп сергә ия. Таяк затлы ташлар белән бизәлгән. Таяк дык итеп идәнгә кадала икән, димәк, ханның кәефе юктыр, ә инде хан кулындагы серле таяк алдына килеп баш орган кешенең аркасына йомшак кына кагыла икән — ханның сиңа киңәше бар, башың күтәр дә дикъкать белән тыңла; таяк ханның тәхетенә сөяла икән — тыныч бул, борчылма, гасабиланма, ханның кәефе күтәренке, йомышың йомышларга ашык.

Менә ничә ел инде Сәлим хан янында Болгар тарихын язып утырган кәтиб Хафиз өчен боларның берсе дә сер түгел, әмма ханның хикмәтле хәлләрен белмәгән кешеләр дә килгәли тәхет каршына, ялгышып куючылар да бар — анда инде Сәлим ханнан шәфкать көтмә, суктырмаса да ким куймый, куып чыгарырга кушуы бар.

Кисәктән кәтиб Хафиз хан алдында үзен гаепле итеп хис итә башлады. Яшен тизлеге белән зиһенен яман бер уй ярып узды: сәүдәгәр Биккол Гали оланны Сәлим хан кулына кайтарып биргән булса?..

— Хафиз, — диде хан кәтибенең уйларын сизгән кебек. — Син анда барысын да күрдеңме? Нәрсә авызың ачып каттың?! Әй, күрдеңме дим оланны корбан иткәнне? Нәрсә син гаепле кеше сыман дәшмәс булдың? Әллә чынлап та гаебең бармы?

Хафиз үзе дә сизмәстән гаебем бар дип, чак кына ияк какмый калды.

— Мин анда бернәрсә дә күрмәдем, хан.

— Күрмәдең? Күзең бәйләгәннәр идеме? Менә нәрсә, кәтиб, син миңа яңа кала салынасы төбәктә булган хәлләрне түкми-чәчми язып бир. Бар, катып торма каршымда! Иртәгә иртән язмаң миндә булсын!..

Кәтиб Хафиз, тез буыннары бушавын тоеп, борылды да ишеккә таба китте, ул аркасы белән тойды: хан аңа карап тора. Ни хакында уйлый микән хан? Муены нечкә, җәлладка чабуы кыен булмас дип калдымы?

Шулай дип уйлауга, кәтиб Хафизның аркасы өшеп китте, хәтта үл җәллад чабып ташлаган башын күргән кебек булды. Кайтып керде дә булмәсенә, ятагына ауды, бөтен тәне калтырый, йөрәге ярсыңып тибә иде. Тик бик озак бөкшәеп яткач кына, торып, өстәле янына килеп утыра алды. Кара савытын чыгарды, каләмнәрен тезеп салды. Алдында ап-ак кәгазь бите, зиһен таркау...

Язылмады.

Сәлим хан кәтиб Хафиздан көнләмәде, гәрчә ханбикә Зөбәрҗәт еш кына аның янында булып, кызы Назлыгөлгә сабак бирсә дә. Сәлим хан, кәтибе янына берничә тапкыр ханбикә кереп киткәч, махсус ясалган ярыктан аларның нишләүләрен күзәтеп торды. Әмма кәтиб бер генә шикле хәрәкәт тә ясамады, хатын-кызны котыртырлык, аздырырлык бер кәлимә сүз дә әйтмәде. Хак анысы, янына ханбикә килеп керүгә, кәтиб Хафизның йөзе ачылып китәр, юка иреннәре елмаюга җәелер иде, мәгәр шуннан артмас. Кәтиб Хафиз ханбикәгә тарихтан өзекләр укыр, төрки шагыйрьләрнең яңа китапларын укыр һәм һәрчак аркасы белән тоеп торыр — аны кемдер күзәтә. Нәкъ шул тоемлый ала алуы кәтиб Хафизны Сәлим хан күз алдында изге җан итте бугай да инде. Һәм ул чынлап та изге иде ханбикәгә карата да, кызы Назлыгөлгә карата да, гәрчә икесен дә күргән саен күрәсе килсә дә. Назлыгөлне ул кыска гына вакыт эчендә укырга-язарга өйрәтте. Сәлим хан кәтибеннән ихлас канәгать иде. Моны эче белән тоя торды кәтиб Хафиз. Чөнки ул ханга бернинди дә хилафлык кылмады. Иллә ялгыш тоемлавы да бар иде. Менә хәзер өстәле янына килеп утыргач кына сизде ул, хан аннан шикләнә. Кызы Назлыгөлдәнме?..

Башта кәтиб хан кызы Назлыгөлне иркә, нәзберек һәм бераз һавалы зат итеп кабул иткән иде. Тора-бара бу уеның расланмавын күрде. Назлыгөл бар нәрсә белән дә кызыксынды, иң мөһиме, житди китаплар укыды, кайберләрен аңлады, ә аңламаганнары хакында сорап йөдәтте — аңлатуын үтенде, белергә теләде. Тормыш тәмен яңа гына сизә башлаган кыз бала дөньяви хәлләрнең асылына төшенергә тырыша иде. Хафизны иң әүвәл хан кызындагы әнә шул сыйфат куандырды.

Назлыгөлгә унҗиде яшь тулгач, Хафиз беренче тапкыр аның авызыннан оста Дәүран исемен ишетте. Ишетте дә укучысы өчен курка калды. Мәхәббәт кешенең иң-иң яшерен сере булырга тиеш. Башкача була алмый, башкача булганда, ул мәхәббәт була алмыйдыр. Шулай, бары тик шулай дип аңлый иде кәтиб Хафиз, гәрчә үзе бер тапкыр да гашыйк булып караганы булмаса да. Хан кызы хан колы Дәүранга гашыйк. Мөмкин хәлме?! Сәлим хан өчен һич тә мөмкин хәл булмаса да, кәтиб Хафиз өчен мөмкин хәл иде бу. Чөнки ихлас мәхәббәт дәрәҗәләр белән исәпләшми, аның үз кыйблас, үз бизмәне, үз карашы бар. Әйе, хан кызы Назлыгөл оста Дәүранга гашыйк. Тарих китабына бу хакта яза ала идеме кәтиб Хафиз? Юк. Чөнки китапны вакыт-вакыт Сәлим хан соратып ала, укый һәм үзенә ошамаган хәлләр хакында язылган юлларны яңадан язарга куша. Шуның өчен кәтиб Хафиз үзенә бер дәфтәр тота. Болгарда булган хәлләрнең иң кызыклыларын ул шул дәфтәргә терки бара.

Әле дә ул тарих китабын бер читкә алып куйды, ләкин яза алмады, алдына салган ап-ак кәгазьне дә читкә этәрде һәм өстәлгә яшереп куйган дәфтәрен алды, каләменә үрелде

«Йә алла, мөхәммәдерәсүлулла! Хикмәтле хәлләр хакында язам, кичерә күр бәндәңне. Барысы да синең кулыңдадыр, бирәүләрне хан итү дә, икенчеләрен кол итү дә. Елдан-ел Сәлим хан халыкка ясак салуны арттыра бара, яңадан-яңа кирмән-калалар торгыза, күпләп корал ясата, азатлар санын арттыра. Болар барысы да кара халык җилкәсенә төшә. Моннан ике-өч ел гына элек Ага-Базарда бер жи-

ләнне бер алтынга сатып алып була торган иде, хәзер бер җиләү өч алтын торадыр. Хан үз халкына ышанмый башлады, сарайны читтән яллаган баһадирлардан саклата, төрле килмешәкләрне куштаннары итә. Алар ханга ялагайланалар, аңардан чын хакыйкатьне яшерәләр, җирле халык белән исәпләшмиләр, гореф-гадәтләрен, йолаларын ят итәләр, юк кына гаеп өчен дә зинданга ябалар, җәберлиләр. Бу кадәр җәберләүгә халык түзмәс, көннәрдән бер көнне кулына корал тотып, урамнарга чыгар, хан кирмәненә ташланыр, илдә кан коюю китәр».

Кәтиб каләмен бер читкә куйды да уйга калды.

Кем өчен яза ул бу юлларны? Кем мохтаҗ бу юлларга?! Сәлим хан мохтаҗ түгел, ул боларның барысын да белә, иллә берни дә кылмый. Әә бәлкем белмидер? Шулай да булуы бар ич! Юк, ул язып дөрес эшли. Ул бу дәфтәрне Гали оланга җибәрер, киләчәктә Болгар тәхетенә утырырга тиешле кеше тарихта булмаган хәлләр белән хәбәрдар булырга тиеш. Юкса аның да хаталар кылып ташлавы бар.

Кәтиб Хафиз янәдән ап-ак кәгазьне каршына салды. Ни язарга тиеш ул? Ни язса да соңыннан җуеп булмас. Булган хәлнең асылын язса, хан аның үзен дә, вәзир Исхакны да кичермәс. Хәер, Исхакны хан болай да кичермәс, бәлкем әле кәтибе Хафизны да. Кәтиб Хафиз бераүгә дә үлем теләми. Шуңа күрә Сәлим ханга бер кәлимә сүз дә язмас. Язуның әл-казый Ишкул кулына керүе бар, анда инде шәфкать көтмә: гаепсез кешене гаепле итә ала, диләр аның хакында. Шулай ук шәех Игәнәй дә аны акламас. Киресенчә, ислам кануннарын бозучылар дип, Әбү Җәһилләр сафына куяр, һич булмас димә. Шәех Игәнәй яши белә: тәсбих тарткан саен ханга кулын суза, хан шәехен буш итми, чөнки кем мактар иде Игәнәй мактамаса ханны? Сәлим хан Болгар дәүләтенең уникенче ханы, унөченчесе кем булыр? Хафиз Гали углан дип хыяллана. Нинди заманга туры килде Хафиз, ике туган билләренә кылыч тагарга өлгермәделәр — тәхет өчен тарткалаша башладылар. Һәм моны башлап җибәрүче Сәлим хан үзе. Хәерле булсын, язганны күрми булмастыр, ахрысы.

Сәлим хан еш кына үзенә кадәр Болгар тәхетендә утырган ата-бабаларын хурларга ярата. Әә бит борынгылар: «Атын хурлаган — уңар, атасын хурлаган — туңар», — диганнәр. Аллаһы тәгаләм, моннан соң Болгар тәхетенә игелекле ханнар гына утырсын иде. Андый ханнар юк дия күрмә, ходаем, кояш янында син булсаң, ай янында йолдыз бар. Ул йолдыз — Гали угландыр...

Сәлим хан, борынгы бабаларыбыз йоласына ышанып, Гали угланны милади белән 1177, һиҗри белән 573 елда Яңа кала нигезенә корбан итте. Аның уенча, бу чара каланың куәтен, гомерен үстерү һәм озайту өчен кылынган, ягъни, җир астында ятучы изге җан каланы зур афәтләрдән сакларга тиеш булачак иде. Борынгы бабаларыбыз надан чакта бу килешкәндер, ихтимал. Мәгәр хәзер бу хәл халык тарафыннан яклау табамы? Юк. Әйе, кайда ул нигезенә хан нәселе корбан ителгән калалар? Нинди зилзиләләр җимерде дә аларны, кемнәр җир белән тигезләде?! Кайда Бөек Кубрат хан салдырган Фәнәгүр дә Бөек Болгар дәүләте үзе?! Олы Идел буйларына килеп сыенган илхан Кодрак, ерак Дунай буйларына барып Ил тапкан илхан Аспарух — кайда сез?! Күп тә үтмәде, сез, бертуганнар, бер-берегезне танымас булдыгыз, гореф-гадәтләрегез, иманнарыгыз гына түгел, хәтта телләрегез дә алышынды. Әә бит илегездә яңа кала торгызган саен нидер корбан иткәнсездер, ил-дәүләтегезне мәңгеләштерергә тырышкансыздыр. Хәер, ераккарак китсәк, тагын да әрнүлерәк хәлләребез. Кайда безнең батырлыгы телдән-телгә җырланып килгән Бөек Атилла?! Кайда төрки дөньясын берләштерергә йөргән һәм шул юлда һәлак булган илтабар Көлтәгин ырулары?! Кайда сез?! Хөрмәткә ия Кубрат бабабыз, кайда синең Азак дингез ярларына

сыенган болын-тугайларың, иксез-чиксез далаларың?! Угланнарыңа җирләрең бүлеп бирдең дә, үзең орыш кырында ятып калдың! Идел буена күчеп килгән Кодрак илхан ыруы ислам динен кабул итте, ышбу дин халык күңеленнән синең исемеңне җуйдырды. Бүген исә монда халкыңа ят булган, ком чүлләрендә туып иленә нәмәгълүм пәйгамбәрләр исеме яңгырый. Килер бер көн, Сәлим хан, синең исемеңне дә онытырлар, ел санын да яңа дин нәүбәтеннән башларлар. Хәзер инде барысы да үзгәрде, ашаган ризыкларына кадәр үзгәрде, тоткан иманнары хакында әйтеп тә торасы юктыр. Гасырлар буе төрки телдә сөйләшкән болгар болгарны аңламас булды, үз чыгышыннан ваз кичкәннәре дә аз түгел. Камиллек җитми халыкка. Ни ул камиллек? — дип сорамагыз. Әйтеп бирә алмам. Әбүгалисина сүзләрен куллансак, камиллек өч баскычтан торадыр: беренчесе — үзеңә тиң дуслар табудадыр, икенчесе — синең тарафтан ышбу якты дөньяга хыялга бай һич югы бер фикер иясе тәрбияләп калдырудадыр, өченчесе — иң әүвәл үз-үзең белән, аннары гаиләң, аннары илең белән камил идарә итүгә ирешүдәдер.

Дөньяви хәлләр турында язылган китапларны күп укыды кәтиб Хафиз һәм, укыган саен, белгән-таныганы аз тоелды. Иллә һәр китап аңа яшәү өчен көч бирде, киләчәккә өмет өстәде, күңелендә изгелеккә омтылу хисе уятты. Дөньяви хәлләрне башкаларга караганда күбрәк белсә дә, хатын-кыз янында гүя үсмер иде Хафиз. Ул хәтта аларга туры карарга оялды. Юк, бу курку түгел иде, һич юк, мәгәр гүзәл хатын-кызларны күрүгә, нинди дер үзе дә аңлап бетермәгән тетрәнү тояр иде. Хан кызы Назлыгөл әлегә дөньяви хәлләрнең асылына төшенеп кенә килә. Гүя, ул яз кояшыннан уянган гөлчәчкә, ул гына да түгел, шул чәчкәгә кунган күбәләктер: йөзенә багуга, керфекләре калтыранып китә, күзләрендә йолдызлар балкый башлый. Күренеп тора, кыз бала бәхетле, гүя ул мәхәббәт чәчкәсеннән бал җыярга төшкән — бераз әсәрләнгән, гаҗизләнгән.

«Димак, оста Дәүрангә гашыйк булуың хак, Назлыгөл, — дип уйлады Хафиз.— Тик сиздермәсәң иде моны, гүзәлкәй! Сизсәләр, атаңнан да, анаңнан да шәфкать көтмә, утта яндырмасалар да, суга ташланыр көнгә калдырырлар».

— Саумысыз, мөгаллимем!

Хафиз аңа сирпелеп аяк кага, кызның сәламен ала. Хан кызы өстендәге ефәк күлмәк тын гына аккан чишмәдәй шуылдый. Назлыгөл өстәл читенә утыра. Ул мөгаллименнән тартынмый, ул аны атасыннан да якын күрә. Кыз мөгаллименә таба иелә, көмеш тәңкәләр тезгән толымы кара савытына тиеп зеңләп куя. Кәтиб Хафиз аңлый, хан кызы аның мәхәббәт турында китап укуын тели. Ә бит хан кызы үзе дә бик яхшы укый, иллә нигәдер һәрчак мөгаллименнән укытасы килә. Кәтиб Хафиз озак көттерми, үрелеп кенә китап ала һәм, кирәк битен ача да, сузыбрак укый башлый. Назлыгөлнең күзләрендә моңсулык, кем өчендер кайгыру, борчылу, зарыгу галәмәтләре. Мәхәббәт хикәятеннән соң мөгаллиме аңа Көн батыр турында әкият әйтергә булды.

«Борын-борын заманда Каф таулары артындагы диңгез буенда Көн батыр яши. Батыр көн-төн көтү көтә. Кыш килсә, маллары белән җылы якларга күчә, яз килүгә, ыруы белән бергә Идел буйларына юнәлә. Ул көн-төн табигать кочагында, ул бәхетле, шат. Көннәрдән бер көнне Көн батыр җәй алып килгән ике карлыгачны күрә, күрә дә таң кала. Карлыгачлар шундаен иттереп сөешәләр ки, Көн батыр көнләшеп куя. Шуннан зәңгәр күккә бага, анда ике аккошны күрә. Шул мәлдән Көн батыр сагышлана башлый. Һәм сәфәргә чыга, ул аккошлар киткән тарафка кузгала. Көн бара, төн бара бу. Ниһаять, зур елга буена килеп җитә. Бик сусаган була, тиз тиңентен суга керә дә, кушучына су алып эчмәкче итә. Шул чак

колак янында гына ямьле пышылдау ишетә: «Иел!» Көн батыр иел һәм елгада үзен күрә. Күрә дә күтәрелеп зәңгәр күккә карый. Шунда аның колагы ачылып, күзләре киңәеп киткәндәй була — ул кошлар сайравын, елга шаулавын ишетә. Мондагы табигатьнең матурлыгына, хозурлыгына Көн батырның исе китә. Ул иң әүвәл колагына сеңеп калган тавышны эзли, әмма берәүне дә күрми. Шуннан тирәнгәрәк керә, әмма тәүге тавышны ишетми. Көн батыр судан чыга да яр өстенә менеп ята. Көн көтә ул тәүге ишеткән ямьле тавышны, төн көтә, икенче тәүлек киткәндә Көн батыр янына бер карт килеп чыга. Карт аңа бер сүз дә әйтми, миңа ияр дип ишарә генә ясый. Алда түгәрәк күл күренә, күл күренүгә, карт кинәт юкка чыга, ә күл буенда бер кыз кер чайкый икән. Көн батыр кыяр-кыймас кына кыз янына килә, сәлам юллый, шуннан соң атын сорый.

— Атым Айгөл, — ди кыз.

— Матур исем, — ди Көн батыр. —Мин сине бик ерактан эзләп килдем. Ниһаять, таптым. Мин сиңа өйләнергә телим.

— Минем атам бар, минем анам бар, — ди кыз. — Әүвәл аларның ризалыгын ал. Үз атың ничек соң, сәфәрче?

— Атым Көн батырдыр, — ди егет.

Көн батыр кызның керләрен күтәреп алып кайта. Аталары Көн батырны күрәләр дә шатланып туя алмыйлар. Чөнки ата-ананың угланнары юк икән, бердәнбер кызлары да сазаеп килә икән. Көн батыр аларга ни өчен монда килүен аңлата. Ата белән ана шундук ризалашалар. Мәгәр шарт куялар: бездә калырсың.

Әнә шулай Көн батыр Олуг Идел буенда кала.

Күп тә үтми, Айгөл аңа ул таба, аңа Сөябел дип исем кушалар. Бала туган елны әби белән бабай бер көндә диярлек дөнья куялар. Аларны җирләргә дә өлгермиләр, Айгөл авырып китә. Ул да үлә.

Көн батыр сөйгәне Айгөлне җирләп кайта да Олуг Иделнең ярына барып утыра. Шунда ул кер чайкаучы икенче бер кызны күрә, күрә дә аңа өйләнергә теләге барлыгы, әмма хатыны үлгәннән соң углы калуы хакында әйтә. Кыз риза була. Көн батыр аны өенә алып кайта.

Анадан ятим калган угыл ел үсәсен көн үсә, буй җиткерә һәм, күп тә үтми, атасының малларын көтә башлый. Атасы ауга йөри, углы көтү көтә, яшь хатын өй карый.

Бер тапкыр яшь ана үги углын күрә дә таң кала: үсеп-исәеп киткән, «эх» тә итми бозауны күтәреп ала, үгезне мөгезеннән тотып ега. Гашыйк була үги ана углына. Көннәрдән бер көнне, атасы ауга киткәч, үги ана углы янына килеп ята һәм хыянәт итәргә өнди. Сөябел сикереп тора да, атка атланып, далага чыгып чаба. Үги ана моңа бик тә рәнҗи һәм үч алырга була. Ире кайткач, ул аңа Сөябел мине алдарга теләде, ди. Яшь хатынның авызыннан бу сүзне ишетүгә, атада Сөябел углына карата коточкыч нәфрәт туа. Әүвәл ул углына ялкыны агач очына җитәрдәй учак ягарга куша, учак дөрләп яна башлагач, аңа шунык аша сикерергә боера. Мәкерле хатын Сөябелнең янып үләсенә куанып бетә алмый, чөнки мәхәббәт һәрчак нәфрәт белән бергә атлар, диләр.

Сөябел учакны сикереп чыга һәм, акбүз атына атлана да, атасы белән саубуллашмыйча, Төн илләренә юнәлә. Көн чаба, төн чаба Сөябел. Иртән сызылып таң атканда гына аты бер тугайлыкка туктый һәм кинәт ап-ачык итеп телгә килә:

— Булгырың, иям,— ди.

Шуннан бирле Көн батырның Сөябел атлы углы мондагы урманнарда яши, диләр. Кайчак ул Олы Идел ярына басып җырлап җибәрә, сөйгәнен эзли икән. Ә ул бар, имеш, болгар кызлары арасында икән. Таң беленер-беленмәс Идел буена чыксаң, аны күрергә дә була икән, диләр.

Кайчак ул сандугач сурәтенә керә икән һәм Сөябел, Сөябел, Сөябел,

дип бертуктаусыз сайрый, кемнедер чакыра икән, диләр. Тик ул ихластан сөя белгәннәргә генә күренә икән, диләр. Сөя белмәгәннәргә күренми икән, диләр».

Хан кызы моны, әкият икәнен белсә дә, дикъкать белән тыңлый, мөгаллимен бүлдерми, бары тик чак күперенке иреннәре генә, нидер әйтергә теләгәндәй, кыймылдыйлар.

Әкиятен сөйләп бетергәч, Хафиз сулыш алырга да куркып хан кызының сусыл иреннәренә карый, ап-ак тигез тешләренә игътибар итә һәм, хатын-кыздагы тиңсез камиллекне күреп, карашын читкә ала — үз-үзеннән курка. Мәгәр карашы янә-янә кызның сусыл иреннәрендә, алсу битләрендә, туктала, ул инде чарасыз, гасаби рәвештә кызны күзәтә.

«Кемгә гашыйк, син, гүзәл?»— дип сорыйсы килә Хафизның. Ул белә: хан кызы оста Дәүранга гашыйк, әмма ул бу хәлне җитди итеп кабул итми, чөнки гадәттә хан кызларының язмышы аталары кулында була. Бәлкем, бу чибәрне Сәлим хан Олуг Мөхәммәтнең берәр угланына бирер, йә күрше кенәз онықларына, һич югы, Баян баһадирга? Элек-электән хан һәм кенәз йортларын килмешәк баһадирлар саклаганнар ич. Ханнар кызларын шул баһадирларга биргәннәр һәм шуның белән аларны үз иткәннәр. Килгән кешегә ил алыштыру ни дә, хатын алыштыру ни, аңа алтын, байлык, муд тормыш булсын. Калганы өчен ул кайгырмый, чөнки аның туган иле юктыр, туган ил аңа яттыр. Бәлкем, кәтиб Хафиз ялгышадыр. Баян баһадир Болгарга килгәч өйләнмәде, хәер, бәлкем ул хан кызын көтәдер? Тик Баян баһадир кяфер, ул атна саен чиркәүгә бара, муенында тәре йөртә. Баян баһадир Назлыгөлне сораса, Сәлим хан каршы да килмәстер. Әйе, каршы килмәс. Тик моңа шәех Игәнәй ризалык бирерме? Баян баһадир кяфер, Назлыгөл мөселман кызы. Сәлим хан шәех Игәнәйгә каршы бармас.

— Мөгаллимем, агам әмир Хаҗи биләмәсендәге Шайтан каласында серле манара бар икән, диләр. Манарага кергән кеше кире чыкмый икән. Миңа Баян баһадирның бер азаты әйтте, имеш, анда Шайтан үзе яши икән, дип. Шул Сөябел ятмыймы икән анда, мөгаллимем?

— Сөябел әкият егете. Шайтан каласында меңләгән кеше эшли, кирмәнне меңләгән азат саклый. Миңа калса, анда бернинди дә Шайтан юктыр.

— Илче Садак та шунда кереп киткән дә кире әйләнеп чыкмаган. Аны манарага кертмәскә иткәннәр, әмма ул берәүне дә тыңламаган.

— Кем сөйләде сиңа бу хакта, Назлыгөл?

— Сөт анам, мөгаллимем. Күптән түгел агам Хаҗи анда бер азатны кертеп җибәрә, икенче көнне аны үле килеш елгадан табып алалар...

Кәтиб Хафиз каләмен өстәлгә куйды, беравык уйланып утырды. Ни әйтә ала ул бу гөнаһсыз һәм нарасый кыз балага? Берни дә әйтә алмый. Ни әйтсә дә, ул аңа ышанмас. Кешене кеше итүче сыйфат — мохиттер. Ә бу кыз бала әнә шундый могҗизаларга ышанып үсә. Болгарның бөек елъязмачысы Ягкуб Ногман «Тарихел-Болгар» китабына кеше ышанмастай әкәмәтләр язып калдыра. Булган хәлләр белән тузга язмаганнарны бергә бутап бирә. Ул моны бик тә белеп эшли. Юкса, ул коры тел белән язылган китапны кем укыр иде? Тарих китабын йотлыгып укырга тиешләр. Менә ничәмә тапкыр күчерде инде Хафиз «Тарихел-Болгар» китабын, әле булса яңабаштан йотлыгып укый ала. Ул гынамы, укыган саен яңадан-яңа хикмәтле якларын ача. Кайбер битләрне ул юл аша укый, тасвирланган хәлләрнең асылына төшенергә тырыша. Димәк, яңа кала салынасы төбәктәге хәл хакында аңа язып калдырырга кирәк булыр, тик әле түгел, исән-имин калса...

Иртәгә Сәлим хан аңардан язманы сорар. Язманы укыганда Сәлим хан үзе генә түгел, аның янында яңа кала нигезен карарга барган һәм андагы хәлләргә шаһит булган Саксин казый, шәех Игәнәй утырыр.

Кәтиб Хафиз ялганлый башласа, Саксин казый шундук туктатыр, алай түгел, болай булды, ханым, дип. Хафиз өстенә пычрак өяр. Иң әүвәл шәех Игәнәй атылып чыгар һәм вәзир Исхакны җәлладка бирергә кушар. Аннары шәех Игәнәй кәтиб Хафизга ябырылыр, син ни карадың, дип, күзен дә ачырмас һәм шулай ук аны да җәллад балтасы астына салырга кушар.

Кайсы явызлыкны сайларга соң? Хакыйкатьне язып бирсә, Сәлим хан җәлладка бирер, чөнки халык алдында, шәех алдында үзен акларга тырышыр, ә инде булган хәлне яшереп калса, вәзир Исхакны кичермәсләр — хан да, шәех тә.

Авыр халәттә иде Хафиз. Аның әле сарайдан качып китәсе, әле Сәлим хан каршына барып, баш орасы килә. Орасы да, булган хәлне әйтәсе идә. Тик аңлармы аны Сәлим хан, шундук җәлладны чакырып алмасмы? Әйе, иелгән башны кылыч кисми, диләр. Барырга. Аның яшисе бар, ул Гали оланны Болгар тәхетенә утыртырга тиеш. Бу хәлдән исән-имин котылса, ул Гали оланны эзләргә чыгып китәр. Табар һәм Болгарга алып кайтыр. Ул дәрвиш сурәтендә каладан калага, илдән илгә йөрер, иллә Гали оланны барыбер табар...

Йә хода, ни уйлыйм. Мин беркая да китә алмыйм, китмәм дә, бу китаплардан, ышбу алиһәдән башка яшәүне күз алдына китерүе дә мөмкин түгел. Ул бу фәрештәне һәркөн күрергә тиеш. Китапларны да. Ерак Мисырдан, Сәмәркандтан, Бохарадан, Багдадтан, Өргәнечтән, Румнан — кайлардан гына килмәгән алар монда. Барысы да минем кулда, минем йөрәгемдә, иллә алар да язмышларын белмиләр, мин дә үз язмышымны белмим.

Кәтиб Хафиз китап укып утыручы хан кызына күз төшереп алды һәм күңеленә килгән беренче сүзне язып куйды. «Яшәүнең мәгънәсе имандадыр».

Иман?!

Ул тагын ни инде? Кеше имансыз яши алмый. Иман аның аңы, үе, хисе, кылганы, язмышы, тормышы, яшәү мәгънәсе.

Йә хода, тагын ни уйлыйм инде. Алай дисәң, Сәлим ханның иманы нидән гыйбарәт тә, минеке нидән гыйбарәт? Белмисең! Нәкъ менә белмәү сине алга әйдәде, китап артыннан китап укыдың, хакыйкатьнең асылын, иманның изгесен эзләдең, мәгәр ни таптың? Алдыңа куелган сораулар арткannan арта барды, иманнан читләшә башладың. Шул чакларда син, кәтиб Хафиз, болынга төштең, зәңгәр күккә бактың, сорауларыңа җавап эзләдең. Таптыңмы? Тапмадың, чөнки син үзең әнә шул серле табигатьнең бер бөртеге, тузаны. Йә алла, тагын ни уйлыйм инде! Күк йөзе кам дөңгерәкебек дөмбердәп торса да, сорауларыңа җавап таба алмассыңдыр.

Болгар иле синең күз алдында таркала, мәдәнияте, әдәбияты чит илләргә таратыла. Кайда син, Саксин каласында яшәгән Бөек Болгар шагыйре Сөләйман Бакыргани?! Сәлим хан сине илдән куды, китапларыңны Өргәнечләргә сатып җибәрде. Илдән осталар китә, аларны кенәз Андрей Боголюб колач җәеп каршы ала тора. Нигә алмасын, ул аларга мохтаҗ, аңа чиркәү өстенә чиркәү салдырырга кирәк. Кая син бөтен дөньяга табиблегең белән танылган Таҗетдин?! Вафатмы? Инде хан энесен җибәрде. Син аларны бер чапанга, бер көмеш табакка саттың. Сиңа, Сәлим хан, шагыйрь Әбү Гали килде. Алмадың сарайга. Шагыйрь халкы тыңгысыз була, мин тынычлык яратам, дидең. Ә бит ул сиңа корал тотып килмәде, Сәлим хан, шигырь китабы тотып килде, син аны исә тыңларга да теләмәдең. Имеш, синдә шигырь кайгысы юк, дөньяви хәлләрдән дә гарык. Табиб Таҗетдин «Сырхауларга дәва» китабын язып калдырды. Син аны Олуг Мөхәммәткә бүләк иттең.

Болгар ислам динен кабул иткәндә тәхеттә Айдар хан утыра. Болгарның җиденче ханы була ул. Җиде саны изге сандыр. Айдар ханның бер генә угланы да булмый, ә бердәнбер кызы, өянәге тотып, урында ята. Хан Ага-Базардагы барлык табибләрен үзенә чакырта. Сарайга йөзләгән та-

биб китерелә. Һәммәсе дә авыруны карап чыга. Әмма берәүсенең дә кызны дәваларга алынасы килмидер. Хан тирән кайгыга кала. Шунда вәзире:

— Шөһрәтлем, бүген Ага-Базарга ерак Мисырдан гарәп килеп төште,— ди.— Шуларның берсе табиб, имеш. Шуны дәшеп карасак? Мәгәр кисәтеп куясым килә, шөһрәтлем, ул табиб бөтенләй безнең өчен ят дингә табынадыр.

— Гарәп табибне сарайга алып килегез!— дип боера вәзиренә хан.

Күп тә үтми, Ага-Базарда тамаша кылучы табиб гарәпне тотып сарайга китерәләр. Каршысына китереп бастыргач, хан:

— И-и, гарәп, кайдан килдең?— дип сорый.

— Мәккә-Мәдинәдәндер.

— Кылган һөнәрең ни?— дип сорый хан.

— Табиблек кылудыр.

— Кызым хастадыр, зәхмәт кагылгандыр,— ди хан.— Шул хастага дәва тапмассыңмы?

— Әүвәл хастаны күрим, ханиям,— ди гарәп.

Авыруны карагач, гарәп хан янына әйләнеп килә һәм әйтә:

— Кызыгызга, ханиям, зәхмәт кагылгандыр. Мин аны дәвалап карармын. Тик миңа сарбан яфрагы кирәк булыр.

— Бездә ул агач күптер, килтерегез каен кисеп!— дип боера хан.

— Миңа, ханиям, яфраксыз каен кирәкми, хәзер сездә кыштыр, агачлар яфракларын койганнардыр, миңа ямь-яшел яфраклы каен кирәктер,— ди гарәп.

— Кыш көнендә бездә яшел каен табып булмый,— ди хан.— Кайдан алмак кирәк аны?..

— Иншалла, без аны табарбыз,— ди гарәп.— Килтерегез миңа каен ботакларын.

— Син, гарәп, белеп керешсәң иде кызымны дәваларга,— ди хан.

— Ханиям, әмма бер шарт куям. Кызыгызны терелтсәм, минем динемне кабул итәрсез. Динемә иман иткән көндә генә кызыгызны сихәтләтермен.

Айдар хан кисеп кенә җавап бирми, иман алыштыру җиңел эш түгел, иллә кызын бик тә яратканлыктан, гарәп белән килешергә мәҗбүр була.

Гарәп каен ботакларын җылы сулы чиләккә утырта, эссе җиргә куя да дога укый башлый. Бер дога укый — бер ботак яфрак яра, икене укый — икенче яфрак күренә. Ботакларның барысы да яфрак яргач, гарәп кызу итеп мунча ягарга куша. Мунчаны өлгерткәч, ул кызны мунчага илтергә, каен ботакларын ныклап бәйләргә һәм аңа китерергә куша. Мунчада гарәп кызны бик каты чабындыра, янә дога укый. Күпмедер вакыттан соң кыз мунчадан көлә-елмая кайтып керә. Шул хәлдән соң Айдар хан ислам динен кабул итә, аңа вәзире, сарай куштаннары да иярә. Айдар хан сихәтләнгән кызын табиб гарәпкә кияүгә бирә, ә хан дөнья куйгач, гарәп Болгар тәхетенә утыра, әмма озак яши алмый. Болгар табигате килешмиме, вафат була.

— Мин илемнән беркая да китмим, суга батып үлсәм үләм, китмим,— ди хан кызы Назлыгөл, укыган китабын бер читкә куеп.

— Ә сине, Назлыгөл, берәү дә каядыр җибәрергә җыенмый.

Кисәк барысы да асты өскә килде. Хан кызы Назлыгөл бер аягын өстәлгә куйды һәм бавы чишелгән чүәгенең җебен акрын гына бәйли башлады. Кәтиб Хафизның тыны кысылды, сулыш алырга куркып калды, күзләрен йомды. Чәчрәп торган кояшка караса да, болай ук күзләре чагылмас иде; кәтиб Хафиз мәрмәрдәй ак тән күрде, шым калып, ап-ак йомры тезгә текәлде. Кытай касәседәй ак иде хан кызының тез башы. Кинәт ачылып, шәрәләнеп калган тән күгелҗемләнеп күзне үзенә тарта. Кәтиб Хафизның башына кайнар кан йөгерде, зиһене чуалды. Ә Назлыгөл аны гүя күрми дә, әллә мөгаллиме бар аның өчен, әллә юк иде. Кинәт Кәтиб кулындагы каләм шартлап сынды. Хан кызы Назлыгөл сискәнеп китте, сәерсенеп мөгаллименә карады һәм салмак кына хәрәкәт белән ефәк ыштан ба-

лагын төшереп, ирен чите белән генә, назлана төшеп, елмаеп алды. Кәтиб Хафиз кызның елмаюын күрмәде, ул күргән сурәтне күз алдында озаграк тотарга теләгәндәй, күзләрен йомды.

— Син беләсеңме кем?— диде ул соклануын яшермичә.— Син — зәңгәр күктәге йолдыз, күл өстендәге төнбоек чәчкәсе, син...

— Мин — һавадагы карлыгач,— диде хан кызы.

— Кем шулай диде сиңа? Улмы?..

— Ул, мөгаллимем. Менә күрерсең, мөгаллимем, көннәрдән бер көнне ышбу карлыгач еракка-еракка очып китәр. Сөябел яшәгән урманнарга.

— Назлыгөл, тәүбә диген, йә аллам!

— Итмим тәүбә, итмим, мөгаллимем. Мин аны яратам, ишетәсеңме, мөгаллимем, я-ра-там!

Хан кызы борылды да китеп барды, ә кәтиб Хафиз бер ноктага текәлеп бик озак уйланып утырды һәм каләмен алды да яшерен дәфтәренә яңа кала нигезенә углан урынына эт күмелүе хакында язып куйды. Аннары ул дәфтәрне япты, яшерен урынга урнаштырды. Ханга дигән кәгазьгә бер сүз дә төшмәде, кулы күтәрелмәде. Аның күз алдыннан бер мизгелгә дә хан кызының чынаяктай ак тәне китмәде. Бирсә бирә икән кешегә гүзәллекне бу хода! Кәтиб Хафизда ниндидер күчеш булып алды. Нигәдер аның нәкъ менә хәзер, Хәсән киткәннән соң сарайга табиб булып килгән Антонийны күрәсе килде. Ул аны бер тапкыр гына румнар урамына чакырмый иде инде, гел сәбәп тапты — бармады. Шәех Игәнәйнең: яван кызлары тәннәрен сата, гүзәл булсалар да яманнар, дигән үгете гелән колак очында тора. Кәтиб Хафиз йомышчы малайны табиб Антоний артыннан йөгертте. Тегеләр көттермәде, килеп тә керде.

— Хан кәтибенә ни кирәк булды, авыртамы, бер-бер нәрсә булдымы, әллә гашыйкмы,— дип килеп керде Антоний шаяра-көлә.

— Мин сагышланам, Антоний дус. Нидер кыласым килә, каядыр барып гөнаһ кыласым килә...

Тәҗрибәле Антоний кәтиб Хафиздагы күчешне шундук сизеп алды, елмаеп, бертын аның борчулы йөзенә карап торды:

— Җыен, мин сине бүген җәннәткә алып барам. Беләсеңме,— дип иелә төште табиб.— Анда син генә түгел, Сәлим ханның да булганы бар. Кыюрак, кыюрак, дускай!

Кәтиб Хафиз тәвәккәлләде. Ул беренче тапкыр яваннар урамына барырга булды. Табиб Антоний аңа үзенең чикмәнен бирде, кулына таяк тоттырды. Хафизны берәү дә танырга тиеш түгел, шәех Игәнәй күрсә, таш аттырып үтерттерер. Һич булмас димә. Хак анысы, Сәлим хан берәүгә дә, яваннар урамына йөрмә, дип әйтми, тик чиркәүгә генә кермә. Чиркәүгә керүчеләрне шәех мөридләре дүрт күзләп күзәтәләр.

— Хан кәтибе Хафиз, изге җанмы әллә син. Ир уртасы кеше, кызлар кочагын да татыганың юктыр әле?..

— Мин изгеләр өчен изге, яманнар өчен яман, Антоний.

— Сине бүген аулак өйгә алып барам. Акча алдыңмы?

— Бар булган байлыгым һәрчак үз янымда, Антоний. Мин берәүдән дә ким түгел, минем дә күз төшкән кешеләрем бар. Мәгәр аларга белгертмим. Менә син ханбикә Зөбәрҗәткә күз атып йөрисең һәм моны бар кешегә дә сиздереп эшлисең.

— Ялгышасың, кәтиб, ханбикә мине кызыксындырмый. Мин ханның кызына гашыйк. Өметсез гашыйк, мәгәр гашыйк. Мин аны күрер өчен генә дә әллә ниләрем бирер идем. Әмма хан кызы миңа күтәрелеп тә карамый. Ул башканы ярата. Анасы сизенә сизенүен...

— Анасы барысын да белә, Антоний. Хан кызы, беләсең килсә, оста Дәүранны ярата. Фаҗигагә дучар булуы бар аның, тиңе булмаган фаҗигагә.

— Әйе, кызганыч бетәр хан кызы Назлыгөлнең ышбу мәхәббәте. Оста егет өчен дә, аның өчен дә.

— Күрәзәме әллә син, Антоний?

— Чын мәхәббәтне яшереп булмый, кәтиб Хафиз. Ул гүя җәй башындагы сандугач, я сайрап яши, я үлә...

Кояш баеп эңгер иңгәнме, кибетчеләр чалтыр-чолтыр ишекләрен яба, элмәләргә богау йозакларын эләләр. Урамнарда көндезге ыгы-зыгы кими, ә менә аш-су йортларында шау-шу арта бара. Көнозын кибет саклаган сатучылар аш-су йортларына юнәлә, керә-керүгә, таныш-белешләрен очратып, кычкырып исәнләшә, бер-берсенә мактана, зарлана башлыйлар. Кич җиттеме, рум, әрмән урамнарында җанлылык; бай сәүдәгәрләр аулак өйләргә ашыга, алданрак барып, гүзәлрәк кызны алырга өметләнәләр. Хәмер каба-каба тымызык кына ярымкараңгы бүлмәдә берәрсе янында утырулары үзе бер гомер дип уйлауларыдыр, күрәсең. Андый аулак өйгә керү шактый бәһа торса да, сәүдәгәр кеше моңа бара, чөнки Ага-Базардагы табышын кая булса да илтергә тиештер — янчыктагы алтыннар этәч булып кычкыра. Аннары бераз кылтаебрак, назланыбрак, сылу гәүдәсен уйната-уйната сиңа ризык-ныгъмәт китергән кызга карап торулары сирәк тия — өйдә гаиләсе, хәләл җефете, балалары көтә. Хатыны аны беркайчан да елмаеп каршы алмый; ә монда исә, ярым ачык күкрәкләрен күрсәтеп, алсу-кызыл күлмәк — хитуннарын бер иңеннән төшереп үк җибәргән — күзне котыртып, җанны аздырып тора, җитмәсә, ерык итәк чабуын гелән юри ачып җибәрә, анда күренгән хикмәтләрдән тәмам җаны актарыла сәүдәгәрнең. Сәүдәгәрләрнең күбесе аулак өйдә көнлек табышын калдырып китә, чөнки каршысында авызы белән кош тотарга әзер торган кыз кулыннан килгәннең барысын да эшли, ә һәрбер кылган эшенә кулын суза — алтын белән түләнергә тиеш.

Аулак өйдә генә түгел, яваннар урамында да кәтиб Хафизның тәүге тапкыр булуы. Аулак өйгә ул курка-курка гына килеп керде. Аның ишеткәне бар иде, монда булып кайткан ир-атлар — хан азатлары, авыз суларын корытырдай итеп, хикмәтле хәлләргә тап булулары хакында сөйлиләр. Теләсә-теләмәсә дә кәтиб Хафиз аларны тыңлый һәм үзалдына: «Азгыннар»,— дип кенә куя торган иде. Мәгәр үзе беркайчан да яваннар урамына аулак өйгә килермен дип уйламаган иде. Бүген исә килде, керде һәм ишек төбендә туктап калды.

Өйдә исле май тәмнәре таралган, ишек катында авызында бер теше калмаган карчык утыра. Ул Антонийга күз төшереп кенә алды да түрдә утыручы бер кызга бармагы белән генә ишарә ясады, янәсе, кил, сиңа бу адәмдер. Ярымкараңгы почмакта утырган кыз иренеп кенә күтәрелде, бераз гәүдәсен уйнатыбрак Хафизга таба килә башлады.

Йә хода, ни тамаша килә — су өстендә йөзгән аккош диярсең. Чү, кисәк Хафиз күз алдында хикмәтле хәл булып алды. Аңа таба яван кызы түгел, гүя ки, хан кызы Назлыгөл килә иде. Бу ни хәл инде! Хафиз күзләрен йомды, яңадан ачты. Хан кызы түгел, яван кызы, иллә гүзәл, бераз һавалырак кылана, иллә гүзәл.

Кыз килде дә Хафизны култыклап алды һәм шул мәлдә үк иясенә әверелгән кәтибнең биленә таккан янчыкка суккалап:

— Бер алтының карчыкка ташла,— диде.

— Ташла-ташла,— диде кызны куәтләп табиб Антоний.

Хафиз бер урынына ике алтын ташлады; моны, сукыр булса да, карчык күрде, елмайды, кызга ым какты. Кыз кәтибне култыклап алды да түр якка алып китте. Кызның ефәк күлмәге су коелгандай шаулый, үзеннән татлы исләр килә.

Әллә соң шул буламы җәннәт дигәннәре? Нигә ул моңа кадәр бирегә бер тапкыр да килмәде? Әйе, мөселманнарга монда килергә ярамый, шәригать кушмый. Нигә соң бай мөселман сәүдәгәрләре бер дә куркып тормый, сакта торучы шымчы егетләргә бер-ике алтын ташлыйлар да рәхәт чигәләр.

Кыз аны түр яктагы өстәл янына утыртты, аннары Антонийны китерде һәм чыгып китте. Бераздан ул табакка хәмер, җиләк-җимеш, алма салып китерде. Антоний чокырларга хәмер койды. Хафизны кыстый башлады.

— Тот әйдә, хан кәтибе. Тот-тот, тартынма.

Кәтиб Хафиз бер чокыр хәмерне эчеп куйды, хәмер аңа бераз әчкелтем, усал кебек тоелды, илләә бераздан бу хәл үтте. Аның янына кыз килеп утырды. Хафиз аңа да хәмер салып бирде.

— Эч-эч,— диде Антоний.— Мин сиңа мөселман дөньясындагы иң изге кешене алып килдем. Ярат. Гомер буена оныта алмый интексен!

— Интекмәсәм?— диде бераз кызмачаланган Хафиз.

— Интегерсең, хатын-кыз хәмердән дә яманрак ул.

— Хәериең, хәериең,— диде кыз елмаеп.— Ул миңа ошый, Антоний, ошый.

«Димәк, син, кызыкай, төркичә дә сукалыйсың. Яхшы, мин сине яраттым, ди. Шуннан ни? Өйләнергәме?! Муеныма бау салыргамы? Чү инде, кызыкай, кәтиб Хафиз диләр аны, юк-бар кармакка эләкми ул, менә кармагың алтын булса икән ул, әйтик, хан кызы Наз...

— Син исермә,— диде Антоний.— Исермә. Мин киттем, хуш!

Хафиз табиб Антоний артыннан кузгалмакчы итте, әмма аны кызы култыклап алды, кире утыртты.

— Син мине ярата, мин сине ярата.

Кәтиб Хафиз кызга карусыз буйсынды. Кисәк аның елыйсы килеп китте. Кыз, нидер сизенепме, аны түр якка алып керде, киң сәкегә утыртты. Сәкедә болан тиресе, түр башта тар гына ике мендәр, өй эче караңгы, почмактагы шәм яктысы түр якка килеп җитмичә, бүленеп кала кебек.

Кай ягы белән ошады икән хан кәтибе бу сылуга?.. Кылыч борынлы, тирән утырган күк күзләр, дулкынланып торган кара чәч, сыек, чандыр гәүдә. Бер дә кызыгасы түгел иде кебек хан кәтибе Хафизга, юк, чибәркәй аңа сөлек кебек ябышты. Кыз исә мөлдерәп торган тулы гәүдәле, калку янбашлы, елышканда иң элек күкрәге килеп төртелер, кара күзләрендә әллә сагыш, әллә назга сусау — һич аңламалы түгел. Кыскасы, тора-бара кыз Хафиз өчен күктән төшкән алиһәгә әверелде. Кызның өстендә ерык изүле күлмәк, аякларында челтәрле чүәк, бауларын балтырларына җиткереп урап бәйләгән. Кара чәченә ап-ак гөлҗимеш чәчкәсе кадаган.

Нәкъ менә хан кәтибе Хафизны көткән идеме ул? Юк, әлбәттә. Күр инде бу язмыш дигәнне. Ни әйтергә тиеш Хафиз аңа? Шәмне сүндер дисенме? Ничек алай әйтмәк кирәк! Бер азат әйткән иде аңа, ханбикә Зөбәрҗәткә өйләнгәнче, Сәлим хан да бирегә килгәләгән, имеш. Кич эңгер ингәч, әрмәннәрнең кара чикмәнен кияр иде дә яваннар урамына юнәлер икән.

Табиб Антоний! Нинди максат белән китердең син хан кәтибен ышбу алладан каргалган өйгә? Нинди максат белән китерсәң дә, табиб, сиңа рәнҗемәм. Син күзләрем ачтың, ышбу сылу кочагына китереп ташладың. Рәхмәт сиңа. Тик белмим, тансыкмы мин аңа? Тансык булсам да, булмасам да, минем дә сөясем, сөеләсем килә. Ханга ул яңа сарай салынасы төбәктә булган хәлләрне язып бирә алмады. Язмас та. Язса да, язмаса да, аны Кара Пулатка алып барырлар, хөкем итәрләр. Кем белә, бәлкем аңа дәҗҗал балтасы астына ятырга туры килер. Бу булыр иртәгә, бүген исә аның кочагында алиһә. Кыз аңа сыенган да нидер көтә.

Хафиз хәтта кызның исемен дә сорамады. Нигә аңа бу җариянең исеме? Белде ни дә, белмәде ни. Аннан ни үзгәрер? Шулай да нигә икән бу кыз биредә? Ни китерде икән бу сылуны ышбу аулак өйгә? Хафизның күңеленнән бер җыр калыкты. «Асыл ташлар җирдә ятамы, киткән кызлар кире кайтамы?!» Әйе, кире кайтмый киткән кызлар. Акча китергәндер сине бирегә, кызыкай.

Хафиз кисәк күтәрелде дә түр яктагы ачык ишектән бакчага чыкты. Кыз аны тотмады, туктатмады, ымсынмады, тын гына ятып калды.

Төнге күк йөзен йолдызлар чуарлаган, һәр йолдызда кеше язмышы, диләр. Тәрәзәдән төшкән шәм яктысына керпе килеп туктады һәм тавышсыз гына куаклар арасына кереп китте. Якында гына байгыш кычкыра башлады. Тынып-тынып, үз тавышының кайтавазын тыңлый-тыңлый кыч-

кыра байгыш. Ниһаять, байгыш та тынып калды. Колак янына житеп йөрәк тибә. Ай яктысында бакча гүя көмешкә төренгән. Аяк астындагы чәчәкләр хуш ис бөрки. Чәчкә үстерергә ярата яваннар. Шуның өчен яван базарга чәчкә тотып чыгар, болгар итек тотып, урыс кылыч тотып, дигәннәр. Барысына да чәчкәсе дә, итеге дә, кылычы да кирәк, бәхәссез.

Аңа кемдер килеп сарылды. Инде жанга таныш булып өлгергән ис тойды Хафиз — кыз килеп сарылды. Ул йомшак куллары белән аның муеныннан кочаклады, кайнар иреннәрен битенә тәрәде. Хафиз бермәлгә шым булды. Бу ни бу?! Кызның кайнар сулышы янында гына лабаса.

Хафиз ничек кызны кулларына күтәреп алганын сизми дә калды. Өйгә алып керде, сәке янында аягына бастырды, кызның өстеннән ефәк күлмәк шаулап идәнгә коелды. Кабалана төшеп, Хафиз жиләнен, күлмәген салып атты, кызны күкрәгенә кысты һәм кисәк аркасы өшеп киткәндәй булды — ике арага кызның тәресе кысылды. Салкын иде тәре, сулышны кыса кебек иде. Кыз жиз тәрене иңе аша артка ташлады. Кызның шашынып назлавы, сөюе кәтиб Хафизны әсир итте. Кинәт ул, гүя күккә ашты, гүя гомере буена эзләгән йолдызын тапты. Ә бит күпме эзләде ул йолдызны, күпме килер-килер дип бер көтте, ә ул менә икән, яван кызы...

Хафиз тиз генә аңына килә алмый ятты. Төшендәме, өнендәме бу хәл? Их, Антоний, Антоний, изге кешедер син, изге булмасаң Хафизга шушындый яхшылык кылыр идеңме? Алдыңа тезләнәсем килә, Антоний. Рәхмәт сиңа. Кеше үз бәхетен үзе табарга тиеш, диләр. Мин аны таба алмадым, ә менә бүген таптым.

— Син кайнар ир, — диде кыз. — Мин сине яраттым. Алып кит син мине моннан. Мин сиңа күп-күп балалар табармын, берсеннән берсе матурларны, батырларны...

Хафиз тагын кызны кочагына алды. Тәүге хис ташкыны аны янә өнсез итте, янә ул күккә ашты. Күз алдына хан кызы Назлыгөл килеп басты. Гүя: «Ул ялганламый, мөгаллимем, ул сине чынлап та ярата», — ди сыман иде. Хафиз күз алдына килгән сурәткә гажәпләнә калып, кызның тез башына кулын куйды. Йомры, түгәрәк иде кызның тез башы...

Бик тиз таң атты, төнозын керфек-күзен йоммаган Хафиз таң алдыннан гына йокыга китте. Төшендә ул янә хан кызы Назлыгөлне күрде. Назлыгөл мөгаллименең муенына сап-сары гәрәбә төймә такты. Хафиз карышмады...

Таң атып, яктыра башлаганда Хафиз сискәнеп уянып китте һәм, сикереп торды да, аннан-моннан киемнәрен табып киенде. Аңа моннан тизрәк югалырга кирәк иде. Сәлим ханның азатлары яисә шәех Игәнәйнең мөридләре күрүләре бар иде.

Кәтиб Хафиз тын гына йоклап яткан кызның төшендә кем беләндер сөйләшә-сөйләшә елмаюын карап торды. Ул сак кына чыгу ягына таба кузгалды, алгы өйдә тешсез карчык йоклап утыра, тез өстендә алтын тәңкәләр салган табагы. Тышкы ишек ярымачык, йорт яклап пышан гына сөйләшкән тавышлар ишетелә. Нидер исенә төшеп, кәтиб Хафиз кире борылды, йомарланып яткан кыз янына килде, билендәге янчыгын ычкындырды да кызның мендәр астына тыкты. Янчыкта кимендә йөз алтын иде, теләсә, бу бәһагә кыз үзенә мөстәкыйль тормыш кора ала иде. Хафизга алтынның кирәге калмады. Бүген-иртәгә аның язмышы хәл ителер.

Хафиз ашыга-кабалана йорттан урамга чыкты, тиз-тиз сарайга таба китте.

Яктырып килә. Идел яклап томан күтәрелә, болын яклап ат көтүчеләренең һай-һайлап ат куалаганнары ишетелә, ишегалларындагы жимеш агачларында сандугачлар сайрый. Жәй башы үтеп бара, тиздән сандугачлар да сайраудан туктар, бүген-иртәгә Хафиз да. Әйе, хан аны

кичермәс, кәтибе күпне белә. Менә Хафиз сарай куштаннары яшәгән урамны үтте, кала диварына житте. Каравылбаш аны теләр-теләмәс кенә уздырып жибәрде.

— Кайдан болай бик соңлап, хан кәтибе?

— Син сорама, мин әйтмим, каравылбаш. Мине бүген Кара Пулатта дәжжал балтасы көтә...

— Яваннар урамында булган өченме, кәтиб. Беләсең килсә, Зөбәржәт ханбикә килгәнче хан үзе дә ул тарафка баргалый торган иде. Курыкма, кәтиб.

— Ә мин курыкмыйм, каравылбаш. Гомере кыл өстендә торган кеше ханнан курка буламы?

— Сөйләмә тузга язмаганны, кәтиб. Сиңа балта күтәргән дәжжалның кулы корыр.

— Язмыштан узмыш юктыр, каравылбаш. Сер булмаса әйт әле, яваннар урамына шәех Игәнәй дә баргалыймы?

— Гөнаһка батасым килми, кәтиб, күргәнем булмады. Ә менә мөридләре баргалаштыргалый. Тик мин әйтмәдем, син тыңламадың, кәтиб. Кеше сүзе кеше үтерер. Тукта әле, тукта дим. Бер хикмәтле хәл турында әйтми булдыра алмыймдыр. Хикмәтле хәл шул, кәтиб, менә ай була инде, сарай диварында Шайтан күренә башлады. Ханга әйткән идем, шаркылдап көлде генә. Ә бер дә көлке хәл түгел, менә үз күзләрем белән күрдем. Әле адәм сурәтендә күренә, әле бөтән ни шунда, дүрт аяклы хайван да кебек, адәми затка да охшап китә. Азатларның котлары ботта, каравылга чыгарып булмый башлады үзләрен. Әллә, мәйтәм, ахырзаман киләме, ахырзаман якынайса, ул шайтан дигәннәре күзгә күренә башлар, ди бит. Тагын бер хикмәтле ягы бар Шайтанның. Нәкъ менә хан кызы бакчага йөрергә чыккач диварда күренеп китә. Тик шундук юкка чыга. Хан кызы Назлыгөлне оста Дәүранга гашыйк икән, диләр. Әллә, мәйтәм, шул кызны сагалыймы бу Шайтан дигәне? Ул оста Дәүранны пәйгамбәр нәселеннән икән, диләр. Әйтми генә йөри икән, теге вакытта мең ташчы арасыннан берүзе исән калган. Димәк, чын, пәйгамбәр нәселеннән. Бер тиле азат моңа ташлана, кылыч белән чапмакчы була Шайтанга. Шайтан аңа бер генә кизәнә, азатның кылычы килә дә төшә, аннары өстендәге киеменә ут каба. Дөрләп яна башлагач кына Шайтан юкка чыга. Шуннан соң ник бер азат аның ягына карасын. Йөри икән диварда — йөрсен, күзәтә икән хан кызы Назлыгөлне — күзәтә бирсен.

— Менә нәрсә, каравылбаш, оста Дәүранга хан кызы гашыйк, дигән сүзгә ышансам да, хикәятнең икенче яртысы шыр ялгандыр. Сарай диварына менүләре ансат дисеңме?

— Озын-озын таягы бар икән, шул таякны диварга тери дә йөгерә-йөгерә менеп китә икән. Шайтан инде, шайтан.

— Белеп торсаң иде, каравылбаш. Оста Дәүранны Сәлим хан зинданда яткыра. Кол ул, хан колы. Кол кешегә кияүгә бирә буламы хан кадәр ханның гүзәл кызын? Аннары без барыбез да хан колыдыр, каравылбаш. Син дә, мин дә...

— Кәтиб хан колы буламы, сөйләмә тузга язмаганны, Хафизжан.

— Кем соң ул кол, каравылбаш. Ике аяклы хайван, диган борынгылар. Ярый, каравылбаш, төшер асма күперенне.

— Һәй, кем анда манарада, төшер күперне! — дип кычкырды каравылбаш. — Карале, Хафизжан, мин ул Шайтанны тотсам, хан миңа ни бирер иде икән?

— Кызын, каравылбаш, Назлыгөл атлы гүзәлләрнең гүзәлен.

— Ә мин аны чынлап та тотсам, кәтиб?

— Шайтан изге жан, тәмуг сиңа моның өчен, дөрләп-ялкынлап, улап-үкереп янган тәмугтыр.

Каравылбаш ни әйтергә белми аптырады да калды, ул арада асма күпер төште, Хафиз өенә ашыкты. Бүлмәсенә кайтып керүгә, тән-жанында гаять дәрәжәдә йончу тоеп, чишенми-нитми ятты да йокыга китте.

* * *

Бусагабаш Камай аның бүлмәсенә песи кебек аяк очларына баса-баса гына керде. Хафизның котын алырга иде исәбе, иллә якынрак килүгә, күрде: кәтиб муенында чылбырга таккан яваннар тәресе. Бусагабаш Камай бертын ачкан авызын ябалмый торды. Йә хода, ни бу?! Кәтиб, шайтан күтәреп алып китсә дә, уянмас чиккә җитеп йоклый, нечкә чылбырга таккан тәре бер якка шуып төшкән. Мәгәр тәре, күзләре хак күрә. Камай тамак кырды, төшендә түгелме дип, үз-үзен чеметеп карады — юк, төшендә түгел иде.

Кәтиб Хафиз муенында яваннар тәресе, хан кәтибе чиркәүгә йөри башлаган!

Бусагабаш Камай әпен-тәпен артка чикте, сак кына чыгып шылды. Ул чыгып китүгә, кәтиб Хафиз бүлмәсенә табиб Антоний килеп керде һәм керүгә изрәп йоклап яткан кәтиб муенындагы тәрене сак кына ычкындырды, кесәсенә тыкты, аннары бертын кәтиб йөзенә карап торды. Уятмакчы итте, әмма ул бөтенләй башка эш белән килгән иде, ахры, ничек килеп кергән булса, шулай ук тиз генә чыгып та китте.

Ул арада сулышына кабып, Сәлим хан каршына бусагабаш Камай килеп капланды.

— Шөһрәтлем...

— Ни булды, Иделгә ут каптымы әллә? Кая кәтиб, нигә алып килмәдең?!

— Ханиям, аның муенында...— Бусагабаш Камай пышылдауга күчте, ханга якынрак килде, аяк очларына гына басып, колагына үрелде. — Аның муенында тәре, яваннар тәресе.

— Яваннар тәресе?! — дип кайтарып сорады хан. — Нинди тәре, кем муенында?

— Кәтиб Хафиз муенында, шөһрәтлем.

— Кайда ул!

— Бүлмәсендә җәйрәп йоклап ята, муенында...

— Җитәр! Ишеттем! Тукран түгелдерсең бит?!

Сәлим хан тәхетеннән торды, титаклый-титаклый бусагабаш Камайга иярде. Әйе, Сәлим хан да кеше иде, адәм баласына хас кызыксыну чире аңарда да бар иде.

Килеп керделәр, кәтиб Хафиз баягыдай җәйрәп ята, изрәп йоклый. Мәгәр муенында бернинди дә тәре юктыр. Бусагабаш Камайның, үте сытылгандай, йөзе чытылды. Сәлим хан бер сүз әйтмәде, ишеккә таба борылды, Камай аны узып, ишекне ачмакчы итте, иллә хан аның артына шундаен иттереп китереп типте ки, теге мескен лып итеп артына утырды һәм үкереп җибәрде.

— Аяклы каза, күзең тонмагандыр бит?! Нинди тәре?!

Бусагабаш Камай теләсә нинди мыскылга да түзәргә әзер иде, гадәттәгечә дәшмәде, ханның итек очын үбәргә үрелде.

— Кит, җан көеге, күземә күренмә!

— Ханым, кичер тилеңне. Күземә күренде микәнни...

— Югал күз алдымнан! Һәй, тукта. Бар, уят кәтибне. Кара Пулатка барсын!

Сәлим хан, ни көләргә, ни еларга белми, тәхетенә менеп утырды. Менә ахмак дисәң дә ахмак инде, кәтиб муенында тәре күргән, имеш. Шунда Сәлим ханның келт итеп исенә төште. Тукта, ул үзе дә бер тапкыр шул көнгә калган иде түгелме соң? Әйе, яваннар урамына барды, аулак өйгә керде, мул итеп алтын акча өләште, соңыннан кайтышлый өянәге тотып яткан хатыны янына кагылды. Хаста ханбикә аның муенындагы тәрене күрде дә ике куллап шуңа ябышты... Әйе, булды андый хәл. Тик кәтиб Хафиз да бу хәлгә дучар булса, тәресен кем алган? Ә бит Камай күргән... күргәндер... Куйсана, үткән эшкә салават. Бүген ул вәзир Исхакны хөкем итәчәк. Кәтиб Хафиздан да сорау алыр-

лар. Астыртын әл-казый Ишкул төбенә тоз кояр, иллә хакыйкатьне ачтырып салдырыр. Ишкул самими кеше, нәкъ бала инде, иллә куркыныч бала, рәхимсез, шәфкатьсез. Аны теләсә кем котырта ала, теләсә кем өстерә ала, хан турында әйтеп торасы да юк. әл-казый Ишкул, җидегә ярылып, җидегә ялганса да, хан теләген җиренә җиткереп баш карыр. Ә шулай да вәзир Исхак кызганыч. Акыллы вәзир иде. «Иде» дип тә уйлый башладым вәзирем хакында. Минем аны дәҗҗал кулына бирәсем килми, ә шулай да бирмичә дә булмастыр. Вәзир Исхак Болгар өчен кирәк кеше иде, иллә нәкъ менә аның аша Сәлим ханга күләгә төшкәләде. Ил иминлеккә тиенсә, ханны түгел, вәзирне мактадылар. Миладн белән 1164 елда Болгарга яу килеп, Ибраһим каласын ала язган кенәз Андрей Боголюб белән уртак тел таба алды. Вәзир Исхакның бу сыйфатларын ханбикә Зөбәрҗәт тә, шәех Игәнәй дә инкяр итә алмыйлар. Мин дә инкяр итә алмыйм. Иллә ни кылмак кирәк, вәзир Исхак исән калганда минем атыма күләгә төшәчәк. Бер оныгыма мин тәхет вәгъдә иттем һәм ул олан кала нигезенә корбан ителергә тиеш иде. Бу чараны вәзир Исхак үзе мәҗбүр итте кылырга, үзенә үпкәләсен. Юкса Болгарда ата улны, угыл атаны, туган туганны үтереш китәр иде. Әбү Талиб углы Галинең кыюсызлыгы аркасында өмәвиләр Галига каршы сугыш башлый. Галидән өмет җуйган уникe мең сугышчы, өмәвиләр ягына күчә. Тарафдарлары исә Мөхәммәт пәйгамбәрнең кияве Галине үтерергә мәҗбүр була. Әнә шул хәл ислам дөньясын икегә аера да инде. Бу хәл һиҗри белән 33 елда, милади белән 661 елларда була. Бүген һиҗри белән 573 нче ел, милади белән 1177 ел барадыр. Мәгәр Мисырдагы хәлләр ислам төбәгенең һәр җирендә булырга мөмкиндер. Тәхеткә бер олан гына утырырга тиеш. Димәк, хан буларак, мин хаклы булып каламдыр. Тәхет хакында сүз барганда вәзир башы белән исәпләшмиләр. Ислам дине ике нәрсәгә таянып эш итә: Муса һәм Гайсә пәйгамбәр кануннарына. Адәм баласы Муса пәйгамбәрдән дөньяда яшәргә өйрәнсә, Гайсә пәйгамбәр кануннары буенча рухи яктан күңелен йомшарта: дөньяга ул кунакка гына килгән, нәфесен тыярга, күбрәк ахирәт хакында уйларга тиеш, дип өйрәнә. Мөхәммәт пәйгамбәр исә бу ике пәйгамбәрнең тәгълиматын бергә кушарга омтылган. Нәкъ менә шуның белән бик күпләрне үз диненә ышанырга мәҗбүр иткән. Мөхәммәт безнең иң олуг пәйгамбәребездер. Йә алла, мөхәммәдерәсүлулла. Әстәгъфирулла, ни сөйлим. Ярый әле аллаһы тәгалә: салынган өй җимерелсен, туган кеше үлсен, дип әйткән, юкса, ни кылыр иде бүген Сәлим хан. Хәтта вәзир Исхакны да хөкем итә алмас иде.

## 15

Кояш чыкты. Вәзир Исхакны эзләп бер дистә азат килде. Алар аны ашыктырмады, Сәлим хан, качып китмәгәе, дип курыккан, имеш. Тик кая? Вәзир Исхак беркая да качып китәргә җыенмый. Сәлим хан язган хат кәтиб Хафиз кулында. Хәтта акка кара белән оныкларның берсен яңа кала нигезенә корбан итәргә дигән фәрман бар, ә фәрманны хан үзе язган, хәтта мөһерен дә суккан. Вәзир Исхак үзен үлемгә әзерләде, шул ук вакытта исән калудан да өметен өзмәде. Аны бары тик бер сорау изаладыi: ни өчен Сәлим хан аннан котылырга тели? Нинди хилафлык кылды ул аңа?! Баян баһадир аңа хан фәрманын тапшырды, кәтиб Хафиз аны укып чыкты, барысы да ишеттеләр, барысы да эшнең асылын аңладылар, тик хан оныклары гына бу хәлне уен итеп кабул итте. Ә ул уен түгел, авыр фаҗига иде, аның тарафыннан уйланып табылган, хан тарафыннан хупланган фаҗига иде.

Азатлар унбашы вәзир Исхакка хан фәрманын җиткерде. Вәзир сарайга чакырылган иде. Азатлар килү табигый хәл, аларны Сәлим хан әлек тә җибәрә иде. Янәсе, вәзиренең иминлеген саклый.

— Сарайга мин үзем барырмын, унбаш, — диде вәзир Исхак.

— Баш өсте, вәзир. Килә күрегез, — дип азатларын ияртkән унбаш китеп барды.

Вәзир унбер яшьлек углын дәштерде. Тыштан чабып кергән баланың билендә кылыч, кулында ук-җәя күреп, Исхак йөзен чытты. Яратмый иде хәрбиләрне, ләкин бу аның үз углы иде. Ул каршына килеп баскач, вәзир аның кылычын, ук-җәясен бер читкә алып куйды, иңбашына кулын салып, күзләренә карады.

— Углым, син ханның сарай мәдрәсәсендә укыйсың. Арагызда иң оста мәргән кемдер?

— Сәлим хан оныгы Булаттыр, атам.

— Хан оныгы Булат, — дип кабатлады вәзир Исхак. — Ә син, син аңардан калышасыңмы?

— Ул остарак ата, очкан кошларга тигезә, атам. Аны Җик Мәргән белән чагыштыралар. Мәктәпне тәмамлаганда мин дә Булат кебек өйрәнермен, атам. Болгарда бер мәргән булырмын.

— Болгарда бер мәргән, — диде вәзир Исхак нидер әйтергә җыенып. — Син мәргән түгел, илче буласы кеше. Син иң оста илче булырсың. Мин сиңа бик күп китаплар калдырам. Укы. Ага-Базарга ешрак чык, чит ил сәүдәгәрләре арасында йөр. Тыңла, ни сөйлиләр, дөньяда нинди хәлләр бар, ишеткәнең мыегыңа ура.

— Минем мыегым юк, атам.

— Мыек булыр, бик тиз булыр ул. Акылың югалтма. Мыек үсәр, акылың җуйма. Анаңа әйт, әтием сарайга китте диген.

Вәзир Исхак углын күкрәгенә кысты, чәчләреннән сыйпады.

— Мөгаллимем миннән китапларны кычкырып укыта, «яле, кычкырып укы әле, Гаттар, ошбу сүрәне», ди.

— Игелекле бул, — Вәзир Исхак аны күкрәгенә кысты. — Укы, тырыш. Урыс, фарсы, гарәп, чин телләрен өйрән. Яваннар арасында ешрак бул. Шул булыр сиңа атаң васыяте, углан Гаттар. Инде бар, уйна...

Гаттарның йөгереп чыгып киткәнен карап торды да Исхак сарайга юнәлде, иллә килеп җитәрәк Кара Пулатка таба китте. Соңгы мәлдә генә хан алдына баш иеп барасы килми иде аның. Кылынасы кылынды, укенәсе юктыр. Бүген аны хөкем итәрләр. Иң уртада Сәлим хан утырыр, уң кулында әл-казый Ишкул, сул кулында Саксин казый, аз гына читтәрәк Баштак казый булыр. Шәех Игәнәй килеп кергән хәлдә Саксин казый Баштак казый янына күчеп утырыр. Шәех Игәнәй вәзир Исхакны беркайчан да яратмады. Нишләп яратсын, ди. Вәзир Исхак Андрей Боголюб кенәз белән Сәлим хан арасында тынычлык урнаштырды, ул гынамы, хан угланы Илһамга кенәз токымыннан Мәрьям атлы кәләш алып кайтты, кан кушудан Булат атлы углан туды, аның тәхеткә утыру куркынычы бар. Әлегә ни мөселман, ни христиан булу-булмау мәсьәләсен ачыклап җиткермәгән Сәлим хан оныгы Булатны Баян баһадир тәрбияли. Баян баһадир чиркәүгә фанатик дәрәҗәгә җитеп йөрмәсә дә, баргалый, еш кына епископ Габбас белән бер табында утыра. Әнә шулай Болгарда ике якка аерылып барган сарай куштаннары туып килә. Сәлим хан моны күрми, күрепме күрмәмешкә сабыша, ә бит моның Болгар өчен бик тә хәтәр бетүе бар. Әйе, вәзир Исхак хан оныгын яңа кала нигезенә корбан итеп кайтты, шәех Игәнәй моның өчен аны кичермәс, ул, мөгаен, Гали угланга өмет иткәндер. Ун яшеннән яттан корьән сүрәләрен укыган Гали шәех Игәнәйгә кадерлерәк булгандыр. Шулай икән, шәех Игәнәй аны ничек тә батырырга тырышыр. Ә вәзир Исхак батмаска маташыр, мәгәр моннан берни дә үзгәрмәс.

Вәзир тирә-ягына күз ташлады. Аның кай тарафка һәм ни өчен барганын белгән кебек, очраган бер кеше вәзиргә ихтирам белән баш ияләр. Шул ук вакытта Исхак чамалады: күпләре аны, гүя күрмиләр дә, үтәләр дә китәләр. Ханның ат карауччысын гына күр син, әйтерсең, яныннан вәзир үтеп бармый, һаман ат тарау белән мәшгуль. Ат та иясенең изгелек эшләвен белгән кебек тик тора. Шул ук вакытта ул бераз абайлый бул-

са кирәк, чын иясе бу кеше түгел, бөтенләй башка, ул бик сирәк атлана аңа, әмма атланган чакта җилле йөри, кирмәннән чыгып, болыннарны әйләнеп кайткалаганы да бар. Иясе аның беркайчан да бирүзе генә йөрми, аны һәрчак ике-өч дистә азат озатып, алар аннан һәрчак кала төшеп йөрерләр, беркайчан да иясен узмаслар.

Хан әмере белән вәзир Исхак туры сарайга барырга тиеш иде, ә ул аны узып, Кара Пулатка юнәлде. Чөнки Сәлим хан аны барыбер Кара Пулатка озаттырган булыр иде. Иң яхшысы үзең барып керү. Дошманнар шатлансын, дуслар коралларын барласын, чөнки бүген минем башым киссәләр, иртәгә аларныкын кисүләре бар. Алла саклаганны гына сакларлармын, дигән. Яңа кала нигезен карарга барганда Сәлим хан илбактысы Таймасның кешеләре дә бар иде, вәзир Исхак сукыр түгел, барысын да күрде, гәрчә ул көнне каравыш кызы янында аунап чыкканнан соң башы авыртып, күңеле болганыбрак торса да.

Әйе, вәзир Исхак зур хата ясады. Бу хатасы хакында оныкларына язып калдырасы иде дә бит, юк, өлгермәде, һич югы гыйбрәт алсыннар иде. Бәлкем әле кәтиб Хафиз язар. Язарга тиеш. Аны да Кара Пулатка тотып китермәсәләр. Аны да китерсәләр, кем дияргә инде бу Сәлим ханны? Кәтиб Хафиз кебек изге җанны Болгарда көндез шәм яндырып та таба алмыйсың. Хан фәрманы Хафизда. Кәтиб Хафиздамы, Саксин казый кулына эләкмәдеме? Ни генә булмасын, дөрләп янган учактан очып чыккан аждаһаны барысы да күрде, бу хәлне Саксин казый да инкяр итә алмас. Шулай булгач, нигә куркырга тиеш ул? Шәех Игәнәйнең мөридләре кадим заманнан кергән йолаларны халык күңеленнән җуярга тели, әмма халык үткәнне тиз генә оныта алмый, тартыша. Шуннан ислам дине әһелләре борынгы йолаларны ислам диненә җайлаштырырга кереште. Кайбер йола җиңел генә кереп китте, ә кайберләре... Ил тарихсыз булмый, су — ярсыз. Хакыйкать үлемсез, ул гүя туфракка төшкән орлыктыр, шартлар булганчы ята, ята да, шартлар тугач, шытып чыга һәм чәчәк ата.

Кояш бер дә яман кыздыра. Новгород якларында җәй буена бер тамчы да яңгыр төшмәгән икән. Сәлим хан шуның сәүдәгәрләренә олау-олау ашлык сата, кенәзләргә бүләк итеп тә җибәрде. Изге эш. Урысболгар элек-электән кәләшләр алышып, бер-берсенә ярдәм итешеп килгән. Хак анысы, бу ике халык арасында орышлар да булмаган түгел, булгалаган. Вәзир Исхак ике халыкны дуслаштыруда күп эш башкарды, рәхмәт әйтергә иде, ә юк, бүген аны Кара Пулатка дәштеләр. Аннан бик азлар гына исән-имин чыга.

Вәзир Исхак ашыкмады, тирә-ягына карангалап барды. Көнчыгыш капкадан азатлар китеп бара, Җаек буенадыр, соңгы ике елда, кенәз Андрей Боголюб белән солых төзелгәч, Сәлим хан ни сәбәпледер көнчыгыш чикләрен ныгыта башлады. Билгеле инде, Олуг Мөхәммәттән куркуыдыр. Сәлим ханга аның белән бәхәскә керү кирәкмәс иде. Саксин каласында яшәүче шәех Саттар әбү Талибның даны бөтен Туран дөньясына таралган, Олуг Мөхәммәткә аны илче итеп җибәргән очракта Сәлим хан отар гына иде. Шәех Саттар әбү Талибны Өргәнечтә белмәгән кеше юктыр. Бөек Кала кирмәнен ныгыту урынына Каргалы кирмәнен салып ята. Барып килә алмады вәзир Исхак шул якларга, анда ниндидер мәләкәс ыруы авыл утырган икән, күрәсе килгән иде шул халыкны — хатынкызлары ирләр белән атта бертигез йөри, орыша икән, дип сөйлиләр. Аннары юлга алган ризыкларын мактадылар. Җиде ел, җиде юл узганда да бозылмый торган казылык ясыйлар икән, кымызлары борын тишекләрен ярып чыгардай каты икән, диделәр. Казылык, эремчек, әйрән, кымыз, бавырсак, чәк-чәк бездә дә бар, аллага шөкер. Ә менә саклау ягы кыенрак ул ризыкларны, казылыкны саклап булса да, калганнары айлык юлда искерә башлый. Әйе, күрәсе килгән иде вәзир Исхакның шул мәләкәслеләрне — язмаган булып чыга. Җаек ягына китеп барган азатларның һәрберсендә иш ат. Борын заманда болгар алыбы өчәр ат йөрт-

кән, диләр. Хәзер әнә иш атны да ерак юлга гына алалар. Ә мәләкәсләләр һаман өчәр ат йөртәләр икән.

Кара Пулат янында казый Баштак киләп сара. Кемнедер көтә шикелле, борчулы, бер урында торалмый. Кемне көтә? Шулай ук вәзир Исхакны микәнни? Шулайдыр. Күрде дә әнә аптырап катып калды. Әйе, әйе, казый Баштак, мин киләм, берүзем киләм, син мине хан азатлары китерерләр дип көтә иден, алай булмагач, ни кылырга белми катып калдың, борчылма, казый, барысы да әйбәт булыр — Сәлим хан моның өчен сине гаепләмәс. Беләм, син, ничек инде бу кеше үзе теләп үлемгә килә, дип уйлыйсың. Яшермә, нәкъ шулай уйлыйсың. Тик курыкма, мин бу хәлдә берәүне дә гаепләмәм. Чү, син бит минем иректә булуымны күреп курка калдың, котың алынды! Күрче, шулай бит?! Шулай. Ә сиңа әл-казый Ишкул ни дигән иде: вәзир Исхакны хан азатлары Кара Пулатка китерерләр, бар, кабул итеп ал, янында ике-өч азатны калдыр, дигән иде. Ә ул монда гелән үзе генә килә. Димәк, син, казый Баштак, хан вәзиргә тияргә кушмаган, дип уйлыйсың. Димәк, вәзир үзе кемнедер хөкем итәргә килә. Бәлкем әле синедер, казый Баштак. Ә нигә, гаепсез кеше булмый, шулай, ди, шәех Игәнәй, димәк, синең дә гаебең бар, казый Баштак. Язгыгың булса, аллага хәер биреп кенә котыла алмассың, ул сиңа, гошер сәдакасы биргән саен, гөнаһыңны җуярга өметләндермәс. Вәзир Исхак ни хан янында, ни шәех алдында мәһди була алмады, аллаһы тәгалә ярлыка кыла күрсен.

— Әссәламегаләйкем, казый Баштак!

— Вәгаләйкем әссәлам, вәзир Исхак!

Казый Баштак вәзиргә, кулын йөрәк турына куеп, түбәнчелек белән баш иде. Хикмәт шунда иде ки, казый Баштак вәзир Исхакның Кара Пулатка бер ялгызы гына килүенең төп сәбәбен белми иде, әнә шул белмәү аны үтә кыен хәлгә калдырды: хан вәзир Исхакны аның тугрылыгын сынарга дип җибәргән булса? Туйдылармы казый Баштактан? Кирәге калмадымы? Халык, карга карганың күзен чукымый, дисә дә, әйтик, әл-казый Ишкул үз янында эшләгән шактый кешеләрнең башын җәллад балтасы астына салдырды. Шаһитлардан үз вакытында котылып калу хәерле дип уйлавыдыр.

Шул чакта казый Баштакның башына бер уй килде: вәзир Исхакны берни булмаган кебек чәйгә дәшәргә.

— Рәхим итегез, олуг вәзир, узыгыз, — диде ул һәм арттырыбрак җибәрүен сизеп: — Чәйләп алырбыз, хан кайчан килә әле, — дигән булды.

— Мин хан түгел, казый Баштак, билең авырттырырсың, ул хәтле тырышып баш орма! Хокук вә фәкыйһ кешесе буларак әйт әле, әмир Хаҗи урманнарында качкыннар күбәеп киткән икән, атакайлары кем, беләдеңме?

— Сәлим хан, Болгарда качкыннар юк, дип мактанды. Булмаганны сөйләмәсәнә, олуг вәзир.

— Син ишетмәдеңмени әле, казый, качкыннарның башы Тубыкбай баһадирның туганы Җик Мәргән икән. Ул: Сәлим хан аның ишләренә кагыла икән, мин аны тыныч яшәтмәм, дип әйтеп әйткән икән, диләр.

— Җик Мәргән атаман! Олуг вәзир, син миңа агасы белән бәхәскә кергән Җик Мәргән турында сөйлисең икән, ишеткәнем бар, нигә булмасын ди. Җик Мәргән әмир Хаҗи урманнарында сукбайлык итә. Ишләре күп түгел, — казый Баштак як-ягына каранып алды. — Беләсегез килсә, олуг вәзир, хан аңа үзе тимәскә кушты. Ике туган ызгышалар икән ызгышсыннар, безгә кысылырга ярамас, диде. Җик Мәргән Бачман баһадирның сеңлесе Зәйтүнәгә гашыйк икән. Тегесе көн аралаш урманга — аның янына чаба икән. Кыз үзе дә бик чая, үткен, кыю икән — уктан да ала, кылыч белән дә орыша, ир-аттан бер дә калышмый икән. Иш-ишне тапмый буламы? Табышканнар әнә. Түр урам сәүдәгәре угланы яучысын, әйтсәң дә оят инде, йомшак җиренә тибеп чыгарып җибәргән, диләр.

— Ә син уйланганың юкмы, казый, әйтик, качкыннар нигә гелән әмир Хажи урманнарына килеп сыена, баллымы әллә ул урманнар? Димәк, анда аларга торыр шартлар бар, димәк, аларны әмир Хажимы, башка берәүме ашата, ә кирәк чакта... Кыскасы, казый Баштак, әмир Хажи тиздән атасыннан аерылып чыкмагае — мөстәкыйльлеккә омтыла ул. Сәлим хан вакытында чарасын күрмәсә, әмир үзенә бер дәүләт тә төзеп куяр. Әнә хәзер башкаласын яңа төбәккә күчерергә йөри икән — яңа кала салырга булды бит хан, шул булыр әмир Хажиның мәркәзе. Җиде су юлы чатында. Инде бераз шәйләденме кая таба бара эшләр Болгарда, казый Баштак?

— Борчылма, олуг вәзир, казый Баштак ул хакта белә. Син дә, олуг вәзир, Сәлим ханнан бер дә ким түгел, миңа калса, аннан күп тапкыр акыллыраксың да кебек. Нәкъ менә акыллырак булган өчен, бүген ул сине хөкем итмәкче, олуг вәзир. Тәхет ул һәрчак орыш кыры булып торды. Бездән соң да шулай булыр. Әйтик, әмир Хажи нигә атасы белән килешми? Тубыкбай баһадир белән Җик Мәргән турында әйтеп тә торасым килми. Сәлим ханның энесе Мөхәммәтгалимбәк тә илгә кайтып тәхеткә утыру хакында хыяллаңып йөри ич әле. Дала тармы аңа? Хан кызына өйләнде, кул астында бер бөтен алай, диләр. Ә аның илгә кайтып тәхеткә утыруы бар. Бик бар.

— Телең ни сөйләгәнне колагың дөрес ишетәме, Баштак казый?

— Ишетә, дөрес ишетә, олуг вәзир. Гаебем булса, кичерә күр. Җәллад балтасы астына муенын куярга торган кеше белән яман итеп сөйләшәсем килми. Хан сине нахакка рәнҗетте. Бу хакта үзең дә беләсең! Мәгәр алар сине барыбер тыңламас.

— Син нигә монда, менә син нигә?!

— Мин, олуг вәзир, кеше кулындагы кеше. Минем дә бер заман баш казый буласым килә. Максатсыз адәм — очламаган каләм, ди әнә хан кәтибе. Баш казый булып алсам, мин кешеләрне нахакка рәнҗетмәс идем. Сиңа хан вә аның куштаннары түгел, аллаһы тәгалә җиңеллек китерер.— Казый Баштак ишек ягына карап алды.— Хак булса, олуг вәзир, хан оныгы Гали Өргәнечтә, диләр. Имеш, исән икән.

— Тиле дигән саен тигәнәк бүе сикермәсәнә, казый Баштак. Хан оныгын мин үзем күмеп кайттым. Үз күзем белән карап тордым. Теге дөньядан кайткан кешене моңа кадәр күргәнем юк әле.

— Кам ни кылды соң аның белән? Алар күз буа белә. Күзенне буганнардыр, олуг вәзир.

— Анда йөзләгән кеше иде, казый. Ишетәсеңме, йөзләгән кеше иде.

## 16

Вәзир Исхакның үзе үк Кара Пулатка таба китүе хакында ишеткәч, Сәлим хан икеләнә калды. Әллә соң бар языкны үзенә алып, вәзирен коткарсынмы? Моңа кадәр ул аңа тугрылыклы булды. Бер гөнаһсызга башын кистерергә... Бер гөнаһсызгамы?! Вәзир Исхак аның Гали оныгын яңа кала салынасы нигезгә корбан итеп кайтты. Хан алдында гөнаһсыз булса да, халык алдында, угланы әмир Хажи алдында вәзир Исхак гөнаһсыз була алмый. Хажи көчәеп мөстәкыйльлеккә омтылганда бөтен гаепне үзеңә алу ярармы? Шаех бу хәлнең төп асылын белсә, үз азатларыңа хәтле котырта башлар. Хәерле булсын, язмыштан узмыш юктыр, күрәсең. Аллага тапшырыйк. Вәзир Исхак гаепле, берәү дә аңа кала нигезен карарга барган оланнарның берсен корбан итәргә дип кушмаган, ул аны үз белдеге белән эшләгән, җәзасын да үзе генә алырга тиеш. Барысы да әйбәт бара кебек иде, тик бүген иртәннән бирле күңелне бер нәрсә борчып тора — кәтиб Хафизның төнлә белән югалып торуы. Әгәр ул вәзир Исхакка барган булса? Ул гынамы, бергәләп сүз куешкан булсалар? Әйтик, хан биргән хат-фәрманны укып чыксалар? Дөрес, дарулар ясаучы яван хаттагы язуны ике ат-

надан бетә, дип ышандырды. Ике атна вакыт үтте генә түгел, өченче атнага китте. Әгәр ул язу бетмәгән булса? Хат-фәрман баш казый Ишкул, шәех Игәнәй кулына керсә? Анда хан мөһере, хан кулы?!.

Шул вакыт аның каршына табиб Антоний килеп басты. Дәшми генә баш иде, сүз сорады.

— Әйт-әйт,— диде Сәлим хан.

— Ханиям, кәтиб Хафиз яваннар урамында булды, кичерегез аны, гаеп миндә...

— Хәериен,— диде хан.— Хәериен, Антоний, үзең әйтмешли. Була күрсен.

Табиб Антоний янә баш иде һәм борылды да чыгып китте.

«Димәк, бусагабаш Камай чынлап та кәтиб Хафиз муенында тәре күргән. Тик кем салдырып алырга өлгергән? Хәер, бу хакта соңыннан. Анда ул үзе дә заманында баргалады. Булды андый гөнаһлары, булмады түгел. Әле булса исендә, яваннар урамына ул кояш баегач чыгып китте. Өстендә әрмәннәр чикмәне, билендә бау. Бау ярлылык билгесе генә түгел, бау яһүдләр белән аралашу билгесе дә иде. Аны аулак өйдә таныш яван каршы алды. Яван кызлар белән сәүдә итә һәм ханга япь-яшь кызларны китерә иде. Шушы яван Сәлим ханны җитәкләп диярлек караңгы өйгә алып керде. Ишек төбендә табак тотып торучы карчыкка бер янчык алтын ташлагач, кунакның кем икәнен янчык чамасыннан ук белеп алган карчык, көмеш кыңгыравын зеңләтте. Шундук түр яктан ояла-тартына гына бер зат килеп чыкты, шәм кабыздылар һәм Сәлим хан япь-яшь кызны күрде. Көйчеләр дә чакырулы икән, тын гына кыллы коралда уйный башладылар, ул арада алтын табакка салып, хәмер, җиләк-җимеш китерделәр. Күп тә үтми, Сәлим ханны кызлар уратып алды, алар аның өстеннән чикмәнен салдырды, аяк киемнәрен җыйды. Кайсыдыр хәмер койды, ханга сузар алдыннан үзе эчте, серем белерсең диган хәрәкәт белән, бераз кылтая һәм назлана төшеп, чокырны ханга бирде. Сәлим ханны шәм янындагы күпереп торган мендәргә утырттылар, хан янәшәсенә теге яшь кыз килеп утырды, ә калганнары җил алгандай юкка чыктылар. Табакка куелган нечкә муенлы көмеш савыттан хәмерне берсе артыннан берсен сала-сала эчеп бетерде дә, кесәсеннән көмеш таңкаләр алып, идәнгә сипте — көйчеләр сыдырылып таңкаләрне җыеп бетерделәр һәм чыгып та шылдылар. Сәлим хан кыз белән икәүдән икәү генә калды.

Көйчеләр күрше бүлмәдә уйный башлады.

Кыз аңа кыяр-кыймас кына килеп елышты. Үзе калтырана, үзе һаман елыша. Кызның нәфис бармаклары татлы итеп кытыклыйлар, илереп кычкырып җибәрәсе килә.

Сәлим хан кызның тал чыбыгыдай биленә кулын салды. Кагылыр-кагылмас сыгылып килә иде бил иясе. Сәлим хан кулын түбәнрәк төшерде, биле талчыбыгыдай нечкә булса да, янбашлары өлгергән кабактай йомарланган иде кызның. Сәлим хан астындагы мендәрне түргә ташлады, сузылып ятты. Кыз аның күкрәгенә башын салды. Сәлим хан кызны кочагына алды, астында калдырды. Шул мәлдә кыз еландай шуып чыкты да, сәке читенә барып, тезләрен кочаклап утырды — ул дер-дер калтырана, тешетешкә тими шыкылдый иде.

— Мин куркам, ханиям. Тимәгез миңа, мин куркам!

Моны һич тә көтмәгән Сәлим хан, чәчкәгә кунган күбәләкне тотарга теләгән берәүдәй, кызга ташланды, көчле куллары белән нәзберек затны күкрәгенә кысты. Кыз кычкырмады, чарасыз калып чәбәләнә башлады, иллә хан кулыннан ычкына алырлык көчне бирмәгән иде аңа хода, чәбәләндечәбәләнде дә кисәк таралып китте. Нәкъ менә шунда Сәлим хан хәрәкәтсез калды. «Кыз бала», диган уй зиһенен телеп үтте. Отыры кубып ташланса да, соңгы мәлдә, кыз бала карусызлана калгач, Сәлим хан үзендә әллә ниткән ят хис тууын тоеп алды. Күп еллар элек бер гарәп аңа бик тә гүзәл җария китергән иде. Бикче иде кыз, ул биегәнне көннәр буена да карарга риза иде Сәлим хан. Ул шул кадәр килештереп ян башларын уйнатыр иде ки, Сәлим хан ни кылырга белми үзе торып биеп китәр иде. Бермәлне карап-

карап торды да Сәлим хан кызның үтә дә жилле итеп биюенә, бусагабаш Камайга аны күрше бүлмәгә алып керергә кушты. Теге апара тәпәне кызны биегән жиреннән күтәреп алды да күрше якка алып кереп тә китте. Анда ханның ял бүлмәсе, затлы тирәләрдән жәйгән юрганнар, тәвә кошы мамыгыннан ясалган мендәрләр, һәрчак тымызык кына яктылык булыр. Кыз бу котсыз адәм мине урларга тели дипме, чырыйлап кычкырып жибәрде. Камайның бит-йөзен тырнады, шәрә башын чәп-чәп кыйнады.

— Сабырландыр син аны, сабырландыр,— дип калды Сәлим хан.

Бусагабаш Камай кызны бүлмәгә алып кереп китте. Бераздан бүлмәсенә күз салса, Сәлим ханның ике күзе дүрт булды: Камай кызны астына жыярга, ә тегесе шуып чыгарга, ычкынырга маташа иде.

Сәлим хан ым кагып кына жансакчыларын чакырып алды һәм Камайның ашыгыбрак шәрәләнгән артына шул тиклем каты итеп сыптырды ки, теге мескен бүре кебек улап жибәрде һәм ыштанын да күтәрергә онытып, чатаклый-чатаклый чыгып йөгерде. Сәлим хан жан сакчыларына «чыгып китегез!» дип ишарәләде, аннары камчыны сәкегә ташлады, жиләнен салып атты. Кыз исә аның бу кыланышына коты алынып карап торды-торды да һуштан язды. Сәлим хан ни кылырга белми аптырап калды, аннары кызның өстенә жиләнен ташлады да, жансакчысына табибне чакырырга кушты. Шул хәлдән соң Сәлим хан карышкан хатын-кыз янына беркайчан да бармады. Теләк — теләк тудыра, ә кыз аннан коты алынып курыккан иде.

Сәлим хан кисәк күтәрелде дә киенә башлады. Кыз исә курка калды, сыдырылып сәкедән төште, хан муенына елandай килеп сарылды.

— Бар, хәмер китер,— диде Сәлим хан. Кыз күрше бүлмәгә чыгып олы бер савыт хәмер китерде, үзе үк сала-сала сыйлады, кыюлык өчен булса кирәк, хәтта үзе дә бер-ике тапкыр салып эчте...

Таң атар-атмас аны таныш яван кереп уятты. Сәлим хан кайтышлый хаста хатыны янына керде. Төнлә булган хәлне хәтеренә төшерергә дә теләмәде Сәлим хан. Ул хәл күз алдына килгән саен үзалдына кызарынып оялды. Хаста хатын ятакта, ә ул исерек, хатыны күзләрен акайтып аңа карады да муенындагы тәрене күрде. Күрде дә ике куллап тәрегә ябышты. «Мөртәт!» Хатынының күзләре акайды һәм тәрене жибәрми жан бирде. Сәлим хан көч-хәл аның кулын ычкындырды һәм ишек катында торучы каравыш хатынга: «Ханбикә вафаттыр»,— диде.

Менә ни өчен кәтиб Хафизның муенында тәре булуына ышанды Сәлим хан. Димәк, кәтиб вәзир Исхакта булмаган, ә яваннар урамындагы аулак өйдә кунган һәм аңа, Сәлим ханга таккан кебек, тәре тагып жибәргәннәр. Аны беренче булып бусагабаш Камай күрә, ләкин ул килеп ханга әйткәләгәнче, тәрене кемдер салдырып ала. Кем?

Сәлим хан Камайны чакырып алды. Бусагабаш тәмам курка калган. Бу да белә микәнни вәзир Исхак язмышын? Беләдер. Тик нигә курка? Миңа да ул көн килүе бар дип уйлавымы? Ләкин Камайга ул үзе исән чакта һични кылмас. Ул аңа кирәк. Сәлим хан үзеннән өстен кешеләрне генә жәлладка тапшыра. Камай исә алардан, аеруча вәзир Исхактан чагыштырмасыз түбән. Йөр әйдә тәхет белән бусагабаш арасында корсагың белән идән себереп, сарай өчен синдәйләр дә кирәк. Алай да соңгы вакытта ыспайлангансың кебек әле, корсагың да бераз шиңгән сыман. Туйбикә яшәрттеме үзеңне? Яшәртер, ул хатынга әләксәң. Тик гомере кыска булды мәрхүмәнең, сиңа килүгә, ай да үтмәде. Алпары янына китеп барды. Теге вакытта, үги бала булса да Дәуранны зинданга утыртма, дип килдең бит. Имеш, углы. Их, Камай, Камай!.. Сәлим хан шуңа бара була диме?!.

— Хакимем, вәзир Исхакны хөкем итәргә жыенасыз икән, хакмы шул? — диде бусагабаш.

Шәех Игәнәй керде, сәлам юллады, түргә узды, дога кылды һәм янә исәнлек-саулык сораша башлады.

— Мәхәлләләрдә тынычмы, шәех? — дип сорады хан.

— Тыныч, хан. Вәзир Исхак Кара Пулатта утыра икән инде, үз гаебен таный, димәк.

«Козгын да козгын, бу да козгын, үләксә исенә килгән. Нишлим, янәсе, вәзир Исхак белән».— дип уйлады Сәлим хан.

— Бусагабаш, ишетәсеңме, кәтиб Хафизны да дәш. Кара Пулатка барсын. Карышса, сак астында илттер.

— Кәтибеңне хөкем итмәскә булдыңмыни, ханиям? — дип сорады шәех Игәнәй.

— Кәтиб Хафиз, анда булса да, явызлык кыла торган кеше түгел, шәех.

— Явызлык кылганны карап тору да явызлыктыр, ханиям. Гафиллеге аркасында вәзир Исхак хан оныгын корбан итә, ә ул карап тора. Кылыч тотып аерып аласы иде аңа угланны.

— Вәзир Исхакка каршы сүз әйтсә, аның үзен дә шул нигезгә корбан иткән булырлар иде.

— Булырлар иде микән, ханиям? Хафиз — сезнең кәтибегез, ил серен генә түгел, сезнең серне дә белеп торучы.

— Ярый, хөкемдарларны тыңлап карыйк, шәех. Кәтиб Хафизның гаебе бар икән, үз җәзасын алыр, алланың кашка тәкәсе түгел.

— Ханиям, хак әйттегез. Аллаһы тәгалә язганны күрми чарасы юктыр.

Шәех Игәнәйне аңларга була иде, ул соңгы вакытта вәзир Исхакны гына түгел, ханның үзен дә күрә алмый башлады, иң әүвәл ул Бөек Калага чиркәү салдыруны оныта алмады, ә хан ризалык бирмәгән булса, ул чиркәү салынмаган булыр иде. Хәзер әнә Бөек Каланың ундүрт мәхәлләсендәге ундүрт мәчете арасында бер чиркәү утыра, җыен чәүкә арасындагы козгын диярсең. Аннары епископ Габбас. Кайчандыр шәех Игәнәй кысуына түзә алмыйча Болгардан качып киткән тәре көчеге епископ булып әйләнеп кайтсын әле. Хак анысы, епископ Габбас сарайга бик сирәк килә-килүен, иллә бер килүе дә берәгәйле булып куюы бар. Әләккә иң әүвәл ханнар ышанып, диләр.

Бусагабаш Камай килеп керде, кәтиб Хафизны азатлар белән Кара Пулатка озатуы турында әйтте.

— Әйт әле, Камай,— диде чыгып барышлый хан.— Вәзир Исхак языклымы?

— Без барыбыз да языклы, ханиям, кеше языксыз булмый. Балыксыз күл булмаган кебек, кеше дә языксыз булмый. Языклы кеше иблискә тиң кеше. Аны йә асарга, йә атарга кирәк.

— Йә башын чабарга,— диде Сәлим хан көлемсерәп. Шәех Игәнәй бер сүз дә әйтмәде, алгарак чыкты. Ул гомумән тилемсәрәк кешеләрне яратмый иде. Камай тилемсә түгел, иллә чамадан тыш куштанлана, юхалана, юмакайлана һәм, иң гаҗәбе, хан моны белсә дә, рәхәтләнеп тыңлый, күп чакта ризалаша иде.

Сәлим хан Камайга шәех Игәнәй белән алданрак китәргә кушты, үзе исә артка калды, аның нигәдер берьялгызы барасы килде. Артыннан ияргән җансакчыларына да кул селтәде, янәсе, калыгыз, йөрмәгез, соңрак килерсез.

Кояш инде шактый күтәрелгән, игенчеләр басудадыр. Быел икмәкләр әйбәт, диделәр. Сәлим хан ашлык җыюга нык игътибар итә, игенчеләренә мул түли, үзләренә бер урам салдырды. Болгар борын заманнан ук иген игә, алай да ачлык еллар булгалаштыргалый. Иртәгә җомга, барча игенчеләр дә кырдан кайтыр, мәчетләргә җомга намазына агылыр. Хан мәчетендә шәех Игәнәй Сәлим ханга багышлап хөтбә әйтер. Бер уйлаганда шәех Игәнәй басудагы игенчеләргә хөтбә әйтергә тиеш иде, юк, алай итми ул, хөтбәне Сәлим ханга әйтә.

Шәех Игәнәй белән бусагабаш Камай Кара Пулатка кереп киттеләр. Сәлим хан һаман ашыкмады, ул әле һаман катгый бер карарга килмәгән иде. Нишләтергә вәзир Исхак белән кәтиб Хафизны. Икесенә дә бер чара күрү ярамастыр...

Кара Пулатка җитеп килгәндә генә хан колагы янынннан сызгырып бер ук үтте. Бу ни? Сәлим хан күтәрелеп тирә-ягына карады. Тиле укмы? Алай

дисәң, кем кирмәндә ук атышсын. Азатлар өчен махсус урын бар, мәктәп оланнары өчен вакыты ул түгел. Кирмән дивары өстендә азатлар йөренә, нигә бер ят кеше күренсен. Укны төньяк тарафтан аттылар. Төньяк кирмән диварында бер азат та күренми. Сәер, кем болай шаярыр? Сәлим хан укка үрелде, ләкин шул мәлдә янә ук сызгырган тавыш ишетте. Сәлим ханның аркасы кымырҗып китте. Икенчесе нәкъ аның аяк янына килеп кадалган иде. Сәлим хан иелгән җиреннән акрын гына күтәрелде, тирә-якка күз ташлады. Кайда утыра бу укчы? Диварда? Мөмкин түгел, дивар уч төбе кебек күзәтелә. Укка бөркет канаты ябыштырылган. Димәк, уктан мәргән кеше ата. Кем? Өченче ук сул аяк кырына килеп кадалды. Ук сабына кәгазь кисәге бәйләнгән иде. Сәлим хан үрелеп укны алды, кәгазь кисәген сүтте. Кәгазьгә: «Хан, башың ике булса гына, кәтиб Хафизга җәза бир».— дип язылган иде. Язмада ни имза, ни тамга юктыр. Сәлим хан күктән төшкән хатны укыды да янә тирә-ягына күз ташлады. Шикләнердәй бер нәрсә дә абайламады. Манара ягында да ул-бу күренми. Инде нишләргә?..

Сәлим хан әкрен генә Кара Пулатка юнәлде, иллә аркасы чымыр-чымыр килде. Менә-менә аркасына зәһәр ук килеп кадалыр кебек иде. Ниһаять, менә Кара Пулат ишекләре, як-ягында ике азат басып тора, хан килеп җитүгә, алар сөйләшеп куйгандай икесе дә айбалталарын читкә алдылар. Сәлим хан бусага аша атлады һәм тирән итеп сулыш алды, көч-хәл белән генә үз урынына барып утырды. Исәнләшмәде, сәлам юлламады һәм шуның белән казыйларны бераз аптырашта калдырды. Кечкенә өстәл артында кәтиб Хафиз тырышып-тырышып каләм очлый, ул хан килеп кергәнгә хәтта күтәрелеп тә карамады, хөкем ителәсе кеше урынында вәзир Исхак, ул да читкә караган, ханга игътибар итмәде. Баш казый Ишкул гына чумәлә хәтле чалмасының бер очын түшенә төшергән килеш хан керүгә торып басты, кат-кат сәлам бирде. Сәлим хан, ниһаять, сүз әйтер хәлгә килде, башларга ярый дигән мәгънә салып, казыйларга ияк какты. Ишкул торып, ишек ягын әйләнеп килде, шуннан соң алдына китереп куйган коръәнне тотып, күн тышына иреннәрен тигезеп алды, калган ике казый да аның хәрәкәтләрен кабатлады. Шуннан соң Ишкул:

— Хаҗга барганда мин дөнья каласы Багдадка туктадым,— дип, вәзир Исхакка карады.— Ага-Базар белән ул базарны чагыштыру мөмкин түгел. Базарның ите-чиге юк шикелле. Халык күп, бер яктан икенче якка агыла, төркем-төркем җыелып, кәмит тамаша кылучылар да бар. Мин шундый төркемнәрнең берсенә туктадым, этә-төртә эчкәрәк үттем. Баксам, түгәрәк уртасында бер адәм утыра, ә тез өстендә — маймыл. Иясе маймылга сораулар бирә, маймыл аңа җавап итеп баш кага, килешмәгәннәренә баш чайкый. «Маймылым, тукымалар сатучы булырга телисеңме?»— дип сорады иясе. Маймыл миңа шәрә йөрүе рәхәтрәк, дип, оятлы җирләрен ачып чәпәде, халык егылып көлде. «Маймылым, хәмер сатучы буласыңмы?» соравына җанвар килешеп ияк какты, имеш, сатыр идем дә хәмерем юк. Халык янә көлде. «Маймылым, остаханә иясе буласыңмы?»— дигән сорауга да ризалык бирде — кулына чүкеч алып, кадак каккандай итте. Шуннан иясе аңа: «Вәзир булырга телисеңме?»— диде. Иясе шулай диюгә, маймыл башын чайкады, ә инде иясе: «Буласың, буласың!»— дигәч, кешеләр башы аша чикләвек агачына сикерде һәм ботаклар арасына кереп посты.

Халык шаркылдый, ә иясе көлмәде, «төш инде, төш, вәзир итмим, итмим», дип чакыруын белде. Соңыннан маймыл иясе торды да: «Җәмагать, мин үзем вәзир идем, хәзер менә шушы көнгә калдым».— дип, баш киемен салып, тузанлы җиргә куйды. Халык тарала башлады, күпләре баш киеменә бакыр я көмеш ташладылар. Ә мин маймыл иясенә килдем дә: «Ни өчен сине вәзирлектән кудылар?» дип сорадым. Ул миңа хәтта күтәрелеп тә карамады. «Ил иминлеген саклый алмадым».— диде. Вәзир Исхакның беренче языгы Олуг Мөхәммәт илчесе Садакка сак бирмәүдәдер, икенче языгы, иң яманы — яңа кала нигезенә хан онысы Гали угланны корбан итүдәдер. Казый Саксин, хан онысын яңа кала нигезенә корбан иткәнне син үз күзең белән күреп кайттың. Расла.

— Коръән тотып раслыйм, баш казый, вәзир Исхак фәрманы белән хан оныгы Гали яңа кала нигезенә корбан ителде.

— Йә, вәзир Исхак, хакмы казый Саксин әйткән сүзләр?..

— Баш казый Ишкул,— диде вәзир Исхак.— Әйе, мин шәех Игәнәй үтенече белән Олуг Мөхәммәт илчесе Садакка сак бирмәдем. Шәех аны үз мөридләреннән озаттырырга булды. Бу хакта ул миннән ялынып сорады. Хөрмәткә ия шәехкә мин ышанмый булдыра алмадым. Янә шуны әйтәсем килә, шәех Игәнәйнең илче Садакны озата барган мөриде исән-имин Бөек Калага әйләнеп кайтты, ә илче вафат.

— Илчене үтергәннәр,— диде Сәлим хан.

— Ләкин сакчылар бирмәгәннән түгел, ханиям. Шәех Игәнәй мөриденең исән-имин әйләнеп кайтуы, ә илченең үтерелүе сезне бераз шикләндерміме? Ә инде хан оныгы Гали угланга килгәндә, моны мин, баш казый Ишкул, сиңа мөрәҗәгать итеп әйтәм, гәрчә бу хәлдә һични кыла алмасаң да, хан фәрманы белән эшләдем. Хан фәрманы кәтиб Хафизда. Иллә баштан мин сиңа бер сорау бирер идем, баш казый.

— Бирә күр, вәзир, бирә күр.

— Ялгыз хатынны ни белән чагыштырыр идең?

Көтелмәгән бу сораудан Ишкул бермәлгә телсез калгандай булды. Үтә дә гаҗәпләнде һәм гаҗәпләнүен сиздереп, Сәлим ханга күз төшереп алды.

— Тол хатын өйдән куылган эт белән бердер. Өрсә, саклар иясе юктыр, өрмәсә, эт түгел бу диюдән куркуыдыр.

Баш казый җавабыннан хәтта шәех Игәнәй дә канәгать калды, Сәлим хан да елмаеп куйды.

— Тол хатын корыган елгага тиңдер, баш казый. Аннан сусаган кеше су эчә алмастыр, балыкчы кармак салмастыр.

— Синеке дә дөрес, вәзир Исхак. Иллә юл башым бүтән кебек иде: илче Садакны кем үтерде?

— Әмир Хаҗи кешеләредер.

— Килешми, килешми, вәзир Исхак, әмир Хаҗи хөрмәткә ия кеше, нахакка рәнҗетмә син аны.

— Нахакка мин түгел, син мине рәнҗетәсең, Ишкул.

— Бу сүзләрдән соң миннән игелек көтмә, вәзир.

— Ә мин көтмим дә, баш казый. Синнән игелек көткән кеше ишәктән бер чиләк сөт савып алыр. Дөресен әйтимме, баш казый.

— Йә-йә, вәзир Исхак.

— Мин беркайчан да хан каршына тәлинкә тотып килмәдем. Янә куштанлану да минем өчен ят нәрсә булды. Моны хан үзе дә раслый алыр иде, гәрчә әлегә кадәр бер кәлимә сүз әйтмәсә дә. Сәлим хан соңгы елларда үз шәүләсеннән үзе куркып яши башлады. Бүгенге хан янында төрле куштан яши. Беренчеләре, гәрчә хан моңа лаек булмаса да, аны күккә чөеп мактый, икенчеләре, үзләре ханнан мактау сүзе көтә, гелән әнә шул син күргән маймыллар инде; өченчеләре үзләрен ханнан да акыллырак дип саный, җай чыкса, тәхеткә утырудан да баш тартмаячаклар; дүртенчеләре, хан кушкан һәр эшкә керешеп тә, ахыр чиктә аның очына чыга алмыйча, бу хәлдә башкаларны гаепләргә керешүчеләрдер; бишенчеләре, ахмак булмасалар да, башларын ахмакка салып, хан кәефен күреп яшәүчеләрдер; алтынчылары, сездәй казыйлар, кешеләрне мөселман кануннары белән хөкем итәргә тырышып та, беркайчан да хан вә шәех сүзеннән чыкмаган сакаллы кәҗәләрдер. Инде төп язгыма керешик, баш казый. Мин хан оныгын яңа кала нигезенә ике туган арасында кан коелмасын өчен корбан иттем, гәрчә угланны корбан итәргә хан фәрманы булса да, булмаган хәлдә дә аны мин барыбер корбан итәр идем. Ил иминлеге өчен, дәүләт тынычлыгы өчен. Яңа кала нигезен карарга барыр алдыннан гына хан оныкларына корал тоттырды. Бу шулай. Инде хакыйкатьнең асылын тыңла, баш казый. Мин ул явызлыкны хан фәрманы белән эшләдем. Ышанмасаң, кәтиб Хафиздан, казыең Саксиннан сора, угланны корбан иткәнче иң әүвәл хан фәрманын укыдык, барчасы да ишетте. Фәрман кәтиб Хафизда, иң әүвәл миңа хөкем чыгар-

ганчы, аңардан ул фәрманны укытыр идем. Ишкул казый, әйт әле, кайчаннан бирле хан фәрманын җиренә җиткереп үтәгән кешеләрне хөкем итә башладың? Бер акыл иясеннән: «Кояш нурының тизлеге бармы?» дип сораганнар. «Бар!» дигән бу. «Нигә соң аны син күрәсең, без күрмибез?» дигәннәр болар. «Мин шуның өчен күрәм,— дигән бу,— чөнки мин аллага тиң кеше».

— Димәк, син аллага тиң кеше, вәзир Исхак?

— Мин түгел, син, баш казый. Чөнки ханнан да акыллырак булырга тырышасың. Илле ул сиңа имәс, чөнки караңгыда тудың, караңгыда дөньядан да китәрсең. Хода сиңа башка тәкъдир бирмәс.

— Хан, ни сөйли бу? — дип күтәрелде шәех Игәнәй.

— Фәрманны укы, кәтиб Хафиз, хан фәрманын укы! — диде вәзир Исхак.

Менә монысын көтмәгән иде Сәлим хан, фәрман аның уенча вәзирдә булырга тиеш иде. Һәм вәзир әйткәндә дә шулай дип уйлаган иде хан, чөнки кәтиб Хафизга кечтеки дә күләгә төшәргә тиеш түгел.

— Кәтиб Хафиз, хан фәрманы синдәме? — дип сорады баш казый Ишкул.

— Миндә.

Кәтиб Хафиз куеныннан кәгазь чыгарды, төргәкне сүтте һәм күзләре шар булды. Кәгазь чип-чиста иде, әллә хан мөһере эзе бар кебек. Юк, хан мөһере түгел, сәүдәгәр Биккол мөһере. Ә бит фәрман шул, шул! Хан язган юллар кая?! Хафиз бик тиз исенә килде, хәтере шәп иде аның, ул фәрманны яңа кала нигезендә укыган кебек сүзен-сүзгә укып чыкты.

Сәлим хан белән Ишкул күзгә-күз карашып алдылар. Хан үзе дә сизми калды бугай, аягүрә торып басты. Яван сихерчесе бер атнадан язу үзеннән-үзе бетә дигән иде, ике атна вакыт үтте, кәтиб Хафиз ул язган юлларны сүзен-сүзгә укып чыкты.

Баш казый Ишкул Саксин казыйга кәтиб Хафиз кулындагы кәгазьне алып китерергә кушты.

Нииндидер уенга охшаган иде бу хөкем. Хәер, ханнар өчен кеше башын кисү уен гына түгелмени?! Кәтиб Хафизга фәрманны укый башлагач та ханның сикереп торып басуы ошамады. Монда нииндидер сер бар иде, сер генә түгел, оста оештырылган ялган, мәкер. Бит ул хан кулы белән язылган юлларны үз күзе белән укыган иде.

Саксин казый, титаклый-титаклый, кәтиб Хафиз кулындагы төргәкне алып, баш казый Ишкулга китереп бирде. Ишкул кулына төргәкне алды да әйләндереп-тулгандырып карады, сүтте, алдын-артын бакты. Кәгазь битендә бер кәлимә сүз дә юк иде. Кәгазь битен үрелеп кенә шәех Игәнәй алды, ул да әйләндереп-тулгандырып чыкты, кәгазь ханга күчте, хан кәгазь битенә хәтта карап та тормады.

— Кая ул фәрман, кәтиб Хафиз? Ни укыдың син?!

— Фәрештәләр сүзен укыды ул, ханиям,— диде шәех Игәнәй.

— Әллә изге җанмы минем кәтибем, шәех?

— Гөнаһсыз җан, ханиям.

— Ә вәзирем?

— Вәзирең гөнаһлы. Ул кеше ышанмастай гафиллек кылган. Иблис кылмастай явызлык кылган.

— Хәзер миңа гөнаһсыз җан янәдән укысын хан фәрманын,— диде хан.

Саксин казый хан кулыннан кәгазьне алды, йөгерә-атлый диярлек кәтиб Хафизга китереп тоттырды.

— Йә, кәтиб Хафиз,— диде хан.— Укы, нигә телең йоттың?

— Елга ярсыз, ил чиксез булмый, ханиям. Мин ул фәрманны яттан гына укыган идем, хәзер гүя, җил алды.

Вәзир Исхак көлемсерәп куйды һәм икенче мәлдә инде бирелә барган чарадан җирәнеп читкә карады. Сәлим хан гасабилана башлады. Вәзир үзен гаять дәрәҗәдә тыныч тота кебек иде, һәрхәлдә ханга шулай тоелды.

Вәзир аңа кирәк иде, хәтта бик кирәк, ләкин бүгенге хөкем түмәрендә утырган вәзир түгел, элеккесе, хан өчен утка да, суга да керергә әзер торганы. Элегрәк булса, бик ихтимал, хан вәзирен кичергән дә булыр иде, хәзер юк, хәзер кичерсә, аны берәү дә акламас. Ташның тамыры, ханның кардәше юктыр, бәласеннән башаяк. Бусагама йөз сөрүче табылыр, баш исән булсын да халык алдында вөҗданың пакь булсын. Кем булыр вәзирем? Бусагабаш Камай. Балта биреп, шөшле алу була булуын да, нишләмәк кирәк, бичарадан шуңа барырга туры килердер.

Сәлим хан баш казый Ишкулга күзләрен йомып ияк какты, янәсе, башла, хөкемең чыгар. Ишкул Болгарда иң олы хокуклар белгече. Җаен тапсын. Сәлим ханның күз йомып, акрын-сабыр гына ияк кагуы, вәзир Исхакны кылган гөнаһлары өчен башын кисәргә боерык иде.

Баш казый, аллаһы тәгаләгә мөрәҗәгать иткәндәй, ике кулын күккә күтәреп, иреннәрен кыймылдатып кына нидер укыды, аннары әле бер казыйга, әле икенчесенә карап алды, янәсе тегеләрдән ризалык сорады, казыйлар, аларга ияреп, шәех Игәнәй һәм хан, килешеп, ияк кактылар. Шуннан Ишкул:

— Илгә, ханга кылган гөнаһлары өчен вәзир Исхакның башын кисәргә. Җәллад хөкемне...

Каршы яктан тоташ карадан киенгән җәллад керде, ул ашыкмый гына, гадәти эшен башкарган берәүдәй, вәзир Исхакның башына капчык кигерде, шулай ук ашыкмый гына түмәр янына тезләнергә, башын түмәргә салырга кушты. Шулчак кәтиб Хафиз Сәлим хан алдына килеп тезләнде.

— Кичерегез аны, ханиям! Алла хакы өчен кичерегез. Вәзир Исхакның гаебе юк, ул гаепсез! Уг...— «Углан исән, исән!» дип әйтергә теләде кәтиб Хафиз, ләкин артында җәллад айбалтасының дык итүен ишетеп, әйләнеп карады һәм, вәзир Исхакның канлы гәүдәсен күрде дә, ике кулы белән йөзен каплап, сыгылып төште.

— Монысын зинданга илтеп ябыгыз! — дип сикереп торды Сәлим хан.

Шул мәлдә Кара Пулатка бәрелә-сугыла ханбикә килеп керде. Килеп керде дә, Исхакның җансыз гәүдәсен күргәч, чырыйлап кычкырып җибәрде.

— Ханиям, нишләвең бу?! Кылма явызлык, явызлык сиңа һәрчак явызлык китерде!..

— Алып чыгыгыз моннан ханбикәне!

Боерыкны үтәргә дип җансакчылар ханбикәгә ташландылар, әмма Зөбәрҗәт аларны, гүяки, селтәп кенә җибәрде һәм ханга таба атлады.

## 17

Болгар тәхетенә утырганнан бирле Сәлим хан бик күп кешеләрнең башына җитте. Алар арасында тәгаен гөнаһсызлары да булгандыр. Йә алла, барысы да синең кулыңдадыр. Иншалла, ул җәзалаган адәмнәрнең җаннары оҗмахта булыр. Нишләмәк кирәк, буйсынмаган, баш бирмәгәннәргә, качкыннарга бердәнбер чара баш кистерүдер. Җәза биргәндә ни шәфкатьсез булса да, Сәлим хан күңеленнән аллаһы тәгаләдән мәрхәмәт сорады, бөтен булган языкны казыйларга, җәлладына төшерүен үтенде.

Җәллад балтасында кан кипмәвен белеп-ишетеп торган сарай халкы да куркуга калды, бу курку хәтта Ага-Базарга ук барып җитте. Хан Ага-Базарга юнәлдеме, куштан халык җил алгандай юкка чыкты. Әмма Сәлим ханга явызлык явызлык китерә торды, аңа корбан эзлисе юк иде, алар үзләре килә торды.

Мәгәр соңгы елларда халык алдына бик сирәк чыкты, күп очракта киңәшчеләре аша хәбәрдар булды. Киңәшчеләре хан алдында ялагайланды, юмакайланды, сырпаланды. Дөрес, чамадан уздырып җибәрүчеләре дә бар иде, әмма ул аларны кичерде, чөнки баллан-

ган сүзләрне тыңлавы рәхәт иде. Кайберәүләре исә аны пәйгамбәр итте. Сәлим хан белә иде: ул пәйгамбәр түгел, әмма күңел зурлауны барыбер кабул итәр иде.

Болгарда аңа баш бирмәгән, буйсынмаган, ни уйлый, шуны әйтердәй бары тик ике кеше бар иде — ханбикә Зөбәрҗәт һәм өлкән угланы әмир Хаҗи. Вәзирнең башын кистергәч, ханбикәсе казый һәм җансакчылары алдында чәрелди-чәрелди: «Син — Газраил, син — башкисәр!» дип кычкырды.

Мәгәр Сәлим хан Зөбәрҗәт ханбикәдән курыкмый иде. Хатын-кыз чәпчер-чәпчер дә туктар. Ахыр чиктә ул ил тынычлыгы, дәүләт иминлеге өчен кыла бу явызлыкларны. Болгар бай, җитешле яши. Урыслар әйтмешли, монда беркайчан да сөт елгалары акмаган, кисмәкләргә бал таммаган — барысы да хан тырышлыгы белән килгәндер. Анңары Олуг хан дип халык та, солтаният илләрендәге кебек, ул атланган атның тояк эзен үпми. Болгар гадәттә болганырга ярата, бу халыкны богауда тоту өчен кодрәт, дәһшәт кирәк. Ә дәһшәт дигәне Сәлим ханда бар — һәммәсе дә курка. Әйе, өлкән угланы дәшмәс булды. Ямчы җибәрә — килми, хат яза — җавап юк. Кала сала, вакыты тар, имеш. Ә менә мин сиңа үзем барып төшсәм, углан? Әйе, әйе, үзем. Һәм буш кул белән түгел, гаскәр белән?

Хәер, шуңа охшаш хәл Бөек Болгарда да булган түгелме соң? Олуг хан Кубрат хәзәрләр яу килүен ишеткәч, өлкән угланы Батбайга ямчысын җибәрә: «Илгә яу килә, ярдәмгә чык!» Әмма Батбай угланы атасына җавап та бирми, ярдәмгә дә килми. Олуг хан Кубрат хаталанган. Аңа әүвәл угланы кырына яу чабасы иде. Әүвәл башбирмәс угланын акылга утыртасы, ил-гаскәрен таратасы булган. Сәлим ханга монысы да билгеле. Кубрат хан үлгәч, угланнары кайсы-кая таралып бетә. Икенче угланы ыру-кардәше белән Идел буена күчеп килә. Илтабар Кодрак Тәңре алласы белән үлсә дә, аннан соңгы ханнар акрынлап ислам динен кабул итә. Әнә шулай Болгар бабалары алласыннан йөз чөерә. Хәер, алла алыштыру бик борынгыдан киләдер. Борынгы мисырлылар Ра аллаларын да шулай итә, халыкны куандырмый башлагач, Әсирис һәм Исидә белән алыштыралар. Әмма бу аллалар да мисырлыларга җәннәт китерми...

Инде менә ничәме йөз ел Мисырда да, Болгарда да ислам дине хакимлек итә. Изге китапта: «Аллаһы тәгалә юлында корбан булган мөселманны ахирәттә җәннәт көтәр», дигән юллар бар. Сәлим хан да алла юлында, иншалла, җан биргәнгә, җүн бирер әле.

Сәлим хан урелеп кенә изге китапны алды, юраучыларга фал ачты һәм күзе төшкән юлны укыды: «Сабыр иткән — морадына ирешкән».

Китапны япты да янә уйга калды.

Әйе, сабыр итә алдымы ул?

Төрле хәлләр булгандыр. Әйе, адәм баласына ялгышу да хастыр, кайбер кыштаннары әйтмешли, ул пәйгамбәр түгел, була да алмас.

Ни өчен?

Кылган хаталары шулдыр: җир-суларын угланнарына бүлеп бирде, бөтен халык алдында вәгъдә итсә дә, тәхетен югалтудан куркып, Яңа Кала нигезенә оныгын күмдерде, ахыр килеп, гөнаһсыз вәзирен языклы итеп, башын кистерде.

Явызлыкмы бу?

Әйе, явызлыктыр, шәфкатьсезлектер, миһербансызлыктыр.

Мәгәр дөнья яратылганнан бирле шулай килгән ич: арыслан кодрәт белән, чүл бүресе явызлык белән көн күргән.

Син кем соң? Арысланмы, чүл бүресеме?

Тик кем генә булмасын, ул угланы әмир Хаҗины буйсындырыр-

га тиеш. Хак анысы, Болгарда ата белән углан сугышмаган. Әмма Сәлим хан сугышыр, моны аннан аллаһы тәгалә, ил иминлеге таләп итә.

* * *

...Җария кыз күзләрен челәйткәч, Сәлим хан аның толымын җибәрде, бала шундук аның аяк астына ишелеп төште. Сәлим хан почмакта өелгән, котлары алынып куркынган кызларга, идәндә аунап яткан җариягә карады да җилләнеп чыгып китте.

Атына ничек атланганын ул хәтерләми, Баян баһадир катына килеп кергәч кенә исенә килде һәм капкадагы ясавыл азатка:

— Баһадирыңны чакыр! — дип кычкырды.

— Мин монда, ханиям! — дип килеп чыкты Баян.

— Баһадирым, Назлыгөлне урлаганнар. Куа чык. Җир астыннан булса да йолып алып кайт. Ишетәсеңме, баһадирым, җир астыннан булса да!

— Баш өсте, ханиям. Быргычы! — дип боерды баһадир.

Быргы кычкырттылар, капка катына атлы азатлар җыелды, баһадир аларга боерык бирде һәм алар йөзәр-йөзәрләп кирмән капкаларына таба чаптылар. Боларның барысын да күзәтеп торган Сәлим ханга бераз гына тынычлану килде, борылып сарайга кайтты.

Тәхетенә утырып, тирә-юньгә күз ташлагач кына:

— Бусагабаш, Назлыгөл белән күл буена төшкән кызларны дәш, — диде.

— Ханиям, — диде бусагабаш. — Ул кызлар ханбикә янында, алар берни дә белми. Назлыгөл күл буена үзе генә төшеп киткән булган, болар өстәге аланда калганнар.

— Күл буенда бер кеше дә булмаганмыни? Ир-ат дим, ир-ат?

— Бер карт булган. Юкә батыручы диме. Ләкин ул чукрак, начар ишетә.

— Китер шул картны. Колагы ишетмәсә, күзе күргәндер. Тиз йөр!

Сәлим хан гасабилы иде, тәхетеннән купты да, ишекле-түрле йөренә башлады. Кешегә әйтсәң, кеше ышанмас, билләһи, көпә-көндез хан кызы кадәр хан кызын урласыннар инде. Ясавыллар ни караган? Хәер, ул аларга үзе күл буена төшәргә кушмаган иде. Кем эше булыр? Шулай ук Олуг Мөхәммәт онытмадымы? Үч алумы? Һич булмас димә. Кенәз Всеволод түгелдер инде? Алай дисәң, Саксиннан гүзәлләрнең гүзәлен алды. Юк, Всеволод кенәз булмас. Мөмкин түгел. Анда хатын кайгысы түгел, минемчә. Әйе, Олуг Мөхәммәт, бары тик...

Ул арада тәхет ханәсенә бусагабаш килеп керде, янәшәсендә кәрлә буйлы, кәҗә сакаллы карт. Сәлим хан тәхетенә утырды, бусагабаш картны хан каршына китереп бастырды.

— Йә? — диде хан. — Ни күрдең бүген иртән күл буенда?

— Ханиям, ул начар ишетә, чукрак, кычкырыбрак.

— Син кычкыр колагына син. Әйт...

— Сөбханалла, ханиям. Күрдем, күрдем. Ике җария өске аланда калды, берсе, нурлы киенгәне, йөгереп күл буена төшеп китте.

— Шуннан, шуннан?

Кәрлә карт янә хан аягына килеп тезләнде.

— Гаеп миндә, ханиям. Шайтан котыртты. Мин аларны коеныргa килгәннәр дип белгән идем. Күз — шайтан, күңел — шомбай, диләр бит. Сылулар, зифалар, күрер идем дә төшемә керерләр иде.

— Шуннан ни булды соң?

— Бермәлне өермәдәй өч егет килеп чыкты. Атлары, мин сезгә әйтим, ханиям! Канатлары гына юктыр. Алмачуарга атланганы күл

буена төшкән кызны карчыгадай эләктереп алды да, фьют, әйтерсең, җил очырды үзләрен. Мин исемә килә алмый тордым.

— Күл буена төшкән кыз, җайдаклар килеп чыккач, кычкырдымы соң, ярдәмгә чакырдымы?

— Менә анысын ишетмәдем, ханиям. Чукрак бит мин. Яшь чакта ат типкән иде.

— Каракларның йөзләрен күрмәдеңме? Танымадыңмы берәрсен?..

— Алмачуарга атланганының күлмәге җофар тиресеннән иде, йөзен күрмәдем, ханиям. Ерак иде. Мин куаклар арасында идем, алар — түбәндә.

— Киемнәре, киемнәре кай халыкныкы?

— Сезнекенә охшаган, ханиям, сезнекенә — затлы, ипле, матур. Атлары да канатлы диярсең. Әле дә күз алдымда, кызны алганы алмачуар атта, калган икесе җирәндә иде бугай. Әйтәм ич, канатлары гына юк иде атларының. Әй оста эләктереп алды да соң кызны, нәкъ карчыга чыпчыкны каптырган кебек, теге бичара исенә килә алмый да калды.

— Тукта, карт. Атың ничек?

— Кәшәй мин, Кәшәфетдин...

— Кәшәфетдин, димәк. Камай, картка ике алтын бир дә озат үзен.

— Ханиям, — диде карт тегене алып китә башлагач.— Кызыгыз Назлыгөлне кем урлаганны әйтимме? Өстәгез тагын өч алтын, ат алыйм. Һәй, шул бер атка атланып чыксаң икән ул!

— Бирегез картка тагын өч алтын..

Камай Кәшәй картның уч төбенә тагын өч алтын салды. Карт алтынның өчесен дә тешләп карады, тәгаен алтын икәненә инангач кына:

— Олуг Мөхәммәт кешеләре урлады кызыгызны, ханиям, — диде.

— Әллә синең башың икеме, карт?

— Бер, бер, ханиям. Сез илчесен үлтердегез, ул кызыгызны урлады. Бер яманга бер изге. Хода аны бик тә белеп биргән кешеләргә, ханиям.

Шунда гына тәхет артына килеп баскан ханбикәне күрде Сәлим хан, күрде дә кисәк куркып киткәндәй булды.

— Ханиям, Гали оныгымны корбан итүче вәзир Исхакмы?

— Мин аңа җәза бирдем инде, ханбикә.

— Бу карт дөресен әйтсә? Назлыгөлне чынлап та Олуг Мөхәммәт кешеләре урлаган булсалар?

— Мин бу тиле-миле картка ышанмыйм, ханбикә, — Сәлим хан, алып китегез картны, дип кул селтәде. — Назлыгөлне урлаучыларны Баян баһадир куа китте. Ул аларны тотар. Тиздән белербез, ханбикә. Елама.

— Мин еламыйм, ханиям, бәгырем катты. Соңгы вакытта син бик күп явызлыклар кылдың.

— Ханбикә, Назлыгөлебезне табармын, табармын!

— Күктәге айны күлдән эзләмиләр, ханиям. Чакырыр идең угланнарыңны, киңәшер идең. Кызыбызны чынлап та Олуг Мөхәммәт кешеләре урлаган булса — җибәр бер угланыңны Өргәнечкә...

— Сабыр итик, ханбикә. Сабыр төбе — сары алтын ди халык. Ни каттың, кап корсак, җибәр чапкыннар угланнарга! — дип җикерде Сәлим хан бусагабаш Камайга һәм тегене гүя җил алды.

## 18

Мәргән кушаматы аңа хан мәктәбендә тагылды. Бачман баһадир тарафыннан. Чөнки Тубыкбай баһадир энесе Җик уктан шул хәтле төз ата иде ки, теләсә, кошның күзенә тигезә иде.

Тубыкбай баһадир энесен хан мәктәбенә җиде яшь тулгач китерде. Хәрби орышларга өйрәтүче Бачман баһадирга:

— Ите сиңа, сөяге миңа, — дип калдырды һәм яшь мәргәнне, бары тик ундүрт яшь тулгач кына, алырга килде. Җик абыйсы белән кайтып китмәде, Булат углан белән Саксин каласына китте. Тубыкбай баһадир ни әйтергә белми аптырады да калды. Булат беренче елын укый, ә Җик Мәргәнгә (аңа башкача дәшүче юк иде инде) ундүрт яшь тулган иде. Җәй айларын Саксин каласында уздырып, Җик Мәргән янә мәктәпкә әйләнеп кайтты, тик бу вакытта Бачман баһадир әмир Хаҗи карамагындагы Казан кирмәненә күчкән иде инде. Җик Мәргәнне Баян баһадир тәрбиясенә күчерделәр. Хан оныкларына ундүрт яшь тулганда Җик Мәргән сарай мәктәбен тәмамлап, меңбаш дәрәҗәсе алып, иленә кайтып китте. Кайткач күрде: абыйсы үзен эрерәк тота, Җик Мәргәнне үз янында меңбаш дәрәҗәсендә хезмәт иттермәкче. Карап-карап торды да Җик Мәргән абыйсының кыланышларына, түзмәде, көннәрдән бер көнне:

— Миңа атамның ярты җирен бирерсең, моннан ары болай яши алмам,— диде. Тубыкбай дәшмәде, энесенең теләген кабул итмәде, иллә ачуы чыгуын сиздермәскә тырышты.

— Җаек буена кирмән салырмын, торыр илем Җаекның түбән тарафы булыр. Мин синнән моны таләп итәм, абыем, — дип өстәде Җик Мәргән.

Тубыкбай камчысын ике арага ташлады, болай да калын муен тамырлары чыбыркы сабыдай кабарып чыкты.

— Җаек буйларын гына түгел, энекәш, сиңа Ык буйларын да бирмәмдер,— диде. Каты итеп, кайтарып сорамаслык итеп, теш арасыннан еландай ыслап әйтте.

— Бүртенмә юкка, абыем, мин анда ил чиген саклаячакмын.

— Ил чиген ил бүлеп сакламыйлар, энем. Яшәсәң, кул астымда яшәрсең, яшәмәсәң, кан дошманыма әверелерсең,— диде Тубыкбай баһадир.

Һәм шул житә калды Җик Мәргәнгә, сикереп торды да икесенең уртасында яткан камчының сабын шартлатып сындырып абыйсы ягына ташлады. Ташлады да, артына әйләнеп карамыйча, чыгып китте. Иң якын иш азатларын алды да Бөек Калага китте, Сәлим ханга баш иде.

— Ханиям, абыем мине илдән куды. Мин аны моның өчен кичермәм. Ыруыбыз моннан ары миннән башланып, миннән китәр,— диде.

Сәлим мәргәннең бу кыланышына ирен чите белән елмаеп кына куйды. Кайнарлану дала ыруына хас сыйфат, үтәр, дип уйлады. Мәргәннең, ил чигенә кирмән салам, дию ханга ошады, мәгәр ул аның теләген хуплый алмады — Тубыкбай баһадир белән арасын бозарга теләми иде.

— Мин сине сараема баһадир итеп алам,— диде Сәлим хан.

— Ханиям, сарай тирәсенә — сорыкорт, елга буена кош җыелыр, ди, булмастыр алай,— диде һәм борылды да чыгып китте.

Башимәс энесен куып тотарга чамалап, Тубыкбай баһадир Бөек Калага килде, әмма хәбәр иткәннәрмедер, Җик Мәргән хан кирмәненнән чыгып китәргә өлгергән иде. Тубыкбай энесен куа чыкты, иллә беркайда да таба алмады. Ни Чулман, ни Җаек тирәләрендә, ни Идел якларында күренмәде Җик Мәргән, гүя җир упты мәргәнне. Ай буена ары чабып, бире чабып алҗыган Тубыкбай баһадир кул селтәде дә иленә кайтып китте, иллә кайтып керүгә аңа:

— Энең Җик Мәргән яшь хатының белән болынга төшеп китте,— дип әйттеләр. Тубыкбай баһадир, ачуыннан шартлар дәрәҗәгә житеп, җансакчыларына әйтергә дә онытып, чаптырып болынга төшеп китте һәм су буенда ике атның гына утлап йөрүен күреп, яшел үләнгә капланды да үкереп елап җибәрде.

## 19

Хажи белән Илһам угланнары каршысына килеп баскач, Сәлим хан ачуы килүен яшермичә эндәште:

— Сеңлегезне урладылар, ә сез аю кебек өйдә ятасыз. Кем эше дип беләсез?

Угланнар дәшмәде, башларын игән килеш тора бирде. Ниһаять, Хажи углан телгә килде:

— Мин урлаган дип уйлавың түгелдер бит, атам?..

— Хан кызларының берсе урыста, берсе гарәптә, берсе табгачта — урладылармы сеңлебезне, үзе теләп китүеме әллә, атам? — диде Илһам углан.

— Нәрсә син, Илһам углан, болгар кызларын ике тиен бер акчага сатып торган сыман... Назлыгөлне берәрсенә ябышып киткән дип әйтергә исәбең юктыр ич?

— Хатын-кызга ил ни дә, ата-ана ни? Карама куышыннан төшкән халык бит ул. Назлыгөлгә оста Дәүран гашыйк икән дип житкерделәр миңа,— диде әмир Хажи кыюлана төшеп.

— Тәхетем өстендә әйтәм, сөйләмә тузга язмаганны, углан Хажи. Ничек инде хан кызы кол остага ябышып чыксын ди?!

— Атам, оста Дәүранны мин коллыктан азат иттем, ул, дөньясын онытып, яңа кала салып ята. Киләсе елга Владимирдән, Румнан сәүдәгәрләр кабул итәргә исәбем. Кунакханәләр корабыз.

— Мине синең кунакханәләрең кызыксындырмый, углан.

— Ишетүемчә, атам, вәзир Исхак Гали углымны яңа кала нигезенә корбан иткән икән. Мин аны җәзаларга дип килдем.

— Мин аны җәзаладым инде, углан. Бер кешенең ике тапкыр башын чапмыйлар.

— Атам, аллаһы тәгалә алдында ант итәм, үзе үлтерелгән булса, углын яңа калага илтеп корбан итәчәкмен.

— Житте, Хажи углан. Вәзир Исхак аллаһы тәгалә алдында да, синең белән минем алда да үз җәзасын алды инде. Углы мәктәбемдә укый, акыллы бала.

— Мин сиңа әйттем, атам. Инде миңа нишләргә, вәзир Исхакның нәсел-нәсәбен корытыргамы, углым кабере өстенә ятып еларгамы?

— Сабыр итәргә, сабыр итәргә, углан...

— Сабыр итә алмамдыр, атам. Мин әле кемнән үч алырга белмим, тик мин аны белермен, атам, белермен.

— Сабыр, сабыр, углан, әйтмә килешмәгән сүзләр. Тел ярасы кылыч ярасыннан да ямандыр. Сабыр ит, явызлыкның явызлык булып кайтуы бар. Ә син нигә дәшмисең, Илһам углан?

— Иңендә ил кайгысы, атам. Мин сеңлем турында уйлыйм. Барысына да илче үлеме гаепле кебек миңа. Бүген сеңлебезне урладылар, иртәгә илгә яу килер сыман.


— Син тыя алган булыр идең аны, атам. Вәзир җүләр кеше түгел иде, ничек ул моңа барды микән?.. Кыен миңа, атам, бик тә кыен! — диде әмир Хажи.

— Үлгән артыннан үлеп булмый, үлгәнгә ожмах, үлмәгәннәргә дөнья кайгысы,— Сәлим хан әмир Илһамга таба борылды: — Акыллы хатын ике көзге тотар, ди. Берсе аша иренә, икенчесе аша күршесенә карар, ди. Булат оныгымны ал да Өргәнечкә җыена башла. Киләсе язга кузгалырсың. Олуг Мөхәммәт кулы булса, бәхиллегем юк, һич югы, шул сүземне әйтеп кайтырсың үзенә.

— Атам, китим мин. Акбикә киленең үз-үзенә урын табалмый калды. Югалтуым, хәсрәтем чамасыздыр.

— Ил өстенә төшкән кайгы түгел, түз, углан.

— Гали углым кәтиб Хафизны ярата иде, бир син миңа аны, атам.



*А. Тимерғәлина рәсеме.*

— Кәтиб Хафиз зинданда.
— Зинданда?! Ни өчен?
— Кала нигезен карарга ул да барган иде. Вәзир Исхак аның каршында кешегә әйтсәң кеше ышанмастай явызлык кыла, ә ул барысын да күрә, дәшми, туктатмый. Дәшкән бер гаепле булса, дәшмәгән ике гаепле.
— Атам, син аны хәзер үк зинданнан чыгарырсың һәм миңа биреп җибәрерсең. Мин моны синнән таләп итәм, атам!
— Хаталанма, углан, хаталана күрмә. Кем сине әмир итте, кем сиңа тиңе булмаган җирләр бирде, кем сиңа яңа кала күтәртә? Ишеттем, башкаланңны да анда күчерергә исәбең икән. Күчерә бир, иллә артыгын кыланма. Ә кәтиб Хафизны алып китәрсең. Әй син, бусагабаш, кәтиб Хафизны әмир Хаҗига биреп җибәр, ишетәсеңме!
Бусагабаш чыгып киткәч, әмир Хаҗи атасыннан сорап куйды:
— Сарай хансыз, хан вәзирсез булмас, диләр, вәзирең кем булыр инде, атам?
— Хак әйттең, углан. Вәзир ил күзе дә, сарай күзе дә. Мин бу хакта ашыкмаска булдым. Бусагабаш Камай да вәзир булмаслык кеше түгел.— Сәлим хан әмир Хаҗиның йөзе сытылуын күрде дә Камайны мактарга кереште: — Син аңа алай мыскыл итеп карама, углан. Вәзир кеше булырдай ул. Тыңлаучан, сабыр.
— Агач нигә корый, атам? Тамыры киселгәч, кәүсәсендә сул йөрми башлагач. Әйтер сүзем шулдыр, атам, Болгарның берәм-берәм тамырың кисәләр. Ярый, бусагабаш Камайны ил күзе дип кабул итәсең икән, итә күр. Мәгәр мин аның белән яуга бармас идем. Янә шигемне әйтми дә китә алмамдыр, атам. Назлыгөл оста Дәүран кулында түгел микән дигән шигем бар.
— Назлыгөл Олуг Мөхәммәт кулында, угланнар. Барыгыз, китегез. Син, Илһам углан, Өргәнечкә җыена башла, ә син тизрәк яңа калаңны кор. Сараең салгач, үзем килеп карармын.
Әмир Хаҗи тыенкы гына баш иде һәм алдан чыгып китте, әмир Илһам кала төште.
— Углан Илһам,— диде Сәлим хан.— Син Өргәнечкә барма. Олуг Мөхәммәткә мин башка берәүне җибәрермен. Хуш, углан.
Сәлим хан тәхетеннән төште, ишекле-түрле йөренә башлады. Хаҗи аның өчен көннән-көн сер тубалына әверелә бара иде. Шайтан каласындагы хикмәтләр, карурмандагы сукбайлар, качкыннар, юлбасарлар — барысы да әмир Хаҗи җирләрендә сыену урыны таба. Әмир Хаҗи алар белән көрәшкән дә кебек, шул ук вакытта берәүсен дә тотып китергәне, башын кискәне юктыр. Аннары Хаҗи угланы кулында Болгарның барлык тимере, Төн илләренә чыгасы сәүдә юллары, ниһаять, Казан кирмәне. Шуларның барысын да күз алдына китерүгә, Сәлим хан үзалдына өшеп киткәндәй була. Йөргән җиреннән туктады, бөкшәеп, бусагабаш урындыгына утырды. Уйланырлык иде Сәлим ханга, угланы Хаҗи мөстәкыйльлеккә омтыла. Оста Дәүранга ирек биргән — коллыктан азат иткән, хәзер әнә сарай кәтибе Хафизны алып китте. Ә бит кәтиб Хафиз Болгарда бер акыл иясе диярга була.
Сәлим ханның төсе-йөзе качып, үз урындыгында утыруын күреп, Камай аптырый калды. Иллә Сәлим хан гүя аны күрмәде дә, уйлана бирде. Кимсенү дә түгел иде бу халәт, әллә ни шунда, гүя аны тәхетеннән бәреп төшергәннәр иде. Тәүге көче-гайрәте юктыр, кем ни әйтсә, шуны тыңларга әзер халәттә иде Сәлим хан. Ә бит Тубыкбай энесе Җик Мәргән дә аның урманында качкынлык кыла. Нигә соң әле ул угланы алдында каушап калды? Иң әүвәл катгый төстә, Тубыкбай энесе Җик Мәргәнне сарайга тотып китер, дип әйтәсе булган. Җитмәсә, болай да шикле күңелгә әллә ниткән шом салып китте. Имеш, Назлыгөл оста Дәүран кулында булмагае. Бу ни хәл

инде тагын! Елдан-ел елгырлана, үҗәтләнә бара әмир Хаҗи углан. Инде ни кыларга?..

— Камай, бар, Хаҗи угланны бор. Тиз! Йомышым калган.

Күп тә үтми,әмир Хаҗины китереп тә җиткерделәр. Ул китмәгән, анасы Зөбәрҗәт янына кергән булган икән. Угланы кергәләгәнче, Сәлим хан тәхетенә күчеп утырды.

— Ни булды, атам?

Тып-тыныч, әйтерсең, берни дә булмаган.

— Күчтем сәүдәгәрнең энесе тимерче Әхмәттә көн күрә икән. Олуг Мөхәммәт илчесе Садакның да җанын җәһәннәмгә ул җибәрмәде микән? Бел һәм миңа хәбәр ит.

— Яким Күчтем сәүдәгәр энесе Апанай сәүдәгәр түгел, атам, оста булырга теләүче адәмдер. Корал ясаучы ул, болгарлардан корал ясарга өйрәнә. Аннары Болгар борын-борыннан Владимир кенәзләре белән осталар алышып яшәде. Монда мин бер хилафлык та күрмим, атам.

Нәкъ менә шунда Сәлим ханның башына бер хикмәтле уй килде. Әгәр дә мәгәр, Болгардагы урыслар сиңа каршы сүз куешалар, ил-халкыңны котырталар, дип Андрей кенәзгә илче җибәрсә? Ул бер дә ышанмастай хәбәр түгел. Китан Күчтемнәр белән һәрчак бәхәстә. Илче итеп бусагабашы Камайны җибәрер, ышаныч зуррак.

Сәлим хан кисәк кенә башына килгән уйдан хәтта ияген чөя төште һәм алдында әмир Хаҗи угланын күреп:

— Сараең әзер булуга, карарга килермен,— диде.— Оста Дәүранны да күрәсем килә. Аңа ирек биреп әйбәт иткәнсең. Сарай йортыңа борынгы бабаларыбыздан калган казанны илтеп күмәрсең. Казанны бусагабашым бирер. Оста Дәүранга җиткер, атам килә, диген. Каланы миңа ошатырлык итеп корса, иң гүзәл жариясен бирергә ышандырды хан, диген. Беләсеңме, кызлар хакында ни язып җибәргән атаңа Олуг Мөхәммәт? Белмисең! Инде менә тыңла: Мәккәдән китерелгән кызлар кәнтәй булыр, күңел ачып яшәргә яратырлар, дигән. Мәдинәдән китерелгән кызлар исә иркәләнергә һәвәс. Дәмәшкъ кызлары акыллы вә сабыр булыр, һәрчак белемгә омтылыр, дигән. Бәрбәрәйдән китерелгән кызлар ел саен бала табучан, кара тәнле кызлар биергә, күңел ачарга җайлыдыр. Иң кадерле, иң бәһалесе ак тәнле яван, болгар, урыс кызларыдыр. Мөхәммәт пәйгамбәрдән соң килгән хәлифләр барысы да диярлек ак тәнле кызларга өйләнгән. Хатын-кызга бүтән дингә күчү авыр түгелдер, ир-атка исә ул үлем белән бердер. Әйтик, янә шул бар: ислам дине жарияң белән якынлыкны гөнаһка санамый, христиан дине исә жарияң белән якынлашуны гөнаһка саный. Шуның өчен мөселман жарияне үзенә хатын алгандай сайлый, христиан исә сеңлесен тапкандай сатулаша...

Әмир Хаҗи әтисен тыңламый иде инде. Булган хәл аны тәмам борчуга салды. Гали угланны кала нигезенә корбан итәләр. Назлыгөлне урлыйлар, ә әтисе ниндидер жарияләр турында авыз суын корыта. Я хода, атакай, картаюыңмы, акылдан яза башлавыңмы...

Әмир Хаҗи атасына яңадан бер кәлимә сүз дә әйтмәде, борылды да сарайдан чыгып китте. Атасы Сәлим хан угланын туктатмады, әйтәсен әйткән иде инде. Ә менә угланы белән әңгәмәдә башына килгән уен бик тиз тормышка ашырыр. Шәех белән киңәшер, кирәк икән, хәтта епископ Габбас белән дә. Тик игелекле киңәш бирә алырлармы аңа алла ялчылары?

## 20

Яңа вәзир Камай каршына килеп туктагач, Хафиз башта аның аякларын гына күрде. Ул аны аякларыннан да таный иде инде.

Вәзир Камайның итекләрендә тузан, кулында камчы, камчысы белән итектән тузан сибелә. Нигә Кашан кадәр Кашанга килде микән Камай? Ни калган әмир Хаҗи каласында, Сәлим хан үзе әйтмешли, бу апара тәпәнәнә?

Кәтиб Хафиз каләмен өстәлгә куйды, әкрен генә күзләрен күтәрде. Шунда ул вәзир Камайның елмаюга җәелгән калын иреннәрен күрде, кысык күзләрендә әйтелмәгән сүзләр биешә кебек иде.

— Ни хәл кылып ятасың, кәтиб Хафиз?

— Хәлләр аллага шөкер, вәзир Камай. Безнең ни, безнең шул язу да сызу инде.

— Мин сиңа бик тә кәттә йомыш белән килдем бит әле, кәтиб Хафиз. Хан җибәрде, үзе...

— Йомышыңны йомышла соң, вәзир...

— Һич югы, утырырга тәкъдим итәр идең?

Кәтиб Хафиз бүлмәсенә күз йөртеп чыкты, аның янына әмир Хаҗидан башка берәүнең дә кергәне юк диярлек, ә иясе кергән саен аның янәшәсендәге түмәргә килеп утыра. Әмире утырганга ул түмәргә кәтиб Хафиз мендәр куя торган иде, түмәрдә әле дә йомшак мендәр иде.

— Бу урын әмир Хаҗиныкы да инде, кадерле кунак килгәч, ни кылмак кәрәк. Утыр, әйдә, рәхим ит янәшәмдәге түмәргә, вәзир.

— Хафизҗан, син миннән курыкма,— диде Камай йомшак мендәргә утыруга.— Мин сиңа беркайчан да яманлык кылмам, әйе, кылмадым да.

— Фәрештәләрнең амин дигән чагына килсен иде дә бит бу сүзләрең, вәзир...

— Тыңла әле, Камайны, кәтиб Хафиз. Мин сине хан әмире белән сарайга алырга килдем.

— Сарайга?! Йә хода. Хан әмере белән?

— Әйе, кәтиб Хафиз.

— Фәрманын күрсәт...

Вәзир Камай куеныннан хан мөһер суккан төргәк чыгарды, кәтиб Хафизга сузды. Хафиз әүвәл хан мөһеренә игътибар итте, аннары җепне өзеп, төргәкне сүтеп җибәрде. Хак, аны хан кире сарайга чакырган иде. Боермаган да, итагатьле генә итеп дәшкән.

— Хан сине рәнҗетте, кәтиб, булды андый хәл, булмады түгел. Мин дә сине вакытында яклый алмадым. Хәзер төшендем, синнән башка сарай ямьсезләнде, ямь китте сарайдан.

— Мин кеше кешесе, вәзир Камай. Минем иям бар, син әүвәл аңа мөрәҗәгать итәр идең.

— Мин бернәрсә ишеттем, кәтиб Хафиз. Имеш, моннан берничә ел элек Ибраһим каласы өчен әче сугыш барганда сине Әндери кенәз азатлары әсир иткәннәр. Кенәздән сине Яким сәүдәгәр сатып алган... Шулаймы?

Кәтиб Хафиз гаҗәпләнүен яшермичә, яңа вәзирнең хәбәрдарлыгына исе китеп торды. Ә бит булган хәл. Милади белән 1164 елда яшь кенәз Андрей Боголюб Болгарга яу белән килде. Хафиз ул вакытта Ибраһим каласында иде. Ләкин аны әсирлектән бик тиз коткардылар — Яким Күчтем, Хафизның кем икәнен белүгә, кенәз йөзбашыннан сатып алды һәм янә Болгарга китерде.

— Булдым, вәзир Камай.

— Тел вә гореф-гадәтләрен дә өйрәндеңме?

— Телләрен дә беләм, вәзир.

— Ничек соң Әндери кенәз кулындагы кеше Күчтемгә барып эләктең?

— Моның өчен сиңа әсир төшеп карарга кирәк, вәзир Камай. Мәгълүм булса кирәктер, кенәзләр әсирләрен байларга әләшә, бушлай түгел, әлбәттә. Кенәзгә дружинасын тотарга акча кирәктер. Акча кемдә? Байда. Ә Яким — урыста иң бай сәүдәгәр.

— Син белекле галимме, тимерчеме?

— Мин, вәзир, галимдер. Ләкин галим дә түгелдер мин — китап күчерүчедер, тарих язучы, бер сүз белән, елъязмачы. Тагын да аңлаешлырак итеп әйтсәк, мин, вәзир Камай, Болгарның бөек галиме Ягъкуб Ногманның эшен дәвам итүчедер.

— Изге кеше, димәк.

— Эш булганда изге, эш булмаганда...

— Мин сине, кәтиб Хафиз, үзем белән Владимиргә алып барырга булдым. Хан рөхсәтен бирде. Тылмачым булырсың.

— Урыс телен син үзең дә начар сукаламыйсың кебек, вәзир. Аннары тылмачка мин сиңа кеше табармын, вәзир. Аннары кабат әйтәм, мин — кеше кешесе. Мин әмирнең угланын укытам, мин сабак бирәм...

— Әмирнең кече угланы тиздән сарайда булыр. Угланга җиде яшь тулган, хан аны барыбер сарай мәктәбенә алыр. Сарайда сабак бирерсең әмир угланына.

— Җитмәсме икән бер углан ханга, вәзир Камай? Гали угланны... хәзер кичесен...

— Бу хакта, кәтиб Хафиз, ханга үзең тәфсир итәрсең.

— Ханның кызын таптылармы соң әле?

— Олуг Мөхәммәт кулында, диләр. Хан үз-үзенә урын табалмый, ханбикә турында әйтеп тә торасы юктыр.

— Ә бит аның Болгарда сөйгән егете калды, вәзир Камай.

— Алпар углы оста Дәүранмы? Кол...

— Ул хәзер ирекктә, вәзир.

— Ирекне остага хан үзе генә бирә ала.

— Мин сиңа, вәзир, ата белән углан арасына кермәскә киңәш бирер идем. Карга күзен карга чукымый.

Камай бертын дәшми торды. Аңлап бетермәле түгел иде бу кәтиб Хафизны. Бар нәрсәдән дә хәбәрдар, җитмәсә, киңәш бирә. Киңәше начар дип тә әйтеп булмый. Чынлап та, ата белән углан арасына кереп, ике ут арасында гына калуың бар, баш-аяклары бер казан, тик бәхәсләшсеннәр үзара. Әмир Хаҗи атасына баш бирми башлады, ә Сәлим хан угланны бер сүз белән буйсындырмакчы була. Хаҗиның хәзер үзеннән күп тапкыр куәтлерәк, гайрәтлерәк икәнен белми: Казан елгасы тамагына тиңе булмаган кала корып ята. Кашанын ташлап шул тарафка күчеп тә куйса, бөтен сәүдә юллары әмир кулына күчәчәк. Юк, әмирсез алып китеп булмас бу кәтибне. Ә бәлкем алтынга алданыр.

— Хан сиңа зур өметләр баглый, кәтиб Хафиз.

— Тагын ни әйтерсең, вәзир? Күп алтын түләргә дә вәгъдә иттеме?

— Итте, кәтиб, итте. Ханга карышуың килешми.

— Акбикәдән сора һич югы, вәзир Камай. Хәер, бикә үз урынында, әмир үз урынында. Каравыш кыз турында сүз барса икән, вәзир...

— Үҗәт кеше син, кәтиб Хафиз. Дөньяда никадәр золым-җәбер кылына, кеше дигәнең һаман карыша. Кылынган явызлыкларда җан иңри, ә бит, кәтиб Хафиз, син мине чарасыз итәсең... Син хәзер минем белән сарайга китәсең, кәтиб Хафиз. Хан фәрманы. Җыен.

Йортта вәзир Камай белән килгән йөзбаш һәм аның азатлары тора, күбесе аттан да төшмәгән. Димәк, вәзир аны, хәзер алып чыгам, дип кергән. Ә ниндидер кәтиб карышып тора. Азатларның сабыры төкәнер, вәзир дәшүгә, бәреләсугыла өйгә керерләр. Азатлар янында әмир Хаҗиның каравыш кызлары урала. Кылтая, ирәешә, күз кысыша, көлешәләр.

Яңа вәзир аны барыбер алып китәр, әмир кайтып җитсә дә, җитмәсә дә. Шулай да кәтиб Хафизның күзгәләсы килми иде. Әмир Хаҗи аны хөрмәт итә, китаплар алырга акча бирә, аннары Җаббар угланны да ташлыйсы килми иде кәтиб Хафизның. Иллә хан боеры-

гына буйсынмый беркая да бара алмастыр.

— Бикәгә үзең кереп әйт, кәтибегезне алып китәм, диген. Мине син ирексезләп алып китәсең, вәзир.

## 21

Тардыр бу дөнья. Бик тардыр. Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнәгә Болгарга килгәндә бары тик тугыз яшь кенә тулып килә иде, хәзер әнә сазап та бара кебек инде. Күзләренә һичкем аңламаган моң иңгән, кыш көннәрендә еш кына тәрәзә каршына килеп утыра да ап-ак кар диңгезенә карап уйга кала. Кем өчен шулай сагышлана кыз? Әмир Хаҗиның да, Акбикәнең дә сораганнары юк, бу хакта Бачман баһадирның да сүз катканы юктыр. Баһадир белә: сеңлесе үзе теләмәгән кешегә кияүгә чыкмаячак. Килгән яучылар кыздан рәхимле караш көтеп ала алмый, борылып китәргә мәҗбүрләр. Ике баласы да угыл булгангамы, Акбикә Зәйтүнәне үз баласыдай якын итте. Ничек кенәләр якын итсә дә, ул кыздан кемне яратуы хакында җавап ала алмады. «Кемне көтәсең, балакай, вәгъдә биргән егетең бармы әллә?» — дигән чаклары да булды, иллә уктан алуда, атта йөрүдә егетләрнең асылларыннан да калышмаган Зәйтүнә барыбер ачылып китмәде. Тугыз ел инде менә Гали угланын югалтканга, әмма һаман күңелдән китми, хәзер әнә Җаббары йөзбаш булды. Ул арада Сәлим ханның Мәрьям килене дә малай тапты, Габдулла дип аталган угланга җиде яшь тулып килә икән инде, аны да сарай мәктәбенә алырлар, аны да меңбаш итәрләр, туганнар арасында кан коюю китмәсме? Сәлим хан шуңардан курка, диделәр. Бу хәлдә Акбикә Сәлим ханнан да битәр курка. Бер-бер сәбәп табып, Җаббар угланның да башына җитсәләр? Гали угланны бабасы үтерткән икән ич. Вәзир Исхакка үзе үк фәрман язып биргән, аннары үз фәрманыннан үзе ваз кичкән, имеш. Сәлим хан фәрман бирмәсә, угланда нинди үче булыр иде вәзир Исхакның? Ни әмир Хаҗи, ни Акбикә вәзиргә дошман түгелләр иде кебек. Хан әйткән, имеш, ике углан бер тәхеттә утырмый. Әйткәндер, әйтүе дә бар, утырмасыннар да, тик нигә баланы яңа кала нигезенә корбан итәргә?! Җитмәсә, әмир Хаҗи киләсе елда Казан дип аталган яңа калага күчәбез дип йөри. Бабалардан калган җиз казанны күлгә ташладылар да яңа калага Казан исеме бирделәр. Әйдә, бирсеннәр, тик нигә баланы корбан итәргә? Вәзир, вәзир! Шулай ук син дә җәбер-золымга бардыңмы? Гөнаһсыз сабыйның җаны кыелганын үз күзләрең белән карап тордыңмы икән?! Иңрәгәндер, наныем, әрнешкәндер, җан ачысы белән кычкыргандыр, минем килүемне көткәндер...

Акбикә Казан юлына карап торды-торды да күз яше белән елап җибәрде. Беренче тапкыр гына түгел инде аның елавы — күңеле әллә кайчан Казанда, яңа калада. Ичмасам, углы корбан ителгән төшкә ятып туйганчы бер елар иде, үксеп-үртәлеп, углына кул күтәргән кешене каргый-каргый. Ана каргышы тиз төшә, диләр. Төшсен иде, күрсен иде халык каргыш төшкәнне. Вәзир Исхакның да углы сарай мәктәбен тәмамлаган, диделәр. Имеш, Сәлим хан угланны атасы кебек үк әүвәл илче иткән, аннары үсә-исәя төшкәч, вәзире итеп тә куюы бар...

Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә урманга дип киткән иде, һаман кайтмый. Ул бала да күңелен борчый бикәнең. Егерме ике яшенә җитеп кыз бала берәүгә дә гашыйк булмады. Абыйсы Бачман да бер сүз дә әйтми. Сеңлесе дә зарланмый абыйсына. Әлек урманга җиләккә дип китә иде, хәзер ни сәбәпледер Шайтан каласына юнәлә. Бара алмады инде шул Шайтан каласына да бикә. Ичмасам Бачман баһадир да килми. Баһадир бикәгә битараф түгел, югыйсә,

бикәне күргән саен ачылып киткәндәй була. Әлегә чаклы өйләнми. Ә бер тапкыр: «Мин сезне яратам, бикә»,— дип тәмам акылдан шаштыра язган иде. Шул хәлдән соң Акбикә аны хәтта төшләрендә күргәләде.

Акбикә әкрен генә болдырга менде, шулай ук уйлана, моңлана-сагышлана өйгә керде һәм Зәйтүнә бүлмәсенә узды, кыз урындыгына утырды. Кичә аңа асрау кыз: «Зәйтүнә урманда бер батырны очраткан һәм шуңа гашыйк булган»,— диде. Акбикә шул сүзләрне ишеткәч, асравына ышанды да, ышанмады да. Ләкин күңел төпкелендә әллә ниткән шик калды. Ире әмир Хаҗи: Җик Мәргән безнең урманда йөри дигән иде. Анда качып йөрсә, бер күренер иде. Аннары күптән түгел әмир урманнарын Тубыкбай баһадир мең азат белән килеп, атна буена айкады, хәтта ат эзе дә тапмаган, диделәр. Димәк, юк сүз. Ә Җик Мәргән чынлап та урманда качып ятса, Зәйтүнә аның янына йөрсә?..

Бүлмәгә асрау кыз килеп керде һәм, борчуына гафу үтенгәндәй, чүгеп башын иде:

— Бикә, кырыбызга Бачман баһадир килде, сезне сорый.

Акбикә үзалдына кызарып китте, көткән иде ул аны. Бәлкем күптәнге вәгъдәсен үтәргә килгәндер — бикәне Шайтан каласына илтер, Шайтан манарасын күрсәтер?

Акбикә кунак каршысына чыгып, күрешергә дип кулын сузды.

— Хуш киләсең, баһадирым!

— Яңа каладан сәламнәр китердем сезгә, бикә.

— Күңелем яңа калага ашкына, баһадир. Үзем дә аңламыйм.

Бачман бүреген салып култык астына кыстырды, кыяр-кыймас кына түргә узды, бикә күрсәткән урындыкка утырды.

— Исәнлекме-саулыкмы, бикә?!

— Аллага шөкер, баһадир. Әмир кайтмаска да булды инде әллә? Кашанын бикәсенә калдырырга җыенмыйдыр ич?

— Киткәндә генә күрә алмадым, бикә. Анда эшләр бик кызу бара. Әмир мәчет салдыра. Мин сезгә сөенче китердем бит әле, бикә...

— Сөенче?! Нинди сөенче, баһадирым! Болай гына әйтәсеңме, бүләк кертимме?

— Сезнең елмаеп каршы алуыгыз минем өчен зур бүләктер, бикә.

— Куй әле, баһадирым. Шайтан каласына алып барам дип вәгъдә бирүеңә ничә ел инде?

— Гаеп миндә, бикә, кичерә күрегез.

— Йә, баһадирым, сөенечең әйт инде. Хатын-кызны көттерү гөнаһтыр.

— Бикә, миңа: Гали олан исән икән, дип ишеттерделәр. Өргәнечтә шәех Пәһлеван Мәхмүттә аңа ошаган бер шәкерт укый икән...

— Баһадирым, ниләр бирим икән бу сөенечеңә! Миңа бу хакта берничә кеше әйтте инде. Ике тамчы судай охшаган кешеләр азмыни бу дөньяда? Күңелемне тынычландыра алмасаң да, сөенечең өчен рәхмәт, баһадирым. Кызганыч, Өргәнечкә чыгып китә алмыйм, мин ул баланы күз карашыннан ук таныр идем. Хәзер аңа егерме өч яшь булыр иде.

— Быел мөгаллим буласы икән, диделәр.

— Һәй, баһадирым,— диде бикә читкә каерылып.— Җаны чыкмаган бала, һич югы, кош теледәй хат җибәрер иде анасына. Биккол сәүдәгәр әнә ике елга бер Өргәнечкә йөреп тора.

— Шул Биккол сөйләде дә инде миңа аны, бикә.

— Биккол ни сөйләмәс, дөньядагы барлык хәбәр аңарда, ялганы да, чыны да, булганы да, тузга язмаганы да.

— Мин бирегә сеңлемне күрергә килгән идем, бикә. Тик әүвәл вәгъдәмне үтәргә телим. Җыена алсагыз, Шайтан каласын күрсәтеп кайтыр идем.

Акбикә көмеш кыңгыравын чыңлатуга, бусагабаш килеп керде.

— Миңа ат иярләгез, туры бияне.

— Баш өсте, бикәм,— диде бусагабаш һәм аннары баһадирга борылып эндәште: — Баһадир, азатларың бикәнең кызларын рәнҗетә.
— Нишлиләр?!— дип сорады бикә.
— Каравыш кызлар белән ирәешәләр.
— Ирәешсәләр ни? Әллә каравыш кызларым арасында сөйгәнең бармы? Нигә дәшмисең? Файдаланып кал. Баһадир Бачман янымда чакта, теләгән кызыңны вәгъдә итеп куюым да бар үзеңә.
Бусагабаш йөгереп килде дә бикә алдына баш орды.
— Бу нигә тагын, бусагабаш!
— Каравыш кызларың арасында Гөлчәчкә атлы берсе бар, фатихагызны бирегез, бикәм!
— Менә сиңа мә. Сөешәсез икән...
— Мин аны яратам, бикәм.
— Ул дамы? Тор инде, тор, баһадирдан яхшы түгел, бөтен ирләр дә шулай баш орып яшәсә, миңа ни сан, дип уйлавы бар. Яле, чакырып китер әле сөйгәнеңне...
— Ул килмәс, бикәм, ул миннән көлә генә.
— Их, бусагабаш, бусагабаш, соң син әүвәл аннан сорар идең, «яратасыңмы мине, Гөлчәчкә?» дип... Алай да чакыр әле сөйгәнеңне, бар инде, бар.
Бусагабаш кыяр-кыймас кына күтәрелде, шигаебрәк, ишеккә таба китте.
— Тизрәк йөр, минем вакытым тар!
Бикә белән баһадир күзгә-күз карашырга да өлгермәделәр, бусагабаш сөйгән кызын җилтерәтеп алып та керде.
— Йә-йә, якынрак килегез. Гөлчәчкә, әйт әле миңа, яратасыңмы син бусагабаш Гатаны?.. Кыюрак, кыюрак, әмиреңнең бусагабашы сине сөя икән, ни әйтерсең?
Кыз тәмам югалып калды. Җитмәсә, баһадир Бачман елмаебрак утыра, кайчандыр ул аны сыйпап киткән иде. Бусагабашның әйткәне дә булмады ичмасам, һич югы бер тапкыр яратам дип пышылдасын иде, я сиздерсен иде, әнә баһадирның йөзбашы кебек. Ул бер дә оялып тормады, «әй, тутырган тавык, чыгасыңмы үземә кияүгә, чыксаң, хәзер үк бикәгә кереп ризалык алам», дип төчеләнеп торды. Кыз кырын күзе белән генә бусагабаш Гатага күз төшереп алды. Юк, гомер ир-ат йөзе күрмәсә дә, моның кочагына иңә алмас. Әнә вәзир Исхак белән бер кич кунган Сания, дөньяда сөйгәнең кочагында эрүдән дә татлы нәрсә юк, дигән була, моның кочагында эрү түгел, боз булып катарсың, җитмәсә шадра, борыны кирәкмәгән зур...
— Бикәм, мин бусагабаш Гатаны хөрмәт итәм, күзен төшергән өчен рәхмәт аңа. Тик... мин аны яратмыйм...
— Яши-тора яратып китүең бар, ашыкма әле син алай, Гөлчәчкә, егетнең күңелен төшермә. Уйлап кара. Ике-өч көннән кереп әйтерсең, ярыймы?
Кыз бусагабаш тоткан кулын ычкындырырга тырышты, ә теге, күрәсең, шул хәтле нык ябышкан, ни тартса да җибәрмәде.
— Җибәр, җибәр, Гата, кызның кулын. Сөймәгән сөякләрең булса, кияүгә чыкса да, игелек күрсәтмәс ул сиңа. Җибәр. Чәнечкеле икән бу кыз, бусагабаш...
— Чәнечкеле булса да, мин аның күңелен яуларммын, бикә.
— Менә монысы егетләрчә, Гата. Инде җибәр кызны, җибәр. Ат әзерме?
— Әзер, бикә.
Акбикә бераздан хәрбиләрчә киенеп чыкты. Болдыр янында аны иярле ат көтә, яшь азат атның ял астын кашып тора иде. Бикә атка атланды да тезгенне кулына алды, тайпыл читкә дип, азатка ияк чөйде. Аның янына баһадир Бачман килде.
— Мин азатларымны калдырам.

— Дөрес эшлисең, баһадирым. Гата, баһадирның азатларын ашатыгыз, күңелләрен күрегез,— диде бикә һәм ачык капкага таба кузгалды. Алар каладан атларын юырттырып чыктылар.

— Минем Шайтан манарасына керәсем килә, баһадир.

— Анда керергә киңәш итмәс идем, бикәм. Аннан әле бер кеше дә исән чыкмады, кергән һәрберсенең үле гәүдәсен елга буеннан гына табып алдылар.

— Баһадирым, синдәй ир-канатлар да шулай дигәч, тагын кемгә ышанырга тиеш инде мин? Шайтанның үзен күрәсем килә, үзен! Анда Чәчкә Ананың ире Болгар кам яшәгән, диләр. Имеш, аны кирмән нигезенә күмеп калдырганнар, шуның өрәге йөри, манарага керүчеләрне шул үтерә бара икән. Хакмы шул, баһадирым?

— Бикә, мин камнардан ерак торам. Әмма сезнең белән җәһәннәмгә дә китәргә әзермен. Дөресен әйтергә кирәк, мин үзем дә шайтан манарасына керергә күптән хыялланып йөрим. Анда кеше башына кем җитә икән? Чынлап та шайтан үземе, я кам өрәгеме? Әлбәткем анда качкыннар ятадыр? Мин, бикә, сеңлем Зәйтүнә дә шулар янына йөрми микән, дип шикләнә башладым. Менә ничә ел инде Җик Мәргән дә кеше күзенә чалынмый. Сәлим хан да тынычланды, баһадир Тубыкбай да кул селтәде бугай энесенә. Җик безнең урманнарда көн күрә дигән сүзләр йөри. Алайса нигә бер дә күзгә күренми?.. Шайтан манарасына исә берәүнең дә керергә хакы юктыр, бикә. Аны шайтан үзе саклый, диләр.

— Йә ходам, кем сөйли моны: әмир Хаҗи баһадирымы, Әтрәк хан азатымы?

— Сәлим хан үзе шайтан белән килә-китә киңәшә, диләр.

— Халык ни сөйләмәс, баһадир. Чәчкә Ананы албасты, сихерче диләр иде. Ә хәзер ханның иң якын кешесе булып китте. Минем ул шайтанны үз күзем белән күрәсем килә.

— Бикә, ни кылмакчы буласыз?

— Сеңлең Зәйтүнә кем янына йөри?

— Мин аны белермен, бикәм. Ләкин нигә шайтан манарасына керергә? Шайтанның теләсә кем сурәтенә керүе бар.

— Баһадир, килешми, килешми. Кем үлтерде илче Садакны, кем яшь азатның башына җитте? Кеше үтерүне кайчан явызлык дип санамый башлады әле баһадирлар? Минем аны күрәсем килә, баһадирым.

Бачман баһадир кыю, тәкәббер хатынга сокланып, шул ук вакытта бераз курка төшеп карады. Тиздән шайтан каласына җитәрләр. Бикә чынлап та шайтан манарасына керсә? Ни кылырга тиеш ул?

Бикәнең билендә алтын тәңкәләр тезгән каеш, каешка энҗеләр белән бизәлгән сөяк саплы хәнҗәр тагылган, аякларында үкчәле сафьян итекләр. Ефәк камзулы, балаклы чалбары да үзенә килешеп тора. Бикә маңгаена борынгы болгарларча яшел ефәк тасма бәйләгән, озын толымнарына көмеш тәңкәләр тезеп үргән иде. Кәмәрендә асыл ташлар, билбау чуклары төрле төстәге җепләрдәндер. Бикә үзенә аерым тегүче тота иде, хаситәсенә карасаң, күз камаштырырлык. Күлмәк җиңе очларын шул тиклем матур итеп челтәрләгән ки, бикәнең затлы киеменнән күз алмалы түгел иде. Баһадирның сокланып каравын бикә әллә кайчан сизә-тоя барды, шуңа күрә ул алгарак чыгып чапты, әле баһадир белән янәшә атын атлатып барды. Менә кирмән дә күренде. Шайтан кирмәнен меңбаш Бакырбай азатлары саклый. Зәйтүнә шуның янына йөрми микән, дигән уй килде Бачманга. Бакырбай күптән аның сеңлесенә күз атып йөри иде. Дөрес, Зәйтүнә аңа җавап бирде бугай инде — яучыларын кабул итмәде. Әлбәткем хәзер килешкәндер, картлар әйтмешли, кем белә бит әле, әллә юкә өзелә, әллә каеш. Аннары сеңлесе Зәйтүнәне келәмче әрмән сорады. Аннан да баш тартты кыз.

Кояш баш очына җитеп килә. Бикә әле янәшәсендә атын юырттырып барган, әле үзеннән кала төшкән баһадирга карый да үзалдына елмаеп

куя. Моннан шактый еллар элек. Бачман баһадир әмир Хажига хезмәткә килгәч, Акбикә аңа гашыйк булган иде. Гашыйк булса да, ул бу хакта баһадирга әйтергә кыймады. Моның соңы ни белән бетәсен әйбәт белә иде бикә. Болгарда ятлар белән язык кылган хатын-кызларны ботын-ботка аералар. Әмма йөрәккә йозак салып буламы! Яратуы хак иде. Илләкавышырга язмаган булып чыкты. Әнә шулай гомер дә үтеп бара. Ике углан тапты Акбикә. Галиен яңа кала нигезенә корбан иттеләр, хәзер әнә икенчесенең башына житмәкчеләр. Әйләнеп кайтырмы Кашанга углы, әллә анысын да шул ук язмыш көтәме? Бик күп сулар акты бугай инде шул гомер эчендә, ә тәүге мәхәббәте әле дә хәтерендә, әле дә йөрәген кузгатып куя. Зәйтүнәне үзендә калдыргач, куанып бетә алмаган иде Акбикә. Үсмер кызны кочагына алыр иде дә кысып-кысып яратыр иде, кайчак кочагында кыз бала түгел, гүя аның абыйсы Бачман булыр иде.

Көн матур, күк йөзендә ашъяулык кадәр генә болытлар йөзә. Чулман елгасының иң биек яр башында шайтан кирмәне утыра. Кирмән янәшәдә генә кебек, ләкин шактый барасы әле. Андагы хәлләр хакында ул ире Хажидан хәбәрдар. Әмирнең Шайтан каласында иң кадерле осталары — чуен коючылары эшли. Күпме кеше эшләвен Акбикә белми иде. Ул иренең андый эшләренә бөтенләй катнашмады. Әмма бер нәрсәне бик яхшы белә иде: әмир чуеннан тимер ясатып сата һәм шактый мул табыш ала. Хажиның тимерне озатучы ышанычлы сәүдәгәрләре бар. Владимир кенәзе Андрей Боголюб белән тыгыз элемтәдә тора. Кашанда урыслар урамы үсеп чыкты, кайбер урыс сәүдәгәрләре табышның симезен сизеп, Кашанга күчеп килә башлады. Әүвәл бу хәлгә вәзир Исхак канәгатьсезлек белдерде, хәзер ул юк, хәзер исә хан үзе угланына ризасызлыгын сиздерде. Әмма Хажи атасы кисәтүен үз авызыннан ишетмәгәч, тимерне күпләп сатуны дәвам итте.

Менә кирмән дә уч төбендә кебек кенә инде. Дивар өстендә ике-өч азат йөренә, баһадирны күргәч, багучы азатлар йөзбаш Бакырбайга хәбәр иттеләр, анысы ашыга-кабалана капкаларны ачты, асма күперләрне төшерде. Кирмәнгә кергән бер кешене әнә күзеннән үткәрәләр, сорауны гадәттә йөзбаш Бакырбай үзе ала, бүген исә, бикәне һәм баһадирын күргә, йөгерә-атлый каршы килде, чаптарны йөгәненнән эләктерде дә кунакка аттан төшәргә ярдәм итте. Шайтан каласына килгән мосафирның кулында хан ярлыгы булырга тиеш. Ярлык юк икән, калага керергә хакы юк, кергән хәлдә дә ерак китә алмый, аның һәр адымын дүрткүзләп махсус куелган азатлар күзәтә, анда да дөмбә мичләре урнашкан урамга керергә хаклары юктыр.

— Әнә ул шайтан манарасы,— диде баһадир Бачман бикәгә.

— Аны кем ашата, кем эчерә?— дип сорады бикә көлемсерәп.

— Манарада берәү дә яшәми, бикә.

— Анысы хакында белəм, баһадирым. Бер түгел, мең ишеттем. Кая соң Зәйтүнә? Йөзбаш Бакырбай,— диде бикә,— бирегә Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә килгәлиме?

— Булганы юктыр, бикәм.

— Бөтенләйме?

— Әйе, Зәйтүнәне күргәнем булмады. Кем янына килгән ул монда?

— Менә анысы сиңа билгелерәктер, йөзбаш. Син биредә ия, син каравылбаш.

— Әйе, мин каравылбаш, бикә. Ләкин Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнәнең кирмәнгә аяк басканы юк.

— Шайтан манарасына керергә исәбем, йөзбаш?

— Ихтыярыгыз, бикә, тик әмир Хажига баһадир ни дип җавап бирер икән? Минем дә башымнан сыйпамас әмир.

— Син кайсы заманда яшисең, йөзбаш Бакырбай?!

— Бик хәтәр заманда, бикәм. Кирмәндә каравылбаш булып торсам да, манарага ялгыш та кереп караганым юк.

— Теләгән иденме?

— Әйе, иллә әмир Хаҗи рөхсәт итмәде. Сезне дә әмир рөхсәтеннән башка кертмәмдер, бикәм.

Акбикә бер мизгелгә икеләнә калды. Чынлап та, әмире ни әйтер, башбаштакланып йөргән өчен ризасызлыгын белдерсә?

— Йөзбаш, бу манараны кем салып калдыра?

— Кубрат хан, диләр, бикә.

— Ярый, Кубрат хан да булсын ди. Тик нигә анда кергән бер кеше... Минем анда керәсем килә, йөзбаш?

— Игелегем бирә алмамдыр, бикәм. Әмир Хаҗи манарага берәүне дә кертергә кушмады.

— Мине дәме?

— Сезнең хакта бөтенләй сүз булмады, бикәм.

— Баһадирым, кемгә буйсына бу йөзбаш, сиңа түгелме?

— Миңа, бикәм.

— Шулай булгач, боер әле үзенә, бирсен манара ишегенең ачкычын. Ачыгыз ишекләрне!

— Әүвәл диварга менеп карагыз, бикә. Биредәге хозурлыкны кайда күргәнегез бар икән.

— Шулаймы? Ярый, йөзбаш, кайсы баскычтан менәргә анда?

— Кайсысыннан да ярый, бикәм.

Акбикә диварга йөгерә-атлый менде, аңа Бачман баһадир белән каравылбаш Бакырбай иярде. Иллә ярты баскычны үткәч, Бачман баһадир йөзбашка «кал» дип ишарә ясады.

Киң диләр дөньяны! Чынлап та киң икән бит! Таң калмалы. Еракта-еракта, көнчыгыш тарафта җир белән күк йөзе тоташкан җирдә, күгелҗем сурәт. Чулман елгасы шул күгелҗемләнеп күренгән җиргә кереп югала. Түбән таба баксаң — елгада көймә чаклы гына булып күренгән кораблар...

— Кораблар кемнеке, баһадир?

— Күчтем сәүдәгәре Бөек Калага төшеп бара, бикәм.

Акбикә дивар читенәрәк атлады, түбән карады, шундук башы әйләнеп киткәндәй булды, шуны гына көткән кебек Бачман баһадир бикәнең беләгеннән эләктереп алды. Бикә шым булды, күзләрен йомды. Күптәнге, бик күптәнге хыялы күкрәген ярып чыкты да Чулман өстенә акчарлак булып очып китте. Баһадир Бачман да үзендә хис ташкыны дөрләп китүен тойды, ул бикәне күкрәгенә кыса төште.

Акбикә күзләрен ачты, янә Чулманга карады. Текә-текә яр астында ялгыз карама үсеп утыра. Карама картайган, ялгыз үскәнгәме, ботакларын киң җәеп, яр кыяларына тотынырга теләгәндәй, калкып торган ташларга сыенган. Баһадирны беренче тапкыр күргәндәге ялкынлы хисе янә бер кабатланды бикәнең. Бер картлыкта, бер яшьлектә, диләр, әллә соң шулмы бу мәхәббәт дигәннәре, дип уйлады бикә. Ул кымшанмады, аның шулай торасы да торасы килде, гомере буена, үлгәнче. Бикәнең йөрәге ярсынып тибә, тәүге катылыгының эзе дә калмады. Борынгы болгарлар язык кылган хатын-кызны ике аягын ике агач очына бәйләгәннәр дә... Кем аңа шулай дип сөйләгән иде әле? Ә, Чәчкә Ана. Димәк, булган хәл. Әмир Хаҗи ишетсә, аны да... баһадирга булган мәхәббәтен инкяр итә алмас, дөресен әйтер...

— Рәхмәт, баһадирым. Әллә нишләп башым әйләнеп киткән кебек булды. Бигрәкләр дә биек икән шул.

— Түбән карамагыз, үтә ул.

Акбикә борылды да төшү ягына юнәлде, ә бөтен тәнендә баһадирның көчле кулларын, кайнар күкрәк җылысын тойды. Бикә үена янә тиле бер уй килде: манарага керергә һәм үзе белән баһадирны да алырга. Яратулары чынмы икән?! Чын булса, ул анда керми калмас. Мәхәббәт уттан курыкмый. Манарада шайтан булмагае. Тәңре үзе булсын, ул хәзер үк анда керер.

— Минем манарага керәсем килә, баһадирым. Хәзер үк. Алыгыз ишекләр ачкычын. Ачкычлар йөзбаштадыр.

Баһадир Бачман бикәнең күзләренә карау белән үк аңлады, ихтыяры чиктән ашкан, теләгәнен кылыр, тыйма, ирек бир, ни кушса, шуны башкар. Бачман баһадир йөзбаштан манараның ишек ачкычларын сорап алды, тәвәккәл рәвештә манарага юнәлде. Бикә аңа иярде. Кемдер аңа дәште, кайсыдыр тыярга теләде, йөзбаш хәтта беләгеннән тотмакчы итте, иллә бикә хәтта аңа таба әйләнеп тә карамады.

Бүген ул шайтан янына гына түгел, иблиснең үз янына да керер бер халәттә иде. Иң мөһиме — баһадир аның белән булачак, баһадир янында ул, үлсә дә, үкенмәс.

Баһадир манараның ишекләрен киң итеп ачты, бусаганы атлап керде, аңа бикә тагылды. Керүләре булды, ишекләр ябылды, баһадир үрелеп кенә кисәү агачы алды, ут салды. Баһадир баскычлардан сак кына өскә таба күтәрелә башлады, йөрәге дөп-дөп типсә дә, бикә аңа иярде. Алар бербарсенә бер авыз сүз дә әйтмәде. Колак түрендә кан шаулый, ярканатлар колак янныннан гына җилпенеп уза. Дымсу, сөрсү ис. Алар икесе дә сүз куешкандай туктап калалар, колак салалар. Тып-тын. Йөрәкләре генә күкрәккә сыеша алмый, бер дулкында тибә.

Бикә баһадирның беләгенә ябышты, ташлама мине дигәндәй, елыша төште. Баһадир дәшми, ул үзе дә сәер бер халәттә иде. Ул сак кына тагын ун-унбиш баскыч өскә күтәрелә, кулына сарылган килеш бикә атлый. Күккә ашсалар икән шулай бергә! Күккә ашсалар да риза бикә. Риза! Тик ул гына янында булсын, тик ул гына курыкмасын.

Менә күк йөзе күренде. Йолдызлар җемелди. Ни бу? Алар көпә-көндез кереп киттеләр ләбаса. Шулай үк озак күтәрелделәр микәнни?

Манараның иң югары баскычына күтәрелделәр, ике кеше басарлык кына мәйданчыкка басып, тын гына тирә-юньне күзәттеләр. Үреләсе дә, бераәм-берәм йолдызларны җыясы шикелле иде. Бикә янә баһадирга сарылды. Баһадир Бачман аны кочагына алды, күптән көткән истән исереп киткәндәй илереп йөзен үбә башлады. Бикә карышмады, киресенчә, үзе үк аңа тартылды, аңа елышты.

— Ишетәсеңме, баһадирым, монда бернинди дә шайтан юк. Син дә мин генә монда. Син дә мин генә! Ишетәсеңме, баһадирым!

Чү-ү, кем анда авыр итеп сулыш алгандай итте? Курыкканга куш кына күрендеме?!

— Төшик, бикә.

Бикәнең төшәсе дә, кузгаласы да килми, ул шунда үлсә дә риза иде, кешеләрнең котын алган шайтан манарасында.

Кисәк кемдер аны күтәреп алды һәм күз ачып йомганчы түбән таба алып төшеп китте. Бикә кычкырасы итте, әмма өне юк иде, булган хәлдән ул өнсез калды, тавышы югалды, куллары — әйбер, тәне күлмәген тоймады. Йөрәге бугазына килеп тыгылды, сулыш алу авырайды, кычкыру мөмкин түгел иде, бары тик курку һәм ярсып типкән йөрәк бар иде.

Аны кулына алган кешеме, шайтан үземе, бик тиз түбән төште, аннары ул тар тәнһөлдән йөгерде, капылт тарлавыкка килеп чыкты, бикәне аягына бастырды, шунда гына бикәнең сүз әйтергә теле ачылды.

— Хода бәндәсеме син, шайтан үземе?.. Иә аллам!

Җавап булмады, билгесез зат аны упкынга табарак этеп җибәрде, бикә тәгәрәп китте. Тарлавык төбендә генә ул исенә килде, торып басты һәм күлмәк итәген каккалап:

— Баһадирга тимә, баһадирга тисәң, жаныңны җәһәннәмгә олактырырмын!— диде.

Җавап урынына шаркылдап көлгән тавыш ишетелде, тавыш кайтаваз булып, бик озак яңгырап торды. Шунда бикә чырыйлап кычкырып җибәрде. Бер кычкырды, ике.

Берәү дә аңа ярдәмгә килмәде, берәү дә аны ишетмәде, ул үзе да кайда

булуын белмәде. Төн карангы, күк йөзен йолдызлар чуарлаган, тарлавык төбендә көндезге кояштан суынып җитмәгән ком.

Ни булды аның белән, кем аны күтәреп бире китереп ташлады? Баһадир кая? Аны да... Бачман баһадирым, кайда син?!

— Кайда мин, кайда?! Әнекәем!?

Ниһаять, бикә үз тавышын үзе ишетте. Бая ни кычкырса да тавышы бик зәгыйфь чыккан икән бит.

— Баһадир Бачман?!

— Тарлавык буйлап атла, артыңа әйләнмә!— диде янәшәсендә генә ят тавыш.

Бикә акрын гына тарлавык буйлап китте. Кем бу? Кешеме? Кеше булса, нигә шушындый карлыккан тавыш...

Бикә кайтарып сорамады, адымын тизләтә төште. Кисәк ул борылды да биленнән хәнҗәрен суырып алып, артыннан атлаучы яман затка ташланды. Күз ачып йомганчы кулыннан хәнҗәре читкә очты, үзе тәгәрәп китте.

— Әстәгъфирулла! Адәми затмы син?

Яман зат тоташ карадан киенгән, күзләре генә елтырый, йөзенә кара яулык бәйләгән иде.

— Тарлавык сезнең өчен бердәнбер котылу юлы, бикә. Китә бирегез!

— Бачман баһадир кайда?

Карангы төшә башлады, тарлавыкта инде күз дә рәтле абайламый. Бикә йөгерә-атлый тарлавыктан китте. Кинәт ул үзе белән шайтан сөйләшүенә ышанды.

— Бачман баһадирны елга буеннан табарлар. Сеңлесе Зәйтүнә хакына ул исән калды. Бикә, артыгызга борылмагыз, юкса мәңге шушында калуыгыз бар...

Аякларда буын юк, гәүдә камырдай. Һични тоймый, чигә тирәсендә гөжләп кан шаулый.

Акбикә аланга килеп чыкканда ай калыккан иде инде. Ай юнәлешен чамалап, бикә барды да барды. Бик озак атлагач, ниһаять, болынга килеп чыкты. Көтүчеләр учак яга, берәүсе курайда уйный, икенчесе сузып җырлый иде. Бикә аларга акрын гына якынайды, тамак кырды. Курайчы уйнаудан туктады, җырчы ярты сүзендә шым булды. Көтүчеләр аны таныдылар, икесе дә сикереп торып аягүрә бастылар.

— Бикә!— диделәр икесе дә беравыздан.

— Әйе, мин — әмир Хаҗи бикәсе. Миңа ат бирегез, изге көтүчеләр.

Акбикәгә иярле ат китереп бирделәр, атланырга ятдәм иттеләр, кай тарафка барса, кирмәнгә килеп чыгасын аңлаттылар, шунда берсе бикәне озатырга алынды. Атка атланып алгач, бикә булган хәлне онытырга тырышып, җилле генә юырттырып барган көтүчегә иярде. Күп тә үтми алар кирмән каршына килеп чыктылар. Көтүче исемен атап, каравылбашка кычкырды, бикәне алып кайтуы хакында әйтте. Бикәне үз күзе белән күргәнче тәмам исе китеп торган Бакырбай, аттан төшкән Акбикәнең аякларына егылды.

— Кичер мине, бикә, кичерә күр. Мин гаепле, мин. Мин бирдем ачкычларны.

— Тор, каравылбаш. Сине гаепләүче юктыр. Бачман баһадир кайда?

— Бикәм,— диде йөзбаш якын ук килеп.— Аны, кул-аяклары бәйләнгән килеш, яр буеннан табып алдык. Кычкырып ята иде.

Бикә тәмам тынычланды, ләкин тизрәк баһадирны күрәсе килүе хакында йөзбаш Бакырбайга әйтергә кыймады.

— Мин өшедем, каравылбаш, җылы өйгә илтегез,— диде.

Аны озаткан көтүче, атын алып китеп барды, бикәне иң кәттә өйләрнең берсенә урнаштырдылар. Шунда кереп, мич каршына утыргач кына, бикә бераз тынычлана төште, булган хәлне аңларга теләп, манара эчендәге һәр мизгелне күз алдыннан кичерде. Әйе, аны сизмәстән күтәреп алдылар, мәгәр баһадир нигә дәшмәде? Аны нишләттеләр?

Баһадирны күрәсе, һәммәсе турында да сорашасы килсә дә, бика яхшысынмады. Төнлә очраштылар, дип әмиргә җиткерүләре бар иде.

* * *

Иртән иртүк аның хозурына баһадир Бачман килеп керде. Бикә юынган, чәчләрен тараган иде инде. Ул юлдашын елмаеп каршы алды.

— Рәхим ит, баһадирым, рәхим ит. Тагын бер кереп чыкмыйбызмы шайтан манарасына?..— дип, шаярткандай итте бикә.

— Кичерә күрегез мин тилене, бикә. Елга буенда ничек кул-аякларым бәйләнгән көе ятуымны сизми дә калганмын. Башыма да сукмадылар кебек, ят нәрсә дә иснәтмәделәр шикелле, ә тәмам аңым җуйганмын.

Киң җилкәле, типсә тимер өзәрдәй сәламәт-таза баһадирның шайтан каршында мескенләнеп калуы, хәзер исә гаепле кеше сыман бикәсе каршында басып торуы, җитмәсә, акланырга тырышуы бикәгә бик тә көлке күренде. Әмма эчтән көлсә дә, тыштан көлә алмады Акбикә, ул үзе дә әле булса исән калуына ышанмый тора иде.

— Баһадирым, мине анда шайтан күтәреп йөртте,— диде бикә, уенынчынын бергә кушып.

Бачман баһадир, ни көләргә, ни җайлы сүз әйтергә базмыйча, тәмам каушый калды, бары тик бертын сүзсез торгач кына:

— Ә минем кул-аягымны бәйләп ташлады,— диде.

## 22

Җик Мәргән берәүгә дә күренмәскә тырышты. Әмир Хаҗи урманына килеп төпләнергә ниятләгәч, ул ишләрен беренче очраган аланлыкта калдырды да якын-тирәне әйләнеп килергә булды. Әмир Хаҗи урманнарында качкыннар яши, үткән-сүткән сәүдәгәрләрне борчыйлар, әмма ни хан, ни әмир качкыннарны эзәрлекләмиләр, дип ишеткәне бар иде аның. Моның сәбәбен белми иде Җик Мәргән. Шуңадырмы, аның иң әүвәл качкыннарны табасы, алар белән күзгә-күз очрашасы, аңлашасы килә иде. Урала-тулгана торгач, ул урманны ошатты, кош-корт күп, качып ятырга тарлавыклар бар. Идел белән Чулман елгалары арасындагы бу урманны күзәтергә әмир Хаҗиның кулы җитмиме, качкыннар аңа зыян китермиләрме — Җик Мәргән моны ачыклый алмады. Ярты көннән артык урманда тулганды Җик Мәргән — ник бер җан иясе очрасын. Бу хәл аны бераз шомга салды. Җир — иясез, ат — йөгәнсез булмый, монда исә гелән адәм аяк басмаган, диярсең.

Кояш авыша башлагач, Җик Мәргән ишләрен калдырган аланга кайтырга булды. Тик күпме генә чамалап йөрмәсен, ишләрен таба алмады. Аваз салырга курыкты — ят урманда кемгә тап булмас, аннары йә әмир, йә хан азатларына очравы бар иде. Кыскасы, әмир азатлары белән күзгә-күз очрашмау хәерлерәк булыр яшь батырга.

Иллә ул ишләрен табар. Алардан ерак китмәде, чамалап бара, тиздән юлыгыр. Ахыр чиктә, куркыныч булса да, авазын салыр.

Дала булса икән ул. Далага килеп чыктымы, Җик Мәргән үзе аңламаган ярсыну тоя, аты да, иясенең теләген аңлагандай, киң далага килеп чыгуга, җилне узардай булып чаба башлый. Ә монда, куе агачлар арасында, сирәк-мирәк кенә аланнар очрый. Җик Мәргән шуларның берсенә туктарга, җиргә ятып тавыш-фәлән тыңларга булды. Янәсе, якын-тирәдә ул-бу ишетелмиме? Җик Мәргән атын тышаулап маташмады, йөгән тезгенен ат бәкәленә бәйләде дә, куе үлән өстенә сузылып ятты. Җирән Кашкасы кетер-кетер печән ашый башлады. Җик Мәргән кулларын баш астына салды да күккә бакты. Куе зәңгәр күк йөзендә анда-санда гына болытлар йөзә. Өздереп-өздереп сандугач сайрый, тынып-тынып кәккүк кычкыра, ул түгел, куркынып калган саескан шаркылдый башлый. Ниндидер җанвар якынаюын саескан гына түгел, ат та сизә, ул башын күтәрә, колакларын

торгыза һәм, минем монда иям дә бар дигәндәй, тавышлы итеп пошкырып куя, йөгән тимерләрен зеңләтеп ала. Бу аның бередә синнән дә көчлерәк зат бар дөнья иде, күрәсең.

Атның пошкыруын, колакларын торгызып агачлар куелыгына карап торуын күреп, иясе дә тезгенгә таянып күтәрелде, тирә-ягына карангалап алды. Иясенең тыныч тавыш белән «Ни бар анда?» дип дәшүе чынлап та тынычландырды бугай, ул янә йөгән тимерләрен зеңләтеп алды.

Жик Мәргәнгә уйланырлык иде. Нишләргә тиеш ул? Сәлим хан алдына барып баш орса, һичшиксез, аны сарай мәргәне итәр. Абыйсы Тубыкбай белән арасын бозмаска теләп, тотып аңа тапшырмасмы? Бу хәлне дә булмас димә. Димәк, Сәлим хан алдына барып баш орырга ашыкмаска кирәк. Ашыкмыйча ни кылыр? Качкын булып, берүзе урманда яшәсенме? Әллә соң әмир Хажига барып егылыргамы? Аны иртә кеше, диләр.

Жик Мәргән сикереп торды да йөгән бавын ат ялына ташлап, өзәнгегә аягын куйды. Шул мәлдә ул агачлар арасында басып торган бер азатны күрде. Ул аны күзәтә иде, кулында ук куйган җәясе. Жик Мәргән азатны күрмәмешкә салышты, атына атланды да акрын гына аланнан чыга торган сукмакка таба кузгалды. Сәер бер халәттә иде ул. Аның бер әйләнеп карыйсы, бер ял өстенә ятып, җан фәрманга чабасы килде. Аты да, иясенең карарын көткәндәй, акрын гына атласа да, эчтән ашкынып тора иде. Ул да күрде бит азатны, ук аның иясенә тимәгән хәлдә, аңа тиюе бар иде. Агачлар сирәгәя башлауга, Жик Мәргән тезгенен тарта төште. Жирән Кашка чабып китәргә җыенды. Шул чак аның каршына ат менгән өч азат килеп чыкты.

— Юлчының аты, юнәлгән юлы кай тарафка?— дип сорады унбаш алгарак чыга төшеп.

«Абыйсының азатлары, аны эзлиләр,— дип уйлады Жик Мәргән.— Алар мине укка алмас, танылылар, танымаганга гына салышалар». Күз ачып йомганчы ул кылычын чыгарды һәм каршындагы азатларга ташланды, тегеләр моны һич тә көтмәгәннәр иде булса кирәк, атларын читкә каердылар, ул арада Жик Мәргән алар яныннан узып китте һәм чаптарына: «Алдыр, Кашкам!»— дип кычкырды. Ат иясен аңлады, сөлек кебек сузылып чапты, тиздән ул иясен елга буена алып чыкты һәм яр буйлап алып китте. Бертын киткәч, Жик Мәргән атын тыя төште, атыннан төшеп, куа килмиләрме дип, колагын жиргә куеп тыңлап карады. Куа килүче ишетелмәде. Шик юк, азатлар аны эзли, бәлкем әле абыйсы Тубыкбай да ерак түгелдер. Абыйсы аңардан үч алырга тели, үтерүе дә бар, ә азатларга Тубыкбай да, Жик Мәргән дә барыбер, алар кемгә буйсынса да буйсынучылар. Жик Мәргән әле аларга якынрак та, шул ук вакытта Тубыкбай баһадирдан да куркалардыр. Сәлим хан тарафыннан иркәләнгән Тубыкбай һичкем белән исәпләшми, үзбаш карар кыла, буйсынмаган азатларының башларын кисәргә дә күп сорамый иде.

Жик Мәргән атына менде, уратыбрак янә урманга юнәлде. Дала аңа бүген куркынычрак иде, ачык жирдә аны күрергә тиеш түгелләр. Куе урманга килеп кергәч, Жик Мәргән атның тезгенен жибәрде, ат үзе теләсә кая алып барсын, аның язмышы минем язмыш, дип уйлавы иде. Бер аланга килеп чыкты ат, икенчесендә туктамады, өченчесенә бик озак барды. Менә, ниһаять, янә бер алан. Алан уртасында кам басып тора.

— Тукта!— диде ул, кулындагы таягын күтәреп.

Жик Мәргән атын туктатты, сикереп жиргә төште.

Сәләмә киемнәр кигән, муенына төрле шылтыравык әйберләр таккан, таягы очына тиен койрыгы бәйләгән, сырма итәкләренә бүре, төлке, куян, җофар, сусар тагын әллә нинди җәнлекләрнең койрыкларын таккан, башына тубал кадәр бүрек кигән камны күрүгә, Жик Мәргән кыю рәвештә аңа таба атлады. Нидер сизенеп, кам кача башлады. Жик Мәргән яшен тизлеге белән аңа аркан ташлады һәм, бауны сава-сава, үзе янына тартып китерде.

— Син кем? Кайсы төбәк камы? Урманда кемнән качып йөрисең?

— Тимә миңа, батыр. Минем берәүгә дә зыяным тигәне булмады. Монда шәех Игәнәй мөридләреннән качып йөрим. Алар мине суга батырып үтерергә иттеләр, качып кына котылдым. Инде хәзер икенче берәүнең кулына килеп эләктем. Беләм, мин шәех Игәнәй мөридләреннән качып йөрсәм, син хан азатларыннан сакланасың.

— Кайдан беләсең?

— Мин барысын да беләм. Тиздән Болгарга яу килер. Батырлар яуда кирәк, ә сине абыең урманга качарга мәҗбүр итте. Тәңре барысын да күрә. Сине монда абыең азатлары эзли.

— Кайдан беләсең?

— Кам барысын да күрә, барысын да белә, Мәргән. Кам ишләреңне тураган кешеләрне дә белә.

— Кем турады аларны?! Син барысын да күреп-күзәтеп тордыңмы?

— Җибәр мине, батыр. Миңа болай сөйләшүе авыр.

Җик Мәргән арканны бушатты. Кам аягына торып басты.

— Бар, кам, китә күр. Кем белә, бәлкем без икебез дә янә очрашырбыз. Кайда дип сорама, үзең беләсең. Хан кулына эләксәң, икебезне дә дар агачына астырыр. Мәгәр шуны аңламыйм, кам, шәех Игәнәй мөридләренә нигә кирәк син? Ул сорыкортларның ни коралы, ни атлары юк, дигәндәй.

— Ялгышма, батыр. Шәех Игәнәй мөридләре көн-төн уктан атарга, кылыч белән эш итәргә, аркан ташларга, сөңге ыргытырга өйрәнә. Шәех Игәнәй мөридләре хәзер хан азатлары кебек үк хәрбиләрдер. Алар азатлар кебек үк корал йөртә. Мөридләргә тап булма, батыр...

Җик Мәргән аны янә бер күздән кичерде. Түшенә ялтыравык тәңкәләр, төрле төстәге чүпрәкләр таккан җан иясенең кыяфәте генә түгел, үзе дә көлке тоелды. Мәргән шуның тәңкәләренә генә кагылган иде, шул мәлдә аны кам баш аша ташлады да, өстенә менеп, тезе белән бугазына басты. Җик Мәргән бераз исенә килә алмый торды. Ни булды аңа? Яңа гына кам алдында басып тора иде, инде аның астында җирдә ята. Җик Мәргән чарасыздан шаркылдап көлеп җибәрде. Моны һич тә көтмәгән кам сикереп торды да артына әйләнеп карамастан урман куелыгына таба йөгерде.

Җик Мәргән сикереп торды. Әүвәл ул камны уктан алырга теләде, ләкин бу уеннан шундук сүтелде һәм баш очыннан очып барган ала карганы атып төшерде. Агачлар арасына килеп керүгә, артына әйләнеп караган кам батырның очып барган кошны атып төшергәнен күрде дә шып туктап калды.

— Батыр, Җик Мәргән бит син?!

— Җик Мәргән, кам, Җик Мәргән!

— Сине урман бетереп Тубыкбай абыең эзли, ишләреңне тураучы да ул. Исән чакта Казан елгасы буйларына кач. Анда үзеңә ишләр табарсың.

— Кам, әйткәнең хак булса, колың булырга ризамын.

— Мин беркайчан да, беркемгә дә ялганламадым, Җик Мәргән. Ишләреңне үтерүчеләр әле ерак китмәде, абыең елга кичүе янында кунарга булды. Үч алыйм дисәң, төн бүген караңгы булыр...

— Мин сиңа ышаныйммы, кам?

— Бүрене ат белән, куянны эт белән куалар, Җик Мәргән. Сак бул, абыеңның сиңа ачуы яман дыр. Сәлим хан Тубыкбай абыеңа сине тотып бирергә вәгъдә иткән. Тубыкбай башыңны кисеп китерүчегә мең ат ышандырган.

— Мең баш ат?! — дип гаҗәпләнде Җик Мәргән һәм җәясенә ук элеп, әйләнә-тирәсен карап чыкты.

— Юлың уң булсын, батыр егет. Иртәгә иртән кам сине ошбу аланда көтәр...

Сәер кам куе агачлар арасына кереп югалгач, Җик Мәргән аты янына килде, ял астына кулын тыгып, бертын уйланып торды. Нишләргә

тиеш ул? Абыйсын куарга чыксынмы, я барысына да кул селтәп, Казан елгасы аръягындагы урманда көн күргән качкыннар янына китсенме? Юк, ул әүвәл үч алырга тиеш.

Җик Мәргән сикереп атына атланды, җилле генә юырттырып, Чулман тарафына таба китте. Камга ышанды да, ышанып та җитмәде. Абыйсы чынлап та аны эзләп йөриме икән? Аңа комачауламый, илдән чыгып китте, җир сорамый лабаса инде. Ефәк юлын сакларга алынмый. Ләкин абыйсының аннан котыласы килә. Ни өчен? Ялгызы калырга телиме? Ни кылыр бер ялгызы калып? Угланнарына таянырга мы исәбе?

Ат, юлны яхшы белгәндәй, җилле генә юыртып бара, тиздән елга да күренер. Ләкин Җик Мәргән атын кисәк борды да ишләрен калдырган якка таба чапты. Абыйсы аның ишләрен чынлап та очратуы һәм турап ташлавы мөмкин иде. Алар яшеренгән төбәккә якынайган саен ярсына, күңеле гасабилана башлады. Ишләрен бик уңайлы урында калдыруы хак. Ул тарлавыкка бары тик бер яклап кына керергә була, ишләре үткен күзле мәргәннәр... Урман яклап, өске тарафтан өсләренә кисәктән килеп төшкән булсалар? Анда инде харап, кылычларын да алырга өлгерми калулары ихтимал... Алар аны беркая кузгалмыйча көтеп торырга тиешләр иде. Менә ул тарлавык, беравык барасы да...

Җик Мәргәннең тыны кысылды, үз күзләренә үзе ышанмады: андасанда ишләренең мәетләре ауный, аларны унлап бүре ботарлап ята иде. Ерткычлар шул кадәр мәет ашау белән мавыкканнар иде ки, мәргәннең килеп чыгуын сизми дә калдылар. Явыз җанварларның киткәнен көтеп, агач башларында козгын-саесканнар, ала каргалар сабырсызланып утыра, агачлар арасында ач төлкеләрнең күзләре елтырый. Ат менгән кешене беренче булып саесканнар күрде, котырынып шаркылдарга тотындылар, ахыр аны күреп төлкеләр таралыша башлады, бүреләр исә һаман мәетләрне ботарлый. Җик Мәргән җәясенә ук артыннан ук элде. Тарлавыкта унлап бүре, аларның берсе дә моннан чыгып китә алмас. Ул бүренең баш чирәбенә атты, күбесенең күзенә тигезде. Тик алданрак ашарга керешкән сизгер ана бүре генә ук-җәя тоткан җайдакны күреп, тешләрен ыржайтты һәм Җик Мәргән ягына сикерде. Җик аңа, очып килгән кошка аткандай атты, бүренең тешләрен ватып кергән ук шартлап сынды, иллә тамагына кереп кадалган ук аның яшәү котын алган иде инде — ерткыч ат аягы астына диярлек килеп төште һәм, бер-ике тапкыр тартышып алды да, тынып калды.

Җик атыннан төште, авын-тәвен килә-килә бер-ике адым ясады да, ике кулы белән йөзен каплап, үкереп еларга кереште. Кисәк ул кылычын тартып чыгарды һәм ярсынып бүреләрне турарга тотынды, тарлавык — кан исе, агач башлары козгын-карга белән тулды. Җик Мәргәннең күзләрен кан баскан, ул әле бер бүре янына ташланды, әле икенчесенә — барысын да турап, тапап бетергәч кенә туктады да, дөп-дөп типкән йөрәген тыя алудан гаҗиз калып, мәетләргә янә бер күз йөртеп чыкты. Мәргәннең кулындагы кылычы үзенә корбан эзли һәм җиңелчә калтырана иде.

Бүреләргә булган ачу әкрен генә кайтты — ишләрен үтерүче бүреләр түгел, абыйсының азатлары иде. Ул хәзер үк аларны куа чыгар, җитәр һәм соңгы тамчы канына хәтле орышыр. Ул җиңел генә бирелмәс, башта аларны уктан алыр, аннан сөңгегә утыртыр, аннары кылыч белән орышыр, ахыр чиктә бугазларына тешләре белән ябышыр.

Менә шуннан кузгалмыйча үч ала алса икән ул алардан?! Инде нишләргә тиеш? Куа китәргәме?!

Җик Мәргән талымсызланып аның китүен көтеп торган козгыннарга, ала каргаларга, сиртмә койрыклы саесканнарга карады, агач араларындагы ач төлкеләргә күз төшерде. Кем яратты икән бу дөньяны? Нигә бар җан иясе бер-берсенә үлем тели? Көчленеке, гайрәтленеке, куәтленеке замана. Әллә соң абыйсына буйсынмыйча начар иттеме? Абыйсы азатлары аның ишләренең коралларын да салдырып алганнар иде. Бол-

гарда борын-борын заманнан бирле азатны корал-киеме белән күмәләү
ә монда, оятларын югалтып, ишләренең ук савытларына кадәр җыеп а
ганнар.

Җик Мәргән колакларын торгызып иясенә карап торган аты янына килде. Бертын уйланып торды. Шуннан яр кырына таба китте. Зур бу-
маган чокырны күреп, кылычы белән ярсынып кабер казырга керешт
Башта ул киемнәрен салмый казыды, ахырда күлмәктән генә калып
шактый тирән кабер өлгертте. Балчыкны ул өскә калканы белән ташыды
Кабер өлгергәч, урман артына тәгәри башлаган кояшка карады. Кояш-
тан кан сава кебек иде. Җик Мәргән берәм-берәм ишләренең мәетләрен
кабергә ташыды, ул күтәргән берсенә аты-исеме белән дәште, аны юатты,
тыныч йокы теләде. Барысын да кабергә ташыгач, калканы белән күмде
һәм дәү балчык өеме кырына тезләнде дә һәммәсен дә күз алдыннан уз-
дырды. Ишләренә ул әйтер сүз тапмады. Ул аларны түгел, бары тик
үзен, бер үзен гаепләде. Үзе дә алар янында калган булса, ихтимал,
абыйсы азатларны үтермәгән һәм ач бүреләргә калдырмаган булыр иде.
Бите буйлап кайнар күз яше акты, ул күз яшен сөртмәде, тәмам акылдан
шашар халәттә иде. Утырган саен ачуы кабарды, үч алу теләге, ачы нәф-
рәт тамак төбенә төер булып тыгылды. Торды. Калканын кабер өстенә
куйды, ике ягына ике ук салды, янә баш иеп бертын басып торды. Ни-
һаять, атына таба китте. Аты янына килеп, өзәнгегә аягын куйгач кына,
җеп өзәрлек хәле дә калмавын тоеп, беравык тынып калды. Янә үч алу
ачуы йөрәген өздереп алды. Иясенең хәлен белгәндәй, ат ал аякларына
тезләнде. Җик Мәргән атына атланды да, Җирән Кашкасы аягына бас-
кач, ялына ятып, күз яше белән елап җибәрде. Ул атына матур-матур
сүзләр әйтте, кешегә зарлангандай зарланды. Аңладымы аны Җирән
Кашкасы? Белмәде, мәгәр шул моң-зардан соң эче бушап калган кебек
булды.

Ул арада эңгер иңде. Җик көнчыгышка таба юл алды. Ул аларны
куып җитәр. Җитәргә тиеш. Җик Мәргәннең камны күрәсе килде. Ул
аңа хәзер ышанды. Абыйсы ерак китмәгәндер, чынлап та елга буенда ял
итәдер. Тубыкбай аны тотса, бөтен халык алдында хөкем итәр. Җәзанын
да яманын сайлар. Башкаларга гыйбрәт булсын өчен, ат койрыгына
тактырыр, таш атып үтерттерер, хәтта күмәргә дә рөхсәтен бирмәс, ур-
манга бүреләргә ташлатыр.

Болгар өченҖик Мәргәннең үлеме ил өстенә килгән афәт түгел иде,
түгелен. Болгар өчен ун азат һәм бер мәргән — күлмәктән суырып алган
бер карыш җеп кенә. Әмма күлмәк таман булсын өчен бер карыш җеп тә
үз урынына кирәк икән. Сәлим хан моны соңрак аңлар, ике елдан урыс-
лар яу белән Болгарга килгәч. Хәзер исә ул үзсүзле, башимәс батырлар-
ны зинданнарга яба, башларын кистерә иде. Качкын азатлар Сәлим хан-
ның кан дошманына әверелде. Ул аларны рәхимсез рәвештә эзәрлекләде,
тоткыннарын рәхимсез рәвештә асты, кисте, ат койрыгына тактырды.
Тубыкбай энесе Җик Мәргән Сәлим хан өчен нәүбәттәге качкын батыр-
гына иде.

Төнлә нинди дер инеш буенда кунды, абыйсы Чулманны кичкән бу-
лып чыкты. Иртән ул, эзләп-эзләп тә кичү тапмагач, елганы аты белән
йөзеп чыкты һәм очраткан һәр кешедән, абыйсының азатлары еракмы, бу
тирәдән күптән уздылармы, дип сораша-сораша, Ык елгасына таба чапты.
Аның исәбенчә, абыйсы бүген шул төбәктә кунарга тиеш иде. Икенче
көнне кичен ул, ниһаять, эзләгән азатларын күрде. Ашыкмый иде абый-
сы, туганы Җик Мәргәнне тота алмаса да, үч алды — аңа ияреп киткән
азатларны турап, бүреләргә ботарларга калдырды. Җик Мәргән абыйсы
азатларына күренер-күренмәс кенә барды. Шунда бер хикмәтле нәрсәне
абайлады: азатлар арасында әсирләр дә бар иде. Кайдан? Качкын азат-
ларын Сәлим хан биреп җибәрде микәнни? Тубыкбай аларны Өргәнеч
сәүдәгәрләренә кол итеп сатып җибәрәчәк. Кол тамгасы салынган кеше-
гә Болгарга әйләнеп кайту юк, аны берәү дә азат итеп тә, хезмәтчесе

итеп тә алмый, иясе тапса, бәладән башаяк. Качкыннарны бер-берсенә бау белән бәйләгәннәр, җәяү куалар. Ниһаять, Җик Мәргән абыйсын да күрде. Тегесе йөзбашына нидер әйтте дә, җансакчыларын алып, Ыкны кичте һәм чаптырып, тауга менеп китте. Әүвәл Җик Мәргәннең абыйсын куып җитәсе һәм аңардан үч аласы килде. Иллә алар күп иде, ул берүзе. Дуамалланып башын әрәм итүе бар иде. Китә бирсен абыйсы. Ул калганнардан үч алыр. Ләкин калганнардан кем гаепле? Абыйсы котырта ич аларны, аның ишләрен үтереп, урманда бүреләргә калдырырга боера.

Җик Мәргән куе әрәмәлектә туктады, кич кунарга калган меңбаш азатларын күзәтә башлады. Бавырчы азатлар аш әзерли, беришесе елга яры өстенә кырын төшкәннәр дә мәзәк сөйли, шаркылдап көлешә; качкыннар исә, бер-берсенә бәйләнгән килеш, тыныч кына яр буенда утыра.

Кояш баеды, күп тә үтми эңгер иңде. Җик Мәргән атын тышаулап җибәрде дә куаклар арасыннан абыйсы азатларына таба китте. Азатлар ит кимереп утыра, атларын болынга җибәргәннәр, караучы да куймаганнар. Ышаналар, бу төбәкләрдә качкыннар юклыгын беләләр, чөнки талар нәрсә юктыр бу җирләрдә. Болгарның олы калалары Идел, Чулман, Җаек буйларында. Ык буйларында исә иген игүчеләр, мал тотучылар көн күрә, аларның күбесе Тубыкбайга, беришесе әмир Хаҗига ясак түли.

— Йөзбаш, качкыннарга да ит бирикме?

— Бирегез. Алар да кеше.

— Болары кеше түгел инде, йөзбаш. Тиздән аларга Тубыкбай тамга сугар, сукмаган хәлдә — Өргәнеч сәүдәгәрләренә сатып җибәрер.

— Син, азатым, болай бик кәперәймә әле. Кем белә, синең дә шул көнгә калуың бар.

— Кичерә күр, йөзбаш. Болай гына мин. Хак, алар да кеше. Әй, бавырчы, качкыннарга да ит өләш! — дип кычкырды ашчы азат. Җик Мәргән аларның барысын да танып ук бетермәсә дә, күбесен күреп белә иде, алар да аны таныйлардыр. Тик барыбер аңарга алар янына чыгарга ярамый. Җик Мәргән куеныннан корт йомарламы чыгарды да кимерә башлады. Ни кыласын белми иде әле ул, иллә ни дә булса кылыр. Азатларның берсе, тамагы туйгач, курайда уйнап җибәрде, икенчесе җыр башлады. Кая китте икән абыйсы йөз азат белән? Бире дә бер кирмән дә юктыр. Иген игүче бортасларгамы, мал асрап көн күрүче мәләкәсләргәме, я булмаса авыл-авыл утырган кыпчакларгамы? Әллә соң Чәчкә Ана янынамы? Аны бу якларда тора, диделәр. Ни генә булмасын, абыйсы кире әйләнеп кайтыр. Аннары кем дә булса ул яшеренгән куаклар янына килми калмас. Йөзбаш янында куштан Сарбай да бар, ахрысы. Нишләп йөри куштан Сарбай? Кая бара? Тубыкбай авылына шәех итеп алып кайтамы әллә үзен? Нигә дәшми, әйтерсең авызына су капкан. Сәлим хан сараенда ук хезмәт итмәсә дә, куштан Сарбай шәех Игәнәйнең иң якын мөриде иде. Хәзер ул, димәк, абыйсында, аның авылында үгет-нәсыйхәт алып барачак, оланнар укытачак. Сәлим хан Тубыкбайга авылында мәктәп ачарга кушкандыр, я булмаса, шәех Игәнәй.

Җик Мәргән сабый чакта ук түземле булырга өйрәнде. Хәрби уеннарда ул бик озак яшеренеп ята алды, бүтәннәр түземлекләре җуелып, атылып килеп чыкканда, ул бик озак чыкмый ятыр, нык яшеренер, аны һәрчак җиде-сигез кеше эзләр иде. Аның шулай озак ятуына ишләре үпкәли, аның белән уйнамас дәрәҗәгә җитеп тарала, иллә Җик Мәргән хәтта сарай мәктәбенә килгәч тә бу гадәтен ташламаган һәм баһадирлардан һәрчак мактау сүзе генә ишеткән иде. Уктан алуны инде әйтеп тә торасы юк, ул сарай мәктәбенең иң дәрәҗәле мәргәне иде. Ун яшендә Җик укны укка утыртa башлады, унике яшендә ханнан бүләкләр алды, мәктәпне бетергәндә аңа Сәлим хан үзе Мәргән исеме бирде. Шул көннән алып, Җик атына Мәргән сүзе өстәлде. Үсә-исәя төшкәч, Җик Мәргән мондый хәлләрдә тагы да сабырлана төште, ауга барса, алыр җәнлеген көтеп, көнозын утырыр, иллә теләгенә ирешми калмас иде. Монда да

ул көтәр, берәрсе бире килер, килми калмас, чөнки Жик Мәргән урынны бик белеп сайлады, кеше күзенә бик чалынмый торган куаклар, чокыррак урын, тышка чыгасы кеше моннан да җайлы урынны тапмаячак. «Энгер-энгер, инче, ике күзем, күрче», — дип такмаклап утырды Жик.

Әһә, әнә берәү килә дә. Менә шулай, кил-кил, бире кил, бирерәк, дип утырды Жик Мәргән. Ул корбанын тотарга җыенган җанвардай бераз күтәрелә, кулына алган ефәк бауны җайлый төште. Азат һични уйламый утырды. Шул мәлдә аның муенына бау ташланды. Жик Мәргән, азатны тартып китерде, күзләре акая башлавын күреп, авызына чүпрәк тыкты, бауны бушатты. Аннары тегенең ыштанын күтәрде, бавын бәйләде һәм үзе белән әйдәде. Шактый җир киткәч кенә ул аның авызыннан чүпрәкне алды, кулларын чиште.

— Жик Мәргән! — диде азат.

— Жаның ике булмаса, кычкырма! Мин сорыйм, син җавап бир. Килештекме?

— Баш өсте, Мәргән. Килешми буламы? Әһе... Син — монда, абыең сине әллә кайларда урман бетереп эзли. Бер гаепсез кешеләрне турап ташладык.

— Абыем ишләремне танадымы?

— Танымый буламы, Жик Мәргән. Үзе үк кадап йөрде.

— Нинди әсирләр ул, кая алып барасыз?

— Тубыкбай баһадир ханнан алды. Мин аларны көтүче итәм, ди. Далам зур, малым күп, көтүчеләр житми, ди.

— Атың ничек?

— Артык мин, Мәргән. Анам бәби таба-таба туйгач кына, ходай аңа тагын бер бала биргән, шуннан исемемне Артык кушканнар.

— Менә нәрсә, Артык. Сиңа бары тик ике юл бар. Беренчесе — минем белән китәсең, икенчесе...

— Китәм, Мәргән, китәм.

— Ярый. Хәзер син, Артык, ишләрең янына бар. Абыем кайткандыр. Тирмәсенә кер дә әйт: Жик Мәргән энең ишләрен үлтергән өчен кыямәт көндә дә кичермәм, дип ант итте диген. Шул. Әйт: үлем сорар, дип әйтеп әйтте диген.

— Жибәрмә абыең каршына мине, Жик Мәргән. Мин аңардан куркам. Иң әүвәл моның өчен атам кичермәс, аннары абыең да. Атам мине яратмый. Анам вафат булгач, яшь хатынга өйләнде. Атам яуга киткәч, үги әни мине үз янына алып керде. Шуннан ул, җай килгән саен, минем янга керә башлады. Атам шикләнә, шул хәлдән соң туган авылыма кайтармас булды мине. Хәзер гел үзе белән йөртә. Минем хәзер авылыма кайтасым да килми. Коткар мине бу хәлдән, Жик Мәргән, гомерем буена изгелегеңне онытмам.

— Артык, чынмы, ялганмы бу хәлләрең — анысы караңгы. Ләкин беләсең, хәзер мин бернинди дә мәргән түгел.

— Сине әле булса хан мәргәне, диләр, батыр.

— Ант итик!

Жик Мәргән уч төбен ярды, аннары шул ук белән Артык та уч төбен яргач, канлы кулларын кысыштылар.

— Без хәзер бертуганнар, Жик Мәргән.

— Бертуганнар, Артык. Тик абыем Тубыкбай белән минем кебек дошманнар түгел. Тәңрем, безне үлгәнче бертуган ит! Орыш кырында да, ил-йортта да бер уй, бер теләктә яшик.

— Минем киңәшемә мохтаҗ булсаң, тыңла азатыңны, Жик Мәргән. Абыеңнан бүген уч алма. Китсен үз юлы белән. Ходай бар ул, мәргән, бар. Коткарыйк качкыннарны да, качыйк моннан. Качкыннар кирәк безгә, күп, бик күп кирәк. Бары тик шуннан соң гына абыеңа яу бар. Мин янында булырмын, халыкка чын хакыйкатьне ачып салырга тырышырмын. Абыең җир-сулары сиңа калыр, ил башына син утырырсың... Туган туганны үтерү дәвер чиренә әверелеп бара шикелле, мәргән...

— Әллә ялгышаммы мин, Артык? Абыемның шымчысы булып куюың да бар ич синең.

— Шымчы сине эзләп Бөек Калага, әмир Хажи урманнарына барыр идеме, Мәргән?

— Бар, атыңны тотып кил, Артык. Минем белән китәрсең. Киңәшеңне тотарга булдым әлегә.

## 23

Сәлим хан берәүдән дә ярдәм көтмәде. Ул гелән үзенә ышанды. Хәтта угланы әмир Хажига да ул бик сирәк мөрәҗәгать итте. Акча кирәксә, сәүдәгәрләрне кысты, кирмән салдырды — ташчыларга аз түләп котылды. Оста ташчыларның Владимир кенәзлегенә күчеп китүләре табигый хәл иде. Иллә соңгы елда, Казан каласы салына башлагач, Бөек Кала ташчылары шунда таба агылды. Бу хәлгә башта Сәлим хан дәшмәде, соңыннан исә, Бөек Каладан өер-өер ташчылар Казан каласына күчә башлагач, киңәшкә шәех Игәнәйне чакырды. Әйе, ни кылырга тиеш ул? Кала салуны үзе башлады, ә менә ул төбәктәге җир-суларны угланы әмир Хажи үз канаты астына җыя башлагач, курка калды — аерылып чыгуы бар иде углының. Аерылып чыккан хәлдә ул төбәк җирләр генә түгел, салынып яткан яңа кала да аның кулыннан китәчәк. Хәер, шәех турында да яман сүзләр ишеттергәлиләр. Имеш, кайсыдыр мөриде кызы Назлыгөлгә никах укыган. Кемгә кияүгә чыккан Назлыгөл? Төрле гайбәтләр, сүзләр, имеш-мимешләр йөри иде Назлыгөл турында. Шул ук вакытта бераз чамалый иде Сәлим хан, кызы Назлыгөл Олуг Мөхәммәт кулында. Олуг Мөхәммәт аңардан илчесе өчен үч алды. Бары тик шул. Һәм Сәлим ханга барысы белән дә килешергә генә калды. Килешми кая барасың, Олуг Мөхәммәткә каршы сугыш башлап булса икән. Сугыш дигәннән, вәзир Камай да Владимирдан һаман кайтмый. Ә бит вакыт инде, бик вакыт.

Ул арада чалмасын чамадан тыш күпертеп ураган шәех Игәнәй килеп керде, тыенкы гына сәлам юллады, утырды, догасын укыды, битен сыпырды, аннары янә ханның сәламәтлеге белән кызыксынды.

— Аллага шөкер исәнлегем, — диде Сәлим хан, вакыты тарлыгын аңлатып. — Сиңа киңәшем бар иде, шәех.

— Киңәшле эш таркалмас, дигәннәр, ханиям.

Шәех Игәнәй дисбесен чыгарды, күзләрен йома төште, иреннәрен кыймылдата-кыймылдата дога укып алды һәм янә ханга карады. Янәсе, мин сине тыңлыйм, ханиям. Ул бераз чамалый иде ханны ни борчуын. Владимирдән вәзире Камай һаман кайтмый, хәбәре-хәтере дә юк, моның янына кызы хакында төрле имеш-мимешләр йөри. Иң мөһиме, Владимиргә Андрей Боголюб янына киткән вәзир Камай белән ул-бу булуы бар иде. Ә шәехнең белмәгәне юктыр, аның һәр илдә, һәр калада үз кешеләре яши. Ике мөриден Камайга ияртеп җибәрде. Бу хакта хәтта хан да белми калды. Тылмачлык өлкәсендә тәҗрибәсез Камай мәрхүм вәзир Исхакның сыңар тырнагына да тормый иде. Вәзир Исхакны шәех Игәнәй яратмады, шуңа карамастан, ул аны хөрмәт итте. Һәрчак төпле фикер йөртер, һәммәсе белән дә итагатьле итеп сөйләшер, кешене дәрәҗәсенә карап каршы алыр, акылына карап озатыр иде.

— Халык уракка төште, шәех. Тиздән гошер сәдакасы җыер көннәр җитәр. Сәдака бирүдән баш тартучылар да бар икән. Хакмы шул, шәех? Хак булган хәлдә, нигә мин белмим?.. Әллә соң җыйган сәдака ашлыгын мөридләрең яшереп калдырамы? Андый хәлнең дә булуы бар. Аллаһы тәгаләгә иман иткән һәр адәм сәдака бирергә тиеш.

Шәех Игәнәй Сәлим ханнан бу хәтлесен үк көтмәгән иде, ул әүвәл аңа кырын күз белән карап алды һәм керфекләрен ярым йомып, дисбесен тарта башлады.

— Аллаһы тәгалә безгә гошер сәдакасын җыярга язган, ханиям. Ил куәте сәдакага калса, Болгар югалды дияр идем мин. Ил куәте сәүдәгәрләр. Гошер сәдакасы исә күлмәк өстенә төшкән ямаулык кынадыр. Без ул сәдаканың уннан бер өлешен казнагызга китерербез, ханиям. Шикләнмәгез. Сорыйсым килә, епископ Габбас ни тапшыра сезгә?

— Епископ Габбас үз өлешен төгәл китерә, шәех. Аңа минем дәгъвам юктыр. Ә менә мөридләрең хакында төрле сүзләр йөри. Берәүсе әнә кызыма никах укыган, имеш.

— Епископ Габбаска сүз әйтергә дә бирмисез, ханиям. Китан кенәздән куркуыгыз түгелдер ич?

— Мин берәүдән дә курыкмыйм, шәех. Епископ Габбас та, син дә хан карамагындагы кешеләр.

— Кяфер белән мөселманны бер күреп, аллаһы тәгалә алдына баргач ни әйтерсез, ханиям?

— Ни сораса, шуны, шәех. Үткән атнада мөридләрең Ага-Базарда кяферләрне кыйнаган. Бу ни инде тагын?

— Дошманнар сүзе, ханиям. Мөридләрем беркайчан да гаепсез адәм баласына бәйләнмәде. Сабакны адәм баласына китап сүзе белән генә биреп бетереп булмый, ханиям. Мөрид кулы тигән адәмнең тәне тәмугта янмас.

— Шәех, моны син Сәлим ханга түгел, мәхәллә картларына сөйлә. Белеп торсаң иде, чит ил сәүдәгәрләре миңа үз халкымнан да кадерлерәктер. Ни урысларның, ни яваннарның безгә яманлык кылганнары булмады кебек.

— Ханиям, чит халык үз халкыңнан кадерлерәк була алмый. Кунак килер дә китәр, халкың белән гомер итәсе. Кан кушып кына кадерле кардәш булып булмый, ханиям. Кешегә әүвәл иман итү кирәктер. Кяфер базарда да, табында да кяфер булып калыр. Борынгылар илне биш сыйфат бизәр, дигәннәр. Тугры хан, тугры казый, бай базар, оста табиб, сулы елга. Болгарда боларның барысы да бар иде. Хәзер ул сыйфатлар берсе артыннан берсе югала бара. Табиб Хәсәнне Олуг Мөхәммәткә җибәрдегез, Бөек Калага чиркәү салдырдыгыз, җирегезне угланнарыгызга өләштегез. Бирүләре ансат булса да, алулары ай-һай авырдыр. Хәзер әнә угланыгыз әмир Хаҗидан Казан каласын алып карагыз. Ул анда үзенә бер дәүләт корып ята. Мөридләрем җибәргән идем, күбесен сак астына алган...

— Шәех, хәтерем ялгышмаса, табиб Хәсәнне син үзең Олуг Мөхәммәткә биреп җибәрергә киңәш иткән идең түгелме?

— Бәлкем иткәнмендер дә, ханиям. Мин бары тик киңәш бирүче, сез исә хәл кылучы. Урыс сәүдәгәрләре Ага-Базарны басты. Степан Кучтем сәүдәгәр углы Апанай Болгарда тиңе булмаган остада корал ясарга өйрәнә. Угланыгыз Илһамны кенәз кызына өйләндердегез. Кяфер киленнән туган углан Болгар тәхетенә утырырга тора. Илгә яман сүзләр таратырга сәбәпчеләр дә шул хәлләр түгелме икән? Болгар бары тик бер иманга гына табынырга тиеш. Юкса безне кяфер басар...

Сәлим хан җансакчыларына ияк какты. Ике җансакчысы шәех Игәнәйнең ике ягына килеп басты.

— Шәех, болгарда мөселманнар да, кяферләр, мәҗүсиләр дә яши. Ә ил байлыгы — халыкта. Христианнар белән мәҗүсиләрне кысрыклый башласам, беренчеләре Владимир канаты астына, икенчеләре Төн илләренә күчеп китә башлар. Рум белән сәүдә итүебез яваннар кулындадыр, урыс белән сәүдә итүем Яким Кучтем сәүдәгәр товар ишләрендәдер. Минем аларны югалтасым килми. Мин синнән, шәех Игәнәй, акыллырак киңәш көткән идем.

— Ходай тәгалә илгә бәла-каза китермәсен, илдә һәрчак иминлек булсын. Минем теләгем бары тик шулдыр, ханиям.

— Халкым мине иманы белән түгел, байлыгы белән кинәндерә, шәех. Иман ул кешенең рухи дөньясыдыр, байлык исә — ил куәте, ил мул-

дыгы. Байлык ул алтын гына түгел, корал да, азатлар да. Сараемда илле бең азат тотам. Аларның күбесе төрле кирмәннәрдә, иллә барысын да мин ашатам, мин карыйм. Кенәз Әндеригә әчең пошмасын, шәех. Мин исән чакта, ул Болгарга яу килмәс. Сәбәбе юктыр. Тиздән Болгарда Идел буйларына салынган калаларның барысыннан да куәтлерәк Кала күтәрелер. Күп тә үтмәс, Казан көнчыгыш белән көнбатышны бәйли торган олы базар каласына әверелер. Моңа иманым камил. Әндери кенәз үзе баш иеп килер Болгар белән сәүдә итәргә. Дөньяда булмаган чуен коябыз, ул да — куәтебез билгесе.

— Әйтер сүзегез шул гына идеме, ханиям?

— Шул гына иде.

Шәех Игәнәй, ике ягында басып торучы азатларга күз дә ташламыйча, ишеккә таба кузгалды. Сәлим хан туктатмады, әйтәсен әйткән иде инде. Әйе, ул шәех белән дорфарак сөйләште, ләкин бу кирәк иде — шәехнең мөридләре узына башлаган. Бөек Калада болгарлар белән кардәшләшеп беткән яваннарны рәнҗеткәннәр. Сәлим ханның аларны бер дә рәнҗеттерәсе килми иде. Кайчандыр әрмән чикмәне киеп, шулар урамына йөргән көннәре күз алдына килдеме, чарасыз калган чаклары була. Нәкъ менә шунда инанды бугай ул: нинди дингә табынса да, иманлы кеше кеше булып кала. Нинди генә дингә табынса да, кешедә иман бар, иманы барның догасы бар, догасы барның дугасы бар, дугасы барның капкасы бар, капкасы барның өе бар, өе барның көе бар, көе барның кереме бар, кереме барның һөнәре бар, һөнәре барның дога кылырга түмәре бар. Иманлы түгел, имансыз кеше яман икән дәүләт өчен. Хак анысы, Сәлим ханга имансызларны гына түгел, иманлы мөселманнарны да теге дөньяга озатырга туры килгәләде, иллә ул үз иминлеге өчен кылды.

— Бусагабаш, шәех Игәнәйне борып кертче, әйтер сүзем калган.

Ул аны Назлыгөл турында бер-бер нәрсә белмиме дип чакырткан иде. Мөриде чынлап та никах укыдымы, әллә булмаса халык гайбәте генәме?..

Игәнәйне җилтерәтеп алып керделәр, бу хәлгә ул бераз аптырый калган иде, иллә сер бирергә теләмәде, тәүге урынына узып утырды.

— Шәех, миңа мөридләреңнең берсе хан кызы Назлыгөлгә никах укыган икән дип ишеттерделәр. Хакмы шул?

Игәнәй бик озак дәшми торды. Ул белә иде, моның белән ул ханның түземлеген сыный. Әгәр дә мәгәр хан, сабыры төкәнеп, башлап сүз катса, шәех аннан өстенлеген исбат итәчәк.

— Мин мөридләрем белән сөйләшермен, ханиям.

— Сөйләш, шәех, сөйләш. Гайбәт сатучыларның телләрен кистерү минем эш, аларны табу синең эш. Назлыгөл белән бер-бер кеше никахлашкан икән һәм синең мөридең аларга никах укыган икән, бу хәл чын булып чыкса, сиңа, шәех, мең алтын вәгъдә итәм.

Шәех Игәнәйнең үте сытылыр дәрәҗәгә җитеп ханга ачуы чыкты. Кем ул аңа? Нинди шәех үзенең мөриден хан җәллады балтасы астына куяр икән? Андый шәехнең абруе көне белән юкка чыгачак. Хан кызына бер-бер мөриде чынлап та никах укыган икән — язгы үзенә, даны шәехкә. Димәк, халык алладан курка. Алладан курыккан, шәехтән дә куркыр. Болгарда кыз урлау шаккатырлык хәл түгел, яшереп никах укулар да булгалап тора. Бу хакта шәех эш үткәч кенә ишетә, иллә яшерен никах укыган мөридենә җәза бирергә ашыкмый. Таяк ике башлы, мөриднең никах укуын фаш итү — иманың фаш итүдер.

* * *

Икенче көнне иртәнге аштан соң шәех Игәнәй берәм-берәм мөридләрен янына чакыртып алды. Ул берсенә дә хан кызы хакында сүз әйтмәде. Ул бары аларның хәл-әхвәлләрен, кайларда булуларын, бүген ни

кылып ятуларын, ниятләрен генә сорашты. Мөриде Бәдретдиннең кулындагы зөбәрҗәт кашлы йөзеккә, чалмасындагы гәүһәргә игътибар итеп:

— Йөзекне кем бүләк итте? — дип сорады. — Әллә бирәр бай сәүдәгәргә яки качкыннарга никах укыдыңмы?

Бәдретдин мулла агарынып китте, чарасыздан йөзеген салып, шәехкә сузды. Шәех йөзекне алмады, кул гына селтәде.

— Кемгә укыдың?

— Гаеп миндә түгел, шәехем. Төнлә белән эләктерделәр дә алып киттеләр, сизми дә калдым. Ике көнлек юл үткәч кенә күземне ачтылар.

— Качкыннарга никах укырга сиңа кем рөхсәт итте?

Бу хәтлесен үк Бәдретдин мулла бөтенләй көтмәгән иде, ул шәехнең итек очын үбәргә ташланды.

— Мәҗбүр иттеләр, шәехем.

— Качкыннар кулында кызлар күпме? Хан кызыНазлыгөл дә алардамы?

— Аллам сакласын, шәех. Башыма тай типкәнме әллә минем. Никахны качкыннарга гына укыдым. Хан кызы Назлыгөлне таныйм, ул алар арасында юк иде, корьән тотып ант итәм.

— Ашыкма, кабаланма, мөридем, бу дөньяда төрле хәлләр була. Бәлкем хан кызын танымагансыңдыр?

— Таныр идем, шәех. Ипи тотыйм менә, анда булмады.

— Нигә баш тартмадың? Язгыгың кая илтерсең?!

— Карыша алмадым, шәех. Янадылар, муеныма бау ташладылар.

— Мин сине казый кулына бирергә мәҗбүрмендер, мөридем. Килеш, язмыштан узмыш юктыр. Качкыннарга никах укыган өчен, беләсеңме, хан сине нишләтәчәк?

— Шәех, коткар мине, ни кушсаң, шуны кылырмын. Ни кушсаң да...

— Хан җәлладыннан башың чаптыртасың килмәсә, мин әйткәнне тыңла, мөридем. Епископ Габбас саулыгыннан зарлана икән урынга калган, диләр. Газраил көтеп ятуыдыр. Ярдәм итәрсең үзенә... Аннары бер җайдан чиркәвенә дә ут салырсың. Шуларны кылсаң, үлемнән генә түгел, барлык гөнаһларыңнан да котылырсың. Алган савабың гомерең буена җитәр, урының оҗмахта булыр.

Мөрид шәех Игәнәй каршына капланды:

— Шәех, таш чиркәү янмас лабаса.

— Йөрәк ачуың белән ут салсаң, агач түгел, таш та янар, мөридем.

— Муеныма бау салдырма, шәех. Коткар, изгелегеңне онытмам, гомерем буена битем белән җир себерермен...

— Тор, мулла. Бар, кушканны үтә! Сиңа башка чара юктыр...

Бәдретдин чыгып киткәнче шәех аның бөкшәеп калган җилкәсенә карап торды. Епископ Габбасны үтерсә, шәех үзе дә юкка чыгар. Җитте аңа да. Моның белән ул ике дошманыннан берьюлы котылыр. Җыйган малы ике тапкыр хаҗга барырга җитәрлек. Димәк, вәзир Камайның хатыны Туйбикә бөтенләй үк саташмаган икән. Хан кызының оста Дәүран кулында булу ихтималы да бар. Шул ук вакытта аны Олуг Мөхәммәт кешеләре дә урлавы мөмкин, ул гынамы, Сәлим ханның энесе Мөхәммәтгалимбәкнең шушы юл белән абыйсыннан үч алуы бар иде. Кыскасы, шәех Игәнәй баш өстендә болытлар куера башлады. Үлем белән тартышып яткан Туйбикә аңа: «Угланым Дәүран хан кызы Назлыгөлне ярата. Ул аңа өйләнер, син аңа ярдәм итәрсең. Ишетәсеңме, шәех, ярдәм итәрсең. Нәзерең ал, менә монда, мендәр астында. Ал-ал, бу байлык сиңа җиде тапкыр хаҗга барырга җитәр...» — дигән иде. Үткән эшкә салават, әмма аның алтын тулы янчыкны алуын оста Дәүран күреп торды. Останың бу хәлне ханга җиткерүе бар иде. Җиткермәде Оста, китеп барды. Димәк, хан кызы кулына төшүенә һәм аңа шәех Игәнәйнең никах укуына иманы камил иде.

Үз гомерендә беренче тапкыр диярлек шәех Игәнәй кыен хәлдә калды. Әйе, ул китәргә тиеш. Иллә ул башта оста Дәүранны күрер...

Таң атыр-атмас, ул шәкертләре Гатый белән Такыйны чакыртып алды да, чиркәү урамы башында мелла Бәдретдинне көтеп торырга һәм тотып алып аягын-кулын бәйләргә дә коега ташларга кушты.

— Кеше-кара күзенә чалынмагыз. Сезне дә, мелла Бәдретдинне дә беркем дә күрергә тиеш түгел. Кушканны үтәсәгез, урыныгыз оҗмахта булыр...

* * *

Бөек Каладан чыгуга, шәех Игәнәй атын куалап алып китте. Ул белә иде: бүген төнлә Бәдретдин епископ Габбасның башына җитәр. Калганы барысы да ул уйлаганча барыр. Мелла шул ук төндә чиркәүгә ут салыр, соңра аны тотарлар, ханга илтерләр, инде тотмаган хәлдә, мәхәлләгә кайтканда ике шәкерт бөтәрләп капчыкка тыгар да коега ташлар. Шулай дип уйласа да, шәех нидәндер шикләнде, кемдер аны куа чыгар, тотар да ханга алып кайтыр кебек иде. Ләкин бу куркудан туган уй гына, тиздән ул Ибраһим каласында булыр, аннан Казанга да ерак калмас. Шәех юлына ризык-нигъмәт алмады, аны Болгар илендә белмәгән кеше юктыр, кемнең капкасына кагылса да, кадерле кунак булыр, бәлки авылларга туктап та тормас.

## 24

Урманга килеп керүгә, Зәйтүнә гүя үз дөньясына кайта иде. Иксез-чиксез далада үссә дә, урманны ул беренче килүгә үк яратты. Даланың үз яме, урманның үз манзарасы.

Үсеп-исәя төшкәч, абыйсы аны Бөек Калага алып килде, аннан Кашанга — әмир гаиләсенә бирде. Акбикә аны үз кызыдай якын итте, иллә урман гүяки аның икенче анасына әверелде. Урманга килеп керүгә, аның сулыш алулары үзгәрер, күңеле күтәрелер, җырлыйсы килеп китәр иде.

Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнәгә егерме яшь тулганда җиде-сигез җирдән яучы килгән иде инде. Иллә кыз берсенә дә ризалык бирмәде. Аңа өйләнергә теләгән егетләр арасында аталыклар да, меңбаш баһадирлар да, сәүдәгәрләр дә, сарай куштаннарының угланнары да бар иде.

Хәзер инде, сазаган кыз атын алса да, кияүгә чыгарга һаман теләмәде. Зәйтүнә үз кешесен көтте. Хыялы белән ул аны әле урманда, әле сарайда, әле урамда очратты. Ләкин аның булуына иманы камил иде, тик әлегә кадәр алар очрашмадылар гына, бер очрашырлар. Очрашырлар да Зәйтүнә аңа барысын да сөйләп бирер. Юк, ул аңа һични әйтә алмас, бары тик күзләре белән генә сиздерер, аллаһы тәгаләдән аңа язган кеше булса, ул аның мәхәббәтен йөрәге белән тояр.

Зәйтүнә урманга күп вакытта атка атланып барды, иллә җәяү барган чаклары да булгалады. Менә бүген дә ул җиләк җыярга җәяү китте. Таныш аланына җиткәч, чәчләрен сибеп төшергән аккаенга, аның белән янәшә көч-куәте күзгә ташланып торган карт имәнгә игътибар итте. Алар артында, сәер хәл, яфраклары белән усаклар шыбырдашып утыра. Зәйтүнә үзалдына елмаеп куйды. Рәхәт иде аңа монда. Аяк астында — таҗларын җәеп утырган күкбашлар, куе яшел үлән. Үлән арасында — кып-кызыл башларын түбән игән җиләкләр. Түзмәде, тәлгәшләрен салындырып торган берничә төпне күрүгә, җиргә утырды. Кипкәннәр, коелганнар...

Зәйтүнә алан уртасында калдырган тубалын алды да йөгерә-атлый таныш сукмак буйлап китте. Берара барасы да ышбу сукмактан урман авызына килеп чыгасы, анда инде Кашан да ерак калмас. Кояш инде урман артына төшеп бара. Зәйтүнә йөгерә үк башлады. Шулчак аның каршында җайдак пәйда булды, гүя җир астыннан калыкты.

— Һәй, тукта, кем син? Кая болай чабасың, кем куа?!

Зәйтүнә туктады, җайдакка карады. Хәрби җайдакларга хөрмәте зур иде аның, аннары ул аны абыйсының азаты дип уйлады.

— Тубалыңда ни?

— Берни дә юк. Баланга дип барган идем, тапмадым.

— Бир әле тубалыңны!

Зәйтүнә бирде, азат тубалны ияренә тагып куйды.

— Син кем?

— Күрмисеңмени — азат! Кемнән болай кача идең, чибәркәй?

— Синнән. Син карактан!

— Мин карактан?! — дип гаҗәпләнде азат. — Мин — карак?!

— Карак! Бир тубалымны!

— Бирмәсәм? Бирмәсәм ни кылырсың, чибәркәй?

— Ни кылырга белермен. Син кем дерсең, белмим, иллә мин, азат Бачман баһадирның сеңлесе мендер.

— Әнә ничек, әнә нинди асыл кошка тап булганмын икән!..

Азат әче итеп сызгырып җибәрде, шундук урманнан тагын ике җайдак килеп чыкты һәм, чаптырып, алар янына килеп җиттеләр. Җайдакларның берсе килә-килүгә атыннан төште һәм Зәйтүнәгә баш иде.

— Саумысез, Зәйтүнә туташ! Сез, зинһар, кичерә күрегез инде Артыкны. Исеме дә Артык, кылганы да күп чак артык буладыр. Ул сезне танымый, күргәне булмагандыр, кичерә күрегез. Артык, беләсеңме кем синең алдыңда? Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә, гүзәлләрнең гүзәле, җиде яктан килгән җиде башкоданы кире боручы.

— Качкын Җик Мәргән! Саумы! Искитмәле хәл, сине урманда очратырмын дип кем уйлаган. Баһадир булырсың дип йөри идем, мәргән, ә син башыңны качкынлыкка, юлбасарлыкка салгансың.

— Һәй, гүзәл кыз, узынма әле син алай! — диде Артык. — Җик, рөхсәт ит, алып китимче мин бу гүзәлне урлап? — Артык шулай диде дә, атыннан төшеп, Зәйтүнәгә таба атлады. Хикмәти хәл, Җик Мәргән күз ачып йомарга да өлгермәде, Зәйтүнә Артыкны төртеп екты да, аның атына атланып, калага таба чапты. Җик Мәргән башта ни көлергә, ни кыз артыннан куа барырга белми торды. Шаккатмалы хәл иде. Ул арада кызыкай шактый ераклашкан иде инде. Мамак җәясенә ук элде.

— Уктан алыйммы, Җик Мәргән!? — диде.

Җик Мәргән айнып киткәндәй булды. Мамакның чынлап та кызны уктан алырга җыенуын күргәч, тегенең ук-җәясен сугып төшерде.

— Акылдан шаштыңмы әллә, Мамак! Мин аны куып җитәм.

Җик Мәргән сикереп атына атланды һәм кызны куа китте, аның артыннан Артык:

— Атымны, атымны алып кайт! — дип кычкырып калды.

— Зәйтүнә, Зәйтүнә! Туктагыз, туктагыз, тукта!?

Иллә соң иде инде, кала яклап унлап азатның аларга таба чаптырып килүен күргәч, Җик Мәргән атын кире борырга мәҗбүр булды. Артык Мамакның атына икенче кеше булып атланган иде инде, ул аларга «урманга таба чабыгыз» дип ишарә ясады да ук-җәясен алды. Азатлар куа килгән хәлдә, атышырга иде исәбе. Ләкин азатлар, берара килделәр дә, кире калага борылдылар. Урман сукмагыннан бертын баргач, ниндидер аланга җиткәч, Җик Мәргән атыннан төште, йөгән тезгенен аягына киеп, сузылып үлән эченә ятты. Ат умырып утларга тотынды. Ул арада аның янына Артык белән Мамак килеп туктадылар. Артык аттан сикереп төште дә тыз-быз йөренергә кереште, ә Мамак исә кет-кет көлә башлады. Җик Мәргән торып утырды һәм Артыкның чәбәләнүенә елмаеп куйды.

— Күрдеңме, ничек ташланды миңа! Ә син аны Мамактан уктан алырга кушмадың, җәясен бәреп төшердең!..

— Оял бераз, Артык, хатын-кызны уктан ал, имеш. Үз акылыңдамы син? — диде Җик. — Син аны урларга иткән идең түгелме?

Артык Җик янына утырды һәм, Мамакка ияреп, хәзер инде үзе көләргә тотынды:

— Шәп шылды ич үзе, ә? Кем уйлаган аның шулай итәсен? Сизми дә калдым, төртеп кенә җибәрде.

— Путасында хәнҗәре бар, ул сине барыбер якын җибәрмәс иде,— диде Мамак.— Уктан да синең белән миннән остарак ала, диләр аны.

— Әй сылу да соң үзе, күзләре — ут диярсең. Горур, тәкәббер, һавалы. Тикмәгә генә җиде-сигез башкоданы кире бормагандыр шул, үзенә тиңне тапмагандыр. Җик, миңа кайдан ат табабыз инде?

— Атыңны үзең урлаттың, үзең тап та инде, Артык. Елга буендагы болынга төшәрсең...

— Берүземме?

— Минә нәрсә, азатлар, бу урман миңа ошый. Әллә, мәйтәм, биредә калабызмы? Кыз да, бер килмәсә, бер килер, ә, Артык?

— Миңа кая да бер,— диде Мамак.

— Миңа да,— диде Артык.— Тик минә атым гына урлаттым.

— Ат табылыр, баш исән булсын. Әмир Хаҗи болынында ат бетмәгән, нинди телисең, шундаен сайлап аласың.

— Тотсалар? Әмир көтүчеләре зәһәр халык, беләм мин аларны.

— Ә син сатып ал, алтын биреп. Өч алтынга алар сиңа менә дигән ат сатып җибәрер.

— Әмир Хаҗиның атлары тамгалы, Җик. Миңа тамгалысы кирәкми. Ат табармын, кайгырмагыз. Бүген төнлә үк, тик берегез сунарга үз бахбаен гына биреп торсын.

— Яхшы, алырсың. Тик кара аны, эләксәң — бире кайтмыйсың. Без синең өчен, син безнең өчен үлгән саналыр...

— Баш өсте, Җик Мәргән. Атыңны гына бир, бер урынына ике чабышкы кайтыр, әйтте диярсең. Ук савытымны, калканымны гына кызганам, Кашанның иң оста тимерчесеннән ясаткан идем,— диде Артык үкенеп.

— Алары булыр, җайларбыз,— диде Җик Мәргән.— Инде кая кунабыз? Куыш ясыйсы иде һич югы, Мамак?!

— Ясыйбыз аны. Кояш баеп килә, башта чишмәгә барып су алып килим дә.

— Ә мин куышка агачлар кисә торам,— диде Җик.— Артык, нигә аптырап калдың. Атны ал да китә бир. Иртәнгә монда бул!

— Булырмын, баһадир. Әйтте диярсең, булырмын.

— Алла теләсә, диген.

— Әйе, алла теләсә. Карале, баһадир,— диде Артык кыяр-кыймас кына.— Әллә ул Бачман баһадир сеңлесенә гашыйк булдыңмы?

— Әллә яучы булып барыргамы исәбең, Артык?

— Ә нигә, кирәк икән барырмын да. Чирканчык алдым.

— Юк белән хыялланма, Артык. Кемнәр без? Качкыннар. Ә әмир Хаҗи һәр качкын башына ни бирә?

— Йөз алтын!

— Күрдең, ни бәя безнең башлар!

— Синең баш мең алтын тора, баһадир.

— Минеке кыйммәтрәк тә хәтта. Димәк, син әйткән хәл буш хыял гына, дускай. Әмма ошады ул миңа, тәкәбберлеге өчен генә түгел...

— Шулай икән, кыз монда булыр, Җик Мәргән. Артык артыгын сөйләмәс.

— Моның өчен әмир башыңны кистерер, Артык.

— Башны кисү өчен, иң әүвәл Артык качкынны тотарга кирәк әле, баһадир. Ярый, мин китим, аллага тапшырыйм, баһадир.

Ул арада Мамак тире капчык белән су китерде.

— Хуш, Мамак,— диде атка атланган Артык.

— Игелек сиңа, Артык, игелек! — диде Мамак.— Баһадир, куышны әнә теге карама астынарак куйыйк. Ышык, кеше күзенә дә бик ташланмас. Карале, баһадир, әмир Хаҗи Болгардан аерылып чыгарга тели, дип сөйлиләр, хакмы икән шул?

— Сиңа барыбер түгелмени?

— Барыбер түгелмени дип, ни ич инде, бердәмлеккә ни житә. Әнә теге вакытта, кенәз Всеволод яу килгәч, кем ярдәмгә ашыкты дип беләсең? Әмир Хажи. Башта ул кенәзнең көймәчеләрен пыр туздыра, аннары Бөек Калага юнәлә. Кенәз ни өчен солых төзергә ризалашкан дип беләсең? Аңа әмир Хажиның гаскәре Бөек Калага якынлаша дип житкерәләр. Всеволод тиз генә солых төзи дә, кирәген алып, китү жаен карый. Хәтта үзе белән Болгарга яу килгән кыпчак ханы Янтакның кияве Мөхәммәтгалимбәккә дә ярдәм итми. Шуннан файдаланып, Мөхәммәтгалимбәкне Сәлим хан тар-мар итә. Гыйбрәтле хәл. Хан-кенәзләргә ышанма — Иделгә таянма. Коры жиргә ни житә.

— Куе кара урманга диген, Мамак!

— Син дә хаклы, баһадир. Миңа да ошый бу урман. Әллә, мәйтәм, жайлы урын табып, калабызмы? Мин менә тарлавык буенча барып карадым. Хикмәтле урыннар бар анда, өч кешене генә түгел, мең азатны да яшереп була.

— Күз күрер,— диде Жик Мәргән һәм күктә кабынган беренче йолдызга игътибар итте. Йолдыз белән бергә күңел күгендә Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә пәйда булды.

## 25

Кам үлде, ә ул һаман китми, нигәдер курыкмый да. Кисәк ул кайдандыр өстән килгән сөйләшү авазы ишетте. Ишетте дә нигәдер чыгу юлына карады, тавыш шул яктан килә кебек иде, ләкин икенче мәлдә инде тавыш янә өстән ишетелде.

— Монда бер упкын! — дип кычкырды ниндидер ир-ат.— Баһадир, якын бара күрмә!

Зәйтүнә әпен-тәпен артка чикте һәм ишектәге чыптаны күтәрде. Шул мәлдә нәрсәдер гөрселдәп китте һәм кам куышына гөрс-гөрс килә-килә таш, балчык коела башлады, жир шундаен каты итеп убылды ки, ишектәге чыптаны йолкып атты. Зәйтүнәнең өстенә зилзилә жиле килеп бәрелде, битенә вак ташлар яуды. Зәйтүнә бәрелә-сугыла чыгар юлга ташланды. Үзе дә сизмәстән, чырыйлап жибәрде, бары тик алда яктылык нуры күренгәч кенә, диварга килеп сөялде дә үксеп еларга тотынды.

Зәйтүнә тау куышыннан чыкканда эңгер иңеп, караңгы төшеп килә иде инде. Ул аты янына килде дә, аны муеныннан кочаклап, башыннан сөйде, ялларын бармаклары белән тарады һәм тезгенен ычкындырып атланды да тарлавык буйлап түбән таба төшеп китте. Ул арада ай калыккан, ай яктысында тарлавык караңгыланып калган шикелле иде. Ни сәбәпледер Зәйтүнәнең күз алдында янә Жик Мәргән килде. Аның кыланышына әллә сокланып, әллә гажәпләнеп елмаюы, куа килүе.

Зәйтүнә атын калага таба куалады. Юк, ул бу урманга яңадан килмәс. Жик Мәргән таныш булса да, хан мәргәне исемен йөртсә дә, ул качкын. Тубыкбай абыйсы аның башына мең алтын вәгъдә иткән.

Урманнан чыгуга киң болын башланды, монда ай яктысы бигрәк якты иде. Кинәт учак исе килеп бәрелде. Якында гына учак ягалар. Кемнәр? Качкыннар!

Зәйтүнә төтен исе килгән якка каерылып карады. Таныш аланы ягына. Шулай ук качкыннар аның аланына урнаштылар микәнни? Юк, бу мәлдә аны ниндидер качкыннар кызыксындырмады, күңелен нәкъ менә Жик Мәргән жилкендереп, йөрәген ярсытып куйды. Йә аллам, тагын шул Жик Мәргән. Гашыйк булуымы әллә? Кайчандыр хан мәктәбендә укыганда аның уктан алганын Зәйтүнә сокланып карап торыр иде. Ул чакта алар үсмерләр генә иде шул. Хәзер шул Жик Мәргәнне янә күрде дә тәмам тынычлыгын югалтты. Әллә соң мәхәббәт дигәнең шулай киләме кешегә? Күңеле теләми, ә йөрәге аның янына әйди. Ярый учак ягучылар Жик Мәргән ишләре булса? Аягы тартмады, ә үзе атын төтен исе килгән якка борды.

Аңа берәү дә беркайчан да ихлас күңелдән гашыйк булмады бугай, кызыктылар гына: батырлыгына, уктан оста алуына, ирләр кебек тәвәккәл булуына, һичкемнән курыкмый карурманнарда берүзе йөрүенә. Чынлап та, аңа гел менә бай угланнары яучы җибәрде. Зәйтүнә аларны күрер иде дә ирен чите белән елмаер иде. Моннан шул аңлашылыр иде: тиң түгел ул аңа. Аңа инде күптән ирдәүкә аты кушканнар, кушамат ук булмаса да, күз алдында ук әйтмәсәләр дә, артында аңа ирдәүкә Зәйтүнә диләр иде. Моңа Зәйтүнә гарьләнмәде, киресенчә, бераз горурланыр иде. Аның каравы бикә гарьләнер иде Зәйтүнә өчен. Кемнең дә булса авызыннан ирдәүкә сүзен ишетсә, мәрхәмәт көтмә бикәдән, куып ук җибәрмәсә дә, асрауга көн күрсәтмәс иде. Ирдәүкәсен ирдәүкә, ә бит ул хатын-кыз, хатын-кыз гына түгел, сөелмәгән, кем дә кочмаган, кемнең дә кочагында булмаган кыз бала, егерме ике яше тулып узса да, саф кыз бала һәм сазаган да түгел әле ул. Егетләрне күрсә, күзләренә туры карый, иң мөһиме, алардан мыскал да курыкмый. Ләкин берәүсенә дә яратып караганы булмады әле. Дөрес, сынап карады, сынарга хакы бар иде, ә менә яратып, сокланып, гашыйк булырдай дәрәҗәгә житеп... Җик Мәргәнне күргәч кенә, тәмам тынычлыгын югалтты, җитмәсә, төшенә кереп интектерә качкын Мәргән.

Һәй, кем булса да күрсен әле үзләрен бер. Аты кулында, коралы билендә, ук-җаясе иңендә. Аннары соңга калып кайтып керсә, бикә дә курка калыр. Болай ичмасам абыйсында булдым дияр.

Шунда берәү шаркылдап көлеп җибәрде һәм шундаен каты итеп көлде ки, Зәйтүнә атын калага таба боруын, җилле генә юырттырып урманнан ерагая баруын искәрми дә калды. Нигә кирәк аңа качаклар? Качак ул, кем генә булмасын, качак. Качакның иманы да, аты да, иле дә, туганы да, сөйгәне дә аңа тиң булмас. Качкын берәүгә дә тиң кеше түгел. Качкын, димәк, ким кеше, үз хыялын тормышка ашыра алмаган, шул сәбәпле көрәштән ваз кичеп, качып йөрергә мәҗбүр булган адәми зат. Андыйларга гашыйк булырга түгел, аларны тотып зинданга ябарга кирәк. Мөгаллиме әйтмешли, кулыңа кылыч тотканчы, иманың хаклыгын акылың белән расла.

## 26

Кичтән үк ат алырга киткән Артык, таң аткач кына ике юртак ияртеп кайтып төште. Җик Мәргән кайдан алуын сорап тормады. Барыбер түгелмени.

— Ияр булмадымыни? — дип сорады Мамак.

— Күр әле моны, ат та булсын, ияр дә, кыз да булсын, буаз да,— дип сукрана башлады Артык.— Ашарга бармы берәр нәрсә? Ач мин, бүредәй ач.

— Куышка кер, анда казылык, корт бар.— диде Җик Мәргән.

— Биредә яшәп булмас, баһадир, аулаграк урын табасы иде,— диде Мамак.

— Табарбыз,— диде Җик Мәргән.— Эзләгән таба.

Табарбыз дисә дә, Җик Мәргән кая торасыларын хәл итмәгән иде әле. Кая китә алалар соң алар? Кашан урманнары кебек аулак җир беркайда юктыр. Монда хәтта хан азатлары да керергә курка. Аннары аның Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнәне күрәсе бар. Артыкның атын алып киткән өчен генә түгел. Юк. Кызны күргәч, Җик Мәргәндә үзе дә аныклап бетермәгән күчеш булды. Бер ялгызы калдымы, шундук Зәйтүнә күз алдына килә. Әйе, башта ул аны күрер. Күрер дә киңәшер.

Аның янына Мамак килде, янәшәсенә утырды.

— Мәргән, без сине баһадир итик. Әйе, син баһадир...

— Баһадирның гаскәре була, Мамак. Көлке.

— Булыр,— диде Мамак дәртләнеп.— Булыр синең гаскәрең, баһадир.

— Куй, Мамак. Нинди баһадир ди инде ул. Абыем белән бәхәскә кер-

мәгән булсам, бер хәл иде әле. Ханга барып яллана ала идем, әмиргә. Хәзер барысы да сибелде, таралды, юкка чыкты. Артык, кил әле бире! — диде Жик Мәргән.— Кил әле, кил! Тыңла әле. Утыр янәшәмә. Мине Мамак баһадир итте, шулаймы?

— Ә нигә исең китте, Жик? Мин сиңа күптән баһадир дип дәшәм бит инде, искәрмәдеңмени?

— Син аны шаяртып кына әйттең ич.

— Гафу ит, баһадир, мин уйнап әйтмәдем. Гомумән уйнарга дип килмәдем мин сиңа иш булып. Уен, имеш. Безне тотсалар, беләмсең, нишләтәчәкләр? Ат койрыгына тагачаклар, менә нишләтәчәкләр безне. Уен түгел бу, баһадир. Кара уем белән мин болай уйлыйм: безгә качып йөрергә кирәкмәстер. Халык белән булырга кирәк, халык арасында. Мин сиңа менә нәрсә киңәш итәм, баһадир. Эзләп тап син башта Бачман сеңлесе Зәйтүнәне, аның аша баһадирга чыгарбыз. Бачманны җилле егет диләр. Керер хәлеңә, кермичә калмас. Меңбаш итмәсә, йөзбаш итәр. Ә без синең янда булырбыз.

— Ярый, Мамак, сезнеңчә булсын, баһадир икән — баһадир. Алайса, эшләрне дә бүлешик инде. Син, Мамак бавырчы булырсың, бу эшкә кулың килеп тора; син, Артык, ризык табучы, мин — суга баручы. Мамак, бир күн капчыгыңны, чишмәгә суга барып килим. Кай тирәдә ул, еракмы?

— Ерак түгел, баһадир. Ярты чакрым да юктыр. Тарлавык буйлап барасы-барасы да, сул кулда булыр шунда,— диде Мамак һәм Жик Мәргәнгә күн капчык китереп бирде.

Жик агачлар арасына кереп китте. Ишләренең аны баһадир итүләре көлке иде, әлбәттә. Иллә хәтта шул нәрсә дә аның кәефен хушландырып җибәргәндәй булды. Менә тарлавык бормаланып-сырмаланып югары табарак күтәрелә, монда аю-бүреләр генә яшәсә яшидер. Тарлавыкның киңәеп киткән җирләре дә бар. Хикмәтле бер гадәте бар иде Жик Мәргәннең: серле, куркыныч урын таптымы, ул аны тәмам тикшермичә, нигә булса да инанмыйча, туктый алмый. Хәзер дә, тарлавык һаман югарыга сузылгач, чишмә янында туктамады, бара бирде. Ниһаять, ул зур булмаган мәйданчыкка килеп чыкты. Аңа тарлавык кирмәнгә килеп төртелгән кебек тоелды. Мәгәр чын булса, тарлавык Шайтан кирмәненә якын торса, әйбәт түгел — монда яшәп булмас. Бер күрмәсәләр бер күрерләр, җәй күрмәсәләр кыш күрерләр. Кыш көннәрендә тарлавыкны кар басар, кереп булмый башлар — эзләр турында әйтеп тә торасы юк. Димәк, монда калу буш хыял гына, ахры... Әйе, Җаек буйларына, далага китү хәерлерәк булыр. Абыйсы кешеләре тынгылык бирмәс бирүен, шул ук вакытта аларга таянырга да, ышанырга да булыр сыман, чөнки халык абыйсын яратмый башлаган, икенче хатынга өйләнгән өчен генә түгел. Аңа Җаек буе меңбашы үзенең кызын бирмәкче булган икән, ә Тубыкбай кәләшне Бөек Каладан алып кайткан. Шуннан соң Битекбай меңбаш Тубыкбай баһадирга яман нык ачуланган икән. Башта Жик моңа бик үк игътибар итмәсә дә,бүген шулар хакында уйлап куйды. Кыенга килсә, аны яклар кардәше бар икән бит — Битекбай. Битекбай Тубыкбайга караганда күп тапкыр белекле кешедер.

Жик тирә-ягына күз йөртеп чыкты. Кояш күтәрелеп килә, тып-тын, бераз дымсурак һава, шылт иткән тавыш юктыр. Рәхәт тә соң шундый мәлләрдә. Тикмәгә генә көн туусы борынгы бабалары тезләнеп, дога укыйукый каршы алмаганнар икән. Ихахайлап кычкырып җибәрәсе килә. Ябалдашларын киң җәеп, карт карамалар утыра, тарлавык килеп төртелгән кыяларда нииндидер могҗиза белән мәңге яшел наратлар үсә. Каян аш, каян дым ала икән бу мәһабәт агачлар. Кыядан челтер-челтер итеп су да ага. Димәк, кайдадыр өстә чишмә чыга. Матур җир, шомлы җир, куркыныч җир. Карурман Жик Мәргәнне һәрчак бераз куркыта иде. Далага ни җитә! Атка атланып алуың була, син гүя очар кош! Их, бер җырлап җибәрсәң икән ул! Ярамас. Шайтан кирмәне ерак түгел кебек. Чү, нинди төтен исе бу!?

Жик Мәргән, табыш эзләгән эт кебек, төтен килгән якны исни-исни эзләде. Кайдандыр өстән! Әллә соң чынлап та кирмән якында гынамы?
Жик Мәргән ашыга-кабалана өскә үрмәләде, текә жирләрне урап-урап чыкты. Ниһаять, ул шактый күтәрелде, түбән таба карады. Һәм кисәк башы әйләнеп киткәндәй булды. Төтен исе дә кисәк юкка чыкты.
«Йөрмә тилереп, төш, ишләрең анда су көтә!» диде ул үз-үзенә һәм сак кына түбән төшә башлады. Сәере шул булды, өскә бик тиз үрләсә дә, түбән төшүләре яман булды, бер-ике тапкыр чак кына аяклары ычкынып мәтәлмәде. Ниһаять, төшеп житте, буыннарында жиңелчә калтырану тоеп, беравык типкән йөрәген тыңлап торды. Төтен исе дә юкка чыккан, тарлавык та киңәебрәк киткән кебек. Жик Мәргән чишмәгә ашыкты, килеп житкәч, куш учына көмеш кебек саф су алып, рәхәтләнеп эчте. Чишмә суы тешне камаштырырлык салкын һәм бераз татлырак кебек иде. Эчкән саен эчәсе килә.
— Һәй, кем анда минем чишмәдән су эчә!
Жик Мәргән ялт итеп тавыш килгән якка карады, чарасыз кулын билендәге хәнжәренә салды.
Кайдан ишетелде, нинди тавыш? Житмәсә, Зәйтүнә тавышына тартым иде. Һичкем күренми, тып-тын. Әллә соң саташты гынамы? Бу суны эчә-эчә исердеме әллә? Үзалдына көлемсерәп, капчыгына су тутырды.
— Жик Мәргән! — дигән тавыш ишетте ул кабат. Шик юк, аңа хатын-кыз дәшә иде. Күрмәсә дә, аңа:
— Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә! Мин монда, монда! — дип жавап бирде.
Кыз көлеп жибәрде һәм шундук кыл аркан чажлап егетнең муенына килеп төште. Жик аннан арынмакчы итте, иллә өлгерә алмады, аркан муенын кысты.
— Жик Мәргән. Мин сиңа чәбәләнмәскә киңәш итәр идем,— диде кыз. Ә үзе һаман күренми дә күренми!
Жик Мәргән ике кулын күтәрде, аркан бушады, шундук аның каршына агач башыннан Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә сикереп төште. Кызның өстендә хәрби кием, каешында хәнжәр, иңендә жәя, кулында нечкә кыл арканның бер очы. Күзе күрде Жик Мәргәннең бу сурәтне, күңеле ышанып житмәде — аның каршысында уен биләгән Зәйтүнәме, урман иясеме? Кыз елмая, иллә ачулы елмая иде. Жик авызын ачып сүз әйтергә кыймый торды. Иң әүвәл ул моның чынлыгына ышанмый иде, ышанган хәлдә, ул әсир ич, кыз кулында әсир! Күр инде ир-атны элмәккә алуын. Чынлап та ирдәүкә икән бит бу! Инде нишләргә? Ни дип әйтергә бу әкәмәт сәер кызга? Баш орыргамы, әллә арканын тартып алып ботарлап ташларгамы? Алай дисәң, элмәкне кинәт тартып буып куюы бар!
— Кичер мине, Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә! Кичер, булдыра алсаң.
— Мәргән, төчеләнмәсәң иде. Килешми! Мин бит синең кем икәнеңне бик яхшы беләм, син дә минем кем икәнемне беләсең. Шулай булгач, әүвәл мине тыңла. Бу урман минеке. Монда калмассыз! Бүген үк китүегез хәерле. Мәгәр әүвәл бер йомышымны йомышлап китәрсез.
— Әүвәл арканыңны муенымнан салырга рөхсәт ит, баһадир кыз Зәйтүнә!
Зәйтүнә арканны бушатты, тиз генә жыеп, бил путасына тагып куйды. Ул аны шундаен оста, житез итеп жыйды ки, Жик Мәргән моңа игътибар итте һәм елмаеп куйды. Нигәдер кыз алдына ятасы да моңа кадәр беркемгә дә әйтмәгән татлы сүзләр әйтәсе килеп китте.
— Су гына алыйм инде, Зәйтүнә туташ?
— Мине тыңласаң иде башта, Жик Мәргән?
— Хуш, Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә. Мин сине тыңлыйм.
— Сезнең кыз урлаганыгыз бармы?
— Кыз?! Кичерә күр, гүзәл зат, туры килмәде.
— Сезгә шушы көннәрдә бер кызны урларга туры килер, Мәргән. Ишләрең каршы килмәс дип уйлыйм.

— Кемне урларга, Зәйтүнә туташ?

— Анысы сезгә барыбер түгелмени? Ат урлый белгәч, кызны да урларсыз. Качкын азатың Артык...

— Кичерә күрегез, Зәйтүнә туташ, Артык атларны сатып алып кайтты.

— Сатып? Ул Олашчы авылының игенче Бакыйҗан утарыннан атларны бушлай алып китә. Акчасын бирергә онытып, мәргән. Ә син аңа ышандың. Карак ул, ат карагы синең Артыгың!

— Әйткән сүзләрең хак булса, мин аны янымда калдырмам. Ышан!

— Мин беләм, Мәргән, син — качкын! Ишләреңә дә, үзеңә дә мин ышанып җитмим. Беләсең булса кирәк, сине абыең Тубыкбай гына түгел, хан да, әмир Хаҗи да эзли. Мин сине бүген алар кулына тапшыра ала идем. Иллә сиңа тимәскә булдым. Ләкин белеп китсәң иде: син мактанчык, көч-куәтеңә масайган, тәкәббер бер мәргән. Миңа әле дә мыскыллы елмаеп торасың. Ышанмыйсың, имеш, ничек инде ышбу кыз даны бөтен Болгарга таралган Җикне бәйләп хан кадәр ханга илтеп бирә алсын. Шулаймы?! Шулай, шулай, әнә һаман елмаясың. Кирәк дип табам икән, мин моны расларлармын, мәргән. Янә бер яңалыкны ишет: сине ил-халкың кабул итмәде. Бу — хак. Югыйсә, әмир Хаҗи урманнарында качып йөрмәс идең, әүвәл үз халкың йөзендә терәк эзләр идең. Димәк, син халкың өчен бары тик тузганак. Җил чыгуга тузарсың да китәрсең. Бу — бер. Икенчедән, мәргән, син ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен боздың. Абыең Тубыкбайга кеше иңе күтәрә алмастай таләпләр куйдың. Илгә кайткач, әүвәл халкың алдында абруй казанырга, аннары гына абыеңа таләпләрең куярга идең, тик моны эшли алмадың. Шуның өчен минем алда да дәрәҗәң төште, Җик Мәргән. Ә бит мин сине еш кына искә ала торган идем. Син минем өчен дә, халкың өчен дә, абыең өчен дә атыңнан егылдың, мәргән. Син — качкын! Шуңа күрә моннан китүең хәерлерәк булыр. Тик йомышымны йомышлап...

— Йомышың әйт, Зәйтүнә туташ! Йомышың әйт!

— Әйтмим, Мәргән. Күрәм, син кызу канлы, һәр нәрсәне куркытып хәл итәргә өйрәнгәнсең. Ә мин синнән курыкмыйм.

— Зәйтүнә туташ, бабаларыбыз төркиләрне ике очракта гына тез чүгә диләр иде: чишмәдән су эчкәндә һәм иленә ант иткәндә. Биредә чишмә, мин аннан тезләнеп су эчтем, инде синең алга тезләнеп ант итәм: моннан ары беркайчан да караклык итмәм, юлбасарлар белән бер юлда булмам, гаделлекне халкым белән бергә эзләрмен!

— Тор, Җик Мәргән, тор! Үз алдымда тезләнеп торганыңны күрәсем килми! Ир-егет бул! Инде йомышым тыңла. Мин бүген Бөек Калага китәм. Хан кызы Назлыгөл янында утырмада булачакмын. Ишеткәнең бардыр, Җик Мәргән, хан кызы оста Дәүранга гашыйк. Ләкин алар беркайчан да насыйп итми кавыша алмаслардыр. Ә без аларны кавыштырыйк. Хан кызын урлап, яңа калага, оста Дәүранга илтергә кирәк.

— Зәйтүнә туташ, хәтерем ялгышмаса, оста Дәүран хан колы иде шикелле?

— Әйе, хан колы иде, әмма әмир Хаҗи аңа ирек бирде. Өч көннән сез дә Бөек Калага килегез. Җомга көн иртәнге якта Назлыгөл Хан күле янына төшәр. Калганына сезне өйрәтәсе юктыр дип уйлыйм. Икенче көнне хан кызы Назлыгөл яңа калада булсын. Мин сезне каршы алырмын. Хан кызын оста Дәүранда калдырасыз. Шуннан туры Иске Казанга китәрсез. Абыем Бачман баһадирга менә бу беләзекне бирерсез.

Җик Мәргән кыз кулыннан үрелеп беләзекне алды һәм баш иде.

Зәйтүнә сызгырып җибәрүгә, каршына ак ат чабып килде, иясен күргәч, хәтта кешнәп куйды. Кыз егетләргә хас җитезлек белән атка атланды да, артына да әйләнеп карамый, күздән югалды.

Ни булды? Төшендәме, өнендәме? Хикмәт димәсең, хикмәт. Ниндидер кыз килде дә Җик Мәргән кадәр Җик Мәргәнне арканга алды, ант иттерде. Инде антын җиренә җиткереп башкармаса, нәзере тотар. Җик карама башында утырган саесканга игътибар итте, шуннан күзе чишмә янында яткан

күн капчыкка төште. Су, су алып кайтырга кирәк ич аңа. Ишләре көтәләрдер.

Аланга ул йөгерә-атлый кайтып керде. Артык белән Мамак куышта утыра, нидер сөйләшә, атлар утлый. Атларны да эчерәсе иде бит, нишләп утыралар. Каравыллары кая! Жик Мәргәннең ачулы чагы иде, су тулы капчыкны куышка терәп куйды да, атларның тышауларын чишеп, тезгеннәрен җыйды һәм чишмәгә эчерергә алып китте. Атларны эчереп кайтып килгәндә генә, кабалана-кабалана якынлашучы Артык белән Мамакны күрде.

— Баһадир, баһадир! — диде Артык коты алынып.— Атларыбызны урлаганнар дип торабыз! Күр инде, тәмам котны алдың!

— Мин аны бераз абайлаган идем,— диде Мамак, елмаеп.

Жик Мәргән атлар тезгенен ишләренә бирде дә, бер сүз әйтми, алдан китте. Артык белән Мамак күзгә-күз карашып алдылар. Аланга кайтып җитеп, атларын тышаулагач:

— Шүрәле очрадымы әллә, баһадир, нигә бик озак йөрдең? — дип сорады Артык.

— Артык, син кем атларын урладың? — дип эндәште аңа Жик. Үзе җәясенә ук алып маташа.

— Баһадир...

— Ни булды, баһадир! Баһадир?! — дип килеп чыкты куыштан Мамак.

— Китеп тор, Мамак. Китеп тор, дим! — дип җикерде Жик.— Җавап бир, Артык!?

— Мин аның сука атларына тимәдем, баһадир.

— «Сука атларына». Күр әле нәрсә ди?! Күр әле моны! Ә нигә башка атларына тидең?! Нигә урладың атын?! Ә бит ялганладың, җир бит, ялганладың. Имеш, акча биреп алган. Акчага икән, ул сиңа ияреп дә биргән булыр иде?! Инде нишлибез моның белән, Мамак?!

— Ат кыз түгел, баһадир, кичерик,— диде Мамак.

— Кем түгел? — Мәргән ирексездән елмаеп куйды.

— Ат кыз түгел дим, кичерик бер юлга. Аннары аш та суына, ашап алырга иде...

Жик Мәргән җәясен иңенә элде, угын садагына салды.

— Яшә, эттән туган нәмәстә! Тик мине тагын кичерер әле дип уйлама!

— Яңадан кылмас ул андый ахмаклыкны, кылмас, баһадир,— диде Мамак. Аннары икенче иптәшенә эндәште:— Йә, ни катып калдың, бар, агачлар арасына кереп елап кил!

— Бар-бар, аннары бер кызык сөйләрмен үзегезгә! — Жик Мәргән күңеленнән Артыкны кичергән иде инде, иллә йөрәге һаман да килешми иде. Егет аларны алдады, ике бөртек дустын, ә күбәү булсалар, ун, егерме, йөз, мең... һәм һаркайсы баһадирларын алдаса? Ант эчкәч, бер табынга утырып ашагач?.. Ләкин шундук Зәйтүнәнең Артыкка хәзергә берни дә белдермәскә дигән сүзе исенә төшүгә, үзалдына кызарынып куйды. Ә бит ул үзе дә кызга биргән вәгъдәсен бозды. Кыз урларга бару алдыннан башларга ярый идеме бу сүзне? Юк.

Табын янында Артык ипи тотып тәүбә итте, атларны ул чынлап та игенче утарыннан урлаган икән, акчаны чынлап та бирмәгән. Артык янчыгындагы берничә алтын тәңкәне ашъяулыкка чыгарып салды.

— Мин аңа бүген үк илтеп бирермен ышбу акчаларны, баһадир. Кулымда коръән булса, коръән тотып ант итәр идем.

— Кыланма, шамакайланма,— диде Жик сарык ботын кимерә-кимерә.— Коръән тоту өчен әүвәл сиңа аны укый белергә кирәк. Ә синең укуың ташка үлчим.

— Анысы хак,— диде Мамак.— Җайлап имла да куя белми. Хәтта тамгасы да юк.

— Куеп тор әле, Мамак, ул хәлне. Анысына өйрәтербез. Тамгасы да булыр, имласын да куяр. Мине тыңлагыз әле: өченче көнгә, хәтта әйтергә

дә куркыныч, хан кызы Назлыгөлне урларга китәбез!

Мамак сөяк кимергән җирдән шым булды, Артык исә ачкан авызын яба алмый торды.

— Ни-ни? — диде, ниһаять, Артык.— Ни диден, баһадир?

— Хан кызы Назлыгөлне урларга!

— Һе,— диде Артык.— Һе, хан кызын. Тотып ат койрыгына такмаслармы соң безне, баһадир. Шул гына җитмәгән тагын. Качкын булдык, карак аты тактылар, инде хәзер кыз урларга, җитмәсә, хан кызын урларга? Кем өчен соң?

— Сиңа барыбер түгелмени, Артык?

— Барыбер түгел, баһадир, барыбер түгел.

— Миңа калса, тәҗрибәң җитәрлек; карак атың да бар. Ат урлау ни дә, кыз урлау ни...

— Барыбер түгел,— дип күтәрелде Артык.— Кыз урлау күңеллерәк, иллә соңы яман бетүе бар.

— Кыз урлау, минем кара уемча, караклыкка керми. Киресенчә, мактаулы эш диясем килә,— диде Мамак.

— Яхшы әйттең, Мамак, бик матур әйттең... Йә, Артык, элдер атлар иясенә. Атның берсен илтеп бирерсең, шул исәпкә ияр алып кайтасың.

— Көпә-көндезме, баһадир?! Хан азатларына тап булсам?..

— Аллаһы тәгаләдән ярлыкау сора. Явызлык кыла белгәч, җавабын да тота бел. Хуш, Артык!

Җик Мәргән амин тотты да куыштан чыгып китте. Шунда гына исенә төште: аларның өчесен дә шушы куышта куыра алырга мөмкиннәр иде ләбаса. Хан азатлары белән орышу түгел, сак куя да белмиләр. Әйе, ишләрен әрләргә түгел, үзен орышырга тиеш ул! Баһадир буларак, иң әүвәл үзе сак турында кайгыртырга тиеш иде! Ә аның гамендә дә юк. «Баһадирыбыз бул!» — дигәч, килеште тагын үзе. Адәм көлкесе. Ике азатлы баһадир. Чын баһадирда илледән артык җансакчысы гына була. Кәмит, бары кәмит.

— Артык, озак йөрмә,— диде Җик егеткә.

— Мамак та барса икән минем белән, баһадир?

— Нинди баһадир булыйм ди мин сиңа?!

Мамак белән Артык янә күзгә-күз карашып алдылар.

— Шулай сөйләшкән идек ич инде, Җик?

— Сиңа Мамак нигә кирәк?

— Кеше белән сөйләшә белә, мин ике сүз әйтәм дә күтәрелеп бәреләм. Аннары Мамак күп нәрсәдән хәбәрдар. Әйтик, ул Шайтан каласына бакыр чыгарган, Урал якларыннан эремә таш ташыган. Агыйделнең салкын суында алтын юган кеше. Абыең Тубыкбайда азат булган. Күрмәгәне юк аның...

— Башыңа төшкәч, син дә өйрәнерсең,— диде Мамак.— Дөнья михнәт чиктерә ул.

— Бакырны кай тарафтан чыгардыгыз, Мамак?

— Бакыр базлары моннан ерак түгел. Шайтан манарасыннан да төшеп була. Ләкин аннан юлны бикләделәр бугай, әмир Хаҗи манараны күтәргәч, юлны каплаган, диделәр.

— Тагын ни беләсең, Мамак?

— Борын-борын заманда Таман ярымутравында һәм Тын елга буйларында яшәгән төрки болгарлар монда күчеп килгәч, Шайтан тавына манара күтәрәләр, күзәтү манарасы. Ләкин төрки болгарлар килгәнче үк инде биредә ниндидер мәҗүсиләр поты була. Төркие, чирмеше, ары, мукшысы, исүе, висүе шул потка корбан бирә торган булган. Бик борын заманда бала-чагаларын, угланнарын, аннары мал-туар корбан итә башлаган икән мондагы халык. Тәңреләре саф алтыннан булган, диләр, атнага бер, халык бик күп корбан биргән көннәрдә, ил арасына чыгып йөри торган булган, кичен, эңгер-меңгер вакытта. Шунда арада берәүсенә кагылып киткән һәм теге кешене шундук корбан иткәннәр, диләр. Моны миңа кам сөйләде, ул еш кына безнең янга килер иде. Хәзер менә ничә ел инде ул камны да күргәнем юк. Аны тыңласаң, баһадир, гел менә хикмәт инде. Белмәгәне юктыр. Хә-

вер ул синең алдында кәҗәгә, хәзер атка, хәзер зифа кызга әверелә. Әкәмәт инде менә. Ә менә безнең арада берәү бар иде — Румнан килгән оста. Ул аңа ышанмый иде. Минем күз алдымда зифа кыз түгел, шамакай кам басып тора, ди торган иде. Олуг тимерче Әхмәт, ишеткәнегез бардыр, бәлкем, кам белән үтә дә дус иде. Оста Әхмәтне'әнә әмир Хаҗи яңа каланың тархәны иткән, диләр. Угланы, имеш, Шайтан каласында. Ниндидер каты тимер коя, диләр.

— Чуен ул, чуен, диләр аны, Мамак.

— Хак, чуен, менә искә төште. Башта без аны кабып та караган идек, имеш, катымы. Акчаны кабып караган кебек. Тешең сына, чуен дигәнендә теш эзе дә калмый. Аннары Шайтан каласына теге хан колы оста Алпарның Туйбикәдән туган угланы килде. Манараны өр-яңадан торгызды, әллә нинди хикмәтле төньюллар ясады, диделәр. Сәлим хан килгәч, манарага керә икән, керә дә остага төн юлларын күрсәт, ди. Теге әйтә, үзең тап, ди. Шуннан хан остага кылыч белән ыргыла. Хан шул чуеннан ясаган кылычын ала да орыша башлый. Ханның кылычы останың кылычына тиюе була, шартлап сына. Шуннан ханның җансакчылары ябырыла остага, тегеләрнең дә кылычларын үлән кискәндәй кырып ташлый Дәүран. Шуннан хан останы манарага ябып калдырмакчы була, әмма яба алмый, кинәт манараның дивары кузгала һәм барысы да ишегалдына коелалар. Китә орыш, кырыш — Дәүран ханның меңләгән азатын харап итә. Ниһаять, тегенең кылычын бәреп төшерәләр дә останың кул-аягын бәйлиләр. Бәйлиләр дә Бөек Калага, хан зинданына озаталар.

— Болгатма әле, Мамак. Сәлим ханны угланы әмир Хаҗи коткара, ташчылар фетнә кузгата, ханның күп кенә азатларын кыралар, ярый әле әмир Хаҗи килеп җитә һәм атасын йолып алып кала. Әмир Хаҗи баш күтәргән барлык осталарны, башларын кисеп, елгага ташлата, ә оста Дәүранны, атасы кушуы буенча, Бөек Калага озата. Соңыннан әмир Хаҗи шул останы үзенә сорап ала һәм аны яңа каланы салырга алып китә. Менә шул кешегә, Мамак дускай, без синең белән хан кызын урлап алып барырга тиешбез...

— Баһадир, мөмкин хәлме бу?!— диде әле булса китә алмаган Артык.

— Ә син китмәдеңмени әле, Артык!

— Киттем, киттем, баһадир...

Артык күздән югалгач, Мамак Җик янына килеп утырды.

— Оста Дәүран турында да әллә нинди хикмәтләр сөйлиләр, баһадир. Имеш, ул егет хан кызын сихерләгән икән. Ләкин мин моңа теге вакытта да, әле дә ышанып җитмим. Мин шуны беләм: Дәүранның анасы Сәлим ханга икенче хатын булып килә, иллә күпме торса да, балага узмый. Хан тота да моны кол остасы Алпарга бирә. Башта Туйбикә оста турында ишетергә дә теләмәгән, диләр. Аннары үзен күргәч, аллага тапшырган, чөнки, имеш, шул төндә төш күргән икән. Төшендә ул шушы кол Алпардан угыл тапкан. Ләкин, төшендә тапса да, өнендә бу хәл тиз генә булмаган. Ул арада Сәлим хан кыпчак ханы кызы Зөбәрҗәткә өйләнә. Теге аңа берсе артыннан берсе ике углан табып бирә — Хаҗи белән Илһамны. Берничә ел үткәч, инде яңадан бала тапмам дип торганда, Зөбәрҗәт ханга бер кыз тудыра — Назлыгөлне. Шул ук төндә, әйтсәм әйтим, теге остага кияүгә бирелгән Туйбикә да бала таба — ир бала, атын Дәүран куштыра. Туйбикә камнан юраткан икән, ди: аллаһы тәгалә кемгә язган, имеш, хан кызын? Кам, синең угланыңа, дигән. Туйбикә үләр алдыннан угланын чакырып алган да: «Дәүранкаем, төшемә керде, син хан кызы Назлыгөлгә өйләнерсең!» — дип әйтеп әйткән, ди. Шуннан соң оста егет хан кызына күз сала башлаган һәм тегене тәмам сихерләгән, ди. Хан кызы әле дә гел оста егет турында гына уйлый икән...

— Мамак, син кем? Хикмәт, мин сине гап-гади азат дип кенә белә идем, чичән икәнсең бит, әллә соң хан шымчысымы?

— Мин чичән дә, шымчы да түгел, баһадир. Мин бары тик тыңлый беләм. Сөйләмим, тыңлыйм да тыңлыйм. Тыңлаган — акыл җыяр, сөйлә-

гән — акыл сатар, ди. Мине башка нәрсә борчый әле. Хан кызын урларга баруыбыз акланамы, тозакка гына эләкмәбезме? Әмир Хаҗи гаиләсендә тәрбия алган, ир-егетләрдән бер дә ким орышмаган Бачман баһадир сеңлесе корган хәйлә генә түгел микән дим? Җик Мәргән үзе үк хан кулына килеп керүе ихтимал лабаса.

Мәргән дәшмәде. Чынын гына әйткәндә, ул үзе дә бу хакта уйлаган иде, мәгәр кызга шиген белдерәсе килмәде, хәзер исә, ният чынга әверелә башлагач, моның янына Мамак та шиген белдергәч, Җик шомлана калды. Шул ул вакытта белә иде, ул хан кызын урларга барыр, бармый калмас, чөнки Зәйтүнәгә вәгъдә итте. Ә ул ирдәүкә кыз менә ничә көн инде аның күз алдыннан китми дә китми. Әгәр дә мәгәр Зәйтүнә күктән йолдыз алып бирергә кушса, аны да алып бирер иде кебек. Әнә шундый бер халәттә иде Җик Мәргән. Шуңа ул азаты Мамакка дәшмәде. Дәшкән бер откан, дәшмәгән — ике, ләкин ул шуны да аңлый иде: азатына ни дә булса әйтергә тиеш, иң яхшысы чынын, мыскалын да яшерми. Мамак белергә тиеш: кая, ни өчен бара ул, кем белән. Бәхәссез, Зәйтүнә туташның нияте ихлас булса, кызы югалу белән хан аны эзләргә керешер. Моның өчен бөтен гаскәрен аякка бастырыр да, чат саен сак куяр, иллә үзенекен итәр — урланган кызын табар. Кыз табылгач, барысы да ачыкланыр һәм Җик Мәргән үз гомерен дар агачында бетерер. Кызы югалуга, Сәлим хан угланнарын дәшеп алыр, аларга да урланган кызы Назлыгөлне эзләргә кушар. Назлыгөлне алар яңа калага илтергә тиеш, ә әмир Хаҗи башкаласын шунда күчереп ята. Димәк, хан кызын бер күрмәсә, бер күрәчәк. Кеше энә түгел, энәне дә тапкан кешеләр бар. Шулардан Таймас баһадир һәм Бачман баһадир. Сизенә, сизенә Җик, Бачман баһадир белән аның күзгә-күз очрашасы бар әле. Ләкин нинди сәбәпләр аркасында? Җикне качкын буларак тотармы Бачман баһадир, әллә кыз урлаучы итепме? Ни генә булмасын, Бачман баһадир белән ул очрашыр. Ә инде Зәйтүнәнең сүзләрендә хаклык ятса, Җик Мәргән үзе Иске Казанга барыр. Йолып калырмы аны Бачман баһадир, әллә тотып Сәлим ханга илтеп бирерме?

— Хан кызын урларга мин берүзем булса да барырмын, Мамак.

— Хан кызын урлау ил өстенә төшкән афәт булыр, баһадир. Шигем бар, Җик. Кыз урлауны Сәлим ханның энесе Мөхәммәтгалимбәк оештырмады микән? Абыйсыннан үч алырга иткән булса? Ямак хан кызына өйләнсә дә, бабасы тегеңә җир-су бирсә дә, кеше сүзенә ышансак, Мөхәммәтгалимбәк һаман Болгар тәхете турында уйлый икән.

— Ике туган арасына кереп булмастыр, Мамак. Алар тәхет өчен, без синең белән ирек өчен көрәшәбез. Мине бирегә ирек китерде. Мин бүген берәүгә дә буйсынмыйм, берәүгә дә бил бөкмим. Бачман баһадир кулына эләгүем белән мин кеше кешесе булачакмын. Бу йөгәнне мин абыемда да кия ала идем.

— Кызларга вәгъдә бирү изге нәрсәдер, Җик. Син Бачман баһадир сеңлесенә вәгъдә бирдең һәм аны, шул юлда егылып үлсәң дә, башкарып чык! Егет сүзе бер булыр! Куркак турында тарихка язмыйлар. Тарихка каһарманнар турында гына язалар.

— Килештек, Мамак, барабыз. Язганы булыр. Ә хәзер, бар, атларны карап кил, ерак китмәсеннәр.

Ни ул ихтыяр көче? Моңа кадәр сораган булсалар, Җик, ихтимал, тапталган сүзләр белән җавап бирер иде: тапкырлык, тәвәккәллек, батырлык. Әйе, бу сыйфатлар күп кешегә хас нәрсәдер. Ә ир-егеттәге ихтыяр көче ни? Кылыч-сөңге тотып Ватанның саклаумы, үлемгә каршы барумы? Әллә соң бөтенләй башка нәрсәме ул ихтыяр көче диган ир-егет сыйфаты? Әйткән сүзендә торудамы, кирәк икән, туган ил һәм сөйгән өчен үз-үзен корбан итүдәме?

Әйе, Җик аңа вәгъдә итте һәм, таш яуса да, хан кызын урлар, яңа калага — Казандагы оста Дәүранга илтеп бирер. Йөрәкне капчык авызы итеп, кысып бәйләп булмый. Ул аңа гашыйк, бу хакта Җик

соңгы мәлләрдә генә инанды. Әйе, ул аны ярата. Болгардагы кызларның меңнән берсе генә яраткан егетенә кияүгә чыгадыр. Шуларның берсе Зәйтүнә булса? Әйтик, ул моңа кадәр берәүне дә яратмаган һәм, Жикне күргән дә, аңа гашыйк булган? Ләкин тәкәббер кыз егетнең батырлыгын сынарга тели булса кирәк, хан кызы Назлыгөлне урларга куша. Ихтыяр көче моңа җитәрме, янәсе, үзе сайлаган егетнең? Бик ихтимал ич! Әйе, Җик Бачман баһадир сеңлесе ни кушса, шуны кылыр. Кыядан ташлан дисә — ташланыр. Хан кызын урла дисә — урлар, гәрчә тегене дә, моны да эшләргә күңеле тартмаса да. Оста Дәүран — хан колы, Назлыгөл — хан кызы. Икесе ике ярда басып сөйләшергә дә хаклары булмаган затлар. Җик Мәргән ике көннән аларны кавыштырыр. Моны аңа Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнә кушты. Ачуы да килә Җикнең тәкәббер кызга, шул ук вакытта ул кушканны кылмый тынычлана да алмастыр, күрәсең.

— Атларны таптым, баһадир, болынга чыгып баралар иде,— диде Мамак куышка керә-керә.

— Карале, Мамак, мин сарайда белем алган кеше. Бачман баһадир сеңлесе безгә качкын атын такса да, ул көнгә калганыбыз юк ич әле. Сәлим хан дошманым түгел, абыем да. Хан кызын урлау игелекле эш булырмы икән?

— Күр инде, Җик Мәргән әйтәме моны? Баһадир Мәргәнме?! Аның башына хан белән абыйсы мең алтын вәгъдә иткәннәр, ә ул «ай-һай, гөнаһ кылмагаем!» дип үкенеп утыра. Хан алдына тотып китерсәләр, кызганыр микән ул сине? Аягыңнан агачка асып, аю-бүреләргә ботарларга калдырмас микән? Син инде, баһадир, икеләнеп маташма. Икеләнгән бер откан, тәвәккәлләгән — ике, диләр.

— Куй-куй, Мамак! Ышандырдың. Егет икәнсең, рәхмәт!

— Оста Дәүран кол, имеш. Ул кол дигән халык башкалардан киммени? Әйтик, синең белән миннән? Аларда да йөрәк бар, күңел. Хан кызы Назлыгөл — гүзәлләрнең гүзәле, ә оста Дәүран — осталарның остасы. Ул ясаган бизәкләрнең җаннары гына юк, ди. Хан үзе аның эшенә көннәр буе карап туя алмый икән, диләр. Без Дәүранга игелек кылабыз, Җик. Хыянәт итмибез ич! Хыянәт итсәк икән ул! Изге эшкә барабыз, баһадир. Мин сиңа сөенче китердем, баһадир. Әйдә, чыгып кара.

— Ни тагын?..

— Әйдә, әйдә, башта чыгып кара!

Алар икесе дә куыштан чыктылар. Алан уртасындагы ак атны күрде дә Җик таң калды, сораулы күзләре белән Мамакка текәлде.

— Мамак, бу ни дигән сүз?

— Сиңа, баһадир, Зәйтүнә туташ үз атын җибәрде. Менә ни!

— Кем китерде, нигә миңа әйтмәдең?

— Үзе әйтергә кушмады, баһадир. Миңа калса, ул кыз сиңа гашыйк булгандыр, сиңа булган мәхәббәтен шулай сиздерүедер.

Җик җавап бирмәде, бүләк ителгән атка таба китте. Ат башта чит кешедән ятсыныбрак торды, иллә Җик, атларның телләрен белмәсә дә, аларга йомшак итеп дәшә белә иде. Ул әкрен генә толпар янына килде дә ял астыннан сыйпады, сөйләнә-сөйләнә сөйде, колак артын кашыды. Ат, пошкырып, башын чайкап куйды да, ашарга ирек бир дигәндәй, үлән чемченергә тотынды.

— Бәйрәм ашы кара-каршы гына булды, Мамак. Бачман баһадир сеңлесе Артыкны атсыз калдырган иде.

— Артыкка түгел, сиңа, сиңа атап бирде ул аны, баһадир.

— Үзе кайчан килә́м диде?

— Менә анысын әйтмәде, баһадир. Иллә килер ул, килер.

— Көрәзәлек итәсең. Мәгәр үзе белән әмир азатларын алып килсә?

— Менә анысы булмастыр, баһадир. Мәхәббәт малга сатылмый. Күңелем белән сизәм, ихластан йөри ул кыз бала.

— Димәк, Мамак, хан кызы Назлыгөлне урларга ходай үзе кушкан булып чыга.

— Әгәр дә мәгәр ошбу көннән Бачман баһадир сеңлесе синең өчен хода үзе икән, кушкан булып чыга, баһадир.

## 27

Яңа каланы салып ятучы осталарның остасы Дәүран хан кызы Назлыгөлне күрде дә тәмам телсез калды. Кайдан?! Әлбәттә инде, Бөек Каладан. Әмиргә корган өйне карарга дип килгәнме? Шулайдыр, әлбәттә Әмир сараен тәмамладылар, рәхәтләнеп карый ала. Тик хан кызы нигәдер аның өенә килгән. Җитмәсә, үз итеп елмая. Хан кызы артында басып торучы азатлар да самими елмаю белән елмаялар. Ханның җансакчыларыдыр. Хан кушса, хәзер үк аның башын кисәчәкләр.

— Әмир сараенда туктадыгызмы?— дип сорады оста Дәүран.

— Эшеңне карарга килдем,— диде, ниһаять, Назлыгөл.

— Күрдегезме соң?

— Күрдем. Бик ошый. Матур!— диде хан кызы башын чөя төшеп.

— Сәлам, оста Дәүран!— диде азатларның берсе.— Җик Мәргән мин, ишеткәнең бармы?

— Хан мәргәне?

— Үзе. Таныдың, димәк. Менә нәрсә, оста,— диде Җик Мәргән, Дәүранның терсәгенә кагылып.— Хан кызы Назлыгөл синдә калып торыр.

— Миндә-ә?!

— Синдә, синдә, оста.

Җик Мәргәнне оста Дәүран чынлап та белә иде. Ишетеп. Соңгы вакытта аның турында әллә нинди хәбәрләр сөйли башладылар. Имеш, абыйсыннан качып йөри икән, хан мәргәнне эзли икән. Кыскасы, хан мәргәне качкынга әверелгән, имеш. Абыйсы Тубыкбай хәтта энесе башына мең алтын вәгъдә иткән дигән сүз дә йөри. Гайбәт кенәдер, юкса хан кызы белән остага килеп кермәс иде. Димәк, Җик Мәргән Сәлим ханның җансакчысы йә йөзбашы йә меңбашыдыр.

— Кичерә күр, Җик Мәргән, мин бернәрсә дә аңламыйм. Ни бу? Синең белән килгән азат кем?— Ул мәргәннең колагына иелә төшеп пышылдады.— Хатын-кызга охшаган.

— Күзең очлы икән, оста. Бачман баһадирның сеңлесе Зәйтүнә ул. Нишлисең, хәрбиләр киеме ярата. Назлыгөлне дә ул алып килде.

— Кәтиб Хафиз шәкерте Зәйтүнә Назлыгөлне миңа алып килдеме?

— Куй әле шул гаҗәпләнүеңне. Зәйтүнә — хан кызы Назлыгөлнең ахирәте. Назлыгөл аңа синә булган мәхәббәте турында чишелгән... Һәм менә без монда...

— Ничек монда?! Бу бит, Җик Мәргән?..

— Курыктың, оста! Курыкма, хан кызы сине ярата. Ишетәсеңме, ярата!

— Әйе, мин сиңа бөтенләйгә килдем, Дәүран. Бөтенләйгә!— диде хан кызы һәм егетләр янына таба ымсынып куйгандай итте.

— Мөмкин хәлме бу, Назлыгөл, мөмкин хәлме?! Моның өчен иртәгә үк синең дә, минем дә...

— Нигә син болай куркакландың, Дәүран? Шайтан каласында баш күтәргәндә бер үзең бер көтү хан азатын куып йөргәнсең, диләр.

— Анда мин ишләремне якладым, Җик Мәргән.

— Монда мәхәббәтеңне якла!

— Мәхәббәтем?!

— Әйе, ул сиңа килде, оста Дәүран. Табын хәстәрләр идең,— диде Җик, хуҗаның иңенә кагылды.— Без юлдан килгән кешеләр. Малаең юкмыни?

— Юк, мин үзем генә торам.
— Зәйтүнә, алгы якта останың ризык-нигъмәтләре бардыр. Табын хәстәрләсәгез иде.
— Мин үзем, үзем,— диде оста, кабалана төшеп.
— Куй, андый эшне хатын-кызга тапшыр инде, оста Дәүран. Катышма син аларга. Хәстәрләсеннәр.
Барысына да ышанырга була иде, әмма хан кызының үз янына качып килүенә? Җик Мәргән — хан җансакчысы, шаяртадыр әле. Шаяртмаган хәлдә... Ул турыда хәтта уйлавы да куркыныч иде.
Күп тә үтми, ир-егетләрне табын янына чакырдылар. Оста Дәүран хан кызына ояла-тартына гына күз төшергәләп алды. Назлыгөлнең үз өендә утыруына ул әле һаман ышанмый иде.
— Шактый җитеш яшисең тагын үзең,— диде Җик, табынга күз ташлап.— Күр әле, казылык, корт, чәк-чәкләрне. Анысын кем китерә инде?
— Тархан тырыша. Ипле кеше, игелекле.
— Үзең игелекле булганга игелекледер,— диде Җик Мәргән.
— Менә өрегеннән дә, йөземеннән дә, хөрмәсеннән дә җитешегез, Назлыгөл,— диде оста Дәүран, табындагы ризыкларны аңа табарак күчергәләгәндәй итеп.
— Дәүран, мин сиңа — «син», ишетәсеңме!
Хәйран, ни ди инде бу хан кызы тагын? «Син» дип дәшергә куша. Ханга җиткерсәләр? Назлыгөл аның күзләренә карады. Һәм оста егетнең йөрәге ярсынып китте.
— Килешерме соң, Назлыгөл?
— Күр әле моны, Назлыгөлем-былбылым диген, җүләр беткән. Ул сиңа бөтенләйгә килде. Бөтенләйгә!
— Мин сиңа чынлап та бөтенләйгә килдем, Дәүран,— диде Назлыгөл һәм йомшак кына егетнең кулына кагылды.
Дәүранның битенә кайнар кан йөгерде, борыны очына тир бөртекләре тибеп чыкты. Оста егетнең күңеле наз белән тулды. Иллә авызын ачып сүзен әйтә алмады. Ни әйтсә дә, чын булмас кебек иде.
— Назлыгөл, чынмы бу хәл? Чын булган хәлдә, мин иртәгә, берсекөнгә ни кылырга тиешмен!..
— Куркуың хаклыдыр, Дәүран. Атам мине эзләп тапса, икебезне дә кичермәс. Абыем әмир Хаҗи азат итсә дә, син әле булса атамның колысыңдыр. Шуның өчен мин сиңа, Дәүраным, хан кызы булып түгел, малай булып килдем. Без киңәштек инде дусларым белән. Минем хакта шау-шулар тынгалаганчы, йомышчы малаең булып торырмын. Иртәгә үк миңа малай киемнәре алып кайтырсың. Шулаймы, Җик Мәргән, Зәйтүнә ахирәтем?..
— Танысалар?
— Танысалар. Хан кызының оста Дәүранда йомышчы малай булып торуы кемнең башына килер. Каланы салып бетергәч, атам сиңа ирек бирер. Никах укытырбыз.
Хәлләр чынга таба бара иде. Мәгәр Дәүран алдагысы турында уйларга курыкты. Аның янында — әлегә кадәр уй-хыялында гына йөрткән Назлыгөл. Әйтсәң, һичкем ышанмастай хәл. Әңгер иңәр-иңмәс килде дә керде. Тәвәккәл иде хан кызы. Дәүран Назлыгөлнең кулын кысты. Хан кызының кулы йомшак, салкын иде.
— Кем урлады сине, Назлыгөл?
— Ахирәтем Зәйтүнә, Җик Мәргән, аның ишләре Мамак белән Артык.
— Алар кайда соң?
— Сакта, оста Дәүран. Безне монда бераү дә күрергә тиеш түгел.
— Назлыгөлне ахирәте Зәйтүнә кушуы буенча урладык, оста. Йә, безгә китәргә вакыт, Зәйтүнә,— диде Җик Мәргән.— Хан кызының исеме Тансык булыр. Онытма, Тансык. Син дә онытма, Дәүран.

— Җик Мәргән, сезгә булган рәхмәтемне...

— Куй, кылынасы кылынды инде. Кызны син алдың, мин бирдем. Хуш, хан кызы!— дип баш иде дә Җик Мәргән, ишеккә таба китте. Зәйтүнә ахирәтен кочагына алды, колагына нидер пышылдады, аннары кызлар битләрен битләренә куештылар да саубуллаштылар. Ишек ябылды, өйдә тып-тын булып калды. Кеше булганда хан кызы да, Дәүран да үзләрен иркенрәк тоталар иде, үзләре генә калгач, нигәдер бербереннә күтәрелеп карарга оялып тордылар. Аннары хан кызы табынны җыештыра башлады, Дәүран аңа булышырга ташланды. Алар сөйләшмәделәр, ризык-нигъмәтләрне ашъяулыкларга төрделәр, куллары-кулга тиеп киткәндә колак очларына кадәр кызарыштылар.

Шуннан соң Назлыгөл түр якка кереп китте, берүзе калган Дәүран гүя күккә ашты, йолдыздан йолдызга сикерде, болыттан болытка күчте. Назлыгөл түр яктан килеп чыкты.

— Өй үзеңнекеме, Дәүран?

— Үземнеке. Үзем салдым. Әмир рөхсәт итте. Киләсеңне белгән булсам, диварларыма аккош сурәтләре төшергән була идем.

Дәүран кызның үзенә таба ымсынып куйганын күрде дә, тегене кулына күтәреп алды һәм зырылдатып әйләндерергә кереште. Озак әйләндерде, ахыр идәнгә утырды. Бераз гына башлары әйләнә иде. Сөйләшмәделәр, күзгә-күз генә караштылар, йөрәкләре сөйләште.

Назлыгөл диварлардагы бизәкләрне карарга тотынды. Матур иде алар. Әйе, бизәкләрне Дәүран үзе төшерде, шул чакта күз алдында гел сөйгәне булды. Сурәтләр бүлмәләргә тансык ямь бирде. Әзер өйне карарга әмир Хаҗи үзе килде. Ул йорт эченә кергәч, бүлмәдән-бүлмәгә йөрде, йөрде дә: «Хәзер өйләнергә да була, күзең төшкән кызың булса, әйтерсең»,— дип чыгып китте. Ә Дәүранның ул хакта уйлап та караганы юк иде, күңелендә гел Назлыгөл, башкаларны ул күрмәде, күрергә дә теләмәде. Ә менә бүген аңа хан кызы үз аягы белән килеп керде. Хыялы тормышка ашты. Анасы дөрес әйткән булып чыга. Түшәктә ятканда: хан кызына өйләнерсең, дигән иде. Фәрештәнең амин дигән минутына туры китереп әйттеме әллә?!

Оста Дәүран ишекне барып бикләде. Иртән иртүк какмый-шакымый кала тарханының килеп керә торган гадәте бар иде. Керми торсын әле. Яңа кала тиз үсә, төрле яктан халык күчеп килә, һәркайсы урын сорый, кала тарханы аларны башта оста Дәүранга җибәрә, өй зурлыгын анык белән килешкәч кенә, тархан теге я бу урынны йорт салучыга бирә. Тарханның җитеп килгән өч кызы бар. Шуларның берсен оста Дәүранга кияүгә бирергә йөри иде. Тархан, остага белдерми генә, өй салучылардан кул очына ришвәт ала. Ул ничә тапкыр инде остага акча тәкъдим итте, әмма Дәүран якын да килмәде. Шуңа күрәмедер, тархан остага килүен ешлатты, хәтта бер тапкыр асрау кыз китергән иде. Дәүран аны алмады, малай булса карар идем дигән булды. Хәзер Назлыгөл: «Йомышчы малаең булырмын»,— дигәч, Дәүран шул хәлне исенә төшерде.

Дәүран сүзсез генә Назлыгөлгә карап утырды. Гүзәл иде хан кызы, шушы гүзәлне йомышчы малай итеп күз алдына китерү кыен иде. Кем ягыннан алып килгәндер бу тамаша гүзәллекне Назлыгөл, иллә Болгарда аңа гашыйк булмаган егет табылмастыр. Күзләре, гүяки, зәңгәр һавадыр, кашлары карлыгач канатыдай кыйгачтыр, алтын төсендәге чәчләрен ике толымга үргән дә, бер толымын күкрәгенә төшергән, башында энҗеләр тезгән калфак, кулында зөбәрҗәт ташлар утырткан беләзек, бармакларында якут ташлы йөзек. Малай булса, боларның берсе дә булмас.

— Мин түр якта йоклармын, Дәүран. Ә сиңа урынны алгы якка җәярмен,— диде хан кызы, күзләрен күтәреп карарга оялып.

Ул сүзсез ризалашты. Ул көтәр, сабыр итәр. Килер бер көн, хан аңа ирек бирер һәм шунда ул аңа өйләнер, никах укытырлар.

# 28

Икенче көнне иртән Дәүран таныш сәүдәгәр кибетендә утыра иде инде. Оста егет, ояла-тартына гына, малайлыкка алган оланга киемсалым сорады. Күпне күргән сәүдәгәр оста егеткә ышанды да, ышанмады да, шул ук вакытта егеткә ышанмаслык та түгел иде. Хан колына малай тоту ярый, тыелмый. Ә ул оста кеше, калада корыласы өйләрнең сызымнарын әүвәл аңа күрсәтәләр.

Дәүран киемнәрнең үзе теләгәннәрен сайлады: түбәтәйне дә ошатты, бишмәт-күлмәкне дә, сырмасын да килештерде. Ләкин хан кызын ышбу сырмадан күз алдына китерә алмый гына йөдәде. Сәүдәгәр итекләрнең бигрәк әйбәтләрен тапты. Җитмәсә, Дәүранның котын алып: «Мондыйларны, беләсең килсә, хан кызлары гына кия,— диде. Аннары Дәүранга: — өйләнергә ниятең юкмы соң, малай тотканчы өйләнүгә ни җитә»,— дигән булды. Дәүран, колакларына кадәр кызарынып, җавап табалмый торды. Ахыр тизрәк киту ягын карады.

— Тукта әле, оста егет, тукта. Телисеңме, үзеңә алиһәдәй кыз табып бирәм, бер кашык балдай инде менә, кабасы да йотасы гына. Мәшәкате булмас, яучы мәшәкатьләрен үз өстемә алам. Беләсенме, кем кызы? Әнә, күрәсеңме, Болакның теге ягындагы яшел түбәле йортны? Кем йорты дип беләсең? Сәүдәгәр Бакыргали йорты. Дүрт кызы бар, дүртесе дә мөлдерәп торалар. Бигрәк тә икенчесе, һай, бирсә бирер икән ходай чибәрлекне бу хатын-кызга? Шуны күрсәм, ике-өч көн йокыдан калам, төшемә кереп интектерә, балакаем. Минем дә кызым бар иде, былтыр вафат булды. И-и еглодым, и-и еглодым инде үзе өчен, балакаем... Кызганыч икән шул, кыз бала, әй кызганыч! Акыллы, сабыр, тыйнак иде үзе. Менә шул кызның бирнәгә дигән сандыгы калды. Курыкма, курыкма, оста, мин аны кыйммәткә бирмәм. Ят кеше түгелсең, әмир остасы. Күз өстендәге каш диярлек. Игелеген күр. Сандыгы-ние белән синеке. Һәй, кем бар анда!— дип кычкырды сәүдәгәр Кәримулла.— Бире килегез әле.

— Нәрсә, бай абзый,— дип йөгереп килеп җитте шактый таза егет.

— Түр якта мәрхүмәмнең сандыгы бардыр, ат җик тә шуны оста өенә илтеп куй. Эленке-салынкы йөрмә, бер аягың монда, бер аягың анда булсын!

— Кирәкмәс иде, Кәримулла агай, яхшы түгел бит. Аннары минем янымда ул хәтле акча да юктыр,— дигән булды Дәүран.

— Акча нигә ул синдәй кешегә, син үзең алтын. Алабайдан аласың булсын, бирерсең. Илдән качып китәргә җыенмыйсыңдыр бит? Юкмы? Әнә Әхмәт тарханның углын табалмыйлар. Урал ягына эремә таш алырга китә дә кораблары-ние белән юкка чыга. Берәүләр урысларга тап булгандыр дип сөйли, икенчеләре юлбасарлар кулына эләккәннәрдер, дигән була. Ә мин уйлыйм, Бәкер атлы бит әле ул, әйе, Бәкер, хатыны алып киткәндер аны. Кая? Бер хода үзе белә.

— Бәкер кайткан,— диде Дәүран.— Чуен коючы Бәкер Шайтан каласында. Атасы әйтте. Монда бит ул. Әмир аны үзе белән алып килгән. Монда алачык ачтырмакчы, Кәримулла агай.

— Һы, шулаймыни, аты коргыры, ни генә сөйләми бу сәүдәгәр халкы. Сүз куертырга дисәң, безгә бир инде аны, оста егет, сәүдәгәрләргә. Бәһасе өч алтын булыр, энем. Сиңа кызгана буламы. Өй салырга сызымнарны кем бирде? Син. Хак анысы, кала бие акчаны каерды каеруын, аның каравы йортымны күр! Болак буенда. Бөтен чит ил кораблары кайда туктый? Шунда килеп куна. Кәттә, кәттә булды йорт, әйтәсеме. Күрерсең менә, оста, Кәримулла агаң әйтте диярсең, тиздән Бөек Кала сәүдәгәрләре бире күчә башлар. Бөек Кала ни шәп булса да, су юлыннан да ераграк, төн илләреннән дә. Ни өчен гарәп-чин, коман, угыз-әрмән агыла дип беләсең бирегә? Монда болгары, ары, урысы

сату итә. Ә алар кулында тиреләрнең затлысы, алтын бәһасе торганнары. Алып җибәр бер кеш тиресе булачак хатыныңа!

— Юк-юк, Кәримулла агай, миңа бернинди тире дә кирәкми.

— Алырсың әле, алырсың. Хатын-кыз ул башта гына барысыннан да канәгать булып яшәгән шикелле кылана. Ә бер синең холкың-фигылең, гадәтең-җаең белеп алдымы, юха еландай ни тели, шуны синнән эшләтә. Әле әнә кеш тиресе кирәкми дисең, өйләнгән генә, кирәгер ул, оста, кирәгер. Әйбер-кара кирәк булса, берәүгә дә барма, үземә кил. Шәйлисендер, миндә барысы да бар. Килә йөр. Тукта әле, тукта! Нигә соң әле үзеңә берни дә алмадың? Тиздән өйләнәм дигән буласың? Өй-каралтылар салуда акыл иясе булсаң да, сату-алу эшендә бик сай йөзәсең икән иң, энем. Өйләнмәгән дип торма. Өйләнерсең. Болын чәчкәсез, ир хатынсыз булмый. Чиләгенә күрә капкачы ясала. Ходай тәгалә аны шулай иткән инде, берсенә таккан, икенчесенекен чапкан. Бергә-бер Хатын-кыз артык икән, моңа хода гаепле түгел, ир-ат сугышта кырыла. Кол мин дип торма, коллыктан да азат итәрләр, капкасына күрә кодасы да булыр. Умартасы барның балы да булыр, ди. Хатын-кызның асылы бал да май гына бит ул.

— Мин китим инде, Кәримулла агай?

— Әйе, бар инде бар, хуш! Беләм, күп сөйләшәм. Сөйләшмәсәм дә кыен. Син әнә гелән авызыңа су капкансың, ә мин ул авыз дигән әгъзаны яба алмый интегәм. Ә хатын-кыз татлы сүзләр ярата, оста. Телең кызганма син аларга. Керпе дә әнә сөйгәнен йомшагым дип ярата, ди, аю исә аппагым, дип. Ни әйткән шагыйрь шул хакта:

Үзең, ходам, мине комнан яраттың,
Оҗмах вә җәннәт белән котырттың.
Янә гөнаһ, язык диеп куркыттың.
Кызлар миңа шәраб вә йөзем улды,
Оҗмахың калдыр үзеңә, йә раббым!—

дигән. Җәннәт инде ул, җәннәт хатын-кыз куеннары, оста. Әллә мәйтәм, шәраб салыйммы үзеңә? Син аны бөтенләй тотмыйсың дамыни? Шәехтән куркасыңмы? Әллә син аларны тотмыйлар дип уйлыйсыңмы! Һай, кем бар анда, чыгарыгыз әле шәраб чүлмәген!

— Кирәкми, Кәримулла агай, кирәкми. Мин киттем.

Дәүран йөгерә-атлый урамга чыкты. Ул өенә йомышчыдан алданрак кайтып җитәргә тиеш иде. Күр әле бу шагыйрьнең сүзләрен, ничек итеп тапкыр әйткән: «Оҗмахың калдыр үзеңә, йә раббым». Чынлап та шулай түгелме соң? Назлыгөлнең килеп керүе булды, гүя күк капусы ачылды. Сарай сәүдәгәре Бикколга әйтергә булыр әле, алып кайтсын китаплар, я булмаса, кәтиб Хафиздан үтенергә, җибәрсен берничә җыру дәфтәре. Кәтиб Хафиз төннәр буена китап укып утыра, диләр иде аңа. Дәүран бер тапкыр аңардан сорарга да иткән иде, анасы ачуланыр дип курыкты. Укый-укый да тик торганда елап җибәрә икән. Назлыгөл дә белә микән шагыйрьнең бу юлларын? Сәүдәгәр белсен дә, хан кызы белмәсен, ди. Дәүранга уку такы-токы гына тиде, анасы аны кәтиб Хафизга төннәрен генә китерер иде, кеше күрмәгәндә генә. Сабакны кәтиб Хафиздан шәм яктысында алды Дәүран.

Хәзер ул тик бернәрсәне күз алдына китерә алмый иде: никахны кем укыр? Кем кол егеткә хан кызын никахлаштырыр? Моңа бер шәех тә бармас, чөнки хан аны моның өчен ат койрыгына тактырыр, тереләй җиргә күмдерер.

Тимерче Әхмәт биргән йозакны ачканда янә әнә шундый уй килде оста Алпар угланы Дәүран башына. Ләкин эчтәге: «Дәүран, синме бу!» дигән тавышны ишетте дә барысын да онытты, барысы да астыөскә килде. Ишекне ачты һәм бусагада яшьле күзләре белән үзенә карап торган Назлыгөлне күрде дә, ни кылырга белми, кызның аягына төште.

Вәзир Камай Владимир кенәзе Андрей Боголюбка буш кул белән генә барырга теләмәде. Сәлим хан киңәше белән ул күптән түгел ислам диненә күчкән Апанайны да алырга булды. Апанай иң бай нәселдән — күчтемлеләрдән. Абыйсы Яким моннан өч ел элек Апанайны Болгарда — тимерче Әхмәттә калдырып китте. Якимның сәүдәгәрнең бер Бөек Калада гына җиде-сигез кибете бар иде. Апанай Яким абыйсының кибетләрендә дә күз-колак булды, шул ук вакытта Әхмәттә тимер эшләренә дә өйрәнде. Апанайның әле монда, әле тегендә күренүенә шаккатмадылар, шулай да вәзир Камай күптән түгел генә муенына тавык тәпие тагып йөргән, аннары ислам диненә күчкәч, тәресен йолкып алып елгага ташлаган Апанайга шикләнебрәк карый иде. Яким Күчтем Болгар сәүдәгәрләре белән тыгыз элемтәдә тора — товар ишләре. Товар ишләре арасына хәтта хан һәм кенәзләр дә керә алмый иде. Товар ишләре сугыш теләми, угланнарын орышка җибәрмәскә тырыша. Кыскасы, сәүдәгәр халкы өчен сугыш яман нәрсә. Товар ишләре арасында ханнар да, вәзирләр дә, кенәзләр дә аңлап бетерә алмаган дуслык, бердәмлек бар иде. Сәере шул иде: товар ишләре төрлесе төрле дингә табына, иллә шуңа да карамастан, алар бер-берсен яклый иде. Муеныннан алтын тәресен йоклаганда да салмаган Яким, энесе Апанай мөселман диненә күчкәч, күтәрелеп бәрелмәде, «син — бусурман» дип акырынмады, кул селтәп китте дә барды. Вәзир Камай исә урыс Апанайның ихластан ислам диненә күчүенә ышанып җитми иде. Гомумән, хан һәм кенәзләр кебек, ул да сәүдәгәрләрне өнәп бетерми, гәрчә ил-дәүләт байлыгы күп очракта алардан булуын аңласа да. Сәүдәгәрләр арасында Болгарга килеп чалма кигән, Владимиргә барып тәре таккан кешеләрне дә күргәне бар иде аның. Тора-бара вәзир Камай үзе дә бер нәрсәгә инанды: хикмәт диниманда түгел, вәгъдәсезлектә икән.

Вәгъдәсезләрне яратмый иде Камай, гәрчә үзе бу өлкәдә бик үк тугры булмаса да. Апанайны тылмач итәр өчен генә алмады, үзе дә урыс телен ару гына сукалый иде. Ул аны башка уй белән ияртте. Кенәз янына нинди дә булса сәбәп табып керү кирәк иде, керде исә сүз катырга тиеш иде. Кенәз Болгарда булган яман хәбәрне ишеткәндер инде. Баштан ук аңардан: «Епископ Габбасны кем үтерде?»— дип сорар. Эшне бик үк катмарландырмыйча, вәзир епископны үтерүчеләр һәм чиркәүгә ут салучылар арасында Апанай да булды, диячәк. Ул гынамы, Күчтем Апанай, ягъни Андрей Боголюбның каенише, ислам динен кабул итте, диячәк. Чиркәүгә ут салуга һәм епископны үтерүгә ышанмаса да, Апанайның мөселман диненә күчүенә ышаначак иде кенәз, чөнки вәзир Камай аның муенында тәресе юклыгын белә. Кенәз моны тикшерергә кушар. Һәм ул әйткән хәл расланса, бөтен ачуын Апанайга юнәлтер, ә шаех мөридләре бер яктарак калыр. Изгелек — игелексез булмый, кенәз Болгар ханы Сәлимне кичерер, үч алам дип йөрмәс. Вәзир Камай белә иде, кайчандыр Юрий Долгорук Яким белән Апанайның атасы олуг сәүдәгәр, Мәскәү атлы утары булган Степан Күчтемне үтерә, кызы Улитаны Андрей угланына кияүгә ала. Иллә Улита кенәзне яратмый. Кем инде атасын үтергән нәселне яратсын, ди! Шуннан соң Андрей Боголюб Сәлим ханның сеңлесе Рокыяга өйләнә. Олыгаеп киткәч булса да, Кияүкала тәхетенә барып утырган Юрий Долгорук угланын Суздальга кайтарып җибәрә. Андрей кенәз Суздальга тукталмый, башкаласы итеп Владимирне сайлый һәм анда чиркәү өстенә чиркәү күтәрә башлый. 1157 ел май аеның унбишенче төнендә кияүкалалылар Долгорукны агулап үтерәләр. Олуг кенәз хокукын чиркәү әһелләре дә, бай сәүдәгәрләр дә Андрей Боголюбка йөклиләр. Кенәз Кияүкала тәхетенә ашыкмый, Владимирдә кала. Монда епископ итеп Константинополь тарафыннан расланмаган Феодорны күтәрә. Иллә кенәз күпме генә үзенең яраткан епископын якламасын, 1169 елда епископ Феодорны

Кияүкалага чакырып алалар һәм үтерәләр. Чиркәү әһелләре халыкны, байларны кенәзгә каршы котырта. Кенәзгә митрополиттан баш тартырга туры килә. Шуннан күп тә үтми, Болгар епископы Габбасны үтерәләр һәм чиркәүгә ут төртәләр. Әйе, ачуы чыгарлык була Андрей Боголюбның. Һәм бар нәрсәдән дә хәбәрдар вәзир Камай кенәздән бер дә юкка гына курыкмый, әлбәттә. Иң әүвәл кенәзнең Камайны кабул итмәве бар иде. Борчылырлык та, уйланырлык та иде вәзиргә. Сәлим хан аңа кисәтеп куйды: ничек кенә булса да, күңелсез хәлне йомып калырга, кенәзгә бүләкләрне кызганмаска. «Сакалың белән җир себер, мәгәр кенәзне юатмыйча кайтма!»— диде аңа хан. Сәлим ханның урыс кенәзләре белән бер дә сугышасы килми иде. Һәр сугыш саен ул ниндидер каласын, ниндидер биләмәсен югалтты. 1164 елда, мәсәлән, кенәзнең атасы Долгорук Болгарның сәүдә каласын тартып алды. Хак анысы, Базар Кала бер аныкы гына түгел иде, азмы-күпме ясакны Болгар тарханнары җыя иде. Хәзер әнә кенәз кешеләре җыя. Сәлим хан Владимирдәге хәлләрне белеп торырга тели иде, ә ул хәбәрне бары тик вәзир Камай гына алып кайта ала. Вәзир дүрткә ярылыр, әмма үз дигәненә ирешер. Камайның әле булса хәтерендә, 1172 елда кенәз, сәүдә каласын бөтенләй үзендә калдыру нияте белән, Болгарга яу оештыра. Иллә соңгы мәлдә генә үзе килми. Угланы Мстислав дружинасы белән Городец каласында атасын көтеп тора-тора да воевода Борис Ждислав белән Болгарга яу кузгала. Алар Болгар җирләренә үтеп, алты авылны, берничә утарны талыйлар һәм яндыралар. Гадәти булмаган кышкы көннәрдә яу килә владимирлеләр. Аларның яу килүен ишеткәч, болгарлар алты мең тирәсе гаскәр җыеп, дошманны куа чыгалар. Владимирлеләр тәртипсез рәвештә кача башлый. Сура елгасын чыкканда кенәз Мстиславның аты боз астына китә, көч-хәл белән котылып калган яшь кенәз кайтып озак та тормый вафат була, күп тә үтми Андрей кенәзнең икенче угланы Изяслав та дөнья куя. Олуг кенәз янында бердәнбер угланы — Георгий кала. Вәзир Камай белә: уңышсыз яуның башы кенәзбикә Рокыяда һәм бай сәүдәгәрләрдә. Рокыя да, байлар да Болгар белән сугышырга теләми, олуг кенәзнең угланына ярдәмгә килмәве дә шуннан була. Моның өстенә 1173 елда Галич кенәзлегендә булган яман хәбәр Владимиргә — кенәзгә ирешә. Ә анда мондый хәлләр була. Китан кенәзнең апасы Ольга, угланын ала да, ире кенәз Ярославтан китеп бара. Сәбәбе болай була: кенәзнең сөяркәсе Анастасия угыл таба. Кенәз уйнаштан туган углын ярата төшә. Галич байлары бу хәлгә баш күтәрәләр, кенәзнең сөяркәсе Анастасияне утта яндыралар, углын төрмәгә ябалар, кенәзне кулга алалар, аның дружинасында хезмәт иткән кыпчакларны тураклап ташлыйлар. Иленнән качып киткән кенәзбикә Ольганы шуннан соң гына чакырып кайтаралар. Ольга — кенәз Андрей Боголюбның апасы. Узына башлаган галичлыларны, кияүкалалыларны акылга утыртасы иде дә бит, кул җитми. Атасы аларны тату яшәтер иде. Баш имәгән кенәзләрнең кайсына яу чапты, кайсы белән тәре үбеп килеште, кайсының башын кистерде. Ә менә атасы Юрий Долгорук урынына олуг кенәз булып калган Андрей Боголюб һични кылмый. Владимирдә мөстәкыйль митрополит булдыру нияте барып чыкмады, ул сайлап куйган һәм үз белдеге белән епископ дәрәҗәсенә ирештергән Феодорны төп йорттагы дин әһелләре Кияүкалага чакырып алып җәзалап үтерделәр. Ясак җыярга дип җибәргән вәкиле Михәйнең сакалын кыркып, корсагы җиргә тияр дәрәҗәгә җиткән карт биягә атландырып, мыскыл итеп кайтарып җибәрәләр. Әнә шуларның барысыннан да соң Боголюб кенәз тәвәккәлли: 1174 елда ата-бабаларыннан калган төп йортны янә кулга алу нияте белән заманына карата тиңе булмаган гаскәр белән Кияүкалага яу кузгала. Иллә юл өстендә Вышгород каласын да ала алмыйча, шактый гаскәрен югалтып, кире борылырга мәҗбүр була. Яуда катнашкан байлар, дин әһелләре бу хәлгә канәгатьсезлек белдерә. Әмма кенәз берәүне дә тыңламый, берәү белән дә сөйләшми.

Владимиргә кайтуга, ул туры утарына китә, хәтта Болгар илчеләрен кабул итүдән дә баш тарта. Болгар илчеләрен кенәзнең киңәшчесе кабул итә. Менә шунда инде аңа вәзир Камай Яким бай энесе Апанайның ислам диненә күчүе хакында әйтә. Бу хәбәрне шундук кенәзгә җиткерәләр. Яудан кәефе кырылып кайткан Андрей Апанайны чиркәү каршындагы мәйданда дар агачына асарга куша. Кушып кына калмый, якынына бу хакта фәрман язып бирә. Фәрманны Яким бай кияве Петрга күрсәтteләр. Апанайны иртәнгә кадәр төрмәгә ябып куялар.

Бу көн Яким кияве Петрның туган көне була. Ул агай-эне байлары, кенәз куштаннарын үз утарына кунакка чакырган була. Петр утары кенәз утарына терәлеп тора диярлек. Егермеләп бай вә куштан кичен Петр утарына җыела. Алар арасында кенәзнең келәтчесе Анбал, бабасы Яким дә була. Ашап-эчеп, бераз төшереп алгач, байларны өстерү нияте белән, утар хуҗасы Петр:

— Байлар, Андрей кенәз узынды,— дип сүз башлый.— Бабай,— ди Петр һәм Яким бабасын чупылдатып үбеп ала.— Бабай, атаңның утарын кем тартып алды? Кем башына җитте Степан Кучкинның? Шулар, шулар. Юрий Долгорук. Атаңны үтерү генә түгел, утарына кирмән сала башлады. Хода бар ул, аны да аллаһы тәгалә җыйды. Инде хәзер монысы кайнагам Апанайны астырмакчы. Кайчанга кадәр...

— Утыр! Утыр әле, кияү,— дип, Яким сикереп тора.— Хак әйтәсең, кияү, атабыз Степанның утарын Юрий кенәз тартып алды, угланы Андрей аны кайтарды. Ни өчен? Улита хакына. Улита белән Андрей тормый. Болгардан мөселманны алып кайтты. Хәзер әнә энем Апанайның башына җитмәкче. Анбал, әйт әле, ни диде кенәз Апанай хакында?

— Бөтен халык алдында дар агачына астырырга,— диде.

— Ишеттегезме, ишеттегезме, байлар, кая таба бара эшләр? Кенәз иртәгә минем энемне астырыр, аннары берәм-берәм үзебезне. Ни кырып кайтты ул яудан?! Барыбыздан да гаскәр өчен акча җыйды лабаса. Кем кием-корал, ат-ияр алып бирде кенәзгә?! Без түгелме?! Тагын ни диде, Анбал, кенәз? Ни дип янады байларга?..

— Мин аларга күрмәгәннәрен күрсәтермен әле, диде.

— Күрдегезме, күрдегезме, инандыгызмы инде, байлар? Без соң, без кемнән ким?

— Анбал, ачкычлар үзең беләнме?— дип күтәрелә Петр.

— Ачкычлар һәрвакыт үзем белән,— ди Анбал.

— Кенәз янында кемнәр бар?

— Пажы Прокопий, берничә сакчы. Кенәзбикә килмәде, угланы Владимирдә калды.

— Петр, кияү! — дип кузгала Яким.— Уең дөрес булса?

— Кенәз яшәргә тиеш түгел. Галичлар кенәзне төрмәгә япканнар, кияүкалалылар Юрийны нишләтте?..

— Агулап үтерде.

— Без, без соң?!

Байлар барысы да беравыздан:

— Үтерәбез!— дип кычкыра һәм куркынып күзгә-күз карашып алалар.

— Сакчыларын үзем юк итәм,— ди Петр.— Корал барыгызга да житәр.

— Кияү хаклы, без аны үлтермәсәк, ул безне берәм-берәм, берәм-берәм,— ди Яким һәм беренче булып урыныннан кузгала.

— Халык ни әйтер, халык, җәмәгать,— дип күтәрелә байларның берсе.— Кенәз ич ул, кенәз!

— Халык ул — кара сарык! Без, без байлар илгә ия, кенәзләр түгел! Кем байлыгына гаскәр җыя кенәз! Синең байлыгыңа түгелме?!

— Сабыр, сабыр итик, җәмәгать. Башта уйлашыйк.

— Без уйлашканчы, ул уйласа, иртәгә үк безнең башларны кистерә башласа?!— дип күтәрелә бериш бай.

— Мин шуны беләм, байлар,— ди Яким.— Андрей кенәз яшәмәскә тиеш. Йә ул, йә без. Новгородлылар кебек, кенәзне без үзебез сайларга куярга тиешбез! Үзебез!

— Хак, дөрес әйттең, Яким бай, дөрес! Әйдәгез! Якимушка, без сиңа һәрчак ышана идек. Анбал, Анбал, бир ачкычларны.

Анбал теләр-теләмәс кенә ачкычларны Петрга бирә. Байлар ябырылып, аскы якка төшә, һәммәсе дә коралллана.

— Үлем, үлем Андрей кенәзгә!

Кенәз утары капкасында торучы сакчыларны Петр белән Анбал чабып ташлый. Эчке якта торучы кенәз пажы Прокопийны эләктереп, кул-аягын бәйләп, авызын мүкләп чоланга ябалар. Кенәзнең йокы бүлмәсенә юл ачык. Әүвәл Анбал кереп кенәзнең кылычын алып чыга. Андрей кенәз киң җилкәле, һәр корал белән дә гаять оста орыша, ә кенәзне үтерергә килүчеләрнең берсенең дә үләсе килми. Анбал сак кына икенче катка күтәрелә, иллә коты алынып яңадан төшә. Яким бай кияве Петр аны селкеп җибәрә дә үзе күтәрелә. Аңа байлар ияре. Икенче катка күтәрелгәч, кенәзнең йокы бүлмәсенә кадәр ун-унбиш адым тар ара, шуннан йокы бүлмәсенә юнәләләр. Бүлмә бикле. Петр Прокопий тавышы белән кенәзгә: «Олуг кенәз, мин бу, мин», ди. Иллә кенәз Петрның тавышын танып ала. «Прокопий, син түгел бит, кем анда?!» дип дәшә. Башка чара калмый, байлар ишекне бәреп керәләр һәм кенәзгә ташланалар. беренче булып килеп кергән Петрны Андрей бөтереп алып астына сала, күкрәгенә тезен кадый, шул чак аңа чәнчәләр, сугалар. Кемнең кулында ни була, шуның белән кенәзгә кадыйлар һәм теге тынып калгач, үлгәндер инде, дип түбән төшәләр. Җинаять кылган байлар бер-берсенә мактана башлый, ишегалдына чыгалар, болдырдагы Прокопийны кылыч белән чабалар. Шул чак берсе кенәзнең баскычтан төшеп килүен күрә. Караңгы төн, аңа ышанмыйлар. Икенче мәлдә инде баскычта берәү дә булмый. Ә теге «күрдем инде, күрдем», дип исбатларга тотына. Кенәзне эзли башлыйлар, ике-өч кеше йокы бүлмәсенә йөгереп менеп төшә, анда һичбер җан иясе юк. Байлар куркуга кала. Йорт бетереп кенәзне эзләргә керешәләр. Ахырда шәм алып киләләр, кан эзе буенча баралар. Андрей ерак китмәгән була, сакчыларны дәшәргә дип, алгы өйгә таба атлаган, әмма барып җитә алмаган, койма буена утырган да кемнедер дәшә икән. Ут тотып килгән байларны күргәч, ул аякка баса, алдан килгән келәтчесе Анбалга:

— Син — кабәхәт!— диярга өлгерә. Икенче мәлдә инде Яким кияве Петр аның кулын чабып өзә. Мизгел эчендә байлар исләренә килә һәм кенәзгә ташланалар. Бу юлы инде аның кадалмаган җире калмый...

Бу хакта вәзир Камай олуг хан Сәлимгә ишеткән-белгәннәренең барысын да язып җибәрде. Үзе, Андрей кенәзнең үтерелүен ишетү белән, икенче көнне үк Болгарга юл чыга һәм атна дигәндә кайтып житә. Чөнки кенәз үтерелгәч, биләмәләрендәге байлары, ярлы-ябагасы умарта күче кебек гөжли башлый.

Бу хәбәрне беренче булып житкергән азатка Сәлим хан билкаешын салып бирде. Мәгәр соңыннан үкенеп куйды. Ни өчен бирде ул каешны? Начармы, яхшымы, Китан кенәз аның кияве иде, угланы яу килсә дә, кенәз үзе бер тапкыр да Болгар җиренә яу чапмады. Боголюбтан соң нинди кенәз килә бит әле. Азатка бил каешын бирү түгел, тотып ярырга иде үзен шул каеш белән. Ләкин кылынасы кылынган иде инде. Ә бит уйланырлык явызлык ясаган Владимир байлары. Болгарда да байлар житәрлек, көннәрдән бер көнне аларның да ханга кул күтәрүләре бар иде. Бүген кенәзне үтерсәләр, иртәгә ханны мөмкин. Яман хәбәр яманлык тудырыр, ди.

Сәлим хан тәхетеннән купты, ишекле-түрле йөренергә керешгә. Шунда бусагабашы керде, ачуы чыккан Сәлим хан аңа:

— Югал күз алдымнан!— дип җикерде.

Уйлана торгач, Сәлим ханны кенәзнең үтерелүе куандырмады гына

түгел, тәмам кайгыга сабыштырды. Аның да хәлләре шәптән түгел икән бит. Башта угланы әмир Хаҗи канын кайнатты, аерылып чыга, мөстәкыйль тормыш кора, имеш, аннары кызын урладылар, аның да ни аты, ни хәбәре юктыр. Җитмәсә, энесе Мөхәммәтгалимбәк ишләре белән чик буйларында күренгәли башлаган. Бер кыйналу җитмәгән микәнни? Моның өстенә, угланы әмир Хаҗи башкаласы Кашанны ташлап, илгаиләсе белән яңа кала Казанга күчеп киткән. Хәзер әнә үзенә гаскәр җыя икән, дип җиткерделәр. Гаскәрне җыйсын, сакланганны саклармын, дигән аллаһы тәгалә, иллә нигә акча суктырырга? Бу мин сиңа буйсынмыйм, үземә бер Ага-базар ачам дигән сүземе!? Менә монысы инде бөтенләй ошап җитми иде Сәлим ханга. Ахыр килеп Шайтан каласы да, борынгы Сувар да угланы кулында. Яңа Казанның да торабара олы сәүдә үзәгенә әверелеп китүе бар иде.

Сәлим хан тәхетенә утырды, вәзир Камай җибәргән язманы янә бер тапкыр укып чыкты. Вәзир ханга барысын да тәфсилләп язган иде. Китан кенәзнең үтерелү мәлләрен укыганда Сәлим ханның аркасы чымыр-чымыр килде. Күр инде бу байларны, кенәз кадәр кенәзгә кул күтәргәннәр. Рокыя кая барыр?.. Аңа бәйләнеп тә маташканнар икән. Имеш, кенәзнең угланы Мстислав Болгарга яу килгәндә анасы аны җибәрмәскә теләгән, ул гынамы, ирен җибәрми алып калган, шуннан Владимирлеләр җиңелеп, качып китәргә мәҗбүр булганнар. Һәм иң хәтәре — бу гайбәтне дин әһелләре тарата икән. Чөнки төрки Болгарда чиркәүгә ут салдылар, епископны үтерделәр.

Сәлим ханның кәефе бозылды, ул җиз кыңгыравын шалтыратты.

— Бусагабаш, ханбикәне дәш!

Бикәсе Зөбәрҗәт килеп кергәч, хан аңа янәшәсеннән урын күрсәтте.

— Ни булды, ханым?— диде ханбикә утырыр-утырмас ук.— Әллә Назлыгөл хакында берәр хәбәр бармы?

Менә ул ханбикә һәрвакыт шулай, килеп керер дә йомшак, ягымлы тавышы белән: «Ни булды, ханым?»— дияр. Ә бит хатын-кызның ягымлы тавышы да кайчак ир-атны тынычландыра икән. Элегрәк ханбикәсенең шулай йомшак итеп дәшүеннән Сәлим ханның җаннары эреп китәр иде. Хәер, ханбикә хәзер дә кимен куймый куюын, әмма картлык үзенекен итә икән шул, соңгы вакытта бикәсеннән дә ягымлы тавышлар ишетми башлады хан.

— Кергән саен шулай сорамасаң иде, ханбикә,— диде ул.

Үпкәләмәде дә кебек ханбикә, ачуланмады да, үртәлүен дә сиздермәде шикелле, ә менә кисәк кара коелды.

— Ханым,— диде дә тынып калды. Ханбикә күтәрелеп ханга карады һәм ир йөзендә кырыслык күреп, хәтта каңгырып калу сыман нәрсә шәйләп, ханның кулына кагылып алды. Үз итеп елмайды, мәчене сыйпагандай итеп:— Әллә нигә ачулысың кебек, ханиям,— диде.

— Булырсың ачулы,— диде хан.— Боголюб кенәзне үлтергәннәр.

Ханбикә «аһ» итте дә ачкан авызын яба алмый торды.

— И-и ходаем, кем, нигә?

— Нигә-нигә,— диде Сәлим хан урынында борсаланып.— Байларга ярамаган. Юрий кенәз, Әюп хан кияве, кайчандыр Чтапан Күчтемне үлтергән иде бит, шуларның токымы, ди. Яким һәм аның кияве Петр. Ә безнең Апанайны төрмәгә япканнар, ди. Мөселман диненә күчкән өчен. Иртән астырам, дип янаган кенәз. Ә төнлә белән үз башына җиткәннәр.

— Йә аллам, йә ходаем, ниндәен явыз кешеләр бар. Ничек аларны җир йотмый, ничек аяз көндә яшен сукмый!

— Нишлисең, ханбикә, тәкъдире шуннан булгандыр. Мине менә әмир углан, Хаҗи угланым борчый! Дәшми-нитми генә башкаласын Яңа Казанга күчергән, ил-гаиләсен дә анда алган.

— Каланы син салдырдың ич, ханиям, син! Нигезенә оныгымны күмдердең! — Ханбикә ачулыгы белән йөзен каплады, шыңшый башлады.— Син дә явыз, вәзирең дә, барыгыз да.

— Житмәсме, ханбикә! Мин аңарга оныгымны кала нигезенә кү мәргә дип фәрман бирмәдем. Аннары вәзир Исхак җәзасын алды, мәрхүм инде...

— Мәрхүм,— диде Ханбикә үкси-үкси.— Мәрхүм. Явызлык явызлык китерә. Вәзир Исхак исән булса, углан бер дә яңа калага күчәм дип тормас иде. Усал иде вәзирең, мәгәр гадел вә акыллы усал иде. Ә синең Камаең, әйтсәм әйтим...

— Алай димә, ханбикә. Ульдимирдәге хәбәрләрне энәсеннән-җебенә тезеп ул алып кайтты. Сөенче җиткергән азатына бил каешым салып бирдем...

— Нигә соң бер җайдан чапаныңны да салып бирмәдең?!

— Каешы өчен дә үкенеп утырам әле. Аркасын камчы белән каезлыйсы булган да бит ул яман хәбәрне җиткергән азатның...

— Әнә-әнә, син дә вәзир Камаең кебек фикер йөртә башладың. Әле бер төрле сөйли, әле икенче төрле. Сүзеңнең бер дә аты-җәбе юктыр, ханиям. Кенәз Боголюбны үлтергәннәр икән, кайгысын уртаклаш, кеше җибәр.

— Кем янына, кемне?

— Кем булыр дип беләсең Владимирдәге олуг кенәз?

— Бер хода белә. Миңа калса, Михәй, я Всеволод булыр.

— Михәй була күрмәсен диген. Всеволод безнең кияү... Владимир сәүдәгәрләре арасында танышларың булса, җибәр Всеволодка вәзиреңне. Котлат үзен!

— Менә анысы кирәкмәстер, ханбикә. Минем үз кайгым үземә бик җиткән. Башта үз угланым әмир Хаҗи белән араны өзим әле, ханбикә, аннары күз күрер. Михәйме утырыр Владимир тәхетенә, Всеволодмы — анысы безнең кулда түгел. Безнең кулдагысы — Яңа Казан...

— Яңа Казанны үзең салдырдың, синеке ул, ханиям. Углан атасына каршы төшмәс, килешер. Гали оланны тәхетенә утыртырга иткән идең, язмаган булып чыкты. Менә хәзер бар да Илһам угланның Булатын Яңа Калага әмир итеп утырт та кайт. Угланың Хаҗи Кашанына кайтып китсен.

— Әйбәт фикер бу, ханбикә, әйбәт. Һе, шулай итми дә булмастыр. Җаек буена ямчы җибәрәм дә...

— Кеше җибәрергә ашыкма, ханиям. Башта әмир Хаҗи угланың янына барып кайт. Үзең белән гаскәр ал, угланың кадереңне белә төшәр.

— Күр инде, күр, ханбикә, әйтер сүзләремне тел очында гына тотасың икән ләбаса! Үзем дә шулай уйлап тора идем. Барырга угланга, иллә гаскәр белән барырга...

— Ханиям, сиңа бер йомышым бар иде. Бөек Калага Саксиннан әдип Габделгаләү килгән. Сарайга дәшәсе иде үзен, игелекле кеше, диләр. Оланнарга да сабак бирер иде.

«Һәй, хәйләкәрсең дә соң, ханбикә,— дип уйлады Сәлим хан.— Габделгаләү шагыйрь ярлы-ябагага җырын җырлый. Хан вә әмирләр аңа ят. Адәм җаенда торган әдип булса, мин аны әллә кайчан сараема алдырткан булыр идем. Кәтиб Хафиз аны миннән сарайга китерик дип, былтыр ук сораган иде инде. Хәзер ханбикә үтенә. Әллә соң килсенме? Оланнарга да сабак бирер. Яман сөйләсә, күз күрер. Данга ия шагыйрь, исеме-аты бар. Бәлкем сарайга килгәч, хан җырын җырлый башлар? Кәтиб Хафиздан башка Сәлим хан бер генә әдипне дә яратмады. Шул шагыйрь әйткән бугай, Габделгаләү: «Эзләмә, хан, ерактан алтын-таш, аяк астында ятадыр асылташ...» Шәп әйткән, килешле һәм тапкыр.

— Габделгаләү әдип бирәдәмени, ханбикә? Бирәдә булса, кәтиб Хафизга әйт, чакырсын сарайга үзен. Мин разыймындыр...

Хан авызыннан бу сүзләрне ишеткәч, Зөбәрҗәт елмаеп куйды. Хәтерендә әле, кайчандыр Габделгаләү турында сүз кузгаткач, «мин исән

чакта ул башбирмәснең сарайда эзе дә булмас», дигән иде. Мәгәр хан бүген бөтенләй башкача уйлый иде.

— Минем аны оланнарга сабак бирү өчен генә сарайга китертәсем килми, хан. Шагыйрь Назлыгөлебезнең кайда икәнен белә дип әйтеп әйттеләр. Чынмы бу хәл, ялганмы, белмим, әмма ишеттергәннәре шул булды.

Бусы ханбикәнең чираттагы хәйләсе иде. Каян белсен соң инде Саксин каласында яшәүче кеше ул хәлләрне? Сәлим хан кул гына селтәде, хәтта ханбикәдән бу хакта кайтарып та сорамады.

— Ә мин кызыбыз Назлыгөлне энем Мөхәммәтгалимбәк урлаган дип уйлыйм, ханбикә. Ул әле һаман Болгар тәхете турында хыяллана, ди. Белми микәнни, бахыр, тәхет абыйсы кулында түгел, алла кулында, мин ышбу тәхеткә аллаһы тәгалә тарафыннан утыртылган кеше...

Зөбәрҗәт ханбикә ханның бу сүзләренә елмаеп кына куйды. Хан Сәлим шаех Игәнәй җырын җырлый иде. Тегесе котырта шулай дип, монысы котыра. Иллә ханбикә бу хакта ханга беркайчан да әйтмәячәк. Нигә кирәк, аннан ни үзгәрер?

— Мин дә ул хакта ишеткән идем, ханиям. Сәүдәгәрләр җиткерде. Әмма ул халыкка ышансаң... Энең Мөхәммәтгалимбәк Болгарны яуларга кәттә гаскәр белән килергә җыена, имеш. Янтак хан картайган, угланнарында өмет юк икән, кайсы-кая таралып беткәннәр. Ә менә кияве Мөхәммәтгалимбәк бик тә тырыша икән инде бабасына ярарга...

— Имеш-мимешләр күп инде ул, ханбикә. Баян баһадир әнә Яңа Казанда Бачман баһадир сеңлесе Зәйтүнәне күрдем дип бара.

— Шуңа исең киттеме, ханиям? Акбикә бит инде күптән Яңа Казанда, ә Зәйтүнәне калдыра буламы бикә, ул бит аны үз кызы кебек күрә.

— Итәк тутырып бала тапкан булса, кеше баласы өчен алай кайгырмас иде. Ике бала тапты да...

— Менә-менә, орыш әле шул киленеңне, орыш. Юкса, торасың да Акбикәне мактыйсың, торасың да аны телгә аласың. Кая ул Мәрьямбикә киленең турында сүз кату, аллам сакласын. Шул киленеңнән куркып, угланы Җәббарны алмый тордың. Угланы үсте, балигъ булды. Кем итмәкче соң Акбикә киленең аны?!

— Илче итәрмен, ханбикә. Бүген-иртәгә вәзир Камай кайтып җитә, Яңа Казанга кузгалабыз, шунда баргач, барысын да җайлармын. Хәтәре ул түгел, ханбикә, хәтәре башкада. Шымчыларым җиткерде, качкын Җик Мәргән Бачман баһадирда йөзбаш булып йөри икән. Менә аның белән ни кылырга?

— Җик Мәргәнгә тимә, ханиям. Аның бер гаебе дә юктыр. Абыйсы Тубыкбай белән бүлешмәгән биләмәләре бар икән, тик үзара ызгышсыннар. Ә син алар арасына кермә. Син — хан! Олуг хан!

— Бәлкем кызыбыз Назлыгөлне урлаучы да шулдыр әле. Күңелем тыныч түгел.

— Багучы меңбашың Таймас әйттеме бу гайбәтне?

— Ул булса ни, ханбикә?

— Ул исерек башыңа ышанмыйм. Гайбәтче, бушбугаз! Ничә хатыны бар инде ул меңбашыңның? Өч, дүрт?..

— Ә нигә, дүрт икән, дүрткә өйләнсен. Көче бар икән, шәригать хакимнәргә дүрт хатынга өйләнергә куша.

— Дөрес әйтә кәтиб Хафиз: урыс баеса, чиркәү сала, болгар баеса, хатын ала, дип.

— Син алай димә әле, ханбикә. Хатын ул байлык. Бер хатын — бер бала таба. Ике — икене. Дүрт хатының була икән, димәк, дүрт угланың була. Ә инде углан бала ул — азат. Азат кем? Азат ил сакчысы, менә кем!

— Дүрт хатын дүрт углан таба да аннары дүртесе тиң тәхет өчен

кан коешалар, ил бүлешәләр. Кәтиб Хафиз әйтә, ил бүлгән көн күрмәс, ди.

— Илемне бүлдермәс өчен, ханбикә, Яңа Казанга гаскәр белән барырга булдым да инде.

— Туйбикәңнең углын да күреп кайтырсың! — диде ханбикә кинаяләп.

— Әй нигә, аны да күреп кайтырмын. Каланы ул күтәрә, диварларны ул өйдерә. Аннары минем колым ул, ханбикә, колым!

— Назлыгөлгә гашыйк булып йөргән иде ич әле шул колың?

— Хан кызына гашыйк булу гөнаһмы, ханбикә?

— Гөнаһ! Син барысын да күрдең, белдең, дәшмәдең! Балалар күз атыша, ә син елмайдың. Шул вакытта ук шикләнгән идем аны, бала күңеленә агуын салыр, дип. Нишләде Назлыгөлең үсеп-исәйгәч, ике авыз сүз саен шул колның исемен атады. Дәүран бизәк төшергән дә, Дәүран моны эшләгән, Дәүран тегене эшләгән. Әйткәннәр иде аны, теге еланың Туйбикә камнан сихерләткән дип, ышанмаган булган идем.

— Шуннан ни?! Хәзер ышандыңмы?..

— Ышандым. Үзе гүргә керде, йөрәгендә һаман эзе бар. Хәзер әнә угланын яклыйсың. Киявең иткән генә булсаң!

— Ханбикә, ханбикә, ярамас иде алай. Мәрхүм кеше турында дим.

— Бер дә бүтән түгел, шул урлагандыр әле Назлыгөлне!

Бу сүзне ишетүгә, Сәлим хан тәхетеннән күтәрелде, арлы-биле йөренергә кереште. Йөзе кызарган, муен тамырлары бүртенеп чыккан иде.

— Бу ни дигән сүз инде тагын, ханбикә! Сиңа әйтәм, ни дигән сүз?!

— Кол түгел ул, аждаһа, ханиям, аждаһа! Җитмәсә, сарай башына аждаһа сурәте төшереп китте бит әле. Үз сурәтен ясады ул, үз сурәтен! Кызыбыз аңарда, аңарда!

— Бу шигең расланса, мин аны муенына таш бәйләтеп Кабан күленә ташлатам, ишетәсеңме, ханбикә, Кабан күленә! — диде Сәлим хан ярсынып.— Кем бар анда, әй, бусагабаш!

Йөгереп бусагабаш килеп керде.

— Шайтан каласына ямчы җибәр, меңбашы иртәгә-берсекөнгә Бөек Калада булсын, гаскәре белән! Ишеттеңме, гаскәре белән!

— Гаскәр белән кемне алырга барасың анда? Кызыңнымы?

— Йә алла, ишетәселәрем бар икән, әй! Назлыгөл оста Дәүран кулында. Үз акылыңдамы син, ханбикә? Минем Яңа Казанда ышанычлы шымчыларым бар, берсе күрмәсә икенчесе күрер иде, кеше энә түгел, эзләгән кеше энәне дә таба...

— Син әүвәл анда бар, бар!

— Барып та тапмасам?

— Тапмасаң, муеныма таш бәйләп, үзем Кабан күленә ташланырмын.

— Йә алла, ханбикә, тәүбә диген, бу ни дигән сүз инде тагын?!

— Кызыбыз Назлыгөл Яңа Казанда! Ишетәсеңме, Яңа Казанда! — диде ханбикә Зөбәрҗәт һәм, урыныннан купты да, астындагы мендәрен күпертә башлады, ахыр мендәргә капланды да илереп елап җибәрде. Аннары кисәк күтәрелде дә, берсүз әйтми, хан яныннан чыгып китте. Сәлим хан аны туктатмады, үзе өчен ул кыласын кылган иде инде: тиз арада гаскәр белән Яңа Казанга кузгалачак. Сәлим хан Зөбәрҗәт ханбикә сүзләренә ышанмады. Ничек ышанмак кирәк, ничек Назлыгөл Дәүран янында булсын, ди? Тузга язмаганны! Әйе, ул кызының Туйбикә углы Дәүранга тартылуын күрде. Күрде, әмма моңа бик үк исе китмәде. Чибәр вә гүзәл хан кызына егетләрнең сокланып каравында ничек мәкер күрмәк кирәк, ди? Аннары күңел түрендә һаман Туйбикә. Юк, Зөбәрҗәт ханбикә кебек чибәр дә түгел иде ул хатын, ә менә күңелдән китми генә бит! Нигә Туйбикә аннан бала тапмады икән? Ни өчен оста Алпардан соң булса да тапты һәм иң гаҗәбе — нәкъ Зөбәрҗәт белән бер көнне? Шаккатмалы хәл иде. Сәлим хан Туйбикә күз алдына килү белән

йөрәге кысылып куюын тойды. Күр әле, үлгәннәр дә үзәкне өзеп сагындыра икән ләбаса! Янә бер нәрсәне исенә төшерде Сәлим хан, оста Дәүранны күрдеме, күз алдына Туйбикә килер иде. Бәлкем, ул останы нәкъ менә шуның өчен Боголюб кенәзгә биреп җибәрмәгәндер? Югыйсә, соратты, соратты Боголюб оста Алпар углы Дәүранны. Иллә Сәлим хан кенәзгә, бик күп осталарын җибәрсә дә, Дәүранны бирмәде. Оста, үсмер генә булса да, аның үзенә кирәк иде. Аның кулы уйган бизәкләргә хан үзе генә сокланмый иде шул.

Сәлим хан тәхетенә утырды. Шунда утыруы рәхәт иде аңа. Югыйсә, картаеп килә, ә күңеле яшь, тәхете җылы, аерыласы килми җылы урыннан. Ләкин барыбер туры килер. Әллә соң тәхетен онычы Булатка бирсенме? Владимир кенәзе дә канәгать калыр, ни өчен дисәң, Булат Мәрьямбикәдән туган, ә Мәрьямбикә, уйнаштан дөньяга килсә дә, кенәз токымыннан. Булат әнә Җаек кирмәнен тәмам ныгытып җиткергән, ди. Җитмәсә, хан сәүдәгәре Бикколны туктаткан, аннан өлеш алырга хакы булмаса да, алган. Бу хакта ишеткәч, Сәлим хан эчен тота-тота көлгән иде. «Бикколны сәүдә эшеннән бушатырга туры килер,— дип уйлады Сәлим хан.— Җиде-сигез тел белә, илләр гизгән, акыллы адәмнәр сарайга да кирәк».

Шуңа күрә, Сәлим хан Булат онычына ямчысын җибәрде: олан, ялгышма, дәү атаң сәүдәгәрен тиз арада Бөек Калага кайтара күр, диде. Чиркәүгә ут салып, епископ Габбасны үтергәч, Сәлим хан шәех Игәнәйне табып сарайга китерергә боерган иде. Кала бетереп эзләсәләр дә, багучы меңбашның азатлары аны таба алмады. Соңыннан ишеттерделәр, шәех Игәнәй Өргәнечкә чыгып сызган икән. Бу хакта ханга аның ике мөриде килеп әйтте. Мөридләрнең икесенә дә чапан бирергә кушты Сәлим хан, әмма иртәгә үк Бөек Каладан чыгып китүләрен сорады. Яратмый иде ялагайларны. Түрәсен саткан илен дә сатар. Аннары, әләкләгән өчен хан чапан бирде, дип мактанып йөрүләре дә бар иде. Мактанмый торсыннар, шуның өчен Сәлим хан мөридләрне икенче көнне үк меңбаш Таймаска Җаек кирмәненә озатырга кушты. Ә үзе онычы Булатка: «Бу кешеләр дөньяда яшәргә тиеш түгелләр»,— дип хат язды. Калганы онычы кулында иде, ул аңардан «мөридләр белән нишләдең?» дип беркайчан да сорамас. Бикколны ул шәех Игәнәйне табарга һәм алтын биреп булса да үтертергә дип җибәргән иде. Башкара алганмыдыр Биккол бу йөкне, юкмыдыр, янә артык кызыксынмады Сәлим хан, аның кызыксынганы кызы Назлыгөл иде. Кызы Назлыгөлне Хәрәзем шаһы Олуг Мөхәммәт кешеләре урламады микән? Менә шуны белер өчен ул зар-интизар булып сәүдәгәре Бикколны көтә иде. Аннары Биккол онычы Галине дә сорашырга тиеш иде. Ул углан хакында әллә нинди такмазалар сөйлиләр. Гали олан исән-сау, имеш... Йә хода, бу хәл хак булып чыкса, ни кылырга тиеш инде ул?

Ни генә булмасын, Биккол сәүдәгәр аның йомышын үтәгәндер, хода аңа барысын да биргән, берсеннән дә мәхрүм итмәгән. Кирәк икән, ул йомакай да, шомакай да, кирәк икән кара елан булып куеныңа керә, дәрвиш яки галим, шымчы яки вәзир дә ул Биккол сәүдәгәр. Сәлим хан сәүдәгәргә җирен генә түгел, илен дә тапшырып калдыра алыр иде.

Сәлим хан үрелеп кенә мәрмәр өстәлдә яткан дисбесен алды һәм акрын гына шуны тарта башлады. Хикмәтле нәрсә дә соң бу дисбе дигәнең, кулга керүе була, күңелне били дә ала — тынычландыра.

Бусагабаш керде, ханга баш иде.

Сәлим хан гадәттәгечә аңа: «Йә!» димәде, дисбе тартуын дәвам итте.

— Шөһрәтлем, Владимирдән вәзир Камай кайтып төште, Шайтан капкасыннан кереп бара.

Сәлим хан дисбесен чапан кесәсенә койды, акрын гына күтәрелде дә йөренергә керешге. Яратып бетерми иде ул вәзирен. Ләкин хикмәтле хәл, хәзер инде ансыз яши дә алмас кебек иде. Вәзир Камай аңа һәрва-

кыт кирәк. Ансыз — дөнья сансыз. Кая гына, нинди генә йомыш белән бармасын вәзир Камай, судан коры чыга, исән-имин әйләнеп кайта. Ә бит ни йөз юк үзендә, ни гәүдә, ни кыяфәт. Ни белән алдырадыр — бер хода үзе белә иде.

— Ханым! — дип килеп керде вәзир Камай һәм бер тезенә тезләнеп баш иде.

— Әйдүк-әйдүк, вәзирем! Исән-имин әйләнеп кайттыңмы? Хатыңны алдым, сөенчең житте.

— Боголюб кияүне үлтерделәр, ханым.— диде Камай һәм күз яшен чапан чабуы белән сөртеп алгандай итте.— Байлар, ярасының саны юк, диделәр...

— Рокыя, Рокыя кая?..

— Рокыя кенәзбикәне байлар кай тарафкадыр алып киткәннәр. Бер ходай белә кайдалыгын. Гәрчә гаебе булмаса да, кенәзнең беренче хатыны атасы утарына кача. Кенәзне үлтерүчеләр арасында, язган идем инде, Апанай абыйсы Яким дә була. Апанайны зинданга яптылар... Владимирлеләр, Суздәлләр баш күтәрде, ни кылганнарын үзләре дә белми, туган-туган белән орыша, диделәр.

— Тәхеткә кем утырыр дип беләсең?

— Анысы бер ходай кулындадыр, ханиям. Миңа калса, Михәй булыр шикелле. Халык күбрәк аның атын телгә ала.

— Всеволод ни карый?

— Нидер көтә кебек. Белмәссең, кеше күңеле карурмандыр, ханиям.

Сәлим хан жиз кыңгыравын зеңләтте.

— Һәй, кем бар анда! Әче бал китерегез! — дип боерды хан һәм вәзиренә эндәшеп: — Әйдә, әйдә, түрдән уз, утыр яныма,— диде.

Сәлим ханның вәзире белән киңәшәсе бар иде. Заманында Боголюб кенәз дә дин әһелләре белән бәхәскә кергән иде. Үзенә бәйсез яшәргә теләп, Кияүкаладагы митрополитка буйсынмыйча, Владимирдә баш булып маташты. Иллә ни килеп чыкты? Яраткан епископ Феодорны Кияүкалага чакыртып жәзалап үтерделәр, ә Владимиргә епископ жибәрми тордылар. Ахыр әнә үзенең дә башына життеләр. Игәнәй илдән качкач, Сәлим хан да шәех мәсьәләсен үзбаш хәл итте, олуг шәех Пәһлеван Мәхмүт белән киңәшмичә, әлказый Ишкулны шәех итеп куйды. Шәех Игәнәйнең кайбер мөридләре канәгатьсезлек белдерде, иллә эшләр баш күтәрүгә үк барып житмәде. Мәгәр гайбәт-коткысыз да булмады түгел. Ага-Базарда тискәре мөридләр коткы тарата башладылар. Имеш, Сәлим хан кяферлеккә күчәргә йөри икән. Әнә ничек. Кеше авызы мунча тишеге түгел, чүбек тыгып куеп кына булмый. Сәлим хан шымчыларын Ага-Базарга чыгарып жибәрде. Һәр котырткан вә коткы тараткан мөридне сарай зинданына китереп ябарга кушты. Күп тота алмадылар, әмма тотылганнарына жәзаны каты бирде Сәлим хан: кылыч белән туракларып, урманга бүреләргә ташлаттырды. Бөек Калада яшәгән әрмән, рум, урыс халкы ханның бу адымын хуплап каршылады. Ә шәех Игәнәй яклы мөридләр исә идән астына постылар. Анысы менә шәптән түгел иде, халык арасындагы дошманнан идән астындагы дошман яманрак. Сәлим хан христианнар яшәгән урамга үзе барды, чиркәүне торгызырга вәгъдә итте. Христианнар бик шаулаша башлагач, тиздән Владимирдән епископ соратып жибәрермен, диде. Ханның бу сүзләреннән бигрәк тә Баян баһадир канәгать калды. Владимир епископ бирмәсә, тел вә диннәре башка булса да, кайчандыр бер телдә, бер диндә булган Дунай буе болгарларыннан епископ китертергә була, дигән фикер әйтте. Әнә шул хәлдән соң мөселман мәхәлләләрендә: «Сәлим хан христиан диненә күчә икән»,— дигән коткы тарата башладылар.

Табын янында вәзир Камай Владимирдә булган хәлләрне янә бер кат түкми-чәчми сөйләп бирде.

Ахырда Сәлим хан вәзиргә кат-кат, әче бал сала-сала әйтте:

— Вәзирем, сиңа тагын Владимиргә барырга туры килер,— диде.

— Барырмын,— диде Камай.— Барырмын, ханиям. Тик бу юлы бусагабашың Абашны да үзем белән алырмын.

— Анысы нигә тагын? — диде хан.

— Бусагабаш Абаш Ибраһим ханның Всеволодтагы кенәзбикәсе Энҗе белән сарай мәктәбендә бергә укыган иде, онытмагандыр, шаять...

Сәлим хан вәзире белән килешеп баш иде.

— Тик әүвәл бергәләп Яңа Казанга барып кайтырбыз, вәзирем,— диде ул.

## 30

Оста Дәүран өчен хан кызы Назлыгөл гүя күктән төшкән алиһә иде. Ул ышанды да бу хәлгә, ышанмады да, ә инде ышангач, тәмам йокыдан калды. Көн саен мәчеткә намазга барды, коръән хәдисләрен яттан өйрәнде, шуның белән хан мәчетендәге шәех Тәтешне үзенә җәлеп итте. Көннәрдән бер көнне яшь шәех Тәтеш аны туктатты да:

— Оста, син кешеләрдән нидер яшерәсең, йөзеңдә һәрчак борчылу галәмәтләре, ни булды? — дип сорады.

— Мин кол кеше, шәех. Кайчан ирек бирерләр икән, дип борчылам.

— Әйтүләре хак булса, әмир ирек биргән бугай ич инде?

— Әмир бирде, әмма хан колы мин, шәех.

— Хан колы? Сәер, әмир Хаҗи — хан угланыдыр. Аның сиңа ирек бирергә хакы бар. Ләкин синдә, оста, ул кайгы түгел кебек миңа... Әллә бер-бер гүзәлгә гашыйк булдыңмы?

— Булдым, шәех,— диде оста Дәүран.

— Бәхетле чагың, оста, бәхетле чагың. Сине әмир хөрмәт итә, ышбу мәчетне коручы да үзең. Әмир Хаҗига: «Өйләнәм!» дисәң, ул үзе башкода булып барыр. Йә-йә, кем инде ул алла фәрештәсе?

— Сер саклый белү адәм баласы өчен изге нәрсәдер, шәех.

— Йә алла, бик хуп, бик хуп. Әйтер сүзең пешкән җимештәй өлгереп торса, әйт инде аны, әйт...

— Өлгереп җитмәгән шул әле, шәех. Аннары вакыты да ул түгел кебек миңа. Китим инде мин, шәех...

— Сөбханалла, сөбханалла, әйдә, син дигәнчә булсын. Ил күрке — ир сүзедер, җир күрке — ил күгедер. Тик вәгъдәңне онытa күрмә, оста.

— Онытмам, шәех,— диде Дәүран һәм шәехкә баш иде дә китеп барды. Һәрчак затлы яшел чапаннан йөргән, башына шул ук төстәге чалма ураган, аягына кара читек кигән Тәтеш шәех чагыштырмача яшь иде әле, ул Болгарга күптән түгел генә килде һәм үҗәтләнеп үз вазифасын үтәргә кереште. Шәехне әмир Хаҗи үзе соратты. Заманына күрә белекле шәех Бохарада укыган Пәһлеван Мәхмүттән сабак алган иде. Ишан ук булып җитмәсә дә, шуңа омтылган кеше иде. Әнә шул зат оста йөзендә ниндидер гасабилану күрде. Шатлык та, хәсрәт тә түгел иде оста йөзендә, ә ниндидер борчылу, сагыш иде. Бай кызына гашыйк, күрәсең, ә үзе кол кеше. Гашыйк булуы хакында берәүгә дә әйтергә кыймый. Әмма ары таба болай яши алмавына да инанган егетнең чиргә сабышуы бар иде. Мәхәббәт чир бит ул, авыр вә сагышлы чир. Тәтеш шәехкә дә аны татырга туры килде. Өргәнечкә килгәч, ул Олуг Мөхәммәтнең дүртенче хатынына гашыйк булды. Хөрмәткә ия яшь шәех шаһ сараена керә йөрер иде. Шунда күрде алиһәдәй гүзәлне. Күрде дә таң калды. Йә хода, гүзәллек иде хатында. Хатын да аның карашын тойды, күрде һәм яшь шәехнең мәхәббәтен сизеп алды. Мәгәр курыкты бугай, янадан күзенә чалынмас булды. Һай авыр булды да сөйгәненен күрми яшәүләре. Чиргә сабышкан иде инде. Ярый әле җизнәсе Пәһлеван Мәхмүткә чишелде. Җизнәсе аны әйбәтләп тыңлады һәм, бер сүз әйтми, ак кәгазь алып, ул гүзәлнең атын җиде тапкыр язды да җиде бөкләп

Тәтешкә бирде, ятканда баш очына куеп ятырсың, диде. Тамаша лабаса, ул үлепләр гашыйк булган гүзәл алиһә аның түшенә керде. Тормыштагыча, чын булып, ул гынамы, Тәтеш аны сөйде, яратты, илерер дәрәҗәгә җитеп назлады: нечкә биленә кул салды, анадан тума көе янында ятты, акрын гына кочагына керде, хуш исләр килеп торган тәненнән иснерде, канатларын җәйгән аккош кебек, аякларын җәйде һәм ләззәт коесына чумды... Уянгач, бу хәлнең булуына ышанмыйча ятуы, әмма аннары төннәрен рәхәтләнеп йоклавы һәм янә мәхәббәтен төшендә күрүе, янә шул ләззәтле мәлләрнең кабатлануы аны бөтенләй башка итте. Яңадан ул аны эзләмәде, бер күрер өчен сарайга бармады... Останы да ул гүзәл заттан шул шифа белән биздерер...

Оста Дәүран исә шәехкә серен ачмавына куанып бетә алмады. Шәех аның серен белсә, һич булмас димә, икенче көнне үк Бөек Калага ямчы җибәрер. Бу хәлнең ахырын күз алдына китерүе дә хәтәр иде. Ә Сәлим хан аны кызганмас, җәзаның яманын бирер, кызы Назлыгөлне дә кичермәс, таш бастырып үтермәсә дә, игелек күрсәтмәс.

Өенә Назлыгөл килеп кергәннән соң, Дәүран тәмам тынычлыгын югалтты. Назлыгөлгә бу хакта әйтергә базмады. Куркак икәнсең, Дәүран, дип әйтүеннән коты алынды. «Йомышчы малай» белән бер өйдә тора башлагач, гаҗәеп тә сәер тормыш башланды оста Дәүран өчен, гүя өенең караңгы почмакларына кадәр кояш нуры тулган иде. Әмма бу хәл аңа чын да кебек, чын түгел дә кебек иде. Чөнки ничәмә атна инде бер өйдә торалар, икесенең берсе кыеп: «Никахны кем укыр?» дип әйтмәде. Кыз аннан көтте, ә Дәүран исә Тәтеш шәехкә бу турыда ачылырга курыкты. Әнә шулай гомер дигәнең уза торды. Дәүран иртән торды да аннан-моннан капкалап эшкә китте, кич кайтты да... Юк, ул һәркөнне аны сагынып, ашкынып кайтты, кайтты да шәехне бүген никах укырга чакырам дип алгысынды, иллә хан кызы Назлыгөлне малай киемендә күрер иде дә барысы да элеккечә калыр иде. Ул гынамы, Назлыгөлгә туры карау түгел, дәшәргә кыймас иде. Оялу идеме бу, куркуымы, һич аңламады, әмма әйтер сүзен әйтә алмады. Ә Назлыгөл исә бик тырышып, бик тә төгәл итеп йомышчы малай вазифасын башкарды. Дәүран кайтуга һәрчак табыны әзер булыр, җиз таз куеп, җиз комганнан аны юындырыр, бит-кулын сөртергә иңенә сөлгесен салып торыр. Сөйләшү юк, күзләр генә серләшә дә, йөрәкләр генә бергә тибә. Кыскасы, әйтерсең, оста Дәүран өенә ул чынлап та йомышчы малай вазифасын гына үтәргә килгән иде.

Ялгызы гына калган мәлләрдә Дәүран, ата-бабаларның гореф-гадәтләрен дә әйтер идем инде, дип үзен-үзе орышты. Әйтик, ни өчен алар никах укымый гына кавышырга тиеш түгелләр икән? Ләкин шулай дип күпме генә сукранмасын, «йомышчысы» ягына керергә кыймады. Бер уйлаганда, әйтсәң, кеше ышанмастай хәл иде бу, әмма хак — никах укытмыйча, ул аның янына керә алмый иде.

Әнә тулган ай да калыкты, керфекләр дә авырайды, күзләр камаша башлады. Йокларга вакыт, иртә кичтән хәерлерәк, ул аңа тиңсез мәхәббәте хакында иртәнге якта әйтер. Әйтер дә ничек тә булса шәех Тәтешне никах укытырга китерергә тырышыр.

Иллә хода бар икән әле, көннәрдән бер көнне кич кояш баеп, эңгер ингәч, аларның ишекләрен шакыдылар. Сәере шул булды, сорамый-нитми ишекне «йомышчы малай» ачты. Өйгә, шау-гөр килеп, өч азат керде. Дәүран аларны шундук таныды, күрешергә дип каршы китте.

— Саумы-исәнме, Җик Мәргән, саумы-исәнме, Зәйтүнә, саумы-исәнме, Артык! — диде Дәүран һәрберсенең кулын кысып. Аннары Назлыгөлгә таба борылды да: — Табын хәстәрләсәк иде, Назлыгөл,— диде.

Назлыгөл аңа елмаеп карап алды һәм, Зәйтүнәне дә әйдәп, табын әзерләргә, алгы якка кереп китте.

— Әллә безне танымый тордың инде, Дәүран,— диде Җик, дивар кырындагы миндәргә кырын төшеп.

— Таныды,— диде Артык.— Таныды, әмма курка калды. Хан азатлары дип белде. Шулаймы?

— Булды андый хәл, күрү белән кот ботка китте.

Ул арада алгы яктан затлы хатын-кыз киеменнән Зәйтүнә белән Назлыгөл килеп чыктылар. Күрделәр дә егетләр кызларны, ачкан авызларын яба алмый тордылар. Йә хода, гүзәллек иде кызларда. Хан кызын, хан кызын гына күр әле, әле генә гелән малай кебек иде, хатын-кыз киемен киюгә — алиһә дә алиһә, ул да алиһә булды.

— Тә-тә-тә,— дип яткан жиреннән сикереп торды Жик.— Күр әле боларны, оста дим, күр әле, күр. Бер кашык бал белән кабып йотарлык.

— Бик телеңә салышасың, мәргәнем! — диде Зәйтүнә янагандай.

— Бетте, бетте, карлыгачым, кара кашым, әйттем исә кайттым.

Дәуран Назлыгөлне янә хатын-кызлар киемендә күреп, тәмам дивана хәлендә калган иде. Үзе елмая, аннан башка берәүне дә күрми.

— Назлыгөл! — диде ул, очып китәргә житешеп.— Назлыгөлем!

— Житәр, уятыйк моны,— диде Артык.— Әй син, оста, кара әле!

— Тимә син аларга. Тиздән шәех килер...

Бары тик шәех сүзе генә оста Дәуранны айнытып жибәрде.

— Нинди шәех? — диде ул, кисәк туктап. Ул туктауга Назлыгөл аңа килеп сыенды.

— Никах укырга шәех килә,— диде ул пышылдап.— Синең белән миңа никах укырга.

— Безгә дә, безгә дә, хан кызы,— диде Жик Мәргән һәм Зәйтүнәне кулына күтәреп алды да түгәрәкләп йөгереп йөри башлады.

Оста Дәуран кайсы шәех дип сорамады. Кем никах укыса да барыбер түгелмени? Әйтик, аңа шәехнең бер мөриде дә бик житкән. Ләкин кем булса да, аларга никах укучыны Сәлим хан дар агачына астырачак. Бәлкем әле алай мәшәкатьләнеп тә тормас, үзе үк кылыч белән урталай чабар!

— Табын янына утырыйк әле, дуслар,— диде Артык.

Түр якка кереп, киез өстенә жәйгән ашъяулык тирәли тезелешеп утырдылар. Дәуран барысына да чынаяк белән кымыз салып чыкты.

— Мәргәннәр, хәлләрегезне белеп бетермим. Гәрчә ишетеп-күреп яшәсәм дә, сез минем туганым да, агай-энеләрем дә түгел. Мәгәр ышбу якты дөньяда сездән башка беркемем дә юктыр. Бүген бер нәрсәне төшендем: якыннарым бар икән, менә янәшәмдә иң-иң изге кешем — Назлыгөлем утыра. Син, Жик Мәргән, хәзер шәех килер, диден. Минем аны көтүемне белсәгез?!. Хәзер бернидән дә курыкмыйм. Ассалар да, киссәләр дә курыкмыйм, чөнки сезне күрдем. Сез миңа сөйгәнемне алып килдегез, бәхетле иттегез, сез минем өчен иң-иң изге жаннар. Ант эчәм, борынгы бабаларыбызча эчәм, тәкъдир килеп үлем түшәгендә ятканда да күз алдымда сез булырсыз. Менә карагыз,— Дәуран кулына пычак алды, кулына чәнечте, канын чынаягына агызды да Жик Мәргәнгә бирде. Жик Мәргән үз чынаягына үз канын тамызды, Дәуранга бирде — барысы да ант эчтеләр. Хәтта хан кызы Назлыгөл дә бармагына пычак белән төртеп кан чыгарды, әмма авыртуга түзә алмыйча, башта бармагын авызына капты, шуннан соң гына, тегеңә һәммәсе дә елмаеп карагач кына, касәсенә кан тамчыларын тамызды. Дәуранына бирде. Дәуран аның, ул Дәуранның кан катыш кымызын эчеп куйды. Эчеп куйды да хан кызы, керфекләрен еш-еш каккалап, Дәуранына карап тора башлады.

— Борынгы заманда бабаларыбыз сөннәр никахны шулай гына укыганнар — кымызга кан тамызып бер-берсенекен эчкәннәр дә кавышканнар,— диде Назлыгөл.— Моны миңа мөдәррисем кәтиб Хафиз сөйләгән иде.

— Мәргәннәр, мин азат түгел, кулымда кылыч урынында һәрчак ташкискеч булды. Жырымны да таштан таптым, мәхәббәтемне дә ташка бизәкләр төшергәндә очраттым. Ләкин бүгенге көнгә кадәр, сине генә яратам дип әйтә алмадым. Бүген әйтәм: мин хан кызы Назлыгөлне

яратам, үлепләр яратам. Мин аның өчен тиңе булмаган сарайлар, сезнең өчен дошман ала алмастай кирмәннәр салырга әзер. Хан колы түгел мин бүгеннән, сезнең колыгыз, дусларым! — диде Дәүран.

— Минем дә әйтер сүзем бар,— дип күтәрелде Зәйтүнә.— Иманым камил, бүген шәех оста Дәүран белән хан кызы Назлыгөлгә никах укыр. Укыр бит, Җик Мәргәнем?

— Егет сүзе бер булыр! — диде Җик Мәргән, күкрәгеннән киерә төшеп.

— Мәргәнем, никахны без дә укытырбыз. Бикә ризалыгын бирде.

— Ә әмир?

— Әмир белән сөйләшмәдем. Абыем, әмир белән үзем сөйләшермен, диде. Мәгәр мин бер нәрсәдән куркам: хан кулына эләксәк, ул оста Дәүранны да, Җик Мәргәнне дә кичермәс. Шуның өчен бу хакта әмир Хаҗига да әйтик.

— Юк! — диде Җик Мәргән.— Синең белән минем хакта белсә дә, оста белән хан кызы никахын ул белмәскә тиеш. Артык, бир әле миңа дөмберәмне, бир әле, бир. Оста Дәүран, синең тимерче Әхмәтне вә аның улы Бәкерне күргәнең бармы? Юк, димә, күргәнең бар. Менә шул егет каравыш кызга өйләнде. Югыйсә, хан кызына өйләнердәй хөрмәтле кеше. Менә нишләтә мәхәббәт адәм баласын, диясем килә. Башта алар җай гына сөйләшә дә белмәгәннәр, күзгә-күз карашып кына мәхәбәттә аңлашканнар. Бу хәлне ишеткәч, тимерче Әхмәт бик лаф орды, иллә һични кыра алмады, барыбер мәхәббәт җиңде. Оста Дәүран, мин сиңа мөнәҗәт әйтәм.

Җик Мәргән думбрасын көйләп, башын кырын сала төшеп, күзләрен йомды, кылларга чиртеп алды.

Әй остазым Дәүранҗан,
Казан-Идел буена
Кала сала икәнсең...
Кала гүзәл төбәктә,
Төрки халкым йөрәктә —
Нигезендә кем ята?
Хан оныгы Галидер...

— Миңа куркыныч,— диде Назлыгөл. Дәүран аны күкрәгенә кысты.— Туганым Галине кала нигезенә күмәргә атам фәрман биргән, диләр.

— Кала нигезендә бернәрсә дә юк. Хан мәчетен салганда шундый гайбәт ишетеп, нигез казыганны үзем карап тордым,— диде Дәүран.

— Гали углан күккә аша. Аждаһаны туган төбәгеннән кам куа һәм ул, уч итеп, үзе белән бу тамашаны карап торган Галине дә алып китә. Миңа бу хәлне үзе карап торган азат сөйләде,— диде Артык.

— Мин бөтенләй башка гайбәт ишеттем,— диде Җик Мәргән.— Имеш, Гали угланны вәзир Исхак чынлап та кала нигезенә күмәргә иткән, әмма кам аның урнына эт күмеп калдырган, ә угланны ниндидер сәүдәгәргә кол итеп сатып җибәргән, имеш.

— Гали олан кала нигезендә ята,— диде Артык.— Азат миңа бу хакта антлар эчә-эчә сөйләде.

— Бу хәлнең асылын кәтиб Хафиз белә, диләр. Мәгәр ул берәүгә дә әйтми икән.

— Миңа әйтте,— диде Назлыгөл.

— Ни дип әйтте?

— Гали туганың исән, диде.

— Исән?! — дип сорады Җик Мәргән.

— Атам кушуы буенча аны чынлап та Чияле тау түбәсенә күмәргә тиеш булалар...

— Күмәләрме соң? — дип сорады Дәүран.

— Кәтиб Хафиз, минем мөдәррисем, хан мәчете нигезендә Гали туганым түгел, эт сөякләре ята, диде.

— Ялган, ялган, хан мәчетенә нигез казыганда берниндн сөякләр дә чыкмады. Коръән тотып ант итә алам,— диде Дәүран.

— Алай димә әле, Дәүран,— диде Артык.— Бәлкем сез эт каберенә

тап булмагансыздыр?
— Мөмкин түгел, нигезне бик тирән казыйбыз.
— Кәтиб Хафиз алдамас.
— Алай димә әле син, хан кызы. Кәтиб Хафиз түгел, пәйгамбәрләр дә изге ялганга юл биргән.
Шулчак ишек шакыдылар. Табындагылар башта күзгә-күз карашып алды, аннары барысы да дәррәү урыннарыннан купты. Җик Мәргән боерды:
— Кызлар түр якка, егетләр шәехне каршы ала! Ишекне үзем ачам!
Оста Дәүран, шәехне күрүгә, каушый калды. Ничәмә тапкыр ул аңа эч серен сөйли язып калды, ә хәзер менә үзе килеп керде.
— Әссәламегаләйкем, хода бәндәләре! — диде шәех һәм бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкты.
— Вәгаләйкем әссәлам, шәех! — диде егетләр баш иеп.
Җик Мәргән шәехне түргә алып китте, кабартып куйган мендәргә утыртты.
— Хуш, бер дога кылыйк,— диде шәех һәм беренче булып кулын күтәрде.
Дога кылгач, шәех янә егетләргә күз йөртеп чыкты һәм Дәүранда карашын туктатып:
— Хәл-әхвәлләрең ничек, оста? — дип сорады.
— Аллага шөкер кебек, шәех. Яшим шунда сезнең хәер-фатихада.
— Амин, амин, шулай була күрсен, шулай була күрсен.— Шәех Җик Мәргәнгә карады.— Йә, ни әйтерсең, мәргән?
— Шул сөйләшкәнчә инде, шәех.
— Кызларыгыз кайда соң?
Җик Мәргән Дәүранга күз кысты.
— Бар әле ашыктыра төш, кияү егет, кызларны. Бар-бар.
Эш чынга әверелеп бара иде, шулай булгач, Дәүран Артыкка: «Әйдә минем белән!» дип кул изәде дә үз ягына алып чыгып китте. Бераздан алар зур гына сандык күтәреп кызлар ягына кереп киттеләр. Шул хәлдән соң эчке яктагы кызларның шатлыктан чинашкан тавышлары ишетелде. Артык белән Дәүран янә әйләнеп керде, егетләр елмая, канәгать, горурлар иде.
— Нинди сандык ул? — дип сорады Җик Мәргән Дәүраннан.
— Әнидән калган, анам истәлеге,— дип ялганлады Дәүран.
Асылда исә оста Дәүран сәүдәгәрдән алган сандыкны Назлыгөл белән Зәйтүнәгә: «Киеме-ние белән сандык сезгә, киенегез теләгән киемнәрегезне!» — дип кертеп биргән иде.
— Кызлар нишли анда, нигә бик озак! — дип түр якка ишеттерде Җик.
— Тире иләп, күн эшлибез! — дип җавап бирде аңа Зәйтүнә.
Кызларны тагын шул хәтле көтәргә туры килде, шәех Тәтеш хәтта борсалана башлаган иде инде, ишектә хан кызы Назлыгөл күренде. Егетләр генә түгел, хәтта шәех Тәтеш тә аягүрә торып басты: шәех хан кызын танымый, белми иде әле, шуңа карамастан, ул эчке бер тоем белән сизде: бу бала гади гаиләдән түгел. Шәех утырды һәм Назлыгөлгә текәлебрәк карап алды. Кызлар икесе дә бала итәкле күлмәктән иде, түшләрендә хәситә, беләкләрендә көмеш беләзек, бармакларында кашлы йөзекләр. Кабартма җиңле, бала итәкле күлмәгенең җиңе бөентеләнеп китерелгән, гәрәбә муенсалары, ике толымга үргән чәчләрендәге көмеш таңкәләр, бигрәк тә кызларның елмаюлары егетләргә исерткеч кебек тәэсир итте.
— Шәех, минемчә, башласак та ярардыр,— диде Җик Мәргән.
— Әйе, башлыйк, килеп бассыннар каршыма,— диде шәех, әле булса Назлыгөлдән күзен дә ала алмыйча.— Кемнәргә башта укырга?
— Оста Дәүран белән хан кызы Назлыгөлгә,— диде Артык.
— Хан кызы! — диде гаҗәпләнүен мыскал да яшермичә шәех.—

Мин хан кызы белән оста Дәуранга никах укырга тиешме?

— Без синең белән, шәех Тәтеш, бу хакта сөйләшкән идек бит инде! — диде Жик.

— Хан кызына никах укыячагымны белмәгән идем. Мин сине шаяртасың, дип уйладым. Монда чынлап та хан кызы икән ләбаса!

— Пәйгамбәр кызы булса да, шәех, син бүген оста Дәуран белән Назлыгөлгә никах укырсың. Ишетәсеңме, шәех?! Бире кара, кем әйтә сиңа моны? Жик Мәргән.

— Хан кызына ата-анасы ризалыгыннан башка никах укыган өчен мине...

— Дөрес әйтәсең, шәех, сине дар агачына асачаклар. Булачак кияү кайчандыр кол булса да, күптән инде ул коллыктан азат ителде. Димәк, сиңа бер сүз әйтүче дә булмастыр. Моның янына берәр елдан Назлыгөл таштай-тукмактай малай да табып куйса... хан сине киңәшчесе итеп сараена алачак, менә әйтте диярсең.

Шәех, хан кызының бит алмалары алсуланып китүен күреп, янә гасабилана башлады. Бу ни инде тагын! Барысы да аның җавабын көтә. Һәм аның бер сүзе Дәуран белән Назлыгөлне иксез-чиксез бәхетле итәчәк, тик аның бу башбаштаклыгы гына ничек бетәр? Болар арасында адәм рәтле бер Дәуран гына бар, ул да әнә хан колы икән. Жик Мәргән качкын, аның тиңе Артык та, ишегалдында каравылда торучысы да качкындыр. Кем китерде аны бирегә? Ни китерде? Нәфсе?! Шул-шул. Инде нишләргә тиеш ул? Аның белән бер буйдан сөйләшкән Жик Мәргән дә хан күзенә күренергә куркып йөри. Назлыгөл турында әйтеп торасы да юк. Оста Дәуран җирлеге дә бик үк нык түгел, шәехнең мөридләре түкми-чәчми җиткереп тора: гәрчә әмир Хажи аңа ирек бирсә дә, хан бирмәгән бит әле. Ахыр чиктә останы коллыктан бары тик хан үзе генә азат итә ала. Әнә шул кеше белән урланган кызга ул никах укырга тиеш. Хан аны моның өчен кичермәс, мең төрле җәза уйлап табар. Җизнәсе Пәһлеван Мәхмүт аңа Болгарда аерата сак булырга, төрле ялганнарга, шәригать кануннарын бозуга бармаска кушкан иде. Олуг шәех янына кергәч, ул аның янында Болгар ханының оныгын күргән иде. Ул затлы яшел төстәге чапан кигән, озын буйлы, зәңгәр күзле, ак йөзле иде. Күкрәгенә кулын куеп, Тәтешнең сәламен алды. Тәтеш: «Мин иртәгә Болгарга сәфәр китәм»,— дисә дә, бер кәлимә сүз әйтмәде. Саубуллашуы да сәер килеп чыкты. Тәтеш аңардан: «Кемгә сәлам юллыйм?» — дип сорады, хан оныгы исә көлемсерәп кенә куйды. Тәтеш янә сәерсенеп калган иде, гәрчә олуг шәех Пәһлеван Мәхмүт аның җизнәсе булса да, бу хакта аңардан сорарга базмады. Китәр көнне олуг шәех аны озатырга килде һәм каенишен бер читкә алып: «Хан оныгы Өргәнечтә юк, син аны күрмәдең!» — диде. Олуг шәехкә шул кадәр хөрмәте зур иде ки Тәтешнең: «Ярый, җизнәй»,— дигәнен сизми дә калды. Ә Яңа Казанга килгәч, аңа бер хикмәтле хәл сөйләделәр. Әнә шул җизнәсе олуг шәех янында күргән Сәлим ханның оныгы кала нигезендә ята, имеш. Бу хикмәтле сүзне бер сәүдәгәр авызыннан ишеткәч, Тәтеш шәех елмаеп кына куйган иде. Ул бу хакта берәү белән дә бәхәсләшмәде һәм аңа аның кирәге дә шуның гына хәтле иде. Ул начар урнашмады, әмир Хажи аны әйбәт каршылады. Белемгә хирыс, иманы камил шәех Тәтешнең халыкка әйтер сүзе бар иде. Монда аны яраттылар, әмир Хажи Бөек Каладан мөридләр китерттерде, шәех үзе дә шәкертләр булдырды. Кыскасы, яңа калада ул әмирдән кала икенче кеше иде. Һәм шул кеше бүген әйтсәң ышанмастай хилафлык кылачак. Болгар төркиләре горурлар, бераз гына кыргыйрак булсалар да, үзләре ни теләгәнен бик яхшы беләләр. Чынлап та беләләр икән бит! Менә Тәтеш кадәр Тәтешне хан кызына яшереп никах укырга алып килделәр. Хәзер инде укымыйча да булдыра алмастыр. Бохарада булса, хан кызына пәрәнҗә кигерерләр иде, болгар төркиләренең, кая ул, пәрәнҗә турында ишетәселәре дә килми. Аннары болгарларның хатыннары

үзләрен бик иркен тота икән, хәтта илчеләрне кабул иткәндә дә хан янында ханбикә утыра икән. Боларның берсен дә үз күзе белән күрмәсә дә, күргәне дә бик җиткән иде Тәтеш шәехкә. Хатыннары пәрәнҗә кимиләр — моңа ул Яңа Казанга килү белән инанды, илчеләрне кабул иткәндә ханбикәнең хан янына утыруына да шикләнмәде — хан кызы каршында, әле кемгә чыгарга тора — колга! Ходавәндә, бу ни инде тагын! Әллә нишләмәк кирәк, чоры-заманы үзгәрде, дин-йоланы кылыч белән тарату заманы үтеп бара. Төрки Болгарына ислам дине кылыч белән килми, бәлкем шуңа бу халык үзен иркенрәк тотадыр. Әйтик, хан кызын урлап, аны колга кияүгә бирү хәлен Өргәнечтә күз алдына китереп кара. Халык үзе үк аларны таш атып үтерәчәк, кара канга батырып, хур итеп. Болгарда сак булырга, бик алай үз сүзен сүз итмәскә, үгетнәсихәтне пәйгамбәрләр мисалында җиткерү хәерлерәк булыр дип әйтеп әйткән иде җизнәсе. Ә ул әнә нинди Дәҗҗал кулына килеп капты. Боларга вәгазь укып торуның хикмәте булмастыр, болар өчен кыйбла Мәккә-Мәдинә түгел, ә хаклык, күрәсең. Тәтеш шәех Болгарда балалар укыту өчен «Иман шартын» язып ята иде. Аны да бетерә алмады. Халыкны гына түгел, үз кул астында булган унлап мөриден дә өйрәтеп өлгермәде. Ислам диненең биш баганасын иман итмәгән кеше ихлас мөселман була алмый: иманга килү, намаз уку, ураза тоту, зәкят әйтү, хаҗга бару. Халык түгел, кул астындагы мөридләре дә моңа ирешеп өлгермәделәр шикелле. Ләкин Тәтеш шәехнең хәйләсе бетмәгән иде әле. Ярый, ул никах укырга риза да булды ди. Әмма шәригать буенча мондый хәлдә кызның ата-анасыннан, аерата атасыннан ризалык кирәк. Икенчесе, кызның ризалыгы зарури — үзе теләп чыгамы хан кызы остага? Янә без шигыйлар түгел, хан кызы белән колны никахлаштыру сөнниләр канунына сыймыйдыр.

— Кһм,— дип тамак кырды Тәтеш шәех.— Хуш, Җик Мәрген, аллага тапшырыйк.

— Әйе, шәех, син ишан түгел, мин хан, дигәндәй, тапшырыйк,— диде Җик Мәрген.— Башта оста Дәүран белән хан кызына укырсың.

— Бисмиллаһи рахманы рәхим...— Тәтеш шәех, күзен ярым йома төшеп, никах укый башлады. Коръәннең дүртенче сүрәсеннән өзекләр әйтте дә хан кызыннан сорады: — Назлыгөл, син Дәүран атлы егеткә үзең теләп кияүгә чыгасыңмы?

Шәригать кануннары буенча, кыз дәшми калса да ярый иде, ләкин Тәтеш шәехнең хан кызы ризалыгын үз колагы белән ишетәсе килде. Назлыгөл, Тәтеш шәех бу хакта сорагач, башта оста егеткә сыенды, беләгенә ябышып, тегенең күзләренә карады.

— Мин оста Дәүранга кияүгә чыгарга ризамын, шәех,— диде хан кызы.

— Мин Назлыгөлне хатынлыкка алырга ризамын,— диде Дәүран.

Тәтеш шәех үзе гадәти коръән сүзләрен укыды, үзе уйлады.

Хәерле булсын. Мөхәммәт пәйгамбәр дә әллә кем булмаган, соңра әнә кем дәрәҗәсенә ирешкән. Өргәнеч сәүдәгәрләренә ышанырга мөмкин, алар хәзер Бөек Калага туктамый, туры бирегә килә — Яңа Казанга. Кем белә, бәлкем ышбу кала киләчәктә Болгарның үзәгенә әверелер. Хәер, үзәк кала булса да, булмаса да, Сәлим хан аны бу хәле өчен кичермәс. Ә бит аңа Бохарада, Һиратта, Сәмәркандтә яисә Өргәнечнең үзендә калырга була иде, бирегә ашкынды, хатын-кызлар пәрәнҗә ябынмый торган мөселман төбәгенә. Ә монда халык үзенә бер әкәмәт икән, бүген мөселман, иртәгә әллә кем. Сәүдәгәрләр арасында Бөек Калага килгәч чалма киеп, Владимиргә киткәч, муенына тәре тагып йөрүчеләр дә бар икән. Язмышны аллаһы тәгаләдән сорап кына китереп булса икән ул. Тәтеш шәех моңа инанды инде. Менә ул да үзенә бер язмыш сайлап алды. Монда килүе бер хәл, урланган хан кызына никах укуы бөтенләй башка нәрсә.

Күңелен торган саен вәсвәсә баса иде.

Җик белән Зәйтүнәгә дә укыды никахны Тәтеш шәех. Биргән бүләкләрен алып, дога кылды, шуннан тамак кырды, янәсе, мине дә тыңлагыз әле.

— Никахны укыдым, Җик Мәргән,— диде Тәтеш шәех, нигәдер бары тик аңа гына мөрәҗәгать итеп.— Инде язмышымны сезгә тапшырам. Хәтерем ялгышмаса, син, Җик Мәргән, ышбу сәгатьтән Бачман баһадир кияве булдың. Бачман баһадир — әмир Хаҗиның уң кулы...

— Син дә, мин дә, шәех, бүгенге көннән хода кулындадыр.

— Аллаһы тәгалә саклаганны саклармын, дигән, мәргән!

Шәехнең сүзләрендә Җик аңлый алмаган хаклык бар иде. Болгарга килгәч, Тәтеш шәехнең дөньяга карашы шактый үзгәрде, ул инде тирәюненә җизнәсе Пәһлеван Мәхмүт күзе белән карамый иде. Мәдрәсәдә дөньяви хәлләрне өйрәнү бер нәрсә булса, халык арасында яшәү бөтенләй башка нәрсә икән бит!

Тәтеш шәех шулай дигәч, Назлыгөл аңа карап, елмаеп куйды. Шушы елмаю шәехнең йөрәгендә мәңгегә уелып калыр дип хан кызы уйлап та бакмады. Янадан шулай елмайтыр өчен, ул теләсә ни кылырга да риза иде.

Учына бер янчык алтын керсә дә, никах укып торганда инде Тәтеш шәех ике юлның берсен сайлаган иде. Әйе, ул ханга аны көчләп укырга мәҗбүр иттеләр, дияр. Әүвәл ышбу кол егеттән, хәзер инде ирдән талакы хали дип әйттерүгә — хатынын аерып, үз иркендә калдыруга ирешер, аннары...

Иң мөһиме — ул хан кызын күрә алды. Аның елмаюын күрү өчен генә дә гайре булмаган хәлләр кылырсың. Ә насыйп итеп, үз кулына төшерсә?

Шәех оста өендә озак юанмады, тизрәк кайту ягын карады. Җик Мәргән аны капка янына кадәр озата чыкты, хәерле юл теләде. Никах укыган өчен алган алтын, кайта-кайта, шәехнең уч төбен пешерә башлады. Ни белән бетәр бу хәлләр? Шиге калмады, ул бу хакта ханга хәбәр итәр. Тик менә соңы ничек бетәр? Аерылырга теләрме хан кызы кол Дәүраннан? Хәер, теләде ни дә, теләмәде ни, моны атасы эшләр. Дәүранны юк итәр, кызына башка чара калмас. Тәтеш шәех ягына карар. Карар да елмаер, елмаймаса елмаймасын, тора-тора елмаер, дөнья ул... Хан кызындагы гүзәллекне ул ни белән чагыштырырга да белмәде. Фәрештә дияр иде, фәрештәләрне күргәне юк, хур кызы дисә, бәлки туры да киләдер? Шәех өчен, гүя күк капусы ачылды, гелән бер төсле дөнья гүзәл манзарага әйләнде.

Тәтеш шәех берәүне дә күрмәде, күрер халәттә дә түгел иде, ул ашыга-ашыга мәчет күршесендәге өенә кайтты. Аны ниндидер шәүлә капкасына кадәр озата килде, өенә генә кермәде.

Шәех аннан-моннан гына тәһарәт алды да намазга утырды, әмма ни тырышса да, хан кызын күз алдыннан җибәрә алмады. Изге китап юлларын әйтә генә башлый, әйтерсең, телен бәйлиләр дә күңелен шуңа таба борып җибәрәләр иде. Ахыр чиктә ул күз яше белән хан кызына мәхәббәте хакында сөйләвен абайлап алды һәм куркып китеп, тирә-ягына төкеренде, янә бисмилласын кабатлый башлады, иллә тагын хан кызы күз алдына килде, тагын теле мәхәббәт турында сайрарга кереште. Яз көнендә чыгып килгән кояшка караган кебек, ул да бу мәлдә Назлыгөлдән гайре беркемне дә күрмәде, ә теле белән ул идарә итми иде инде, гүя теле аныкы да түгел иде.

Хәзер ул шигырь язса, хан кызына багышлар, чәчкә үстерсә — аңа өзеп бирер. Намаз укылмагач, изге китапны кулына алды, ант итте. Әйе, аңа бәлкем хан кызына булган мәхәббәте юлында башын салырга туры килер, иллә ул чигенмәс, хан кызын яратыр, яратыр, яратыр...

*Ахыры киләсе санда*

ШИГЪРИЯТ

## Шамил Маннапов

# ҮКЕНМӘСЛЕК БУЛСЫН

## Үзгә бәйрәм

Бәйрәм бүген туган якларымда,—
Яңарышлар белән яңарган.
Яңа арыш, яңа уңыш исе,
Яңа ачыш хисе аңарда.

Һәр ел күтеп алган бу бәйрәмнең
Артты кебек тагын ямьнәре...
Халык хисабына үзенә һәркем
Бәйрәм ясаучылар бәйрәме
Вәйран булды!
Инде хаклыкны да
Ришвәт итеп беркем алалмас,
Аллы-гөлле шардай
Кабартылган саннар
Бәйрәм күрке булып саналмас...

Ямьлелеге шуңа бу бәйрәмнең,
Матурлыгы шуңа бу таңның:
Башыбызга аек акыл кайтты
Туры сүзе сыман Тукайның.
Тарихыбыз, телебезне онытып,
Бара идек тәмам таркалып.
Килде хаклык!
Тарих мәйданында
Үз урынын барлый һәр халык.

Бу бәйрәмдә шуңа урының түрдә:
Нинди генә кыен чакта да
Тукайларың, Җәлилләрең белән
Булдың, халкым, алгы сафларда.

Синең бәйрәм — Ил бәйрәме белән,
Яңарышлар хисе аңарда.
Җир үзе дә Тукай хыялланган
Исән үпкә булып яңара.
Яңарсын ул!
Сулыш юлларында
Сугыш микроблары калмасын.
Ул микроблар, Җиребездән күчеп,
Галәмнәрдә, берүк, азмасын!
Бәйрәм булсын бөтен планетада,
Дөньяларга күчсен яңарыш,
Хаклык Кояшыбыз һәркемгә дә
Тигез сипсен нурын алланып.

Бәйрәм бүген Илем киңлегендә,—
Яңарышлар белән яңарган.
Яңа арыш, яңа уңыш исе,
Алга барыш хисе аңарда...

## Күрше абзый ник зарлана?

Без кайчандыр якын дуслар идек,
Әйбәт кенә иде күрше малай.
Әтисе аның фронтовик иде
Һәм мыеклы иде Сталиндай.

Күрше малай «ристан кәҗә»ләрен
«Сталин сыеры!» — дип тукмаганга,
Атасыннан ай-һай нык эләкте,
Башындагы җөе — шуннан тамга...

---

Шамил МАННАПОВ *(1938) — шагыйрь, прозаик; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән унга якын китап авторы. Казанда яши.*

— Өлкәннәргә каршы тел күтәрмә,
Дөрес булмаса да, дөрес диген!
Мин үзем дә өрә белми өреп,
Үз өстемә күп китердем бүре.
Теле озыннарның буе үсми,
Иелгән башларны кылыч кисми...—
Әти кеше шулай акыл бирде,
Гәрчә үзе туры сүзле иде...

Башта атасының орышканыннан,
Аннан:
«Атаң — халык дошманы!»ннан
Безнең күрше малай йөрәгендә
Курку калды — «шәхес өрәге»ннән...

Кылыч кисмәсен дип иелде баш,
Йөрәк белән бергә сүрелде баш,
Дәхи аягүрә йоклады баш,
Баш булудан тәмам туктады баш...

Инде ераклардан кайткан ата
Малаена карап башын вата:
«Каян килгән безгә мондый мокыт,
Мондыйлар бит безнең нәселдә юк?!

Аталылар мондый булмый иде,
Нишләп мондый булды
минем малай?» —
Күрше абзый шулай зарлангалый,
Һәм мыегын бора Сталиндай...

## Кайтаруы кыен...

*Кайбер шәһәрләрнең үз исемнәре кайтарылу уңае белән*

...Инде бик күп, бик күп нәрсәләрнең
онытып бара идек чын атын:
күрәләтә начар белән яхшы,
дошман белән дуслар буталды.

Кемнәргәдер, халкын яратканга,
«Бу, диделәр, ата милләтче!»
Үзен генә белгән космополит
булып йөрде бәйнәлмиләлче.

Кайсылары җилкәбезгә менеп,
җитәкче без сезгә, диделәр.
Оҗмах төзеттеләр... үзләренә,—
ышанычны җимерә-җимерә.

Шундыйлар бит яңа кала өчен
бер таш чыгармыйча карьердан,
фейерверк төсле сүзләр атып,
ясадылар монда карьера.

Яңарышны халык тансыклавын
сизә иде алар бер чама,—
яңарырга теләделәр бугай
исем алыштырып булса да...

Халык исеменнән... Ләкин алай
булмый икән бүтән шаярып,
һәр нәрсәнең үз исеме белән
әйткән хәбәрдарлык заманы
кайтты кабат! —
Теге еллардагы
югалган күпләрнең берседәй,
Тик югалган халык ышанычын
кайтаруы кыен тиз генә...

❁

Ни булды соң табигатькә:
Язлар килә соңгарып?
Ялгышалар алмагачлар
Иртә бөре чыгарып.

Ни булды соң бу күңелгә:
Язны көтеп алды да,
Ашыкмый никтер, ашыкмый
Бөреләр чыгарырга;

Онытмый бугай бөреләр
Ул алданган көннәрен,
Чәчәкләрен кырау сугып,
Шиңеп калган көннәрен...

Кысыр чәчәкләр калдылар,
Чыннары юкка чыкты.
Узган кырауларны сукты
Язларга ышанычны?

Яңа язда яңа чәчәк
Атмакчы була күңел,
Ашыкмый ләкин.

Бу күңел
Әллә минеке түгел?

Ни булды соң табигатькә?
Бу яз тагын соңгарып,
Ялгышмасмы алмагачлар
Иртә бөре чыгарып? —
Шундый уйлардан борчылып,
Каршылыйм язгы таңны.
Авыр туа таң... Газапта
Мин тудырам күк аны...

Шәһәр урамында корыган тирәк,
Тамырлары — асфальт астында.
Шул асфальтмы тота җибәрмичә,
Аваргамы курка катыга? —
Шыр сөяккә калса да ул, үзе
Һич ашыкмый әле аварга.
Ярдәм көткән сыман карап тора
Урам тулып аккан гавамга,
Илтифат юк ләкин аңарга...

Ә бит анда...— туган урманында
Яшь тирәкләр ботак-култарда
Тотып кына яткырырлар иде...
Һәм кешеләр килеп урманга,
Бик кадерләп салып китәр иде
Машинага яки арбага.
Кешеләргә җылы бирә-бирә,
Насыйп булыр иде янарга...

Илтифат та монда итүче юк,
Гомер үтте каты асфальтта.
Авуның да һич мәгънәсе юктыр,—
Чүп кенә син монда, аугач та...

Үзгәрергә, дибез дә бит,—
Азмы үзгәрдек инде.
Үткәндәге гыйбрәт-сабак
«Аһ»лап сөйләрлек инде.

Болыннарны сукаладык,
Сазлыкларны киптердек.
Табигатьне «җиңә-җиңә»,
Танымаслык иттердек.

Имеш, җирне арттырабыз,
Күбрәк уңыш алабыз.
Инде коргаксыган җирне
Елгадан сугарабыз...

Җир астына су кудырып,
Алдык арзанлы нефть.
Инде эчәр өчен суны
Чистартыйк икән ничек?!

Урман полосасы белән
Кыр, дидек, бигрәк ямьле.
Ә чын урманнар, баштагы
Чәч кебек, сирәкләнде.

Элек тә бит оран салдык:
«Үзгәртәбез! Ямьлибез!»
Инде ул чак үзгәртергә
Дәшкәннәрне әрлибез...

Имансызларны мактадык,
Иманлыларны сүктек.
Инде бүген зарланабыз:
«Имансыз яшьләр үсте...»

Эх, безнең җүләрлек,
Исәпләсәң, көләрлек:
Яхшыга үзгәрәбез, дип,
Ничә төргә үзгәрдек.

Ә үзгәрү кирәк,—
Тормыш
Ничек үзгәрми торсын?!
Үзгәрик без,
Тик соңыннан
Һич үкенмәслек булсын!..

# Кадыйр Сибгатуллин

## Ашкын ат

Гомерендә чабып күрсәтте ул,
ашкынып та, гаярь булып та.
Мәйданнарны уктай тишеп үтте,
тота алмады кеше, куып та.
Түзә алмады өстә җайдак булса,
ачылып киткән чакта канаты.
Ярыш юлларында егылып төшеп
күпме малай йөзен канатты!
Ул икенче булып килә алмый,
башкаларда аның эше юк.
...Ул беренче килде!
Ялгыз килде! —
Җилкәсендә тагын кеше юк.
Һәм салдылар тышау.
Утарында
чабышкылар башка токымнан.
(Бер уйласаң, әле моңа кадәр
ул коллыктан кемнәр котылган?)
— Йөрәгендә моның, җелегендә.
Ашкын атлар алар тик тормас.
Баш бирәчәк түгел,— диде хуҗа,—
бер ычкынса, бүтән тоттырмас.
...Болыннар да иркен, дөнья да киң,
сулышлар да күпкә җитәрлек,
чыклы таңнарында кешни-кешни
офыкларга чабып китәрлек.
Яратмыйлар ялгыз йөгергәнне.
Яратмыйлар алай узганны.
Күзгә керә ярыш чатларында
башкаларның тояк тузаны.
Гомере буе — әле кайчан да бер
чабып китәренә ышанды.
Кага йөрәк һаман...
Аяклары,
аяклары гына... тышаулы.

## Бөек сер

Туа кеше.
Озак яши кеше.
Үлә кеше серне аңламыйча.
Илаһи Көч Җирдә йөртә аны
гомере буе һич тә алдамыйча.
Алмаш туа аңа.
Яши.
Үлә.
Ул да китә.
Сере кала шулай.
Йөзенчесе,
меңенчесе серне
ачылмаган килеш ала шулай.
Еллар үткән.
Мең еллар да үткән.
Миллион еллар шулай үтәр тагын.
Ачылыр, дип, Бөек Яшәү Сере,
Һәрбер кеше әле көтәр тагын.
Шуңа күрә дә бит Бөек Сер ул,
бөек Сер ул һәрчак читтә тора.
Кеше аңа якынайган саен
шуның кадәр ул да китә тора.
Ул ачылмас.
Ачылса да бары
ачылыр ул башка затлар өчен.
Ачкычлары галәм төпләренә
салынгандыр мәңге саклар өчен.
Бер күкләргә карап уйлау кызык,
үз-үзеңне һич тә алдамыйча.
Килгән китә!
Без дә бер китәрбез
үзебезне үзебез аңламыйча.
Яшәргә дип кенә тудырылган,
гомере бар,
кеше яши генә.
Илаһи Көч Җирдә йөртә аны,
алдамый ул —
бары дәшми генә.

---

Кадыйр СИБГАТУЛЛИН *(1942) — шагыйрь, татар һәм рус телләрендә басылган унга якын китап авторы. Чаллыда яши.*

## Яңадан сайлау

Алла булу алай ансат түгел.
Баткан иде шактый гөнаһка.
Төшерделәр ходай тәгаләне
каравылчы итеп оҗмахка.
Уйладылар,
озак баш ваттылар,
сайлый-сайлый тәмам туйдылар.
Гөнаһлары юк, дип,
фәрештәне
алла итеп сайлап куйдылар.
Бер ел үтте.
Тәмам тәртип бетте.
Башбаштаклык китте һәр эштә.
Зобанилар тулды оҗмахына,
гөнаһыга батты фәрештә.
Җыелдылар кабат җыелышка.
Һич булмаган мәхшәр кузгалды.
Каушап калды мескен фәрештә дә.
...Бер пәйгамбәр шунда сүз алды:

— Ялгыштык без,— диде,—
тарихта юк
фәрештәнең алла булганы.
Моңа кадәр бармы бер алланың
каравылчы булып торганы?
Гөнаһлы ул, дидек.
Йә, кайсының
гөнаһысы бер дә булмаган?
Алла инде ул алла булып туган,
каравылчы булып тумаган!
Сөйләделәр:
Алла әйбәт, гадел...
Гөнаһысы да юк олыдан.
Ул бит бары үзенең гөнаһысын
ярлыкарга үзе оныткан.
Юл куйма, дип, андый гамьсезлеккә,
бер фикергә килеп аннары,
бик канәгать булып,
алла итеп
сайладылар тагын Алланы.

## Бурыч

Гаҗәпләнеп шуны уйлап йөрим,
(яңа килде уйга — томана!),
тик бер генә сүзне хәтерләп тә
яшәп була икән дөньяда.
«Бурыч» дигән матур сүз бар икән,
матур итеп әгәр кулланса̧ң,
Күзләреңне юньләп ачып йөрсәң,
төшеп калган бәндә булмасаң.
Кеше бурычларын кеше белми,
кешенекен кеше түләми.
Һәркем үзе билгеләргә тиеш
бирер бурычлары күләмен.
Бурычлы мин, диеп йөри кеше,
бурычлы, ди, анам-атама.

Ул бурычлы икән кешеләргә,
ул бурычлы Илгә, Ватанга.
Фикер туа: бу — намуслы кеше,
тыйнак кеше, уйлы, хәтерле.
Җәмгыятькә безнең әнә шундый
аңлы иптәшләр бик кадерле.
Ялгышы да күптәр — тормыш бит ул,
дөнья һаман булмый уңышлы.
Ул үзе дә һаман әйтә тора:
бурычлы бит егет,
бурычлы!
«Бурычлы мин», диләр гомер буе,
«зур бурычлы мин», дип яшиләр...
Бурычларны түләр вакыт җиткәч
бурычлылар бер сүз дәшмиләр.

*

Очраштылар сабакташлар — дуслар.
Күпме җәйләр, кышлар үткәннәр.
Икесе дә шәхес,
икесе дә
зур кешеләр инде күптәннән.

Сөйләшәләр:
олы фикер, акыл
аңкып тора әйткән сүзләрдән.
...Ике малай бер-берсенә карый
аптырашып ачык күзләрдән.

*

Далаларга килсәң, диңгез тарта.
Диңгезләргә китсәң — далалар.
Тауга менсәң ярсып, сагындырып
үзәннәре көтеп калалар.
Туган җирдән туеп китми кеше,
эзләп китми кеше каберен.
Эзли кеше һаман күрмәгәнен,
яшәүләрнең белсә кадерен.
Мин ышанам: гел кайтасы килер,
кая гына адәм китсә дә.
Туктый алмас ләкин
Җирнең,
Күкнең
кырыена барып җитсә дә.

## Күптәнге бер хакыйкать

Үтә икән бөтен кичергәннәр,
вакыт ала икән.
Тик шулай да, алар үтеп киткәч,
нидер кала икән.

Мәрхәмәтең, изгелегең кала
җанда балкыш булып.
Җирдә кылган бөек эшең кала
күктә алкыш булып.

Сакламасаң, киткән мәхәббәтең
сагыш булып кала.
Кешеләрне рәнҗетәсең икән,
каргыш булып кала.

Кимсетсәләр сине бер дә юкка,
җанда кала ачу.
Гаепләсә сине кемдер юкка,
җанда кала ярсу.

Кешеләрнең хыянәте кала
синдә нәфрәт булып.
Якыннарның бәхетсезлекләре
кала хәсрәт булып.

Бер яхшылык эшли сиңа кемдер —
рәхмәт кала аңа.
Тик бер шырпы сыза, шул йөрәктә
гомер буе яна.

Аңламасак шуны, бу хакыйкать
күптән таныш булып,
яшәвебез безнең, гомеребез
калыр ялгыш булып.

*

Кайнар, диләр, кызу канлы, диләр,
җитеп бетми, диләр, сабырлык.
Ул гаеплемени? Дөнья эссе,
кабынып китеп йөрәк янарлык.
Тоя тормыш, дөрләп янган чакта,
әле синең Җирдә барыңны.
...Кайнар канны суытучы булыр,
кем җылытыр суык каныңны?!

*

Үзәкләрең өзелеп төшәр чакта
чакыра алсаң икән: «Кил!» — диеп.
Килсеннәр дә, елмайсыннар иде:
«Килдем бит мин, менә — мин»,— диеп.
Кирәк икән без дә дөньяда дип,
бер куансаң иде шул чакта!
Бездән бәхет китә алмас иде
нинди генә хәлдә булсак та...

# Газинур Моратов

## Атом-кирмән

(ФРАГМЕНТЛАР)

1

Кама Аланында — котлованнар,
Өем-өем туфрак-катламнар...
Җылы кирәк илгә, якты! —
Кирәк
Баш очында Кояш та, димәк?!

Атомны да тәртә арасына
Кертә халык — тормый аптырап.
Җылы кирәк илгә, якты кирәк —
Җылы булсын еллар, яктырак.

Җылы булсын еллар, димәк — җырлы!
Халкым минем борын-борыннан
Икмәксез дә хикмәт эзләгән гел,—
Икмәк тәме килә моңыннан.

Якты булсын еллар, димәк — хаклы!
Хаксызлыкны халкым күп күргән.
Ничә кабат сиратларны кичкән
Галиләре салган күпердән.

Идегәе булып Идел кичкән,
Тукай булып туңган иләндә.
Һәм Туфаны булып Себер киткән,
Ил язмышын салып иңенә.

Якты булсын еллар!
Якты җырлар
Җырлый-җырлый язсын яшәргә.
Ил күгендә Хаклык уты сүнсә,
Әверелә Яшәү мәхшәргә...

Якты булсын еллар!
Әле анда,
Әле монда — канлы вакыйга...
Ил күгендә Ирек уты сүнсә,
Әверелә тиран «даһи»га.

Якты булсын еллар!
Хаклык утын
Ильич үзе биргән халкыма.
Без яшибез бүген — күңелләра
Бөек аңлашулар хакына.

Якты булсын еллар!
Караларын
Газиз халкым, юк, онытмады...

...Ә ник әле Атом-кирмән төзи
Алып оныклары?!

2

Җир тарихы... Җир дә тора
Тарихи катламнардан...
Легендага күчеп яши
Монда таш кантарлар да.

Легендага күчеп яши
Кашаны, Биләрләре...
Хәрабәләр ханлыгы бу,
Болгар биләмәләре.

Әнә Сувар... Ага-Базар...
Ташлардан гыйбрәт алыйк.

Монда — китапларга түгел —
Ташка басылган тарих.

Әнә Нөкрәт... Шайтан кала...—
Юлыккан ни казага?
Ташка әверелгән монда
Чуен койган казан да.

Ташка әверелгән монда
Яшәеш тә, үлем дә...

---

Газинур МОРАТОВ *(1959) — шагыйрь, «Җир хәтере», «Мин дөньяны тыңлыйм» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Экскаватор кулы әнә
Тарихыма үреләп.

Замананың тимер кулы
Тарихымны актара.
Чын тарихны актарсаң да
Язык түгел — аклана.

Җир тарихы... Катлам-катлам
Тарихыма сөялеп,
Торам менә...
Кулларымда —
Бабамның баш сөяге...

3

Җир әйләнә, кошлар оча иде —
Җырдагыча! — Заман тизлегендә!..
Баш сөяге телгә килде кинәт:
— Ни күмдегез кирмән нигезенә?

Баш сөяге телгә килде кинәт —
Телгә килде гүя телсез тарих:
— Кирмән ватып күңел ачты җирдә
Күпме башкисәр җан, күпме кабих.

Мәйданнарда изге китап ягып,
«Мәгърифәтче» булды күпме тинтәк.
Оныклары аннан тарих язды —
Үзләренчә сипләп.

Һәм туктаусыз тукыдылар башка:
— Уйлау — язык, өйрән уйламаска!
Хөкем ителәчәк һәр уй, ният!
Ни кылса да безләр — тәрәккыят!

Тукыдылар башка:
— Уйламаска!
Ачы шәраб акты мичкәләрдән.
Әмер булды кабат:
— Айнымаска!
Тәгәрәде уйлар кискәләрдән,—
Мәңгелеккә лаек — аек уйлар!..

Ачы язмыш, каргыш махмырыннан
Мәмләкәтләр язды һушларыннан.
...Бу тарихта кайчак халыклар да
Әверелде халык дошманына.

Җир әйләнә, кошлар оча иде —
Җырдагыча! — заман тизлегендә!
Баш сөяге телгә килде кинәт:
— Ни күмдегез кирмән нигезенә?

Баш сөяге телгә килде кинәт:
— Ни күмсәгез — шуны табачаксыз.
Эт күммәгез берүк — эт көненә
Үзегез дә бер көн калачаксыз.

Кардәшләрем минем, эргәдәшләр,
Нык берексен җиргә тамырыгыз.
Нык берексен! — Кирмән нигезенә
Якты өмет салып калдырыгыз.

Җирдә якты җиңә барган саен,
Арта барыр илдә кадерегез.
Кардәшләрем!
Кирмән нигезенә
Гүзәл гамьнәр салып калдырыгыз.
...Тамырланып, нык берексен җиргә
Рухи тамырыгыз.

4

Экскаватор кулы гүя
Хәтеремне соса.

Шайтан кала эргәсендә
Чуен койган Оста.

Әйткән хаким: «Бу калага
Узалмасын кош та» —
Мәшригында, мәгърибендә
Ул бердәнбер Оста.

...Энгер төшсә, күкне иңләп,
Каракошлар оча.—

Оста кирәк һәр хакимгә —
Шул бердәнбер Оста.

Оста аулау хакимнәрнең
Биләп алган уен.
...Ядрә булып кирмән ваткан
Төрән булыр чуен.

Бөек Сердән легенда һәм...
Кисәү калган бары...
Шайтан кала эргәсендә —
Шайтан таяклары...

* * *

— Кайда гына орлык сибеп,
Үсмибез кайда гына.
Шуңамы әллә кадер юк
Без — шайтан таягына?

Үзебезчә без дә чәчәк,
Без дә җиргә береккән.
Тарих безне «татарник» дип
Атый элек-электән.

Үзебезчә без дә чәчәк.
Яшәрәбез. Сулабыз.
Җилләр кыйный, силләр кыйный —
Чәнечкеле шуңа без.

Гөл-чәчәкләр ыруында
Үзгә чәчәк, үзгә без.
Җилләр кыйный, силләр кыйный,
Ә без — сабыр. Түзәбез.

...Кайда гына шытсак та без,
Үссәк тә кайда гына,
Чәчкәләр дип эндәшегез
Без — шайтан таягына.

Үзебезчә без дә чәчәк.
Күзләр җитсә, сулабыз.
Хаҗи-Морат карашыдай
Кырыс, уйчан шуңа без.

## 5

...Ә ул көнне илдә бәйрәм иде.
Вәйран җанны ефәк-укага
Төрми генә шигырь укыдык без
Ирек мәйданында — Тукайга.

Ә ул көнне Тукай 100 дә иде,—
Кем бозарга базсын бәйрәмне?!
Дөнья читлекләрен тарсынган Кош
Үз янына безне әйдәде.

Дөнья читлекләрен тарсынган Кош
Очып йөрде Апрель күгендә.
Заманалар кыршау кидергәндә
Һәрбер кошка, һәрбер күңелгә,

Ярсып-ярсып шигырь укыдык без,
Ә кемнәрдер, беләм, тукынды —
Җыр өстеннән донос юллады
һәм
Тәре үбеп ясин укыды.

Ә ул көнне илдә хәвеф булган.
Дөнья черем иткән арада,
Кыршауларын, тышауларын өзеп,
Шашкан Атом качкан араннан.

Ирек мәйданында ирек даулап —
Тышауланган халык-илләргә,
Репрессияләнгән дастаннарга,
Идегәйдәй алып ирләргә —

Телгә килгән чакта ирексезлек,
Шашкан Атом качкан ...иреккә.
Ут-яллары күкне өтәләгән,
Тояклары җирне эреткән.

Сабыйлардай — мич артына кереп
Яшеренгән сыман яшеннән,
Поскан Вакыт үлән арасына —
Баш сөяге Көннең яньчелгән.

Типкән Атом, кушаяклап типкән,—
Җиргә иңгән тәңре, алласы...
Припятьта кармак салган картның
Күккә сеңеп калган карашы.

Кыйтгаларга барып ишетелгән
Кара Атның кешнәп көлгәне.
Припятьта кер чайкаган кызның
Диңгезләргә аккан керләре.

Припятьта кер чайкаган кызның
Көмеш сулар юган эзләрен.
Көмеш суда йөзгеч-канат булып
Бәргәләнгән көмеш тезләре.

...Ә ул көнне илдә бәйрәм иде,—
Кем бозарга базсын бәйрәмне?!
Дөнья читлекләрен тарсынган Кош
Үз янына безне әйдәде.

## 6

*...Стенамда — «Помпейның соңгы көне». Тереклекнең һәлакәтеннән бер мизгел... Бөек рәссам рухы Кешелекне соңгы кабат кисәтә кук...*

*Ә Сэмюэл Коэнның үлем лабораториясендә кеше үтерүнең яңарак, камилрәк ысуллары өйрәнелә...*

...Җир — мәҗрух җанвар сыман
ыңгырашып куйды.
Кояш куркып, сискәнепме,
яктылыгын җуя барды,
җуя барды... җуйды...
Чал кыялар телгә килде:
— Без — яралы.
Гөл-агачлар пышылдашты:
— Без — янабыз.
Киек кошлар һава ярды:
— Кая очыйк?
Сак җәнлекләр аваз салды:
— Кая посыйк?
Җир дәшмәде...
Ә кешеләр, аквариумда
бәргәләнгән балыклар кук,
һәммәсен дә сизеп торды,
белеп торды, күреп торды...

*АЭСның беренче реактор котлованын казыганда экскаватор чүмече палеозой казналыгыннан мамонтның казык тешен суырып чыгара. Табылдык хәзер музейда саклана...*

## 7

...Еллар шәмдәлендә — шәмнәр, шәмнәр...
Сүнә... берәм-берәм.
Үлчи Вакыт кылган гамәлеңне
Бишьеллыклар белән.

Минем чорым — бишьеллыклар чоры,
Мин шул чорда туган.
Әмма минем үз бишьеллыгым ул,
Үземнеке, туган.
Минем бишьеллыкта — милли байлык
Үлчәнә Тел белән:
Әрәмтамак булып җан асрый
Ваз кичкән теленнән.
Минем бишьеллыкта прораб — Иман! —
Өмет, җыры барга
Сметада акча каралмаган
Хәрби чыгымнарга.
Минем бишьеллыкта тик тел-лөгать,
Җыр алмаша илләр;
Тарих өсләп өмет җыры оча,
Киләчәкне иңләп.
...Хатын-кызлар таңда бәби таба,
Иген игә ирләр —
Минем бишьеллыкта!

# Әмир Мәхмүдов

## Мәхәббәт

Зур дуслыкны дошман какшаталмас —
Бөек дуслык килә алыстан.
Россиясен кочкан Татарстан:
Дуслыклары ныграк корычтан.

Мәхәббәт ул көчле атомнардан,
Кодрәтлерәк үткен кылычтан.
Сөеклесен кочкан Татарстан:
Мәхәббәт ул көчле сугыштан.

Зур дуслыкны дошман какшаталмас,
Сөю хисе көчле сагыштан.
Халыкларның кайнар мәхәббәте
Тынычлыктан килә... алыстан!

## Бабамнар

Чал курганнар йокыларга талганнар...
Кылганнарга әйләнгәнме бабамнар?!
Курганнарда башын игән кылганнар,
Әйтерсең лә зур кайгыга калганнар.
Шатланмагыз, зур гөнаһлар кылганнар,
Далаларда уяу әле кылганнар.
Бабайларга дан җырлыйлар оныклар,
Алар өчен кызарсын кем? — сатлыклар...
Хыянәттән һәлак булган бабамнар,
Далаларга кызыл каннар тамганнар.
Каннарыннан хасил булган Иделләр,
Бабамнарның пульсын тоя киң илләр.
Үткән чорлар, үзгәргәннәр холыклар,
Кол булмаган ирек сөйгән халыклар!
Киң галәмгә алар юллар салганнар,
Алар — исән, йолдызларда калганнар!
Иген игә сыман анда бабамнар,
Татар моңы кебек таңда — сигналлар.
Сак булыгыз, олуг гөнаһ кылганнар!
«Барабаннар кагып», кайта бабамнар!

---

Әмир МӘХМҮДОВ *(1947) — шагыйрь, тәнкыйтьче; «Матурлык тантанасы», «Мәңгелек моң» исемле шигырь китаплары һәм «Муса Җәлил иҗатында эстетик идеал» исемле монографик хезмәт авторы. Казанда яши.*

## Шәүләләр

Еллар үтү белән үзгәрәләр —
Канашевич, Ильминскийлар:
Танып булмый хәтта йөзләрен дә,
Шәүлә булып калган... мескеннәр!

Зур гөнаһлар өчен җәза көтә! —
Юмарт алар бүген «тәүбәгә».
Шәүлә булып калган бу мескеннәр
Әйләнмәсен янә... гәүдәгә!

❁

Без белмәгән тарафларга
Китә Кеше кинәт кенә.

Кеше үлми, Кеше — исән,
Туктый бары... йөрәк кенә!

## Зоопаркта

Зоопаркта, тыныч җирдә
«Оя корган» бөркетләр...
Кем ирек сөйгән кошларны
Зур ташларга беркеткән?!

Мәңге азат, курку белмәс
Мәгъруp кошлар, бөркетләр!
Чакырып, дәшеп тора сезне
Биеклекләр, киң күкләр.

Ризамы сез, шат-көрме сез
Тук тормыштан, бөркетләр?
Кыяларны, горур кошлар,
Калдыргансыз бик күптән:
Биеклекнең ни икәнен
Оныткансыз, бөркетләр...
Озаккамы язмыш сезне
Шул ташларга беркеткән?!

## Түрә

Бүрәнә аша бүре күреп,
Дачасында яши түрә.
Халкын үзенә тиң күрми,
Шуңа күрә җаны шәрә.

Койма белән уратылган
Дачасы да зират кебек.
Күңеле — тонган судай тынган,
Үтәр юлы — сират кебек.

## Матбага белән уйнаучы елак балага

Тынгысыз бала булды бу!
Елап караган була:
Тәнкыйтьче ролен Союзда
Уйнап караган була.

Мәшһүр шагыйрьләр белән ул
Сугышып караган була...
Никадәр ышкып юса да,
Җаны каралган була.

## Юха елан

Тәнкыйть итүдән Шагыйрьне
Кичә генә тыелган...
Дошманын мактап,
зиратта
Сүз сөйли Юха Елан.

Геннадий Паушкин

# ИДЕЛ БИТ УЛ, ИДЕЛ БИТ УЛ!..

*«Кадерле иптәшләр, дуслар!*

*Идел буенда яшәүчеләрнең күп санлы тәкъдимнәре һәм журналистлар, язучылар, галимнәр, юристлар, культура эшлеклеләре, башка һөнәр ияләре тарафыннан чакырылган оештыру конференциясе карары белән, Иделне коткару җәмәгатьчелек комитеты оештырылды. Аның Программасы һәм Уставы расланды...»*

*Бу юллар — Мәскәүдә оештырылган әлеге комитетның халыкка Мөрәҗәгатеннән алынды. Мәгълүм ки, Идел — тереклек чыганагы буларак, бу төбәктә яшәүче һәркем өчен кадерле елга. Шунлыктан аның иминлеген, киләчәктә дә мул сулы саф елга булуын тәэмин итү өчен көрәшкә күпләр күтәрелде. Минем аңлавымча, язучылар, журналистлар да бу юлда көчкуәтләрен, сәләт һәм активлыгын кызганмаска тиешләр. Язучы Г. Паушкин мәкаләсе — журналдагы беренче карлыгач.*

Марсель ЗАРИПОВ,
язучы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, «Советская Россия» газетасының үз хәбәрчесе, «Иделне коткару җәмәгатьчелек комитеты» члены.

Элек монда иксез-чиксез болын җәйрәп ята: күз карашы гына җитәрлек түгел. Иделнең буеннан-буена сузыла, әллә кая офыкларга китеп, зәңгәрләнеп тора иде. Язын елга ярларыннан чыгып ташый башласа, бу киңлекләрне су баса, көзгедәй яссылыкта, бөдрә талларның, бәләкәй калкулыкларның түбәләре генә күренеп кала. Май ахырларына исә барысы да үз урынына кайтып төшә: елганың кысалары ачыклана, язгы су керенгән болын яшеллеккә күмелә, әрәмәлекләрдә сайрар кошлар хакимлек итә башлый.

Иделнең сулъяк ярында исә күлләр тезмәсе хасил була. Күлләргә үрдәкләр, киек казлар, челәннәр хуҗа. Ә Идел өстендә — акчарлаклар. Ни әзлиләр, үзара ни хакында гына «чөкердәшеп» бетерәләрдер?! Тавышларына, чикылдашуларына чик-чама юк!

Яр буйларын камышлы сазлыклар «саклый». Шуңа күрә бу тирәләрдә кеше-кара бөтенләй юк диярлек. Ара-тирә ялгыз балыкчыларны гына очратырга мөмкин. Аларның, кармакка күз тегеп, көннәр буе утыруы тулысынча аклана: кәрәкә дә, кызыл канат та, чуртан, хәтта җәен дә эләктерәләр.

Августта әрәмәлекләр ягыннан хатын-кыз чыр-чуы ишетелә башлый. Гаҗәп түгел. Алар карлыган, кара кура җиләге, бөрлегән җыя. Бераздан гөлҗимеш, миләш, мүк җиләге өлгерә...

Бу якларда туып үскән егет, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, РСФСРның атказанган урман белгече Николай Напалков миңа болай сөйләгән иде:

— Заманында Иделнең сулъяк яры, Тәтештән алып Кама Тамагына кадәрге төбәкләр, иксез-чиксез болыны белән дан тотты. Язын бу киңлекләр су дәрьясы астында кала, соңрак анда котырып үлән үсә. Бер тиен чыгымсыз үскән печәнне гектарыннан 65 әр центнер җыйганнар. Кама Тамагында печәнне тыгызлап көлтәгә бәйләгәннәр,

Аннан армиягә озатканнар. Бөтен кавалерияне асрарга җиткән ул. Шул байлык хәзер мәңгелеккә су астында калды. Кызганыч, һай, кызганыч! — Әңгәмәдәшем тирән сулап алды.— Зур су илдәге балык байлыгын арттыруга ярдәм итәр дип уйлаганнар иде. Анысы да көткәнчә булмады. Июль айларында Идел, бичара, «чәчәк ата» башлый. Әлеге су астында калып, быкырдыкка әйләнгән болыннарда исәпсез-сансыз су-үсемнәр котыра. Балык һәлак була. Элек монда мәрсин балыгы да бик күп үрчи иде. 1921 елда Тәтеш балыкчылары җәтмәсенә җитмеш ике (!) потлы кырпы балыгы эләккән. Аны ярга сөйрәп чыгарыр өчен атлар алып килгәннәр. Ул балыкның баш сөяге Казан университетының зоология музеенда саклана. Шула-ай, — дип сүзды галимем. — Иделнең күп кенә байлыгы музей экспонатына әйләнеп калды. Иделнең киңлеге, урыны-урыны белән, егерме чакрымга җитә. Су өстендә өзлексез җил уйный, дулкыннар ярны кимерә дә кимерә...

Галимнең сүзләрендә хаклык зур иде.

Су, проектта билгеләнгәнгә караганда, күбрәк мәйданга җәелде. Тирә-юньдә тереклек итүче җир-су хайваннарыннан бакалар, су күселәре, җизбаш еланнар юкка чыкты. Алар авыл хуҗалыгына зыян салучы күп кенә корткычларга каршы көрәшә иде. Ә аларның үзләре белән Идел өстендә очучы кошлар тамак туйдыра иде. Шул рәвешле, бер һәлакәт икенчесенә килеп ялгана. Элек-электән Иделне туган йорты иткән кошкортлар 1956 елда күзгә күренеп кими башлады. Изге урын буш тормый, дигәндәй, затлыларны тилгән, диңгез бөркете кебек ерткыч кошлар алмаштырды. Алар болай да хәлсезләнгән балыкларны кыра. Балык исә Идел суының ясалма чигенешләренә түзә алмыйча хәлсезләнә. Күбесенең уылдыгы ук һәлак була.

Идел-Кама тыюлыгының Саралы мәйданы — фәнни-тикшеренүләр өчен алыштыргысыз урын. Монда СССР Фәннәре Академиясенең Казан биология институты үз лабораториясен оештырды. Галимнәр урман, болын һәм судагы тереклекнең гаҗәеп дөньясын өйрәнәләр. Аларның күзәтүләренә караганда, Иделнең элекке ярларын су белән күмдерү нәтиҗәсендә, күп кенә җан ияләре бөтенләй һәлак булган. Арадан бик сирәкләре генә яңа ярларга күчеп, ияләнеп китә алган. Кызганычка каршы, бу ярларның чиге һаман үзгәрә тора. Аны дулкыннар да ишә, җил дә какшата, көчле җил белән очып килгән ком бөртекләре дә яр буендагы үсемлекләр дөньясына тискәре тәэсир итә икән. Һәр өч ел саен алып барыла торган фотодәлилләр сулъяк ярның тәмам «пеләшләнеп» калуын һәм бу күңелсез хәлнең өзлексез дәвам итүен раслыйлар.

Галимнәр шундый нәтиҗә ясады: Иделнең болынлы ярларын су астында калдыру үз-үзен һич тә акламаган, киресенчә, зур материаль югалтуларга китергән. Өстәвенә, су төбенә дуен утырып, Иделнең сафлыгына һәлакәт яный башлаган.

Хәтердә әле: без бик яратып ял итә торган «Обсерватория» тирәсендә элек искиткеч чиста күлләр тезмәсе иде. Куе таллар арасында әллә кайдан ялтырап күренә торганнар иде. Комлы утрауларында озын тәпиле, чәрелдек тавышлы шөлди-кошлар патшалык итә, акчарлаклар белән «эрләшәләр». Раифа урманнарына барып тоташкан күлләр Сумка елгасына елышып яшәде. Елга әллә кайдан, каруман эчендәге саф сулы чишмәләрдән башлана, алга киткән саен, кыюлана, киңәя, тирәнәя бара. Аннары балыкчыларның иң яраткан сулыгыннан саналучы Олы күлгә коя иде.

Әле сулъяк ярны су баскач та, беренче карашка, күңелне тынычландырырлык «таяныч»лар бар иде кебек. Проект дигәннәренә «каршы килеп» булса да, Идел итәгендәге кайбер урыннар, серле утрау хәлендә, суга күмелми калды. Балыкчылар, аучылар бу утраучыкларны сырып ала торган иде. Гап-гади ишкәкле көймәләргә утырып, һичнинди шау-шусыз гына утрау читенә килеп чыгалар. Куна калсалар, палатка корып куялар. Вакыты җиткәч, төялеп китеп тә баралар. Әмма утрауларның мондый тыныч рәхәте озакка сузылмады. Беренче булып кайсының күңеленә килгәндер — утрауларда җәйге йортлар салырга тотындылар. Төзү кирәк-ярагын ташу өчен моторлы көймәләрне эшкә җиктеләр. Проектта күмелергә тиешле урын булганлыктан, бу җирләргә карап һичнинди хуҗа да: «Тимәгез, утраучыкларны харап итмәгез!» — дип, чаң сугарга уйламады. Идел, бичаракай, ары-бире чабучы моторлы көймәләр тавышыннан, машина майларыннан тончыга башлады. Тын утрауларда, култыкларда ял итәргә өйрәнгән кешеләр Иделгә бармас булды, чөнки комсызлар «һөҗүм»гә чыккан көннәрдән башлап анда тынычлык бетте.

Күңелләрен кытыклап торучы елгадан ямь киткәч, җанлы дөнья һәлакәткә йөз тоткач, балыкчылар да аңа әллә ни кызыкмадылар, билгеле. Агышына ясалмалык кертелүдән һәм иртә яздан ук әрсез моторлар белән «ермачлану»дан балыкларның уылдыгы күпләп харап була. Утраучыкларда оялап алган шәхси милекчеләр исә бу хакта уйлап та карамадылар. Балык заводлары Зөя тамагы турысыннан Иделгә маймычлар җибәреп-җибәреп карый, әмма балык үрчеп китә алмый, чөнки иң кирәкле чакта аларны көчле дулкыннар таркатып бетерә, моторлар суны кискәләп-кискәләп үтә дә маймычларның күпчелеген һәлак итә.

1979 елда гаҗәеп хәл булды. Ул чакта су, бөтен чамаларны узып, нык кына күтәрелде. Эреле-ваклы өйләр белән тулган утраучыклар су астына китте. Идел өстендә гаҗәеп манзара пәйда булды: елганың буеннан-буена... йортлар ага иде. Суның күтәрелүе елга өчен дә афәтләр тудырды. Яр буена гына өеп куелган химикатлар ишелеп-ишелеп төште. Болай да сафлыгы чамалы калган Идел бу коточкыч агуларны «йотарга» мәҗбүр булды.

Татар халкында: «Идел бит ул, Идел бит ул, Идел бит ул киң бит ул!» — дип, елганы олылап, горурлык тоеп җырлана торган бу суның киңлеге, тирәнлеге, алкынлыгы кешеләрдән зур кайгыртучанлык таләп итә икән ләбаса! Без, кешеләр, мәсьәләнең бу ягын тәмам онытып җибәргәнбез. Иделдән мөмкин булганны умырып алу ягын гына чамалыйбыз. Елгага ярдәм итү турында уйлаучы ифрат аз.

Казан кунаклары башкалабызның соклангыч күренешенә таң калалар: «Карасана! — диләр. — Шунда ук Кабан күле, шунда ук киң Иделе, яр буенда текә таулары, бөдрә урманнары, серле утраулары!» Хәтта газеталарга язып чыгалар. Гаҗәпләндергәне шул: әле бүгенге көннәрдә дә «Татарстанның башкаласы танымаслык үзгәрде! — дип соклanулар дәвам итә. — Идел Кремль диварларына кадәр килеп җитте. Казан чын мәгънәсендә Идел каласына әйләнде...» (С. Донской. «Вечерняя Казань», 1987 ел).

Шулай соклана-соклана Иделнең һәлакәтенә шаһитләр булырбыз дип кем уйлаган?! Яңа кысага куылган киң Иделнең холкы үзгәрүен Казанда элек-электән яшәгән кешеләр тиз сизделәр. Язгы ташу вакытында боз агуын карарга йөрүчеләр бетте. С. Донской мәкаләсендә телгә алынган «Маркиз» атавы да 1956 елда су астында калды. Бу утрау казанлыларның иң яраткан ял итү урыны иде. Аңа «Волгарь» пароходына утырып барасың. Аның борылып килүен көтәр чамаң булмаса, унбиш-егерме тиенеңне түләп, ишкәкле көймәче ялларга да мөмкин.

Комлыкта палатка сыман нәрсә дә корып куясың. Балыкчылар затлы балык сатып йөри. Казан асып, шулпа пешерергә яки балык кыздырырга да ярый иде. Әрәмәлектән карлыганын, кура җиләген, файдалы үләннәрен уч тутырып җыеп чыгасың да хуш исле чәй кайнатасың. Болай мәшәкатьләнәсең килмәсә, рәхим итеп, җәйге ресторанга кер! Ял көннәрендә оркестр да уйный хәтта. Бие, җырла!..

Яр буенда да тормыш башка иде. Шулпада пешкән, кыздырылган балыклары белән дан тоткан ашханәләр-фәләннәр... Бәйләм-бәйләм сатыла торган кипкән балыкны малга да санамыйлар. Аңа игътибар итсәләр дә, балык сыртын кояш яктысына куеп, тикшерәләр: «Үтәли күренәме? Майлымы? Тозы артык түгелме?»

Хәзер кипкән балыкны кибеттән, көндез чыра яндырып эзләсәң дә, таба алмыйсың. Мәрсин балык турында әйткән дә юк. ГЭСлар салып, Куйбышев сусаклагычын булдырганнан соң Иделдә балык нык кимеде. Кибетләребездә елга балыгы бөтенләй күренми. Хәтта балык кибетенә исемне дә «Океан» дип куштылар. Менә шулай, Иделебез киңәйде киңәюен, тик балык кына яратмады бу ясалма «киңлекләр»не...

С. Донскойның «Вечерняя Казань» газетасында басылган мәкаләсе минем күңелне шуңа күрә борчыды да — авторга суның зураюы бик ошаган! Әйтерсең лә һәр зурлык, һәр киңлек фәкать яхшылыкка илтә?! Хәер, бер әлеге хәбәрче генә түгел, зур-зур рәссамнар да, язучылар да Иделдәге яңарышларга заманында мәдхия җырлады. Елганың киңәюе тирә-юнь мохитенә ничек тәэсир итәчәк — болар хакында ул чакта берәү дә уйланып тормады. Татарстанның 24 районына кагылышлы җирләр су астында калды. Уңдырышлы җирләрне, көтүлекләрне, печән болыннарын әйтеп тормастан, кешеләр яшәп ята торган 137 авылны күчерергә туры килгәнлеген искә төшерү генә дә укучыга күп нәрсә аңлатыр. Казанны су басудан саклау өчен нинди кыйммәтле корылмалар ясалды!

Ә нәтиҗә? Нәтиҗәдә, Идел ел саен... саега бара. Су, бер караганда күп һәм гомергә җитәрлек кебек. Идел биниһая киң булып күренә, әмма асылда ул буеннан-буена, тереклек суы булудан бигрәк, пычрак су җыелмасына, төрледән-төрле авырулар чыганагына әйләнеп бара. Елга хәзер үзен-үзе сафландыра алмый башлады, чөнки агыш тизлеге ясалма рәвештә тоткарлана. Рыбинскидагы су Волгоградка элек илле тәүлектә килеп җитә торган булса, хәзер моның өчен ел ярымлап вакыт кирәк. Димәк, елга үзен-үзе сафландыру сәләтен җуйган.

Иделнең язмышы шушы хәлендә калса, гомум һәлакәт озак көттермәячәк. Бу хәвефле янауга колак салып, илдә «Иделне коткару җәмәгатьчелек комитеты» төзелде. Комитетның эшенә һәрьяклап ярдәм итү һәрберебезнең изге бурычыннан саналсын иде!

## Флүс Латыйпов

# «ЯКТЫ ЮЛ»НЫҢ ЙӨЗЕ ЯКТЫ

Бүгенге авыл. Аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге...

Ил тарихы, халыкның тормыш дәрәҗәсе авылдан аерылгысыз. Авыл бай, тук һәм җитенкелектә яшәргә тиеш. Шунда гына ил тулаем бай була ала торгандыр. Ач крестьян янында тук эшче була алмый. Әгәр була икән, бу җәмгыятьтә социаль гаделлек юкка чыгарылган, тигезсезлеккә юл куелган дигән сүз. Шушылар турында уйланып йөргән көннәрдә кулыма кечкенә генә бер китапчык килеп эләкте. Кул яссуы хәтле генә, кызыл ефәк белән тышланган, яхшы кәгазьгә басылган затлы китап иде ул. Тышына «И. Сталин» дип язылган алтын йөгертелгән металл пластинка беркетелгән. Титул битендә кызыл хәрефләр белән мондый юллар язылган: «ВКП(б) ҮК эше турында партиянең XVII съездына отчет докладыы». 1934 елда Партиздат нәшриятында чыгарылган бу басма илебездәге колхозлашу елларын чагылдырганлыктан, кызыксынып битләрен актарырга керештем. Игътибарымны бер таблица җәлеп итте. «Совет халыкларының атасы» крестьяннарның хәле чәчәк атуны съездда мондый саннар белән раслаган. 1929 елда илдә атлар саны 34 миллион булса, 1933 елга, ягъни коллективлаштыру тәгәлләнеп килгән чорга ул 16,6 миллионга «җиткән», мөгезле эре терлекләр саны 68,1 миллион баштан 38,6 миллионга, сарык һәм кәҗәләр саны 147,2 миллионнан 50,6 миллионга, дуңгызлар 20,9 миллионнан 12,2 миллионга калган. Дөрес, крестьяннарның күпмесе юк ителүе, күпмесе туган җирләреннән сөрелүе әйтелми, илдә сыйныф булярак кулакларның бетерелүе исә тантаналы төстә игълан ителә. Инде шуннан бер цитата китерим. «Кулак кабаласы бетү белән авылда хәерчелек тә бетте. Әгәр дә намуслы эшләргә теләсә, ялкауланмаса, сукбайланмаса һәм колхоз байлыгын урламаса, хәзер теләсә кайсы крестьян, колхозчы яисә аерым хуҗалыкчының кешечә яшәү мөмкинлеге бар».

Ленин декреты белән күптән түгел генә җир алган, инде, ниһаять, ипигә тиенермен, дип өмет иткән авыл агаеның ул еллардагы халәтен аңлау кыен түгел. Иөз еллар, мең еллар буена иген иккән, газиз туфракны тир белән сугарып уңыш үстергән, шушы ихтыяҗ канына сеңгән кешедә җир хуҗасы булу, җир кайгысы белән яшәү тойгысы әнә шул елларда әкренләп сүндерелә башлый. Аннан соңгы чор барыбызга да мәгълүм.

«Халыклар атасы»ның бер каләм тибрәтүе белән көнлекчегә әйләндерелгән колхоз агае «кешечә яшәү» генә түгел, әле бик озак ипигә тиенә алмый. Офыкта гарасатлы 1941 ел. Ил өстенә ябырылган фашист өерләре. Фронтта газиз ирләрнең, әтиләрнең, абыйларның кырылуы. Авылларда ачлыктан шешенә башлаган балалар, көч җитмәс авыр хезмәт, михнәт. Үстерелгән икмәк кырып-себереп фронтка озатыла. Барысы да җиңү өчен! Иң элек фронтны туйдырырга кирәк. Ирләр дә, крестьянның беренче таянычы атлар да фронтта. Сабанга сыер, алар янәшәсенә хатын-кыз җигелә. Кавырсыннары да катып җитмәгән ир балалар сабан тота. Ярый әле табигать мәрхәмәтле! Кесәсеннән чыккан бер уч борчак яисә арыш өчен «кәтер» китәсе үсмерләрне, бүген без табынырга тиешле, вакытыннан элек картайган корткаларны ул саклый. Яз җитү белән кузгалак баш төртә, юа күренә башлый, балтырган, кәҗә сакалы җитешә. Болар колхозныкы түгел, күпме җыйдың дип кесәңне капшаучы, тентүче юк. Аннан соң җиләк, шомырт, карлыган, миләш, балан, чикләвек...

Сугыштан соңгы еллар да авыл кешесенә мантырга ирек бирмәде. Үзе бер гомергә тиң, иксез-чиксез тоелган дүрт елда колхоздан да, авыл кешесеннән дә сыгасы сыгылып, алынасы алынып, туздырыласы туздырылып беткән иде инде. Шул елларның авыр мирасы булып колхоз председательләрендә, бригадирларда усал холык, ке-

шене талап, куркытып эшләтү гадәте калды. Аш күрмәгән җирләр ачыкты, болай да чимегән мал-туар кырылды. Инде көчләп, куып эшләтү генә дә файда бирми. Болар турында сөйләгәндә, хәтеремдә ирексездән балачак хатирәләре яңара.

...Башлангыч классларда укыганда мин урман арасына посып утырган авылга җәй саен әбием янына кунакка кайтып йөри идем. Өченче-дүртенчеләрдә укыган чак булгандыр. Кайтуга мине малайлар чолгап ала. Алар өчен мин — кунак, район үзегеннән генә булсам да, шәһәр малае. Чөнки районда «милитсиә бар, төрмә бар, бүлнис белән әптик бар, олы-олы кибетләр, урысча укыта торган таш мәктәп бар. Бөтен күрсәтмә-фәлән районнан килә».

Көннәрдән беркөнне чикләвеккә барырга җыендык. Малайларның миңа чын урман күрсәтәсе дә килә иде бугай. Чикләвек котырып уңган ел иде ул. Әбием кечкенә генә киндер капчыктан, почмакларына агач тыгып бәйләп, биштәр ясап бирде, аны ничек итеп төйнәргә, аркага асарга өйрәтте. Күрше малайлары белән көтү куганда ук юлга чыгарга килешендек. Әмма дә чикләвекле җиргә эләктек! Кәшәнкесеннән аерып, чүмләп, менә дигәннәрен — чәйнәгән саен сыгылып мае чыга торган иң тук чикләвекләрне генә җыйдык. Басу юлыннан күпме барганбыздыр, күрше малае Мөдәррис колакны ярып, курыккан тавыш белән кычкырып җибәрмәсенме:

— Беттек! Председатель килә!

«Нигә беттек, нигә председательдән куркырга тиеш, ди без?» Боларны аңлап та өлгермәдем, сөрелгән җир буйлап, безгә турылап, чыбык тарантаска җигелгән айгыр өстебезгә ажгырып килә иде.

— Капчыкларны эскерткә!

Монысын кем кычкыргандыр, белмим, әмма малайлар, тилгән куркыткан чебешләр тавык янына йөгергән кебек, юл өстендәге эскерт янына ташландылар, ашыгып, кабаланып, калтыранган куллары белән капчыкларын салам эченә күмәргә тотындылар. Каушавымнан нишләргә белми торган арада, Мөдәррис капчыгымны тартып алды, үзенеке янына ташлап, салам ишеп төшерде дә кулымнан тартты:

— Чаптык!

Урманга карап йөгерәбез. Анда барып җитсәк, котылдык дигән сүз.Чикләвек куаклары, чытырманлык арасында җигүле айгыр белән куып булмый. Йөрәк дөп-дөп тибә, сулуым кысылды, җитмәсә эчкә кату төште. Башымны һаман бер сорау бораулый: нигә чабабыз соң, председатель безне нишләтәчәк?

Менә артта ат тоягы тавышы көчәйде, чыбык тарантасның шыгырдавы ишетелде, аны күмеп, зәһәр сүзләр дә килеп җитте:

— Анагызны фәлән иткерләре!..

Менә егылам, менә егылам дип, сөрелгән йомшак җир өстеннән элдертәбез. Инде барып капландым дигәндә генә, аркамны чыбыркы очы яндырып үтте һәм, шул мизгелдә соңгы ыргым белән атылып, коткаргыч урман авызына килеп кердем. Малайлар төрлесе төрле якка сибелде. Председательнең сүгенә-сүгенә эскерт янында казынганын озак карап тордык.

Соң гына кайттык. Әбием инде хәлне белә икән. Аны-моны дәшмәде, тик: «Бугазына тыгылсын, әйдә», — дип кенә куйды. Икенче көнне капчыкларны килеп алырга дәштеләр. Әбием буш капчык күтәреп кайтты.

Еллар үткәч кенә белдем, тугыз-ун яшьлек ул малайлар колхоз эшенә йөрергә тиеш булган икән. Председатель шуңа җенләнгән.Ә чикләвекләребез — колхоз файдасына конфискацияләнгән булып чыкты.

Үзем тир түгеп, көч куеп җыйган хәләл ризыгымны авызымнан беренче тапкыр әнә шулай тартып алдылар. Ә еллар буе таланып килгән колхоз кешесе нишләргә тиеш? Ипи үстереп ипиcез яшәгән кеше нишләсен?

Мәңгегә җиргә беркетү өчен паспортсыз калдырылган, ягъни хокуксызландырылган авыл кешесенең теләсә нинди юл белән читкә чыгып китәргә омтылуы, үз авылында, туган җирендә күңел биреп эшләмәве дә бүген, хакыйкатькә күзебез ачылган чорда, аңлашыла булса кирәк. Озак, ай-һай, озак дәвам итте бу хокуксызлык! Авыл кешесенең күңеле җирдән бизде, мал асраудан бизде. Авылдан качып котылганнар шәһәрләргә барып егылды, иң дәрәҗәсез кара эшкә алынды: урам себерде, көрәк белән җир казыды, тулай торак, дымлы подвал, сипушка дип атала торган землянкаларда оя корды. Беркемнән дә сер түгел, әле алтмышынчы елларда гына да берәүне кимсетәсе, мәсхәрәлисе килсә, шәһәр кешесе иренен кыйшайтып: «Һи, колхозник!» — дияр иде. Рәсми власть тарафыннан хокуксызландырылганнарны кала мещаннары, обывательләр үзләреннән берничә баскычка түбәнрәк саный башлады. Кемгә дә булса: «Һи, эшче» яки «Һи, бухгалтер», — дип әйтеп кара, ул күкрәген киереп, «Әйе шул, бухгалтер шул!» — дияр. Һәм мактануы белән мең тапкыр хаклы булачак. Ул иртәнге тугызда гына конторына барып утырыр, алты тулар-тулмас: «Уф, арыдым», — дип, кайтып китәр һәм... окладында каралган фәлән йөз акчасын каерып алыр. Ул елларда

колхозчыга түләүне исә ташка үлчим!.. Әнә шулай итеп, озак еллар дәвамында җир йөзендәге иң изге, иң кадерле хезмәткә — игенче хезмәтенә, терлекче хезмәтенә түбәнсетеп карау тәрбияләнде. Җир кешесе җирдән аерылды. Авылда калганнар да үз юлын тапты — ир-ат балта эшенә маһирланды, калайчы, мич чыгаручы һөнәрен үзләштерде. Алар җәен эленке-салынкы булса да колхозда йөриләр дә, көз керүгә, балталарын билбауга кыстырып чыгып китәләр. Аларны җәйгә кадәр авылда күрермен димә...

«Якты юл» колхозы председателе Хәмит Гәрәев белән очрашканда без болар турында шактый озак сөйләшеп утырдык. Декабрь азаклары иде. Тышта егерме биш градуслар тирәсе суык. Чыгуга ук тынны куырып ала. Ә ак кирпечтән салынган идарә бинасының икенче катындагы бу бүлмәдә җылы, уңайлы. Зур кисмәкләргә, чүлмәкләргә утыртылган бихисап гөлләр, исемнәрен дә белеп бетергесез ниндидер үсемлекләр, кактуслар өйдәгечә уңайлылык тудыралар иде. Ашыкмый гына әңгәмә җебен сүтәбез. Ара-тирә баш экономист Наил Сәгыйтҗанов кереп чыга, партия оешмасы секретаре Мөхәммәт Гыйниятов күренеп ала. Өстәл янында сөйләшү җайланмасы телгә килә, телефон шылтырап куя. Барысы да гадәти, һәр колхоздагыча... Хәер, алай микән?! Шунысына игътибар итми кала алмадым, Хәмит Гәрәев боерык бирми, ә киңәш иткән сыман дәшә.

— Хәмит абый, иртәгә Малмыжга чыгып кирәсе иде! Вак таш кайтарасы бар...

— Хәмит Гәрәевич, Мари-Төректән килгәннәр. Вика орлыгын коелмый торган бодайга алыштырмассызмы диләр...

Беткәнмени хуҗалыкта хәл итәсе мәсьәләләр! Председатель исә күзләрен кыса төшеп, сөйләүченең күзенә туры карап тыңлый да тавышын күтәрми генә киңәш бирә:

— Барыгыз, бар. Язга чыкканчы ташып бетерергә кирәк.

— Уйлашыгыз. Безгә кирәкме икән? Күршеләргә ярдәм итми булмас. — Аннан елмаеп өстәп куя: — Күрше хакы — алла хакы диләрме әле?..

Күзгә күренми торган зур, катлаулы механизмның нерв җепселләре шушы бүлмәгә килеп тоташканлыгын, без сөйләшеп утырган арада «Якты юл» колхозы» дип язылган машиналарның төрле йөкләр белән авылга ашыгуларын, күрше бүлмәдә тугандаш республикадан килгән белгечләр белән сөйләшү барганлыгын — кыскасы, кыш көнендә дә хуҗалыкның тыгыз хезмәт белән яшәвен аңлап алдым. Аңладым да, шундый вакытта комачауламыйм микән дип, уңайсызланып куйдым. Уйларымны сизгәндәй, председатель миңа карап, көлемсерәп куйды.

— Ни эшләсен үзләре беләләр алар. Мөстәкыйльлеккә өйрәнгәннәр. Вак-төяк белән кермиләр. Үзләре хәл итәләр.

Әңгәмәбезнең очын югалттык ахры, дип шикләнергә дә өлгермәдем, берни дә булмагандай, ялгап та китте:

— Кайда калган идек әле... Шабашниклар мәсьәләсе... Безнең якларда ул бер афәткә әйләнгән иде. Үзегез беләсез, безнең җирләр артык уңдырышлы түгел, соры туфрак. Уңыш начар. Иң әйбәт дигән елда да унбер-унике центнердан артмый. Әле дә хәтерлим, бер елны унбиш центнер алган идек. Авыл халкы шаккатты, мондый иген дә булыр икән, дип. Менә шул, ир-атны авылда тотып булмый, аларны ай күрде, кояш алды дигәндәй. Егетләр армиягә китәләр дә, аннан соң авылга кайтып күренсә күренде, күренмәсә юк. Еландай телләреңне чыгарып ялынсаң да, хан сарае вәгъдә итсәң дә калдыра алмыйсың аларны. Буш сүзләрнең ни икәнен белеп бетергәннәр инде. Кызлар китә башлады. Кайчандыр өч йөз йортлы авылда сөрәеп йөз илле өй утырып калды.

Иөрәген бер генә тапкыр әрнетмәгән, күрәсең, Хәмит Гәрәев әле моннан утыз еллар элек авылда хөкем сөргән аяныч хәлне бәйнә-бәйнә сөйли... Кышкы көннең озынлыгы — бер саплам. Бүлмәгә кичке эңгер сеңде. Утны яндырырга да онытып истәлекләргә биреләдек. Аның басынкы тавыш белән, сүзнең егәрен белеп сөйләгәненә сокланып, вакытның үткәнне сизелмәде дә. Үзем тыңлыйм, ә күз алдымда бер-бер артлы вакыйгалар туа, кеше язмышының кабатланмас сәхифәләре ячара...

...Киров өлкәсендәге Чавал авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап кайтканда Хәмиткә егерме яшь кенә иде әле. Кесәдә агроном дипломы, күңелдә исә канатлы хыяллар. Алабута, әрем, билчән, эт эчәгесе баскан басуларны рәткә кертәсе, фәнни нигезләнгән чәчү әйләнеше булдырасы, суыкларга да, корылыкка да чыдам, яхшы токымлы орлыклар юллыйсы бар. Алдагы эшләрнең иге-чиге юк.

Әле яңа мыек төрткән, урта буйлы, каратут йөзле, хәрәкәтчән егетне авылдашлары әле иген басуларында, әле ферма янында күрәләр. Кышын да, җәен дә тынгы белми ул. Тик озын-озак балачакның бетмәс-төкәнмәстәй тоелган газаплы елларында ташландык хәлгә диярлек килгән җирләрне тиз генә адәм рәтенә кертермен димә. Хуҗалыкның техникасы юк. МТС механизаторлары өчен «Якты юл» ни дә, күрше «Активист» ни! Җирне ермачлап чыгалар да — вәссәлам. Анда ни үсә һәм,

гомумән, үсәме — моңарда аларның кайгысы юк. Бөтенесе дә колхоз җитәкчеләре, белгечләре өчен җәфа. Җирне тиешенчә эшкәрттерү, уңышның үстерелгән кадәресен бөртегенәчә җыйнау өчен күп тырышты Хәмит. Күбрәк эшләгән, башын ваткан саен бер нәрсәне ныграк аңлый барды — инде техникум белеме генә җитми икән. Кайчандыр имана җирендә бер түтәрәм тары, арыш, бодай иккән, бөтен хуҗалыкны үз тәҗрибәсеннән чыгып алып барган крестьян заманасы үтеп бара. Хәер, ул тәҗрибә дә инде онытылган. Кайчан, ничек, нәрсә чәчәсен дә, күпме чәчәсен дә, нинди ашлама кертәсен дә районнан җиткереп торалар. Әйтерсең, мәктәп бетергәннән соң комсомолда эшләгән, кайдадыр курслар тәмамлаган һәм район аппаратында ыштан төбе туздырган функционер фәлән басуның нинди матдәләргә мохтаҗ икәнен шушы җирдә бөкресен чыгарган, үзе генә түгел, ата-бабасы, нәсел-нәсәбе маңгай тире түккән игенчедән яхшырак белә! Ашлыкны күбрәк үстерим, уңышны мулрак алыйм дисәң, ата-баба тәҗрибәсенә дә, фәнгә дә таянырга кирәк. Белем кирәк! Ә еллар үтә тора. Агроном булып эшли башлаганга да тугыз ел үтеп киткән... Җирдән, туган авылдан, өметләрен аңа баглаган авылдашларыннан аерыласы да килми. Тәвәккәлләп, Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетына укырга керә. Читтән торып уку җиңелдән түгел. Бигрәк тә авыл кешесенә. Аның шәһәр кешесе белмәгән мең мәшәкате, тавык та чүпләп бетерә алмаслык үз эшләре бар. Озакламый Хәмитнең тәрҗемәи хәленә үзгәреш кертәчәк тормыш агымы башлана: чәчү, печән өсте — сессия; урак өсте, дәүләткә ашлык тапшыру — сессия; орлык әзерләү, язга әзерләнү — сессия... Көндезләрен кырда, идарәдә, кич янсә төнлә — өстәл янында, дәреслекләр, конспектлар арасында.

Халыкта бик тапкыр, тирән мәгънәле мәкаль бар: «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык күрер, халык күрмәсә — балык күрер». Бөтен барлыгын туган авылына, игенче хезмәтенә багышлаган Хәмитне дә авылдашлары инде күптән күреп өлгергәннәр, кирәк чакта үз-үзен аямый эшли белүен мыекларына чорнап куйганнар икән. 1969 елда, әле институтның дүртенче курсында укып йөргән чагында, егеткә хуҗалыкны үз кулына алырга тәкъдим итәләр. «Алда дәүләт имтиханнары тора, укыйсы бар», — дип икеләнә-шикләнә, әмма риза була. Моның авылдашлары күрсәткән ышанычы кына түгел, ә бәлки үзенә йөкләнгән авыр, бик мәшәкатьле җаваплылык икәнен дә яхшы аңлый Хәмит.

Яңа сыйфатта беренче эш көне...

Идарәгә барганда авыл өйләренә беренче кат күргәндәй гаҗәпләнеп карый. Һай, бигрәкләр дә тузган икән шул авыл. Йортларның күбесе салам түбәле, ихаталар ярымҗимерек, фермалар иске. Идарә үзе дә кайчандыр кулак дип сөрелгән хәлле авыл агаеның борынгы йортына урнашкан. Сөенер әйбер аз!

Хисапчы өстәлгә еллык эш йомгакларын кертеп сала. Ниләр бар? Яңа елга нинди мая туплап атлыйбыз? Хәер, нинди мая!? Хуҗалыкның ике миллион ярым сум бурычы бар, сыерлардан уртача савым 2 700 килограмм тәшкил иткән, бөртеклеләрнең җыемы — гектарыннан 11 центнер...

*Егерме яшендә егетнең кулына көч керә,*
*Утыз яшендә егетнең кулыннан эш килә...*

Хәмитнең ул чакта әле утызны гына тутырган чагы икәнен онытмыйк. Нәкъ менә кулыннан эш килә торган чак! Егерме елдан соң, бүгенге көн биеклегеннән карап фикер йөртү җиңел. Инде кырыкка җитеп килсә дә ата-ана җилкәсеннән төшмәгән инфантиль ир-атлар, егерме яшендә балага саналучы ир-егетләр заманында кырыкмаса-кырык йөкне үз җилкәсенә алган председательнең эшне нидән башлавын күз алдына китерүе кыен. Барлы-юклы биш-алты ел эчендә уртачадан түбән хуҗалыкны районда алдынгы, республика күләмендә танылган колхоз итәр өчен ни кадәрле рухи, матди һәм әхлакый көч кирәк?!

Хәмит энекәштән — Хәмит абыйга, кемнәрдер өчен Хәмит Гәрәевичкә әйләнгән председательдән мин беренче итеп шуны сорадым.

— Нәрсәдән башладыммы? — дип сорауга сорау белән җавап кайтарды ул һәм үзалдына көлемсерәп куйды.— Бер сүз белән әйтү кыендыр. Әмма шунысын беләм — иң элек кеше турында, колхозчы турында кайгыртудан башладык. Монысын тәгаен белеп әйтәм. Ир-атка эш җитмәгәнлеген беләбез, аларның елның күп вакытын шабашкада үткәрүен туктатырга кирәк иде. Менә шуннан башладык та инде. Яңадан бурычка керсәккердек, әмма шул елны ук авыл уртасында клубка нигез салынды. Шабашникларның күбесе озын берлек эзләүче түгел, ә бәлки аптыраганнан чыгып киткән кешеләр. Гаиләне туйдырырга кирәк бит!.. Аларны бригадага тупладык. Соңрак балалар бакчасы, фермалар, кибет, мәктәп төзергә керештек, идарә белән авыл советы бинасы сала башладык. Хәзер менә төзүчеләр җитми. Аларны махсус укытып кайтарабыз. Колхозга ташчы да, сы-

лаучы да, бетончы да, буяучы да, сантехник та кирәк. Шәһәрдәге кебек...

Хәмит Гәрәев сөйләгәндә барысы да җиңел, шома баргандыр сыман тоела. Әкият тәге тылсымлы таякны селтәү белән Куныр авылы уртасында зәвык белән салынган бина лар пәйда булгандыр, шабашниклар сүз дә әйтми колхозның иң алдынгы, авылпәрвәр кешеләренә әйләнгәндер кебек. Юк! Алай булмаган. Чир китә, гадәт кала, ди бит. Гадәтләрен куучылар да булган. Авыл кешеләре, колхоз белгечләре, Хәмит Гәрәев үзе дә озак елларга сузылган кара дәгъваны яхшы хәтерли, ул гына да түгел, республика матбугатында уелып калган язмалар бар. Аларның берсе — «Казан утлары» журналының 1986 елгы 6 санында.

Кабатлап әйтәм, авыл халкы Хәмит Гәрәевне чын күңелдән олылый, хөрмәт итә. Яше дә, карты да... Монысын үзем күрдем.

*Кырык яшендә егеткә аң керә,*
*Илле яшендә егеткә дан килә.*

Бу хөрмәт, олылау, дан килгәнче күпме газаплы уйлар, җиңел кәсепкә өйрәнгәннәр белән бәрелешләр, рия саклаучылар белән аңлашулар булмагандыр. Анысын да мин белмим. Хәмит Гәрәев тә, авыл кешеләре дә бу турыда сөйләргә яратмый. Үткән — беткән! Ә мин күргәнемне язам.

Куныр урамы буйлап атлыйбыз. Өйләдән соң тагын суытып җибәрде. Авыл өстенә тымызык томан төшкән сыман. Аяк астында кар шыгырдый. Морҗалардан чыккан төтен баганалары туп-туры күккә үрли.

Кунырның үзәгендә киң, төзек мәйдан оешып килә. Олы юлдан кергәндә сезне иң элек халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукайга куелган биек, ак сын каршы ала. Арырак — сугышчы һәйкәле. Янындагы таш диварга Бөек Ватан сугышында ил азатлыгы өчен корбан булган якташларның исемнәре уелган. Шушында ук киң иркен ихатада яңа унъеллык мәктәп, ашханә, юлның икенче ягында ике катлы балалар бакчасы, хуҗалык әйберләре, кызыл мал, азык-төлек кибетләре, идарә... Барысы да ап-ак кирпечтән, кайбер авыллардагыча әвеш-тәвеш китереп түгел, ә бер җепкә тезгәндәй тигез һәм сылу итеп салынган. Болары — колхозның барлык кешеләре өчен уртак корылмалар. Әле тагын һәр гаиләне, аерым һәр кешене күздә тоткан төзелешләр дә байтак. Авылда яшьләр урамы үсеп килә. Колач җитмәстәй юан нарат бүрәнәләрдән менә дигән йортлар калка. Тагын бер нәрсә игътибардан читтә калмый, урамдагы һәр йорт янында диярлек каезланган чиста нарат бүрәнә өемнәре. Димәк, анда кешеләр җитенкелектә яши, йортын, каралты-курасын, мунчасын, йә булмаса өен тагын да киңәйтергә, тагын да яхшырак итәргә исәп тота, бүгенге белән генә түгел, ә иртәгәге көн белән, алга карап яши. Шуларны уйлап, эчтән күтәрелгән сөенү хисенә канатланып атлыйм. Уйларымны Хәмит Гәрәевнең басынкы тавышы бүлде:

— 1988 елда дүрт йорт җиткердек. Өчесе бүрәнәдән, берсе агач щитлардан — типовой йорт. Ел саен шулай. Бура күтәрмәгән ел юк...

— Аларны кемнәргә бирәсез соң?

— Өчесенә яшь гаиләләр күчте, берсен ялгыз пенсионер карчыкка бирдек. Озак еллар колхоз хуҗалыгында көч түккән, аны үстерү өчен хәләл хезмәтен кызганмаган һәр кеше карт көнендә безнең кайгыртуга мохтаҗ. Картлар турында кайгырту — ул безнең бүгенге яшьләребез турында, хуҗалыкның бүгенге эше һәм киләчәге турында да кайгырту дигән сүз.

«Картлар турында кайгырту — колхозның киләчәген кайгырту ул». Беренче карашка сәер тоелган бу раслауда гаять тирән мәгънә ятканлыгын бераздан гына аңладым.

— Менә карагыз,— дип дәвам итте председатель,— хәзер колхозда, Куныр һәм Шода авылларында бер мең ике йөзләп кеше яши. Шуларның өч йөз сиксәне — колхозчы, ягъни эшкә йөри торган кеше. 17-30 яшьлекләр — егерме биш проценты чамасы. Әгәр бүген армиядән кайткан һәр егетебез диярлек авылда кала икән — бу әнә шул картлар турында кайгыртуыбыз, аларга һәрьяклап ярдәм күрсәтүебез нәтиҗәсе. Киләчәген, картлыгын уйламаган кеше юк. Һәрхәлдә, булырга тиеш түгел. Яшьләр монда кайта, күрә — син эшләгән чакта гына түгел, ә картайгач, ялга чыккач та шушы күмәк хуҗалыкның тулы хокуклы әгъзасы буласың икән...

Олы бер гаиләгә әйләнеп баручы күмәк хуҗалык өчен авылда яңа гаилә оешу да, дөньяга килүче сабый да уртак шатлык. Хәмит Гәрәевнең сүз төбендә яшерен горурлык ярылып ята:

— 1985 елда егерме, 1986 елда ун яңа гаилә төзелде. Куныр чишмәләренең суын эчеп үскән яшьләребезнең чәчләре чәчкә бәйләнде, мәхәббәтләре туган якларында бөреләнде. Ничек сөенмисең, шул 1986 елда гына да егерме биш сабый, дөньяга килүен белдереп, тәүге кат тавыш бирде... Инде хәзер балалар бакчасында урын җитми башлады, аңа янкорма салабыз.

Гаилә корган яшьләргә бирелгән йорт бәясенең яртысын колхоз түли, калган акча бурычка биргән булып исәпләнелә һәм яшьләр аны акрынлап, егерме ел дәвамында түли алалар. Һәр җиткән егет, һәр кыз турында шулай кайгырту үзенең матур нәтиҗәләрен бирми калмаган, әлбәттә. Хуҗалык эшче куллар белән тулысынча тәэмин ителгән, һәр тармакта — авылның үз белгечләре. Хәтта «Читтән кеше алмаска» дигән махсус карар чыгарырга мәҗбүр булганнар.

«Якты юл» — экономик яктан көчле, тотрыклы хуҗалык. Шулай да аның тагын да үсүе, ныгуы һәм колач җәюе соңгы елларга — 1985 елның апреленнән соңгы чорга туры килә. Ни өченме? Җавабы беренче карашка бик гади — ниһаять, колхозлар мөстәкыйльлек ала башлады, хезмәтенең соңгы нәтиҗәсе буенча түләү алуга иреште. Хуҗалыкта асрала торган барлык 2600 баш тана да арендаторлар кулында. Кунырда сигез, Шодада дүрт аренда звеносы. Һәр абзар аерым бер коллектив карамагында.

«Якты юл» — махсуслашкан хуҗалык. Моннан 420 шәр килограммлы, нәселле буаз таналар республиканың башка колхоз-совхозларына сатыла. Терлекләр көр, чыдам. Байтак күрсәткечләр буенча «Якты юл» республикадагы төрдәш махсус хуҗалыклар арасында беренче урында тора.

— Сез элек тә республикада иң алдынгылардан санала идегез. Арендага күчү элек үк юлга салынган хуҗалыкка берәр нәрсә өсти алдымы?

— Иң беренче чиратта эшкә мөнәсәбәт үзгәрде,— диде председатель.— Яхшылыкның, тырышлыкның чиге юк бит аның...

— Азыкны сак тоту, һәр нәрсәдә экономиягә омтылу барлыкка килде,— дип өстәде баш экономист Наил Сәгыйтҗанов.

— 1988 елгы корылык хәтердә бик озакка уелып калыр. Бөртеклеләрдән нибарысы 10,1 центнер уңыш җыеп алдык. Ә бит аннан алда — 1986 елда инде 32,7 центнерга җиткерגән идек. Бәрәңге 160 тан 108 центнерга калды. Тамыразыклар шактый кимеде. Азыкны чамасын белеп, сак тотуның әһәмиятен беркемгә дә аңлатып торасы юк,— дип сүзгә кушылды партоешма секретаре Мөхәммәт Гыйниятов.

Алар атаган саннарны, дәлилләрне блокнотыма тезә башладым.

— Быел бик күп вак бәрәңге калды. Шуны терлекчеләргә тәкъдим иткәч, алмадылар. «Юк, бу кыйбат, алмыйбыз»,— диләр. Электр уты, мәсәлән, фермада тәүлек буе яна иде. Хәзер карап кына торалар. Барысы да хезмәт хакына бәйләнгән. Бер центнер артым алу өчен 196 сум акча билгеләнгән. Абзарның ничек җиһазландырылуына, терлекләрнең яшенә карап азык, электр, амортизация һәм башкалар өчен 169 сум чамасы чыгым каралган. Шуннан калган 27 сум эшкә түләүгә тотыла. Чыгым никадәр азрак булса, түләү шулкадәр күбрәк.

Баш экономистның сүзен председатель дәвам иттерде:

— Ләкин хезмәткә түләү мөмкинлекләре әле безне канәгатьләндереп бетерми. Колхозның еллык хезмәт хакы фонды 730 мең сум тирәсе. Гамәлдәге инструкцияләр, финанс документлары нигезендә аны берничек тә үзгәртеп булмый. Әйтик, терлекчеләр гаҗәеп яхшы эшләделәр, ди. Димәк, аларга түләүне дә арттырырга кирәк. Ә безнең андый мөмкинлегебез юк, чөнки инструкцияләр безне чикли. Очсыз-кырыйсыз экономия була алмый. Колхоз хезмәт хакы фондын, матди кызыксындыру һәм түләүне максатка ярашлы күләмдә үзе билгеләргә тиеш. Ни өчен әле мин колхоз эшләп тапкан акчаның һәр тиенен тоту өчен банктан рөхсәт сорарга тиеш? Акыллы хуҗа акчаны кая тотарга икәнен дә, кемгә күпме түләргә икәнен дә үзе билгели ала. Аңа өстән күрсәтеп торуның кирәге юк дип саныйм.

Колхозның экономик күрсәткечләре шундый афәтле елда да шактый ук яхшы. Дәүләткә ашлык, бәрәңге, терлекчелек продуктлары сатуның өч еллык планнары уңышлы үтәлгән. 1988 елда уртача савым бер сыерга 4 мең килограмм, тәүлеклек артым 603 грамм тәшкил иткән. Продукция җитештерүнең үзкыйммәте кими бара. Хуҗалыкның төп эшчәнлеге терлекчелек икәнен онытмаган хәлдә, аларга да күз салыйк. Терлекләрдән бер центнер артым алу 1986 елда 253 сум 70 тиенгә, 1987 елда 273 сум 54 тиенгә төшкән булса, 1988 елда инде ул авыл хуҗалыгы өчен иң уңай килгән сиксән алтынчы елдагыдан да кимрәк була — 252 сумга кала. Зур мәйданнарда игелә торган бәрәңге белән дә шундый хәл: 1986 елда үзкыйммәт 14 сум 19 тиен булса, 1988 елда ул 13 сум 60 тиен. Соңгы елда колхоз 420 мең сум саф табыш алган. Бүгенге көндә «Якты юл»ның 700 мең сум тирәсе запас акчасы бар.

Саннар күбрәккә китте, ахрысы. Ләкин аларсыз да булмый. «Саннар дөнья белән идарә итми, әмма алар ничек — яхшымы-начармы идарә ителүен бик ачык күрсәтәләр»,— дигән гыйбарәне искә төшерү урынлы булырдыр.

Әйе, кайчандыр 2 миллион ярым сум бурычы булган хуҗалык бүген, кесәмдә 700 мең сум запас акчам бар, дип әйтә алсын өчен, саннарны бик белеп санарга, тиеннәрне уйлап исәпләргә кирәк булгандыр. Ә «Якты юл»да нәкъ шулай эшлиләр дә. Моның мисалларын мыңа адым саен диярлек күрергә туры килде. Санау гына түгел, акчаны кирәк

максатка тота да беләләр. Ул һәрвакыт әйләнештә, тиеннәрдән сумнар җыела.

Әгәр Кунырдагы барлык төр эшчәнлекне санасак, күпләр сүзне колхоз түгел, ә нин-дидер шәһәр хуҗалыгы турында бара дип аңлар иде. Әйдәгез, бармакларны бөкли баш-лыйк. «Якты юл»да инде 1977 елдан бирле ак он тегермәне эшләп утыра. Ул — районда бердәнбер. Кайчандыр 20 мең сумга төшереп корылган АВМ-3М маркалы бу тегермән үзен аклау гына түгел, хәзер ел саен колхоз кассасына берничә мең сум табыш китерә. Бер центнер бодай тарту колхоз членнарына ике, читтән килүчеләргә ике сум илле тиенгә төшә. Мари АССР белән Киров өлкәсенең чиктәш күрше районнарында да андый нәрсә юк. Барысы да ашлыгын төяп Куныргa килә. Сменага өч тонна ак он тартыла монда. Ә киләчәктә карабодай ярдыру җайланмасы куярга, колхозда бу культура чәчүне дә әйләнешкә кертергә хыялланалар.

«Якты юл»да тагын асфальт заводы, кулинария цехы, лимонад кайнату участогы, тегү цехы һәм агач эшкәртү цехы бар. Соңгы өчесе әле 1988 елда гына эшли башлаган. Шул ук елда 400 тоннага исәпләнгән заманча бәрәңге саклагыч файдалануга тапшырыл-ган. Анда бәрәңге элеккечә бөтенесе бергә өелеп түгел, ә махсус контейнерларда саклана, махсус приборлар дымлылыкны да, температураны да тикшереп тора.

Эшче көчләре нибары 380 кеше булган колхоз өчен артык күп түгелме болар?

— Юк! Күп түгел. Киресенчә, без тагын яңа төр производство берәмлекләре булды-ру турында баш ватабыз,— диде миңа Хәмит Гәрәев. Һәм үзенә хас саллылык белән са-нарга, аларның авыл кешеләренә китерәчәк файдасы, колхоз кесәсенә бирәчәк табышы турында сөйләргә кереште.

Алары хакында без алдарак сөйләрбез. Ә хәзергә менә шушы кечкенә бер шәһәр ху-җалыгына тиң мәшәкатьнең ни өчен кирәген, аның кешеләргә, колхозга һәм, гомумән, Балтач районына ни-нәрсә бирүен дә күздән кичерик.

«Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттә»,— ди халык мәкале. Кунып һәм Шо-да авылы кешеләре нинди хикмәт көтеп яши?

...Сәүдә үзәгенең азык-төлек кибетенә бераз шикләнә төшеп кергән идем. Безнең Та-тарстан төшенчәләре белән аңлатканда, олы юллардан читтә, «шүрәле каргаган якта» ни генә булыр янәсе. Озак еллар журналист булып эшләү тәҗрибәмнән беләм: мондый авылда түгел, хәтта шәһәр исемен күтәргән җирдәге кибетләрдә дә товар чамалы, ташка үлчим... Еллар буе өелеп яткан минтай консервы, капкачлары күгәрә башлаган пыяла банкалы яшел помидор, серкәгә салынган кыяр яисә кәбестә белән тулган булыр ул. Шуннан башкасын өмет тә итмә. Ә монда? Керүгә аптырый калдым. Ак пластиктан ясалган җыйнак киштәләрдә гәрәбәдәй балкып чәк-чәк өемнәре утыра, кызарып пешкән вак күмәч, алтынсу печенье, бавырсак...

Сатучы кыздан: «Боларны кайдан гына кайтарып өлгерәсез?» — дип сораганымны сизми дә калдым. Ә ул исә Балтач яклары кешеләренә хас тыйнаклык белән елмаеп җа-вап бирде:

— Кайтармыйбыз! Үзебезнеке алар. Кунырда кулинария цехы бар бит!..

Түмен белеп кенә, азлап кына бавырсак үлчәтеп яткан хатыннар сүзгә кушылды:

— Әле бүген артык күп түгел әйбере. Паштет та пешерәләр алар, төрле бәлешләре дә булып тора.

— Кирәксә, алдан заказ биреп пешертеп алабыз. Камыр ризыгына, тәм-томга иф-рат та остардылар хәзер.

Арада әңгәмә башланып китте.

— Сезнең монда шәһәрдәге кебек икән, кибетегезне әйтәм. Цехыгыз зурмы соң, кайчан эшли башлаган иде?

Авыл хатыннары салпы якка салам кыстырырга тырышыбрак биргән соравымны игътибарсыз калдырдылар сыман иде. Ә тел төпләреннән — кылтаймыйча, масаймыйча гына барысын да аңлатып биргәннәрен төшендем.

— Ипине генә Чепьядан ташыйлар. Безнең юллардан кайтып җиткәнче бәрелеп, имгәнеп бетә дигәндәй...

— Анысы да булыр, алла боерса... Үткән җыелышта Хәмит әйтте бит: яңа елга чыккач, пекарня сала башлыйбыз, диде.

— Ул әйтсә булыр,— дип ахирәтен җөпләде сүзне башлаганы.— Менә бу кулина-рия цехын да шулай аһ ормый гына, иплән кенә башлаган иде. Әнә, рәхәткә тиенгәнебез-гә җиде-сигез еллап булыр.

— Әйтәсең бармы!? Җәй буе лимонадка кинәндек. Үзебезнең чишмә суыннан биг-рәк тә тәмле була икән ул.

Лимонад цехы 1988 елның җәендә, сабан туйлары башланыр алдыннан эшли баш-лый. Колхозның баш экономисты Наил Сәгыйтҗанов мондый саннар атады:

— Җәен көнгә бер мең, ә барысы 32 мең 75 шешә лимонад чыгарылды. Аны район авылларыннан гына түгел, күрше Мари АССРдан, Киров өлкәсеннән дә килеп алдылар. Өч кыз эшләде инде ул цехта. Һәр шешәдән өч тиен табыш алып бардык. Менә шул тиен-

нәрдән сумнар җыела инде,— дип көлемсерәп куйды ул.

«Якты юл» колхозындагы мөстәкыйльлеккә, һәр нәрсәнең хуҗалыкка ни-нәрсә бирәчәген алдан уйлап эшләнүенә кайта-кайта сокланырлык. Хуҗалыкка һәм аның экономикасына гына түгел. Иң беренче чиратта — кешеләргә! Тегe яки бу чара, тегe яки бу эшчәнлек авылда яшәүчеләргә нинди уңайлыклар тудыра ала, аларның хезмәтенә, көнкүрешенә нинди җиңеллек китерә?

Язын-көзен кешенең аягыннан резин итек төшмәгән якларны да беләбез. Авыл урамнары танк сугышы узгандагыдай тирән-тирән чокырлар, су тулы тәгәрмәч эзләре белән җәрәхәтләнгән булыр. К-700 тракторына бер капчык он салып, авыл урамыннан җилдереп үтүне күпләр егетлеккә дә саный торгандыр әле. Куныр белән Шодада мондый нәрсә юк! Ул гына да түгел, колхозның үз асфальт заводын ходка җибәргәннәренә инде өченче ел. Былтыр ферма тирәләре, бәрәңге саклау урыннары, ындыр табаклары асфальт белән капланган, быелгы җәйдә чират — авыл урамнарына. Аннан соң кабиналарына «Якты юл» эмблемасы сугылган асфальт җәю машиналары, катоклар Куныр — Балтач, Куныр — Шода юлларына да чыгар. Җәйгә запас туплау — вак таш һәм битум кайтару кыш буе дәвам итә.

Колхозда моңа ничек ирешә алганнар соң? Республика фондларында колхозларга бирү каралмаган ул завод җиһазларын, вак ташны, йөзләрчә җайланмаларны кайдан юнәткәннәр? Кабинетта утырып, өстән кәгазь килгәнне көткән җитәкче өчен мәңге чишеп бетергесез авыр сораулар болар. Чыннан да, гаҗәп бит!

Хәмит Гәрәевнең җавабы исә мин көткәннән күпкә гадирәк булып чыкты:

— Безнең егетләр Мари-Төректән гамәлдән чыгарылган, ягъни списать ителгән АБЗ агрегаты (шул асфальт-битум заводы була инде ул) күреп кайтканнар иде. Шуны алып кайтып төзәттек, җайлап куйдык. Киров өлкәсендә вак таш әзерләүгә килешендек. Битумны Түбән Камадан да, Арчадан да, Кукмарадан да — кайда якты йөз күрсәтәләр, шуннан ташыйбыз,— диде ул ишегалдындагы утынны башка җиргә күчереп өю кебек гадәти бер эш турында сөйләгәндәй. Үзенең күрше өлкәгә, республикага күпме йөрүен, күпме кеше белән очрашып сөйләшүен, килешүен генә телгә алмады председатель. Хәер, аны аңлап була. Балтачлыларның гадәтен үзгәртермен димә.

«Якты юл»ның экономик бәйләнешләре якын күршеләр белән генә дә чикләнми хәзер. Идарәдә миңа яхшы ак кәгазьгә басылган бер килешү кәгазе күрсәттеләр. Анда мондый юллар бар:

«Бер яктан «Росагропромэкспорт» экспорт һәм импорт Россия берләшмәсе, икенче яктан Татарстанның Балтач районы «Якты юл» колхозы түбәндәге договорны төзеделәр шул хакта:

— «Якты юл» колхозы 1988 елда 50 мең данә күләмендә щетка саплары ясау һәм озатуны

— «Росагропромэкспорт» аларны «Новоэкспорт» Бөтенсоюз берләшмәсе аша тышкы базарда сатуны үз өстенә ала»...

Аннан соң һәр ике якның бурычлары, бер-берсе алдындагы җаваплылыклары тәфсилләнгән. Хәер, канцелярия теленең бөтен нечкәлекләрен белмәгән кешегә бу килешү кәгазен аңлау шактый кыен булыр иде. Кыскача мәгънәсе исә мондый: колхоз эшчәннәре Германия Демократик Республикасына әзерләп озатылган көрәк һәм щетка саплары өчен 37 мең сум табыш алачаклар, шуның кырык проценты хуҗалыкка валюта акчасы булып кайтачак.

Дөрес, балта эше остаханәсендә бу шактый четерекле һәм катлаулы эш санала. Шунлыктан яңа станоклар, җайланмалар куярга туры килгән. Анысы белән «Росагропромэкспорт» үзе ярдәм күрсәткән. Шунысы да бар, экспортка чыгасы әйбер җиз иләктән үткәрелә. Әгәр саптагы ботакның диаметры биш миллиметрдан арта икән, ул инде кабул ителми. «Якты юл»лылар монда да башларын эшләтә белгәннәр: экспорт таләбенә туры килмәсә, сапларга себерке бәйләп, Казанга озаталар. Анысын да алучылар көтеп кенә тора. Хәзер исә паркет ясау станогы кайтарту турында сүзләр бара.

Колхоз кассасына акча әнә шулай керә.

Лимонад ясау цехы, тегү цехы, асфальт заводы да әнә шул акчадан юнәтелгән. Тегү цехы турында аерып сөйлисе килә. Бөтенесе дә кеше турында уйлаудан башлана дигән идек. Монда да нәкъ шулай. Хәзергә цехның махсус бинасы юк. Машина-трактор паркында буш торган бүлмәләрне җайлаштырып, шунда сигез тегү машинасы куелган. Куныр һәм Шодада өйдә утырып, үз машиналарында эшләүчеләр дә бар. Кыскасы, технологик яктан барысы да җайга салынган.

Тегү цехы... Якты тәрәзәләр янында электр машиналары келтери. Үзара нидер сөйләшә-сөйләшә кызлар тегү тегә. Ирексездән, Казандагы фабрикаларны күз алдына китердем. Әнә берсе махсус өлгеләр белән кием кисә, икенчесе яңа гына машинадан төшкән жилетның җөйләрен тикшерә... 1988 елның ноябрендә генә эшли башлаган цех ай ярымда ук җитмеш жилет, күп кенә эш бияләе һәм халатлар тегеп өлгерткән.

— Бусы безнең кисүчебез Мәсгудә Сәләхетдинова. Район көнкүреш комбинатында эшли иде, цех ачылгач, авылга кайтты,— дип берәм-берәм таныштыра башлады Хәмит Гәрәев.— Кызларны тегү эшенә дә ул өйрәтте. Әнә теге елмаеп торган чибәр егетебез механик Фәрит Хәкимҗанов булыр. Казанга җибәреп, өйрәтеп кайтардык.

— Тукымалар, сәдәф, каптырма ише нәрсәләр җитәрлекме соң?

— Җитә, барысы да әйбәт,— дип сүзгә кушылды Мәсгудә елмаеп.— Ивановодан егерме биш мең сумлык төрле тукыма алып кайтып бирделәр. Менә жилетка дигәне калын, җылы саклаучан материал. Аны терлекчеләргә дип тегәбез. Болары — механизаторларга.— Һәм ул стенада эленеп торган төрле үлчәмдәге, төрле фасондагы кием үрнәкләрен күрсәтте.

Су үткәрми торган яшькелт тукымадан тегелгән штормовкаларга, җөен-җөйгә, ибен-ипкә китереп тегелгән халатларга, чалбар-курткалы заманча костюмнарга шунда гына игътибар иттем. Алар барысы да мөмкин булганча затлы, сыйфатлы итеп тегелгән.

Эш киемнәренең гадәттә артык тупас, зур үлчәмдә булуын еш күрергә туры килә. Шуны истә тотып: «Болай бик кыйммәткә төшмиме соң ул?» — дип сорап куйдым.

Кызлар сабыр гына елмаештылар. Мәсгудә башын чайкады.

— Юу-ук! Кыйммәт түгел.— Бераз уйланып торды һәм көлемсерәп дәвам итте.— Без бит авылдашларыбызга — үзебезнең әти-әниләргә, абый-апаларга, энеләр-сеңелләребезгә дип тегәбез. Алар барысы да матур булырга тиеш. Әле менә без бу халат, штормовка һәм курткаларга «Якты юл» дигән эмблема да чигәргә сөйләштек. Безнең колхозныкы икәне әллә каян күренеп торсын!

Саннар, экономика мәсьәләсендә Хәмит Гәрәев ярдәмгә килде:

— Кием тегүдән без шактый отыш алачакбыз. Матди отыш кына түгел, әхлакый ягын да онытмыйк. Һәр кешегә яхшы, чыдам эш киеме бирергә тиешбезме? Әлбәттә, тиеш! Менә шул. Әйтик, эш бияләе кибеттән алганда 1 сум 50 — 1 сум 70 тиенгә, кайчакта хәтта 3 сум 50 тиенгә төшә. Ә безнекеләр алтмыш-җитмеш тиеннән артмый. Терлекчеләрнең жилетлары — дәүләт бәясе белән унсигез сум. Безнеке — җиде. Механизаторлар киеме белән дә шулай. Үзебезнең колхоз кешеләрен тиешле үлчәмдәге киемнәр белән тәэмин итеп бетергәч, без аларны башка колхозларга, оешмаларга сатарга җыенабыз. Килере шактый булырга тиеш. Ул гына да түгел, колхоз эшенә йөри алмаган күпме хатын-кыз эшле булды. Анысы да вак мәсьәлә түгел. Шулай бит!

Тегүчеләр белән хушлашып урамга чыгабыз. Куныр өстендә кышкы кояшның сүрән балкышы уйный. Күз күреме ераклыктагы тау битләре, кырлар, авыл үзе калын кар юрганы астында. Озакламый җылы язлар килер, бу якларны яңа ямьгә төрер.

Уйларымны сизгәндәй, Хәмит Гәрәев еракта гы күгелҗем тау битләренә күрсәтте:

— Әнә, чәчүгә яраксыз буш җирләрдә, тауларда дүрт йөз гектарлап урман утырттык. Тагын ун-унбиш елдан Куныр ны танымассыз әле. Яшеллек диңгезендәге утрау кебек булачак ул.

Шәрык халыкларының бер акыллы тәгъбире искә төште: «Иртәгәсен кайгырткан иген үстерер, ун елга алга уйлаган бакча утыртыр, ә инде ерак киләчәген күздә тоткан кеше — бала тәрбияләр». Миңа калса, бүгенгесен, иртәгәсен һәм ерак киләчәген уйлаган кеше генә — зирәк кеше, дигәнне дә аңлата бу мәкаль. Юкса, моның киресен аңлатканы, бүгенге көн белән генә яшәүчене хурлап әйтелгән «Иртәгә өчен ишәк кайгырган» дигәне булмас иде. «Якты юл»лылар исә әнә шулай, бүгенге белән иртәгәне дә онытмыйча, киләчәккә карап яшиләр, эшлиләр, якты хыяллар коралар: иген үстерәләр, бакча утырталар, нәниләре колхоз салган бакчада тәрбияләнә, колхоз корган мәктәптә белем ала.

Үзгәртеп кору шартларында үзләренә ышанычлары, мөстәкыйльлекләре арткан җир кешеләренең яшәү рәвеше, тормышы һәм өмете зурдан. Хәмит Гәрәев һаман тынычлана белми. «Колхозда дүрт буа бар. Аларга карп белән табан балык маймычлары җибәргән идек. Киләсе елда балыкчылыкны арендага бирәсе иде. Әнә элекке сарык фермасы бушап калды. Анда йөз баш нутрия (саз кондызы) асрарга була. «Зверопром»да булган идем, ярдәм итәргә ризалаштылар. Аны асрасак, тегү цехында бүрек тегүне дә җайлап була. Тире иләү остабыз бар. Планнар күп анысы... Менә хәзер үзебезнең профилакторий өлгереп килә, көнкүреш йорты саласы бар. Авылның кер юу пункты булса, начармыни? Хатын-кызлар бер авыр эштән котылыр иде. Үзебезгә махсус теш врачы укытып кайтарырга кирәк...»

Тынгысыз, бик тә тынгысыз кеше Хәмит Гәрәев. Аңа һаман нидер җитми, нидер кирәк, эшлисе, корасы, яхшыртасы бар. Ә андый тынгысызлар булу үзе бер бәхет түгелмени?! Заманыбыз тынгысызлар заманына әйләнеп бара, эзләнүчән тырыш кешеләр заманына. Ә алар уңышка ирешә белә. Шунысы куанычлы, Балтач якларында андыйлар күп. Заманында борынгы Болгарда, Казан дәүләтендә яшәгән һөнәрчән, эшсөяр кешеләрнең турыдан-туры дәвамчылары, рухи варислары алар. Борынгы данныбызны алар яңарта.

# ҖАН ТЫНЫЧЛЫГЫ — ЫШАНУДА

**СССРның ЕВРОПА ӨЛЕШЕ һӘМ СЕБЕР МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ — МӨФТИ ТӘЛГАТ ТАҖЕТДИН БЕЛӘН ЯЗУЧЫ САЛИХ МАННАПОВ ӘҢГӘМӘСЕ**



*Әфганстан. 1988 ел.*

Гомеремдә беренче тапкыр мәчет бусагасын атлап керүем. Җанда, тәндә — ниндидер мөһим бер чикне узу тойгысы... Таш кала гөрелтесе, шалтыр-шолтыр килгән трамвай тавышлары, фани дөнья мәшәкатьләре тышта, бусаганың теге ягында калды. Ә биредә — гасырлар төпкеленнән килгән сыман тирән, уйчан тынлык.

Миңа бүген тагын бер чик сызыгын үтәсе бар. Бөек шагыйребезнең «Туган тел» гимнын да:

*И туган тел! Синдә булган иң элек кылган догам:*
*Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам,*

— дигән юлларыннан башка гына укып үскән буын бит без. «Безнеке генә дөрес» дип, чын күңелдән ышанып яшәгән, бүтән фикердә торганнарны идея дошманы дип, «глушить» итәргә өйрәтелгән буын. Хәер, бер безнең буын гынамы...

Шундый кичерешләр тәэсирендәдер, мөфти хәзрәт белән безнең сөйләшү алдан билгеләнгән эздән бик тиз читкә чыкты. Бәхәскә керешеп китәрдәй чакларда да инде мин аны «төзәтергә» ашыкмадым, бүлдермәскә тырыштым. Ниһаять, безгә бүтәннәр фикерен тыңларга да вакыт! Шуңа күрә, кайчак, читтән караганда, ихтимал, без фикердәшләр булып та күренгәнбездер. Әмма ниндидер күзгә күренмәс чик сызыгы барыбер бар, тик ул безнең икебезнең арадан бигрәк, әгәр шулай әйтергә мөмкин булса — мөфтинең үзе аша, аның уй-фикерләре, хис-кичерешләре, халәте рухиясе аша үтә иде...

Без иң әүвәл Бөек Болгар иленә Багдад хәлифәлегеннән дин алып килгән Ибн Фазлан, гасырлар дәвамында татар тормышын агартуда һәм алга этәрүдә катнашып килгән асыл затлар турында искә алдык. Диннең бүгенге тормышыбыздагы урынына бәйле уй-фикерләр дә шактый җыелган икән. Менә шулай, әкренләп, гәпләшүебез сорау-җавап рәвешен алды.

**Язучы.** Иман, тәүфикъ, вөҗдан... Без бу сүзләрне гамәл буларак та, хәтта төшенчә сыйфатында да онытып бара идек инде... Халыкның күркәм йолаларын һәм ышанулар шигърияten тар-мар иткәндә рухыбызга, әхлагыбызга да зыян килде. Соңгы юлга озату, җир куенына иңдерү тәртибен аңлаткан өчен генә дә тәнбиһ сүзләре ишеттек. Ә инде безне гомер юлы буйлап озата барган рухи бәйрәмнәр — исем кушу, никах туйлары! Заман төсмерләре белән баетасы урында, алар тәмам читкә тибәрелде. Шул бушлык бәрабәренә «тәпи юу», «юл аягына тоту», «баш төзәтү» кебек «яңа йолалар» ныгыды. Шуңа тикле барып җиттек: кабер казучыга ришвәт төртмәсәң, ахырдан «поминка»сы оештырылмаса — адәм баласына үлгәннән соң да тынычлык бетте.

Менә сез, хәзрәт,— мөхтәрәм дин әһеле һәм заманыбызга сизгер мөнәсәбәтле шәхес буларак,— бу хәлләрне ничек бәялисез? Замандашларыбызның кешелеклелек һәм әхлак югарылыгын саклауда нинди юллар күрәсез?

**Мөфти.** Балага матур-аһәңле исем кушу, бишектән төшкәнче үк акны карадан аеру, изгелек белән яшәү юлларын өйрәтү — ата-ана өстендәге иң зур бурыч. Әле без үскәндә дә ипи валчыгын таптамау, өстәл янында әдәпле утыру, өлкәннәргә башлап сәлам бирүнең халыкчан кагыйдәләре, гыйбрәтле тыюлары бар иде. Әбиләр безгә шуны өйрәтәләр иде. Коры сүз белән, үгет-нәсихәт белән түгел, үзенчә бер гыйбрәте, мәсәл-хикмәте бар иде ул гореф-гадәт мәктәбенең. Ризыкны, ата-ананы, олыларны хөрмәтләү — болар гомер-гомердән килгән кануннар ич. Үсеп егет булгач, армиягә киткән вакытында Коръән авазы белән озату, кайткан чагында ил агаларын җыеп шатлык-сөенечләрне бәйрәм итү. Яңа йортка күчсәң дә иң әүвәл шешә түгел, яхшы сүз, икмәк-сый керү. Дөньядан үткән якыннарыбызны бәхиллек белән, тән һәм күңел пакьлеге белән озату. Чисталык-арулык мәсьәләләре, олыны олы итү, ата-бабадан килгән йола-гадәтне бозмау — болар бөтенесе дә халкыбызның канына сеңгән күркәм сыйфатлар иде. Гореф-гадәт законнан да көчлерәк иде. Кызганычка каршы, утызынчы еллардан башлап шул гадәтләрнең күбесеннән без биздек, хәтта үзебез көлеп карый башладык. Ләкин көләрлек хәлләр микән бу?!

Башкалар күзендә безнең әби-бабаларыбыз тән пакьлеге белән, күңел сафлыгы белән танылган. Шуның белән хөрмәтле, абруйлы булганнар. Башка милләт кешеләре дә борын-борыннан үзенә хатынны рәхәтләнеп татар милләтеннән алган. Дин аермасына, тел аермасына карамастан. Шунысы да бар, кемгә кияүгә чыкса, безнең кызлар шулнңча була, аларның җаена ята торган була. Бу үзенә кабатланмас бер күренеш дип әйтергә мөмкин. Шуңарга күрә дә гореф-гадәтләребезне саклау, аларга яңача кыяфәт бирү бик мөһим. Ул безнең милли йөзебезне, рухыбызны саклауга да бер терәк булыр иде.

Без вату-кыру, җимерү белән шулкадәр мавыгып киттек, шулкадәр күп югалтулар кичердек. Шуңа күрә дә, ихтимал, кешеләр кинәнеп яшәсен, бер-берсенә дус, туган булсын дип төзегән җәмгыятебездә дә усаллык, явызлык, үзара дәгъвачыллык, кинә тотышу шулкадәр артты, кешеләрнең күңеле шулхәтле катыланды, зәгыйфькә дә, ятимгә дә, сугыш гарибенә дә каты бәгырьлелек күрсәтү белән адым саен очрашып торабыз. Инде замандашларыбыз миһербанлырак була алмас хәлгә килгәннәр кебек. Утызынчы еллардан төшкән кара шәүлә — сәяси «уяулык» күрсәтү, якын кешеләребезгә дә шик белән карау, халык дошманы эзләү еллар буенча каныбызга сеңде, милли сыйфатыбызга әверелә язды. Кешеләрдә ышаныч кимеде, тәмам бетә язды — җитәкчеләргә дә, бер-береңә дә, үз-үзеңә дә. Хәзер халыкның күзе ачыла, ышанычы әкренләп терелә, иманы яңара — бөтен көч белән шул ышанычны якларга һәм акларга кирәк. Чиркәүләрне җимергәндә, мәчет манараларыбызны кискәндә кешеләрнең йөрәгеннән шәфкать качты, ышаныч тамыры киселде. Югалтуларыбызның бер очы шунда да булса кирәк...

**Язучы.** Гадел булыйк дисәк, милли сәясәттә, вөҗдан ирекe мәсьәләләрендә ленинчыл мөнәсәбәтнең беренче нәтиҗәләрен дә онытырга ярамый. Революциядән соңгы ун ел эчендә, мәсәлән, илебездә 7 мең мәчет ачыла. Дин идарәсенең рәисен — мөфтине беренче мәртәбә халык үзе сайлап куя... Әмма Ленин билгеләгән юлдан тайпылу тиздән бу мәсьәләләрдә дә үзен нык сиздерә.

Шәхес культы дәверендә 14 мең 349 мәчет җимерелә. 60 нчы еллар башында, «халык соравы буенча», исән калган гыйбадәтханәләрнең дә байтагы ябыла. Вөҗдан хокукларын гамәлгә ашыручы кешеләр икейөзлеләнергә, дингә ышануларын яшерергә мәҗбүр ителә. Мәхәллә-мәчетләр тоту бер газапка, законнан тыш хәлгә әверелә. 1961 елда хәтта «Дини мәхәлләләрнең, дин әһелләренең шәфкать эшчәнлеге белән шөгыльләнергә хакы юк» дигән кебек күрсәтмәләр бирелә...

**Мөфти.** Илебездә Шәфкать һәм сәламәтлек фонды төзелгәнен Сез беләсез инде. Аны оештыру мәҗлесендә мин мөселманнардан вәкил булып катнаштым. Ул фонд әгъзалары саф күңелле, чын иманлы кешеләр булырга, ятим калган бер генә баланы булса да тәрбиягә алырга яки елына җиде көн ятимнәр, зәгыйфьләр йортында эшләргә тиеш. Бу җәһәттән пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам, «үксез калган баланы тәрбияләгән, аңа шәфкатьле булган кеше җәннәттә минем белән бергә, ике бармак шикелле, янәшә булачак», дигән. Ә шәфкать, мәрхәмәт юллары күп. Ахирәттә генә түгел, фани дөньяда да күңел шатлыгына ирешергә мөмкин.

**Язучы.** Халыкның бер өлешенә сыену мөмкинлеге биргән, үзенең тәрбия-йогынты чаралары булган дини оешмалар да җәмгыятьне савыктыруда катнаша алырлар иде, әлбәттә.

Конституциябездә дин тоту-тотмау һәркемнең үз ихтыярында дигән сүз булса да, әлегә вөҗдан ирекe турында кануныбыз юк безнең. Төрле заманда кабул ителгән, шуңа күрә хәтта бер-берсенә каршы килә торган күрсәтмәләр генә бар...

Үткәндәге хаталарны ачыктан-ачык тану, ленинчыл нигезгә кайту дәверендә яшибез

икән, вөҗдан ирege дә безнең илебездә махсус закон төсен алырга тиеш. Аның каралама хәлендә үк дин әһелләре белән киңәшеп әзерләнүе мәгълүм. Ул законны тикшергәндә Сез нинди хисләр кичердегез? Сезнең тарафтан да өстәмәләр, тәкъдимнәр булгандыр, бәлки?

**Мөфти.** Безгә Дин эшләре советыннан Вөҗдан ирege турында законның проекты бирелде. Без аның белән таныштык. Минем фикеремчә, ул искиткеч яхшы бер канун булачак. Бу башбаштаклык, йә аңлашылмаучылыкларны бетерергә нигез булачак закон ул дип уйлыйм. Анда дини оешмаларга шактый гына иркенлекләр күздә тотыла һәм канунны бозмаска, эшне тәртипле итеп алып барырга шартлар тудырыла. Шуның белән бергә дини оешмаларның матбагалар тотарга, укыту мәсьәләләрен җайга салырга шактый киң мөмкинлеге ачыла. Тулаем бик хуп күргән хәлдә, без кайбер фикер-тәкъдимнәребезне дә язып бирдек. Әле тагын әйтәсе теләкләребез бар.

Безне уйландырган мәсьәләләрдән берсе, әйтик: дини җәмгыятьне теркәү, рәсмиләштерү тәртибе. Хәзергә без яңа мәхәлләне теркәү, яңа мәчетне ачу өчен башта райисполкомга, ул ризалык биргәч горисполкомга, аннары республиканың Югары Советына, иң соңыннан Мәскәүгә мөрәҗәгать итәбез. Мәскәүдән тагын шул баскыч буенча сикерә-сикерә кайтканда, хәтта бөтен кабинетларда «әйе, ярар» дип торган чагында да, ким дигәндә, ярты ел вакыт үтә иде. Җиде ел вакыт китте Зеленодольскида мәчет ачу өчен. Менә яңа канун буенча ул ихтыяр турыдан-туры район Советына бирелә. Бу бер ягыннан уңайлы — мәсьәләне тиз хәл кылып була. Икенче яктан, ул дини җәмгыятьләр арасында бер-берсенә каршылыкны көчәйтергә мөмкин. Мәсәлән, бер үк мәхәлләдә биш-алты кеше башка халыктан аерылып, азгын фикергә ияреп, диннең килешмәгән ягыннан, диннән кешеләрне биздерерлек, нәфрәтләндерерлек итеп үзләренчә мәхәллә оештырырга мөмкин. Менә шуны истә тотып, без уйлыйбез: яңа мәхәлләләр ачкан вакытта нәзарәтнең дә фикере, моңарга мөнәсәбәте билгеле булса иде дип. Яңа пәйгамбәрләр уйлап чыгарып, «изге хатлар» язып, янсә ахырзаман җитә дип, Коръәнгә бөтенләй каршы булган мәзһәбләр барлыкка килә хәтта Европа илләрендә дә. Әгәр дә яңа мәхәллә-мәчетләр ачуда нәзарәтнең фикере исәпкә алынмый торган булса, безнең дә шундый хәлләргә юлыгуыбыз ихтимал; алар арабызда коткы салу, бер-беребезнең башын кимереп ятуга сәбәпче булырга мөмкин.

Бу еллар эчендә безнең башка ихтыяҗларыбыз да байтак җыелган, әлбәттә.

Ислам дине намазны җәмәгать булып, бергә укырга куша — безгә мәчетләр кирәк. Үзгәртеп коруның изге җилләрен тәүге көннәрдән үк тоя башладык: хәзер байтак урыннарда мәчетләр, мәхәлләләр ачыла, искеләре яңартыла. Безнең эшчәнлегебезгә яңача караш, партия һәм Совет дәүләте тарафыннан җитди игътибар шушы эшләрне тизләтү мөмкинлеген бирде. Тобол, Горький, Свердловск, Сибай, Волгоград, Кемерово һәм башка шәһәрләрдә мәчетләр аякка бастырыла. Үткән ел Горький өлкәсенең Красная Горка, Ульяновск өлкәсенең Яңа Тимерчән авылларында, Йошкар-Ола, Түбән Кама шәһәрләрендә һәм Буада яңа мәхәлләләр ачылды. Казан, Чаллы, Нефтекамск, Белорет һәм башка шәһәрләрдә дә мәчетләр салыначак.

Күп еллардан бирле Коръәнгә зур ихтыяҗ. Быел, Болгар бабаларыбызның ислам динен кабул итүенә һиҗри белән 1100 ел, ә Диния нәзарәте төзелүгә милади белән 200 ел тулу уңаеннан, ул ихтыяҗ да күпмедер канәгатьләндереләчәк. Диния нәзарәтенең элекке рәисе мөфти Ризаэддин ибн Фәхреддин хәзрәтләренең пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәдисләрен шәрехләп биргән китабы 1916 елгы рәвешенчә, ә Әхмәдһади Максудиның ислам дине гыйбадәтләрен аңлатучы китабы хәзерге хәрефләр белән басылып чыгуын да зур вакыйга дип саныйбыз.

Безнең Диния нәзарәте янында махсус курслар, Бакуда яңа мәдрәсә ачылу да хәлне беркадәр җиңеләйтер дип өметләнәбез. 25 егет Бохара мәдрәсәсендә һәм Ташкент Ислам институтында белем ала. Гомумән, безгә дин җәһәтеннән генә түгел, намаз-нияз, никах, күмү эшләрендә генә түгел (алары да бик мөһим), дөньяви мәсьәләләрдә дә гыйлемле, фәһемле кешеләр кирәк. Халыкның рухи дөньясын, әхлагын сафландыруда, милли аңын һәм ватанпәрвәрлеген үстерүдә лаеклы катнаша алырлык затлар кирәк.

Намаз уку һәм ураза тотуны гына гыйбадәт дип санамыйбыз без. Пәйгамбәребез: «Аллага үзеңне танытуның уннан бер өлеше сәҗдә булса, уннан тугыз өлеше — хәләл ризыкны кәсеп итү»,— дигән. Шуңа күрә һәр эштә намус белән эшләү, илнең һәм халыкның байлыгын арттыруда катнашу үзе хәләлдән кәсеп-гыйбадәт була.

Куркып, качып-посып яшәргә тиеш түгел дин әһелләре. Юк! Җәмгыять тормышында, перестройка барышында җиң сызганып катнашырга кирәк безгә.

**Язучы.** Хәзрәт, безнең әңгәмә шактый гына фикер уртаклыгы, Сез әйткәнчә, бер-беребезнең «җаена яту» белән башланып китте шикелле.

Коммунист белән дин әһеленең гәпләшүен башкачарак күз алдына китерүчеләр дә бардыр, әлбәттә... Әйтик, бәгъзе берәүләр миннән, материалист, атеист буларак фаш итү һәм сүгену сүзләре генә кычкыруымны көтәләрдер. Ә Сез, «чалмалы...» икәнсез, һич-

шиксез, Фәтхулла хәзрәт рухындарак, йодрык төенләп: «Дәһри, кяфер, мәлгунь!» — дип, миңа ташланырга тиешсездер. Ләкин шул ук вакытта Сез бит әле — миннән биш кенә яшькә өлкәнрәк, бер үк чорларда мәктәптә укып йөргән һәм комсомол тәрбиясе алган, ниһаять, һәркайсыбыз кебек үк бик еш кына «син үзеңне безнеңчә тот, безнеңчә йөрт» камчысын татыган кеше... һәм Сез — илебезнең Европа өлешендә, Себер киңлекләрендә яшәүче барча мөселманнарның рухани җитәкчесе... Кирәк чагында ел-көн агышын һиҗри исәп белән санап, әйтик, 3 августта яңа 1410 нчы елны каршыларга әзерләнсәгез дә, безнең сәгатьләр бер үк вакытны күрсәтә. Ягъни, халыкның бүгенге тормышыннан, илдә барган үзгәрешләрдән Сез дә читтә кала алмыйсыз. Шуңа күрә минем чираттагы соравым бик туры һәм бик гади: 1985 елның апреленнән соңгы чорда иҗтимагый тормыш, демократия, хәбәрдарлык, үзгәртеп кору төшенчәләренең асыл эчтәлеге Сездә нинди фикерләр, нинди хисләр уята? Бу дәвер ватандашларыбыз тормышына нинди үзгәрешләр алып килер дип уйлыйсыз?

**Мөфти.** Безнең һәркайсыбыз гомер юлын тирән акыл-фикерләү белән, изге эш-гамәлләр белән узарга омтыла. Ә гомер тәүлеге чиксез түгел. Атналар, айлар, кәгазь битләре төрелгәндәй, үз эченә төрелә, бикләнә бара. Көн һәм төннәр, бер-бер артлы җибәрелгән хатлар кебек, бер-берсен куып җитә алмаслык дәрәҗәдә үтеп китә. Көннәр үткән саен, бик ерак булган нәрсәләр дә якыная, яңадан-яңа эшләр, мәшәкатьләр пәйда була — гомер агыла... Яңа көн туып, таң ата башлады икән, бер нида-тавыш килә: «Әй адәм баласы, мин Аллаһның яңа яраткан көне, синең бу көндә кыла торган гамәлләреңә гуаһ-шаһит булачакмын; минем кадеремне бел, әрәмгә үткәрә күрмә, бу көнеңә мин кыямәт көнендә шаһит булырлык хәерле гамәлләрне кыла күр...» — дип, һәр көннең таңы шундый кисәтү белән башлана.

Илебездәге яңарыш һәм үзгәрешләр дулкыны һәр көннең, һәр сәгатьнең мәгънәсен тагын да баетты, кадерен арттырды. Җәмгыятебездә бара торган бу үзгәртеп кору хәлләре безнең күңелебездә ихлас шатлык хисләре уята. Без бу көнне, бер бәйрәм шикелле итеп, җиде дистә ел буена көтеп килдек. Җәмгыятебезнең бөтен тормышын демократия нигезләренә, ачыклык-хәбәрдарлык шартларына кайтару — бу чын хәлгә кайту, табигатькә кайту дигән сүз. Ә бит әле кайчан гына лаф орадыр идек: табигатьтән рәхимлек көтеп ятмыйбыз, табигатьне үзебезгә буйсындырабыз дип. Янәсе, бөтенесен ватам да җимерәм, тибәм дә аударам, барысы да мин теләгәнчә генә булсын! Ә дөнья үзенең асылы белән алай иттереп яратылмаган. Шушы дөньяда кош-кортка да, хайванга да, кешегә дә — бөтенесенә дә яшәрлек, тереклек итәрлек шартлар булдырылган, бөтенесе бер-берсе белән шулхәтле бәйле: хәтта төшкән яфрак та әрәм булмый — җир астындагы кортка ризык булып кала. Күкләрдә очкан кошка канат биргән, җирдән шуышкан еланга җитезлек биргән икән, адәм баласының да шул табигать эчендә үз урыны бар. Аллаһ тәгалә Коръән кәримдә: «Вәләкадь кәррәмнә бәни адәмә уә хәмәлнәһүм фил-бәрри уәл-бәхри... — Адәм баласын без җир йөзендәге бөтен мәхлүкать арасында иң кадерлесе итеп яраттык, хәтта җирләрдә, диңгезләрдә без аларны күтәрдек», — ди Аллаһ тәгалә... Безнең хәзер моңа кушып әйтүебез мөмкин: хәтта күкләрдә дә дип. Адәм баласы — бу дөньяның иң асыл заты, тормыш агачының иң асыл җимеше. Шуның өчен таң атуы да, кош сайравы да, чишмәләрнең агуы да — бөтенесе адәм баласы өчен. Шуңа күрә без табигатьне буйсындыру, рәнҗетү түгел, аны саклау, арттыру рәхәтеннән ямь вә тәм табарга тиешбез...

**Язучы.** ...Сезгә ияреп, Коръәннән шундый бер аятьне исегезгә төшерәсем килә: «Ин әхсәнтүм — әхсәнтүм лиәнфусикүм уә ин әсәэтүм фәләхә... — Игелек эшләсәгез дә — үзегезгә, явызлык эшләсәгез дә — үзегезгә». Ягъни, барысы да кешенең үзенә кире әйләнеп кайта. Ничә еллар табигатьне рәнҗетүнең нәтиҗәләрен хәзер татыган кебек, замандашларыбызның әхлагында, рухында килеп чыккан тайпылышларның сәбәбен дә без якын һәм ерак үткәннән эзләргә тиеш булабыз...

**Мөфти.** Әйе, диңгезләр, чишмәләр, хәтта җир асты сулары пычранган төсле, адәм балаларының да табигатенә куркыныч яный. Мин әле әхлак-әдәп сафлыгыннан да бигрәк, рух сафлыгын, рух азатлыгын күздә тотам. Бездә бармы соң ул азатлык, без аннан файдалана беләбезме соң? Романовлар итеге астында тапталганда «ак патша»га дога кылмадыкмы? Октябрь революциясе биргән мөмкинлекләрдән ничек файдаландык? Культ елларында Сталинны үзебезгә «алла» итеп, аңа табындык. Әле дә булса бәндәгә сәҗдә кылудан арына алмыйбыз лабаса... Шул елларның шаукымы күңелләребезне богаулаган, рухыбызны гарипләндергән булып чыкты.

Перестройканың саф җилләре халыкны ничә еллык йокысыннан уятты. Үлмәгәнбез икән әле, шөкер, йоклаганбыз гына икән. Безгә хәзер рухыбызны савыктырырга, бер-беребезгә кул сузарга, бергәләшеп алга атлауны дәвам итәргә кирәк. Иншәаллаһ, инде бер хакыйкатькә төшенә барабыз шикелле: без бер-беребезнең кирәклеген тоеп яшәргә, башка кешенең, башка халыкның шатлыгын йә кайгысын бүлешеп, хәлен аңларга тиешбез.

Без хәзер үзебезне яңадан Нух галәйһиссәлам көймәсендә кебек хис итәбез. Бөтен

кешелек бергәләшеп, атом туфаныннан котылып калырга телибез.

Шуңа күрә дә без, Совет иле мөселманнары, хөкүмәтебезгә мөрәҗәгать иттек: бу елның ахырында, йә киләсе елның башында «Роль и место мусульман и ислама в перестройке» дигән бер съезд үткәрәсебез килә Мәскәү шәһәрендә, илебезнең җитәкчеләрен дә чакырып. Мөселман халыклары — безнең илебездә алар әз түгел — биштән бер өлеше диярлек,— җәмгыятебез тормышында үзләренә лаеклы урын билиләр. Үзгәртеп кору эшләрендә дә без читтән карап торучы гына түгел, кул куәтләп, бөтен җаныбыз-тәнебез белән, җиң сызганып бу сәясәтне гамәлгә ашыруда катнашабыз.

**Язучы.** Сез бүгенге Җир шарын Нух көймәсенә төялгән тереклек дөньясына охшаттыгыз. Димәк, хәлне чыннан да бик киеренке дип саныйсыз... Шулай да дөньяның киләчәгенә нинди өметләр белән яшисез? Дөнья, янәсе, ут белән яратылган һәм ут белән бетәчәк тә, дигән сүзләр рас килер дип уйлыйсызмы? Җирдә тынычлыкны, иминлекне саклау юнәлешендә дин әһелләре, ислам дине башлыклары, Сез җитәкләгән Диния нәзарәте нинди эшчәнлек алып бара? Илебез игълан иткән тынычлык башлангычларын ничек бәялисез?

**Мөфти.** Дөнья ут белән яратылган — ут белән бетәр дигән сүзгә мин кушылмыйм. Дөнья Аллаһның әмере белән бар булды, Аллаһның әмере белән генә юк булачак дип ышанабыз без.

Аллаһ тәгаләнең «бөтен тереклекне мин судан яраттым» дигән сүзләре бар. Хәтта атабыз Адәм галәйһиссәламне яраткач, Иблискә сәҗдә кылырга кушты, Иблис баш тартты, сәҗдә кылмады: «мин уттан яратылдым, кеше исә балчыктан, нигә мин балчыкка буйсыныйм, нигә мин балчыкка сәҗдә кылыйм»,— дип баш тартты, киреләнде. Без, мөэминнәр, дөньяны Аллаһ тәгалә үз теләге белән бар итте дип таныйбыз. «Күн фәйәкүн» («Бул!») дигән сүзендәге кяф (к) белән нун (н) арасында дөньяның барлыкка килүе булды.

Ә инде дөнья кайчан бетә дигәчтен, пәйгамбәребез әйтә: «Җир йөзендә бер генә дә «Лә иләһе иллаллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ» дип әйтүче калмаса, ягъни «Аллаһтан башка хак-илаһ юк, Мөхәммәд саллаллаһи галәйһиссәлам аның илчесе» дип әйтүче калмаса,— ди,— шул вакытта гына дөнья бетә»,— ди. Ягъни дөньяда Аллага ышанган, Аллаһ кушканча эш итә торган кешеләр яшәгән вакытта дөнья бетми... Кайчан дөнья арбасында инде «кая да булса бер алып чыгар әле» дип аягын салындырып утырган «куяннар» гына калса — үзеннән-үзе булган, үзеннән-үзе бетә дип, ут белән дә уйнаучылар, кеше язмышы белән дә шаяручылар күбәйгәч, дөньяда бер дә иманлы адәм калмый торган булса, шул чакта гына дөнья бетәчәк. «Куяннар» бит берәү-икәү генә булганда, ул вакытта гына билет тикшерү кызык. Әгәр дә инде бөтен вагон билетсыз булса, өстәвенә билет тикшерүчеләргә каршылык күрсәтергә керешсә, андый вагонны төртеп аударудан башка бернинди чара калмый... Шуның шикелле үк, дөньяның соңгы сәгате дә иманның зәгыйфьләнүеннән башлап тәмам бетүенә җиткәч туктала.

«Торгынлык дәвере» дип аталган елларда без билет алып тормый гына, сызгырып кына коммунизм арбасына утырган идек тә, әнә нинди чиккә килеп җиткәнбез булып чыкты... Ләкин бүгенге көнебездә хөкүмәтебезнең җитәкчеләре һәм халкыбыз да әкертенләп-әкертенләп аңлап килә: дөньяның барышы үзебезнең хезмәтебездән дә тора икән. Без тик ятып кына эш булмый икән. Аллаһ тәгалә Коръән-кәримдә: «Уә кули-гмәлү фәсәйәр-аллаһу гамәләкум уә рәсүлүһү уәл-мөэминүн...— Әйт, йә хәбибем, эш итегез, тырышыгыз, хезмәт итегез, сезнең хезмәтегезне тиздән Аллаһ, Аллаһның илчесе һәм иманлы кешеләр күрерләр»,— ди.

Безнең илебезнең җитәкчесе Михаил Горбачев, эшне кулына алу белән, халык тарафыннан хупланып (Аллаһ тарафыннан дип әйтсәк тә була: чөнки җирдәге солтаннарны без Аллаһның җир йөзендәге илчесе дибез), эшкә ныклап тотынды, иң әүвәл илдә демократияне торгызды, ачыклыкны, һәрбер эшне халык белән киңәшеп башкаруны урнаштырды. Илебездәге халыклар арасында татулыкны урнаштырырга, бигрәк тә менә инде ничә еллардан бирле киеренке тормышка, зур чыгымнарга сәбәп булган хәлгә — Америка һәм башка мәмләкәтләр белән мөнәсәбәтне яхшыртуга баскыч куйды. Аллаһ ярдәм бирсен аңа. Тынычлык дөньясының беренче кирпечләре шулай куелды. Инде сигез елдан бирле әрнеп килгән Әфганстан халкының хәлен дә аңлыйк. Бәгырь җимешләре — балалары кан коеп, зиратларда урам-урам булып кабер ташлары куелганда, безнең халкыбыз да әрнеде бит. Шушы сугыштан котылуга Михаил Сергеевич бик батырларча, бик нык иттереп керәште, һәм без өмет итәбез, иншәаллаһ, якын араларда ул күрше дус илебездә дә тынычлык урнашачак. Күршеңдә ир белән хатын талаша башласа да, ашык-пошык араларына керергә тиешле түгел... Әфганстан хәлләре, билгеле, моннан күпкә четереклерәк иде. Ул күп газаплар күргән ил һәм безнең ярдәмебезгә бик мохтаҗ ил. Һичшиксез, анда көрәш алып баручы төрле көчләр, бер милләт булганга күрә, ватаннары бер булганга күрә, милли килешүгә килерләр дә, тынычлык урнашып, безнең хөкүмәтебезгә дус бер ил булып калыр дип өмет итәбез. Шуның белән, Аллаһ насыйп итсә, дөньядагы бөтен

мөселман илләренең дә ышанычларын без кире кайтарырга бер баскыч атлаган булабыз. Чөнки, турысын әйтергә кирәк, Әфганстанга барып керү белән, бик күп мөселман халыклары Совет иленә шикләнеп карый башладылар, элеккеге, патша заманындагы юлбасарлар политикасын алып барасыз дип, безне сүгә башладылар.

Мин берничә ай элек Әфганстанда булдым. Анда пәйгамбәребез саллаллаһи галәйһивәсәлләмнең туган көне уткәрелде һәм исламда иҗтимагый гаделлек һәм тынычлык политикасына багышланган конференция оештырылган иде. Әфганстанның халкы да тынычлыкка бик сусаган, аларның тезисе, тормышларын ямьлисе бик күп эшләре бар. Коръән-кәримдә Аллаһ тәгалә адәм балаларына: «Изгелек, яхшылыкка ярдәм итешегез, әмма явызлык, дошманлыкка ярдәм итешмәгез»,— ди.

Шуңа күрә безнең Ватаныбыз киләчәктә дә бу илне — Ленин заманыннан ук тыныч яшәгән күршебезне үзенең ярдәменнән ташламас дип өмет итәбез. Без мөселманнар исеменнән биш мең тәңкәлек балалар киеме алып, Әфганстанның башкаласы Кабулдагы ятимнәр йортына җибәрдек. Бу уңайдан ук тагын шуны әйтеп була: барлык мәхәлләләребез берләшеп, без һәр ел саен 250-275 мең сум акча Тынычлык фондына да күчерәбез.

Гомумән алган вакытта, безнең илебез җитәкчеләренең хәзер һәркем белән каракаршы утырып, ачык итеп үз фикерләрен сөйләүләре — бу безгә гайрәт бирә, бу — киләчәккә ышануыбызны арттыра. Хәзер без кичә дошман дип санаган кешеләр, илләр белән дә бер өстәл янына утырып бәхәсне хәл итә, уртак фикергә килә башладык. Әфганстандагы үзгәрешләр, Иран белән Гыйрак арасында күпме еллар дәвам итеп килгән сугышның бетүе әнә шуның да нәтиҗәсе. Инде менә күңелебезне әрнетеп торган тагын бер яра — пәйгамбәребез исеме белән бәйле әл-Акса мәчете бүгенгә көнгә хәтле Израиль баскыннарының кул астында кала. Совет җитәкчелегенең Якын Көнчыгыш илләре арасында тынычлык, дуслык урнаштырырга омтылышы безгә тагын да дәрт бирә, куәт бирә. Шуның өчен дә безнең илебез алып барган тынычлык сәясәте — коралларны һәм кораллы көчләрне киметү, хәтта әлегә берьяклы гына булса да — болар бөтенесе илебезгә ышанычны арттырды, халыкларның бер-берсенә ышана башлавына сәбәп булды, без моның тагын да хәерле дәвамын көтәбез. Илебезнең җитәкчеләренә тынычлык, иминлек юлларында куәт, дәрт бирсә иде дип, һәрбер җомгадан соң дога кылабыз.

**Язучы.** Чирен яшергән — үлгән, ди халык. Күңелдәге уйны ачыктан-ачык әйтү, четерекле мәсьәләләрне бөтен кискенлеге белән кую шартларында, әледән-әле бер мөһим сорау алга баса. Ул — милли мөнәсәбәтләр, милли дәүләтчелек мәсьәләсе. Күпмилләтле ил өчен гадәти, табигый мәсьәлә. Шул ук вакытта, мәгълүм чорлар, мәгълүм сәбәпләр нәтиҗәсендә, бу өлкәдә байтак кына «чи төеннәр» дә барлыкка килде. Кайбер халыкларның шул исәптән, русларның да милли тел язмышы өчен, милли культура язмышы өчен борчылып, чаң суга башлавы, кайбер төбәкләрдә милли нигездә аңлашылмаучылыклар килеп чыгуы шул хакта сөйли. Татар халкының да еллар дәвамында төенләнеп килгән үз проблемалары һәм башкалар белән уртак мәсьәләләре бар. Халыклар арасындагы дуслыкны ныгыту өчен, милли мәсьәләләрне хәл итүдә гаделлек урнашсын өчен, иң мөһиме нәрсә дип саныйсыз?

**Мөфти.** Бүгенге көндә, кызганычка каршы, кайсы да булса хайваннарны гына түгел, кайбер кошларны гына түгел, милләтләрне Кызыл китапка кертергә якынайдык. Болгар бабаларыбыз телен хәзерге галим-голяма «үле тел» дип язган шикелле инде, татар телебез дә «кухня теле»нә, «деревня теле»нә әйләнеп бара икән ләбаса. Уртак ватанда шактый ук булсак та, тырышлыклар ясап, милләтләребезне, туган телләребезне сакларга вакыт җиткән. Үзебез Кызыл китапка әлегә язганбыз. Ләкин безнең андый хәлгә үк каласыбыз килми.

Аллаһ тәгалә безне чын бәндә иттереп яраткан икән шушы дөньясына, бөтен мәхлүкать арасында иң кадерле зат икәнбез, иң зур байлыкларыбыздан булган туган тел, милли аң, милли культураны сакларга бурычлыбыз. Тигез хокуклы милләтләр гаиләсе итеп яшәткәндә генә безнең илебез куәтле һәм шәүкәтле була ала. Илебездә дә, бөтен җир йөзендә дә яшәүче халыкларның бер-берсенә ышанып, бер-берсеннән хәвефсез яшәүләре, шул рәвешле тынычлык-иминлек бәрәкәтен татулары кирәк. Чөнки җирдәге тотрыксызлык, шау-гөрләр бер-беребезгә ышанмаганлыктан килеп чыга. Адәмнәр дөньясын берберсеннән курку тойгысы дер селкетә. Ә бит нинди генә динне тотса да — Гайсә галәйһиссәламне олылыйммы ул, Муса галәйһиссәламнеме, һич булмаса ташка, агачка, яә сыерга табынамы,— Аллаһ бәндәсе үзе кебек үк ике аяклы, югары зиһенле затның һөҗүменнән түгел, үзенең табигатьтән төшеп калуыннан куркысын.

Сугыш чыгу куркынычы белән генә берегеп торган дөнья нык түгел ул. Куркыту юлы белән генә берләшеп торган һични дә нык була алмый. Үзара бәйләнганлыкны аңлаудан туган ныклык кына дөньяны бербөтен итә, кешелекле итә. Шуңа күрә кешеләр, милләтләр, мәмләкәтләр мөнәсәбәтендә иң мөһиме — ышаныч дип саныйм. Ышаныч. Без аны иман дибез. Иман — кешенең кеше булып яшәвендә беренче шарт. Аллага ышанасы килмәгән бәндә һич булмаса изгелеккә ышансын. Адәм баласының да, халык кадәр халыкның да чын йөзе изгелекнең кадерен тануда ачыла.

Милли мөнәсәбәтләрнең бигрәк тә хәзерге вакытта катмарланып китүләре, бик күп халыкларның үзләренең киләчәге өчен кайгырулары ул табигый хәл. Аллаһ тәгалә безне яраткан төрле төстә, төрле телләрдә сөйләшә торган итеп. «Йә әййүһәннәсү иннә халәкъ-нәкүм мин зәкәрин үә унсә үә җәгальнәкүм шугубән үә кабәилә литәгарәфү...— Мин сезне бер ата, бер анадан яраттым, төрле төстә, төрле телдә сөйләшүче халыклар иттерел,— бер-берегезне таныгач, изгелектә узышу өчен»,— ди Аллаһ тәгалә. Аллаһның хозурында мин урыс дип, йә мин гарәп дип, мин татар дип, мактанышу юк. Аллаһның хозурында изге эшләрне күбрәк эшләгәнегез кадерлерәк, ди. Менә шуның өчен дә, безнең илебездә йөздән артыграк милләт бар икән, аларның һәркайсының кадере арту бер-берсенә ышаныч күрсәтү белән бәйләнгән. Бездә бит 15 союздаш республика бар дибез; шул 15 халыкның вәкилләре генә сәхнәгә чыгып бии башласалар, үзләренең гореф-гадәтләрен күрсәтсәләр дә, иң яхшы нәфис фильмнан да һәйбәтрәк була. Исебез китә: нинди ямь бар ул халыкларның үз-үзен тотышында, килеш-килбәтендә, гореф-гадәтләрендә. Һәм шуның шикелле үк, төрле милләтләрнең килешмәгән төшләре дә бар. Менә шуларның бер союзга берләшеп, бер иттихадта яшәүләре — үзе гаҗәп эш. Мондый хәлнең милләтләр бер-берсен хөрмәт иткәндә генә, бер-берсенә ышанган вакытта гына барлыкка килүе мөмкин.

Мәсәлән, кулыңда бер төрле чәчәк бар икән — ул роза гөле ди. Роза гөлен кулыңа тотарга да куркасың. Никадәр хуш исле булса да, никадәр матур булса да, кулыңа тотуга аның чәнечкеләре синең кулыңны кадый. Матур бит ул үзен саклый белә. Аллаһ тәгалә шулай иттереп яраткан. Ә шул роза гөле янына башка гөлләрне — пионнарнымы, канәферләрнеме кушсаң, тагын урман гөлләреннән уч-уч итеп шуның янына китерсәң, ул вакытта розаны тотасың, инәләре сине кадарга җитми, ул капланып кала, йомшак гөлләр — халыклар белән... Яисә үзен генә алган вакытта ул гади бер чәчәк шикелле, зәңгәр бер чәчәк шикелле. Руслар аны василёк дип әйтәләр...

**Язучы.** Күкчәчәк...

**Мөфти.** Менә мин үзем, ата-анам урыс булмаса да, кайбер чәчәкләрнең исемен урыс телендә әйтергә мәҗбүр; мин аларны никадәр яратсам да, үз туган телемдә атап күрсәтә алмыйм. Урыс мәктәбендә укыдым, татар телен өйрәтү дәресе кергән булса да, атнасына бер-ике тапкыр, аңардан качадыр идем, чөнки ул башкаларга караганда миңа нагрузка иде, артык иде. Хәзер артык түгел, белдем кирәк икәнлеген...

Инде асыл максатыбызга килгән вакытта, бер букет иттереп җыйсаң шул күкчәчәк-василек кебек күрексез генә чәчәкләрне,— исенә шаккатасың, төсенә шаккатасың, һәм гел исең китә, хәйран каласың. Менә шуның шикелле, без әгәр дә һәрбер халыкның, һәрбер милләтнең безнең Союздагы гына түгел, бөтен дөньядагы халыкларның кадерен-хөрмәтен белеп, милли гореф-гадәтләрен, туган телләрен сакласак, шундый күп бизәкле дөньяда яшәвебезгә үзебезнең исебез китеп, йөз генә ел түгел, мең ел яшисебез киләчәк. Ә бүгенге көндә, кызганычка каршы, кайсыбер кеше егерме биш-утыз ел яшәгәннән соң ук дөньядан туя да, китәсе килә. Чөнки барысын кабып карады, барысын татыды да, һәммәсеннән бизде, дөньяның бер кызыгы да калмады аңарга. Аллаһ үзе моңардан безне сакласын!

**Язучы.** Сез ничек уйлыйсыз, культ һәм торгынлык елларында изелгән милли горурлык яңадан башын күтәрә алырмы? Юклык заманында ни барына шөкерана итәсең, татар телен гамәлгә кую тарафына бер-ике адым ясалуына да куанасың. Әмма социалистик Татарстан башкаласында татарча игълан ишетеп шаккату, шуны рөхсәт иткән түрәгә мең-мең рәхмәт уку — бусы инде изелгәнлек, аборигенлык рухи халәте түгелме?.. Ризаэддин Фәхреддин хәзрәтнең сүзләре күңелгә килә: «Әй тырыш һәм чыдам бабаларыбыз!.. Сез хәзер генә бу илдә гомер сөрә идегез... Бу көндә бу хәлләргә ни булды?.. Үзегез инде кайларга киттегез?..»

**Мөфти.** Мондый хис руста булсын, әрмән яки эстонда булсын — һәр халыкта исән дип беләм. Аның белән исәпләшмәгәндә ил болгана, анасы үлгән умарта кučедәй тынычсызлана башлый халык. Карабах хәлләре, яисә Кырым татарлары язмышы шуңа күрә борчый безне. Халык хәтле халык тулысы белән хыянәтче дә түгел, икенче-өченче сортлы да була алмый. Халыкларны газиз туфрагыннан аеру Усал Иван заманыннан соң явыз Сталин хакимлек иткән дәвердә генә мөмкин булды. Без инде шул хакта ачыктан-ачык сөйләшә, гөман кыла башлаганбыз икән — алга таба тагын да кыюрак адымнар ясалыр, шаять. Зур илнең — күп милләтле дәүләтнең гамь-мәшәкатьләре дә күп, четерекле. Без үз халыкларыбызның язмышын үзебез хәл итә алырга тиешбез, дошманнар сүзе үтмәслек итеп.

**Язучы.** Ислам дине Болгар дәүләтенең мөстәкыйльлеген, үзаллы яшәвен көчәйткән, дибез. Шул ук вакытта бабаларыбызның башка диндәге кешеләрне ригая кылуы, үзара килешеп көн итүе дә мәгълүм (шәһре Болгарда да, хан заманындагы Казанда да, әйтик, чиркәү үзенә лаеклы урын тапкан). Киңрәк алганда, ислам һәм христиан идеяләренең гаҗәеп кушылмасы булган испан культурасын һ. б. мисалларны искә төшереп булыр иде. Сез менә Русьның христиан динен кабул итүенә мең ел тулу бәйрәмендә катнашкансыз. Хәтта ике

дин башлыкларының әледән-әле очрашкалый торуын да яшермисез. Турысын гына әйтегез әле: мондый дустанә мөнәсәбәтләр ислам кануннарына каршы килмиме? Ике татар үзара русча сөйләшеп торса да, алар кяфер чутыннан китә дип тәрбияләнгән мәчет картлары ничек карый бу хәлләргә?

**Мөфти.** Гомумән алган вакытта без, мөселманнар, динебез өйрәтүе буенча һәртөрле диннәрнең — христиан дине буламы ул, яһүд дине буламы — бөтен диннәрнең дә асыл чыганагы Аллаһтан дип таныйбыз. Төрле заманнарда халыкларның иҗтимагый үсешенә карата Аллаһтан үз заманына яраклы чаралар иңдерелгән. Шулай булгачтын без аларның һәммәсен дә хөрмәт итәргә тиешле. Коръән-кәримдә 20 дән артыграк пәйгамбәр искә алынган булса, Аллаһ тәгалә аларның әле әйтелмәгәннәре дә искиткеч күп, ди; һәрбер заманда, һәрбер халык арасында Аллаһ тәгалә халыкның хәлен төзәтерлек, дөреслеккә алып барырлык затларны сайлаган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһи галәйһивәсәлләм әйтә: башка диндәге кешегә зыян китергән мөселман — ул миңа зыян китерде, ди. Миңа зыян китергән кеше Аллаһка зыян китерергә маташа, ди. Аллаһка зыян китерергә маташкан кеше була икән, аның белән Аллаһ үзе эш итәчәк, ди. Ягъни, шәригатебез буенча, башка дин әһелләре белән без тату, матур иттереп яшәргә тиешле, дөреслекне аңлашуда уртак фикерләребезне, якынлыкны табарга тиешле. Совет дәверендә, бигрәк тә Бөек Ватан сугышы вакытында булды андый уртак эш: илебезгә олы яу килгән вакытында, төрле дин вәкилләре маллар җыеп, иганәләр, сәдакалар җыеп, танк колонналары, хәтта самолет эскадрильялары төзеттеләр. Безнең Диния нәзарәте дә моңарга үз өлешен керттe, мәхәлләләребез җан-малларын илебезнең азатлыгы өчен кызганмадылар. Шуның белән бергә сугыштан соңгы дәвердә дә,— Тынычлык фондының эшендә булсын, хәзер менә Шәфкать һәм саулык фондының эшендә булсын,— төрле дин әһелләре һәм җитәкчеләре уртак иттереп, илебездә шәфкатьлелек артуга, җир йөзендә тынычлык урнашуына, бөтен дөньядагы халыкларның үзара аңлашуына хезмәт итеп киләләр. Халыкларны — төрле дин әһелләрен бер-берсенә ышанырга, сугыш бәласеннән котылу юлларын бергәләп эзләргә чакырабыз без. 1982 елда Мәскәүдә патриарх Пименның нияте, башлавы белән туксаннан артыграк илдән вәкилләр килде, шуның арасында мөселман илләреннән 200 гә якын кунак бар иде. Безнең илдәге ислам оешмалары, дини нәзарәтләр дә катнашты. Аллаһның изге ямәү бүләген — Җир йөзен атом сугышының афәтеннән коткаруга багышланган конференция иде бу. Савaплы эш булды.

Тормышыбызны яхшыртуга алып бара торган хәрәкәтләр булса, без, төрле дин вәкилләре — мөселманнар, христианнар, яһүд динен тотучылар, буддистлар һ. б. мәзһәб вәкилләре — һәрвакытта да илебезнең башкаласы Мәскәүдә очрашып киңәшәбез, фикер уртаклашабыз. Төрле мәзһәбләрдә булсак та, максатыбыз бер: халыкларны дөньяда яшәгән вакытларында бәхетле итәргә, ахирәттә дә җәннәтле булуларына юл салырга; ә дөньядагы бәхет, әлбәттә, тынычлык белән була, бер-береңне кеше дип тануда була. Бер-беребезгә карата бездә тәкәбберлек булырга тиешле түгел. Безнеке генә хак, без генә өстен диган нәрсә һич дөрескә чыкмый ул. Тәкәбберлек — ул Аллаһка гына килешле нәрсә, адәм баласына килешле нәрсә түгел ул.

Бөек рус халкы — безнең иң якын күршебез. Илебез бер, суын эчкән Иделебез бер. Шуның өчен дә, узган елны илебез буенча һәм бөтен дөньяда рус халкының зур бәйрәмен — христиан динен кабул итүгә мең ел тулуын үткәргән вакытында, без дә аларга кушылып бәйрәм иттек. Анда мин генә түгел, ислам дәүләтләреннән дә кунаклар бар иде — мөфтиләр, дин эшләре министрлары. Бу бәйрәм арасында Рус чиркәвенең җитәкчесе патриарх Пименның илебезнең җитәкчесе Михаил Горбачев белән очрашуы булды. Христиан дине һәм хөкүмәт арасында гына түгел, бәлки бөтен дин әһелләре белән хөкүмәт арасында яңа мөнәсәбәтләр, тагын да чын күңелдән бер-беребезгә ышанып, эшебезне дөресләүгә, аңлашылмаган, йә киртә булган нәрсәләрне бетерүгә юл ачты ул очрашу. Бу иркенлек хәзер менә безнең тормышыбызга да кагыла башлады әкертенләп, әлхәмделиллаһ. Моның дәлиле дип саныйбыз: хөкүмәтебезнең рөхсәте булды быел безгә ислам динен болгар бабаларыбызның кабул итүенә 1100 ел һәм Диния нәзарәтебезнең төзелүенә 200 ел тулу бәйрәмен үткәрергә. Бу юбилей гадәти дини бәйрәм генә түгел, халкыбыз хәтерен уяту ул, тарихыбызны яңарту ул. Мәдрәсәләребез — тиләләр йорты, язуыбыз — «комган» хәрефләр, муллаларыбыз — тинтәк, томаналар, гомумән халкыбыз «абдулка»лардан гына гыйбарәт иде, югыйсә... Мондый кәферлек тагын күпме дәвам итәргә мөмкин. Тарих коесына төкергәнче, шул ук коедан су аласыңны онытмау фарыз.

**Язучы.** Тарихи хәтерне яңарту мәсьәләсен Сез бик урынлы күтәрәсез. Дөньяга караш фәне инкарлеген дә онытырга ярамый шул тарихның. Хәтта бүгенге хәлебезнең алшартлары да ерак гасырлар итәгендә ята бит... һәм бүген СССР тарихыннан дәреслекләрдә Россия халыкларының, шул җөмләдән татар халкының да, үзенә лаеклы урын ала алмавы ышанычны, дуслыкны ныгытуга хезмәт итми. Ил тарихы — сугышлар кендәлегеннән бигрәк, халыклар язмышының елъязмасы булырга тиеш. Иҗтиһадлы, зыялы бабаларыбыз бөек күршеләре белән кан коешып кына яшәгән диган сүзгә ышану мөмкин түгел... Тарих

чынбарлыгын торгызу җәһәтеннән Сез нинди фикердә торасыз?

**Мөфти.** Чынбарлыкны без һичшиксез кайтарырга тиешле. Чөнки безнең халыкны монгол-татар белән генә бәйләп карау — бу искиткеч зур хата. Без инде монгол-татарның дөньяда яңгырый башлаганына хәтле үк булганбыз. Болгар дигән халкыбыз булган. Хәтта Иделнең дә бүгенге көндә Волга булып танылуына да шул болгарлар сәбәпче. Киевтән караган вакытта аны «река булгар» дигәннәр. Аннары «р»ны, ни хикмәттер, чәйни башлаганнар. «Р» хәрефе төшеп-җуелып, «Булга» булып кына калган. Аннары «б» хәрефе дә «в»гә әйләнгән: Волга булган. Шушы бөек елгага исемен биргән халык без. Монгол-татар чирүе Көнчыгыш Европага килгән чагында, Жигули тауларында каршы алып, Сүбәдәй баһадирны илле сугыштан соң беренче иттереп тар-мар иткән халык — без. Янә 13 ел үткәч кенә монгол-татарлар бу җирләргә яу белән килергә батырчылык итә. Русьта, рус дөньясында ачлык булган вакытта икмәк җибәреп торган халык — без. Рус халкы үзенә дин эзләгән вакытында, исламны кабул итмисезме дип, такмыйча-нитмичә, үзләренә тәкъдим иткән халык — без. Аннан соң да, заманнар буенча үтеп, рус дәүләтенә кушылганнан соң, җәберләнеп, кан түгеп кушылган булса да, рус дәүләтен үзенә ватан итеп саный башлаганнан бирле, Полтава сугышында булсын, бүтән кыен хәлләрдә булсын — бөтенесендә безнең халкыбыз корал белән Рус дәүләтен саклауга ярдәм иткән. Наполеонны куган вакытларда да — Парижның уртасында татар-башкорт атлы гаскәрләре биегән түгелме соң? Бөек Октябрь революциясенең икенче көнендә үк Петербургтан соң Казанда Совет хакимияте урнашуы да моңарга зур дәлил. Мөселманнар: «Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!» — дип тәкбирләр әйтеп урамнарга чыгалар... Ун меңләп мәчете җимерелгән булса да, безнең халык Бөек Ватан сугышын батырларча каршылый. Хыянәт бездә булганы юк гомер буена — моны тарихыбыз исбат итә. Халыклар, милләтләр язмышы белән киләчәктә шаярырга ярамавын кисәтү өчен, чын тарих кирәк безгә.

**Язучы.** Зур тарихыбызда ислам дине белән җитәкләшеп кергән язу культурасы, Шәрык фәне һәм әдәбияты, шулай ук әхлак һәм гореф-гадәт үзенчәлекләре — болар барысы да Идел буенда яшәгән бабаларыбызның зирәк акылы, саф калебе аша үткәрелеп, татар халкының милли-мәдәни йөзен билгеләүдә дә катнашкан.

Соңгы дәверләрдә Шиһабеддин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин кебек дин әһеле һәм галим булган шәхесләребезнең халык тарихын торгызудагы хезмәтләре мәгълүм.

Ә бүген Диния нәзарәте халкыбызның милли-мәдәни, архитектура мирасын саклауда катнаша аламы? Төрле сәбәпләр аркасында чит мәмләкәтләргә «агып киткән» тарихи ядкярләребезне халыкка кайтаруда, киләчәктә фәнни әйләнешкә кертүдә нииндидер мөмкинлекләре, ниятләре юкмы нәзарәтнең?

**Мөфти.** Безнең Диния нәзарәте, чыннан да, бик күп еллардан бирле милләтләребезнең асыл байлыкларын саклауга өлеш кертте. Ләкин менә, кызганычка каршы, соңгы вакытларда без бер ят нәрсә — ят та, оят та — бер хәлне күрә башладык. Бу — башкорт белән татар халкы арасындагы уйдырма дошманлыкны кемнеңдер уйлап чыгарырга маташуы. Без — бер үк тамырлы, нәселле, гомердән бер-берсенә кода-кодагый булып яшәгән халыклар. Милли гореф-гадәтләребез, уен-көлкеләребез, җыр-моңнарыбыз уртак. Шуны хәзер кемдер икегә аерып, уртабызга дошманлык хисе кертергә маташа. Әле, Аллага шөкер, бу безнең халыкларның гади катлавы арасында юк, тик үзен инде бик зур иттереп, милләттән дә зуррак иттереп санаган кешеләр арасында гына килеп чыкты бу... Ике йөз ел элек үзебезнең кем икәнлегебезне танытдык һәм таныттык без Пугачев восстаниесе вакытында. Салават Юлайлар да, Бәхтияр Канкайлар да кушылып, Пугачевның гаскәрендә — яртысы дип әйтергә мөмкин — мөселманнар иде. Шунда гайрәт белән, көч белән эш иткән татар-башкорт үзенең кем икәнлеген танытырлык хәлгә җиткәннән соң, Әби патша бик тирәнтен уйлап, рөхсәт бирде Диния нәзарәтенең төзелүенә. Быел нәзарәтнең төзелүенә 200 ел, дидек. Менә шул дәвердән бирле Диния нәзарәте татар-башкорт халкын бергә саклап килде, шуның белән бергә — казах халкының да бер өлешенә сыену бирде. Безнең, мәсәлән, Волгоград өлкәсендәге мәхәлләләребез арасында, Омскида, Троицкида, Тобольскида хәтта казахлардан да кешеләр бар. Бер-беребезне син татар, син башкорт, син казах дип бүлүгә түгел, юк, бөтенебез бертигез, мөселман без, Аллаһның бәндәсе без дип алып баруга килдек. Шуның өчен дә Диния нәзарәте киләчәктә дә бу халыкларның бер-берсен хөрмәт итүенә, бер-берсенә ярдәмле булуына, иншаалла, хезмәтен алып барачак һәм, әле Сез әйткәнчә, тарихи-мәдәни булган истәлекләребезне — кайда гына булса да алар — саклауга, кире үзебезгә кайтаруга хәрәкәт итәчәк. Әйтик, Казан күрке булган, аның тарихи төсе булган Сөембикә манарасын гына алыйк. Ә бит ул — халкыбыз кичкән авыр сынаулар ядкяре дә әле. Сөембикә манарабыз яңгыр суларыннан түгел, шәһитләр каныннан ава язды. Сөембикә манарасына ай куйыйк, дип Югары Советтан рөхсәт сорадык. Болытлы төннәрдә, күктәге аебыз күренмәгәндә, Сөембикә манарасындагы аебызга карарбыз. Чиркәве дә, хачы да торсын. Хачы янында ае да булсын. Рус халкы белән дус булып яшәвебезне күрсәтеп торсын! Ай булыр, аны күргәч, иманнарыбыз яктырып китәр...

Инде үз тормышымнан да бик гади генә бер мисал китерәсем килә. Моннан бер-ике ел элегрәк, Ризаэддин ибн Фәхреддин хәзрәтләренең «Әлбәләгуль-мөбин» дигән китабының кульъязмасын Үзбәкстанга бирәүләр алып сатканнар иде. Юлда күреп, инде Үзбәкстанга китә торган кулларда күреп шул кульъязманы, мин алты йөз сумга кире сатып алырга булдым, ике бәя биреп булса да. Чөнки бу кульъязмалар безнең байлыгыбыз ул, безнең халкыбызның хәзинәсе ул. Нәзарәтнең яңа бинасын төзегән вакытта без, иншәалла, илебездә ислам тарихы музеена да урын ясарга уйлыйбыз. Ләкин Уфада гына түгел, безнең зур биналарыбыз Казанда, Мәскәүдә, Ленинградта, Әстерхан шәһәрләрендә дә бар. Иншәалла, һәрбер мәчеттә мондый бүлекләр булыр дип уйлыйбыз.

**Язучы.** Халкыбызга татар китабы һәм язма мирасы музее да бик кирәк. Казан университетының сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлеге кебек, тимер рәшәткә артындагы, әз кешегә генә күрү мөмкинлеге бирелгән хәзинә булмасын иде ул. Әгәр инде тиешле дәүләт оешмалары кызыксыну күрсәтмәсәләр, мәчетләр каршында да бу эшне башкарырга мөмкин түгел микән? Ташъязмаларыбыз, мең елдан артык тарихы булган кульъязма китапларыбыз бергә җыелса, мәшһүр Матенадараннан бер дә ким булмас иде.

Кызганыч хәл түгелмени, хәзрәт: без мең еллык язма культурабыз бар дип күкрәк сугабыз, ә кайда ул язма мирас дигәнебез?.. Чишелмәгән табышмакка әйләнеп, чормаларда тузан эчеп, җир куенында череп ятты-ятты да... Ә бит мирас бик астында түгел, халык күңелендә яшәвен дәвам иткәндә генә, аның көндәлек тормышында турыдан-туры катнашканда гына чын мәгънәсендә байлык һәм бәрәкәтле туфрак була ала. Нибары «әлифба» сүзе генә кайчандыр шундый хәрефләребез булганны искәртеп тора... Әле моннан дүрт-биш ел элек кайбер зыялыларыбыз ачыктан-ачык: «Кемгә кирәк ул «комган» хәрефләр?» — дип әйтергә оялмыйлар иде. Дөрес, бернечә ел эчендә әлифбаны алфавитка, аннары азбукага алыштырган халык — шул халыкның бер өлеше — хәзер бик кызыксынып тарихи («борынгы» түгел, «иске» түгел — тарихи!) язуын өйрәнә. Әмма теге «зыялылар»ның соравы искә төшә: өйрәнеп тә нәрсә укырлар соң алар?.. Шуңа күрә хәзерге хәрефләрне «камилләштерү» юлы җиңелрәк тә, дөресрәк тә, дип раслаучылар күп; алар үзләренчә хаклы бугай...

Җәмәгатьчелек белән бер очрашуда Сез «камилләшкән», «койрыклы» хәрефләргә мөнәсәбәт сиздереп алган идегез. Ләкин шунысы аңлашылып җитмәде: татар әлифбасының бүгенгесен һәм киләчәген ничегрәк итеп күз алдына китерәсез?

**Мөфти.** Кызганычка каршы, соңгы илле-алтмыш ел арасында безнең халыкка һәм илебездәге башка төрки халыкларга да бик үкенечле хәлне кичерергә туры килде. Ул да булса — шушы дәвердә өч тапкыр әлифбаның үзгәрүе. Мең ел дәвамында кулланылып килгән гарәп язуы безнең үз хәрефләребез булып әверелгән иде. Тарихыбыз шул хәрефләр белән язылган. Буыннан-буынга күчеп килгән, шуңа күрә безнең өчен кадерле мирас, атабаба васыяте булган, шуның белән бергә күз ямебез дә булган әлифба ул. Халыкны хәтта матурга гадәтләндерү, матурга омтылдыру тәрбиясе дә булды бу хәрефләрнең. Әйтик, ул заман китапларының зифа буй-сынны «әлиф»кә, кочаклашып торган егет белән кызны «лям-әлиф»кә охшатуы бик истә калган... Шиксез ки, матурга омтылган кешедә начарлык кимрәк була. Хәтта пәйгамбәребез саллаллаһ галәйһивәсәлләм дә, яхшылыкны, изгелекне матурлыктан эзлә, дип өйрәтә.

Безнең халык һәртөрле реформага һәвәс дип тә әйтер идем. Ләкин ул бездә ни өчендер гел ярым-йортырак килеп чыгучан була. Латинга, аннары кириллицага күчү, инде бүген үзләрен галим дип йөргән кайсыбер кешеләрнең хәрефкә койрык тагу белән мавыгуы — болар берсе дә алга китешне кайгырту түгел, бары тик халыкның яңарышка сусавын үз мәнфәгатьләренчә басу омтылышы гына. Сез, бәлки, моның белән килешмисездәдер...

Әмма манаралар кисү, чиркәүләрне җимерттерү кебек үк, халыкның рухында бушлык хасил итте хәрефтән аеру. Ул бушлыкка ни тулды? Болыннарыбызны баскан, авылларыбызны күмгән, зиратларыбызны юган ГЭС суларымы әллә? «Куып җитәбез һәм узып китәбез» дигән язулы чүпрәкләрме? Шуның өчен кайбер кешеләрнең бүгенге көндә безгә хәзерге алфавитны үзгәртеп, кайсына койрык тагарга, кайсына тагын бүтән үзгәрешләр кертеп яраклаштырырга уйлавы — бу бер иләктән икенче иләккә су салу шикелле генә булыр дип уйлыйм. Әллә нәрсә уйлап чыгарасы түгел, мең ел безнең халкыбызга яраган язуны кайтарудан башка чара юк дип уйлыйм. Бу — минем генә фикер түгел. Хәтта үзбәк, азәрбайҗан, төрекмән, казах арасында да бу хәрефне кайтару хакында сүзләр йөри. Моңа үрнәк эзләп йөрисе дә юк: Балтик буе халыкларында булсын, шул ук Әрмәнстанда, яисә Грузиядә булсын — үзләренең борынгы әлифбаларын саклап калган милләтләргә туган телләрен дә сакларга уңайлырак булды, шуның белән бергә милли гореф-гадәтләрен, халыкның тарихи аңын, мәдәни байлыгын сакларга да шуның ярдәме тиде. Әгәр без дә киләчәктә, озакка сузмыйча, бу хәрефләрне кайтара алсак, тормышыбызга кертә алсак,— әлбәттә, бер көндә генә эшли торган эш түгел ул, алдан аны ихтыяри рәвештә, аңлы рәвештә

өйрәнү, аннары халыкның зур өлеше таныганнан соң гына рәсми рәвештә дә кайтару мөмкин — шуның белән без бөтен ислам дөньясы белән үзебезнең борынгыдан килгән мәдәни һәм тарихи элементләребезне тагын да ныгытуга ирешер идек, безнең Совет иленә дөньяда үзенчәлекле мәйдан биләгән ислам дәүләтләре белән дус булырга да моның тагын бер ярдәме булыр дип уйлыйм.

**Язучы.** Гарәп язуының бизәк, кайчакта сурәт рәвешенә үк керүе ислам дине белән, аның рәсем сәнгатен төрлечә тыюлары белән бәйләнгән, диләр. Җан ияләрен ясау тыеламы, дигән сорауга Ибн Габбас исемле хәкимнең җавабын искә төшерәләр: «Рәхим итеп ясый бирегез! Тик бер генә шарт: төшергән рәсемегез тереклек иясенә охшамасын»,— дигән ул... Ә сүз белән сурәт ясау Коръәндә үк бар. Коръән — ислам динендәгеләргә аллаһ сүзе булудан тыш, дөньядагы бүтән диндәге, яисә дингә ышанмаган кешеләрне дә илаһи бер күренеш булуы белән сокландыра. Белгәнебезчә, андагы аһәң, сурәтлелек, фикер галәме заманында хәзрәте Пушкинны да рухландырган. Пушкинның Коръәнне нинди телдә укыган булуы әле хәзер дә төрле бәхәсләр уята... Сезнеңчә, шушы гаҗәеп язмышлы китапның татар телендә лаеклы тәрҗемәсе бармы? Бу юнәлештә нинди дә булса эш алып барыламы?

**Мөфти.** Дөньядагы бик күп халыклар, хәтта япон, француз, инглиз телләренә дә тәрҗемәсе бар Коръән-кәримнең. Тик әлегә татар теленә бигүк яхшы тәрҗемәсе күренми. Тәфсирләр бар. «Әл-иткан фи тәрҗемәтил-Коръән», «Тәфсир Ногмани» бар. «Тәфсир әл-Фәүаид» бар. Аларда Коръән-кәримнең мәгънәләре татарча аңлатыла. Без шушы мөнәсәбәт белән Татарстан хөкүмәтенә мөрәҗәгать иттек: Коръән-кәримнең тәфсирен якын елларда бер утыз меңләп данә булса да бастырып чыгарырга ярдәм-рөхсәт сорадык. Татар телендә бик яхшы бер тәрҗемәсе кирәк иде. Ләкин хәзерге көндә бездә ул дәрәҗәдәге белгечләр, чын затлар юк дип әйтергә мөмкин. Әле рус телендә дә Коръән-кәримнең яхшылап чынлап таяна алырлык тәрҗемәсе юк. Крачковский булсын, Саблуков булсын,— алар бик зәгыйфь тәрҗемәләр.

**Язучы.** Коръәнгә теләсә кем килеп тотына алмый шул. һәр сүрәсе, һәр аяте аша аңлаптоен бетерә алмаган мәгънәләре күңелгә тапшырыла. «Сүрә» дигән сүзнең баштагы мәгънәсе «таш дивардагы рәт» икәнен белсәк, кирпечкә кирпеч куелган кебек тыгыз, нык җөмләләр рәте күз алдыбызга килә. Болай карап торышка гади генә стена сыман, ә нинди измә-раствор белән береккән — шуның хикмәтен әлегәчә таба алмыйлар...

Хәзрәт, дини һәм иҗтимагый эшчәнлек Сездән күп җегәр, күп вакыт сарыф итүне сорый. Шулай да, Коръән һәм башка дини китаплар укудан тыш, дөньяви әдәбият, матбугат белән дә беркадәр танышырга мөмкинлек табасыздыр дип уйлыйм. Бүгенге язучылардан яисә классик әдәбияттан нинди әсәрләр, китаплар игътибарыгызны җәлеп итә?

**Мөфти.** Без үзебезне, ягъни совет кешеләрен, дөньяда иң күп китап укучы дип саныйбыз бик хаклы рәвештә. Әмма, мин әйтер идем, дөньяда иң күп укучы халык ул — балалар һәм яшүсмерләр. Мин үзем әдәбиятны бик күп итеп укыдым мәдрәсәгә барганчыга хәтле. Шул, үземне таный башлаганда, унөч-ундүрт яшемдә, китапны алсам, укый идем мин ике көн, күп дигәндә. Чөнки төннәр буенча да укып чыгадыр идем. Әни әле шуның өчен орыша торган булса да, күзләрең бозылыр, дип... Мәдрәсәгә киткәннән соң һәм менә эшли башлаганнан соң инде, кызганычка каршы, калын-калын романнарны уку рәхәте бик сирәк насыйп була. Башка нәрсә белән шөгыльләнү күп вакытны ала. Ләкин барыбер «Казан утлары»н, «Агыйдел»не карап чыгарга тырышам. Калышмаска тырышам. Шуның белән бергә Чыңгыз Айтматов язганнарны махсус күзәтеп барам. «Буранный полустанок» һәм «Плаха»сын укып бик куандым. «Буранный полустанок» дигән китабында бигрәк тә — кайсы төшендә сөенеп, кайсысында көенеп — җылый-җылый укырлык сәхифәләре күп булды... Ул язучыга күңелемнең иң нечкә бер төшендә аерым мәхәббәтем бар.

**Язучы.** Артыгын тәпченә дип уйламагыз, хәзрәт, әмма күңелне кытыклап торган бер соравым бар... Игътибар итеп калдым: әңгәмәбез алдыннан гына, «фәлән артист китерде» дип, Сезгә магнитофон кассетасы тапшырдылар...

**Мөфти.** Ә без аны тыңлап та карый алабыз хәзер. Анда яңа җырлар, татар эстрада көйләре булырга тиеш...

**Язучы.** Рәхмәт, вакытыбыз калса, бәлки, соңыннан тыңларбыз. Мәчеттә җыр-музыка тавышын ишеттерү гөнаһ саналмасмы соң? Ул кассетаны Сезгә алып килүләренең хикмәте нәрсәдә?

**Мөфти.** Аның сәбәбе бик гади. Һәрвакыт, юлга чыкканда безнең машинабызда «җыр тартмасы» йөри. Татар-башкорт халкының көй-моңнарын, намаз вакыты булмаса, сөенеп тыңларга яратам. Сөенеп! Чөнки алар буыннар буе безнең каныбызга сеңгән, күңелнең иң нечкә кылларын тәрбияләгән. Ләкин, кызганычка каршы, әле безнең җырчыларыбыз да, музыкантларыбыз да арттарак калып баралар дөньядан. Мин шуны да уйлыйм: үзебезнеке белән генә чикләнергә тиешле түгел без. Ничек итеп кырдагы төрле гөлләрнең исен иснәү безгә ләззәт китерә торган булса, төрле халыкның мәдәниятеннән өлеш алу кеше-

не баета гына, бер вакытта да фәкыйрь итми. Дөньяда бүгенге көндә танылган, яшьләр ярата торган ансамбльләр, яңа җырлар, көйләр бар. Аларны да үзебезнең телебезгә, үзебезнең моңнарга якынайтырга, Көнбатыштан да, Көнчыгыштан да үрнәк алырга кирәк. Без үз казаныбыздарак кайныйбыз шикелле һаман да. Бүтән төрки халыклар әдәбиятта булсын, җыр-музыкада булсын — шактый алга киттеләр; безгә дә дөнья культурасына, музыка һәм җыр культурасына якынаюда юл эзләргә кирәк иде, дип уйлыйм мин. Менә шул уңай белән бик сөендергән бер вакыйга: Шиһабеддин Мәрҗани хәзрәт исемендәге җәмгыять Казанда очрашу үткәрде дин әһелләре һәм җәмәгатьчелек белән; көрәшүебезнең ахырында бик матур концерт булды. «Сорнай» дигән ансамбль борынгы болгар көйләрен безгә ишеттерде. Шундый эзләнүне безнең яшьләребездә күрү — бик шатлыклы, сөенечле бер хәл. Әле күңелемнең бер төшендә тотам: бәлки, Аллаһ насыйп итсә, киләчәк вакытта мәчетләр янында хәтта дискотекалар да булыр дип уйлыйм. Яшьләр дә килсеннәр. Картлар намаз укырлар, яшьләр биеп торырлар. Бер-берсеннән үрнәк, гыйбрәт, дәрт алып. Бии алган кеше намазны укый ала, әмма намаз укый алган һәр кеше бии алмый.

**Язучы.** Телевидениенең беренче программасы буенча Сезне «Кинопанорама»да күреп калган идек. Сез анда, кино сәнгате ислам дине кануннарына каршы килми, дидегез.

Татар халкы әлегәчә әнә шул олы сәнгатьтән — үз телендә, үз тормышыннан кино төшерү һәм караудан мәхрүм... Ул ихтыяҗны әле дә булса театр гына азмы-күпме канәгатьләндереп килә. Шуңа күрәдер бездә хәтта бик көпшәк, ясалма спектакльләргә дә халык күп йөри...

Ә Сез театр карарга вакыт табасызмы, театрга бару Сезнең дини вазифагызга каршы килмиме? Хәзерге татар-башкорт театры турында фикерегезне ишетү кызыклы булыр иде.

**Мөфти.** Иң бәхетле сәгатьләр итеп саныйм гомеремдә — кирәк татар театрында, кирәк башкорт театрында булуымны. Без кадерле кунаклар килгән чагында, хәтта кайберләре (мәсәлән, гарәпләр) телне аңламасалар да, моңыбызны, рухыбызны аңласыннар дип, театрга алып барабыз. Мин безнең театр эшлеклеләренә — Казанда булсын, Уфада булсын — зур уңышлар телим, алар үзләренең вазифасын безнең кайбер муллаларыбызга караганда да яхшырак итеп үтәп киләләр. Аллаһ ярдәмнәр бирсен аларга. Чөнки алар милләткә хезмәт итә, яшәвебезгә хезмәт итә, милли гореф-гадәтләребезне, моңыбызны саклауга бик зур өлеш кертәләр. Изге эш дип саныйм аларның эшләрен.

**Язучы.** Сезне татар, рус һәм гарәп телләреннән тыш, кайбер Европа телләрен дә беләсез, дип сөйлиләр. Эш буенча, янсә сәяхәт тәртибендә әлегәчә кайсы чит илләрдә булырга туры килде?

Соңгы вакытларда чит мәмләкәтләрдә яшәүче күренекле милләттәшләребез, бигрәк тә галимнәр турында кайбер мәгълүматлар ачыктан-ачык языла башлады. Чит илләрдә яшәп калган татарлар Диния нәзарәте белән элемтә тоталармы? Алар белән үзара танышлыгыгыз ничек, араларында кызыклы шәхесләр бармы?

**Мөфти.** Хезмәтем буенча, әлбәттә, миңа дөньяның бик күп почмакларына барырга туры килде. Гарәп илләренең күбесендә булдым. Мисырда дүрт ел яшәүдән тыш, тагын Ливиядә, Тунисга, Мароккода, Сүриядә, Иорданиядә, Йәмәннең икесендә дә, Согуди Гарәбстанда берничә кат, Төркиядә.

Дөнья күрү — бүтән ил, халыкның һавасын сулау, аның тарихының кайнар сулышына кагылу, бүгенге гамь-мәшәкатьләрен тою гына түгел, ул үзеңне, үз халкыңны да аңларга ярдәм итә. Гарәп-Көнчыгыш илләре — «Мең дә бер кичә» әкиятләрендәге кебек, мең еллар дәвамында тупланган гаҗәеп рухи хәзинә сандыгы ул. Дөнья диннәре һәм культуралары тарихында искиткеч урын тоткан җирләр. Безне бәйләп торган дини-тарихи-мәдәни уртаклыклар күп. Пәйгамбәребезнең туган җирендә — Мәдинә шәһәрендә, мәсәлән, Казан мәчете бар. Аның янындагы мәдрәсәдә 70 нче елларга кадәр татар телендә дәрес бирелде... Әмма тарих кына түгел, ислам илләренең бүгенге тормышта, дөньяда биләгән урынын да исккә алганда, бу кызыксыну-тартылу тагын да ныграк аңлашыла.

Европа илләреннән миңа Даниядә, Финляндиядә, Франциядә булырга туры килде. Японнядә бер-ике тапкыр булдым. Америка Кушма Штатларында. Бу сәяхәтләр, әлбәттә, гадәти сәфәр булудан бигрәк, кайсылары андагы дини оешмаларның чакыруы буенча, кайсысы — безнең илдән төрле делегацияләргә катнашу иде (мәсәлән, Алжирга, Әфганстанга шулай бардым). Бу сәфәрләрдә, әлбәттә, төбе безнең илдән чыккан ватандашларыбыз, бигрәк тә татар халкының вәкилләре белән очрашуларыбыз булды. Тормышның, язмышның төрле хәлләре аркасында алар бездән аерылган, ерак булсалар да, туган илләренә искиткеч мәхәббәтләрен саклаганнар. Моңарга дәлил — Австралиядә янсә Япониядә яшәп тә, үзебезнең телдә саф, нәкъ Казанда сөйләшкән шикелле иттереп сөйләшүләре, балаларын шул рухта тәрбияләргә тырышып, милли әдәбиятыбыз белән кызыксынып, гореф-гадәтләребездән аерылмыйча, хәтта үзләрендә Сабантуйлары ясаулары. Ана кичә-

ләре үткәрүләре — болар бөтенесе туган илгә булган ихлас мәхәббәтләрен күрсәтә. Шуның белән бергә, илебездә бара торган үзгәртеп кору шартларында, чит илдәге дин һәм милләт кардәшләребез белән элемтәләребез көннән-көн ныгып килә. Быелгы бәйрәм мәҗлесебездә катнашасылары килеп, бик күп илләрдән — Америкадан, Канададан, Төркиядән, ГФРдан, Австралиядән гаризалар, теләкләр алынды. Бу кешеләр, әлбәттә, безнең халкыбызның язмышы белән, бүгенге көне белән бик кызыксыналар, илебез хакындагы төрле уйдырмалар белән башлары мөлдерәп тулган булса да, аның ялган икәнлеген әкренләп аңлый баралар, шуны үз күзләре белән күрәселәре килә: безнең илебезгә килеп, туган авылларын, шәһәрләрен, ата-бабалары яшәгән җирләрне күрергә телиләр. Боларның арасында зур галимнәр бар, бүгенге көндә төрле өлкәләрдә хезмәт күрсәтүче кешеләр, промышленниклар, миллионерлар бар. Тормышта үзләренең урыннарын тапкан кешеләр күп. Боларның безнең илгә килүе, Диния нәзарәте һәм илебездәге башка оешмалар белән элемтәдә булулары, бер-беребезне аңлаулар һичшиксез дөньядагы бөтен илләр арасында татулыкны урнаштыруда, бер-беребезгә ышануның көннән-көн ныгуында ярдәм булыр дип өмет итәбез. Диния нәзарәте алар белән һәрвакытта язышып тора, илебездәге матур үзгәрешләр турында аларны хәбәрдар итә.

**Язучы.** Мисырда дүрт ел яшәдем дип, анда укыган елларыгызны искә алгансыздыр, әйеме? Татарлар арасыннан чит илдә укыган кешеләр булу хәзер әллә ни гаҗәп тә түгел. Ә менә Шиһабеддин Мәрҗани «Мөстафадел-әхбар...»ында ук укымышлы мулла-мөдәррис Шәмседдин ибн Габдерәшид Кышкарый турында язып калдырган... Сезгә бу исем, әлбәттә, таныш: Каһирә университетында ул җиде ел фарсы теле укыткан. 150 елдан соң Сез — аның якташы, милләттәше — шушы университетны тәмамлагансыз. Аңа кадәр дин гыйлемен кайда үзләштердегез, гомумән, бу юлга ничегрәк кереп киттегез?

**Мөфти.** Әти-әниләрем мөселман гаиләсеннән. Әти дә, бабаларым да рухани булмаганнар, муллалар түгел, ләкин мөселман булып яшәгәннәр. Аллага ышанганнар, диннең гореф-гадәтләрен тотарга тырышканнар. Әбием миңа өйрәтеп килде һәрвакытта да догаларны. Үндүрт-унбиш яшьләремдә, мәктәптә укыган чагымда, инде мин шәмаилләр белән кызыксына башладым. Шәмаилдә, аннары Коръәндә ниләр язылганны укый, аңлый алмау — шул мине бик көендерә иде. Гарәп теле белән ныклабрак кызыксына башладым. Кулыма гарәп теле дәреслеге эләккән иде, шуңардан гарәп хәрефләрен өйрәнеп алдым, бераз җөмләләр төзергә өйрәндем. Аннары мәчеткә йөри башладым. Ул вакытта, билгеле, «торгынлык» заманы иде, дип әйтик,— бик күп кешеләргә, укытучыларга, хәтта кайбер якыннарыбызга да ошамый иде минем бу кызыксынуым. Шулай да мин мәчеткә йөрүемне дәвам иттем. Ә инде унсигез яшь тулган чагында, 1966 елны, Казан Мәрҗани мәчетенең муллалары һәм мөдәррисләре мине Бохара мәдрәсәсенә күндерделәр. Ләкин ул вакытта да берничә тапкыр кыенлыклар кичерергә туры килде. Төрле яктан ризасызлыклар булу аркасында, мәдрәсәдән чыгару мәсьәләләре булды. Казанга кайткан чагымда хәзер Мәрҗани мәчетендә имам-хатыйб булып торучы Әхмәдзәки хәзрәттән сабак алдым, өенә йөреп. Ул чакта үзем ашханәдә эшләдем. Ике көн эшлидер идем, ике көн Әхмәдзәки хәзрәткә укырга барадыр идем. Гарәп телен, тәфсирләрне, хәдисләрне өйрәнеп чыктым. Бу сабак алуым мәдрәсәне тәмамлауга бик яхшы ярдәм итте. Мәдрәсәне 1973 елны бетергәннән соң, нәзарәт мине Казанның Мәрҗани мәчетендә икенче имам-хатыйб итеп билгеләде. Соңыннан, нәзарәтнең күндерүе белән, 74 нче елдан алып 78 нче елга хәтле Каһирәдә әл-Әзһәр университетында укыдым. Ул еллар миңа гарәп телендә осталыкны арттырырга, сөйләшү телен ныклап өйрәнергә, дөнья әдәбияты һәм дини әдәбият белән тирәнрәк танышырга ярдәм итте, шуның белән бергә дус-ишләр арттыруга да сәбәпче булды: анда 70 кә якын илдән студентлар укый иде. Каһирәдән кайтканнан соң, Мәрҗани мәчетендә беренче имам-хатыйб булып хезмәт иткән идем. 1980 елда мөфти итеп сайланганчы.

**Язучы.** Мөфтине ничә елга дип сайлыйлар? Аннары кайберәүләрдә шундый кызыксыну да булырга мөмкин: әйтик, мөфтинең хезмәт хакы күпме, аны кем түли?

**Мөфти.** Октябрь революциясенә хәтле мөфтине патша куядыр иде. Мөфтиләрнең айлыкларын да патша бирәдер иде. Октябрь революциясеннән соң иң беренче сайланган мөфти Галимҗан Баруди хәзрәтләре булды. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең ректоры. Аннан соң — Ризаэддин ибн Фәхреддин хәзрәтләре... Мин бүгенге көндә уникенче мөфти — сайлап куелган. Гомерлек иттереп сайланды. Ләкин без хәзер яңа уставларны эшлибез. Анда ничек куелыр — 5 елгамы булыр, яисә гомерлеккәме булыр — халыкның фикеренә, теләгенә карарбыз. Бездә дә перестройка һичшиксез булырга тиешле.

Айлык хезмәт хакы түләнә мөселманнарның сәдакаларыннан. Хөкүмәттән бер тиен дә алмыйбыз. Хезмәт хакы мөфтинең — алты йөз сум.

**Язучы.** Мөфтинең төп эш урыны кайда булуын, аның ниләр белән шөгыльләнүен дә бераз аңлатыгыз инде.

**Мөфти.** Төп эш урыным — Уфада, Диния нәзарәтендә, ләкин миңа эш урынымда утырырга сирәк туры килә. Әйткәнемчә, елына берничә тапкыр чит илләргә чыгам. Үзебезнең илдә ел арасында унбиш-егерме мәхәлләдә булам — безнең халыкның теләген искә алып. Имам белән мөтәвәллият арасында, кайвакытта мөтәвәллият һәм имам белән хөкүмәт арасында аңлашылмаган-килешенмәгән нәрсәләрне хәл итешәм. Яңа мәхәлләләр ачу, яңа мәчетләр салуны юллап барулар бик күп була. Шуның белән бергә мин Мәскәүдәге чит илләр белән элемтә бүлегебезнең рәис-мөшәрифе — дүрт Диния нәзарәтенең рәисе үл эшне уртак итеп алып барабыз. Чит илдә укырга шәкертләр җибәрү, чит илдән кунаклар китерү, бездән дин әһелләренең төрле делегацияләрдә чит илгә чыгуын хәл итү — болар барысы да безнең эшебездән санала. Шуның өчен дә, ай саен дип әйтергә мөмкин, берничә тапкыр юлда булам.

Кайберәүләр нәзарәтне Казанга күчерү турында сүз кузгаталар. Әби патша аны юри Уфага илтеп куйган, диләр. Ләкин бездә андый уй юк. Без бөтен төшне изге дип санайбыз. Тарихи яктан, ике йөз ел буе Уфада урнашкан икән, бу һәр җәһәттән дөрес булса кирәк. Аның хәтта географик яктан да бик күп уңайлыклары бар. Казанга да, Мәскәүгә дә якын, шуның белән бергә Оренбург, Себергә дә якын. Нәкъ Мәккә шикелле, кыл уртасында илебезнең.

**Язучы.** Без инде Сезнең хезмәтегезгә генә түгел, шәхси тормышыгызга да кагылышлы сорауларга килеп җиттек бугай. Шул уңайдан яшәү урыныгыз, җәмәгатегез турында берничә сүз ишетәсе килә.

**Мөфти.** Тууым-үсүем Казанда иконлеген әйттем. Мөфти итеп сайланганнан соң инде гаиләмне Уфага күчерергә мәҗбүр булдым. Хәзер Уфада яшибез, нәзарәт йортында.

Әти-әниләрем Казанда. Сеңелем, башка туганнарым, җәмәгатемнең әти-әниләре, абый-энеләре Казанда яши.

Гаиләм: минем биш балам бар — ике кызым, өч малаем. Олы кызыбызны инде кияүгә бирдек. Казан егетенә. Улларымның олысы техникумны, кече кызым аш-су әзерләү училищесын бетерде. Ике улым мәктәптә укый: Мөхәммәт — алтынчы классны, Гомәр — өченчене тәмамлады.

Җәмәгатемнең исеме Сания. Ул алдан заводта эшләде, беренче балабыз туганчыга хәтле. Беренче балабыз туганнан бирле инде эшләми беркайда да дип әйтсәм, гөнаһ булыр — өйдә эшли, балаларыбызны мөселман иттереп үстерергә тырыша.

**Язучы.** Балаларыгызны тәрбияләүдә, аларның шәхси кызыксынуларына йогынты ясауда Сез ничек катнашасыз? Алар ни белән мавыга? Киләчәктә Сезнең юлны сайларга ниятләп торучысы күренмиме?

**Мөфти.** Балаларга, аларны тәрбия кылуга беркадәр әһәмият бирергә тырышам. Күбесенчә, әлбәттә, аналары янында. Ананың вазифасыннан инде ул. Ир кешенең җаваплылыгында бит гаиләнең тамагын туйдыру, өстендә түбә булдыру. Аларга, әлбәттә, бераз авыррак туры килә минем бу сәфәрләрем аркасында, ләкин моңа күнектеләр инде. Хәтта мин чит илдә торып укыган вакытта да сабыр итеп, балаларны үстерергә, тәрбияләргә җәмәгатем күнде. Шуның өчен минем ярты эшемне хатыным эшли дип тә әйтергә мөмкин.

Балаларыбыз барысы да гарәпчә укыйлар, язалар, Коръәнне таныйлар. Намазны бөтенесе дә укый. Мәктәпкә беренче киткәннәреннән алып намаз аларга өйрәтелеп киленгән. Хәзер инде үзләре аңлап, белеп укыйлар. Хәләл белән хәрәмне барысы да аералар. Аллага шөкер, балаларыбыз бездән дә күбрәк мөселман.

Хайваннарны яраталар. Этләрме анда, мәчеләрме, балыклармы, кошлармы — аларның бөтенесе дә безнең өебездә бар. Ул җан ияләре балаларга бик яхшы тәэсир итә. Аларның күңелләрен йомшаграк итеп тәрбияләүгә. Мин үзем дә хайваннарны яратам.

Ата-ана бурычын үтәр өчен, балаларыбызга мөселманча исем кушарга тырыштык, әдәп-әхлаклы итеп тәрбияләргә тырыштык. Аннан соң инде, үсеп җиткәннән соң, Аллаһ һидаят бирсен дип һәрчак теләктә торабыз. Ләкин нинди һөнәр, нинди юлны сайлауга аларны мәҗбүр итәчәк түгелбез гомумән.

**Язучы.** Мөфтинең көндәлек тормышы намаз уку, вәгазь сөйләү белән генә үтмәгәнлеге инде шактый яхшы аңлашылды. Шулай да ял сәгатьләрегезне ничек үткәрәсез?

**Мөфти.** Кичке сәгатьләрне гаилә белән, балалар белән бергә уздырабыз. Телевизорны бик яратып карыйм. Иң яратканым — мультфильмнар, «Вакыт» программасы... Нәфис фильмнарны да караштыргалыйм.

Фильм дигәннән, нәзарәтнең хезмәткәрләре белән бөтенебез җыелышып культпоходлар ясыйбыз: кинога чыгабыз (абонементларыбыз бар), йә театрга, концертка барабыз. Кыш көннәре чаңгыда чыгулар да була.

Без халык арасында күбрәк булырга, халыкның сүзенә колак салырга, үзебезнең сүзне аларга җиткерергә тырышабыз. Илебездәге саф җилләр халык белән дин әһелләре

арасындагы киртәләрне җимерде. Аллага шөкер. Без бит кешеләр арасына хәнҗәр тотып түгел, аракылы стакан күтәреп түгел, гаделлеккә, шәфкатьлелеккә, әхлаклылыкка өндәү сүзе белән киләбез.

**Язучы.** Сезнең сүзне ишетерләр һәм дөрес аңларлар дип ышаныйк, хәзрәт. Әңгәмәгез өчен рәхмәт. Мондый сөйләшүгә ихтыяҗ бар иде, минемчә. Соңгы вакытларда матбугат битләрендә руханиларга сүз бирүнең гадәти хәлгә әверелүе дә шуны раслый.

Әле менә күптән түгел генә «Правда»да Рим папасы белән очрашу хакында мәкалә чыкты. Ул «Папа булу кыенмы?» дигән сорау белән башлана. Сезгә дә иң соңгы итеп шул сорауны бирәсе килә: мөфти булу кыенмы?

**Мөфти.** Кыен мөфти булу. Авыр. Мин мөфти булырга дип тәкъдим ителгән чагында ел ярым каршылык күрсәттем. Ләкин инде барыбер миңа йөкләнгән икән, хәзер мин ул йөкне тартам, Аллаһ ризалыгы белән. Һәм минем эшем мөселманнарга лаеклы булган вакытта, ул авыр түгел. Чөнки әгәр дә дөрес иттереп алып барсак, Аллаһ үзе ярдәм итә. Аллаһ ярдәменнән ташламаганда, бер эш тә авыр түгел, иншәаллаһ.

* * *

Адәм баласы Җир белән Күк арасында яши.

Җир табышмагына җавап эзләп, Кеше Күкләр белән сөйләшә.

«Маймыл варислары» булган бабайларның фикер галәменә ис китәрлек!

Ә без, без соң — космос гасырында яшәүчеләр — башны күтәреп күккә багарга вакыт табабызмы? Ни белән яшибез? Ни өчен яшибез? «Идеал — алла ул» дигән сүзләрне ничек аңлыйбыз?..

Бу сорауларны инде мин үз-үземә бирдем.

...Мәчеттән без мөфти белән бергә чыктык. Юбилей уңаеннан аның фани дөнья белән бәйле үз мәшәкатьләре — Кремльгә, Татарстан китап нәшриятына, тагын кайларгадыр барасы бар икән.

Юк, дин белән мәгыйшәт арасы — Тәлгат Таҗетдин белән безнең ара үтеп чыга алмаслык чик сызыгы белән бүленмәгән. Ул, чын мәгънәсендә, ике дөнья арасына баскан. «Теге» дөнья белән «фани» дөньябыз арасына гына түгел, кешенең матди дөньясы белән рухи дөньясы, җәсәде белән җаны арасына басып, бик авыр бурычны — адәм баласының рухиятен, табигатен яклауны үз өстенә алырга тырыша мөфти хәзрәт. Бу юлда аңа теләктәш булмый мөмкинме?! Үзе үк әйтмешли, «ходай ярдәм бирсен».

**Артур Сәгадиев**

# МӘРҖАНИ ҺӘМ ГАРӘП ФИЛОСОФИЯСЕ

Гаять зур һәм күпкырлы бу проблеманың без бер ягына гына тукталырга булдык. Бер яктан ул татар халкының күренекле галиме һәм фикер иясе Шиһабетдин Мәрҗанине фәлсәфи фикер тарихчысы буларак күз алдына бастырырга ярдәм итсә, икенче яктан ул гарәп-мөселман мәдәниятен өйрәнүче хәзерге заман галимнәре өчен дә гыйбрәтле. Атап әйткәндә, без үз халкының культурасын өйрәнүче татар галименең Көнбатышның ориенталистика (ягъни Шәрыкны өйрәнү фәне) казанышларына мөрәҗәгать итмәгән хәлдә моннан берни дә югалтмавын гына түгел, ә киресенчә, Көнчыгышның философик фикерләре турында Европа стереотипларына бәйле булган хаталардан азат буларак, кайбер мәсьәләләрдә Көнбатыш ориенталистикасын тулы бер гасырга узып китә алганлыгын күрсәтмәкчебез.

...1899 елда Казанда В. М. Ключников басмаханәсендә Россиядә иң беренчеләрдән һәм шул ук вакытта урта гасыр гарәп-мөселман философик фикере тарихы буенча иң төпле хезмәтләрдән булган китап басылып чыга. Ул — «Мөгътәзилиләр: ислам дине өлкәсендә догматик-тарихи тикшеренү» дип атала. Аның авторы күп еллар Россиядә, шул җөмләдән Казанда да яшәгән һәм хәзерге көндә Палестина гарәп халкының горурлыгы саналучы палестиналы гарәп Пантелеймон Жузе була. Ул урта гасыр гарәп-мөселман культурасында бу рационалистик юнәлешнең чәчәк аткан чоры турында язганда мөгътәзилиләрнең хөр фикерлеге үсешендә әл-Мәэмүн хәлифәнең (813-833) уңай роль уйнавын аеруча басым ясап күрсәткән. «Бу мәгърифәтле хәлифә, — дип язган П. Жузе, — мөгътәзилиләр доктринасын ачыктан-ачык кабул итү белән генә чикләнми, ә бәлки үзенә буйсынган барлык кешеләрнең дә аның белән бер үк дини карашта булуын тели. Бу максатка ирешү өчен ул, табигате белән бик тәвәккәл кеше буларак, берни алдында да тукталып калмады... Аның вакытында мөселман дөньясы беренче тапкыр дини инквизиция оештырган трибуналлар белән танышты; аның вакытында, шулай ук беренче тапкыр, мөгътәзиләр сектасы әзәрлекләнүче дини мәзһәптән әзәрлекләүче һәм дәүләт дине булып әверелде. Кыскасы, аның идарә итүе мөгътәзилиләр сектасы һәм гомумән гарәп цивилизациясе өчен дә гарәп хәлифәлеге тарихында башка бер тапкыр да кабатланмаган алтын гасыр иде. Мәэмүн бу мәзһәпне яклавын шул кадәргә җиткерә ки, аның иң төп догматларыннан берсен — Коръәннең илаһи яратылышын дәүләт догматы дип таный һәм бар кешегә дә: «Бу догматны танымаучы дәүләт җинаятьчесе буларак җәзаланачак», — дип игълан итә. Моның гади өркетү генә булмаганлыгын яңа догматны таныргa теләмәгән традиционистларның ташкын булып аккан каннары ачык күрсәтеп тора»[1]

Югарыда китерелгән өзектә П. Жузе үз карашларын түгел, ә мөгътәзиләр тарихына карата Европа фәнендә гомум кабул ителгән фикерне бәян итә. Бу караш совет фәнендә, Шәрыкны һәм исламны өйрәнү фәнендә дә ныклап урнашты[2]. Шуннан чыгып Мәэмүн һәм аның ике варисы вакытында хәлифәлектәге идеологиянең торышы турында бик җитди нәтиҗәләр ясалды. Мөгътәзилиләр кеше ихтыяры азатлыгының эзлекле тарафдарлары буларак, ул дәвердә хәлифәлектәге идеологиянең торышы турында шушындый нәтиҗәгә килделәр: «Ихтыярның азатлыгын тану һәрбер кешене үз эшләре өчен тулысынча җаваплы итте. Алла аларның бердәнбер сәбәпчесе булудан туктады. Шуңа күрә феодаль изү көчәю шартларында антифеодаль хәрәкәттә катнашу-

---

Артур СӘГАДИЕВ *(1931 елда туган) — философия фәннәре докторы, СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты өлкән фәнни хезмәткәре. Мөселман Көнчыгышында философия тарихы мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Берничә монография, күпсанлы мәкаләләр һәм гарәп теленнән тәрҗемәләр авторы. Мәскәүдә яши.*

чыларга карата җәзалау чараларын тагын да кыюрак һәм рәхимсез рәвештә кулланырга мөмкинлек туа. Хакимлек итүче өстен катлауга халыкны, баш күтәрүчеләр хәлифәгә һәм феодалларга каршы алла тарафыннан алдан билгеләп кую нәтиҗәсендә түгел, ә бәлки үз ихтыярлары белән көрәшәләр, дип инандыру кирәк иде: халык массаларыннан алланы изүчеләргә каршы көрәшнең беренче сәбәпчесе итеп күрсәтү мөмкинлеген тартып алу кирәк иде»[3].

Ләкин мондый фикерләр бернинди дә фәнни кыйммәткә ия түгел. Чөнки мөгътәзилиләр доктринасын беркем дә хәлифәлекнең «рәсми дине»нә әверелдермәгән, мөгътәзилиләр теологларны хәлифәгә тугрылыкта сынаучы инквизициянең инициаторлары да булмаган: ихтыяр азатлыгы турында тәгълиматны Мәэмүн кабул итә алмаган, чөнки ул җәббарит, ягъни кешенең эш-гамәлләре тышкы көчләр тарафыннан тулысынча алдан ук язылып куелган дигән тәгълиматның тарафдары була. Ул тәгълимат буенча Мәэмүн һәм дә аның ике тәхет варисына тугрылык критерие сыйфатында бары тик бер генә положение — Коръәннең илаһи яратылышы гына каралган була. Бу положение мөгътәзилиләр хезмәтләрендә генә теркәлмәгән дип әйтеп булмый. Мәсәлән, бер үк вакытта җәббарит һәм мөрҗит булган Бишр әл-Мариси да шундый ук караштa торган. Әгәр дә хәлифә әл-Мәэмүннең бер үк вакытта җәббарит, мөрҗит һәм Коръәннең илаһи яратылышы тарафдары икәнлеген искә алсак, аның мөгътәзилиләргә карата булган мөнәсәбәте һәрвакытта да уңай булмаганлыгын күрербез. Бишр әл-Марисиның ташмаңгай догматикларны әзәрлекләүгә бик җитди сәбәпләре булганлыгын да искә алыйк, чөнки нәкъ менә алар, догматиклар хәлифә Һарун әр-Рәшид чорында аны Коръәннең илаһи яратылышы турындагы караштa торганлыгы өчен төрмәгә ябалар. Шулай итеп, 819 елда Багдадка кире кайткан мәгърифәтле хәлифә әл-Мәэмүннең якын кешесенә әверелгән Бишр әл-Марисиның әлеге инквизицияне башлап җибәрүче булганлыгына бернинди дә шик калмый. Европа галимнәре мондый нәтиҗәгә бары тик соңгы елларда гына килә башладылар. Кәлямнең, ягъни догматик дини тәгълиматның чәчәк аткан дәвере турында традицион күзаллауларны тар-мар итеп Ван Эсс катгый рәвештә болай дип белдерде: «Әл-Мәэмүн мөгътәзили булмаган. Инквизицияне оештыруда хәлиткеч роль Бишрга кайтып кала»[4]. Күренекле ислам дине белгече Монтгомери Уотт та бу фикер белән килешә[5].

Әгәр дә узган гасырда Казан зыялыларын Болакның ике ягына аерган читләшү стенасы булмаган булса, атаклы палестиналы галим П. Жузе Европа фәнендә бары тик XX гасырның икенче яртысында гына ачыкланган нәрсәләрне бәлки шул ук вакытта, XIX гасырның икенче яртысында белгән булыр иде.

Ә бит Ван Эсс күренекле татар мәгърифәтчесе һәм галиме Шиһабетдин Мәрҗани һәм аның даирәсенә күптән билгеле булган хакыйкатьне бары тик яңадан ачучы гына. «Инквизицияне башлап оештыручы Бишр булган», — ди Мәрҗани, бик кыска һәм ачык итеп, үзенең «Вафият әл-әсляф вә тәхият әл-әхляф» («Бабайларның үлеме һәм киләчәк буыннарга бүләк») исемле, гаять дәрәҗәдә кыйммәтле, алты томлык кульязма әсәрендә[6].

Ә хәзер икенче мисалга мөрәҗәгать итик. Тарихи-философик әдәбиятта урта гасыр гарәп-мөселман философиясенең төп юнәлеше булган перипатетизмның эзлекле үсеше 1037 елда Ибне Сина үлгәннән соң туктaлып кала һәм алга таба эволюциясендә бу юнәлеш мөселман Көнбатышында — Әндәлүсия һәм Мәгърибтә яшәгән гарәп фикер ияләре иҗатына бәйләнгән, дип раслау таралган. Шуның белән бергә әл-Кинди, әл-Фәраби, Ибне Сина, Ибне-Баҗҗа, Ибне Туфейл һәм Ибне-Рөшд Көнчыгыш перипатетизмының иң күренекле вәкилләре булып санала. Әмма Ибне Сина үлгәннән соң Шәрык философиясенең үсеш тарихы белән танышу, монда перипатетизмның мөстәкыйль философик юнәлеш булып XI һәм XII гасырда да яшәвен дәвам итүен күрсәтә. Мәсәлән, Гали ибне Зәйд әл-Бәйхакиның (1169/1170 елда үлгән) атаклы биобиблиографик әсәре «Татимат сиван әл-Хикма» белән җентекләбрәк танышканда Ибне Сина һәм әл-Бәйхаки дәверләре арасындагы заманда мөселман дөньясының Көнчыгышындагы перипатетик философия, эзлекле рәвештә бер-берсенә бәйләнгән һәм ким дигәндә дүрт буын галимнәр иҗаты белән билгеле булуын һәм алар арасында Ибне Сина белән бәйләнеш өзелмәвенә соңгысының шәкерте Бахманйар ибне Марзубанның роле зур булуы ачык-

---

[1] Жузе П. Мутазилиты. Казань, 1899, 67 б.

[2] Крывелев И. А. История религий. Т 2. М., 1976, 218 б; Петрушевский И. П. Ислам в Иране в VII-XIV вв. Л., 1966, 210 б.

[3] Беляев Е. А. Мусульманское сектантство. М., 1957, 43 б; Крывелев И. А. Күрсәтелгән хезмәт, 216 б.

[4] Van Ess J. Dirar b. Amr und die gahmiyya. — Der Islam, 1967, № 43, S. 34.

[5] Montgomery Watt W. the formative period of islamis tnoight. Edinburgh, 1973, p. 197.

[6] Мәрҗани Ш. Вафият әл-әсләф вә тәхият әл-әхляф. Т. 2, 174 б. — Казан дәүләт университеты Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге, № 610. Мәрҗанинең бу фикеренә сүрияле марксист Т. К. Ибраһим да игътибар иткән. Кара: Ибрагим Т. К. Философия калама (VIII-XV вв.): Автореф. дисс. ... доктора философских наук. М., 1984. 6 б.

лана. Бахманйар белән язышканда Ибне Сина аңа хөрмәт белән, үзенең «хуҗасы һәм башлыгы»на (Мавла'и ва ра'иси) эндәшкән кебек мөрәҗәгать итә[7]. Һәм бу гыйбарә — фарсыча «кийа ра'ис — Бахманйарның мактаулы кушаматына әверелә[8]. Ул гыйбарә аңа карата, философик мәктәп юлбашчысы Ибне Синага бирелгән мактаулы кушаматисем — «Баш шәйх» кебегрәк кулланылган дип әйтергә мөмкин. Әмма Бахманйарның урыны һәм роле мөселман дөньясының Көнчыгышында философия үсеше тарихында эзлеклелекне саклау һәм дәвам итү белән генә чикләнми. Гасырлар буе, һәм әйтергә кирәк XIX йөзгә кадәр, Бахманйар хезмәтләре философик белемнәрнең мөһим чыганагы булып хезмәт иттеләр. Беренче чиратта бу аның «Әт-тәхсил» исемле энциклопедик әсәренә карый. Автор сүзләренә караганда, бу хезмәтендә ул Ибне Сина тарафыннан үстерелгән философик тәгълиматның төп эчтәлеген ачып сала[9]. Мөселман Көнчыгышында зыялыларның философик белемнәрен үстерүдәге әһәмияте ягыннан бу китапны Ибне Синаның «Китаб аш-шифа»сы белән чагыштырырга мөмкин[10].

Ш. Мәрҗанинең атап үтелгән хезмәтендә мөселман Көнчыгышы философиясе тарихында күренекле урын алып торган Бахманйар иҗатының объектив әһәмиятенә лаеклы бәяләмә бирелә. Анда Бахманйар философия фәне өлкәсендә Ибне Синаның иң эзлекле фикердәше буларак тасвирлана, Бахманйарның башка галимнәрдән үткен акыллы, кыю фикерләре, язучылык осталыгы белән аерылып торуы билгеләп үтелә. «Вафият әл-әсляф...»ның кереш өлеше булган «Мөкаддимә, китаб вафият әл-әсляф вә тәхият әл-эхляф» (Казан, 1883, 333-334 б.) исемле хезмәтендә Ш. Мәрҗани урта гасыр гарәп-мөселман философиясенең иң күренекле вәкилләрен саnaганда: «Алар арасында иң бөекләре Әбу Наср әл-Фәраби, Әбу Гали Ибне Сина, казый Әбу-л-Вәлид Мөхәммәд ибне Әхмәд ибне Рөшд һәм Бахманйар ибне әл-Марзубан», — дип яза. Моннан тыш, Мәрҗани үз хезмәтләрендә Бахманйарның философик фикернең күренекле ядкаре булган «Әт-тәхсил» исемле хезмәтенә еш мөрәҗәгать итә.

Шулай итеп Бахманйарның фәнни мирасына күренекле татар галиме тарафыннан бик югары бәя бирелә. Әмма моңа капма-каршы буларак, Көнбатышның тарихи-философик әдәбиятында Азәрбайҗан философының фәнни мирасын гына түгел, хәтта исемен дә күрмәмешкә салыналар. Бу — Көнбатышның философия тарихы фәненә хас булган европоцентризм белән аңлатыла. Философия тарихы мәсьәләләре белән шөгыльләнүче Көнбатыш галимнәре элек-электән үк гарәп-мөселман философиясе традицияләренең урта гасырларда һәм Яңарыш дәверендә Европаның философик фикере формалашуына йогынты ясавы ноктасыннан карап, аның шул хакта хәбәр итүче сәхифәләренә генә игътибарны юнәлттеләр. Күпгасырлы гарәп-мөселман философиясе тарихының башка сәхифәләре ул галимнәрне кызыксындырмады һәм шуңа күрә алар күләгәдә калдылар. Мөселман Көнчыгышында философиянең үсеше Ибне Синадан соң тукталды диган катып калган фикер, икенче бер ялган стереотип белән — янәсе, әл-Газали мөселман Көнчыгышында философик фикергә кабер казучы булган дигән уйдырма белән ныгытылды.

Бу мәсьәләдә барлык нечкәлекләргә кереп тормыйча, без Багдад хәлифәлегенең әл-Мәэмүн дәверендә мөгътизилиләр тәгълиматының роленә Европа тикшеренүчеләре биргән бәядәге хаталар да ул галимнәрнең европоцентристик карашларыннан килеп чыккан дип әйтә алабыз. Шулай итеп югарыда карап үтелгән мисалларның икесе дә урта гасыр мөселман философик традициясен, аның үз мәдәнияте җирлегеннән аерып алып өйрәнүдән килеп туган ялгышлар икән. Бахманйарның энциклопедик хезмәтен өйрәнү Ибне Синаның дөньяга карашы турында тулырак, төгәлрәк мәгълүматлар алырга ярдәм иткән кебек, Ш. Мәрҗани һәм аның даирәсе тарафыннан кәгазьгә теркәлеп калган тарихи-философик мәгълүматлар да безнең өчен теге яки бу мәсьәлә турында Көнбатышның философия тарихы фәне хәбәр иткән мәгълүматларга караганда кыйммәтлерәк булуы мөмкин. Шуның өстенә ул замандагы галимнәр карамагында, кагыйдә буларак, кулъязма чыганаклар, хәзерге вакытта Көнчыгышны өйрәнүче галимнәр кулында булганга караганда күбрәк булганнар. Ул кулъязма чыганакларның кайберләре хәзерге вакытта фән өчен бөтенләй югалган.

Әлбәттә, без Көнбатышның тарихи-философик яки Көнчыгышны өйрәнү фәненең әһәмиятен һич кенә дә кечерәйтеп күрсәтергә теләмибез. Ул фәннең югарыда телгә алынган Көнчыгыш галимнәре мәгълүматларына караганда бәхәссез өстенлекләре дә бар, чөнки Көнбатышның философия тарихы фәне урта гасыр мөселман филосо-

[7] Масса'ил са'ала анха Бахманйар ва иджабат аш-шайх ар-ра'ис Абу Али Ибн'Сина. Үзбәкстан ССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты китапханәсе, № 2385, 192 б.
[8] Низами Арузи Самарканди. Собрание редкостей или Четыре беседы. М., 1963, 127 б.
[9] Бахманйар ал-Азербайджани. Ат-тахсил (Познание). Кн. 1. Баку, 1983, 14 б.
[10] Corbin H. Ja philosophie iranienne islamique anx et XVIII siecles. Paris, 1981, passim.

фиясен киңрәк контекстта һәм концептуаль яктан да тулырак итеп тикшерә. Шул ук вакытта, әгәр дә мөселман Көнчыгышы философик мирасын өйрәнүче урта гасыр философиясе тарихы фәнебез, бу өлкәдә Көнбатыш фәне бәяләмәләрен тәнкыйть күзлегеннән үткәреп, үзенең тәүге практик адымнарын ясый икән, аның өчен эмпирик материалны җыю һәм анализлау иң беренче дәрәҗәдәге мөһим эш булып тора. Ә ул материалның шактый өлеше мөселман дөньясының төрле почмакларында яшәп иҗат иткән галимнәрнең философик хезмәтләрендә теркәлеп калган һәм өлешчә тикшерелгән. Күренекле татар галиме, тарихчы һәм фикер иясе Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләре дә әнә шундый кыйммәтле философик әсәрләр рәтендә тора.

# ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ ШӘҖӘРӘСЕ

Татар халкының культурасы һәм иҗтимагый-сәяси аңы үсүгә XIX гасырда иң куәтле тәэсир ясаган кеше Шиһабетдин Мәрҗани булды дисәк, һич тә ялгышмабыз. Аның фикерләре, шәхесе, татар дөньясы белән генә чикләнмичә, Россиядә, Европада һәм мөселман культурасы илләрендә дә яхшы мәгълүм була. Ш. Мәрҗани хезмәтләре Идел буенда ничә йөз еллар буе барган кайбер бәхәсләргә ачыклык кертәләр, милли тарих фәненең нигез ташларына әвереләләр.

Соңгы елларда җәмәгатьчелекнең Ш. Мәрҗани иҗаты, шәхесе белән кызыксынуы тагы да үсүгә гаҗәпләнерлек урын юк. Галимгә багышлап фәнни хезмәтләр языла, конференцияләр уздырыла, аңа кагылышлы яңа документлар — чыганаклар табыла.

Шундый чыганакларның берсе — Ш. Мәрҗанинең нәсел шәҗәрәсе.

Ш. Мәрҗанинең нәселләрен — бабаларын, аларның тарихларын күрсәткән мәгълүматлар аның «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабының икенче томында өлешчә дөнья күрә. Шуннан соң бу хакта Риза Фәхретдиневнең «Асарь» китабында кайбер мәгълүматлар басыла. Болардан тыш 1915 елда бөек галимнең туууна йөз ел тулуга багышлап Казанда чыгарылган «Мәрҗани» исемле зур күләмле җыентыкта күп кенә мәгълүматлар дөнья күрә. М. Х. Юсуповның 1978 елда Казанда басылган «Шигабутдин Марджани как историк» дигән китабында галимнең ата-бабалары хакында кайбер мәгълүматлар дөнья күрде.


Ш. Мәрҗани архивының зур өлеше янып юкка чыккан. Сакланып калган материаллар арасында Ш. Мәрҗанинең шәҗәрәсен чагылдырган кульязмалар күренми.


Соңгы елларда татар халкы арасында нәсел шәҗәрәләре белән кызыксыну көчәйде. Шул җөмләдән Ш. Мәрҗанинең дә токымнары арасында үз бабалары тарихы белән кызыксыну барлыгы күренә. Танылган татар филологы, гарәп теле белгече Таһир Ильясиның (1881-1933) кызы Нәҗия ханым Ильясованың эшләре бу ноктадан караганда аеруча игътибарга лаек. Нәҗия Ильясованың әнисе Нәгыймә апа Ш. Мәрҗанинең кызы Галиядән (1853-1925) туган.

Нәҗия Ильясова (1919) гомер буе Казан мәктәпләрендә укыткан, Мәрҗани мирасын һәрчак игътибар белән саклаган. Аның катнашында Ш. Мәрҗани китапханәсенең зур бер өлеше 1937 елда Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсенә тапшырыла. Соңгы елларда гына ул әтисе Таһир Ильяси һәм Ш. Мәрҗани китапханәсеннән калган туксанлап китапны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына бүләк итте. Нәҗия ханым шул ук вакытта үзлегеннән Ш. Мәрҗанинең нәсел шәҗәрәсен төзү белән дә шөгыльләнгән. Аның тарафыннан төзелгән шәҗәрә беренче буыннарны да кертеп исәпләгәндә 13 буынны үз эченә ала, ә бөтен нәселдә 238 исем күрсәтелгән. Шәҗәрә заманча, ягъни хатын-кызларны да күрсәтеп төзелгән. Нәҗия Ильясованың хезмәте галимнең беренче тулы нәсел шәҗәрәсен төзү тәҗрибәсе булып тора. Автор бу шәҗәрәне тагы да тулыландыру, камилләштерү уе белән яна.

Журналның бу санында Шиһабетдин Мәрҗани шәҗәрәсенең Нәҗия Ильясова төзегән тексты тәкъдим ителә (күләме сыйдырмаганлыктан, соңгы заманнардагы буыннарның бер өлеше күрсәтелми).

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.




## ИСКӘРМӘЛӘР

1. Ш. Мәрҗани үзе иң ерак бабасы итеп Гомәрне күрсәткән булган (Мәрҗани. Казан, 1915, 3 бит). Гомәр — Ядкарьнең атасы. Ш. Мәрҗанинең бабалары Татарстанның хәзерге Арча районы Комыргуҗа авылыннан чыкканнар. Авылның исеме, Гомәр хуҗа исеменең бер варианты икәне бәхәс уятмый. Шунлыктан ул авылның бөек галимнең бабасы исеме белән аталу ихтималы зур.

2. «Мәрҗани» (Казан, 1915) җыентыгында, галимнең кулъязмасына таянып, Габделкотдус бабасының Мәрҗан авылын нигезләве языла (3 б.).

3. Сөбхан, 87 ел гомер кичереп, Татарстанның хәзерге Арча районына карый торган Кысна авылында 1834 елда үлгән. Ул зур укымышлы, Ш. Мәрҗанине тарих фәне белән кызыксындыра башлаучы беренче остаз була. Сөбхан хәзрәт китаплар күчерү белән дә шөгыльләнгән. Ш. Мәрҗани аның алтмышлап китап күчереп язуы хакында яза. Ул 25 ел чамасы Җәке һәм Кысна авылында имам булып тора, соңыннан һөнәрчелек белән шөгыльләнгән.

4. Баһаветдин Ябынчы һәм Ташкичү авылларында имам булып (Татарстанның хәзерге Арча районына караган авыллар), 72 яшендә, 1856 елда үлгән. Кабере Ташкичү зиратында. Ул мөдәррис буларак 40 ел дәрес әйткән. Аның хатыны, Шиһабетдинның анасы Бибихәбибә бинте Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза бине Гали бине Йосыф әс-Сембери әл-Чокали 1823 елда 29 яшендә үлеп киткән.


5. Садретдин (1827—1916) — Ташкичүдә имам һәм мөдәррис булган кеше. Гомумән, Мәрҗаниләр нәселендә 20 дән артык зур белемле мөдәррисләр барлыгы мәгълүм.

6. Нәгыймә Хөсәен кызы Апанаева — Шиһабетдин Мәрҗанинең беренче хатыны.

7. Галия (1853-1925) Сафиулла Габдуллин исемле кешегә кияүгә чыккан. Шунысы кызыклы, Ш. Мәрҗани үзенең кызын кияүгә биргәндә Казаннан читкә алып китмәскә һәм җибәрмәскә дигән шарт белән биргән (Нәҗия Ильясовада саклаучы документтан).

8. Зәкәрия — Казанда 1912 елның 10 декабреннән 1918 елның 24 июненә хәтле чыгып килгән демократик рухлы «Кояш» газетасының редакторы Зәкәрия Садретдинов, 1930 елның 9 декабрендә Казанда вафат.

9. Мәхмүт Мәрҗани — татар әдәбияты классигы Мәхмүт Галәү (1886-1938).




*Нажия ИЛЬЯСОВА төзеде.*

# ГАБДЕЛГАЛЛӘМ ФӘЕЗХАН УГЫЛЫ ТУРЫНДА*

Шундый шәхесләр була, аларның эшчәнлеге һәм хезмәте, җәмгыять үсешенә алар керткән өлешнең әһәмияте соңыннан, еллар узгач кына, күренә башлый. Шундыйларның берсе — халкыбызны агартуга зур көч куйган Габделгаллэм Фәезханов. Филология, тарих, фольклор, политэкономия һәм башка өлкәләрдә Г. Фәезханов калдырган мирас аеруча игътибарга лаек.[1]

Габделгаллэм Фәезхан улы Фәезханов 1850 елда элекке Сембер губернасының Кормыш өязе Сабачай авылында дәүләт крестьяны гаиләсендә дөньяга килә (хәзер Горький өлкәсе, Пильнин районы, Красная Горка авылы). Фәезхан абзый гаиләсендә балаларны хезмәт халкын хөрмәт итү рухында тәрбиялиләр, хезмәт сөяргә өйрәтәләр. Кечкенә Габделгаллэм башлангыч белемне Уфада ала. Табигать белеменнән һәм тарихтан аеруча сәләт күрсәтеп, ул гарәп, фарсы һәм рус телләрен дә өйрәнә башлый.

Язмыш Габделгаллэмне зуррак белем алу теләге белән укырга Казанга китерә. 1862 елда, күренекле галим-ориенталист, Петербург университетының шәрык телләре укытучысы, бертуган абыйсы Хөсәен Фәезхановның (1828-1866) турыдан-туры киңәше буенча, Габделгаллэм мәшһүр мәгърифәтче Ш. Мәрҗани (1818-1889) мәдрәсәсенә укырга керә һәм шунда алты ел буе укый. Әйтергә кирәк, Хөсәен Фәезханов үзе дә Ш. Мәрҗанинең шәкерте, соңыннан исә аның якын дусты-фикердәше була. Ул чорда татарларда дөньяви белем бирүче башка уку йортлары булмаганлыктан, гыйлемгә сусаган Габделгаллэм үзлегеннән күп шөгыльләнә. Көнчыгыш әдәбиятын, рус һәм татар телләрен өйрәнә. Булачак мәгърифәтче татар халкын агарту, аңа белем бирү юлын рус халкының алдынгы мәдәниятен үзләштерүдә, алга куелган максатка нәкъ менә рус культурасы аша баруда күрә.

Мәдрәсәне тәмамлагач, Г. Фәезханов мулла да, хәлфә дә булырга теләми, бары тик алга таба укырга — Казан университетына керергә хыяллана. Әмма ярлылык сәләтле егеткә бу хыялын тормышка ашырырга мөмкинлек бирми. Остазы М. Мәрҗани тәкъдимен кабул итеп, һичшиксез, гыйлем эстәүне иң изге максатлардан санап, заманасының шактый укымышлы һәм алдынгы карашлы кешесе, Казан артыннан чыккан сәүдәгәр Садретдин Мифтахетдин улы Нәзировка сәүдә вәкиле булып яллана, Бохара һәм Сүрия тарафларына юл тота. Шәрык уку йортларында гарәп, фарсы, төрек әдәбиятлары, география, математика буенча белемен камилләштерә, шактый бай китапханәләрдә, чын мәгънәсендә, шифалы гыйльми һава белән ризыклана. Төркстанда һәм Гарәп Көнчыгышында 5 ел гомер кичергәндә Габделгаллэмгә абыйсы Хөсәеннең өлкән кызы Бибигайшәнең ире, Петербургта кадет корпусын тәмамлаган Хәйдәр Сыртланов (бер уллары, Галиәсгар Сыртланов, Петербургта адвокат булып, III Дәүләт думасында әгъза булган; икенче уллары — Равил Сыртланов, офицер, 1916 елның җәендә фронтта һәлак булган) зур матди ярдәм итә.

1873 елда ул Уфага кайта. Биредә, 1872 елның октябрь азагында, «Русиядә яшәүче инородецларны укыту чаралары турында»гы 1870 елгы положение нигезендә, татарлар арасыннан укытучылар хәзерләү буенча Россиядә иң беренче педагогик уку йорты буларак ачылган укытучылар мәктәбенә укырга керә.

Сүз уңаенда, бу уку йорты белән якыннанрак танышыйк. Ул рус-татар мәктәпләрендә һәм мәктәп-мәдрәсәләр каршындагы рус классларында эшли алырлык рус теле һәм арифметика укытучылары хәзерләргә тиеш була. Мәктәпнең укыту планы яхшы ук киң. Биредә ислам дине, рус теле, арифметика (геометрия һәм сызым белән), география (кыскача тарих белән), табигать белеме, педагогика һәм методика нигезләре, матур язу һәм рәсем, физика һәм тарих укытылган. Мәктәпнең инспекторы — Госман Саинов, 1853 елда Казан гимназиясен тәмамлап, Казан университетының Көнчыгыш телләр бүлегендә белем алган, аннан Семипалат хәрби губернаторы канцеляриясендә тәрҗемәче, Омскида Көнбатыш Себер баш идарәсендә һәм төрле гимназияләрдә эшләгән кеше.

Менә шушы мәктәптә Габделгаллэм Фәезханов 4 ел буе рус теленнән бик төпле белем алган. Рус телен, 18 ел буена, мәктәпнең иң эшлекле һәм тәҗрибәле укытучыларыннан берсе Шаһисолтан Шаһиәхмәтев алып бара. Ул үзе Казан университетының юридик бүлеген фәннәр кандидаты дәрәҗәсе белән тәмамлаган бик сәләтле, тырыш һәм абруйлы укытучы була.

---

[1] Г. Фәезханов хакында иң беренче мәгълүмат бирүче мәшһүр галим Риза Фәхретдинев.— СССР Фәннәр академиясе Урал бүлеге БАССР гыйльми үзәге фәнни архивы, 7 ф., 1 тасв., 12—14 эш. «Асарь», 3 җилд., 53 б.

Укытучылар мәктәбенең бай китапханәсендә фәнни кулланмалар, Көнбатыш һәм рус классикларының әдәби әсәрләре, татарча китаплар күп тупланган. Кайбер галимнәр һәм язучылар үзләренең китапларын китапханәгә бүләк итә торган булганнар. Мәсәлән, Казан уку округының (Уфа шәһәре шул округка караган) милли мәктәпләр инспекторы, атаклы галим-тюрколог В. В. Радлов (1837-1918) үзенең нәшер кылынган барлык хезмәтләрен китапханәгә бүләк итеп барган.

Бу мәктәп, татарлар һәм башкортлар өчен беренче педагогик уку йорты буларак (дөрес, ул ел саен, хәзерге заман күзлегеннән караганда, бик аз — бары тик 10 укытучы гына әзерләп чыгарган), әзлекле рәвештә мәгариф хезмәткәрләре хәзерләүгә нигез сала. Аны 1877 елда тәмамлаган Габделгалләм Фәезханов дөньяви белемнәр, педагогика һәм методика нигезләре белән коралланган татар укытучыларының беренчеләреннән була. Зур өметләр, якты хыяллар белән мәктәпләр оештыру-ачтыру эшенә алынган Габделгалләм, кызганычка каршы, бу дәвердә мәктәптә бик аз эшли. Сәбәп нидә? Илдә революцион хәрәкәт үсүдән курыккан патша хөкүмәте татар мәктәпләренә, уку йортларына чамадан тыш каты басым ясый, укытучыларга бөтенләй эш хакы түләми, алдынгы карашлы мөгаллимнәрне эзәрлекли, мәктәпләрдә казарма режимы урнаштыру кебек реакцион чаралар куллана башлый. Татар укытучысын самодержавиенең реакцион эчке сәясәтен үткәрүче итәргә, аларны шул рухта тәрбияләргә тырышалар. Ә Г. Фәезханов мәгърифәтчелек мәнфәгатьләрен яклаучы, алдынгы идеяләргә турылыклы эшлекле булып кала. Ул халыкны алдынгы карашлар, хезмәт ияләренә тирән ихтирам рухында тәрбияләргә омтыла.

Г. Фәезханов яңадан Уфадагы Себер банкы — сәүдә конторасында эшли башлый, әмма гыйльми карашларыннан бер генә минутка да аерылмый, әдәбият һәм публицистика белән дә шөгыльләнә башлый.

1884 елның азагында Габделгалләм Фәезханов яңадан Казанга килеп, Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә ике ел укытучылык хезмәте белән шөгыльләнә. Шик юк ки, аның эшчәнлегендә Ш. Мәрҗанинең йогынтысы бик зур. Чөнки Габделгалләм дә, нәкъ Мәрҗани шикелле үк, шәкертләргә, бигрәк тә булачак укытучыларга, рус, татар, Көнчыгыш телләрен укыту кирәклеген яклап чыккан. Бу юлы Казанда Г. Фәезхановның шәхси тормышында да зур вакыйга була. 1885 елның 28 мартында 35 яшьлек Габделгалләм, Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә укытучылык итүче Шаһиәхмәт Салиховның (әйтеп үтик, ул Ш. Мәрҗанинең кардәшләреннән) 17 яшьлек, гаҗәеп сылу, чибәр Галия (1868-1920) исемле кызына өйләнә.

Укыту эшеннән тыш, Г. Фәезханов җирле халык белән аралашкан һәм тыгыз бәйләнештә торган, шәһәрдә яшәүчеләргә бер телдән икенче телгә тәрҗемә итүдә ярдәм иткән. Хәер, тәрҗемәчелек хезмәтен ул рәсми рәвештә дә башкарган. Оренбург Диния нәзарәтенең 1893 ел 28 сентябрендә рәис Ибраһимов, секретарь Кадерголов имзалары белән беркетелгән 3889 номерлы белешмә кәгазендә, мәсәлән, бу турыда бик ачык әйтелгән.

Мәгълүм булганча, XIX йөзнең ахырында, XX йөзнең башында Россиядә социаль-экономик һәм иҗтимагый-политик каршылыклар кискенләшә, мәгариф системасы да яңа чор таләпләрен канәгатьләндерми башлый. Җәмгыятьнең алдынгы карашлы вәкилләре арасында халык мәгарифен үстерү өчен көрәш көчәя. Нәкъ әнә шул чорда, заманының алдынгы карашлы кешесе, укытучы-мәгърифәтче буларак, Фәезхановның педагогика өлкәсенә күп көч куюы бер дә очраклы түгел. Аңа гаять авыр шартларда эшләргә туры килә. Укыту өчен әсбаплар, программалар, кулланмалар җитешми. Шулай булса да ул, беренчедән, сөйләү телен үстерүгә зур әһәмият бирә, икенчедән, телне практик кына түгел, ә бәлки теориягә, фәнгә бәйләп тә укытырга тырыша. Үзе дә күптөрле кулланмалар, дәреслекләр, ярдәмлекләр төзи. 1886 елда аның «Татар теленә кыскача гыйльми сарыф»ы, 1888 елда исә «Гомуми җәгърәфия рисаләсе» дөнья күрә.

Г. Фәезханов, тормыш өчен кирәкле фәннәр укыту һәм һөнәрләргә өйрәтү тарафдары буларак, мәктәп-мәдрәсәләрдә, ана һәм рус телләре белән бергә, математика, астрономия, география, тарих, физика кебек дөньяви фәннәр укытылуын күрергә теләп, мәктәптә, рус һәм гарәп телләреннән тыш, нинди дә булса бер Европа теле дә өйрәнелергә тиеш, дип саный.

Мәгърифәтче галим шулай ук мәктәп-мәдрәсәләрне тоту өчен акча табу мәсьәләсенә дә игътибар иткән. Яңа мәрдәсәләрне халыктан һәм укучылардан җыелган акча исәбенә салырга, соңыннан аларны җәмәгать файдасына васыять итеп калдырылган милек исәбенә тотарга мөмкин булыр иде, ди ул.

Күренә ки, Габделгалләм Фәезханов, К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов кебек укымышлыларның фикерләрен үстереп, аны яңа этапка күтәрү, ягъни саф дөньяви мәктәпләр булдыру мәсьәләсен куя. Ул шул идеяләрне гамәлгә ашыручы укытучы кадрлар әзерләүне дә, үз ана телебездә югары сыйфатлы дәреслекләр бул-

дыруны да игътибарсыз калдырмый. Укытучылыкка ул әзерлекле кешеләрне сайлап куярга, шәкертләр, гади халык арасыннан сәләтле балаларны рус һәм Европа илләрендәге уку йортларында укытып кайтарырга тәкъдим итә.

Югары сыйфатлы дәреслекләр әзерләү мәсьәләсендә исә аның үз үрнәге дә гыйбрәтле. Аның дәреслекләре татар мәктәп-мәдрәсәләре үзенчәлекләрен искә алып төзелгән, халыкчан телдә язылган. Югарыда күрсәтелгән «Гомуми җәгърафия рисаләсе»ндә, мәсәлән, автор бик күп яңа атамалар куллана, аларның күбесе хәзерге вакытта да гамәлдә йөри. Аңлаешлы булсын өчен атамаларның русча һәм гарәпчә исемнәре бергә китерелгән. Әлеге зур күләмле дәреслекне уку ярдәмлеге сыйфатында гына түгел, бәлки өлкәннәр өчен уку китабы итеп тә файдаланганнар, чөнки анда теге яки бу дәүләтнең табигате, халкы, мәдәнияте турында мәгълүмат бирелгән.

Г. Фәезханов борынгы Шәрык әдәбиятының иң яхшы үрнәкләреннән саналган Зияддин Нәхшәбинең «Тутыйнамә» (1887), 1889 елда гарәп теленнән Ибне әл-Мөкаффәнең (Габдулла бине әл-Мөкаффә — 721-757) «Китабе Кәлилә вә Димнә», 1891 елда исә «Әбелгазый Баһадир хан. Шәҗәрәи төрек» (француз телендә чыккан басмадан) дигән китапларны татарчага тәрҗемә итә. Билгеле, һөнәр, гыйлем һәм мәгърифәт акчадан куәтлерәк дигән фикер уздыручы, югары әхлак, зирәклек, тапкырлык сыйфатларын мактаучы бу әсәрләрнең эчтәлеге мәгърифәтче Г. Фәезхановның күңеленә хуш килгән!

Г. Фәезханов 1893 елда календарь чыгара, 1896 елда исә аның «Хикәят вә мәкаләт» исеме астында әкиятләр һәм мәкальләр җыентыгы нәшер кылына.

Шул ук вакытта Г. Фәезханов безнең алдыбызга үзенчәлекле фикер иясе, татар халкын үз телендә беренче мәртәбә экономик белемнәр белән таныштыручы,[2] халкыбызның иҗтимагый фикер үсеше тарихында күренекле урын тотучы булып килеп баса. «Мөхәррикел әфкяр» (1893) һәм «Китаби мәҗалис әс-сәрвәт вә-л-мәгаш» (цензура тарафыннан 1892 елның 1 декабрендә расланып, нәшер ителмичә, кульъязма рәвешендә калган) дигән хезмәтләрендә татарлар арасында халык мәгарифе эшенең торышына тирән анализ ясала, шунда ук яшь буынга хезмәт тәрбиясе бирү хакында кызыклы, заманга муафыйк фикерләр әйтелә. «Мөхәррикел әфкяр» исемле хезмәтенең 5 нче бүлегендә, мәсәлән, замананың күренекле галим-эшлеклеләре, мәгърифәтче әдипләре Гатаулла Баязидов (1847-1911), Габделкаюм Насыйри (1825-1902), Хәсәнгата Габәши (1863-1930) һәм Риза Фәхретдинев (1859-1936), Заһир (1870-1902) һәм Муса (1873-1949) Бигиевләр, Шакирҗан Таһири (1858-1918), Һади Максуди (1869-1941) һәм башкалар телгә алынып, күбесенең дини мәдрәсәләрдән соң рус уку йортларында гыйлем алулары, рус һәм төрек әдәбиятларыннан яхшы ук хәбәрдарлыкларына басым ясала.

Г. Фәезханов «Мөхәррикел әфкяр» китабының нигезендә абыйсы Хөсәен Фәезхановның «Ислахи мәдарис» исемле, кульъязма хәлендә калган, хезмәтендәге идеяләрне күрергә мөмкин. Тик бер аерма бар, ул да булса, Г. Фәезханов, агасы Хөсәеннән үзгә буларак, мәсьәләгә заманчарак якын килеп, дөньяви мәктәпләрне Казан шәһәрендә генә түгел, бәлки башка шәһәрләрдә дә ачарга кирәк, бу мөһим эштә рус укытучылары хезмәтеннән файдалану мәгъкул, дигән фикерне уздыра. Әгәр дә халык, миллэт буларак, гасырлар дәвамында гомер сөрергә тели икән, Г. Фәезханов карашынча, ул үз Ватанына җаны-тәне белән бирелгән булырга, туган телен, әдәбиятын яратырга, мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртергә һәм үстерергә, төрле һөнәрләргә ия булырга тиеш.

Югарыда телгә алынган хезмәтләр Г. Фәезхановның укыту эшендә генә түгел, гыйльми эш белән дә тирәнтен кызыксынуын күрсәтәләр. Ул үз ана телен тирәнтен белү белән бергә, рус, француз, гарәп, фарсы, төрек, чуваш, казах телләрендә иркен сөйләшкән. Бу хәл исә аңа рус һәм дөнья әдәбиятлары белән танышырга киң мөмкинлек биргән. Безгә Габделгалләм Фәезхановның оныклары, Бөек Ватан сугышы ветераннары Фердинанд (Уфа авиация институты доценты, химия фәннәре кандидаты) һәм Рафаил (Уфа нефть эшкәртү заводында инженер) иптәшләрдә бабалары китап хәзинәсенең безнең көннәргәчә килеп ирешкән кадәресе белән танышырга насыйп булды. Гаҗәеп дөнья бу! Заманының татар әдәбияты әсәрләрен әйтеп тә тормастан, Көнбатыш Европа, Көнчыгыш әдәбияты үрнәкләре, дәреслекләр, философиягә, медицинага караган хезмәтләр, А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов, Л. Н. Толстой, А. И. Куприн әсәрләре, Н. Рубакин хезмәтләре, Брокгауз һәм Ефронның 86 томлык «Энциклопедик сүзлеге»ме, 1912 елда Мәскәүдә чыккан «Ватан сугышы һәм рус җәмгыяте» һәм башка шундый тарихи хезмәтләрме — кыскасы, бай китапханә булган ул.

Шуны әйтергә кирәк, 1887 елның җәендә Г. Фәезханов, Галия ханым һәм беренче улы Госман белән, Казаннан Уфага күчеп китә.

---

[2] Г. Фәезхановның политик экономиягә багышланган хезмәте турында Ф. Г. Газизуллинның махсус тикшеренүе дөнья күрде. Карагыз: Газизуллин Ф. Г. Дорогой к правде. Казань, 1979. (Ред.)

Соңгы елларында Г. Фәезханов Уфада «Галия» мәдрәсәсен оештыруда катнаша, соңыннан анда, үзе төзегән дәреслекләр буенча, татар теле, география һәм тарих укыта.

1910 елның 12 январенда өендә, балаларына гарәп әдәбиятыннан сабак биргән вакытта, йөрәк өянәгеннән, 60 яшендә Габделгаллләм Фәезханов Уфада кинәт вафат була.

Профессор Миркасыйм Госманов: «Габделгалләмнең ...уллары Госман, Ибраһим һәм Габдрахман Фәезхановлар гасырыбызның 20 нче елларында Уфада яшәгәннәр (кызының исеме әлегә ачыкланмады)»,— дип яза.[3]

Берничә еллар дәвамында Уфа зиратындагы кабер ташларындагы язмаларны өйрәнү, төрле архив чыганакларын барлау, ниһаять, Габделгалләм Фәезхановның нәсел-нәсәбе вәкилләре белән очрашу — сөйләшүләрнең сөземтәсе буларак, без бу мәсьәләгә беркадәр ачыклык керттек.

Исеме югарыда телгә алынган, Казанда туган, Госман Габделгалләм улы башта Уфа ирләр гимназиясендә укый. 1904 елның 23 августында гимназиянең 5 нче классын тәмамлау турындагы бирелгән таныклыктан күренгәнчә, ул, нәселдән килгән зирәклек, аеруча рус, латин, грек, француз һәм немец телләреннән зур сәләтлелек күрсәткән. 1906 елда әтисе аны үзе эшләгән «Галия» мәдрәсәсенә күчерә. Шуны да басым ясап әйтергә кирәк, Госман Фәезхановның татар әдәбияты классигы, революционер һәм дәүләт эшлеклесе Г. Ибраһимов белән дуслыгы аның соңгы көннәренә кадәр дәвам итә.

Госман Пушкин урамындагы йортны 1908 елның 30 декабрендә сатып ала. Бу йорт соңыннан Свердлов урамындагы 47 нче өй булып, кызганычка каршы, 1969 елны бөтенләй сүтелде. Габделгалләм Фәезханов, үз куллары белән, өй каршында утырткан карт тополь генә аның якты хатирәсен искә төшереп, биредә яшәвен дәвам итә. Россиядә Беренче буржуаз-демократик революция елларында Госман Фәезханов анда яшерен матбага оештыра, революционерларның очрашу урыны да шушы йортта булган. Листовкаларны кардәшләренең кызлары Мәрьям, Әминә һәм Зәйнәп апалар тараталар. Соңыннан Госман Фәезханов укытучылык хезмәтен башкара — рус теле һәм әдәбияты укыта. 1911 елларның башында, революцион эшчәнлеге өчен, ул укытучылык вазифасыннан мәхрүм ителгән әтисе шикелле үк, Уфадагы Себер сәүдә банкысында төрле эшләр башкарырга мәҗбүр булган. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, прапорщик дәрәҗәсенә ирешә, солдатлар арасында актив революцион эш белән шөгыльләнә. Сугыштан соң, Уфага кайтып, Колчак гаскәрләренә каршы Себергә юнәлә, милли партизан берләшмәсе оештырып, үзе шул отрядның командиры була, акларга каршы партизанлык хәрәкәтенә җирле Себер татарларын да җәлеп итә, анда Совет властен урнаштыруга зур көч куя. Ахырда Госман Фәезханов Новониколаевск шәһәрендә (хәзерге Новосибирск) төпләнеп кала, өйләнә, шәһәр оешмаларының берсендә баш бухгалтер булып эшли. Ләкин фронтларда алган яра-җәрәхәтләре нәтиҗәсендә аякларында яман шеш авыруы башланып, 1934 елда дөнья куя. Кабере Новосибирскида. Аның өч кызы да шунда яши.

Икенче улы — Ибраһим Фәезханов (1897-1961). 1912-1916 елларда Уфа сәүдә мәктәбен тәмамлый. Гражданнар сугышында катнаша, 1919 елда Петербургта Юденичка каршы көрәшә. Кайткач — гомере буе исәп-хисап хезмәтендә тереклек кыла. Кабере Уфада. Ибраһим абзыйның кызы — А. И. Мамаева Уфада врач.

Өченче улы — Габдрахман Фәезханов (1898-1948). 1917 елда Уфа реаль училищесын тәмамлап, дәһшәтле елларда, шәһәрне aклардан азат иткәч, төрле мәдәни-агарту эшләре белән шөгыльләнә. 1921 елда Төркстанга бара, Көнчыгыш халыклары арасында зур оештыру эшләре белән мәшгуль була. 1924 елда Уфага кайта, өйләнә. Гомере буе бухгалтер булып хезмәт итә. Кабере Уфада. Улы Зирәк — нефтьче инженер.

Кызы — Әминә (1904-1933). Уфада Мариинская кызлар гимназиясен бетерә, Казан университетының медицина факультетын тәмамлап, егерменче еллар азагыннан Казан, Мәскәү һәм аның әтрафындагы шифаханәләрдә врач булып хезмәт итә.

Габделгалләм һәм аның хатыны, балалары үз халкының һәм Ватанының патриотлары иде.

Әйе, Уфаның мәгърифәтчелек тарихы битләрен актара башласаң, искиткеч гүзәл күренешләргә тап буласың... Мифтахетдин Акмулла, Риза Фәхретдинев, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Галимҗан Ибраһимов, Хөсәен Ямашевларны хәтерли ул. Алар тукталган яисә яшәгән йортларның күбесе исән әле. Яшь буында, халкыбызда патриотик хисләр тәрбияләүдә, Уфаның тарихи йөзен, мохитын ачуда мондый истәлекләрнең роле, билгеле, әйтеп бетергесез. Олы шәхесләр исеме белән бәйле урыннарны кадерләп саклау, мемориаль такталар белән билгеләү алар алдындагы зур бурычыбыз булып кала.

Равил ҮТӘБАЕВ.
*Уфа шәһәре*

---

[3] Карагыз: Усманов М. Заветная мечта Хусаина Фаизханова. Казань, 1980, 212 б.

# МОГТӘБӘР ШӘХЕС



Әхмәтһади Низаметдин улы Максуди — татар халкын агарту юлында күп хезмәт куйган журналист, мәгърифәтче галим, педагог. 1868 елның 28 сентябрендә Татарстанның хәзерге Биектау районы кечкенә генә Ташсу авылында туган Әхмәтһади 1881 елда Казанга килеп, Күл буе («Касимия») мәдрәсәсендә укый. Бу еллар, ягъни XIX йөзнең ахыры, яңача укыту ысуллары, җәдитчелек хәрәкәте җилләренең татар мәктәп-мәдрәсәләренә үтеп кергән вакыты. Әлеге яңалык хәрәкәтен мәдрәсәләргә нәкъ менә Һ. Максудилар буыны алып керә. «Касимия»не тәмамлагач, ул шул ук мәдрәсәдә калып, ике ел җәдитчә укыта.

Һ. Максуди 1894 елда, белемен күтәрү нияте белән, Истанбулга сәфәр кыла, анда тәкълим, тәрбия, ислах яңалыкларын өйрәнә. Истанбулдан кайтышлый, Кырымда тукталып, мәшһүр җәдит мәктәбе Зынҗырлыда мөгаллимлек итә. Монда укытканда, җәдитчелекне тырышып пропагандалаучы И. Гаспринский белән күп мәртәбәләр очрашып, укырга-язарга өйрәтү методларын ни рәвешле җиңеләйтү турында әңгәмәләр алып бара. 1896 елда Казанга кайта. Үзлегеннән укып, Уфа учительская школасында имтихан тота һәм учительлек таныклыгы ала. 1903-1905 елларда Казан университетының юридик һәм педагогика бүлекләрендә ирекле тыңлаучы булып йөри. Шулай итеп, ул гарәп, фарсы, төрек, рус телләрен яхшы белгән лингвист-педагог булып җитешә. Махсус укытучы яллап француз телен дә өйрәнә.

1897-1904 елларда Һ. Максуди Печән базары мәчете каршындагы мәдрәсәдә мөдәррис булып тора. Н. Думави үзенең автобиографиясендә Һ. Максудидан шушы мәдрәсәдә гарәп телен өйрәнүе турында җылы хисләр белән искә ала.

Һ. Максуди — укытуда бердәм программа тарафдары. Бердәм программаларның булмавы, дәреслекләрнең кызыксыз төзелүе, укырга-язарга өйрәтүдә гаять кыен булган иҗек методына ябышып яту аны борчый. Ул мәктәпләргә дин гыйлеме белән бергә дөньяви фәннәр кертүне, рус класслары ачуны яклый.

Һ. Максудиның татар халкына күрсәткән тагын бер зур хезмәте — самодержавие хакимлек иткән авыр елларда унөч ел буе (1906 ел, 15 январь — 1918 ел, 21 июнь) «Йолдыз» газетасын чыгарып килүе. Әлеге газетаны чыгару артыннан ул 1903 елдан йөри башлый. Югары органнарга дүрт мәртәбә гариза кертә. Дүртенчесендә генә, 1905 елгы революция тәэсире белән генә рөхсәт алуга ирешә.

«Йолдыз» татар публицистикасы тарихында либераль буржуаз газета итеп бәяләнә.[1] Әйе, Һ. Максуди газетада төрле мәсләктәге мәкаләләр урнаштыра. Либераль буржуазия белән демократия арасында тирбәлгәнлеге өчен классикларыбыз аны вакыт-вакыт тәнкыйть тә итәләр. Ул, әлбәттә, революцион демократ зыялы түгел, мәгърифәтчелек кысаларында эшчәнлек алып барган кеше.

Һ. Максудиның урта мәсләк тотуы реакция елларында байтак матбугат органнары ябылганда, газетаны саклап калу өчен бер чара да булган булса кирәк. «Йолдыз»ның 10 еллык юбилей кичәсендә сөйләгән докладында политикада төрле карашлар хакимлек иткән болганулы елларда газетаны яшәтү өчен төрле чараларга баруы турында ул үзе дә әйтә.

«Йолдыз»га үз чорының демократик фикерләре дә тирән үтеп кергән. Газета Г. Тукай, М. Гафури, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, С. Рәмиев, Ш. Әхмәдиев, Н. Думави һ. б. танылган язучыларның иҗат эшчәнлегенә киң мәйдан ача. XX йөз башында татар демократик публицистикасы моңа кадәр күрелмәгәнчә үсеп китте, дибез икән, монда «Йолдыз»ның да роле, һичшиксез, зур.

Шунысы кызыклы, Г. Камал үзе чыгара торган «Азат халык» газетасы белән «Йолдыз»га килеп кушыла һәм аның җаваплы секретаре вазифасын үтәргә керешә. «Йолдыз»да демократик юнәлешнең көчәюенә Г. Камалның тәэсире зур булгандыр, әлбәттә.

---

[1] Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика. Казань, 1983, 34 б.

«Йолдыз» чыга башлаган елларда татар әдәби теленең бердәм орфография кагыйдәләре булмый, кем ничек тели, шулай яза. Татар телендә газета-журналлар барлыкка килгән XX йөз башында бердәм орфография мәсьәләсе көн тәртибенә баса. Һ. Максуди беренче санда ук: «Гәзитә һәркем укый алачак Казан теле белән язылачактыр, Казан теленчә исеме булмаган чит сүзләр генә үз телендә алыначактыр»,— дип белдерә һәм шушы юлны ахыргача дәвам иттерә.

Егерме сигез хәрефле гарәп алфавитында сузык аваз хәрефләре өч кенә (а, у, и) булуы язу һәм уку эшен гаять кыенлаштыра. Шушы кыенлыкны искә алып Һ. Максуди гарәп алфавитына о-ө сузыклары өсти, шуны Уфа гыйльми мәҗлесендә кабул иттерүгә ирешә. «Йолдыз»да бу хәрефләргә сүз башында, уртасында, ахырында язылу хокукы бирә. «Моның гамәлгә кереп китүе имлямызда яртылай җиңеллек, фәннилек һәм табигыйлек тудыра»,— ди Г. Ибраһимов «Матбугат әңгәмәләре» исемле мәкаләсендә[1]. Соңрак Һ. Максуди «ә» сузыгын да язылышка кертә. «Йолдыз» татар орфографиясен камилләштерү буенча бәхәсләр урынына әйләнә.

Һ. Максуди беренче журналистлык тәҗрибәсен «Тәрҗеман» газетасында ясаса да, публицистлык сәләте тулысы белән «Йолдыз»да ачыла, монда ул орфография, мәктәп тормышы, укыту-методика эшләрен яктырткан дистәләрчә мәкаләләр бастыра.

Үз вакытында популяр газеталардан саналган «Йолдыз» татарлар яши торган күп шәһәрләргә таралган. Һ. Максуди шушы газетаның редакторы һәм нашире, актив язышучысы булуы белән генә дә культурабыз тарихында лаеклы урын алырга хаклы. Ләкин аның педагогика, журналистика һәм лингвистика кебек өч мөстәкыйль өлкәне бергә уңышлы бәйләп алып баруына сокланмый мөмкин түгел.

Китап язу белән дә ул гомере буе шөгыльләнгән. Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсендә аның утыз ике исемдә китабы саклана. Байтагының берничә басмасы булуын исәпкә алсак, бу сан тагын да арта. Күпчелек хезмәтләре лингвистика фәненә карый. «Төрки нәхүе», «Төрки сарыфы», «Төркичә имля кагыйдәләре», «Тел белеге» кебекләре исә мәдрәсәләрдә дәреслек итеп кулланылган. Һ. Максуди «Русистан», «Практический учебник французского языка» исемле тел өйрәнү кулланмалары да төзегән. Аеруча озын гомерле китабы — «Мөгаллим әүвәл» әлифбасы. Шәкерт вакытында төзелә башлап 1892 елда беренче басмасы дөнья күргән бу китап 1917 елга кадәр егерме тугыз мәртәбә басыла, татар мәктәпләрендә укырга-язарга өйрәтүдә төп кулланмаларның берсе булып исәпләнә. Әлифбаның фарсы теленә тәрҗемә ителүе турында да хәбәр бар. Һ. Максуди «Мөгаллим әүвәл»дән килгән табышны «Йолдыз» кирәк-ярагына тотуы турында да әйтә.

Һ. Максуди — үз чорында иҗтимагый тормышның уртасында кайнаган кеше, «Мөселман иттифакы партиясе»ндә мәктәп-мәдрәсәләр комитеты секретаре, Казан шәһәре думасы члены. Ул бу вазифаларыннан да асылда халыкка кирәкле эш эшләү өчен файдаланган. Казанда беренче рәсми татар китапханәсе «Китапханәи исламия»-не ачу өчен ул шәһәр думасына берничә мәртәбә гариза бирә. 1906 елның 2 январенда рәсми рәвештә ачылган бу китапханәнең, фондын оештырып, эшен башлап җибәрә, 1922 елга кадәр аның мөдире вазифасын башкара.

Һ. Максуди Октябрь революциясеннән соң, 1925-1930 елларда, Көнчыгыш педагогия институтында гарәп телен укыта. Мәгариф Халык Комиссариаты каршындагы Гыйльми Үзәктә фәнни хезмәткәр булып исәпләнә. Кызы Бәһрәмия Сәйфуллинаның сөйләвенә караганда ул соңгы көннәренә кадәр армый-талмый эшли. 1927 елда аның «Фәнни камус» исемле сүзлеге чыга. Гомеренең соңгы елларында «Ленин — философ», «Хакыйкать һәм вәхшилек» исемле хезмәтләрен әзерли. Ләкин аларны бастырып дөньяга чыгарырга өлгерә алмый. Бу хезмәтләрнең кульязмалары Казан университеты фәнни китапханәсенең кульязмалар бүлегендә саклана.

Хөкүмәтебез, Һ. Максудиның хезмәтләрен тәкъдир итеп, аңа 1927 елның 1 маеннан персональ пенсия билгели.

Ул 1941 елның 28 июнендә Казанда үпкә авыруыннан вафат була. Тууына һәм вафатына күп еллар үтсә дә, бу могтәбәр шәхес әлегә кадәр тиешле бәясен алмаган. Хезмәтләрен өйрәнеп, аның культурабыз тарихында тоткан урынын билгеләү көн тәртибендә тора.

**Фатыйма ИБРАҺИМОВА**,
филология фәннәре кандидаты

---

[1] Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. 8 т. Төрки һәм татар теле буенча хезмәтләр (1910-1930). Казан, 1987, 66 б.

**Сәлам Алишев,**
тарих фәннәре кандидаты.

**Марат Мөлеков,**
тарих фәннәре кандидаты.

# ВӘИСЕВЧЕЛӘР ТАРИХЫННАН

Татар халкы тарихында XIX гасыр урталары һәм бигрәк тә аның икенче яртысы буржуаз мөнәсәбәтләр формалашу дәвере буларак аерылып тора. Социаль-экономик үсештә феодаль мөнәсәбәтләр, әле сизелерлек булсалар да, инде хакимлек итмиләр. XVIII гасырның икенче яртысында ук барлыкка килгән татар мануфактуралары (комач, күн, сабын) XIX йөздә капиталистик предприятиеләр төзүгә, татар акционер җәмгыятьләре оешуга китерде. Татар җәмгыятенең сыйныфларга бүленеше көчәйде: буржуазия һәм эшчеләр сыйныфы формалаша башлады. Алар, халыкның күпчелеген тәшкил итмәсәләр дә, экономик аралашуда зур урын алып тордылар. Авыл халкы да, феодализм калдыкларының көчлелегенә карамастан, әнә шул буржуаз мөнәсәбәтләр тәэсиренә тартылдылар. Бу күренешләр татар буржуаз милләте оешу процессының төп күрсәткечләре иде. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр һәм культура өлкәсендә дә күп кенә яңалыклар барлыкка килде. Татарларда борыннан яшәп килгән дини мәктәп-мәдрәсәләр торган саен эчтәлекләре белән дөньявилыкка йөз тотты, тормыш шартларына яраклаша башлады. Кайбер мөдәррисләр хәлләреннән килгәнчә, тормышта кирәк булган фәннәр укытуны көн тәртибенә куйдылар. Татарларда грамоталылык дәрәҗәсе тирә-яктагы башка халыклар белән чагыштыргысыз дәрәҗәдә үсә. Ахыр чиктә иске укыту ысулын ташлап, мәктәп-мәдрәсәләрдә яңа метод (җәдитчә) белән укытуга, фәнни белемнәр бирүгә күчү башланды. Гомуми культура үсешенең чагылышы буларак, XIX гасыр башында иҗтимагый фикер өлкәсендә мәгърифәтчелек юнәлеше туа һәм гасыр урталарына зур бер агым булып үсә. Ул вакытта татарлар арасында галимнәр, язучылар, шагыйрьләр, музыкантлар, китап бастыручылар һәм басучылар, дәреслек төзүчеләр, университет студентлары, врачлар, укытучылар, төрле һөнәр осталары шактый иде инде. Димәк, социаль-экономик һәм иҗтимагый-культура өлкәләрендә без халкыбызны, кайбер «фәнни» хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә, артта калган, надан, алга баруга өметен өзеп яшәгән, дип кенә характерлый алмыйбыз. Әлбәттә, мондый фикерләр өчен берникадәр җирлек тә булган. Бу бигрәк тә идеология өлкәсендә ачык сизелә. Электән калган кадим мәдрәсәләрдә йә булмаса Бохарада укып кайтып мулла, ишан булган кешеләр шактый җирләрдә укыту-тәрбия эшләрен үз кулларында тотканнар. Аларның бөтен өйрәтүләре «бернинди яңа нәрсә эшләп булмый, барысы да язмышта алла тарафыннан алдан билгеләп куелганча булырга тиеш» дигән принципка корылган. Бер нәрсә эшләп булмый, димәк, сыйнфый изүгә каршы көрәшеп тә булмый, алар гавәмне феодаль тәртипләргә буйсындырып, фикри караңгылыкта тотарга тырышканнар. Күп кенә мулла-ишаннар шул нигездә байлык туплап изүче хаким сыйныфның бер өлешен тәшкил иткәннәр. Дәүләт крестьяннары булып саналган татар авыл халкы җилкәсенә буржуазиянең дә файдасын яклаучы феодаль дәүләт изүе, җирле властьларның, һәр төрле чиновникларның җәберләүләре, милли изү (мыскыл итү, миссионерларның төрле яла ягулары, чукындырулар, халыкка чит гадәтләр кертергә тырышулар) бик авыр йөк булып төшкән. Шунлыктан крестьяннар төрле юллар белән һәм ничек булдыра алсалар шулай изүчеләргә каршы сыйнфый һәм милли азатлык өчен көрәш алып барганнар. Крестьяннар әле ул вакытта милли дәүләт төзү, мөстәкыйльлек идеясен тудыра алмаган. Ләкин әнә шул төрле изелүдән котылу юлларын эзләгәннәр һәм аңа каршы көрәшнең төрле формаларын кулланганнар. Болар рәтеннән гариза һәм шикаятьнамәләр язуны, лашманчыларның һаман саен эш ташлауларын, уделга, ягъни патша гаилә-

се файдасын карауга беркетелгән татар крестьяннары хәрәкәтләрен, Кырым сугышы вакытында һәм аннан соң хөкүмәткә каршы күтәрелешләрне, авыллары белән элек чукындырылган меңәрләгән татарларның яңадан ислам диненә кайтуларын, аның өчен Себергә куылуга каршы баш күтәрүләрне, һәм, ниһаять, Россиядә икенче революцион ситуациянең бер күренеше булган 1878-1879 еллардагы татар крестьяннары восстаниеләрен күрсәтергә мөмкин. Кыскасы, бу дәвердә крестьяннарның көрәш идеологиясе ислам дине өйрәтүләреннән,буржуаз һәм феодаль фикерләү кысаларыннан инде читкә чыккан, алар социаль-иҗтимагый тормышта пассив булып, баш иеп тормаганнар, ә бәлки актив көч булып хәрәкәт иткәннәр.

1755 елгы крестьяннар хәрәкәте җитәкчесе Батыршадан һәм Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышыннан алып XX йөз башларына кадәр сыйнфый һәм милли көрәш мәйданына чыккан күп төрле иҗтимагый хәрәкәтләрнең берсе булып вәисевчеләр хәрәкәте тора. Ул тарихыбызның үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итә.

Вәисевчеләр хәрәкәтен башлап җибәрүче Баһаветдин Хәмзә улы Вәисев 1819 елда (улы Гайнан 1804 елда туган дип күрсәтә) Татарстанның хәзергә Зеленодольск районы Мулла иле авылында крестьян гаиләсендә туа. Яшьлеген үз авылындагы мәктәп-мәдрәсәләрдә укып уздыра һәм 22 яшендә хәзерге Ульяновск өлкәсендәге Иске Колаткы авылы мәдрәсәсенә барып Җәгъфәр ишан Салиховта укый[1].

Җәгъфәр Салихов үзе егерме ел буе Урта Азия һәм Якын Көнчыгыш илләре мәктәпләрендә укып, зур белем алган, үзенчә яңа карашлы кеше була. Ул буржуаз мөнәсәбәтләр үсүе нәтиҗәсендә кешеләрнең әхлагы бозылуын каты тәнкыйть итә. Сәүдәгәрлек алдашуга китерә, предприятиеләрдә эшчеләр изелә, тупаслана, тәртипсезлекләр күбәя — боларга каршы көрәшергә кирәк, ди. «Үзебезнең Россия патшасының тугрылыклы, игелекле һәм гадел булуын телик, шулай булганда башка чит илләргә мөрәҗәгать итү кирәк булмас», — ди. Ул, мәдрәсәсендә иске схоластик укыту белән чикләнмичә, тормышта кирәк белемнәр бирүне алга куйган мөдәррисләрнең берсе булган.

Баһаветдин, остазы үлгәч, аңардан алган фикерләрне тагын да үстереп, 1862 елда үз тәгълиматын тарата башлый. Бу тәгълиматның төп өлеше түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Ислам дине муллалар, ишаннар, Диния нәзарәте, мөфтиләр тарафыннан бозылып беткән. Диннең сафлыгын, башлангыч һәм беренчел кагыйдәләрне, Коръәннең сафлыгын саклау өчен юлдан язган шәригатьче муллаларга каршы көрәшергә кирәк. Аларга бернинди сәдака бирмәскә, мәчетләренә йөрмәскә кирәк.

2. Җирле властьларга, чиновникларга ышанмаска һәм буйсынмаска, бары тик патша властен гына таныырга. Шунлыктан һәр төрле салымнарны бу чиновникларга түләмәскә, рекрут бирмәскә, җирле властьларның чараларына каршы торырга, боерыкларны үтәмәскә кирәк, киләчәктә бернинди власть булмаячак.

3. Сәүдә, предпринимательлек белән шөгыльләнмәскә, алар халыкның әхлагын бозалар, тәртипсезлекләр тудыралар.

4. Барлык мөселманнар тигез хокуклы саналырга, байлар-ярлылар булмаска тиеш. «Барлык мөселманнар бертуган» принцибын тормышка ашырып, бердәм һәм уртак милек булдырырга.

5. Яңа җәмгыять төзергә кирәк. Ул җәмгыять «алла полкларыннан» торырга тиеш. Һәр полкта 99 башлык, 999 өйрәтүче, 9999 ияртүче-буйсынучылар булырга һәм полклар «дистанция» тәшкил итәргә тиешләр. Бу дистанция, Вәисев фикеренчә, аның кул астында, Россия патшалыгында болгар оешмасы булырга тиеш. Алла полклары авыл кешеләре — крестьяннардан торырга тиеш. Алар авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнергә, килгән керемнән салымнарны дистанция канцеляриясенә, Вәисевнең «Мәхкәмәи шәргыя»сенә түләргә тиешләр. Полкларны берләштергән дистанция начальнигы булып Баһаветдин Вәисев тора. Ул болгар ханнары нәселеннән, имеш.

6. Милли мәсьәләдә Вәисев: без җирле болгарлар, ә муллалар, мөфтиләр монголлар белән килгән татарлар, имеш; «татар» атамасына каршы булырга кирәк, ул җирле болгар, мөселманнарга көчләп тагылган исем, ди һәм башка халыклар белән, бигрәк тә руслар белән, дус яшәргә, рус телен һәм фәнни белемнәрне өйрәнергә кирәк, дип чыга. Ул шундый фәннәр укытыла торган дөньяви мәдрәсә ачарга да тырышкан.

Баһаветдин Вәисевнең дөньяга карашы, күргәнебезчә, идеалистик була, ләкин ул үзенчә утопик социализмга һәм стихияле материализмга кадәр барып җитә. Бу хәл, гомумән, иҗтимагый-экономик үсешнең объектив кануннарын, антагонистик җәмгыятьтәге төп каршылыкны — хезмәтне һәм хезмәт нәтиҗәсендә туган җимешләрне бүлүдәге каршылыкны, эксплуатация һәм аңа каршы көрәш эчтәлеген аңламаудан,

[1] Бу мәкалә Үзәк дәүләт тарих архивының 140, 732, 812, 821, 983, 2839 фондларында саклапучы документлар нигезендә язылды.

кайвакыт аңлашылмый торган сораулар алдында аптырап калудан килеп чыккан. Шундый мәсьәләләрне чишүдә гаҗиз булган Вәисев һәм аның тарафдарларының тактикасы да фанатикларча активлык белән сугарылган. Б. Вәисев, үзенең болгар оешмасын рәсми төстә тануларын сорап, патшага һәм эчке эшләр министрына хатлар яза. Боларның нәтиҗәсе булмагач, Төркиягә, чит илләргә хатлар яза һәм «ислам диненең чын дөреслеген ачу» өчен вәкилләр сайлау турында белдерү белән чыга. Вәисевчеләр тарафыннан дәүләткә салым түләү, рекрут бирү туктатылгач, җирле власть аларга карата җәза чаралары куллана башлый.

Бәһаветдин үзенең канцеляриясен төзи; анда мөһер, басу станогын булдырган, секретаре эшләгән, төрле билетлар, брошюралар бастырылган. Аның ярдәмчесе булып Абдуллин дигән кеше эшләгән. Вәисев явызлык һәм гаделсезлекне, бигрәк тә ислам диненең бозык әһелләрен, надан муллаларны фаш итеп шигырьләр дә яза. Аларны кулдан язып та, бастырып та тарата. 1872 елның июлендә мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев эчке эшләр министры А. Я. Тимашевка Бәһаветдин Хәмзиннан үзен мыскыллап язган хатлар алуы турында зарлана.

1880 елларга Вәисев тарафдарлары шактый күбәя һәм бу хәрәкәт көчәйгәннән-көчәя бара. Шул ук вакытта Вәисевкә каршы, үзенеке булмаган 3 баланы җир астында асраган дип, хөкем процессы кузгатыла. Ә 300 дән артык гаиләне, властьларга буйсынмауда һәм налог түләмәүдә гаепләп, Себергә сөргенгә куалар. Вәисевчеләргә каршы приговорлар төзеп, барлык өязләрдән имза җыйганнар. Вәисев халык арасында киң яклау тапмый. Моның бер сәбәбе — ул вакытта халык нык инанган мәчеткә, мәктәп-мәдрәсәләргә, мулла, мөгаллимнәргә кискен каршы чыгу булса кирәк. Властьларга буйсынмау, гомер буе түләнеп килгән салымнарны түләүдән баш тарту крестьяннарны куркуга да салгандыр, күрәсең. Күпчелек Вәисевнең «өйрәтүләрен» аңламаган да.

Улы Гайнан, әтисенең эш алымнарын бераз үзгәртсә дә, күпчелек вәисевчеләр тәгълиматын кабул итмәгән. Моның өстенә Бәһаветдин Вәисев шигырьләрендә мулла, байларны «дию», «аждаһа» дип атый һәм аларны «ашарлар — адәм, эчәрләр — шәраб» дип тасвирлый. Аның кайбер шигырьләрен улы Гайнан 1907 елда аерым китап итеп бастыра.

Суд, Бәһаветдинда психик авыру дип, аны больницага салырга хөкем чыгара. Ләкин бу кешене кулга алу өчен аның крепость кебек итеп ныгытылган өен штурмларга туры килгән. Полиция һәм янгын командалары, шәһәр обывательләрен җыеп, өйне берничә көн камап торганнар. Ахыр чиктә Б. Вәисев җүләрләр йортына ябыла. Вәисевчеләрнең мөлкәте талана, китапханәләре туздырыла. 1884 елдан алып 1894 елгача, ягъни үлгәнчегә кадәр аны шул «больница»да, бер кем белән дә күрештермичә, тышкы дөнья белән аралаштырмыйча тоталар. Күмелгән җирен, каберен дә беркемгә әйтмиләр.

Үткән гасырның 70-80 нче елларында вәисевчеләр патшага һәм дәүләт учреждениеләренә бик күп хатлар, гаризалар җибәрә. 1883 елда, патшага җибәргән бер телеграммасында Бәһаветдин русча «Дистаночный начальник Дардеманд Дарвиш сотрудник всему миру Багаудин аль-Булгари Догагай Хамзин Ваисов» дип кул куя. Алар турында газеталарда һаман язып торганнар. Патша исеменнән министр Сперанский Казан губернаторына «Кем ул «Дәрдемәнд Дәрвиш», Бәһаветдин Вәисев үлдеме әллә» дип телеграмма суга. Ләкин актив вәисевчеләр Себергә куылгач, Бәһаветдин больницага ябылгач, бу хәрәкәт сүрелә, бетә диярлек. Иректә калган вәисевчеләр патша исеменә бертуктаусыз гариза җибәрүне дәвам итәләр. 1890 елгы гаризаларында алар түбәндәгеләрне сорыйлар: ислам диненең беренчел сафлыгын саклау өчен үзләренең дога йортын, Вәисевне һәм аның өен, мөлкәтен һәм сөргенгә куылган тарафдарларын кире кайтарырга, вәисевчеләрне «татарлар һәм крестьяннар» дип атамаска, ә «мөселман болгарлар» дип атарга.

Вәисевчеләр хәрәкәтенең яңадан күтәрелеп, үсеп китүе Бәһаветдинның беренче улы Гайнан Вәисевка бәйле. Ул 1904 елда Төркмәнстан якларыннан Казанга кайта һәм атасының эшен дәвам иттерә башлый. 1905-1906 елларда 60-70 вәисевче булса, 1909 елда Россиядә барлыгы биш йөзләп крестьян хуҗалыгы вәисевче гаиләләр дип саналган. Шулардан 296 хуҗалык Томскида (элек сөрелгәннәр), 120 хуҗалык Казан губернасында яшәгән. Гайнан шулай ук үзенең мәхкәмәсен (канцеляриясен) булдыра. Авылларда агитация алып бара, китаплар яза һәм аларны бастыру артыннан йөри, патшага һәм дәүләт учреждениеләренә хатлар, гаризалар яудыра. Л. Н. Толстой аның хәрәкәте белән кызыксынгач, Ясная Полянага барып, Л. Н. Толстойда берничә көн торып кайта. 1909 елга кадәр вәисевчеләр патшага, аның хатыны Мария Федоровнага, тәхет варисларына, дәүләт учреждениеләренә барлыгы 33 меңгә якын гариза, үтенеч һәм хатлар җибәргәннәр. Патша хөкүмәтенә аларга җавап эзләргә, бу хәрәкәтне туктату өчен чаралар күрергә, сөргенгә куылучылар белән мәшәкатьләнергә, диния нәзарәтен вәисевчеләрдән якларга туры килә. Бу, әлбәттә, царизмның көчен күпмедер дәрәҗәдә

згыйфьләндерү булган. Дин пәрдәсе астында политик бурычлар да кую һәм халык азатлыгын үзенчә хәл итәргә тырышу — болар барысы да вәисевчеләр хәрәкәтен милли азатлык хәрәкәтенең бер формасы булган дип карарга нигез бирә. «Крестьяннар арасында сектантлык һәм рационализм үсү факты билгеле, — ә дини кабык астында политик протест чыгышы бер Россиягә генә хас түгел, бәлки үсешләренең билгеле стадиясендә барлык халыкларга хас булган күренеш ул»[1], — дип күрсәтә В. И. Ленин.

1909 елда Гайнан Вәисев, өендә корал саклаганы өчен, кулга алына һәм этап белән Сахалинга сөргенгә куыла. Мондый каты җәза, әлбәттә, корал саклау өчен генә булмаган. Шул ук җирле властьларга буйсынмау, налоглар түләмәү, аерым болгар җәмгыяте оештыру, муллаларны, мөфтиләрне тәнкыйть итү, кире кагу кебек хәрәкәт патша хөкүмәте тарафыннан эзәрлекләнгән һәм аңа чик куярга тырышканнар.

1917 елдагы Февраль буржуаз-демократик революция җиңгәч, вәисевчеләр үзләренең изге хыялларын тормышка ашырырга, элекке Бөек Болгар җирендә үз дәүләтләрен төзү мөмкинлеге туды дип уйлыйлар. Ләкин аларга халык массаларын үз якларына тарту авырайганнан-авырая бара. Революция тирәнәйгән, халыкның политик аңы үскән саен вәисевчеләр артыннан баручылар саны кимегәннән-кими. Чөнки бу вакытта инде хезмәт халкының мәнфәгатьләрен кайгырткан социал-демократик хәрәкәт киң колач җәя башлый. Боларның барысын да исәпкә алып, вәисевчеләргә үз тактикаларын яңа шартларга туры китереп үзгәртү турында уйларга туры килә.

Алар әле 1905-1907 елларда ук заманга хас булган иҗтимагый фикер юнәлешләрен өйрәнергә мәҗбүр булалар. Моның нәтиҗәсендә Гайнан Вәисев социалистик тәгълимат белән таныша һәм кызыкына башлый. Большевиклардан ул үз максатына ирешү өчен таяныч эзли. Аңа күренекле большевиклар В. А. Тихомирнов, А. Я. Аросев һ. б. зур йогынты ясый. Үз чиратында В. Тихомирнов, 1908 елда төрмәдә бергә утыруларын күздә тотып, аны үзен горур һәм бәйсез, төрмәчеләр, гомумән власть башында утыручылар белән дорфа тота иде, дип искә ала. («Знамя революции», 1919, 28 февраль).

Февраль революциясеннән соң Г. Вәисев РСДРП(б)ның Казан комитетына килеп, большевиклар яклы булуын һәм үзен «ленинчы» дип атап, большевикларга ярдәмен тәкъдим итә. Әлбәттә, вәисевчеләр җитәкчесенең бу белдерүенә большевиклар бернигадәр шикләнеп карыйлар һәм ышанмаучылык белдерәләр. Шулай да большевиклар партиясенең, дошманга каршы булган көчләрнең барысын бергә тупларга мөмкин, дигән тактик карашы нигезендә, Казан большевиклары вәисевчеләрне вакытлыча булса да союзник итеп алырга мөмкин дип табалар.

Апрель аенда Казанда «вәисевче алла гаскәрләренең» съезды була. Съезд, Петроград эшче һәм солдат депутатлары Советына мөрәҗәгать итеп, кичекмәстән сугышны туктатуны, аннексиясез һәм контрибуциясез солых төзүне яклап чыга, тынычлык конференциясе чакыруны таләп итә. Шул ук вакытта алар Керенскийга да мөрәҗәгатьтелеграмма җибәреп, аңа ышаныч һәм тугры булуларын белдерәләр. Бу вәисевчеләрнең политик җитлекмәгәнлеген, әле һаман да Вакытлы хөкүмәткә өмет баглаганлыкларын күрсәтә.

Ә менә июльдә Вакытлы хөкүмәт эшчеләр демонстрациясен ут ачып таратканнан соң вәисевчеләр айнып киткәндәй булалар. Керенскийга җибәргән телеграммасында Г. Вәисев аны эшчеләр сыйныфына хыянәт итүдә, социализмның дошманына әверелүдә гаепли. «Сез ирекле бөек халыкны мыскыллау юлына бастыгыз, — дип шелтәли ул Керенскийны. — Николай Романов кебек җавап бирәчәксез. Берни дә үзгәрмәде».

Шунысы кызык, әгәр Вәисевнең Керенскийны мактап җибәргән беренче телеграммасы меньшевикларның «Казанская рабочая газета»сында басылган булса (6 май 1917), икенчесе инде Казан большевикларының «Рабочий» газетасында дөнья күрә. (28 июль 1917).

Вәисевчеләр хәрәкәтенә тулаем бәһа биргәндә большевиклар аларны, пролетариатның вакытлы юлдашлары, дип бик дөрес бәялиләр. Чөнки аларның идея һәм теоретик нигезләре марксизм-ленинизм тәгълиматыннан бик ерак һәм аңа капма-каршы иде. Кайбер буржуаз тарихчылар, атап әйткәндә С. Зинковский, Е. Х. Кәрн, Ш. Келькеже һ. б. большевизм белән вәисизмны бергә кушып, аларны бер үк нигездән үсеп чыккан дип карарга маташалар. Алай гына да түгел, Совет көнчыгышы мөселман халыклары арасында марксизмның тиз таралуын коммунизм һәм ислам идеологиясенең тамыры бер булуда дип аңлатырга тырышалар.

Гайнан Вәисев чыгышларында эшчеләрне күп мәртәбәләр телгә алса да, ул сыйныфлар көрәшен аңлау дәрәҗәсенә күтәрелеп җиткән шәхес түгел. Аның өчен ярлысы да, бае да «бертуганнар» булган. Ә социализмны ул фәкать алла белән бәйләп кенә

---

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. Казан, 1955, 4 т. 240 б.

күз алдына китергән. «Знамя революции» газетасында басылган бер мәкаләсендә (24 январь, 1918) Г. Вәисев «Әгәр дә сез, туганнар, социализмга каршы барсагыз, моның белән сез аллага да каршы барасыз», — дип язды. Вәисевчеләр хәрәкәтен яхшы белгән В. Тихомирнов, Гайнан Вәисев бер вакытта да безгә турыдан-туры нәрүче, безнең тарафдар булмады, аның күп идеяләре безнең өчен ят, аңлаешсыз һәм, ихтимал, объектив безгә дошман да, дип язды «Знамя революции» газетасының 1919 ел, 28 февраль санында.

Яшәешебезне үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык шартларында вәисевчеләрнең Бөек Октябрь социалистик революциясендә катнашулары аеруча кызыксыну уята. Элгәрәк елларда без бу турыда сүз йөрткәләсәк тә, әлеге хәрәкәткә объектив бәя бирә алмадык, чөнки дини оешманың социалистик революциядә катнашуы мөмкин дигән караш безнең фикерләвебезгә туры килми иде. Ул гына да түгел, социалистик революциядә бары тик пролетариат һәм ярлы крестьяннар гына хәлиткеч роль уйнадылар, дигән формулага каршы төшеп, революциядә катнашучыларны киңрәк, аны бөтенхалык, барлык изелгән халыклар революциясе дип караучыларга марксизм-ленинизмнан тайпылучы, аңа ревизия ясаучы дигән тамга да салынды. Чынында исә кайбер дини оешмаларның социалистик революциядә катнашулары марксизм-ленинизм тәгълиматына һич тә каршы килми.

Вәисевчеләр Казанда рус һәм татар эшчеләре, солдатлары белән бергә Вакытлы хөкүмәт вәкилләрен бәреп төшерүдә һәм Совет властен урнаштыруда катнаштылар. Документлар күрсәткәнчә, революциягә бер ай кала, сентябрь аенда большевиклар вәисевчеләрне корал белән тәэмин итәләр. Шуңа таянып, француз тарихчысы Ш. Келькеже, вәисевчеләрдән башка татар халкы Октябрь революциясендә пассивлык күрсәтте, дигән уйдырманы алга сөрмәк була. «Казан утлары» журналы укучыларына Муллануp Вахитов җитәкчелегендәге Мөселман социалистлар комитетының, татар эшчеләре һәм солдатларының социалистик революциядә актив катнашулары күптән билгеле факт. Шуның өчен монда ул мәсьәләгә тукталып торуның артык кирәге дә юк.

Вәисевчеләрнең элекке вәкилләре белән булган әңгәмәләр, алар язып калдырган истәлекләр һәм кайбер башка документаль материаллар да бу фактны раслый. Мәрхүм генералыбыз Якуб ага Чанышевның 1967 елның 1 сентябрендә язган хатында мондый юллар бар: «Вәисевчеләр дружинасы Совет ризалыгы белән төзелгәннәр иде һәм алар, Крестовниковлар заводы кызыл гвардиячеләре белән бергә, Округ командованиесе штабы һәм Керенскийның Казандагы вәкиле капитан Калинин урнашкан «Сандецкий сарае» юнәлешендә Октябрь сугышларында катнаштылар». Якуб ага әйтүе буенча, вәисевчеләр дружинасында 200-250 ләп кеше булган.

Ни өчен һәм нинди максат белән вәисевчеләр революциядә катнашканнар соң дигән сорау туа. Моны төрле яктан чыгып аңлатырга кирәк. Буржуаз Вакытлы хөкүмәт халык массаларының бер таләбен дә канәгатьләндерә алмады. Империалистик сугыш дәвам итте. Гасырлар буе крестьяннарның, шул исәптән татар крестьяннарының да хыялы булган җир мәсьәләсе хәл ителмәде һәм бу мәсьәләне хәл итәр дип өметләнгән Учредительное собрание чакыру да нигезсез сузылды. Милли мәсьәлә турында бернинди сүз дә булмады. Боларның барысын да Гайнан Вәисев күрми калмас, билгеле. Шулай ук большевиклар программасының халык мәнфәгатьләренә туры килүен һәм аларның большевиклар артыннан барулары да Г. Вәисевне һәм аның иярченнәрен шул юлны сайларга мәҗбүр иткән дигән нәтиҗә ясарга була. Әлбәттә, вәисевчеләр большевиклар артыннан сукырларча иярәннәр дип әйтеп булмый. Аларның үз программалары, үз максатлары булган. Алар дини нигездә Болгар дәүләтен торгызу планыннан кире кайтмаганнар. Шул ук вакытта большевиклар партиясенең ленинчыл милли программасындагы милләтләргә үзбилгеләнү хокукы бирү мәсьәләсе аларның игътибарын җәлеп иткән дип әйтергә мөмкин. Ләкин бу хокукның кемгә бирелүен алар ахыргача аңлап җиткермәгәннәр булса кирәк.

Совет власте урнашкач, Г. Вәисев Казан губерна азык комитеты һәм Управа члены булган. Бу оешманың ике вәкиле Казан эшче һәм крестьян Советына депутат итеп сайланган. Депутатларның берсе, Ибраһим Зәйнуллин, вәисевчеләр оешмасы җитәкчеләреннән берсе. Ул 1919 елның август-сентябрендә Казан губернасы ревтрибуналы члены да була. Урыннарда да алар Совет власте органнары эшендә катнашканнар.

Совет хөкүмәте тарафыннан ясалган беренче адымнар вәисевчеләрнең дә теләкләрен канәгатьләндерә башлый. Солых, җир, динне дәүләттән һәм мәктәпне диннән аеру турындагы декретларны алар да хуплап каршылыйлар.

1918 елның февралендә татар буржуазиясе барлык контрреволюцион көчләр белән берлектә Совет властена каршы «Болак арты җөмһүрияте» оештырганда, вәисевчеләр штабы шәһәрнең шул як өлешендә кала (хәзерге Г. Тукай урамы, 92 йорт) һәм әлеге җөмһүрият өчен зур куркыныч тудыра. Өстәвенә вәисевчеләр кулында инде меңгә якын мылтык һәм башка корал да тупланган була. Контрреволюцион көч-

ләр иң беренче чиратта вәисевчеләр штабын юк итәргә һәм корал складын кулга алырга маташалар. Үзара атыш вакытында Г. Вәисев һәлак була. «Правда», «Знамя революции» һ. б. газеталарда бу турыда некрологлар дөнья күрә. (Правда. 1918, 10 март (25 февраль); Знамя революции. 1918, 2 март (17 февраль)). Г. Вәисев туганнар каберлегенә күмелгән. Гайнан Вәисев үтерелгәннән соң аның хатынына персональ пенсия билгеләнә.

Ул вакыттагы газеталарда вәисевчеләр хәрәкәтенә дөрес бәя бирелгән. Г. Вәисевнең шул чорда революциягә бирелгәнлеге, Кызыл гвардиягә ярдәмгә мөселман яшел гвардия төзүе, шуның белән буржуазиягә каршы көчләрне бергә туплау һәм Совет властен саклап калуда азмы-күпме көч куюы турында язганнар. Шул ук вакытта аның социализмны фәкать дин аркылы аңлавын, «дини социализм» юлыннан баруын да күрсәткәннәр.

Вәисевчеләр хәрәкәтенең соңгы сәхифәләре Гайнанның энесе Газизҗан белән бәйләнгән. Республиканың Запас Армия махсус бүлек начальнигы аңа «шөһрәт, власть яратучы, дәүләт акылына ия була алмаган кеше» дигән характеристика бирә. Гражданнар сугышы чорында яшь совет республикасын саклау өчен күп көч куярга туры килде. Вәисевчеләрнең гади әгъзалары революцияне саклап кан коялар. Аларның җитәкчеләре дә дошманны җиңми торып программалары үтәлмәячәген аңлыйлар. Шуңа күрә Газизҗан 1919 елның 25 сентябрендә Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросына һәм Бөтенроссия Үзәк хәрби штабына өч ай эчендә 40 меңлек революцион гаскәр төзи алуы турында телеграмма җибәрә. Аның фикеренчә, ул алты айда 200 мең, ә бер елда ярты миллионлык армия җыя алачак. Газизҗан, барлык мөселманнар да аның канаты астына җыелырлар, дип ышанган. Ләкин бу чынбарлыктан бик ерак торган өмет була. Чынлыкта исә 1919 елның декабрендә вәисевчеләр оешмасында, теләктәшлек күрсәтүчеләр белән бергә, нибары 178 кеше саналган.

Шулай да фронт командующие М. В. Фрунзе Самарада вәисевчеләрдән укчы полк төзүгә рөхсәт биргән[3]. Ләкин, бу полкка теләсә кем алыну нәтиҗәсендә, контрреволюцион көчләрнең моннан файдалану куркынычы туа. Шунлыктан киләчәктә вәисевчеләрдән отрядлар төзү тыела. Өстәвенә, урыннарда вәисевчеләрнең «изге гадәт» буенча Совет властена буйсынмау очраклары да күзәтелгән. Үз әгъзаларына Кызыл Армиядә хезмәт итүдән азат ителүләре турындагы белешмәләр дә бирелгән. Әлбәттә, вәисевчеләрнең мондый чыгышларына чик куярга кирәк булган. Ә инде армиягә алынган вәисевчеләрдән (ике батальон һәм комендант командасы) өченче Самара эшчеләр полкы төзелгән. Бу полк атаман Сапожков фетнәсен бастыруда катнаша. Кайбер мәгълүматлар буенча, алар Александр Кут һәм Александр Гай тимер юлын төзүдә катнашканнар. Ә кайберләре Идел буе, Украинаның икмәкле районнарында кулакларга каршы көрәштә һәм ашлык хәзерләүдә дә үз өлешләрен керткән. Бу бурычларны үтәгәннән соң вәисевчеләрнең отрядлары таратыла һәм аның солдатлары өйләренә кайта.

Революция киң колач җәя барган саен большевиклар белән вәисевчеләр арасында каршылыклар тирәнәя барган. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү вәисевчеләр җитәкчелегенең Болгар турындагы әлектән килгән өметләрен юкка чыгарган.

Шуның өчен вәисевчеләр Совет власте белән хезмәттәшлектән шактый читләшкәннәр һәм тора-бара бөтенләй аерылганнар. Ә кайбер урыннарда, мәсәлән Чистай, Арча һәм башка өязләрдә, хәтта Совет властена каршы чыгыш ясарга да маташып караганнар.

Менә шуларның барсын да исәпкә алып, Татарстан АССР Эчке эшләр халык комиссариаты коллегиясе 1921 ел, 21 январь утырышында вәисевчеләр оешмасын бетерү турында карар кабул итә. Шуннан соң Газизҗан Вәисев өметсезлеккә бирелеп Төркстанга киткән һәм 1965 елда Ташкент янындагы районнарның берсендә үлгән.

Вәисевчеләр хәрәкәте политик аңы зәгыйфь булган диндар крестьяннарның социаль гаделсезлеккә каршы көрәш ысулларын чагылдыручы бер тарихи күренеш ул. Бу хәрәкәтнең уңай яклары да, тискәре яклары да булган. Аларның уй-фикерләрен тирәнрәк һәм киңрәк өйрәнү, көрәш ысулларын җентекләбрәк ачыклау киләчәктәге бурычларның берсе дип каралырга тиеш.

---

[3] Фрунзе М. В. Избранные сочинения. Т. 1. — М., 1957. 282 б.

Китап күзәтү

# ГӨЛЛӘР ЕЛЫ

Моннан унбиш еллар элек язучыларның Тукай исемендәге клубында булган бер әдәби кичә хәтердә калган. Бу кичәдә яшь кенә шагыйрә — Эльмира Шәрифуллина «Елмайыйк без, кызлар!» дигән шигырь укыган иде. Артык сурәтләүләрсез генә, самими бер хис белән, балаларчарак язылган бу гади генә шигырь тыңлаучыларның күңеленә бик хуш килгән иде. Шигырьне өлкән шагыйребез Хәсән абый Туфан яратып, сәхнәгә менгән иде. Эльмираның кулын кысып, болай дигән иде ул:

— Елмаеп кер, сеңелем, шигърияткә, елмаеп... Төкле аягың белән!...

Шигърияткә әнә шулай елмаеп килеп кергән Эльмираның узган ел «Гөлләр елы» дип исемләнгән икенче шигырь җыентыгы дөньяга чыкты.

Китап «Хәерле иртә» дигән шигырь белән ачыла:

*Хәерле иртә, туган җирем,*
*Илем-көнем, балаларым!*
*Уяныгыз,*
*Ямьйсы бар*
*Бу дөньяның яраларын!..*

. . . . . . . . . . . . .

*Офыкларда, болытларда*
*Кара тап юкмы?*
*Сабыйларның өсте бөтен,*
*Тамагы тукмы?..*

Үзе тормышның ачысын-төчесен татыган, шатлыкны да, кайгыны да кичергән Эльмира Шәрифуллинага ана хисләре, бала тәрбияләү мәсьәләләре бик якын. Китапта аналар, балалар турында бик матур, тирән мәгънәле шигырьләр бар. Аналар турында шигырьләр күп языла, ләкин Эльмира аналарның бөеклеген, изгелеген үзенчә ача. Гади итеп, шул ук вакытта кайнар хис белән, үтемле шигъри чаралар белән тасвирлый.

*Алиһә дә, ханбикә дә түгел,*
*Син гап-гади татар килене, —*

дип башлана бер шигырь. Әнә шул гади генә татар килене, итәк тулы баласы белән, икмәк үстерә, ил турында кайгырта, ирек яулап, ут-сулар кичеп кайткан иргә терәк булып, тугры гомер итә, мәхәббәтен мәңге саклый белә. Шагыйрә әйткәнчә, аның мәхәббәте, аның сөюе илне көчле итә.

«Син беләсең булыр» дигән шигырьдә лирик герой бәхеткә зур өметләр белән, матурлыкка туймас күзләре аша елмаеп, тормышка аяк атлаганда, якты хыяллары белән егылып төшкәч: «Әйтче, әнкәй, син беләсең булыр, кайгыларның бармы бетәсе?»... — дип ана җилкәсенә башын сала. Аналарның үз баласы турында барысын да белүен, тоюын, бик нечкә сиземләп, хәтта алдан күрүен сурәтли шагыйрә. Аналарны ул яңа биеклеккә күтәреп, «кояш игезәге» дип атый. Аналарның гүзәллеген, батырлыгын дәвам итүче — балалар. Нәселнең дәвамы булырга тиешлеген раслап, шагыйрә:

*Бер өлгесе итеп матурлыкның,*
*Күңелендәге ана горурлыгын*
*Илтә барыйм җиде буынга! —*
ди.

Бүген нәсел-нәсәбен корытучы, баласын ташлаучы тотнаксыз «аналар», юлдан язган хатыннар ешрак очрый барган көннәрдә, илебездә әниле килеш ятимнәр арткан елларда, ана горурлыгын байрак итеп күтәрергә кирәк. Эльмира шигырьләренең чын кыйммәте менә шуңа күрә дә зур.

Э. Шәрифуллина аналар, балалар турындагы шигырьләрен тынычлыкны яклау темасы белән үрә. Әйе, ана, бала, тынычлык — бербөтен һәм аерылгысыз. Бу шигырьләр тетрәтерлек киеренке тойгылар белән, шагыйрә үзе әйткәнчә, «телем-телем туралган җан» белән язылганнар. Чын шигъри чаралар белән сәнгатьчә эшләнгән, күз алдына җанлы кешеләр булып килеп баса торган аналар, балалар — сугыш җәфаларын, газапларын күп кичергән, фашизмның корбаннары булган күп миллионнар шагыйрә йөрәге аша уза.

Газиз балаларын фашизм тырнагыннан ничек коткарырга белми газапланган ана хисләрен шагыйрә үтемле итеп ачып бирә:

*Ташка әйләнсәм, таш бәгырем сызлар,*
*Йөрәгемдә бала ярасы...*

. . . . . . . . . . . . .

*Күкрәгемне көнгә ачып куям,*
*Гыйбрәт итеп йөрәк ярамны,—*

дип, фашизм тоткынлыгында газаплап үте-

релгән ана монологы аша сугышның коточкыч зур җинаять икәнен тагын бер кабат безнең аңыбызга җиткерә. Мондый шигырьләрендә шагыйрә җанны уятып, күңелне кузгатып, чаң каккандай бөтен кешелеккә дәшә.

Сугыш китергән афәтләрнең дәвамы — ил тулы тол хатыннар. Толлык, ялгызлык, ятимлек — барысы да диярлек сугыш нәтиҗәләре. Эльмира Шәрифуллинаның бу китабында тол хатыннар, ялгызлык турында шигырьләр байтак һәм алар күңелгә көчле тәэсир итәрлек шигъри алымнар белән язылган. Беренче карашка гади генә кебек, әмма күз алдында тулы бер күренеш, чын тормыш:

*Өйдән-өйгә, җаннан-җанга*
*Шатлык керер чагында,*
*Япа-ялгыз, нәүмиз булып*
*Утырабыз табында...* —

ди шагыйрә «Күрше хакы» дигән шигырендә. Дәһшәтле сугыш күпме асыл ир-егетләрнең гомерен өзде. Әле бүген дә, тыныч еллар дигән көннәрдә дә күпме һәлакәт, күпме югалту, күпме корбаннар... Хатын-кызлар ялгыз, тол калу һаман дәвам итә... Бу социаль кайгы. Шагыйрә ул кайгыны ил белән кичерә. Шагыйрә һич тынгылык белми. Бу хәлдән котылырга чара эзли, әмма ләкин аннан котылырга чара юк.

*Ярларны сулар кага,*
*Ялгызлар суга бага.*
*Ялгызлыктан качар идем,*
*Суларга ага-ага,*—

ди лирик герой.

Бу инде чын тормыш. Монда ялган, фальшь юк. «Без бәхетле илнең бәхетле кешеләре» дип купшы лозунглар кычкыру заманы үтте. Шигърияттә ачы, ләкин чын тормышны чагылдырыр көн җитте. Эльмира шуның көчле генә үрнәкләрен бирә. Адәм баласын табигать шулай яраткан: дөньяда тол, ялгыз булмаска кирәк, парлы яшәргә кирәк, ә пар буласы җан иясе юк... Кешенең яры булмагач, бәхете түгәрәк түгел. Ул үз мәхәббәтен эзли:

*Куырылып янасын да бел,*
*Күтәрелә әнә кояшка.*
*Эх мәхәббәт, гади тереклектән*
*Һәрчак өстен була бер башка.*

Күңел кояшка күтәрелә, янасын белсә дә үз мәхәббәтенә ашкына. Шагыйрә толлар, ялгызлар турындагы шигырьләрен мәхәббәт лирикасына сала, мәхәббәт лирикасы белән үрелдереп, бу теманы тагын да көчле тойгылар дулкынында айкый. Мәхәббәтенә омтылган җанның күңел халәтен чагылдыручы мондый юллар күп:

*Айкала су, чайкала су,*
*Башларыма уй сала.*
*Иңнәремә болыт ава,*
*Җаныма салкын ява,—*
*Тамчы-тамчы сагыш җыеп,*
*Гомер сөрә кыз бала!..*

Шагыйрә кеше күңеленең нечкә моңнарын, нәфис аһәңнәрен тотып алган:

*...Көләр чакта, ятып еладым,*
*Елар чакта түздем, чыдадым.*
*Мәхрүм итеп кәеф-ләззәттән,*
*Үз җанымны үзем кыйнадым.*

Мондый шигырьләрен укыганда, шагыйрәнең иҗаты, үзәк өзгеч шигырьләре укучыны тетрәндергән Газизә Сәмитова иҗаты белән аваздаш диясе килә. Эльмира — Сәмитова һәм әле күптән түгел генә безнең арабыздан киткән, тирән фикерле шигырьләре белән шигъриятебездә үз биеклеген яулаган Саҗидә Сөләймәнованың матур традицияләрен иҗатына үрнәк итеп куя. Хатын-кыз шагыйрәләргә хас нечкә тоемлавы, фикерләүдә, шигъри сурәтләр куллануда кыюлыгы белән Эльмира Шәрифуллина иҗатының киләчәге зур булыр дип ышанасы килә.

Шагыйрәгә зур өмет баглаган хәлдә җыентыкта шик-шөбһә уятырлык шигырьләр дә барлыгын әйтми булмый. Зур шагыйрәләребезгә аваздаш шигырьләр язган Эльмираның бу китапка керергә лаек түгел әсәрләренең җыентыкта урын алуы күңелне борчый.

*Нишлим икән, тешлим микән...*

. . . . . . . . . . . . . . . . . .

*Йөрәгем — хисләр казаны...*
*Ә күзләрем — суыткыч...*

. . . . . . . . . . . . . . . . . .

*Ишәрмен күк ишмәсен...*

Моныңише юллары булган шигырьләр башка әсәрләрдәге югарылыкны төшерә башлый.

Эльмира Шәрифуллина үзенең шигырьләрендә шулкадәр эчкерсез: күңел түрендәге бөтен серләрен укучы белән уртаклаша, укучыга ышанып, күңелендәге бөтен уй-хисләрен ачып сала. Хәтта шулкадәр ышана, күңел тәрәзәсен шарран ачып куеп, чит-ят күзләргә күрсәтергә, чит-ят колакларга ишеттерергә кирәкмәс нечкәлекләрне дә кәгазь битенә төшерә башлый.

Аннары шуны да әйтеп китәргә кирәк саныйм: бу җыентык ни өчен балаларга багышлап чыгарылды икән? Аталар, аналар, тол хатыннар, ялгызаклар, мәхәббәтнең аяусыз тилмертүләреннән газапланган гашыйклар турындагы шигырьләр балалар өчен түгел.

Күңелне борчыган кайбер уңышсыз шигырьләре, строфалары булса да, китап шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның иҗади үсеше дип бәяләнергә хаклы. Авторга чын күңелдән бер теләк: «Иҗатында «Гөлләр елы» дәвам итсен!»

**Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА.**

# ЮЛДАГЫ ТАБЫШЛАР

Укучыларның игътибарын әдәби әсәр җәлеп итсен өчен, аның үзенчәлекле бер чишелеше, «ачкычы» булырга тиеш. Шул максаттан әсәрдәге гадәти генә эшләрне дә стиль һәм тел осталыгы ярдәмендә күзгә ташланырлык, эстетик ләззәт бирерлек итеп бизәргә мөмкин.

Киресенчә дә була. Уйландырырлык кызыклы вакыйгалар, мавыктыргыч сюжет, кыйммәтле фикерләр кайвакыт шулкадәр төссез тел, примитив алымнар белән сурәтләнә ки, укыгач «нинди зур тормыш байлыгы әрәм булган» дип уфтанып куясың. Кызганыч, иҗат мөмкинлекләре югары булган талантлы язучылар да, вакыты белән, әдәбиятның нәфис сүз дөньясы икәнлеген онытып җибәргәлиләр. Әдәби әсәр, мәңгелеккә йөз тотып, илһам мөмкинлекләренең иң биек ноктасында иҗат ителергә тиеш. Бу хыялың эшкә ашамы, юкмы — анысы сине борчымасын, иҗатыңа комачауламасын! Вакыт барысын да үз урынына куяр.

Мондый фикерләр Гайсә Гатауллинның 1988 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Очар кошлар кебек» исемле җыентыгын укыгач барлыкка килде. Матбугатта сирәгрәк күренгәләсә дә, әлеге автор әдәбият сөючеләргә күптән таныш. Ул шигырьләр дә, хикәяләр дә яза. Беренче җитди адымнарын «Идел» альманахында ясаган иде. Балалар өчен чыккан ике китабы бар. Иң элек шуны билгеләп үтәргә кирәк: Гайсә чәчмә әсәрләрдә уңышлырак эшли — җор телле моңсу күңеле, кабатланмас үзенчәлеге бирелә укучыга көчлерәк тәэсир итә.

Яңа китапның беренче битен ачабыз. «Еракларга китеп...» дип исемләнгән юл повесте шундый сүзләр белән башлана: «Бу дөнья белән алыш-бирешем, юл йөрүләрем инде бик күптәннән башланган иде. Җиде яшемә җиткәндә мин өч төймә, агач саплы пәке югалттым, алмашка ике ат дагасы, биш тиен акча, таш сыбызгы таптым.

Югалтулардан күңел сыкраса да, табышларым мине бөтенләй канатландырып җибәрде: юл буйлап бик озак барсаң, һичшиксез, нәрсә дә булса табасың икән! Моның өчен бик озак — иртәдән кичкә кадәр бертуктаусыз барырга гына кирәк икән...»

Шушы кечкенә генә ике абзаца язучы табигый шаян тел белән беренче карашка юк кына булып күренгән күпме вакыйга сөйләде, шул ук вакытта сиздерми генә, көчләп акыл өйрәтми генә укучыны нинди фәлсәфи югарылыкка күтәрде. Нәфис сүз әсәре буеннан буена шулай гына эш итәргә тиеш тә! Коеп куйган уңай һәм тискәре образлар турында сөйләгән җансыз сүз тезмәләре аша үзеңнең «бердәнбер дөрес» фикереңне көчләп тагу — әдәбиятның үткән чоры. Ул заманнар, шөкер, узып бара...

Әсәрнең төп герое, (бу очракта аны авторның үзе дип әйтергә була) яңа гына мөстәкыйль тормыш башлаган яшь, ләкин дөньяга карашы инде төпләнеп килгән егет. Ул, үз күңеленең тынгысыз һәм хыялый җилкенүенә буйсынып, сәфәр чыга. Чын иҗатчыга хас ярсу эзләнүчәнлек, тормышны тирәнтен аңларга тырышу шул буладыр инде. Ул әле нәрсә эзләгәнен үзе дә белми, аңламый, ләкин бар нәрсәне дә читтән генә күзәтеп йөрми. Һәр эшне, халдән тайганчы тир түгеп, үз җилкәсендә татый — 50 градуслы салкыннарда җир бораулый, аяусыз черкиләр мыжлап торган тайгада урман кисә. Язучы өчен бу — кырыс, ләкин алыштыргысыз чыныгу.

Үз өебездәге проблемалар да тулып ятканда, читкә китеп үзең дә белмәгән нәрсәнедер эзләп йөрүне шик астына куярга була, әлбәттә. Шулай да, ерак вакыйгалар җирлегендә, рухи яктан баеган күңелгә үз йортың да ачыграк күренә, ныграк аңлашыла башлый. Күнегелгән хәлләр яңа яктылыкта ачылалар. Гайсәнең повесте моны ышандырырлык итеп сурәтли. Туган җиреңә кайтып, яңа көч белән эшкә тотыну — иң мөһим икән, дисең.

Повесть, торгынлык елларында язылган булса да, «тайгага такта ташу» кебек акылсызлык күренешләрен читләтеп узмаган. «Урманга утын алып бармыйлар», — дип әйтәләр иде бездә. Алып баралар икән шул... Ул баржаны үз күзләрем белән күрмәсәм, мин дә ышанмаган булыр идем», — дип яза автор.

Әсәрнең тагын бер кыйммәтле ягы — информациягә байлык. Дөрес, кайвакыт, бар белгәнеңне бер әсәргә тутырганда, боламык кына барлыкка килә. Ләкин бу очракта тарих та, география дә, төньяк халыклары тормышы да бер-берсенә органик рәвештә үрелгән.

Кайларга гына китеп, ниләр генә күрсәң дә, билгеле инде, иң мөһиме — кешеләр һәм аралашу бәхете. Кешеләр аша дөньяга күз ачыла, эзләгәнең дә табыла. Төрле югарылыкта сурәтләнгән персонажлар арасында Гайнетдин бабай — әсәрне мәгънәви йомгаклауда авторның күркәм табышы. Җир читенә китеп, халкыбызның энҗе бөртекләре кебек югалырга торган җырларын табып булыр дип кем уйлаган? Без

генә күп вакыт аларның кадерен белмибез, ә читтә алар — бердәнбер юаныч, кадерләп саклана торган хәзинә. Гайсә Гатауллин шушы җырлар аша хәтта глобаль нәтиҗәләр ясый. «Тарихка да бөтенләй башкача карый башладым: дөньяны яулап алырга теләүчеләрнең ни өчен максатларына ирешә алмавын аңладым. Әйе, сугышлар башланмас борын ук җиңелүгә дучар булучан ул, чөнки чит җирдә солдат инде чын солдат түгел, барыннан да бигрәк туган җирен сагынучы кеше...» Шулай, илләр язмышын хәл итүче зур политикларны да уйландырырлык нәтиҗә бу. Әле күптәнме Кушма Штатларның Вьетнамдагы хурлыгы... Ә бүген без Әфганстанның ачы хакыйкатен авыр сызланып тарихыбызга, җаныбызга сеңдерәбез...

Җыентыкта «Алтын» дип исемләнгән тагын бер кечкенә повесть бар. Уен-көлке белән, детектив жанрга пародия рәвешендәрәк башланган бу әсәр, ахыр чиктә, гасырыбыз башы аша, бүгенге җитди әхлак пробемаларына килеп тоташа. Җентекләбрәк тикшерә башласаң, кимчелекләрен дә табарга буладыр, ләкин Гайсә монда да кабатланмас үзенчәлекле чишелеш эзләргә тырышкан.

«Бабай», «Туганнар» исемле моңсу новеллаларның да алда телгә алынган әсәрләр белән рухи бәйләнеше бар. Бәлки, сәердер: Г. Гатауллин әле ир уртасы гына кеше, ә үзе күбрәк картлар, туган җир сагышы турында яза. Югыйсә, яшьрәк вакытта күбебез мәхәббәт кичерешләре тирәсендә бөтереләбез бит... Әйе, мәхәббәт темасына кытлык булмас, ә бүген, милли үзаңыбыз уянып килгәндә, кибә башлаган тамырларга тере су сибү бик тә кирәкле. Инде ничә буын балалары халкыбыздан, телебездән, тәүфыйклы кеше тәрбияләүче гореф-гадәтләребездән читләште. Бу бәладән, һич югында, үсеп килүче буынны саклап каласы иде! Гомер буена сугышта һәлак булган улын көткән, бер тамчы да хәмер капмаган, үлгәндә дә: «Кеше әйберсенә тимәдем, вөҗданыма хыянәт кылмадым», — дип үлгән, пөхтә җанлы, пөхтә гәүдәле картларыбыз һәм карчыкларыбыз турында, үтемле һәм мавыктыргыч итеп күбрәк сөйләргә иде. Бәлки әле соң түгелдер? Бәлки әле ялгап булыр өзелгән җепләрне!

Юморескаларда Гайсәнең таланты тагын да киңрәк ачыла. «Авыл киче», «Бу малай...», «Шомартма, Шомарттин!..» кебек әсәрләрдә ул мәрхүм Фаил Шәфигуллин ирешкән классик үрнәкләр янәшәсендә тора дип һич шикләнми әйтер идем. «Авыл киче»н кабат-кабат укырга була, укыган саен ләззәт алып, елмаеп-көлеп укыйсың. Буш тасвирсыз, артык сүзсез генә тормышның нәкъ үзеннән алынган нинди тере, матур образлар күз алдына килеп баса.

1937 елда репрессияләнгән галим П. А. Флоренскийның шундый сүзләре бар: «Иҗат эшенең сере — яшь булып кала белүдә. Даһилык сере — гомер буена балалыкның, балачак интуициясенең сакланып калуында». Бу сүзләрне истә тотсак, Гайсәнең «иҗат сере»нә төшенү кыен түгел.

Билгеле, «Тәгәрәтеп төяү», «Тормыш җае» кебек мөмкинлекләрдән түбәнрәк эшләнгән юморескалар да бар арада. Беренчесе ипсез генә бер производство мәзәге булса, икенчесе — таушалган схема буенча эшләнгән һәм көндәлек хакыйкатьтән ераграк торган сюжет. Монда авторны стиль җиңеллеге дә, сөйләү осталыгы да коткармый. Хәер, Г. Гатауллин моны үзе дә бик яхшы сизәдер. Яшь вакыттагы бераз беркатлырак тайпылышлар һәркемдә булгалый. Укучылар һәм тәнкыйтьчеләр белән актив аралашып әдәби өйрәнү, калилләшү өчен, әлеге дә баягы, яшьләргә матбугат мәйданы җитми. Тукайлар заманындагы принципиаль, кискен активлыкка, матбугатның күпкырлылыгына, өлгерлегенә, билгеле бер мәгънәдә көнләшеп карыйсың. Ә иҗатка бәя бирүче кайбер администраторлар арасында «ул-бу чыкмагае» дигән җайлашу принцибы әлегә кадәр шулкадәр көчле иде ки, иҗат эшенең төп таянычы булган рухи хөррият турында хыялланырга да туры килмәде. Үз бугазыңны буып, нәрсәне «үткәрәчәкләрен» якынча тоеп, урта кул, шома әйберләрне байтак яздык. Иске богаулар нык тота, «җанны азат итү» процессы озакка сузыла, якын киләчәктә дан тотарлык исемнәребез күренми. Хәер, заманалар үзгәреп килә кебек...

Ә Гайсә Гатауллин иҗатына килгәндә, сәфәр повестеның беренче битләре тылсымына бирелеп җыентыкны сатып алганнар алданмаячаклар! Кирәкле, кызыклы, файдалы китап ул!

Ләкин ниндидер бер канәгатьсезлек хисе тынгылык бирми. Аз, бик аз күренә Гайсә матбугатта. Талантлы, өметле язучы буларак, әдәбиятыбызга ул күбрәк тә файда китерә алыр иде. Сәбәп нәрсәдә соң? Ә бит олы хыяллар утында янып, иҗат куәтен кая куярга белми йөргән егетләрдән Гайсә...

Китаптагы сәфәр чыккан егет ахыр чиктә эзләгәнен таба. Бик тә кадерле, рухи яктан алыштыргысыз нәрсә булып чыга аның табышы... Китапны укучылар моны һичшиксез аңларлар дигән өметтә калам мин.

**Рәниф ШӘРИПОВ**

# ТАТАР ЮВЕЛИР СӘНГАТЕ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

Татар халкына иҗатның бизәү һәм гамәли сәнгать өлкәсендәге барлык төрләре дә билгеле. Алар арасында дөньякүләм үсеш дәрәҗәсенә ирешүе белән ювелирлык аерым урын били. Меңнәрчә билгесез осталар тудырган ювелир сәнгате әсәрләре халкыбызның талантын, аның югары иҗади мөмкинлекләрен, рухи эстетик идеалын чагылдыра, үзен көчле һәм өлгергән итеп таныта.

Бизәү сәнгатендә халыкның сәнгатьчә фикерләү рәвешен гәүдәләндерүче формалар күптөрле. Ул төсләр байлыгы белән дә, асылташ бизәкләренең үзенчәлекле системасы белән дә билгеләнә; якут, алмаз, тау бәллүре яисә фирәзә, сердолик, аметист, яшма кебек асылташларны алтыннан яки көмештән үрелгән бизәнү әйберләренә табигый урнаштыруда да чагылыш таба. Чокып бизәк ясалган көмеш эшләнмәнең өстен каралту, бизәк төшерү, әзер калып белән эшләү (басма), кыйммәтле металлар белән бизәү (каш утырту), асылташларны үю сәнгате, металлны эретеп, әйберләр кою шулай ук татар осталарының техник ысуллар хәзинәсенә кергән. Алтын-көмешче осталар арасында хезмәт бүленеше яшәгән: аларның кайберләре асылмалы бизәнү әйберләрен — муенса, алка, сөяктән ясалган бизәнү әйберләрен, кайберләре исә беләзек, кашлы йөзек, бөти савытлары һәм башка әйберләрне җитештергән. Бу — «ак эш» дип аталган. Асыл металлны пәрәвезләү, ягъни чыбыклардан утә нечкә итеп челтәр үрү серләренә ия булган ювелирлар төркеме алар арасында аерылып торган. Чөнки ул гаять катлаулы һәм бик күп көч куюны таләп итә. Әлеге ысул белән эшләгәндә алтын һәм көмеш чыбыклар бер яссылыктагы бизәк түгел, ә кабарынкы, бормалы-бормалы челтәрле бизәк сериясе тәшкил итә. һәм аларны шул кабарынкылык дәрәҗәсенә карап аералар да. Яка чылбырларында, беләзекләрдә, таңкаларда, күкрәкчәләрдә, Коръән савытларында әнә шул кабарынкылык алтын кебек җемелдәү хасил итә. Бу зиннәтләр, нигездә, Казанда эшләүче аеруча югары osталыкка ия ювелирлар тарафыннан гына иҗат ителгән.

Ювелирлык һөнәре татарлар яшәгән һәр җирдә дә киң таралу алган дип әйтергә була. Алар ялгыз яки зур булмаган артельләрдә эшләгәннәр. Татарстанның Арча, Саба, Лаеш, Мамадыш кебек төбәкләре һәм Казан шәһәре исә осталар аеруча күп тупланган үзәкләрдән саналган. Әлеге төбәкләрдә көмешче осталар сәнгате ювелирлык һөнәренең борынгы үзенчәлекле нигезендә үскән, алар ясаган әйберләрне кешеләр бигрәк тә яратып алган. Татар хатын-кызлары киемендә бизәнү әйберләре аерым урын били. Аларның күпчелеге милли киемнең үсешенә һәм мода юнәлешенә карап үзгәрә — барлыкка килә яки юкка чыга: бу, нигездә, сырга һәм муенсаларга, маңгай таңкаләренә (аларны шулай ук баш хаситәсе дип тә йөртәләр) һәм яка чылбырына, бил каптырмаларына, төймәләргә һәм башкаларга кагыла.

Бизәнү әйберләренең сәнгатьчел формалашу юлы бик катлаулы. Моны Болгар шәһәрлекләрен казыганда табылган күпсанлы хәзинәләрдәге алтын һәм көмеш зиннәтләр дә раслый. X—XV гасырлардагы болгар бизәнү әйберләреннән тыш, аз санлы булса да Казан ханлыгы чоры әсәрләре дә сакланып калган. Мәскәү Кремленең Корал палатасы тупланмасындагы данлыклы «Казан бүреге» (аның Казан осталары тарафыннан ясалган булуын сәнгать фәннәре докторы Ф. Х. Вәлиев нигезле итеп дәлилләде), СССР халыклары этнографиясе Дәүләт музееның татар коллекциясенә куелган алтын бил каптырмалары (күптән түгел Корал палатасы фондларында да шуңа охшаш каптырмалар табылды), зур күләмдәге көмеш төймәләр, уеп бизәкләнгән металл чүлмәк һәм башка әйберләрне шундыйлар исәбендә күрсәтергә мөмкин.

XVIII—XIX гасырларда яшәгән билгесез осталарның чын мәгънәсендә күренекле һәм киң таралган иҗат җимешләре күпчелек очракларда тамгаланмаганнар. Ләкин алар шулкадәр үзенчәлекле һәм индивидуаль: аларны тануы бик җиңел. Мәскәү, Ленинград, Казан, Уфа, Сарапул, чит илләрдәге кайбер музейларның тупланмаларында татар зиннәтләренең күпсанлы коллекцияләре саклана. Төп коллекцияләр Татарстанның Берләштерелгән дәүләт музее, СССР халыклары

этнографиясе Дәүләт музее, Татарстан сынлы сәнгать музее фондларында, аерым бизәнү әйберләре, гаилә ядкарьләре булып, халыкта да сакланып калган. Эш кораллары атадан улга, остадан остага, буыннан-буынга күчә килгән. Әмма бу шөгыль ирләр хезмәте генә түгел: аеруча нечкә, катлаулы бизәкләрне авылларда һәм Казанда — ювелир осталары яшәгән Татар бистәсендә эшләүче хатын-кызлар да иҗат иткән. Осталык серләрендә, һөнәр күнекмәләрендә, сәнгатьчел чишелешләрдәге традицияләр дә әнә шулай буыннан-буынга тапшырыла.

Матурлыкка һәм форма нечкәлегенә, металлның пластикасына мөнәсәбәт үзенчәлекле төстә татар ювелирлары иҗатында чагылыш тапкан. Асыл һәм ярымасыл ташларның төс балкышы белән тагын да тулыланып, алар милли һөнәрчелекнең кабатланмас үрнәген тудырганнар. Материал, бизәкләү рәвеше, асылташлар символик мәгънәне генә түгел, художество-эстетик карашларны да гәүдәләндерә. Тотрыклы сәнгать принциплары, милли эстетик карашлар ювелир әйберләрнең барлык комплексында: асылташлар куелган кыйммәтле зиннәтләрдә дә, күпләп җитештерелгән арзан бизәнү әйберләрендә дә чагылыш таба. Соңгылары, нигездә, саф көмештән түгел, ә көмеш катнашмасыннан ясалган һәм татарлар арасында гына түгел, күрше халыклар (руслар, чувашлар, башкортлар) арасында да, ерак өлкәләрдә — Урта Азиядә, Казахстанда киң таралу алган. Әлеге әйберләрнең бик үтемле булуы XIX гасыр азагында Казаннан ерак түгел Балык Бистәсе авылында ювелир һөнәрчелегенең чәчәк атуына китерә. Аның белән рус осталары шөгыльләнгән. Бизәкләрне исә татар осталарына охшатып ясаганнар. Алар алка, кашлы йөзек һәм бигрәк тә беләзекләрне күпләп эшләп чыгарганнар. Татар ювелирларының кыйммәтле зиннәтләре асылда югары катлау вәкилләренә исәпләнгән була һәм аларда мал-мөлкәтле заказчының зәвыгы чагылыш таба. Әмма XIX гасырның икенче яртысыннан ювелир әйберләрен фабрикада җитештерү нәтиҗәсендә конкуренция барлыкка килә, аның йогынтысы көчәя бара. Бу милли зиннәтләрнең сәнгать үзенчәлекләре арасындагы аерманы бетерүгә һәм XIX гасыр азагында — XX гасыр башында аларның милли киемнәр комплексына кергән (яка чылбыры, хәситә, каптырма, беләзек һ. б.) традицион төрләренең юкка чыгуына китерә. Шулай итеп XX гасыр башында моңа кадәр нык үсеш алган ювелирлык сәнгате халык тормышыннан юкка чыга. Казан артындагы аерым авылларда гына — Коллар, Мөндеш (Арча янында), Эзмә, Тенеки, Килдебәк, Шәмәрдән (Саба янында) авылларында гына аерым осталар заказ буенча бизәнү әйберләренең гади төрләрен: беләзек, алка, кашлы йөзек хәзерләүләрен дәвам иттерәләр.

Бүгенге шартларда традицион ювелир әйбер җитештерү бөтенләй тукталды. Борынгы һөнәрне үстерүче осталар юк диярлек. Саба районының Тенеки авылында яшәүче соңгы осталарыбыз Хәбибрахман Ганиев та сокланырлык гүзәллек үрнәге тудыру серләрен яшь буынга тапшыра алмады. Ә кешеләрдә гүзәллеккә, милли зиннәтләргә мохтаҗлык бай бит. Алар бүгенге стандарт киемгә кабатланмас ямь, үзенчәлек бирерләр, күңелләребездә матурлык тойгысын үстерерләр, милли үзенчәлеклелеккә омтылышны канәгатьләндерерләр иде.

Һөнәрнең үзен югалту белән бергә халыкның сәнгать, рухи тәҗрибәсен югалту да борчылу тудыра. Традицияләрне онытu котылгысыз рәвештә зәвыксызлык, ялган милли формаларның барлыкка килүенә китерә.

Замандашларыбыз һәм киләчәк буыннар хакына традицион ювелир сәнгатен ничек коткарырга, аны ничек яңадан тергезергә соң? Бу сорау татар культурасы белгечләрен һәм энтузиастларын гына түгел, киң җәмәгатьчелекне дә нык борчый. Безнең көннәрдә, алтыннан ясалган галантереяны меңнәрчә тираж белән чыгарган тулы бер «зәвыксызлык индустриясе» эшләгән чакта, халыкка сокландыргыч мирасны ничек тапшырырга?

Әлеге мәсьәлә иҗтимагый әһәмияткә ия. Ул социаль һәм экономик үсеш мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнгән. Хәзер, индивидуаль эшчәнлек турында закон кабул ителгәч, халыкның традицион сәнгатен үстерүгә юл ачылды кебек. Әмма бу мәсьәлә ялгыз кешеләр яки хәтта энтузиастлар төркеме белән дә хәл ителә алмый. Монда халык сәнгате язмышы өчен дәүләт җаваплылыгы кирәк.

Хәзергә ювелир сәнгате культурабызда билгесез хәлдә тора. Ювелирлык һөнәре Татарстан Җиңел промышленность министрлыгы карамагында. Үз вакытында ул халык сәнгате һөнәрләре комбинаты каршында ювелир әйберләр җитештерү цехы оештыру өчен зур тырышлык куйды. Моның өчен аңа рәхмәтлебез. Әмма цехка киеренке, артык зур план җиткерелде. Нәтиҗәдә, анда сәнгать дәрәҗәсе түбән, халык традицияләре белән бернинди уртаклыгы булмаган киң куллану товарлары гына чыгарыла башлады. Өстәвенә, алар үзләренең сатып алучыларын да таба алмыйлар. Һәр стандартның, штампның кул хезмәте нечкәлегеннән һәм осталыгыннан файдаланып кабатланмас формаларда иҗат итүче ювелирлык һөнәре өчен һәлакәтле булуы бәхәссез. Традицион ювелир һөнәрчелеген тергезү турындагы мәсьәлә Җирле промышленность министрлыгы предприятиеләре рамкаларында гына куелырга тиеш түгел. Чөнки сәнгатьнең сыйфаты, эстетик юнәлеше — халык сәнгатенең теләсә нинди төрендәге кебек үк — ювелирлар эшчәнлегендә дә иң алда тора, ул төрле күрсәткечләр артыннан куучы шушы министрлык компетенциясе була алмый. Традицион халык сәнгате, халыкның иҗади-нәфис һөнәр-

ләре белән шөгыльләнергә тиешле культура учреждениеләре — Культура министрлыгы, Художниклар союзы бер читтә калды. Ә бит алар КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советының «Халыкның сәнгать һөнәрләре турында»гы карарында әйтелгәнчә, законлы урын алырга тиешләр иде. Димәк, бу — барыннан да элек, оештыру мәсьәләсе. Һәм, әйтергә кирәк, бик кискен мәсьәлә! Хәзер милли зиннәтләр хәзерли торган материал — көмеш — юк. Дөрес, аны алыштырырлык яңа материалларның ювелир үзенчәлекләрен өйрәнү дәвам итә. Профессиональ ювелирлар төрле эзләнүләр алып баралар. Ләкин алар республикада санаулы гына һәм аларга ярдәм кулы сузучылар, эш шартлары тудырырга ашыгучылар юк.

Инде югалып бетә язган һөнәрне тергезү — гаять катлаулы эш. Әмма традицияләрне үстерү зарури. Ювелирлык һөнәренең халкыбызга хас алымнары, милли зиннәтләрнең сәнгатьчел формалары нигезендә, онытылган һөнәрне яңадан күтәреп алырга һәм бүгенге яңа сәнгатьне тудырырга кирәк. Югары осталыкка бары тик халык традицияләре нигезендә генә ирешергә мөмкин.

Моның өчен нинди юллар бар соң? Безнең карашка, алар түбәндәгеләр:

1. Бәлкем, барыннан да элек, традицион халык сәнгате һәм сәнгать һөнәрләре практикасы турында җитди фикер алышырга кирәктер. Бу чарага кызыксынучы барлык оешмаларны (Художниклар союзын, Культура министрлыгын, Җирле промышленность министрлыгын, Тел, әдәбият һәм тарих институтын, Сынлы сәнгать музеен, Республика халык иҗаты йортын, Берләштерелгән дәүләт музеен) җәлеп итәргә кирәк.

2. Татарстан Художниклар союзы каршында халык сәнгате комиссиясе оештырырга. Билгеле булганча, СССР Художниклар союзының республикалардагы һәрбер оешмасы каршында халык сәнгате буенча комиссия эшли. Ә Татарстанда, билгесез сәбәпләр аркасында, ул төзелмәгән. Халык осталарын (традицион халык иҗатыннан ерак торган үзешчән рәссамнарны яки осталарны түгел, нәкъ менә халык осталарын) исәпкә алу, халык иҗаты үчакларын барлау һәм саклау эшен нәкъ шушы комиссия алып барырга тиеш.

3. Халык осталарын юридик һәм матери-аль яктан тәэмин итәргә. Аларны Татарстан Художниклар Союзының Художество фонды системасына кертергә. Халык осталарын үз әйберләрен сатудан азат итәргә.

4. Художество фонды каршында ювелир остаханәсе оештырырга. Ул профессиональ осталарны берләштерергә һәм аларның эшен милли традицияләр нигезендә үстерүгә ярдәм итәр иде.

5. Халык сәнгате һөнәрләре комбинаты каршындагы ювелир цехын үзгәртеп корырга. Аның эшчәнлеген әйберләрне ювелир сәнгатенең күптәнге милли традицияләре нигезендә аз серия белән эшләп чыгаруга юнәлдерергә.

6. Татар ювелир сәнгатен фәнни консультацияләр һәм иҗади тәкъдимнәр белән тәэмин итәргә (Тел, әдәбият һәм тарих институты).

7. Бүгенге сәнгать һөнәрләре, һәм өлешчә, ювелир сәнгате мәсьәләләре буенча фәнни-тикшеренү һәм методик эш турындагы мәсьәләне куярга (Тел, әдәбият һәм тарих институты, Сынлы сәнгать музее).

8. Рәссам-белгечләр, сәнгать һөнәрләре осталары, шул исәптән ювелирлар хәзерләү буенча кичектергесез чараларны тормышка ашырырга.

Татар ювелир сәнгатенең язмышы халык сәнгате язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Борынгы һөнәрне тергезү өчен киң җәмәгатьчелек чаралары һәм дәүләт оешмаларының ярдәм тырышлыгы безнең көннәрдә аеруча мөһим. Уникаль традицияләрнең исән калган соңгы бөртекләре дә юкка чыкмасын иде. Халыкның борынгы һәм шул ук вакытта мәңге яшь традицион сәнгате өметле шытымнар бирергә тиеш.

**Гүзәл СӨЛӘЙМАНОВА-ВӘЛИЕВА,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

# СӘЙДӘШЕВ НИЧЕК ЯЗГАН?

Замандашлары сөйләвенчә, Салих Сәйдәшев гел сызгырып-көйләп йөргән. Теге яки бу әсәрне язу өчен аңа кайчак тышкы бер этәргеч кенә кирәк була. Х. Фәтхуллинның «Күзләр» пьесасын укып чыккач, композиторның ничек тәэсирләнүен режиссер К. Тумашева болай искә ала: «Ул зур игътибар белән тыңлады. Укып бетергәч тә урыныннан кузгалмады. Озак кына тын утыргач, без: «Я, ничек?» — дип сорадык. «Мин бу пьесага музыка язам, анда көчле, пакь йөрәкле, киләчәккә оптимизм белән караучы, өметле кешеләр бар. Шундый образлар булган пьесага музыка язарга яратам мин. Бу образлар минем күңелемә үтеп керде», — диде ул һәм урыныннан торды. Мин: «Салих, тукта әле, тагын бераз сөйләшергә кирәк, бер-беребезне аңларга кирәк», — дидем. Ул: «Мин барын да аңладым, көйне язып китерәм дә, шунда сөйләшербез», — дип, тын гына саубуллашып чыгып китте» («Соц. Татарстан», 1970 ел, 3 декабрь саны).

Күп замандашлары композиторның теге яки бу көйне чыгаруын үз күзләре белән күреп торганнар. «Совет Армиясе маршы» белән дә шулай була. С. Сәйдәшев янына хәрбиләр исеменнән марш язуны сорап килгән журналист И. Усманов болай дип искә ала: «Төшке аштан соң тәмәке тартып җибәрдек.

— Салих, синең кайчан да булса марш язганың булдымы?

— Юк... Хәер, дөрес әйтмим бугай. Оренбургта музыка мәктәбендә эшләгәндә омтылып караган идем. Ә нигә син бу турыда сорыйсың әле?

Әнә шулай башланып китте безнең сөйләшү. Хәрбиләрнең үтенечен әйткәннән соң:

— Булдыра алмам дип уйлыйм, — диде ул. — Мин лирик бит. Маршта исә күңел нечкәлеген бирү кыен, ул дәртле, күтәренке рухлы булырга тиеш.

Бәхәс купты. Салих урыннан торып, пианино янына килде, аның өстендә яткан папкадан актарып, кечкенә генә нота кәгазе тартып чыгарды. Пианино янына утырып, бармакларын кызу гына клавишлар өстеннән йөгертеп алды да, кайчандыр шул кәгазьгә төшергән фразаларын әкрен генә һәм салмак кына итеп уйнап җибәрде. Бу маршка охшаганрак әсәр иде.

— Юк, марш түгел бу, — дип куйды ул соңыннан.

Без аны-моны сөйләшеп, чәй эчтек, әмма нишләптер әңгәмә ябышмады. Салихның тәрәзәләре артында бакча күренә иде. Менә ул тәрәзә янына килеп басты, кар белән бизәлгән агачларга караган хәлдә, борын астыннан гына нидер көйли башлады.

Шуннан кинәт борылып, пианино янына килеп утырды.

Кашларын җыерып, иреннәрен түгәрәкләп куйганнан соң, азрак кына артка каерылып уйнап ук җибәрде. Күңеле илһамланып, башында яңа көй туган вакытларында ул һаман шулай итә торган иде.

Менә кульминация ноктасы... Аз гына кайгылы, әмма шул ук вакытта кырыс һәм күтәренке трио яңгырый. Кыллар гүли... Литавра һәм труба тавышлары ишетелә, менә безнең Кызыл Армиябез атлый. Салих тәмамлады, бармакларын клавишлардан алмыйча, миңа таба борылды да елмаеп:

— Йә, ошадымы? — дип сорады һәм тиз генә, борын астыннан көйли-көйли, нота билгеләрен кәгазенә төшерә башлады.

— Ә менә оркестрлаштырырга вакытым калмады. Әйдә, соңга калабыз!

Ул репетициягә ашыга иде».

Күп замандашлары Сәйдәшевнең, артист Н. Сакаев вафат булгач, бер төн эчендә язган матәм маршын хәтерлиләр. Иртән аны мәрхүмнең баш очында (җеназасы өстендә) оркестр уйный. М. Мозаффаров хаклы: «Салихны «көйләр чишмәсе» дип атыйсы килә. Читтән караганда, аңа, әйтерсең, көй чыгару белән түгел, ә аларны язып өлгерү белән шөгыльләнергә кирәк иде».

Чыннан да, Сәйдәшев театр спектакльләренә музыканы тиз яза. К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» мелодрамасына һәм «Кандыр буе» пьесасына көй 20 көндә языла. Күп катнашучылары булган спектакльгә Сәйдәшев башта эскизлар, фрагментлар ясап чыга. «Кандыр буе» пьесасына көй язганда да ул фрагментлар уйный һәм: «Болар әле фрагментлар, эскизлар гына, эшләнеп, төгәлләнеп беткәч, бик яхшы булачак, колхоз авылының яңа тормыш пафосын чагылдырган, яңа интонацияле музыка», — ди. Музыкаль образлар үз аңында формалашкач, Сәйдәшевкә шуларны кәгазьгә күчерергә генә кирәк була. Риза Ишморат «Кандыр буе» пьесасына музыка язуда бу этапны болай тасвирлый: «Ике көннән соң иде, ахры, эшнең ничек баруы турында белешү нияте белән оркестр бүлмәсенә төштем. Оркестрчыларның кайсы пианинода уйный, кайсы скрипкада, кайсыдыр виолончель көйли. Үзара сөйләшү, шау-шу. Ә Сәйдәш

озын, зур өстәлгә нота кәгазьләрен таратып ташлаган да, бик бирелеп, дөньясын онытып, нидер яза. Композиторның алдында ниндидер музыка коралы булырга тиеш кебек иде миңа. Ә ул әнә һичбер инструментсыз иҗат итә. Тик ара-тирә бармаклары белән өстәлгә бәреп тукылдатып ала.

Ниһаять, башын күтәрде Сәйдәш. Мине күрде. Исәнләштек.

— Сиңа, мөгаен, комачаулый торганнардыр, әллә музыкант дусларыңның кайтып китүләрен үтеникме? — дим Сәйдәшкә.

— Юк, юк, кирәкми, аларның шау-шулары миңа ярдәм генә итә. Язганда мин бары үз эчемдәге тавышымны гына, үз моңымны гына ишетәм, — ди ул. — Теләсәм, мин өйдә дә яза алам. Бөтенләй тыныч анда, бераү дә юк... Пианино да бар. Ләкин миңа шау-шу арасында язу яхшырак, җиңелрәк. Һәрхәлдә күп кенә очракта шулай, — ди». Әшенең бу этабында Сәйдәш өчен әсәрнең көе-гармониясе генә түгел, бөтен оркестрлаштыруы ачык була. Якын дуслары М. Мозаффаров һәм Җ. Фәйзи әйткәнчә, оркестр өчен эшләгәндә ул еш кына партитураны язмый, партитура аның күңелендә саклана, һәм ул әсәрне ноталарсыз гына дирижерлык итә. Бу очракта Моцарт искә төшә: ул икенче скрипка партиясен яттан гына, тамашачылар шикләнмәсен өчен, пюпитрга чиста кәгазь куеп уйный торган була. Бу сыйфат композиторның музыканы аңлау сәләте аеруча югары булуын күрсәтә.

Сәйдәш кайвакыт иҗат кыенлыклары да кичергән. Ул К. Тинчуринның «Кандыр буе»ннан Гөләндәм һәм Т. Гыйззәтнең «Наемщик» драмасыннан Гөлйөзем арияләрен кыенлык белән яза. Ләкин соңрак, башкаручы белән сөйләшкәндә үк ул дөрес интонацияне тотып ала һәм арияне төгәлли. Бу рольләрне башкарган Г. Кайбицкая болай дип искә ала: «Ничектер Салих мине туктатты да, елмаеп кына: «Галия, син җырлый торган Гөләндәм ариясенең ахыры юк бит, язылып бетмәгән, язып бетерәсе бар», — диде. Мин аның сүзләренә каршы килеп: «Ярар, ярар, ярты-йорты икәнен кем дә белмәс, менә дигән итеп җырлармын, өйрәнергә вакыт калмады», — дип көлеп җавап бирдем. Ул һаман елмайган килеш миңа бераз текәлеп карап торды да: «Әйдә әле, Галия, хәзер арияңне тәмамлап бирәм, ахырын таптым», — диде һәм йөгерә-атлый үз бүлмәсенә кереп китте. Артыннан керсәм, ул инде пианино янында, аккордлар биреп, ариянең ахырын уйнап утыра. Һәм иң гаҗәбе шул: җырның ахырында кычкырып көлгән тавыш — минем тавыш (!) ишетелә иде. Янына килү белән: «Мә, җырлап кара инде хәзер, тулыландымы?» — дип, арияне баштан ук җырларга кушты. Мин әле генә язылган музыкада, үз көлүемне дә тойган хәлдә, Гөләндәм ариясен көлә-көлә җырлап бирдем. Ул шундый җиңел башкарылып, бөтен булып килеп чыкты. Сәйдәшнең йөзе яктырып китте: «Рәхмәт, Галия! Җыр бу, ахыры да, башы да булды хәзер. Бар, Тинчуринга җырлап күрсәт инде», — диде. Җырны режиссер Кәрим абый Тинчурин да хуплап каршы алды.

1928 ел. Атаклы драматургыбыз Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик» музыкаль драмасындагы Гөлйөзем образын икенче вариантта әзерлибез. Беркөн шулай эш кинәт туктап калды. Шаулап репетиция барган чагында, режиссер Вәлиев-Сульва миңа карап: «Кайда музыка?» — диде. Гөлйөзем, үзенең ариясен җырлап бетергәч, биеп китәргә тиеш, имеш. Сәйдәшкә бию өчен дә музыка язарга кушкан булганнар. Ул хәтереннән чыгарган, күрәсең. Салихка күзем төшеп, аның аптыраган кыяфәтеннән көлеп җибәрдем. Ул уйчан, үзен гаять уңайсыз сизә иде сыман. Шуннан мин, аның күңелен күтәрим әле дип, шаян тавыш белән: «И матур син, егеткәй, бу көеңнең ахыры юк бит, егеткәй!» — дип, үземчә такмаклап куйдым. Янә: «Дәвамын да тизрәк тапчы, егеткәй!» — дип биеп тә алдым. Салих миңа карап елмайды, аның күзләре очкынланып китте. Таҗи Гыйззәт белән карашып алды да, урыныннан сикереп торып: «Хафаланмагыз, хәзер ариянең ахырын язам. Әйдә әле, Галия, шул сүзләреңне кабатлый-кабатлый төш», — диде. Үзе рояль каршына килеп утырып, нидер уйный башлады. Мин: «И матур син», — дип, төрле сүзләр әйтә-әйтә, тагын биеп киттем. Режиссер Вәлиев-Сульва да, артистлар да көлешеп карап тордылар. Шул арада Сәйдәш белән Таҗи Гыйззәт, минем әйткән сүзләремнең дә кайберләрен файдаланып, Гөлйөзем ариясен тәмамлап та бирделәр».

Бервакыт Сәйдәш «Күзләр» пьесасының авторы Х. Фәтхуллинга: «Менә репетицияләрдә утырам һәм елыйм, тыела алмыйча елыйм. Бу җырларны, театрдагы кайберәүләр уйлаганча, бер төндә язганмын дип беләсеңдер инде син. Юк, мин аларны күп көннәр буена яздым, никадәр язылган вариантларны юк иттем. («Соц. Татарстан», 1975 ел, 4 декабрь саны).

Тулаем алганда, С. Сәйдәшев тиз һәм җиңел иҗат иткән. Г. Кайбицкаяга: «Көйләрем үзләреннән-үзләре килеп торалар», — дигән ул. Сәйдәшев театрда драматурглар, режиссерлар, артистлар белән тыгыз элемтәдә торып эшли. Әсәрләрен ул драма артистларының башкару үзенчәлекләренә карап яза торган була. Иҗат процессында исә башкаручылар белән киңәшә. «Зәңгәр шәл» драмасында югары вокаль сәләте булмаган

К. Тинчурин өчен язылган Булат җырының беренче варианты ул кадәр үк көйле-аһәңле булмый. Соңрак Сәйдәш аның көен үзгәртә һәм ул җыр хәзергәчә яңгырый башлый.

Сәйдәш — лирик пландагы композитор. Дуслары белән сөйләшкәндә, моны ул үзе дә әйтә торган була. Улының истәлекләренә караганда, ул Чайковскийның «Евгений Онегин»ын, Бизеның «Кармен»ын яраткан, фортепианода Ф. Шопенның Җиденче вальсын, татар халкының «Сарман» һәм «Шөгер» көйләрен яратып башкарган. Замандашлары аның драматик музыка иҗат итәргә яратмаганын искә алалар. Режиссер Ш. Сарымсаков болай дип яза: «Спектакльгә (сүз Т. Гыйззәтнең «Изге аманәт» драмасы турында бара) якыннарын югалткан яшь кыз өчен ике-өч вокаль номер кирәк иде. Сәйдәшев тиз арада аларны язды, ләкин җыр, әйбәт булса да, драматик образга туры килми иде. Ничек кенә үгетләп карасак та, башка характердагы җыр язарга композиторны күндерә алмадык. Композиторның лирик планда отып алган көе үзгәрешсез калды».

Шундый лирик сәләте композиторның өстенлеге иде, ул аның иң гүзәл көйләре чыганагы булды. Замандашлары әйткәнчә, Сәйдәш музыкасы бөтен җирдә — өйдә дә, урамда да яңгыраган. Театрга бары аның тылсымлы көйләрен ятлау өчен генә йөрүчеләр күп булган. Үзенең көйләре белән Сәйдәш легендар шәхескә әйләнә.

С. Сәйдәшев бай иҗади хыял кешесе була. Ул инструментта импровизация ясап утырырга бик ярата. Кайвакыт ул сүзләр кирәк булган урыннарны да импровизация белән аңлата торган була. Урта гасырларда үсеш алган бу импровизация сәнгате, вакытлар үтү белән, юкка чыга барды. Л. В. Бетховен иң оста импровизатор булган дигән фикер яши. Импровизациянең психологик табигате әлегә кадәр өйрәнелмәгән, ләкин аның нигезендә иҗади хыял, иҗади фантастик очыш ятуы бәхәссез. С. Сәйдәшев, «уйнала торган әсәр яхшырак аңлашылсын өчен, музыка яңгырашына бәйләп, төрле хикәяләр уйлап чыгара иде», — дип искә ала аның улы. Мәсәлән, «Шәрык биюе»н яки «Титаник» маршын башкарганда ул Көнчыгыш халыкларының тормышкөнкүрешен сурәтләп бирә торган була. Күп замандашлары аның оста хикәяче һәм үткен телле булуын сөйлиләр. Үзенең кабатланмас юморы белән ул тыңлаучыларны еш көлдерә. Бу мисаллар Сәйдәшнең бай натурасын күрсәтә, аның музыкада гына түгел, нәфис сүздә дә иҗади фантазияле һәм сәләтле булуын раслый.

Сәйдәш иҗатында төрле милли культуралар матур үрелеп тә яши ала. Бу «Сүнгән йолдызлар» әсәрендә һәм кырым көйләре күп булган «Нәнкҗан»да (Г. Кутуй) ачык күренә. Т. Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт» әсәрендә дә албан халык көйләре бар.

Төрле милләт көйләре белән кызыксыну С. Сәйдәшевтә үсмер чактан ук килә. Аның 1921 елда үткәрелгән концерт-турнесы үзбәк музыкасына мәхәббәт белән сугарылган була. Сәйдәш казах җырларын, Э. Гранадосның испан биюен тыңларга ярата иде, дип искә ала пианистка Ф. Фәйзи.

С. Сәйдәшев профессиональ белем алмыйча гына атаклы композитор булып китә. Мәскәү консерваториясе студиясендә үткән дүрт елы аңа берни дә бирмәде диярлек, ул консерватория бетергәнлеккә диплом да алмады, дип искә ала аның педагогы профессор Г. И. Литинский. Бу парадоксны ничек аңлатырга? Юк, эш аның гамьсезлегендә түгел. Эш шунда: студиягә ул 1934 елда — инде композитор булып җитешкәч, карашлары формалашкач килә.

Шуңа күрә, укыганда аңлашылмаучылыклар килеп чыга. Мәскәү консерваториясенә баргач, педагогы Г. И. Литинский Сәйдәшкә студиягә кадәр иҗат иткәннәрен онытырга куша. Яшь профессорның бу тәкъдиме Сәйдәшне аптырашка калдыра, чөнки бу хәл композиторның «мин»ен үтерү белән бер бит!

Үз халкының милли культурасында тәрбияләнгән С. Сәйдәшевкә консерваториядәге гармония, полифония, инструментовка кебек теоретик дисциплиналар һәм гомумевропа культурасының интонацион табигате өчләтә ят була. Бу предметларда композитор, күрәсең, үзе кабул итеп алмаган схоластика күргән. Бу уңайдан Г. И. Литинский болай дип яза: «Бу вакыт Сәйдәшевтә әлеге дисциплиналарга кызыксыну артмады, хәтта анда эчке протест кабына иде». Тагын бер урында: Салихның композиторда булырга тиешле иң мөһим башка дисциплиналарга да (көй язудан башка — Р. И.) битарафлыгын яза.

Шулай да С. Сәйдәшев үзен камилләштерү өчен күп эшләгән. Замандашлары аның «Евгений Онегин» операсы (П. И. Чайковский) партитураларын ныклап өйрәнгәнен сөйлиләр. «Евгений Онегин» операсының клавирын изге әйбер итеп күтәреп йөрде. Оркестр өчен пьесаларга керешләр язганда, ул классикларның увертюраларын өйрәнә, аларны күп тапкыр уйнап карый, аларга форма, төзелеш, көчеш эзли иде», — дип яза оркестрның артисты А. Друтин. Улы Альфред Сәйдәшев болай дип искә ала: «Әтием Чайковский операларын һәм Бизеның «Кармен»ын бик ярата иде. Мин аның берничә мәртәбә шушы спектакльләр барган чагында театрда кулына шул операларның парти-

туралерын тоткан хәлдә 4-5 нче рәтләрдә утырганын күргәләдем. Утырыр, тыңлар, чыгып китәр, аннан тагын кереп тыңлар иде. Ул операның кайбер өлешләрен бик җентекләп өйрәнә иде, ахрысы». С. Сәйдәшевнең төп композиторлык мәктәбе аның практик эше була. Бу планда караганда, В. И. Виноградовның «Татар музыкасы һәм композитор С. Сәйдәшев» дигән мәкаләсе кызыклы («Совет әдәбияты», 1933 ел 11-12 саннар.) Сәйдәшнең композитор булып үсүендә Буа шәһәрендәге хор белән җитәкчелек итүен, Кызыл Армиядә үзешчән сәнгать, драматик театрда эшенең йогынтысын күрсәтә автор. Композиторлык эшчәнлегенең башында Сәйдәш бары музыка теориясе һәм гармония әлифбасы белән генә таныш булган. Үзенең автобиографиясендә дә ул композиторлык юлының Оренбургтагы Көнчыгыш музыка мәктәбендә җитәкче һәм дирижер булып эшләгәндә башланганын әйтә. «Композитор буларак беренче адымнарны нәкъ менә шушында башладым», ди ул. Хәйбулкинның татар җырларын һәм маршларын, З. Яруллинның «Тукай» маршын оркестрлаштырганда ул дирижерлык белемнәрен дә арттыра. Бу чорда ул «Озын сәфәр» һәм «Ай җилләр, җилләр» җырларын язып, композиторлыкка атлый. В. И. Виноградов билгеләп үткәнчә, Сәйдәшнең иҗади үсүенә композиторлык белемнәре түгел, ә аның практик эшен киң җәелдерүе зур йогынты ясаган. Шулай итеп, тулы булмаган белем Сәйдәшне кайбер кыенлыклар алдына бастыра, ләкин зур сәләте белән ул аларны җиңә бара. Җ. Фәйзи аның «Сүнгән йолдызлар» пьесасына увертюра язуы турында болай ди:

«Сүнгән йолдызлар» спектакле премьерасы алдыннан К. Тинчурин Сәйдәшевкә увертюра язарга кушты. Бу көтелмәгән «режиссер капризы» Салихны каушатып җибәрде.

— Нәрсә белән ашыйлар соң ул увертюраны?

— Белмим дип әйтмә. Ул спектакльгә кереш була һәм әсәрнең настроениесен бирергә, аның эчтәлеген ачарга тиеш.

— Ә аны ничек ачалар?

Сәйдәшнең гадилеген белгән Тинчурин да аптырап калды. Чыннан да, увертюраның ни икәнен белмиме ул дип шикләнә калды ул.

— Син «Кармен»га увертюраны ишеткәнең бармы?

— Бик яхшы беләм. Тик мин Бизе түгел бит.

— «Руслан һәм Людмила»га увертюраны беләсең, билгеле.

— Белсәм дә, миндә Глинка таланты да юк.

— Әгәр алай карасаң, синдә Сәйдәш таланты бар. Кирәк икән, язарга!

— Ничек языйм мин аны?

— Син кишер, суган, кыяр, помидор яратасыңмы?

— Яратам...

— Менә шуларга үсемлек мае саласың да, матур музыка язасың. Менә шул «Сүнгән йолдыз»га кереш була инде.

— Димәк, увертюра — төрле музыкадан ясалган «винегрет» була инде, — диде Салих елмаеп.

Инде кайнарланган Тинчурин: «Шайтан булсын, увертюрасыз премьера булмаячак», — дип, тиз генә Сәйдәш янынннан китеп барды. (Җ. Фәйзи. Истә калганнардан. «Азат хатын», 1970 ел, 10 сан).

Профессиональ музыка формаларына композитор шулай иялэнә. «Зәңгәр шәл» пьесасында, В. И. Виноградов уйлавынча, Сәйдәшев үзенең техник арсеналын кереш тон, секвенцияләр, модуляцияләр белән баетып, халык җырлары рамкаларын гына киңәйтеп, сюжетның музыка белән органик бәйләнешенә ирешә. Шулай итеп, композитор музыкаль материал арсеналы үсешен киңәйтә һәм баета, яңа музыкаль формалар иҗат итү өчен зур мөмкинлекләр ача. С. Сәйдәшев халык җырларын тагын да тирәнәйтә һәм ритмик яктан баета. Шулай итеп, без практиканың С. Сәйдәшевкә композиторлык мәктәбе булып хезмәт иткәнен күрәбез. Асылда ул — тумыштан зур талантка ия булган һәм үз хезмәте, үз тәҗрибәсе белән үскән композитор. Революциягә кадәрге көнкүрештәге консерватив шартлар, татарларда профессиональ музыка мәктәбе булмау Сәйдәшнең талантын тагын да тулырак ача алмауга сәбәп иде. Ләкин зур сәләте һәм һәрвакыт мөстәкыйль эшләве Сәйдәшевне профессиональ композитор итә, аны татар музыкасының пионеры итә.

Бу елларда Бөек Октябрь вакыйгалары китереп чыгарган яңа совет халык җырлары тынып тормый. Гражданнар сугышы утларында актив ритм-интонацияле һәм зур революцион пафослы «Марш элгәре», «Көрәш җыры» кебек татар халкының яңа җырлары туа. Болар барсы да С. Сәйдәшевне яңача интонацияле музыка язуга этәрми калмый, билгеле.

Шулай, заман байрагы итеп, С. Сәйдәшев милли музыканы тагын бер баскычка югары күтәрә. Әнә шулай ул үз халкының зур җырчысы булып кала.

**Р. ИСХАКОВА-ВАМБА,**
музыка белгече.



# *Татар халык музыка уен кораллары*

## КУРАЙ

Ата-бабаларыбыз музыка уен коралларын табигатьнең үзеннән алганнар. Әйтик, каз каурыен кыеклап кисеп сыбызгы ясау, җәяне чиертеп музыкаль тавыш чыгару, урманда үсә торган кура үләнен кисеп алып бернинди тишем тишмичә өреп уйнау алар өчен гадәти хәл булган. Заманалар узу белән әлеге уен кораллары камилләшкәннәр, шул җирлектә яңалары барлыкка килгән. Шундый уен коралларының берсе — татар курае.

XIV—XV йөзләргә караган Болгар кабер ташларында җыр, табышмак, әйтемнәрдә курайлар турында бихисап мәртәбәләр искә алына. Курай ясау халык авыз иҗаты әсәрләрендә менә болай тасвирлана:


*Аягын-башын кистем,*
*корсагын тиштем,*
*эченә өрдем,*
*моңайганын күрдем.*

1768-1769 елларда танылган рус галиме И. И. Лепехин Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче халыкларның музыка уен коралларын тасвирлаганда татарларның «курай» дип аталган музыка уен коралында яратып уйнаулары хакында әйтеп китә.

Курадан курай ясау халык арасында бүгенге көнгә кадәр сакланып калган. Мәсәлән, Татарстанның Азнакай районы Туйкә авылында яшәүче Зөфәр ага Камалов, Актаныш районы Иске Сәфәр авылыннан Нәҗибә апа Солтанова курайны үзләре ясыйлар, бик матур итеп уйныйлар да.

Курай — кура (көпшә үсемлек исеме) сүзенә ай кушымчасы ялгану юлы белән килеп чыккан. Курай үсемлеге Татарстан урманнарында да күпләп үсә. Аны август, сентябрь айларында, кибеп көрән төскә кергәч, җыеп алалар һәм кояш төшми торган коры урында киптерәләр.

Ике тишемле курайларны ясау өчен 60-70 см озынлыкта кура сабагы алына. Конуссыман формадагы көпшәнең бер очының диаметры 10-12 мм, икенче очыныкы 17-19 мм булырга тиеш. Көпшәнең юан башын — 40-45° кыеклап кисәләр. Озын, өске ягына, нәкъ 10 мм ара калдырып, 6 × 7 мм зурлыкта шакмаклап тавыш тәрәзәсе ясыйлар. Нәзек очыннан кул учы белән берәр тотам ара калдырып, өске ягына ике тишем тишелә.





Ике тишемле курайда тавыш чыгару өчен әзер тавыш сыбызгысы юк. Аның өчен тавыш тәрәзәсенә көпшәнең эчке ягыннан телне куеп сыбызгы ясыйлар һәм шуңа өреп тавыш чыгаралар.

Көпшәгә дөрес өрү аеруча әһәмиятле, чөнки бер үк тишемнән ике, өч югарылыктагы тавышлар чыга. Элек курайларны билгеле бер тавыш югарылыгына көйләп тормаганнар. Шуңа күрә ноталарның урнашу тәртибе тональностька карап үзгәргән.


Хәзерге вакытта тел курайларын билгеле бер тавыш югарылыгына көйләп эшлиләр. Аның өчен көпшәне азрак озынрак алырга, тавыш тәрәзәсен ясарга һәм көпшәнең нәзек очын кыскартып көйләргә кирәк. Кирәкле тавышны тапкач кына тишемнәр тишелә.

Ике тишемле курайда халык көйләренең һәммәсен дә уйнап булмый. Уйнау мөмкинлекләре чикләнгән. Шуңа күрә дә халык курайны камилләштергән. Курайның камилләшү процессы ике юнәлештә барган. Беренчедән тишемнәр саны артса, икенчедән курай ясау өчен тагын да чыдамрак материаллар (агач, шпон, металл, пластмасс) куллана башлаганнар. Шулай итеп биш тишемле тел курае, алты тишемле җиз курай һәм җиде тишемле сыбызгы курайлар барлыкка килгән.

Биш тишемле курай тавышының моңлы, ягымлы булуы белән күңелгә аеруча якын. Уйнау мөмкинлекләре дә ике тишемле курайга караганда зуррак. Аны кура сабагыннан, агачтан эшләнелгән шпоннан яисә металл көпшәдән ясыйлар. Тавыш тәрәзәсе нәкъ ике тишемле курайдагы кебек. Түбәндә биш тишемле тел кураеның рәсеме һәм үлчәмнәре бирелә:




Әгәр дә размерлары төгәл үлчәнелеп эшләнсә, до мажор тональностендагы курай килеп чыгар. До мажор кураеның диапазоны һәм ноталарның урнашу тәртибе:




Тишемнәрне бармаклар белән каплау түбәндәге тәртиптә башкарыла. Сул кулның баш бармагы (без аны 1 саны белән билгелик) аскы тишемне каплый, сул кулның имән бармагы (2) өске яктан беренче тишемне, атсыз бармак (3) өстән икенче тишемне каплый, сул кулның урта бармагы курайны тотып тора. Уң кулның имән бармагы (4) өстән өченче тишемне, атсыз бармак (5) өстән дүртенче тишемне каплый. Уң кулның баш һәм урта бармаклары курайны тотып тора.

Бу курайларда халкыбызның озын көйләре матур яңгырый. Мәсәлән, «Салкын чишмә», «Озату», «Зиләйлүк», «Порт-Артур», «Кондырак болыннары» һ. б.

Курайлар ике төрле булалар. Беренчесе югарыда сөйләнелгән тел курайлар һәм әзер тавыш сыбызгысы булган җиде тишемле курайлар. Әлеге курайлар тел курайларының тагын да камилләштерелгән бер төре. Тавыш сыбызгысы курайга беренче тапкыр кайчан һәм ничек куелуы билгесез. 1983 елда Апас районыннан Әсрар ага Һидиятов агачны яндырып тишеп эшләнелгән курайда уйнап Казан телевидениесеннән чыгыш ясады. Әлеге курайның әзер тавыш сыбызгысы һәм ике генә тишеме бар. Аның мәгълүматларына караганда бу курайга ике йөз еллар чамасы.

XIX йөзнең азагы — XX йөзнең беренче яртысында алты тишемле җиз калайдан эшләнелгән курайлар киң тарала. Ә инде соңгы елларда җиде тишемле курайлар зур урын алды. Җиде тишемле курайларны эшләү һәм аны пропагандалау өлкәсендә уен кораллары ясау остасы, үзешчән композитор Ифрат Хисамовның хезмәте аеруча зур. 1983 елда Татарстан китап нәшрияты Ифрат Хисамовның җиде тишемле курай ясау һәм аңарда уйнарга өйрәнү өчен кулланма китабын бастырып чыгарды. Түбәндә «ре» мажор кураеның үлчәмнәре бирелә. Ул И. Хисамовның «Курайда уйнарга өйрән» исемле китабыннан алынды.


Курай ике өлештән тора. Сыбызгы өлеше һәм көпшә өлеше. Ясау өчен 220 мм озынлыктагы, эчке диаметры 10-12 мм лы дюралюминий яки пластмасс көпшә алына. (Агачтан да ясарга мөмкин.) Көпшәнең «А» башыннан «В»га таба 18 мм ара калдырып 5 миллиметрлы борау белән бер яктан гына тишәбез. Бу түгәрәк тишемне нәзек игәү белән як-яктан иги-иги 6 × 6 мм лы дүрткел тишемгә әйләндерәбез. Бу тавыш тәрәзәсе була.

Шушы тәрәзәнең А — В ягына 6 мм калынлыктагы яссы игәү яки тимер куеп, чүкеч белән сугып, 1 мм га батырабыз. Шуннан аны өстән аска игәүләп үткенлибез. Ләкин артык игәп шакмак үзгәрә күрмәсен. Эбонит яки плексиглас шикелле материал-

дан көпшәнең «А» башы эченә тыгыз сыешлы итеп, 15 мм озынлыкта бөке эшлибез. Шуннан соң, бөкенең бер ягын 2 мм игәп, һава юлы ясарга кирәк.

Әлеге бөкене көпшәнең «а» башына кагып кертәбез һәм акрын гына өргәндә икенче октаваның «ре» тавышы чыгарга тиеш. Әгәр тавыш зәгыйфь чыкса, һава юлының дөрес торышына, аның горизонталь булуына игътибар итәргә кирәк.

Тавыш тәрәзәсенең нәкъ каршы ягына, сызык сызарга һәм тишем урыннары билгеләп, төрткеләр ясарга кирәк. 1 төрткедән «В»га кадәр булган ара (1-В) — 141 мм; 2-В арасы — 123 мм; 3-В арасы — 104 мм; 4-В — 84 мм; 5-В — 63 мм; 6-В — 41 мм; 7-В — 132 мм. Түбәндәге рәсемдә тишемнәрнең урнашу тәртибе бирелә.




Тишемнәрнең диаметрлары мондый була: 1, 2, 3, 5, 7 нче тишемнәр 8 ле, 4 нче тишем 5 ле, 6 нчы тишем 6, 5 мм лы бораулар белән тишеләләр.

Курайда басып та, утырып та уйныйлар. Кулны киеренке тотмаска, иркен тотарга, терсәкләр аз гына як-якка күтәрелгән. Бармак бите белән тишемнәрне йомшак кына, ләкин һава чыкмаслык итеп капларга кирәк.

Курайда башлап уйнарга өйрәнү өчен берничә киңәш тәкъдим итәбез.

Сул кулның баш бармагы аскы тишемне, имән бармак өстән беренче тишемне, уң кулның имән бармагы өстән дүртенче тишемне каплый, баш бармак аскы ягыннан тотып тора. Ә калган бармаклар тишемнәрдән 1—2 см га күтәрелеп тора.

Курайның сыбызгысын иреннәргә тидерергә һәм акрын гына һәр нотаны аерымаерым, «тефф» итеп өрергә кирәк.

Сул кулның урта бармагы белән икенче тишемне каплыйбыз, акрын гына өрәбез һәм тагын бармакны күтәрәбез. Шул рәвешле бармак күнеккәнче һәм матур, сәламәт тавыш чыкканчы кабатлыйбыз. Аннан соң атсыз бармак белән өченче тишемне, уң кулның урта һәм атсыз бармаклар белән бишенче, алтынчы тишемнәрне кабатлыйбыз.

Бөтен тишемнәрне дә каплап бетергәч икенче октаваның «ре» тавышы чыгарга тиеш. Алтынчы тишемне ачкач, «ми», бишенче — «фа диез», дүртенче — «соль», өченче — «ля», икенче — «си», беренчене ачкач — «до диез» ноталары яңгырарга тиеш. Тишемнәрне ачкан саен көчлерәк өрергә кирәк. Бөтен тишемнәрне каплап тагын да катырак өргәндә өченче октаваның «ре» тавышы һәм алда күрсәтелгән тәртиптә ре мажор гаммасы яңгырар.


Ринат ГЫЙЛӘҖЕВ,
Татарстан АССР культура министрлыгы
фәнни-методик үзәге директоры

# ТӘВӘККӘЛЛЕК ТЕЛИМ

*(Әмирхан Еникинең «Татарстан АССР халык язучысы» дигән исем алганда сөйләгәне)*

Хөрмәтле иптәшләр!

Язучы өчен иң читене — үз иҗатыңны, үзеңнең әдәбиятта тоткан урыныңны дөрес аңлау һәм дөрес бәяләү... Монда ялгышуы бик ансат: йә бәяләп бетермисең, йә арттырып уйлый башлыйсың. Ә кеше дигәнең гадәттә арттырып уйларга ярата. Моның ахыры исә тора-бара бик күңелсез булып бетүе, ягъни көткән дан урынына билгесезлек килүе бик мөмкин. Шуны сизгәндәй мин, кыйналган чакта гына түгел, макталган чакта да үзем турында арттырып уйлаудан сакланырга тырыштым. Кешенең эшен дә, тоткан урынын да ахыр чиктә вакыт билгели — менә мин дә үземне вакыт хөкеменә тапшырган идем. Вакыт ялгышмас, вакыт дөресен әйтер дип ышана идем.

Инде менә миңа Татарстан Верховный Советы указы белән «Халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелде. Бу — вакыт хөкеменә караганда ничектер иртәрәк булды шикелле... Мин үзем дә моны көтмәгән идем... Ләкин бит исемне кешегә тере чагында бирәләр, аннары 80 яшь аз гомер дә түгел, күрәсең, мин күпмедер дәрәҗәдә вакыт сынавын үткәнмендер дә инде. Әгәр шулай икән, әгәр шуннан чыгып безнең Язучылар союзы мине әлеге мактаулы исемгә тәкъдим итүне, ә Верховный Советыбыз президиумы ниһаять миңа шул олы исемне бирүне кирәк тапкан икән, мин, әлбәттә, аларга чын күңелдән тирән рәхмәтемне белдерәм. Шулай ук бу эшне хуплап каршы алучы укучыларыма да һәм каләмдәш дусларыма да тирән рәхмәтемне әйтмичә кала алмыйм: рәхмәт, сезгә, дуслар, рәхмәт, туганнар!..

Билгеле, «Халык язучысы» дигән шәрәфле исемне кер төшермичә йөртүе, бигрәк тә аны аклавы җиңел булмаячак. Үткәндәге эшләр белән генә түгел, яңа эшләр белән дә акларга кирәк булачак. Әмма язучы, ничә яшьтә булуына карамастан, һәрвакыт алга карап яши ул. Теләге, өмет иткәне, күрәсе килгәне барысы да алда — яшәве дә, эшләве дә аның бары шулар хакына!

Без бит бик хикмәтле бер чор кичерәбез. Хәзерге яңарышны, үзгәртеп коруны революция диләр, революция белән тиңлиләр. Ә безнең әдәбиятта, Тукайлар заманында, революцияне таң ату, яңа көн туу белән чагыштырганнар. Тик ул заманда безнең халык өчен таң бик әкрен аткан.

Менә ничек башлана, мәсәлән, Сәгыйть Рәмиевнең «Таң атканда» дигән шигыре:

*Таң вакыты... Татар йоклый...*
*Мин йокысыз, уянам,*
*Уянам да, тиле кебек,*
*Тик бер үзем уйланам.*

*Уйланам, уема батамын,*
*Тормыймын үзем, ятам,*
*Ятмас идем дә, җибәрми*
*Атадан калган хатам.*

Инде Тукайны тыңлап карыйк:

*Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән,*
*Эшкә дәгъвәт итте безне кемдер изге нам белән.*

*Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел,*
*Күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакъ түгел.*

Күрәсез, икесендә дә сүз инкыйлап таңы турында... Әйе, бу беренче таң вакытында татар халкы авыр уянган, ата-бабадан калган хаталар, гасырлар буе сузылып килгән изү-кысулар, шуның өстенә наданлык һәм хорафат аңа тиз генә уянып торырга мөмкинлек бирмәгән. Әмма инде бер торып баскач, ул кыска гына вакыт эчендә бик кызу алга табан атлап китә. Татар дөньясының ике революция арасындагы бу гаҗәеп омтылышын без әле тиешенчә белеп тә, аңлап та җиткергәнебез юк.

Әйтергә кирәк, безнең хәзерге таңыбыз да шактый озак, шактый авыр ата. Күпме еллар буенча җыела килгән аянычлы хаталардан да һаман әле котылып бетә алмыйбыз, күзләрдән көн яктысын караңгылап торган томан пәрдәсе дә әле төшеп бетмәгән. Мондый хәлдә алга таба туры, кыю атлау җиңел түгел, әлбәттә... Димәк, иске карашлардан һәм гадәтләрдән ничек тә тизрәк арынырга кирәк. Шунсыз яңару мөмкин булмаячак. Ә инде халыкны әнә шул иске догмалардан азат итү, күзен ачу, рухын сафландыру, фикери хәрлеккә өндәү — бу әдәбият эше, иптәшләр, бу безнең төп эшебез! Һәм мин бу эштә үземә дә, каләмдәш дусларыма да көч-куәт һәм тәвәккәллек телим.

Рәхмәт игътибарыгыз өчен!

*27 март, 1989 ел.*

## Марсель Галиев

# ИЕ ШУЛ...

(ХИКӘЯ)

Тәминдар абзыйның бүген кинәнеп яшәп ала торган көне. Пөхтә кырынган, яңа эшләпә кигән. Мыек чылгыен сыпырып, сул күзен кыса төшеп, башын артка чөебрәк, склад баскычыннан астагы халыкка вәкарь белән карап тора. Бүген газ баллоннарын алыштыра торган көн. Ә баллоннарга Тәминдар абзый хуҗа. Авылның яшь-җилкенчәге машинадыр, мотоциклдыр — һәртөрле техника белән килеп киткән инде, монда бары карт-корылар — Тәминдар абзыйның чордашлары гына калган. Менә хәзер ясканып изә инде ул аларны:

— Өйрәнеп җиттегез, ә! Газ кирәк, имеш. Утын ягып, казанда быгырдатып аш пешерәсе урында. Убыр утында пешкән аш тәнгә сихәтлек кертә димени! Менә син, Галимҗан кордаш, казанда пешкән аш чөмергәндә болай кәкрәеп йөри идеңме? Юк бит! Хәзер энә, биленә тотынып, тычкан агуы эчкән кебек, чыраеңны сытып йөрисең. Нәрсә, дөрес әйтмиммени?!

— Дөрес, дөрес... Алыштыр да баллонны, китим әле мин.

— Ашыкма, кордаш, башта карыйсы бар баллоныңны, дификте-фәләне юкмы, берәр җире бозылган булса, аны бит миннән кабул итеп алмыйлар. Дөрес әйтәм бит, җәмәгать!

— Ие шул... Ие шул...— диеште карчыклар.

— Шулай...— Тәминдар абзый, сул күзен бер тын бөтенләй йомып бетереп, карап торды.— Синең, Миргас кода, малаеңны утыртканнар икән, ә?! Алты елга диме? Күпме ырыстырата чыкты? Биш мең... Пүчтәк кенә сумма да бит, нишлисең... Тәки җүнле малай үстерә алмадың син, ә! Сезнең очтагы коеда фусфыр күп шул. Фусфыр канны сыеклата. Башы эшләмәгән малаеңның, башы-ы-ы. Синең үзеңнең дә... Егерме ел дуңгыз карый димени башы кәбестә кучәне булмаган бәндә. Малаен укыта, кеше итә янәсе! Сарыктан бозау туар ие! Әнә минем малай Чаллыда ишә генә акчаны. Өченче көн барып кайттым янына, шәп фатир алган, кырык аяклы йорттан. Ул озынлыгы, минсиңайтим, йортның, аскы урамдагы Бүтәкә Әхмәтҗаннан алып күпер төбендәге Ионччу Салихка чаклы булыр. Шул адәм тәганәсе йорт нибары кырык аякта басып тора. Санап киләсең-киләсең дә, утыз сигез белән утыз тугызынчы аяк арасыннан керүгә — туп-туры минем малай ишеге. Төймәгә басуга, эчтә көмеш кыңгырау тавышы бирә: чиң, чиң, чиң...

— Көмеш үк түгелдер лә инде,— дип, шыпырт кына күршесенә төртеп алды Маһи карчык.

— Булыр, булыр... Соңгы унбиш елда Тәминдар, завхоз булып, колхоз байлыгы өстендә атланып утырды бит,— диде Сәрвәр карчык, күршесенә таба иелеп.

— И яшәп ята минем малай, синеке кебек укып азапланмады, зату озын акчаны көрәпме көри!

— Ие шул... Ие шул...— диеште карчыклар уч төбенә йөткергәләп.

Каршы әйтеп кара Тәминдар абзыйга. Элек тә булмый иде, хәзер дә булмый. Председатель чагында тарантаска үрә басып йөрде. Аның усал карашыннан яңа аерткан сөт әче катыкка әйләнә торган иде. Аннары ул амбар мөдире булды, аннары ферма мөдире, аннары — завхоз, үзе әйтмешли, гел җитәкчелек эшендә.

— Син нәрсә, Сәрвәр килен, бер читтә генә торасың әле, якынрак кил. Гомер буе итәк астында балта йөртәсең, телеңә төер чыккыры! Суны Бүре Сәмиг коесыннан аласыңмы әле син? Шул-шул. Ул кое төбендә ачуташ ята дип күпме әйттем. Суы зәһәр булмаса, ажгырып торган самавырны ике

айда тишеп чыгармас иде. Кара инде, иреңнең кеше арасына чыгарлыгын калдырмагансың бит, әй! Кыш буе күзгә-башка күренмәде.

Сәрвәр түтинең ире фермада эшли иде. Яз исе килеп торган бер төндә ул, кызыгып китеп, яңа төшкән игезәк бозауның берсен печәнгә төреп чанасына сала да өенә алып кайта. Бозаулар чутсыз, мин игезәк бозау китергәнием, дип әйтергә сыерның теле юк. Һәйбәт сарайга яшереп, җәй буе хатыны белән бергә карап, тәрбияли торгач, кыш кергәндә бозау тәмам симереп, гөрселдәп торган үгез булып җитешә. Бүген-иртәгә суябыз дип торганда... кичен Сәрвәр түтинең ире шактый нык «төшереп» кайта, юк кына сәбәптән өйдә тавыш-гауга чыга, тәпәләшүгә кадәр барып җитәләр. Сәрвәр түти ачуына чыдаша алмыйча: «Күрсәтәм әле мин сиңа!» — дип, идарәгә чыгып йөгерә, иренең бозау урлау вакыйгасын сөйләп бирә. Икенче көнне, татуланышкан ир белән хатын киң урам уртасыннан, симез үгезне җитәкләп, фермага илтеп тапшыралар.

— Аны бит, әйткәч-әйткәч, бозау йодрык кадәрле чакта барып әйтергә иде. Күпме ашатып, күпме карап үстер дә суяр вакыт җиткәч кенә... әх, мәнсез баш!

— Ие шул... Ие шул...— диеште карчыклар, башларын аска иеп.

— Син, Сафура күрше, нигә дип килдең әле? Сизеп торам бит, карамыйча да белеп торам: баллоныңның яртысы да бушамаган. Тегесендә дә шулай иде. Кешедән көнләшеп кенә алып киләсең син аны, әйтерсең лә мин монда алтыннан койган баллон өләшеп ятам! Кабереңдә дә көнләшеп әйләнгәләрсең әле син. Көннәр буе койма ярыгыннан күзәтеп ятасың бит: кем кая бара, кем нәрсә төяп кайта. Утынга киткән кеше артыннан машинасы ватылса ярар иде дип каласың, печән кайтарып таратсалар, ходайдан яңгыр телисең. Бар, алып кит, берьялгызыңа тагын ике-өч айга җитә әле калган газың да!

— Маллар бар бит, Тәминдар туган...

— Те-һи! Сөйләшеп торуын күр. Бер башың да бер кәҗәң. Сталин сыерына аңа газда бәлеш пешереп ашатырыеңмы әллә! Койма тактасын кимереп тә тамагын туйдыра ул, мур кыргыры!

— Ие шул... Ие шул...— диеште карчыклар, бер көйгә башларын селкеп.

— Ә син Маһи түтекәй, нишләп әле ходайның бирмеш көнендә, урталай бөкләнеп, уфалла арбасы тартып йөрисең? Малаең Казаннан «Волга»сы белән кайтып, газ баллоныңны алыштырып китсә ни булган?!

— Вакыты юк шул аның, Тәминдар кардәш...

— Вакы-ы-ыт, имеш! Министыр булдым дигәч тә... көтүче Хәйрүш кебек айга биш йөз тәңкә хезмәт хакы алам дигәч тә.. үзе белмәгәнне кешегә өйрәтеп йөргәч тә... кем булган ул чаклы! Монда әнкәсе уфалла арбасы тартып йөри, ул анда, корсагын киереп, машинада чаба. Бүтәкә Әхмәтҗан коесыннан аласыңмы әле суны, Маһи түтәй? Шулайдыр. Ул коеның суы тимергә бай. Бүтәкә Әхмәтҗан коесыннан су эчкән малайлар бөтенесе дә нәчәльнек булдылар... Юк, болай йөрмә, Маһи түтекәй, яз, чакырт, кайтарт малаеңны! Нәрсә ул анда... Мин утыра алмыйммы министыр булып... кеше язганны укып, кеше укыганны язып йөрергә кем дә мәчтыр!

— Ие шул... Ие шул...— диеште карчыклар, яулык почмагына йөткергәләп.

Газ баллоннарын алыштырып бетергәнче, әнә шулай, Тәминдар абзый үзенең чордашларын берәм-берәм «сүтеп» чыга. Гомер буе шул рәвешле: сул күзен кысып, өстән генә карап, акыл өйрәтеп кенә яшәр кебек иде дә... нишлисең, вакыт үзенекен итә. «Пенсиягә чыккач та ун ел эшләдең, арыгансыңдыр, инде рәхәтләнеп ял ит»,— дип, җәй башында Тәминдар абзыйны эшеннән азат иттеләр. Көн саен идарә тирәсендә чуалырга яраткан Тәминдар абзый кинәт картая башлады, күзгә күренеп бетеренде. Кай арада арка бөкресе дә бәреп чыкты. Әллә инде, элек булып та, искәрелмәгән...

Челлә көннәрдә дә ул аягына киез итек, өстенә фуфайка, башына эт бүрек киеп чыга, капка төбендәге утыргычта тик утыра. Беркатлы, мәкерсез шул, кинә сакламый сугыш чорын кичергән авыл кешеләре, Тәминдар абзый янында хәл белергә дип тукталалар. Ә ул, кулларын селки-селки, һаман сөйли. Иреннәре кыймылдый — тавышы чыкмый, тимер тешләре елтырый — сүзе ишетелми, тел очы әүмәкләнеп күренә — өне юк. Аның шулай бушка кыймылдаган авызына текәлгән кордашлар, дистә еллар буе күнеккән гадәт буенча, баш кагып, җөпләп торалар:

— Ие шул... Ие шул...

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫ

17-18 майда Казанда, В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалында Татарстан язучыларының XI съезды булып узды. Съездда язучылар, мәдәният эшлеклеләре, Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан килгән кунаклар катнашты. Кунаклар арасында РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты С. В. Михалков, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Э. Ю. Зимин бар иде.

Съездны кереш сүз белән Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әмирхан Еники ачты.

Республикабыз язучыларының иҗаты турындагы отчет докладын идарә председателе Туфан Миңнуллин ясады.

Ревизия комиссиясе отчеты белән комиссия председателе Рәис Даутов чыкты. Аннары жанрлар буенча өстәмә докладлар тыңланды. Проза турында — Фәрваз Миңнуллин, поэзия турында — Тәлгат Галиуллин, драматургия турында — Азат Әхмәдуллин, рус язучылары иҗаты турында — Михаил Скороходов, тәнкыйть турында — Нурихан Фәттах, балалар әдәбияты турында — Роберт Миңнуллин, очерк һәм публицистика турында — Газиз Кашапов, «Казан утлары» журналы редакциясе эшчәнлеге турында журналның баш редакторы Ренат Харис, тәрҗемә турында Солтан Шәмси сөйләделәр.

Аннан соң доклад һәм өстәмә докладларны тикшерү башланды. Фикер алышуларда язучы Р. Мөхәммәдиев, язучыларның Әлмәт бүлеге җитәкчесе Н. Әхмәдиев, В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсе директоры шагыйрь Р. Вәлиев, шагыйрь һәм прозаик Р. Кутуй, Кыргызстан ССРның «Мәктәп» нәшрияты директоры С. Наметбаев, шагыйрьләр Р. Фәйзуллин, Ә. Рәшитов, Ә. Мәхмүдов, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире Ф. Мусин, язучылар И. Салахов, Ә. Гаффар, драматурглар Р. Хәмид, Р. Мингалим, башкорт язучысы Ш. Янбаев, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев, әдәбият билгече И. Нуруллин һ. б. катнашты.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин һәм РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. В. Михалков чыгыш ясады.

Съезд яшерен тавыш бирү юлы белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе итеп Ринат Мөхәммәдиевне, «Казан утлары» журналының баш редакторы итеп Ренат Харисны сайлады.

Съезд эшендә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ш. Ә. Мустаев, ТАССР Министрлар Советы Председателе М. Ш. Шәймиев, КПСС Үзәк Комитетының идеология бүлеге инструкторы А. С. Филин, КПСС өлкә комитеты секретарьлары Ә. Г. Булатов, Г. Ф. Самойлов, КПСС өлкә комитетының идеология бүлеге мөдире О. В. Морозов, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

Татарстан язучыларының XI съездыннан соң сайланган яңа идарәнең беренче утырышы булды. Аны Язучылар союзы идарәсе председателе Ринат Мөхәммәдиев алып барды.

Идарәгә 23 кеше сайланды: Р. Батулла, Ә. Баянов, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, А. Гыйләҗев, Ә. Еники, Ф. Зөлкарнәев, Р. Зәйдуллин, Г. Кашапов, В. Корчагин, Р. Кәрами, М. Маликова, З. Мансуров, Р. Мингалимов, Роберт Миңнуллин, Фәрваз Миңнуллин, Р. Мөхәммәдиев, И. Нуруллин, Г. Рәхим, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Н. Әхмәдиев. Иҗат мәсьәләләре буенча председатель урынбасары итеп Мәдинә Маликова, җаваплы секретарь итеп Мөсәгыйть Хәбибуллин, татар әдәбиятын пропагандалау буенча җитәкче итеп Рәфкать Кәрами сайланды.

Идарә членнары киләчәктә Татарстан Язучылар союзының эшен җанландыру турында сөйләштеләр, үзгәртеп коруның алгы сафында булу өчен планнар кордылар.

## ТАТАРСТАН РӘССАМНАРЫНЫҢ VI СЪЕЗДЫ

27 апрельдә Актерлар йортында Татарстан рәссамнарының VI съезды булды. Аны Татарстан рәссамнар союзы идарәсе председателе В. Маликов ачты.

Татарстан рәссамнарының отчет чорындагы эшчәнлеге һәм КПССның XXVII съезды, XIX Бөтенсоюз конференциясе карарлары яктылыгында иҗат союзының бурычлары турындагы доклад белән идарә председателе урынбасары А. Абзгильдин чыкты. Ревизия комиссиясенең эшчәнлеге турында докладны В. Федоров ясады.

Докладлар буенча фикер алышуда секция җитәкчеләре, тугандаш республикабыздан килгән кунаклар катнашты.

Татарстан художниклары съездында КПССның өлкә комитеты секретаре Р. Р. Идиатуллин чыгыш ясады.

Съезд тикшерелгән мәсьәләләр буенча резолюция кабул итте.

Соңыннан идарәнең һәм ревизия комиссиясенең яңа составы сайланды. Идарә председателе итеп Ә. М. Мәҗитов сайланды.

Съезд эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## КОМПОЗИТОРЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫ

РСФСРда иң зур иҗат оешмаларының берсе булып саналуына карамастан, Татарстан Композиторлар союзының моңарчы үз партия оешмасы юк иде. КПСС члены булган композиторлар консерватория, филармония, театрлар һ. б. партия оешмаларында учетта тордылар. Бу исә Композиторлар союзының, коммунист композиторларның эшендә шактый кыенлыклар китереп чыгара иде. Коммунистлар, үзара киңәшкәннән соң, ниһаять, ТАССР Композиторлар союзының үз партия оешмасын булдырырга дигән фикергә килделәр. Аның беренче оештыру җыелышы булды. Татарстан Композиторлар союзы партия оешмасы секретаре итеп Р. Билалов сайланды.

## ХӘТЕР КӨНЕ

Җыңү бәйрәме алдыннан Татарстан язучылар союзында күркәм чара — вафат булган каләмдәшләребезне, әдәбият-сәнгать осталарын искә алу — «Хәтер көне» үткәрелде.

Шул уңайдан Татарстан Язучылар союзы һәм РСФСР Әдәби фондының Татарстан бүлегендә, «Казан утлары» һәм «Идел» журналларында эшләүче хезмәткәрләр, Ш. Мәрҗани исемендәге мәдәният җәмгыяте вәкилләре, зур төркем язучылар, вафат булучыларның гаилә членнары Казан шәһәрендәге татар зиратында булып, халкыбызның йөз аклыгы, намусы, горурлыгы саналган әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең каберләрен тәртипкә китерделәр.

## НӘҮРҮЗ БӘЙРӘМЕ

ВЛКСМның Казан шәһәр комитеты һәм Татар иҗтимагый үзәгенең яшьләр комиссиясе инициативасы белән быел 21 мартта Казанның Яшьләр үзәгендә беренче тапкыр Нәүрүз бәйрәме үткәрелде. XVII гасырга кадәр халкыбызда Яңа елны март аеның 21 е көнне билгеләп үтү гадәте булган. Бу фарсы-таҗик календаре буенча эшләнгән. («Нәүрүз» фарсыча «яңа көн» дигәнне аңлата). Хәзерге вакытта да Иран, Әфганстан, Казахстан, Азәрбайҗан халыклары бу бәйрәмне зурлап үткәрәләр.

Бездә Нәүрүз бәйрәменең юкка чыгуына, бер яктан, рус патшаларының милли изүгә корылган колониаль политикасы сәбәпче булса, икенче яктан, мәҗүсилек заманнарыннан ук килгән бу йоланы ислам дине әһелләре әзәрлекләгән. Нәүрүз үз көчен XVII гасырда ук югалткан, әмма аның кайбер чаткылары XX гасыр башында да күренеп китүе мәгълүм.

Яз һәм наз бәйрәме Нәүрүздә Казанның 10 һәм 103 нче мәктәп укучылары, шәһәрнең югары уку йортларында белем алучы студентлары актив катнашты. Аларның «Сорнай» фольклор ансамбле, сәхнә осталары Зиннур Нурмөхәммәтов, Клара Хәйретдиновалар алыштырды.

Бу бәйрәмдә үзбәк, таҗик, Кырым татарлары, азәрбайҗан моңнары да яңгырады. Кардәш халыкларның чыгышлары бәйрәмгә ямь, матурлык өстәде.

## БОЛГАР БАБАЛАРЫБЫЗ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Татарстанның Кама аръягы — борынгы болгар бабаларыбыз җире. Биредә яшәүчеләрнең күпчелеге ислам динен тоткан. Мөселман бабаларыбыз мәчеттә намазын укыган, мәдрәсәләрдә белем алган. Әмма Сталинның шәхес культы чорында мәчет маналары киселеп, Чаллы гыйбадәтханәсез калган иде.

1 апрельдә Чаллыда яңа мәчеткә нигез салу тантанасы булды. Бу вакыйга татар халкының борынгы бабалары Идел буе болгарларының ислам динен кабул итүенә һиҗри ел исәбе буенча 1100 ел, диния нәзарәте оешуга 200 ел тулу вакытына туры килде.

Тантанага Казан, Саратов, Тобол, Уфа, Новосибирск, Ростов, Омск һәм башка шәһәрләрдән ислам дине әһелләре килгән иде.

Мәчет проекты элеккеге болгар архитектурасын хәтерләтә. Ул 300 урынлы намаз укый торган һәм 150 урынлы конференция заллары булган ике катлы бинадан гыйбарәт. Хатын-кызлар өчен махсус бүлмә бар. Манараның биеклеге 57 метр. Мәчет үзенчәлекле милли архитектураны искә алып төзелә. Аның смета бәясе 1 миллион 300 мең сум. Төзелешкә халыктан байтак акча керде. Чит илдәге мөселман кардәшләребез дә (Согуд Гарәбстаны һәм Кувейттан) ярдәм итәргә әзер торалар.

Котлованга кагылган беренче субайның бер читенә җиз истәлек тактасы беркетелә. Анда шундый сүзләр бар: «1989 елның 1 апреле көнне Яр Чаллы мәчетенең нигез ташы салынды. Мәчет татар халкының борынгы бабалары дәүләте бөек Болгарда ислам дине кабул ителүнең һиҗри белән 1100 ел һәм Уфада Көнчыгыш Европа һәм Себер мөселманнарының диния нәзарәте оешуга милади белән 200 ел тулу хөрмәтенә төзелә башлады».

Төзүчеләр яңа мәчетне юбилей көннәренә, быелның 23 августына өлгертергә вәгъдә итәләр.

## МӘСКӘҮ КАЗАННЫ ТЫҢЛЫЙ

КПСС өлкә комитетының милләтара мөнәсәбәтләрне камилләштерү һәм хезмәт ияләрен интернациональ тәрбияләү буенча эш группасы карары һәм ТАССР Дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар комитеты тәкъдиме белән СССР Дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар комитеты Мәскәүдә һәм башкала янындагы районнарда Татарстан радиосы программаларын кыска дулкыннарда тапшыра башлау турында боерык бирде.

Тапшырулар 6 сәгать 40 минуттан 18 сәгатькә кадәр — 11 945 кгц ешлыкларында, 18 сәгать 5 минуттан 22 сәгатькә кадәр 17 810 кгц ешлыкларында (25 һәм 17 метр) алып барыла.

СССР Дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар комитеты һәм СССР Элемтә министрлыгы Татарстан радиосы программаларын илнең башка шәһәрләрендә һәм төбәкләрендә тапшыру өчен техник мөмкинлекләр эзли.

## РИЗА ФӘХРЕТДИНЕВНЕҢ ТУГАН АВЫЛЫНДА

Республикабыз җәмәгатьчелеге ел башында күренекле язучы, галим, философ, тарих белгече һәм рухани эшлекле Риза Фәхретдиневнең тууына 130 ел тулу вакыйгасын киң билгеләп үтте.

Яңача фикерләү рухы Казан галимнәрен әдипнең туган авылы Кичүчатка җыеп алды. Әлмәттә яшәүче язучылар, журналистлар, партия һәм совет хезмәткәрләре белән берлектә 24 апрельдә уздырылган түгәрәк өстәл сөйләшүендә Казан дәүләт университетының уку-укыту проректоры профессор Миркасыйм Госманов, шул ук югары уку йорты профессоры Тәлгат Галиуллин, танылган язучы, доцент Мөхәммәт Мәһдиев катнашты. Авылдашлары, мәктәп укытучылары, укучылары белән бергә уздырылган җанлы әңгәмә Риза Фәхретдиневнең олы иҗатын күзалларга, аны киләчәктә колачлырак өйрәнү юлларын ачыкларга мөмкинлек бирде.

Иң куанычлысы шул: шәхес культы һәм торгынлык елларында да якташлары халкыбызның олы улын онытмаган, әтисенең каберлеген кадерләп тоткан, күрше авылдагы Мәмәт урта мәктәбе музеенда Риза Фәхретдиневкә багышланган әдәби-тарихи почмак ачып җибәргән.

Авылдашларының җәмәгатьчелеккә һәм җитәкчелеккә җиткерү өчен шактый дәлилле тәкъдимнәре дә әзер икән: Кичүчатта уку яшендәге балалар булуга да карамастан, көчләп ябылган сигезьеллык мәктәпне яңадан ачу һәм аңа Риза Фәхретдинев исемен бирү, бинага мемориаль такта кую.

## Ш. МӘРҖАНИ ИСЕМЕНДӘГЕ МӘДӘНИЯТ ҖӘМГЫЯТЕ КАРАРЫ

Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге мәдәният җәмгыяте татар халкының бөек галиме, энциклопедисты Ш. Мәрҗани исемендәге биш премия һәм югары уку йортларында укучы студентлар өчен дүрт стипендия билгеләргә карар бирде.

Биш премиянең икесе мәдәниятыбызга ихлас күңелдән бирелеп хезмәт иткән яшьләр өчен билгеләнә. Ә ике премия тел, тарих, әдәбият, техника яңалыкларын ачуда ирешкән уңышлар өчен биреләчәк. Бер премия халкыбызның телен, тарихын, әдәбиятын, сәнгатен башка милләтләр арасында пропагандалауга куйган хезмәтләре өчен яшьләрнең «Идел» журналы редакциясе һәм Ш. Мәрҗани исемендәге җәмгыять тарафыннан галимнәргә, журналистларга, язучыларга бирелә.

Премияләр январь аенда һәр елны Шиһабетдин Мәрҗани туган көндә тапшырылачак. Премиягә лаек булучыларга җәмгыятьнең дипломы һәм 250 шәр сум күләмдә акча бирелә.

Студентларга дигән дүрт стипендиянең икесе — техник вузларда укучылар өчен. Калган икесе — әдәбият, тел, тарих һәм башка белгечлекләр буенча укучы студентлар өчен. Стипендия әхлаклы, халыкның телен, тарихын, әдәбиятын үстерүдә актив катнашкан студентларга бирелә. Стипендиягә лаек булучылар җәмгыятьнең дипломын һәм ай саен 40 сум күләмендә акча алачаклар.

Премиягә һәм стипендиягә кандидатуралар җәмгыятьнең филиаллары — башлангыч оешмалар советы тарафыннан тәкъдим ителеп, җәмгыять президиумы карары белән раслана.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре һәм күп еллар буе нәтиҗәле эшләгәне өчен «Совет мәктәбе» журналының баш редактор урынбасары Шәрифуллин Фәрит Әхмәтнуровичка, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 15 март Указы белән, «РСФСРның атказанган культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Фәтхелбаян Нурлыгаянович Гыйззатуллинга (Баян Гыйззәт), Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 3 апрель Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Азат хатын» журналының техник редакторы Әлмира Лотфулловна Әдиятуллинага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 10 апрель Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

# КҮН КЕЛӘМНӘР

Софья Даниловна Кузьминых турында сөйләгәндә иң элек халкыбызның борынгыдан килгән гамәли сәнгатен күзалларга, әлеге бай һәм зур сәнгатьнең төрле тармакларын, юнәлешләрен барлап карарга кирәк. Чәмчәле читекләр, кечкенә күн сандыклар, күн келәмнәр, җитен тукымадан һәм күннән тегелгән бизәкле өс киемнәре — азмыни халык иҗатында мондый сәнгать җәүһәрләре!?

С. Д. Кузьминых — милләте буенча рус кешесе. Әмма ул Казанда туган, татар сөйләмен, татар җырларын сабый чактан ук тыңлап үскән, татар халкының милли төсмерләрен хәтеренә сеңдергән. Аның күргәзмәсендәге үрнәкләргә күз салсаң, тагын шуны да ныклап тоярга мөмкин: халык аһәңнәрен күңеленә тирән салу белән беррәттән, гамәли сәнгать осталарының элек-электән килгән ихтыяр көчен, сабырлыгын һәм түземлеген, фидакарьлеген һәм күңел байлыгын да үзенә якын юлдаш иткән икән ул.

Чәмчәләп яисә күнгә басып ясалган бу бизәкләр бик борынгыдан калган төсмерләрне уяу саклый. Шул ук вакытта останың хыялы яңа бизәкләр, яңа төсмерләр тудыра, кискеч очы аларны күн җәймә өстенә төшерә. Ләкин, ни генә булмасын, һәр яңа бизәк үзендә халык зиһененә уелган гореф-гадәтләрне, иң якты кичерешләрне, иң изге омтылышларны чагылдыра. Чәчәк бәйләмнәренең һәр бизәгендә борынгыдан килгән фәлсәфи уйларны: тормыш, яшәү, туу һәм үлү турындагы уйлануларны күреп алырга мөмкин. Як-якка сузылып киткән үсентеләр янә шушы уйларга кушыла — яшәүнең матурлыгын, тереклекнең чиксезлеген, дәвамлылыкның асыл табигатен раслый. Гармония дә, табигатьнең олылыгы да әнә шул бизәкләр аша зурлана. Халык иҗатына, халык сәнгатенә чын мәхәббәт, табигатьнең һәм гамәли сәнгатьнең кабатланмас кануннарын йөрәк аша тою, аяк киеме җитештерү кебек катлаулы һөнәрнең хатын-кызга хас һәм хас булмаган якларын җиренә җиткереп белү, кием-салым тегү осталыгын иҗат белән, теоретик эзләнүләр белән бергә үреп бару — болар барысы да С. Д. Кузьминых иҗатына бәрәкәтле сулыш өргән сыйфатлар. «Кырлай» дип аталган мемориал комплекстагы җиһазларны бизәү өчен эшләнгән күн мендәрләр, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасының холлын бизәгән күн келәмнәр әнә шул зур иҗатның гаҗәеп бер үрнәкләре. Әлеге иҗат безгә бүгенге көнне дә, киләчәкне дә, борынгы бабаларыбыз чорыннан килгән изге сулышны да дөрес тоярга, дәвамлылыкның бөек көчен тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

**Р. ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музее хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә**: Казан кремленә керү юлы. XIX гасыр инглиз рәссамы Э. Турнерелли эшеннән репродукция.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосы.

## УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИГЪТИБАРЫНА!

**Күп санлы укучыларыбызның теләген искә алып, һәм журнал алдыруны җиңеләйтү максатыннан, бу санда 1990 ел өчен язылу квитанциясен тәкъдим итәбез. «Казан утлары» журналына язылырга теләүчеләр, квитанциягә үзенең тулы адресын язып, аны күрсәтелгәнчә кисә һәм «Союзпечать» агентлыгы бүлегенә тапшыра алалар. Шунысын да исегезгә төшерәбез: яңа кагыйдәләр буенча, киләсе ел өчен журналга елның теләсә кайсы вакытында алдан ук язылырга мөмкин.**

Министерство связи СССР
«Союзпечать»

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал | 73 210 (индекс издания)

Казан утлары
(наименование издания)

Количество комплектов: 1

на 19 90 год по месяцам

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

ПВ | место | литер | на ~~газету~~ журнал | 73210 (индекс издания)

Казан утлары
(наименование издания)

| Стоимость | подписки | 10 руб. 80 коп. | Количество комплектов: 1 |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | |

на 19 90 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, инициалы)

«Казан утлары» Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Аңа Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. Индексы — 73210. Бәясе — бер елга 10 сум 80 тиен.

## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки)

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ—МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1990 ЕЛДА

Киләсе елда журнал үзенең укучыларына нинди яңа әсәрләр, мавыктыргыч сәхифәләр бүләк итәргә җыена соң? Редакциябез хәзинәсендә татар әдипләренең әле беркайда да басылмаган роман, повесть һәм хикәяләре байтак. Менә аларның кайберләре:

**Атилла Расих. «Альпинистлар».** Романда социаль чыгышы аркасында сталинщина чорының газапларын татып та рухы сынмаган яшь кешенең язмышы һәм татар әдәбиятында сирәк яктыртылган хаҗга бару вакыйгалары.

**Мәдинә Маликова. «Фидая».** Җитәкче урыннарда эшләп, гыйш-гашрәт вәсвәсәләренә каршы торып, хатын-кыз кыенлыклары кичергән саф күңелле бүгенге татар хатыны турында роман.

**Гурий Тавлин. «Афәт».** Роман. Хәзерге алтмыш яшьлек кешеләрнең болытсыз балачактан фаҗигаләр тулы үсмерчакка керүләре турында.

**Тәүфикъ Әйди. «Елан угы».** Роман татар егетенең Бохара Чекасына кереп оялаган дошманнарга каршы гыйбрәтле көрәшен сурәтли.

**Гомәр Бәширов. «Онытма».** Аулак өйдә кунулар, халкыбызның күркәм гореф-гадәтләре һәм саф мәхәббәт турында повесть.

**Аяз Гыйләҗев. «Балта кем кулында».** Повесть хөкем карары чыгаручылар һәм шуны үтәүчеләр, тарих каршында һәркемнең дә җаваплылыгы хакында.

**Гариф Ахунов. «Гомер юлы».** Повестьта күп хокуклардан мәхрүм ителгән, паспортсызлык путасы белән авылга бәйләп куелган крестьянның газаплары, шул чорда да бүгенге үзгәртеп кору көннәрен якынайтышкан җир кешеләре тасвирлана.

**Мәхмүт Хәсәнов. «Көзге йолдызлар астында».** Повесть социаль гаделсезлек һәм битарафлык нәтиҗәсендә яшь гомернең фаҗига белән тәгәлләнүе хакында сөйли.

**Рафаил Төхфәтуллин. «Сарман балладасы».** Икенче Бөтендөнья сугышына киткән гармунчы егет Каюмның үзгәреп, окоп һәм революция елларын кичеп, туган авылына әйләнеп кайтуы турында.

**Разил Вәлиев. «Мирас».** Повесть. Зур төзелеш җирлегендә авыл белән шәһәр, ата белән бала арасындагы мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе, тормышта үз урынының табу кыенлыклары турында.

**Җәвад Тәрҗеманов. «Онытырга мөмкин түгел».** Повесть. Сугышның кешеләргә үлем афәте генә түгел, рухи югалтулар да китерүе, гаилә язмышларын рәхимсез сүтеп ташлавы хакында.

**Газиз Кашапов. «Һәркемнең үз йолдызы».** Повесть. «Беткән» кешенең ничек итеп чын кеше дәрәҗәсендә күтәрелүе, дөреслек хисенең халыкта беркайчан да сүнмәве турында.

**Нәбирә Гыйматдинова. «Сихерче».** Повесть. Фаҗигадән соң яшь кызның кинәттән күрәзәчегә әйләнүе, табигатьнең ачылмый яткан яисә онытылган серләре хакында.

Укучыларыбызның әдәби мираска игътибары артуын исәпкә алып, соңгы вакытларда матбугатта үзе хакында кайнар бәхәсләр уяткан, иҗаты тапталган һәм макталган әдип Гаяз Исхакыйның проза әсәрләрен бирү дә күздә тотыла.

Күренекле шагыйрьләребез һәм шулай ук яшь язучылар иҗатына да киң урын биреләчәк.

Туган телне өйрәнүдән мәхрүм ителгән 5—10 яшьлек балаларыбызны, оныкларыбызны өй шартларында татар теленә өйрәтергә теләүчеләр өчен Ана теле дәресләре ачабыз. 1989 елның сентябреннән 1990 ның май-июнь айларына кадәр һәр санда ата-аналарга киңәшләр һәм практик кулланмалар бирелеп барылачак.


Ленинградта татар культурасы истәлекләре, төрле төбәкләргә, төрле илләргә сибелгән халкыбыз тарихыннан язмалар ел буена дәвамлы серия булып барачак. Журнал битләрендә сәнгатебезнең төрле якларына кагылган мәкаләләр, фәнни материаллар, истәлекләр, әхлак һәм табигатьне саклау, репрессияләнгән шәхесләр язмышына бәйле язмалар, үзгәртеп кору заманының үткен проблемаларын күтәргән очерклар урын алачак.

Күп санлы укучыларыбыз үтенечен искә алып, Коръәннең берничә сүрәсен, дөнья поэзиясе үрнәге буларак, татар теленә тәрҗемәләп бирәбез.

Гарәп әлифбасы нигезендә укырга-язарга өйрәнүне дәвам итү өчен язма үрнәкләр биреләчәк.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)